ISSN 0206-[illegible]189

# КАЗАН УТЛАРЫ

7. 1994





**3 июнь көнне Татарстан язучыларының XII корылтае булып узды. 250 ләп әдипне берләштергән бу оешманың идарәсе 1989—1994 елларда оештыру-иҗат эшчәнлеге турында корылтай алдында хисап тотты. Аерым жанрлар буенча доклад-чыгышлар тыңланды, фикер алышулар булды. Корылтайда, шулай ук, Язучылар берлеген үзгәртеп кору турында Декларация кабул ителде, яңа идарә составы сайланды. Корылтайда, язучылардан тыш, республикабыз җитәкчеләре, күрше төбәкләрдән килгән кунаклар, министрлык вәкилләре һәм журналистлар катнашты.**

*(Татарстан язучыларының XII корылтае турындагы материалларны журналыбызның киләсе санында укырсыз.)*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**7**

**(861)**

**1994**

КАЗАН


## *Бу санда*


ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Ә. ГАЛИЕВ. Һәр солдатның үз язмышы. *Документаль повесть* ..... 3
Р. ГАТАШ. Бер йолдызның нуры. *Шигырьләр* ..... 63
З. МАНСУРОВ. Татар бугазы. *Шигырьләр* ..... 71
И. ГЫЙЛӘҖЕВ. Кем икәнем торсын күренеп. *Шигырьләр* ..... 118

ӘДӘБИ МИРАС

С. МАКСУДИ. Мәгыйшәт. *Милли хикәя* ..... 78

ОСТАХАНӘ

Ф. ТАРХАНОВА. Хушлашу. *Шигырьләр* ..... 123

ПУБЛИЦИСТИКА

Ф. ЗЫЯТДИНОВ. Тоннельдән чыгар юл бармы? ..... 127

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. ХАТИПОВ. Тәнкыйть реализмы булганмы? ..... 135

ЖУРНАЛДА — ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ АНТОЛОГИЯСЕ

С. БАКЫРГАНИ. *Шигырьләр* ..... 140

МӘДӘНИ МИРАС

Ризаэтдин бине Фәхретдин хатлары ..... 142

ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

С. ПОВАРИСОВ. Энҗеләр кайда ята? ..... 150

НӘСЕЛ АГАЧЫ

С. ИМРЕ. Әтием ..... 156

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Л. ХӘМИДУЛЛИН. Гыйбрәтле шәҗәрәләр ..... 168
М. ӘХМӘТҖАНОВ. Һәр ялтыраган алтын түгел ..... 177
А. ДУБИН. Борынгы открыткаларда — Казан ..... 181

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 188

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрваз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән, хатлар — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать, тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: документальная повесть А. ГАЛИЕВА «У каждого солдата своя судьба»; стихи Р. ГАТАУЛЛИНА, З. МАНСУРОВА, И. ГИЛЯЗОВА, Ф. ТАРХАНОВОЙ.
«Литературное наследие»: рассказ С. МАКСУДИ.
«Публицистика»: статья Ф. ЗИЯТДИНОВА «Есть ли выход из тоннеля?» «Литературная критика»: статья Ф. ХАТИПОВА «Был ли критический реализм?»
«В журнале — антология татарской поэзии»: стихи С. БАКИРГАНИ.
«Культурное наследие»: письма Р. ФАХРУТДИНА.
«Острый ракурс»: статья С. ПОВАРИСОВА «Где находятся жемчуга»; воспоминания С. ИМРЫ о своем отце.
«К истории народа»: статьи Л. ХАМИДУЛЛИНА «Эхо далеких веков»; М. АХМЕТЗЯНОВА «Не все золото, что блестит»; А. ДУБИНА «Казань — на старинных открытках».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Переселение на север» — картина художника Р. Загидуллина; писатель Анас Галиев.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: the documentary narrative of A. Galiev «Each Soldier Has His Own Destiny»; the verses of R. Gataullin, Z. Mansurov, I. Gilyazov, Ph. Tarkhanova.
«Literary Heritage»: S. Maksudi's story.
«Publicism»: Ph. Ziyatdinov's article «Is There Any Way Out From the Tunnel?»
«Literary Critique»: Ph. Khatipov's article «Was There Critical Realism?»
«The Anthology of Tatar Poetry in The Magazine»: S. Bakirgani's verses.
«Cultural Heritage»: the letters of R. Phakhrutdinov.
«Keen Foreshortening»: S. Povarisov's article «Where Are the Dearls Situated?»; the reminiscenes of S. Amra about his father.
«To the History of Nation»: L. Khamidullin's article «Echo of the Distant Centuries»; articles of M. Akhmetzyanova «All is not Gold That Glitters», A. Dubin «Kazan on the Antique Cards».
«The Diary of the Social and Cultural Life».
In our corvers: R. Zagidullin's picture «The Migration to the Norths»; the writer Anas Galiev.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.
● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Марсель Галиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 2.06.94 ел. Басарга кул куелды 20.07.94 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 19,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 322. Заказ А-295. Бәясе 1100 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1994 ел.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Әнәс Галиев

#ҺӘР СОЛДАТНЫҢ ҮЗ ЯЗМЫШЫ

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

*(Икенче кисәк)*

*Кереш сүзем*

**Повестьның беренче кисәге «Казан утлары» журналының 1991 елгы 5 санында басылган иде. Анда Бөек Ватан сугышының беренче көненнән алып, кырык икенең сентябрь азагына кадәр, фронтның алгы сызыгында авторның башыннан үткән вакыйгалар тасвирлана. Сугышта катнашкан кеше яхшы белә: елдан артык бероэлексез алдагы сызыкта булып, исән калу бик сирәк солдатка насыйп булды.**

**Повестьның дәвамын язуны сорап миңа хатлар килде. Мин бу эшкә бик теләп тотындым....**

**Тарих шаһит: фашистларның баштанаяк көчле техника белән коралланган солдатларын Кызыл Армия коры кул белән каршы алды. 1941-42 елларда Көньяк фронтның мин булган юнәлешендә, безнең яктан сугышта ник бер самолет, ник бер танк катнашсын. Олы юллар һөҗүм итүче дошман кулында булды. Аның артыннан сугыша-сугыша, иген кыры өстеннән безнең полк чигенде. Бүгенге көн җәһәтеннән караганда ышанырлык та түгел: сугышка кергәндә безгә ике кешегә бер мылтык, утызар патрон тоттырдылар. Ил эченә чигендек. Авыр тупларны иңбашы белән этә-этә, Румын чикләреннән төньяк Кавказга кадәр чигендек. Берничә мәртәбә дошман тылында чолганышта калдык. Бирешмәдек, сугыштык.**

**Сталин һәм аның кайбер сәләтсез генераллары Кызыл Армияне дивизиясе-дивизиясе белән чолганышка илтеп тыкты. Сугышның беренче елында ук безнең миллионлаган сугышчы әсирлеккә эләкте. Күбесе яралы иде. Соңгыларының язмышына мин дә дучар булдым. Әсирлеккә эләккәндә миңа нибары 22 яшь иде. 1942 елның сентябреннән 1945 елның март азакларына кадәр, төрле концлагерьларда тәмуг газабына тиң авыр юл үтәргә туры килде. Качтым, тотылдым. Тагын качтым, тагын тотылдым. .. Америка армиясе азат иткәндә аякта басып торырлык та хәлем юк иде. Башта алар госпиталендә, аннан үзебезнең эвакогоспитальдә дәваланып, армиядән демобилизацияләндем.**

**Әсәрдә берниндн шомартулар юк. Барысын да ничек булган — шулай тәсвирларга тырыштым. Ул үзенең укучыларын табар дип ышанасы килә.**

**АВТОР.**

---

Әнәс ГАЛИЕВ (1920) — *язучы. Төрле елларда дөнья күргән шигырь, повесть һәм романнар авторы. Казанда яши.*

Безне, ун меңләгән әсирне, Армавир шәһәре янындагы кырда — ачык һавада җыеп тоталар. Күбебез яралы. Мин үземнең нинди хәлдә икәнемне һич төшенә алмыйм әле. Аяк-кулымны тотып карыйм, бар да исән кебек. Канга буялган җирем юк. Ләкин хәрәкәтләнергә көчем җитми, кыймылдауга, бөтен тәнем чәнчешә. Шулай да газаплана торгач, торып утырдым. Халык бары да утырып тора. Шул утырып торучылар өстеннән күземне йөртеп чыктым. Иге-чиге юк, бер чигеннән икенче чиге күренми.

Без утырып торган урын иңкү җир, тирә-яктан әрҗәләренә пулеметлар көйләнгән автомашиналар белән уратып алынган. Пулемет артында басып торучы солдатлар чебен дә очырмый, акыра-бакыра, тиктомалдан һавага аталар.

Минем хәлем авыр иде. Баш чатнап авырта. Маңгаемда зур шеш. Эчем януга чыдар әмәл юк. Телем аңкауга ябышкан. Бер генә минутка булса да тәнемнең сызлануын онытырга теләп, баштан узганнарны күз алдыма китерергә тырышып бактым....

Җиргә чүңкәйтеп утыртылган әсирләр шулкадәр күп, Советлар иленең бөтен сугышчысы шушында җыелган, үзебезнең якта берсе дә калмагандыр кебек. Хурлыгы ни тора, шушы кадәр халыкны әсир итеп тотсыннар әле!

«Зинген!» — дип акырган тавышка сискәнеп киттем. Лагерьга яхшы атка атланган Кызыл Армия командиры киемендәге бер кеше килеп керде. Аның гимнастерка җиңнәрендә кызыл йолдыз, петлицаларында ике шпал. Димәк, өлкән батальон комиссары... Ат койрыгына дилбегәгә бәйләп яшь кыз белән яшь егет тагылган. Артларыннан кулына камчы тоткан немец унтере килә. Ачы тавыш белән «зинген» дип кычкыручы шул унтер икән. Егет белән кызны ирексезләп җырлаталар. Бер минут та тынып торырга рөхсәт юк икән бичараларга. Безнең арага кергәч, тегеләр тынып калган иде, унтер камчысын уңлы-суллы биетә башлады. Егет белән кыз ашыгып өзә-өзә мәшһүр «Катюша»ны җырлыйлар. Аларның йөрәк өзгеч тавышы күңелнең иң нечкә кылларын сызландыра.

Атка атланган хәрби адәм лагерь уртасына килеп туктады да нидер такылдарга тотынды. Күршемдә утыручы, тешләрен кысып: «Сатлык җан, сволочь...» — дип ысылады. Комиссар нинди начар сүз бар, шуларны җиде катлап кабатлап, большевикларны һәм яһүдләрне сүкте, «Сезнең шушы хәлгә калуыгызга алар, фәкать алар гына гаепле,— диде.— Алар Россияне, рус халкын саттылар. Берсенә дә тузан кадәрле дә шәфкать күрсәтергә ярамый. Беләм, монда сезнең арагызда алар бик күп. Барысын да тотып бирегез. Каты җәзага тартабыз...

Мин, ирексездән, кесәмне капшап куйдым. Күкрәк кесәмдә комсомол билеты бар иде. Аңымны югалтып, дөньядан юк булып торганда шул билет белән берәр хәл булмады микән, дип шикләндем моңарчы. Мин һаман искечә уйлый идем әле, немец кулында тоткын булып утыруымны һич тә таныйсым, үз хәлем белән килешәсем килми иде. Дөресрәге, аңыма барып җитмәгән иде. Әгәр комсомол билеты югалса, нинди йөз белән иптәшләремә күренермен дип борчылдым. Бүгенге аң биеклегеннән карыйм да ул вакыттагы җүләрлегемә шаккатам!

Күземне ачып, аңыма килүемә шактый вакыт үтте. Сәгатьләр генә түгел, көннәр. Тик ничә көн икәнен генә белмим. Ашау турында сүз кузгаткан кеше юк. Эчәсе килү үзәккә үтә. Карыйм, күрәм: як-ягымда утыручы әсирләр флягаларын, биштәрләрен үзләреннән калдырмаганнар. Минем генә бер нәрсәм дә юк! Хәтта билемдәге каешымны да алганнар...

— Килделәр,— диде күршемдәге әсир кызылармеец. Минем нәрсә турында сүз барганлыгын аңламаганымны сизеп: — Машиналар килде,— дип өстәде, лагерь кырыена килеп туктаган әрҗәләренең өсте ябык машиналарга күрсәтеп.

— Бу техниканың монда нигә керәге бар икән?..
— Безне алырга килгәннәр.
Бу сүзләр яшен суккан кебек тәэсир итте. Минем моннан һич тә китәргә исәбем юк иде. Бераз хәл керү белән качарга ныклы план корып утыра идем. Якында гына башлары күккә тигән биек таулар. Шул таулар арасына кереп яшеренү җиңел булыр төсле тоела иде.
Машиналар лагерь эченә үк килеп керделәр. Әсирләрне көчләп шул машиналарга төяргә тотындылар. Күренеп тора, берсенең дә анда менеп утырырга исәбе юк... Кара сукнодан тегелгән хәрби форма кигән солдатлар, әсирләрнең кай җиренә туры килде, шунда приклад белән төндыралар. Соңыннан белдем: кара сукнодан тегелгән хәрби форманы СС дивизиясендә хезмәт итүче солдатларга кигертәләр икән.
Бер машина безнең төркем янына килеп туктады.
— Ауф! — дип акырды бер унтер офицер. Акырганны ишетәм, торып басарлык хәлем юк! Әгәр урынымнан кузгалырга көчем җитсә, хәзер һич сүзсез машинага менеп утырган булыр идем. Мин әле һаман балаларча хыялланып, акылсыз фикерләр тоткынлыгында яши идем. Янәсе, качарга форсат чыгарга тора: юлда барганда машинадан сикереп төшеп калырга җайлы булачак! Тот капчыгыңны! Менә ике әзмәвер яныма ук килеп басты. Аларны күреп бик гаҗәпкә калдым, өсләрендә кызылармеец киеме, гимнастерка якаларындагы петлицалары гына ертып алынган. Үзара урысча сөйләшәләр. Унтер офицер янымда басып торган әлеге ике кешегә нәрсәдер ымлады. Сизми дә калдым, алар мине күтәреп кузовка ыргыттылар. Башым бортка бәрелеп, чак кына аңымны югалтмадым. Күз алдым караңгыланып, шактый вакыт аяк-кулларымны кыймылдата алмадым. Кузовта энә төшәрлек тә урын юк иде. Бер таза әсир мине җайлап кабина кырыена китереп утыртты. Калганнар бер-берсенә тотынып, аягүрә бастылар.
Көн гадәттән тыш эссе иде. Кояш миләрне кайнатырлык итеп кыздыра. Ярый әле кузовның өсте ябык, югыйсә чыдар хәл булмас иде.
Менә безне алып та киттеләр. Кая алып баралар, белгән кеше юк. Машина соң дәрәҗәдә бара. Бераз юл киткәч, кузов өстенә капланган брезентның бер кырые һава агышына ачылып, тирә-юньне күзәтергә мөмкинлек туды. Әнә юл буенда абрикос агачлары үсеп утыра. Алар миңа бик таныш. Без чигенгәндә үк җимешләре өлгергән иде инде. Абрикосны чиләк тутырып җыйган чаклар булды. Шундый туклыклы җимеш абрикос, аны ашап туйгач, солдат кухнясында пешерелгән чилепешле ризыкны күрәсе дә килми.
Безнең полк, немец танклары белән сугыша-сугыша, шушы юллар буйлап чигенгән икән. Әнә бездән калган тупларны да җыймаганнар әле. Еракка ата торган 122 миллиметрлы гаубицалар мескен булып башларын түбән игәннәр. Аларны күрү бик авыр булды. Күзләремнән яшь чыкты.
Безне беркайда да туктатып тормыйлар. Станицаларны яшен тизлегендә узып китәбез. Урамда ир затыннан беркем дә күренми. Кайбер капка төбендә казачкалар басып тора. Немец машиналары күренү белән, алар да ашык-пошык ишегалдына кереп югалалар.
Менә Куропаткин станицасына килеп кердек. Сугыштан соң аны шәһәр дип атап йөртә башладылар. Әйе, ул матур итеп салынган ике-өч катлы йортлары, төзек, озын урамнары белән юклы-барлы шәһәрләрдән яхшырак. Мин анда февраль аенда, фронттан Краснодарга командировкага барганда булган идем. Тәүлектән артык тукталып тордык. Шуңа күрә бу станица миңа яхшы таныш иде.
Бәхеткә каршы булса кирәк, станицага килеп керү белән, без утырган машина йөрешен әкренәйтте. Шуннан файдаланып яшь бер хатын кузовка ике бөтен яңа гына мичтән чыккан бодай икмәге ыргытты. Шул казачканы күрептерме, озата баручы немец солдатлары, тәртипсез

рәвештә автоматтан атарга тотынды. Мескен хатын исән калгандырмы, юкмы — күрергә өлгермәдем. Машинада утырып барган әсирләр өчен дөньяда шушы безгә икмәк ыргыткан хатыннан да изге, аннан да батыр кешенең булуы мөмкин түгел төсле иде. Алай-болай фашистлар килеп алмасын дип, икмәкне бераз вакыт яшереп тоттылар. Станицаны чыгып шактый ерак киткәч, бөтен әсирләргә тигез итеп икмәкне бүлделәр. Бер кабарлыгы миңа да эләкте. Ачыгу чиктән ашкан иде. Озаклап чәйнәргә түземлегем җитмәде, йотып җибәрдем.

Машиналар бертуктаусыз алга ыргылды. Таныш юллар белән барабыз, таныш станицаларны үтеп китәбез. Менә Павловка станицасы. И, күптәнме әле без анда төн кунып калган идек. Мин ымсынып-ымсынып урамны күзәттем. Анда тыз-быз чабып йөрүче хатын-кызлар арасыннан үзебез төн кунып чыккан йорт хуҗасы Анфисаны эзләдем. Дөрес, без алар урамына кермәдек. Ничектер, ул миңа кая да булса безне күзәтеп басып торадыр төсле булып тоелды. Шул без аларда кунган көнне Анфисаның сержант Башкиров белән анадан тума чишенеп йоклап ятуы күз алдыма килеп елмаеп куйдым. Бар кыю ирләр!

Павловка станицасыннан Ростовка таш җәелгән туры юл сузылган. Хәтерем алдамаса, ераклыгы ике йөз чакрым чамасы. Ул елларда асфальт җәелгән юллар юк дәрәҗәсендә, таш җәелгәннәре дә сирәк иде.

Бара торгач, алда Дон елгасы буендагы Ростов шәһәре күренде. Димәк, безне Батайский күпере аша Донның теге ягына алып чыгачаклар. Бу тирәдә Дон аркылы чыгарга башка күпер юк. Шулай ук безнекеләр чигенгәндә ул күперне җимертмәделәр микәнни, дип авыр сулап куйдым. Әллә җимерелгән күперне төзәтеп тә өлгергәннәрме?..

Машинадагы халык бар да тирән уйда кебек күренәләр иде. Алар да минем кебек үзләренең әсир төшүләрен башларына сыйдыра алмыйлардыр, күрәсең.

Без барып кергәндә, Батайский шәһәренең урамнары тып-тын иде. Беркайда җан иясе күренми. Монда сугышлар каты булган. Йортлар кварталы-кварталы белән җимерек. Кайбер урында урам аша чыга торган түгел, бомба төшеп ярылудан тирән чокырлар барлыкка килгән. Дон елгасын вакытлыча эшләнгән күпер аша кичтек.

Ростов шәһәре дә бик нык җимертелгән иде. Шәһәрнең үзәге — Энгельс урамы белән бераз баргач, без утырган машиналар сулга борылып, Азов диңгезе ярына килеп чыкты.

Бәрелешләр бу тирәләрдә дә каты булган. Безнекеләр чигенгәндә бер карыш җирне дә сугышсыз калдырып китмәгәннәр. Юл буенда исәпсез-хисапсыз ватык машиналар, төрле калибрдагы туплар аунап ята. Сирәк-сирәк танклар да күренгәли. Шунысы кызганыч, барысы да дип әйтерлек безнеке...

Бара торгач, алда, калку җирдә шәһәр күренде. Таганрог диделәр. Хәтта, уң як борт кырыенда чүнкәйгән бер әсир шушы шәһәр кешесе булып чыкты. Ул шәһәр урамына килеп керү белән, анда йөрүче кешеләргә мөрәҗәгать итеп: «Мин шушы кала кешесе Иван Бурда булам. Әти-әнием Маркс урамында, унөченче йортта яшиләр, зинһар, хәбәр итегез!» — дип кычкырырга тотынды. Урамдагы халык аның үтенечен ишеткәндерме, юктырмы, белмим, озата баручы немец солдатларына бу хәл ошамады, автоматтан һавага ата башладылар.

Ниһаять, безнең машина тирә-ягы чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынган урынга килеп туктады. Лагерь. Әсирләр лагере. Ул ачык җирдә. Кырмыска оясы кебек мыжлап тора. Димәк, безгә шушы лагерьда яшәргә туры киләчәк. Озакмы?

Капкадан кереп, йөз метр чамасы җир үтешкә машинадан төшәргә әмер булды. Мин дә бортка тотынып, көч-хәл белән аягыма бастым. Ләкин машинадан төшәрлек хәлем юк иде. Кырыйда басып торучы ике әсир мине күтәреп төшерделәр. Күз алдым караңгыланып, бер читкә

тайпылдым да лып итем җиргә утырдым. Кемнеңдер исемем белән эндәшкәнен ишетеп, артыма борылып карадым. Анда минем белән бергә топовзводта хезмәт иткән Найденов басып тора. Ул безнең штаб батареясының комсомол комитеты секретаре иде. Найденов белән якыннан аралашырга туры килмәде, шуңадырмы, исемен хәтерләмим, фамилиясе генә истә калган. Ул үзен бик эре тота, зур укымышлы кеше итеп күрсәтергә тырыша, вак кына мәсьәләләрдә беркемгә дә сүзен бирми, бәхәскә керешә. Күреп торам, хәзер бөтенләй үзгәргән, песи булып калган.

Найденов яныма килеп чүнкәйде дә:

— Нихәл, яралымы? — дип сорады.

Мин җавап бирмәгәч, аптырап карап торды да кулын маңгаема куйды: «Башың ут кебек, температураң бар ахры»,— диде. Чыннан да, минем бөтен җирем ут кебек яна иде. Аның бил каешына беркетелгән флягасын күреп:

— Суың юкмы? — дип сорадым.

— Нәрсә, эчәсең киләме?

Ул тел белән әйткәнгә генә ышанмас дип уйлады, ахры, флягасының бөкесен алып, авызын түбәнгә таба әйләндереп күрсәтте.

Найденовның минем янда басып торганын күреп булса кирәк, шунда тагын безнең бер полкташ пәйда булды. Ул отделение командиры сержант Привалов иде. Алар якташлар. Авыллары Кировоград тирәсендә. Приваловны күрү белән шуңа игътибар иттем, ул петлицасындагы хәрби дәрәҗәсен ачыклаучы кызыл лак белән катырылган тимер өчпочмакларны алып ыргыткан иде. Найденов аңа:

— Әгәр суың булса, Әнәскә берәр йотым бир,— диде.

Ул теләмичә генә, йөзен чытып, миңа флягадан бер йотым су эчертте.

— Әнәс үзе теләп фашистларга әсир төшкән дигәч, ышанмаган идем, әнә ул нинди хәлдә,— диде Привалов.

Аның сүзләре йөрәгемә хәнҗәр булып кадалды:

— Кем шундый гайбәт тарата,— дип сорадым.

— Синең белән бергә разведкага барган Среда комиссарга шулай дип рапорт язган.— Әгәр мин: «Качыгыз! Фашистлар!» — дип кычкырмаган булсам, Среда үзе дә килеп эләгә иде бит. Мин үземнең урысча сөйләшкәнгә алданып фашистларга ничек-ничек килеп эләгүемне сөйләп бирдем.

— Намуссыз кеше икән ул Среда,— дидем, ачуымны белдерергә бүтән сүз тапмадым.

— Борчылма,— диде Найденов,— яхшы атлы булырга теләсә дә, әллә кая ерак китә алмады, Среда да монда, безнең белән бер лагерьда...

Иптәшләрнең сөйләүләренә караганда, безнең армия тар-мар ителгән. Нинди дер эш белән армия штабына килгән маршал Буденный чак чыгып ычкынган икән. Чолганышта калгач, аны «кукурузник» белән алып киткәннәр. Полк командиры майор Киселев үз-үзен атып үтергән.

— Дөрес эшләгән,— диде Привалов.— Әгәр исән калса, аны коточкыч җәза көтә иде. Ни өчен немец яһүдләрне кан дошманы итеп саный торгандыр. Хәтта балаларын да атып үтерә...

Макс Соломонович милләте буенча яһүд иде. Гражданнар сугышында катнашкан. Курку белми торган батыр кеше. Немецлар бик еш аның башын китергән кешегә зур бүләкләр вәгъдә итеп листовкалар ташлый торганнар иде. Сугышның беренче көненнән алып, әсир калганчы миңа аның белән бергә булырга туры килде.

Найденов, минем хәлемнең авырлыгын аңлап булса кирәк, шинелен җиргә җәйде дә ятып торырга кушты. Аннан, иңбашына аскан биштәрләрен салып, минем баш очына куйдылар да: «Без лагерьны әйләнеп килик әле, тагын полкташларны очратмабыз микән»,— дип китеп бардылар.

Лагерь эче гөжләп тора. Минем янга тагын бер әсир килеп басты. «Сатлык паек юкмы?» — дип сорады. Аның сүзләреннән бернәрсә аңламый аптырап калдым. Минем әле паек дигән әйберне күргәнем дә юк иде. Күңелемдә шик туды. Иптәшләрем калдырган биштәрләрне баш астына салдым.

Сөйләшә торгач, бар да аңлашылды тагын. Монда элегрәк китерелгән әсирләргә, көненә йөз грамм чамасы пычкы чүбе кушып пешерелгән икмәк бирәләр икән. Әсирләр арасында кызу сәүдә бара. Тәмәке төпчеге, чакматаш һәм башка шундый вак-төяк әйберләр белән алыш-биреш итәләр. Шырпы булмаганлыктан, тәмәкегә утны чакма чагып кабызалар. Акча бирәмлеге булып арада шул паекка бирелгән йөз грамм чамасы икмәк йөри икән. Шунысын да әйтергә кирәк, тәмәке төпчегенең бәһасе икмәккә караганда кыйммәтрәк иде.

Найденов белән Привалов минем янга бүтән килмәделәр. Көтеп-көтеп тә күренмәгәч, мин аларны качтылар дип уйладым. Әгәр сәламәт булсам, мин дә алардан калмас идем, дип уфтандым. Беләм, турыдан-туры койма аша качу мөмкин түгел. Лагерьны әйләндереп алган чәнечкеле тимерчыбык ике катлы. Арасына сакчы этләр җибәрелгән. Билгеле бер ара саен пулеметлар белән сакта торалар... Таза әсирләрне шәһәргә алып чыгып, немец офицерларының хуҗалык эшләренә йөртәләр. Икенче көнне дә күренмәгәч, Привалов белән Найденов шундый командага эләгү бәхетенә ирешмәделәр микән дип уйладым.

Беркөнне кичкырын минем үземне дә лагерьдан алып киттеләр. Безне, ягъни аралы, авыру әсирләрне аерып алып, зур машинага төяделәр. Ярый әле ерак алып китмәделәр, югыйсә эш харап иде. Вокзалга гына алып бардылар. Шул якын арада да берничә әсир дөнья белән хушлашырга өлгерде. Яралы әсирләр чебен кебек үлә торды...

Вокзалда безне вагоннарга дыңгычлап тутырдылар. Аягүрә басып, бер-береңә тотынып кына торырга мөмкин иде. Мин чыдый алмадым, баскан урынымда түндем. Як-ягымдагы әсирләр мәрхәмәтле булып чыктылар. Мөмкин кадәр минем өскә басмаска, кысрыкламаска тырыштылар.

Юлда озак бармадык, биш-алты сәгать узгандырмы, поезд зур бер шәһәргә килеп туктады. Бу миңа таныш шәһәр — Сталино иде. Кырык беренче елны чигенгәндә, безгә монда шактый озак тукталып торырга туры килде. Шул вакытта мин аның бөтен урамнарын айкадым. Полк белән армия штабы арасында элемтәче хезмәтен үтәдем.

Килеп туктау белән паровозны өзеп, каядыр алып киттеләр китүен. Ләкин халыкны вагоннардан бушатырга ашыкмадылар. Күпчелек кысталып, хаҗәтләрен шул баскан урынында үти башлады. Вагон эчендәге сасылыкка чыдар хәл калмады. Башка вагоннарда да шундый хәл булса кирәк, андагы шау-шуны ишетеп, безнекеләр дә, кем ничек булдыра ала, шулай вагон стенасын дөмбәсләргә тотынды. Якында гына автоматтан аткан тавыш яңгырады. Ниһаять, зарыгып көтә торгач, морадыбызга ирештек. Вагон ишеген ачып: «Раус, шнелль, шнелль, швайне!» — дип акырдылар. Хәллерәкләр вагоннан чыгып китте, әлбәттә. Без берничә кеше вагон эчендә утырып калдык. Немец солдатлары акырдылар, акырдылар да, без урыныбыздан кузгалмагач, рәхимсез рәвештә өстерәп төшерергә тотындылар. Мин дә атылып җиргә барып төштем һәм чак кына аңымны югалтмадым. Ярый әле полкташларым Найденов белән Привалов калдырган шинельне өстемә киеп, биштәрләрен иңемә асып өлгергән идем. Югыйсә алар вагон эчендә калачаклар иде. Миңа ышанып калдырган әйберләрен югалтсам, бу иптәшләрне кабат очраткан тәкъдирдә, аларга нинди йөз белән күренермен дип борчылдым.

Тырышып-тырмашып аякларыма бастым. Күз алдым караңгыланып күпме басып торганмындыр, хәтерләмим. Үзем кебек ике әсир ике култыгымнан тотып алгач, хәл кереп киткән төсле булды. Алар мине

житәкләп читкәрәк алып киттеләр. Анда безне тагын машиналар көтеп тора иде. Әлеге ике ягымнан култыклап алып килгән иптәшләрем, мине җайлап кына күтәреп, шул машиналарның берсенә менгерделәр. Үзләре дә минем яныма менеп бастылар. Ул арада машинабыз урыныннан да кузгалды. Машинага утырырга хәле булмаган яралы әсирләр шунда — җирдә аунап калдылар. Әгәр шушы рәхимле ике бәндә очрамаса, мин дә шулар янында утырып калган булыр идем. Ә аларны алда нинди язмыш көткәнен бер Алла гына белә. Хәлбуки, немецлар авыр хәлдәге әсирләр белән озак мәшәкатьләнергә яратмыйлар иде.

Озак бармадык, мәһабәт бер бина янына килеп туктадык. Бу бина шахтерларның мәдәният сарае икән. Хәзер аның тирә-ягын чәнечкеле тимер чыбык белән урап алганнар да әсирләр лагерена әйләндергәннәр. Шушы галәмәтне күргәч, немецлар бөтен дөньяны чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алганнардыр кебек тоелды, өметсезлек артты.

Машинаны ишегалды уртасындагы сулы бассейн янына китереп туктатып, төшәргә боердылар. Әсирләрне чишендереп, шул бассейн аша йөздереп чыгаралар. Бассейнга керергә теләмәгәннәрне төртеп төшерәләр. Бассейнның суы тирән түгел икән, югыйсә минем йөзәрлек хәлем юк иде, адымлап аркылы чыктым. Икенче якка чыгу белән безгә шуны аңлаттылар, имеш, монда карантинный лагерь, бассейн аша йөздереп, агу сибелгән суда йогышлы авырулардан котылу өчен дезинфекция ясала!

Безнең веребезгә дә бассейнның теге ягында калдырган үз киемнәребезне бирмәделәр. Гитлер яулап алган Көнбатыш Европа илләреннән таланган, иске-москы солдат киеме киерттеләр. Миңа ямаулы яшел френч, шундый ук төстәге чалбар эләкте. Сөйләүләренә караганда, бу киемнәр Бельгия солдатларыннан салдырып алынган. Бер әсир: «Бездән салдырган киемнәрне кемнәргә киертәләр икән?» — дип офтанып куйды. Иң яманы аякка киерткән агач башмаклар булды. Туып-үсеп, мондый аяк киеме күргәнем юк иде. Алар аякка шундый җайсыз ки, атларга ирек бирмиләр. Агач башмакны киеп маташканда, салып калдырган чалбар бөрмәсенә яшерелгән комсомол билеты исемә төшеп, эчем жуу итте. Нишләргә? Ымсынып-ымсынып бассейнның аргы ягын күзәттем. Хәтта кире шул якка чыгарга да талпынып куйдым. Мин бит әле үземне һаман яшьләр оешмасы сафында итеп хис итә идем. Шулай ук комсомол билетыннан аерылырга туры килер микәнни? Мин бит аңа чиксез зур кыенлыклар белән ирешкән идем. Күпме вакыт социаль чыгышымны сәбәп итеп, мине комсомолга алмый тилмерттеләр. Моннан соң инде миңа бер вакытта да комсомол сафына басарга туры киләчәк түгел!

Булган шыр тиле чаклар, без ул заманның яшьләре барыбыз да дип әйтерлек чын күңелдән шулай уйлый идек. Ахмаклык белән агулану чамадан ашкан иде. Дөресен әйткәндә, акыл ягы да «ташка үлчим» булгандыр, күрәсең. Әгәр төпле акылым булса, мин комсомол билеты турында уйлап баш ватып торыр идемме соң? Бүгенге биеклектән караганда гына шулай уйлавымны искәртеп үтүне дә кирәк саныйм... Әллә, салкын суы тәэсир итте, мин башкалар белән бергә басып торырлык хәлгә килдем. Унар-унар кеше санап алдылар да ишегалды түрендәге агач кисмәкләр янына алып киттеләр. Һәр кисмәк янында кулына озын саплы чүмеч тоткан полицай басып тора. Ул әсир кулына калай җамаяк тоттыра да, чүмеч белән кисмәктән, ниндидер сыекча алып сала. Әсирләр телендә бу сыекча баланда дип атала икән. Җамаякны ике кулым белән күкрәгемә кысып тотып, бер кырыйга барып утырдым. Минем ничә көн инде авызыма бер тәгам капканым юк иде. Җамаяктагы сасы сыекчага күзем төшкәч кенә карыным чиктән тыш ачканлыкны сиздем. Баланда бик сыек иде. Анда берничә бөртек ярма, һәм бер бәрәңге кисәге йөзеп йөри. Җамаякны күтәреп бер-ике генә йоттым.

Янымда утырган битен куе кара сакал баскан әсир: «Ничек соң, туйдыңмы?» — дип сорады. Минем җавабымны көтеп тормады, сүзен дәвам итте: — Немец әсирләргә бөтенләй ашарга бирми дип сөйлиләр иде. Ничек болай халыкны баландадан авыз иттерергә уйлагандыр, болай булса, әле бөтенләй өметне өзәргә ярамый».

Аның сүзләре бер колагымнан кереп, икенчесеннән чыкты, үз хәлем хәл иде. Карыным шулкадәр ачты, ашыйсым килеп саташыр дәрәҗәгә җиттем. Ичмаса тәмәке дә юк. Күкрәк тутырып тәтен суырсам, ашау турында онытып торыр идем төсле тоелды. Ләкин тәмәке кытлыгы икмәккә караганда да көчлерәк иде. Аны беркайдан да табу мөмкин түгел. Чыдар хәлем калмагач, янымдагы немец биргән паекка канәгатьлеген белдереп утырган сакаллы әсиргә мөрәҗәгать иттем: «Тәмәкең юкмы, әгәр тартсаң, миңа да бер-ике суыртыр идең»,— дидем. Ул серле итеп, күзләрен текәп карап торды да: «Мин тәмәке тартмыйм, сиңа да ташларга киңәш итәм»,— диде. Сүзләренә минем игътибар итмәгәнне сизеп: «Син әле бик яшь, үләргә ашыкма...— дип сүзен дәвам итте.— Аннан кире кайтып булса икән, теге дөньядан дим...» Бу сүзләрнең хаклыгын лагерь тормышы бик тиз исбат итте. Тәмәке тартучылар чебен кебек кырылалар иде. Тартучы әсир, бүлгәч, кулына эләккән икмәкне ашыга-ашыга тәмәке төпчегенә алмаштыра. Шулай итеп, ул үзенең ашказанын кәгазь калынлыгы шушы ризыктан да мәхрүм итә. Өстәвенә ачлыктан зәгыйфьләнгән әгъзаларын никотин йотып агулый. Сакаллы әсирнең бик вакытлы биргән акыллы киңәше мине дөрес юлга бастырды. Ул кеше бәлки күптән дөнья куйгандыр инде, минем аны бервакытта да догадан ташлаганым юк. Мең-мең рәхмәт аңа, урыны оҗмахта булсын.

Лагерьга бертуктаусыз әсирләр агылып тора. Аларны да безнең кебек бассейндагы салкын суда чумдырып, өс киемнәрен алмаштыралар. Яралыларга бернинди ярдәм күрсәтелми, хәтта күбесенең җәрәхәтләре дә бәйләнмәгән. Ярага инфекция эләгеп, һәлак булучыларның исәбе-хисабы юк. Беркөнне бер төркем әсирләрне машина белән китереп мәдәният сарае ишеге төбенә бушаттылар. Полицайлар алар белән кызыксынучыларны акырып-бакырып, мәдәният сарае тирәсеннән читкә — ераккарак кудылар. Ул арада кешедән бушап калган мәйданда шартлау тавышы яңгырады. Соңыннан сөйләүләренә караганда, бер кызылармеецның уң кул башына кечкенә калибрлы мина эләгеп, шартламыйча терәлеп калган булган. Бу хәлгә немецлардан игътибар итүче булмаган. Ул мескен күпме вакыт шул минаны үзе белән йөрткәндер, ул турыда белмәдек. Шушы лагерьга китергәч, әсирлеккә төшкән совет хәрби врачы, аны мәдәният сараеның икенче катына алып менеп операция ясаган. Ул яралы әсир кулбашыннан тартып алынган минаны тәрәзәдән ишегалдына ыргыткан. Безгә шул тавыш ишетелгән икән.

Минем күңел читтән тыш төшенке иде. Хәтта үземнең исән калуыма үкенеп куйдым. Үз-үземне юатырга теләп микән, шигырь чыгарырга тотындым.

Ни булды сиңа, кояш? —
Элек син нурлы идең.
Ник сипмисең җиргә нурың,
Нигә соң кара көйдең?

Яшәрә иде киң кырлар
Синең нурларың белән,
Яши идек гөрләшеп без
Шатлык җырлары белән.

Сөя идек чәчәкләрне,
Чәчәкләр безне сөйде.
Әйтегезче, озаккамы
Җир өсте кара көйде?!

Инглизләрнең ашау теләге табынга утыргач туа, дигән тапкыр сүзләре бар икән. Бу очракта минем белән дә шулайрак килеп чыкты. Мавыгып китеп, мин тагын берничә шигырь чыгардым. Кәгазем дә, карандашым да юк иде. Бераз алгарак китеп булса да әйтеп үтим, мин бу шигырьләрне кырык өченче елның язында, Польшада Демблин крепостенда гына кәгазьгә төшерә алдым. Төп нөсхәләре әле дә исән.

Беркөнне ишегалды уртасына зур өстәл чыгарып куйдылар. Аның янына башына иләмсез зур картуз кигән фельдфебель белән беләкләренә ак тасма бәйләгән ике әсир чыгып басты. Фельдфебель, кулындагы букчадан зур кенәгә чыгарып, өстәл өстенә куйды да урындыкка утырды.

Әсирләрне берәм-берәм өстәл янына чакырып, сорау алу башланды. Чират миңа да җитте. Полицайларның берсе тылмач хезмәтен үти. Ватып-җимереп немесчә сукалый. Фельдфебель һәрбер әсирнең исем-фамилиясен, туган елын, адресын, нинди частьтә хезмәт итүен сорашып, кенәгәсенә теркәп бара. Мин һәрбер сорауга дөресен әйтеп җавап бирдем. Соңыннан белдем, күпчелек әсирләр алдашканнар икән. Хәтта исем-фамилияләрен дә үзгәртеп яздырганнар.

Сугышка кадәр көндәлек матбугатта, журналларда хәрби темага багышланган, эчтәлеге белән бер-берсенә ике тамчы су кебек охшашлы хикәяләр, шигырьләр бик еш басыла иде. Ил сакчылары тормышын сурәтләп язган әсәрләрнең барысында да дип әйтерлек дошман кулына эләккән Совет сугышчысы үзен ничек кенә җәзаламасыннар, бервакытта да нинди частьтә хезмәт иткәнлеген, командирларының исем-фамилияләрен әйтми. Бу хәл әдәби әсәрдә тиңе күрелмәгән батырлык итеп бәяләнеп, үлгәннән соң аның орден белән бүләкләнүе турында хәбәр ителә. Хәтерем алдамаса, ул елларда әле герой исеме бирү белән бик мавыкмыйлар иде кебек. Ленин ордены иң югары бүләктән санала иде. Без, шушы әсәрләрне укып бозылган бала-чага, китап сүзенә чын күңелдән ышана һәм андагы батырларга охшарга тырыша идек. Мин үземнең кайсы полктан булуымны әйттем-әйтүен, ә соңыннан үкенеп бетә алмадым....

Сорауларга җавап биреп бетергәч, аркама ак буяу белән зур итеп номер суктылар. Шул көннән башлап, андый-мондый кирәгем чыкса, мине исем-фамилиям белән түгел, шул номер белән эндәшеп, чакырып ала торган булдылар.

Әкренләп бөтен сәер хәлләргә дә күнегелә. Ә менә ачлыкка күнегү мөмкин түгел икән. Ачлык көннән-көн ныграк үзен сиздерә башлады. Яшь организм бернәрсә белән дә исәпләшмичә ризык таләп итә. Өстәвенә, котырынып тәмәке тартасы килә. Минем янга керпе инәләре кебек тырпаеп торган сакал-мыеклы бер әсир килеп басты. Миңа аның куллары шүрәлеләрнеке төсле булып күренде. Ул иңенә кырык ямаулы иске капчык аскан. Сүз башлап: «Берәр сатлык әйберең юкмы?» — дип сорады. Ачуым чыгып: «Йөрмә әле монда эч пошырып,— дидем.— Бетемне сатсам гына инде...» «Бөтен тәнне бет басты. Култык астыннан, бот араларыннан бетне учлап алырга мөмкин. Әлеге әсирнең минем яннан китәргә исәбе юк иде. Ул минем өстемдәге күлмәккә төртеп күрсәтте. «Һе, мондый акыл иясен очратканым юк иде әле, бик ансат кына мине ялангач калдырырга телисеңме?». Ул куен кесәсеннән тәмәке төпчеге чыгарды. «Менә моны рәхәтләнеп бер суыруы ни тора». «Икмәк булса, тагын бер хәл иде. Кит моннан, йөрмә сасы тәмәкең белән кеше алдап». «Ике исәп, бер хисап, аларның бер бәһадә йөргәнен әллә белмисеңме?». Никадәр генә тәмәке тартасым килсә дә, мин аның тәкъдименнән кире кактым. Ул артык сүз озайтып тормады, мине кызыктыруның башка ысулын тапты. Тәмәке төпчеген авызына капты да, кесәсеннән чакма таш чыгарып, чүпрәккә өрергә тотынды. Аның кыланышын читтән күзәтеп торган таза гәүдәле бер әсир безнең арага килеп басты һәм әлеге мине котырткан кешене әрләргә тотынды: «Син, хәшәрәт, ычкын моннан тизрәк! — диде

катгый итеп.— Тапкансың кемне үчекләргә. Күреп торасың бит аның нинди хәлдә икәнен». Ул аны тәрткәләп минем яннан куа башлады. Теге карулашырга тотынган иде, арт ягына типте. Һәм теге бәндә атылып-бәрелеп бер кырыйга барып төште. «Аякка басарлык хәлең бармы? — дип сорады яклаучым миңа мөрәҗәгать итеп.— Әнә анда көнлек паекны бирәләр, әйдә бергәләп барып алабыз». Ул мине җитәкләп, ишегалды уртасындагы кисмәк янына алып китте. Анда арыш онына нәрсәдер кушып пешерелгән, катып беткән икмәк бирәләр иде. Ун кешегә бер ипи. Паек алган әсирләрне ишегалдының икенче ягына күчерәләр. Бер тоткын качып калып, икенче кат чиратка килеп баскан. Аны бер полицай тартып чыгарып, рәхимсез рәвештә дөмбәсләргә тотынды.

Без ун кеше, кулыбызга икмәк эләккәч, бу тирәдәнераграк китәргә тырыштык. Икмәкне ничек итеп тигезләп бүләргә дип аптырап калдык. Арадан беребез, капчыгыннан үзе эшләгән үлчәү көянтәсе чыгарды. Аннан иске чалгыдан эшләнгән пәке белән икмәкне ун кисәккә бүлде дә, көянтәне ике ягына җеп белән бәйләп кисәкләрнең тигезлеген үлчәргә тотынды. Шулай итеп, кәгазь калынлыгындагы ун кисәкнең тигезлеген тикшереп чыкты. Ул икмәк үлчәргә тәмам остарып киткән иде, күрәсең. Арадан берәү аның осталыгына сокланып: «Әптиктә дә бу кадәр төгәл үлчи алмаслар иде»,— дип куйды.

Лагерьда кәгазьгә дә кытлык. Тәмәке төрергә кәгазь таба алмый интегәләр иде. Мин шигырьләремне күңелдә бикләп калырга тырышам. Шулай да берәр кәгазь кисәге кулга төшкәндә вак хәрефләр белән язып та куя идем. Икмәк бүлгәндә бер әсирнең кулында шактый зур картон күрдем. Аны ул бушка бирәчәк түгел, әлбәттә. Картон хуҗасы минем уемны сизде булса кирәк: «Бик өмсенеп карап торасың, сатам, ал»,— диде. Мин аңа нинди җавап бирергә дип аптырап калдым. Ул капчыгыннан тагын бер кисәк картон чыгарды. «Икесенә бер паек икмәк»,— дип, картоннарны миңа сузды. Сүзгә бая мине сатып алырга маташкан спекулянтны куып җибәргән сакаллы әсир кушылды: «Син оят дигән нәрсәне беләсеңме? Әллә андый сүзне бөтенләй ишеткәнең юкмы?». Сорауны ошатмаган картон хуҗасы әрепләшергә тотынды. «Алмасын, мин аңа товарымны ирексездән бирмим ич». «Менә болай эшлибез,— диде сакаллы, картонны хуҗасы кулыннан тартып алып, вак кисәкләргә бүлгәләде һәм җилгә очырды.— Башка мондый юк-бар әйбер белән сату итеп, кеше алдап йөрисе булма». Картон хуҗасы иң начар сүзләр белән сүгенергә, янарга тотынды. «Борыныңнан кыссаң, җаның чыгарга тора. Әле син янап маташасыңмы?!» Алар үзара чәкәләшүдән чак кына тыелып калдылар.

Мин бер читкә китеп утырдым. Күңелдә өметсез шигырь юллары туды.

Саргайды гөл, койды ал чәчәген,
Күзге көн килеп җитәр-җитмәс.
Горур башымны идем тормышка,
Алтын яшьлегем үтәр-үтмәс.

Ерак илтеп атты тормыш дулкыннары,
Алтын яшьлегем яфрак күк саргая.
Канаты сынган коштай сизәм үземне,
Иң матур көннәрем үтә заяга.

Чәнечкеле тимер чыбык арасыннан
Ымсынып-ымсынып карыйм да күккә,
Кычкырам тилмереп: «Әйтегез, кем белә
Чыгармын микән бервакыт ирекка?!»

Ул да түгел, нигә әле болай өметсезлеккә биреләм соң, дип, үз-үземне әрләргә тотындым. Чыдарга, чыдарга. Барлык кыенлыкларны җиңеп

чыгарга тиеш мин. Үләргә бервакытта да соң түгел. Теге дөньядан кире кайтып булса икән... Бөек Гетенең: «Кем көн дә көрәшчеләр сафына баса, шул кеше генә яшәргә хаклы» дигән шигъри юллары исемә төште. Оригиналда ул, бәлки, башкачарактыр. Ә минем күңелдә шушы мәгънәдә сеңеп калган.

Мин шулай уйланып утырганда: «Абтретен!» ягъни, сафка басарга дигән команда яңгырады. Әллә шул кәгазь калынлыгы ипи кисәге хәл кертеп җибәрде инде, торып аякка басканымны сизми дә калдым. Бер чулак унтер ун кешене санап алып, капкага таба алып китте. Шулар арасына мин дә эләктем. Урамга чыккач, сулышым иркенәеп киткән төсле булды. Анда, тротуарда, безне күзәтеп торучы халыкның исәбе-хисабы юк иде. Барысы да дип әйтерлек хатын-кызлар. Немец солдатлары автомат түтәсе белән этқәләп, куып карыйлар, һич тә җиңә алмыйлар. Безне сафка тезелгән килеш каядыр алып киттеләр. Тротуардагы халык та безгә иярде. Алар ашык-пошык безгә төрле ашамлык ыргытырга тотындылар. Җитезрәк әсирләр икмәк һәм дуңгыз мае эләктерде. Мин дә бер тозлы кыяр һәм ике кукуруз чәкәнен кулга төшердем. Өлешемә тигән көмешемә риза булып, күңелем күтәрелеп китте. Мондый хәл озакка сузылмады. Ачыргаланып кычкырган бала тавышы кәефемне җибәрде. Миннән ерак түгел сафлар арасында сары чәчле, җиде-сигез яшьлек бер кыз бала боҗыр кебек йөгереп йөри. Сакчы немец, куып җитә алмагач, мылтыктан атты. Белмим, пуля балага тигәндерме, юктырмы, бер хатын баланы күтәреп каршыдагы ишегалдына алып кереп китте. Шулай ыгы-зыгы килә торгач, тимер юл вокзалына барып җиткәнебезне сизми дә калдык. Анда безне товар вагоннарына төяделәр. Әсирләрне вагоннарга дыңгычлап тутырдылар. Төне буе юлда булдык. Поезд туктый-туктый бик әкрен барды. Сәбәбе: юлны рәткә салып өлгермәгәннәр иде әле.

Ташбака адымы белән үрмәли торгач, иртә белән Горловка шәһәренә килеп туктадык. Кырык бернең көзендә, Зопорожьедан чигенгәндә безнең полк бу шәһәр аркылы да узып киткән иде. Донбассның бу тирәләрен шәһәрләр оясы дип әйтергә була. Шулкадәр еш урнашканнар, берсе белән икенчесе тоташып беткән диярлек.

Поездның моннан кузгалырга исәбе юк иде, ахрысы. Паровозны составтан өзеп, каядыр алып киттеләр. Шактый озак торганнан соң вагоннардан төшәргә әмер булды. Әсирләр лагере тимер юлдан ерак түгел икән. Ул ике кат чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган. Безне шунда алып керделәр. Анда бүрәнәдән салынган ике катлы бараклар тезелеп киткән иде. Бу баракларда сугышка кадәр гаиләләре белән шахтерлар яшәгән булса кирәк. Фронт якынаю белән, алар ашыгыч рәвештә эвакуацияләнгән булганнар. Ашыгыч рәвештә дип әйтүем шуңа, үзләре белән бала бишекләрен алырга да өлгермәгәннәр.

Минем хәл шәптән түгел иде. Аягүрә басып тору читенләште. Аякларымны көчкә өстерәп, уртадагы бер барак эченә барып кердем. Андагы сасыга адәм чыдый торган түгел. Рәттән тезелгән өч катлы сәкеләргә карап тордым да, берсенең түбәнге катына арт ягымны төрттем. Анда берничә әсир сузылып яткан иде. Мин түбәнчелек белән кырыйда ятучының әз генә эчкәрәк елышуын үтендем. Җавап булмагач, соравымны кабатларга мәҗбүр булдым. Никадәр ялынсам да, сәкедә ятучыларның берсе дә соравыма игътибар итмәде. Йоклыйлар дип уйлап, берсенең кулыннан тарттым, кул боз кебек салкын иде. Мин корт чаккан кебек сискәнеп аягыма бастым. Монда мәетләрне тезеп салганнар икән ләбаса! Ярый әле ишектән чыгып өлгердем. Үлекләрне җыючы команда килеп, мәетләрне аякларыннан өстерәп ишегалдына ташырга тотынды. Чыгып китмәгән булсам, шунда рәттән мине дә үлекләр белән бергә өстерәп алып чыгулары бар иде. Алар өчен барыбер — син кирәк. Мәет санына карап хакын түлиләр. Хакы — бер чүмеч баланда.

«Нәрсә шаккатып торасың? Әллә мәет күргәнең юкмы?» — дигән тавышка сискәнеп киттем. «Монда менә эшләр шулай, озакламый безгә дә чират житәр», — диде әлеге кеше, сүзен дәвам итеп. Ул үзебезнең кызылармеец формасыннан иде. Аның мондый киемнән йөрүе миңа гаҗәп булып тоелды. «Ничек сине чишендермәделәр?» — дип сорадым. «Чишендерделәр. Ничек кенә әле. Менә дигән хром итегемне салдырып алдылар». Ул минеке төсле агач башмак кигән аягын күрсәтте.

«Юлдаши, хәзер үк бирегә килеп, сафка тезелегез!» — дигән команда яңгырады. «Нәрсә, белмис штоли, быстро, быстро. Хәзер мин сезгә, анагызны фәлән иткән... аңлатам». Кулына камчы тоткан полицай иң начар сүзләр белән сүгенеп, берәм-берәм Урта Азия, Кавказ кешеләрен өстерәп алып чыгып стройга тезде. Аңа ярдәмгә тагын берничә полицай пәйда булды. Болары бигрәк тә рәхимсез кылана иде. Абайлап тормыйлар, бер гаепсезгә әсирнең теләсә кайсы җиренә камчы белән тондыралар. Җыя торгач, стройда халык шактый күбәйде. Мин күрми дә калдым, строй каршына куллары богаулы яшь бер егетне китереп бастырдылар. Кыяфәтенә караганда, үзбәк егете булса кирәк. Камчылы полицай да аның янына килде. Ул кулларын болгый-болгый сөйләргә тотынды. Анын сөйләвенә караганда, бу егет эшкә алып барган җирдән качкан.. Ерак китә алмаган, тотылган. «Мәрхәмәтле герман командованиесе әсирләрне лагерьдан чыгарып йөртеп, иркен сулыш алдырып кайтара иде. Менә шушы хәшәрәт кара йөз аркасында хәзер юл ябылды. Әсирләргә лагерьдән чыгып йөрергә рөхсәт ителәчәк түгел!» — диде полицай. Ул сөйләп кенә калмады, немецка ышанычлы кеше булуын исбат итәргә теләпме, үзбәк егетен камчы белән каезларга тотынды. Бер унтер аерып алмаса, тоткынны кара канга батырачак иде.

«Ахтунг — дикъкать!» — дигән команда яңгырады. Лагерь тынып калды. Капкада зур чинлы, чиста киенгән офицер күренде. Аны ике кеше озата. Алары тылмачлар икән. Немецчә «долметшер» дип йөртәләр. Офицер урындык өстенә менеп басты да немецча сөйләргә тотынды. Шактый озак сөйләде. Аның сүзләрен без долметшер тәрҗемә иткәч кенә аңладык...

Лагерь начальнигының әмере буенча, качкын үлем җәзасына хөкем ителгән. Ул асып үтерелергә тиеш. Хөкем карарын үтәү кара тәнле әсирләргә тапшырыла. Стройда басып торучылар арасыннан лагерь башлыгының әмерен үтәргә теләүче табылмады. «Теләмисез, димәк, — диде начальник янап, — ул вакытта болай эшлибез, стройдан санап, һәрбер унынчыны шушы әсир белән бергә дарга асабыз». Аның бу кисәтүе дә сафта басып торучыларга тәэсир итмәде. Халык арасыннан чепи күзле бер тоткын атылып чыгып, лагерь начальнигына мөрәҗәгать итте: «Сез аларга тәмле телегезне әрәм итмәгез, рөхсәт итсәгез, боерыгыгызны үзем үтим». «Нәрсә дип әйтә ул?» — дип сорады майор тылмачтан.

Немец үз кулы белән кара эшкә бик сирәк тотына. Ул андыйны башкалардан эшләтә. Мин булган лагерьларның барысында да полицайлар, палачлар тоткыннарның үзләре арасыннан сайланып алынган кешеләр иде. Мондый хезмәтне күбесенчә украин милләтеннән булган тоткыннар башкара. Мин ялгыш уйлыйм бугай, дип һаман үземне үзем битәрли идем. Ләкин алай уйлаучы мин генә булмаганмын икән. Бу турыда сүз чыкканда күпчелек әсирләр минемчә уйлауларын растадылар.

Дарга асылган үзбәк егетен тәүлектән артык элмәктән алмадылар. Ул мескенгә, күп дигәндә, егерме яшь булгандыр.

Шушы хәлдән соң бик озак вакыт мин үземә урын тапмадым. Үзбәк егетенең асып үтерелүе мине генә түгел, күпчелекне тетрәтте.

Бер әсир иңбашыма төртте: «Әйдә, кереп ятабыз, нерваларыңны сакла, кирәк булыр. Әле башлана гына, алда тагын да фаҗигалерәк язмышлар көтә. Мин аңа ияреп, баракка кердем. «Бик ерак китмә, ишеккә якынрак урнашыйк». Нәрсәне күздә тотып болай дип әйткәндер,

аңлап бетермәдем, җавабымны көтмәде, житез генә сикереп, сәкенең өченче катына менде. Минем анда менәргә көчем җитмәде. Астагы сәкегә сузылып яттым. Әле бу сәкедә миннән башка кеше юк иде. «Син нәрсә анда маташасың, минем янга мен». Хәлемне аңлагач, ул үзе түбәнгә төшеп минем белән рәттән сузылып ятты. «Син әллә яралымы?». Аннан минем нинди частьтән булуымны сорашты. Ул үзе тумышы белән Полтава өлкәсеннән икән. Сугыш алдыннан гына өйләнгән булган. Хатыны йөкле булып калган. «Кайтып баламны күрсәм, үлсәм дә үкенмәс идем»,— диде өзгәләнеп. Ул үзе украинлыларга хас акцент белән сөйләшә. Фамилиясе — Кулиба икән. Чын фамилиясен яшерә, дөресен әйтми, дип уйлаган идем, ул шуны сизгәндәй: «Нәрсәгә аны алдап торыйм, куркырлык бер эшем дә юк»,— диде ул горур гына. Минем исемемне сорады. «Ярар, мин сине Анастас дип атап йөрермен»,— диде. «Юк инде, син минем исемемне үзгәртмә, дус булырга теләсәң, дөрес итеп, Әнәс дип әйт»,— дидем. «Кызык кеше булып чыктың әле син»,— диде ул. Һәм миңа якынрак елышты. «Монда, Горловкада, миңа туган тиешле кешеләр булырга тиеш. Әгәр шулар белән элемтәгә керә алсак, безнең эш пешәр иде»,— диде яңа танышым. «Белмим шул, үзләре сине эзләп монда лагерьга килсәләр генә инде. Башкача, ничек аларны очратырга мөмкин». «Бер рәте чыгар әле»,— диде ул, туганнары белән очрашудан өметен өзми иде, күрәсең.

Үзбәк егетен дарга асканнан соң атна да узмады, әсирләрне тагын шәһәргә эшкә йөртә башладылар. Тоткыннарны лагерьдан читкә алып чыгу тыела дип куркытыр өчен генә кисәткән булсалар кирәк.

Кулиба ничек итеп булса да, эшкә йөрүче командага эләгү чарасын күрергә тотынды. Йөри торгач, теләгенә ирешә дә. Беренче көнне ул эштән күтәренке күңел белән кайтты. Алар командасын станциягә алып барып, вагоннардан кирпеч бушаттырганнар. Ул минем янга килеп утырды һәм иңенә аскан капчыгыннан алып миңа шактый зур бер чөгендер белән бер кукуруз чәкәне тоттырды. Тәүлектән артык авызыма бер тәгам ризык капканым юк. Ул көнне норма буенча каралган яртышар литр сыек баланданы да бирмәделәр. Кулиба: «Иртәгә мин сине үзем белән эшкә алып барам, сафка тезеп тикшергәндә үзеңне нык тотарга тырыш»,— диде.

Шәһәр халкы әсирләргә җае чыккан саен азык-төлек белән ярдәм итә. Урамда сафта барганда, конвоирларның рәхимсезлегеннән куркып тормыйлар, төрле ашамлык ыргыталар. Бу эштә бигрәк тә хатын-кызлар батырлык күрсәтә.

«Мин әле бер икмәк кисәге дә эләктергән идем, икмәкне үзем ашадым, боларын сиңа алып кайттым»,— диде Кулиба шапырынып.

Кукуруз чәкәне белән пешмәгән чөгендерне мин минут эчендә юк иттем. Ничек кенә булмасын, ризыклангач, ачлык бераз басылып, йокыга китүемне сизми дә калганмын. Иртәнгә кадәр бернәрсә белешми йоклаганмын. Кулиба мине аякларымнан өстерәп торгызды. «Үлгәнсең дип торам, исән икәнсең әле»,— диде шаярып. Шул бер нәрсә белешми йоклауның файдасы тигәндерме, хәлем яхшырган иде. Кулиба белән бергә сафка чыгып бастым. Анда әсирләрне эшкә алырга килгән конвоирлар көтеп торалар иде. Нәрсәгәдер бик ашыгалар иде. Минем бәхеткә күрә дип әйтимме, башка көннәрдәге шикелле җентекләп тикшереп тормадылар, кырыйдан егерме кеше санап алдылар да, капкадан алып чыгып киттеләр. «Бүген яхшы конвоирлар килгән, кичәгеләре булса, сине калдырулары да бар иде»,— диде Кулиба. Безне саклап алып баручы конвоирлар олы яшьтәге солдатлар иде. Кулларына мылтык тотып карамаулары күренеп тора. «Немец соңгы таянычын — солдат яшеннән чыккан ирләрне җыя башлаган!» — диде янәшәмдәге әсир,— безгә генә түгел, аларга да сугышның түмән татый башларга вакыт». «Татырлар әле, татырлар, сугыш башлана гына». Көн шактый иртә булуга карамастан,

урам халык белән мыжлап тора иде. Бер кешенең дә кулы буш түгел. Күренеп тора, махсус, әсирләр белән очрашыр өчен урамга чыгалар. Алар бертуктаусыз, безнең сафларга төрле яшелчә, кукуруз чәкәне ыргыталар. Икмәк үзләренә дә такы-токы булса кирәк, бик сирәк күренә.

Конвоирлар урамдагы халыкка әлләни игътибар итми, күбесе аларның әсирләргә ризык өләшүен күрмәмешкә салына.

Безне тимер юл станциясенә китереп туктаттылар. Бөтен тирә-як җимерек. Чигенгәндә үзебезнекеләр шартлатканнар. Берничә урында дамбаны яңа гына күтәреп рельс сузганнар. Шул урынга цемент төягән вагоннар китереп туктатылган иде. Безне цемент бушатырга алып килгәннәр икән. Килеп җитеп өлгермәдек: «Лаус-лаус, быстро-быстро!» — дигән фәрман яңгырады. Бөтенебезгә зур-зур көрәкләр, носилкалар тоттырдылар. Һәрбер вагон турысына әсирләрне саклап эшләтер өчен икешәр сакчы килеп басты. Мин, вагон эченә менеп, көрәк белән носилкага цемент төяргә керештем. Кулиба да минем белән иде. Бер носилканы цемент белән тутырып бетерешкә, манма тиргә батып, күз алдым караңгыланды. Кулиба минем хәлемнең авыраюын күреп борчыла башлады. Аның ничек булса да мине ял иттерәсе килә иде. Ул миңа конвоирдан туалетка барырга рөхсәт сорарга тәкъдим итте: «Шунда озаклабрак утырырга тырыш, бераз ял итәрсең»,— диде. Мин вагоннан җиргә сикереп төштем дә, конвоир каршына барып бастым. Ул минем: «Пан, пан!» — дип өзгәләнеп мөрәҗәгать итүемә игътибар итмәде. Кемдер: «Син аңа арт ягыңны тотып күрсәт»,— дип кычкырды. Ниһаять, үтенечем аңлашылып, туалетка барырга рөхсәт алдым. Бәдрәф шактый читтә, анда ялгыз җибәрмиләр. Берничә кеше җыелгач, бер сакчы озата бара. Башка вагонда эшләүчеләр дә туалетка килгәннәр. Без килгәндә анда керер өчен чират иде. Озата килгән сакчы немец акыра. Бераздан шуны аңладым, аның тамагы ярылганчы кычкыруы туалеттагы тоткыннарны ашыктырудан да бигрәк, үзенең монда сакта торуын белдерү өчен икән.

Ачлык әсирләрне чиктән тыш хәлсезләндерде. Бөтенебез дә коры сөяккә калдык, тәндә чебен чукырлык та ит юк. Эш бик акрын бара. Конвоирлар акырып-бакырып приклад белән төрткәләргә тотындылар. Тоткыннар арасында дезинтерия тарала башлаган иде. Бер әсир туалетка барырга сорап карады да, җибәрмәгәч, тәкатьсезләнеп (кысталып) хаҗәтен вагон эчендә үтәргә тотынды. Конвоир күреп, аның башына приклад белән сукты. Ул аңын югалтты. Аны вагоннан җиргә өстерәп төшерделәр һәм эш беткәнче шунда аунап ятты.

Минем хәлем дә мөшкелләнде. Кулиба мине вагон түренә илтеп утыртты да, калганнарга вагон ишеге төбенә басып, немецкә тырышып эшләгән булып күренергә кушты. «Шулай берәмләп ял итик, югыйсә харап булабыз»,— диде. Бу хәйлә конвоирны бераз тынычландырды. Ул күздән югалып торган арада, вагонга чит бер тоткын килеп керде. Бөтен көченә ыргылып түргә узды да, үзен шушында цемент белән күмәргә үтенде. Аның теләгенең серен иң элек Кулиба аңлап алды. Арадан бер әсир ризасызлык күрсәтеп, тавышлана башлаган иде, «Яп ипи шүрлегеңне!» — дип бер генә кычкырды. Читтән кергән әсирне минем янга китереп муен тигентен цемент белән күмделәр дә: «Без эшне бетереп, вагоннан төшкәч, калганын үз кулың белән башкарырсың»,— диделәр.

Ул арада караңгы төште, эштән туктарга әмер булды. Вагонда эшләүчеләрне саклаган конвоир, үзенә тапшырылган әсирләрне санап, лагерьга илтте. Шунда гына бер кешенең юкка чыгуы беленде. Безне төне буе баракларга кертмичә, ишегалдында бастырып тоттылар. Үз күзләренә үзләре ышанмагандай мең кат санадылар.

Кулиба бүгенге хезмәттән бик канәгать иде. «Бердәмлек кирәк, бердәм булсак, бернинди куркыныч та куркыныч түгел»,— диде шатланып.

Шушы хәлләрдән соң лагерьда тагын бер яңалык туды. Һәр иртәдә әсирләрне сафка бастыралар да шәһәрдән килгән төрле дәрәҗәдәге

хәрбиләргә өләшәләр. Дөресрәге, алар сафлар буйлап күзәтеп йөреп, үзләренә ошаган кешене сайлап алалар. Бер көнне шактый олы яшьтәге бер фельдфебель мине һәм тагын өч үзбәк егетен сафтан чакырып чыгарды да үзе белән алып китте. Шактый озак бардык. Ул безне шәһәрнең икенче кырыендагы, бүрәнәдән эшләнгән ике катлы баракка алып керде. Баракның асты өскә китерелгән иде. Идәннәрдә, баскычта кан таплары. Урыны-урыны белән стеналарга да кан чәчрәгән. Бөтен бүлмәләр ватык савыт-саба, җимерек мебель белән тулган.

Фельдфебель безгә чиләк, мунчала, себерке тоттырды: «Рейнмахен — җыештырыгыз»,— диде. Үзбәкләр идән себерергә тотынды. Мин су ташырга керештем. Суны чиләк белән шушы барак ишегалды кырыендагы коедан ташырга кирәк иде. Кое янныннан кукуруз кыры башлана.

Бераз эшләгәч, фельдфебель бөтенебезне бер бүлмәгә бикләп каядыр китеп барды. Ул озак йөрмәде, бидон белән аш алып килде. Күп итеп вермишель салып пешерелгән куе аш. Күптәннән мондый ашны ашау түгел, исен дә иснәгәнебез юк иде. Тамак ялгагач, күңелләр күтәрелеп китте. Бераз ятып ял итеп алырга теләсәк тә фельдфебель рөхсәт итмәде, тамак ялгатуын исәпкә алып булса кирәк, ашыктырып эшләтергә тотынды.

Башыма хәтәр бер уй килде: качар өчен иң уңайлы вакыт түгелме соң бу? Бүген качып котылмасам мондый форсат тагын кайчан булыр?! Коедан су алырга мин берүзем барам. Сакчы юк. Баштарак фельдфебель мине күзәтеп маташты да юкка чыкты. Ышаныч казандым, ахры...

Мин бик ныклап тирә-юньне күзәттем. Кукуруз озын һәм куе булып үскән, иге-чиге күренми. Кукуруз арасында эзне югалту асат булыр төсле тоелды. Күп баш вата торгач, катгый бер карарга килдем. Соңгы мәртәбә бер көянтә су алып кайттым да, тәвәккәлләдем! Чиләк-көянтә күтәреп барактан чыктым да, салмак атлап, кое янына килдем. Су алган булып чиләкләрнең икесен дә коега батырдым. Көянтәсен дә шунда тондырдым. Тирә-якка карап алдым да, җан иясе күренмәгәч, кукуруз кырына кереп кызу-кызу алга ташландым. Шактый җир киттем.

Артымнан бозау кадәр овчарка куып җитүен сизми дә калганмын. Ул минем өстемә сикерде һәм муенымнан каптырып җиргә екты. Ул арада үзем белән бергә эшкә килгән әсирләрне ияртеп, фельдфебель дә килеп җитте. «Син анаңа нәләт нугай...» дип сүгенә-сүгенә үзбәк егетләре мине типкәләргә тотындылар. Аларның сүзләреннән шуны аңладым, имеш, мин фельдфебельнең яхшылыгын аяк астына салып таптаганмын. «Ашка каршы таш аткан кешегә үлем җәзасы да аз...» Берсенең аягы колак төбенә эләгеп, борынымнан гөрләп кан китте. Мине өстерәп баракка алып кайттылар һәм подвалга төшереп яптылар. Подвал эче караңгы, күзгә төртсәләр дә күренә торган түгел иде. Күпме аунап ятканмындыр, хәтерләмим, лампочкага ут кабынгач, сискәнеп киттем. Бераздан атылып фельдфебель килеп керде. Кулында пистолет. Мине, торгызып, стенага терәп куйды һәм пистолеттан атарга тотынды. Шуны сизеп алдым, ул куркытыр өчен генә ата иде. Атылган пуля миңа тими, чыжылдап йә уң ягыма, йә сул ягыма барып керә. Татарчалап, урысчалап сүгенергә тотындым: «Үтер мине тизрәк хәшәрәт, үтер, менә монда төзәп ат!» дип күкрәгемне ачып күрсәттем. Ни гаҗәптер, үзем үлем турында уйламадым. Пуля тисә, аңымны җуеп ятып торырмын кебек кенә булып тоелды. Немец атты-атты да, әллә пулясы бетте инде, чыгып китте. Ул чыгып киткәч, хәлсезләнеп баскан урынымда җиргә утырдым. Бөтен тәнем ут кебек булып кызышты. Шактый озак утырдым. Түшәмдәге лампочка бер сүнде, бер янды. Мин аны күрмәс өчен күзләремне чытырдатып йомдым.

Ишекне дөбер-шатыр ачып, ике солдат килеп керде. Арт ягыма типкәләп торгыздылар да ишегалдына алып чыктылар. Анда әрҗәсе каплаулы машина көтеп тора иде. Мине мәче баласы кебек бөтәрләп шунда ыргыттылар. Үзләре дә яныма менделәр. Немец солдатларының

үзара русча сөйләшүләрен ишетеп, бик гаҗәпләндем. Әллә саташам инде дип уйладым. Ничек инде немец солдатлары урысча сөйләшсен икән. «Әйтегез әле сез кем буласыз?» дип соравымны сизми дә калдым. Соравыма җавап бирүче булмады. Шактый вакыт үткәч кенә урысча сөйләшүче немец солдатларының кем икәнен белдем. Фашистлар үз армияләренә көчләп совет кешеләрен дә мобилизацияли башлаганнар икән.

Кузовта, минем янымда бер агач мичкә бар иде. Кулымны шул мичкә эченә тыгып карадым. Мичкә кырыена нинди дер, йомшак масса сыланган иде. Учлап алдым да, нишләгәнемне сизмичә авызыма каптым. Май тәме килгәч, ни булса да булыр, дип ашыгып ашарга тотындым. Соңыннан белдем, мичкә маргариннан бушаган булган икән.

Машина чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынган лагерь капкасы төбенә килеп туктады. Ләкин бу иртән мине эшкә алып киткән лагерь түгел, башка иде. Каравыл начальнигы булса кирәк, бер унтер мине кабул итеп алды. Авыз эченнән мыгырданып, башымнан аягыма кадәр күзәтеп торды да, мине капка төбендәге баракның подвалындагы кечкенә бүлмәгә кертеп япты. Өстемнән бикләп куйды. Бүлмә шулкадәр тар, борылырга да мөмкин түгел. Керү белән нәрсәгәдер сөртендем. Анда бер кеше чүнкәйгән иде. Аягым тию белән ул ыңгырашырга тотынды. Миңа басып торырга туры киләчәк. Ике кеше утырып торырлык түгел. «Күптән монда утырасыңмы?» дип сорадым. Аның тавышы бик зәгыйфь, көч-хәл белән: «Икенче көн булса кирәк, мин исәпне югалттым»,— диде. «Нәрсә булды? Нишләп мондый хәлгә калдың?». Ул качкан булган, ерак китә алмаган, тотылган. Полицайлар аңын югалтканчы кыйнаганнар. Сөйләшә торгач шунысы аңлашылды: ул беркөн вагон бушатканда, Кулиба цементка күмеп калдырган әсир булып чыкты. Яшеренгән җиреннән төн урталары узгач кына торып чыккан булган. «Үзебезнең совет кешеләре немецкә тотып бирде,— диде ул күз яшенә тыгылып,— шулкадәр рәхимсез булырлар икән».

Кинәт ишек ачылышка мин сискәнеп киттем. Ишек төбендә бер солдат белән беләгенә ак чүпрәк бәйләгән әсир басып тора иде. Ул: «Котелокларыгызны бирегез, баланда китерәм»,- диде. Җавап булмагач: «Нәрсә, телегезне йоттыгызмы әллә?» — дип акырды. «Котелокларыбыз булгач, бирербез»,— дидем мин. Алар артык сүз озайтып тормадылар, китеп бардылар. Бераздан тагын ишек ачылды. Бу юлы солдат үзе генә иде. Ул икебезгә бер котелок баланда калдырып китте. Мин аны иптәшемә тәкъдим иттем. Баланда ашагач, хәле җиңеләймәсме дип уйладым. «Минем тамагымнан үтми, үзең аша»,— диде ул.

Ул яшәүдән өметен өзгән иде инде, ахры. Үлем якынлашуын сизепмедер, васыятьләрен әйтә башлады: «Мин үзем Мокеевка кешесе.— Мине андый исемдәге шәһәрне белми дип уйлады, ахры, кыскача гына аңлатып үтте.— Моннан ерак түгел ул шәһәр, янәшәдә генә. Анда минем Галина исемле хатыным, өч яшьлек Шурик атлы малаем калды. Бу җәһәннәмнән исән-сау котылсаң, минем кайда үлеп калганымны аларга хәбәр итә күр»,— диде. Адресын, фамилиясен, исемен, атасының исемен кабат-кабат әйтте. Фамилиясе әле дә хәтеремдә — Канапий.... «Бәлки сиңа, ходай насыйп итеп, шәһәргә чыгарга туры килер. Минем турыдагы хәбәрне берәр кәгазь кисәгенә язып, урамда ташлап калдыр. Адрес буенча эзләп табып, минем хатынга тапшырмый калмаслар...» Аны тынычландырырга теләп: «Өметсез булырга ярамый, әле үлмибез, яшибез. Фашистларны дөмектерми үләргә ярыймы соң?» — дидем. «Рәхимсез рәвештә кыйнамаган булсалар, бәлки мин дә исән калган булыр идем. Аяк белән типкәләп эчәгеләремне өзделәр, ахры...»

Чолан ишеген ачып, «раус», дип акырдылар. Анда ике немец солдаты басып тора иде. Канапийның аягына басарлык хәле юклыгын күреп, култыгыннан тотып, көчкә торгыздым. Ул зур газап белән миңа тотын-

ган килеш өстерәлеп кенә ишегалдына чыкты. Аны, утын пуләне кебек, шунда безне көтеп торган машина кузовына ыргыттылар. Канапий йөрәк өзгеч тавыш белән ыңгырашты да, кинәт тынып калды. Саклап баручы солдатның берсе, аның арт ягына аягы белән типте дә, җавап булмагач, «капут», «капут», дип кычкырды. Мин немец солдатының кыланышын күзәтеп, машинаның ике катлы таштан салынган бина каршына килеп туктавын абайламый да калдым. Бинаның урамга каратып эшләнгән ягында тәрәзә юк, тоташ кирпеч дивар.

Мине ишегалды аркылы үткәреп, икенче катка алып менделәр, дәү бер бүлмәгә кертеп җибәрделәр. Бүлмә эче җылы һәм чиста иде. Түрдә өч кеше утыра. Өчесе дә күлмәкләреннән бет чүпли. Икесенең яше минеке чамасында. Өченчесе кара мыеклы, бездән күпкә олы күренә. Алар минем керүемә игътибар итми, бет чүпләүләрен дәвам иттерделәр. Мин аптырап бераз басып тордым да: «Һич аңламыйм, әйтегез әле, нинди урын бу?» — дип сорадым. Мыеклы сүзсез генә ишегалдына карап торган тәрәзәгә төртеп күрсәтте. Тәрәзәгә аркылы-торкылы тимер таяклар кагылган иде. Минем бернәрсә аңламый һаман аптырап торганымны күреп: «Нәрсә, әллә үз гомереңдә төрмәдә булганың юкмы? Менә шулай дустым, бу дөньяга аяк баскан кеше, барысын да үз күзе белән күрергә тиеш». Аның, «дустым» дигән сүзе җанымны җылытып җибәрде. «Нәрсә, лагерьдан качтыңмы? Уйламый эшләсәң шулай була ул. Бик тиз иреккә чыгарга ниятләгәнсең. Алай асат кына иреккә чыгып буламы соң? Акыл белән эш иткәндә генә иреккә чыгып була. Ярар, авызың бер пешкәч, киләчәктә салкын суны да өреп кенә эчәрсең». Ул миңа акыл сата төсле булып тоелды. Читкәрәк тайпылдым. Ул минем рухи халәтемне чамалап алды: «Ә-ә, дөресен әйтү ошамыймы. Туры сүзне аны беркем дә ошатмый»,— дип куйды.

Иң кыска көннәр башланган иде. Караңгыланып, бүлмә эченә тәрәзәдән ай яктысы төште. Бүлмәдәшләрем күлмәкләрен киеп, идәнгә сузылып яттылар. Мин дә яттым. Кышкы салкыннарны шушы җылы бүлмәдә үткәрсәң, начар булмас иде дип хыялландым. Ничектер, күңелгә шигырь юллары килде:

Тәрәзәдән тулган айга карыйм,
Ай да карый болыт арасыннан.
Күз алдымда — әнкәй. Рәнҗи микән,—
Игелек күрмичә баласыннан...

Әйтче, ни хәлләр бар ул җирләрдә?
Безнең турыдан, ай, үтәсеңме?
Әллә кара болытларга күмелеп,
Күрмәмешкә салышып китәсеңме?..

Минем өзелеп-өзелеп ашыйсым килә иде. Онытырга, онытырга. Хәзер ашау турында уйларга ярыймы соң? Нәрсәне, нәрсәне, ашауны оныту мөмкин түгел икән. Менә мин үзем теләгәнчә аякларымны сузып ятып торам. Күптән болай рәхәтләнеп ятып торганым юк иде. Ачлык кына үзәкне өзә. Монда җылы. Ә тышта кыш ишек шакый. Минем исә җиңнәре аерылып төшкән, кайчандыр Бельгия солдаты киеп йөргән френчтән башка киемем юк. Шулай уйланып ятканда түшәмдәге лампочкага ут кабынды. Яктылык күземне чагылдырды. Уйларым бүленүгәме, кәефем кырылды. Камерага хәрби кием кигән бер кеше керде. Бүлмәдәшләрем артларына ут капкандай ашыгып, сикереп торып, аягүрә бастылар. Мин мондый тәртипне белмәгәнлектән ята бирдем. Немец: «Ауф малибаман!» — дип аягы белән типкәч кенә сикереп тордым. Безгә ашарга керткәннәр иде. Ул кәгазь калынлыгы итеп киселгән 50 грамм чамасы икмәк белән бер стакан судан гыйбарәт иде. Тоткыннарга пыяла стакан бирергә куркалар иде күрәсең. Су салган савыт тимерме, керамикамы,

аера торган түгел. Мин икмәкне кулыма алу белән авызыма каптым һәм озак чәйнәп маташмадым, йотып та җибәрдем. Мыеклы кеше күзәтеп тора икән: «Ай-яй, син, егет ничек кабаланасың, бер тәүлеккә бирелгән паекны бер кабуда юк иттең,— диде.— Болай булсаң, бик тиз аягыңны сузарсың. «Шунда гына аңладым, 50 грамм чамасы икмәк белән бер стакан су — тоткыннарга бирелә торган көнлек норма икән.

Мыеклы минем исемемне сорады. Әнәс исемле мин дигәч, гаҗәпсенеп: «Син нәрсә, юлдашмыни?» — дип сорады. Минем шулкадәр ачуым чыкты, җавап бирергә сүз таба алмый тордым. «Димәк, кара күт... Ләкин төсең белән бер дә аларга ошамагансың». Ниһаять, мин телгә килдем: «Ә син үзеңне кемгә саныйсын? Кай җирең алардан артык. Әллә алар кикригеңне кистеләрме?» Ул мондый җавапны көтмәгән иде күрәсең. «Кара, кара, ничек чәпчи. Чәпчемә, без сине урыныңа утыртырга да күп алмабыз». «Көч сынашыргамы исәбең. Кил әйдә, чамалашып карыйк». Сер бирәсем килмәде, хәлем булмаса да, аягыма бастым. «Василий Иванович, син аның белән шаярма, ул кара күт түгел, Казан татары»,— диде, әлегә кадәр сүзгә кушылмый утырган тоткын. Ул элеп киптергәндәй ябыгып, өрәк кыяфәтенә кергән. Василий Иванович минем яңга килде: «Гафу ит, миң синең Казан татары икәнеңне белмәдем»,— дип кулын сузды.

— Мин мондый кара эчле шовинист белән туалетта да янәшә утырырга теләмим,— дидем. «Йә, инде, юкка үпкәләшмик. Мин шаярттым гына бит, дуслыкка ни җитә. Исемең Анастас дисеңме әле?» Аның болай сөйләшүе тагын авырткан җиремә тиде. Үземнең исемемне бозучыга карата булган нәфрәтем турында әйтеп тә тормыйм, урыска ярарга тырышып, мулла кушкан исемнәрен үзгәрткән милләттәшләремне дә җенем сөйми. Без шулай тарткалашып торганда, надзиратель камера ишеген ачып: «Айн ман — бер кеше, быстро!» — дип кычкырды. «Саша, синең чират»,— диде Василий Иванович. Саша тиз генә коридорга чыкты. Мин үземнең: «Кая алып китteләр аны?» — дип соравымны сизми дә калдым. Көн саен бер кешене чакырып коридорга чыгаралар да идән юдырталар икән. Һәр тоткын анда чыгып эшләп керергә атлыгып тора. Хикмәте шунда, анда эшләгәндә көнлек нормага өстәп тагын бер паек бирәләр икән.

Василий Иванович миңа төрттереп сөйләвен нигәдер дәвам итте. Ул мине бөтен эшне дә үз белдегем белән эшләүдә гаепләде. «Син иптәшләрең белән киңәшми лагерьдан качкансың,— диде.— Андый хәлиткеч адымны ялгыз эшләргә ярыймы соң?» Аның ачы сүзләрендә хаклык бар иде, әлбәттә. «Алай бик акыллы баш булгач, үзең нигә монда читлек эчендә утырасың?» — дип сорадым. «Мине бер хохол сатты. Әгәр шул хохол юлыма аркылы төшмәсә, мин күптән үзебезнең якта була идем»,— дип җавап бирде ул. Аннан: «Хохоллар алар бар да сатлыклар!» — дип сүгенергә тотынды. Сүзен исбатлар өчен әсирләр лагерендагы полицайларның күпчелеге украин милләтеннән булуын мисал итеп китерде. «Мондый кара эчле шовинистны беренче мәртәбә күрәм,— дидем мин. Урта Азия халыкларын кешегә исәпләмисең. Хәзер менә украиннарны тоташтан мыскылларга тотындың. Синеңчә, руслар гына кеше була мыни?! Әгәр мондый уйда икәнеңне белсә, Гитлер сине күптән үзенә киңәшче итеп яллар иде». Барыбыз да кычкырып көлдек. Василий Иванович үзе дә безгә кушылып көлгәндәй итте. Бәхәсне бүтән сузарга туры килмәде, мине надзиратель чакырып алды.

Мине кире әсирләр лагерына илтеп тапшырдылар. Бу шул безне фельдфебель эшкә алып киткән лагерь иде.

Төрмәдә утырганда сорау алып теңкәгә тияр дип шикләнгән идем. Сорау алу булмады. Соңыннан шундый нәтиҗә ясадым. Алар, ахры, мине үзләре өчен куркыныч кешегә исәпләмәделәр. Тышкы кыяфәтем белән мин партизанга охшамаган идем. Коры сөяккә калган гәүдә. Айдан артык инде бит-кул юылмаган. Кулның һәр буыны саен

яра. Алланың нинди рәхмәте төшкәндер, беренче качуым шулай артык катлауланмыйча тәмамланды.

Мин төрмәдә утырып чыккан арада халык саны күзгә күренерлек булып кимегән иде. Бараклар бушап калган. Бердән-бер танышым Кулибаны эзләп киттем. Ләкин таба алмадым. Кичкырын эшкә алып киткән әсирләр кайтып базар оештыралар. Мин шул базар була торган урынга чыгып утырдым. Озак көтәргә туры килмәде, төркем-төркем булып шәһәрдән кайта да башладылар. Бар да шукадәр йончылган, өрәккә охшап калган. Аягын өстерәргә аз-маз хәле булган әсир, шушы базар була торган мәйданга килә. Һәркайсы үзенең товарын чыгарып, сәүдә итәргә тотына. Сатыла торган товар пешмәгән чөгендер, кишер, тәмәке төпчеге, кукуруз чәкәненнән гыйбарәт. Сирәк-мирәк паекка бирелгән икмәк тә күренгәли.

Бер әсирнең кулында ике тәмәке төпчеге бар иде. Төпчекләре шактый зур күренә. Ул шул «хәзинә» сенә бер паек ипи яки бер кукуруз чәкәне сорый. Аның янына төртсәң аварга торган озын буйлы бер әсир килеп басты. Ул тәмәке төпчеге белән сату итүчегә беренче мәртәбә күргән шикелле карап торды да: «Ә-ә, бу син икәнсен әле»,— дип аның кулындагы тәмәке төпчекләрен җиргә сугып төшереп, аягы белән таптарга тотынды. «Җәмәгать, бу кешегә ышанмагыз, ул алдакчы, тәмәке дип, кәгазьгә үлән төреп сата!» — дип кычкырды. Ул арада икесе якалашырга да тотындылар. Минем кебек кызыксынып карап торучылар арасыннан бер кеше чыгып, аларны үгетли башлады. Бу кеше минем танышым Кулиба иде. Якалашучылар: «Синең бездә ни эшең бар, кит! Йөрмә буталып»,— дип аңа ташландылар. Аларга тагын берничә әсир килеп кушылды. Китте сугыш... Мин Кулибаны кулыннан тартып читкә алып чыктым. «Әйдә, киттек тизрәк»,— дидем. Ул мине күреп, гаҗәпкә калды. «Син ничек монда?» — дип сорады. Аңа яхшы ук тондырып өлгергәннәр. Борыныннан кан саркый. «Ачлык белән газап чиктерү генә җитмәгән, өстәвенә юк-бар өчен үзара тукмашырга гына калдык».

Кулиба миннән соң икенче баракка күчкән икән. «Минем янда бер буш урын бар, шунда урнашырсың»,— дип, мине үзе белән алып китте.

Без баракка кергәндә Кулиба яткан сәкедә буш урын калмаган иде инде. Аның үз урынында да сакаллы бер әсир ятып тора иде. Кулиба аны аягыннан тартып торгызды да: «Сукыр түгелсеңдер бит, урынның буш түгел икәнен күрсәткән билгене күрмәдеңмени? — Ул идәннән рельс кисәге алып әлеге кешенең борын төбендә уйнатты.— Менә моны мин сәкегә куеп калдырдым, син аны идәнгә алып ыргыткансың». Сакаллының урынны бушатырга исәбе юк иде. Ул ачы итеп сүгенергә тотынды. «Хәзер үк тукта, югыйсә ипи шүрлегеңне җимерәм»,— диде Кулиба аны кисәтеп. Теге бәндә тәртә кебек озын куллары белән кизәнергә тотынды. «Әһә, әле син яхшылык белән әйткәнне аңламыйсыңмыни?» — дип, Кулиба аның кулларын артка борып тотты һәм типкәләп ишек янына илтеп ыргытты. Сакаллы дуңгыз тавышлары чыгарып чинады. Миңа ул кызганыч булып тоелды. «Алай рәхимсез булырга кирәк түгел иде»,— дидем. «Кацапны аны башкача җиңеп булмый. Алар үзләрен бөтен җирдә хуҗа итеп сизәләр. Хуҗа булмый гына торсын әле. Әйдә утыр»,— диде Кулиба, мине үзе янына сәкегә утырырга чакырды. Капчыгыннан зур бер чөгендер белән ике кукуруз чәкәне чыгарды: «Ал, ал,— диде чәкәнне миңа сузып,— ашагач хәл кереп китәр». Мин күзләремнән кайнар яшь атылып чыгуын сизми дә калдым. Аның шәфкатьлелеге мине таң калдырды. Мин аңа кем? Очраклы бер таныш. Нужа бабай таныштырды. Шул уртак язмыш туганлаштырды. Кулибага фронтта озак булырга туры килмәгән. Армиягә алыну белән, ул хезмәт иткән полкны Изюм-Барвенково юнәлешендә маршал Тимошенко җитәкчелегендә барган сугышларда барлыкка килгән капчыкка китереп тыкканнар. Алар бөтен армияләре белән

шул капчыкта ябылып калып, әсир төшкәннәр. Ул украин телендә нинди начар сүз бар, шуларны кат-кат әйтеп, маршал Тимошенкоңе сүгә.

Кулиба үзенең сугышка кадәр кем булып эшләвен әйтеп бетерми. Шактый укымышлы кеше икәне һәр сүзеннән аңкып тора. Аның күңелендә Гитлерның җиңеләчәгенә шик, шөбһә юк иде. Ул аны беренче адымнарында ук ялгыш җибәрүдә гаепләде. «Акыллы булса, ул Советлар Союзына сугыш башламас иде. Немецларның ике фронтта сугыш алып барып авызлары бер пеште бит инде. Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан үз генераллары язып калдырган кисәтүгә колак салмады. Дөрес, хәзергә аның уңышлары зур. Мәскәүгә барып җитте. Идел буенда, Төньяк Кавказда сугыш алып бара. Украина тулысы белән аның кулында. Әйтергә кирәк, колхозчыларның күпчелеге аны көтеп алды. Халык колхоз строеннан тәмам гарык булган иде бит инде. Әмма Гитлер крестьянның өметен акламады. Колхозларны таратып, җирне крестьянга бирү турында уйлап та карамый. Аның исәбе, сугыш беткәч, җиңү яулап алган солдатларның колхозларга хуҗа итеп китереп утырту булса кирәк. Тот капчыгыңны. Үзенең жилкә чокырын күрә алмаган төсле, җиңүне дә күрәчәк түгел ул. Әсирләр белән нәрсә эшли? Аларны ач тотып үтереп бетерергә чамалый. Юк, ул безнең илгә яхшы ният белән килмәгән. Син безнең украинада утыз өчтә Сталин оештырган ачлык турында белмисең, мөгаен. Ул елны ачлыктан күпме халык кырылды. Күпме икәнен бары бер Алла белә. Исән калганнарын бер гаепсезгә Себергә сөрделәр. Үзем барып күргәнем юк. Себердәге лагерьлар турында сөйләп карыйлар анда!... Төптән уйлаганда Сталины да аның Гитлердан артык түгел. Икесе дә бер чыбыктан сөрелгән...

Аның Сталин турындагы сүзләрен ишеткәч, чәчем үрә торды. Ничек курыкмыйча мондый сүзләр сөйли икән, дип уйлап куйдым. Ул вакытта әле минем өчен Сталин изге кеше иде. Аңа тел тидерүне иң зур гөнаһлардан саный идем. Кулиба сүзен дәвам итеп: «Безнең армия дөньяда иң көчле армия дип күпме лаф ордык. Чынбарлык нәрсә күрсәтте? Немец танкларына каршы коры кул белән сугышырга туры килде. Кадровый армиядәге күпме яшь җан кырылды. Һәлак булмаганнары әсирлектә газап чигә».

Мин үз чиратымда Кулибага төрмә хәлләре хакында сөйләдем. Ул минем төрмәдән ансат котылуыма гаҗәпләнде: «Ничек инде сине сорау да алмыйча чыгарып җибәрделәр?» — диде. Аңа үземнең кышны төрмәдә үткәрү турында хыялلануым турында да әйтеп үткәрдем. Ул хәлемне яхшы аңлый. Көннәр шактый салкынайды. Озакламый кар да төшәр. Ә минем җылы киемем юк. Җиңе аерылган френчтән күренеп торган иңбашыма кулын куеп: «Ничек итеп булса да шинель кисәге җүнәтергә кирәк»,— диде ул. «Бетем белән сатып алыйммы?» — дидем өметсезләнеп. «Бигрәк инде бала-чага кебек фикер йөртәсең,— диде ул мине әрләп.— Көн саен монда хәзер күпме халык теге дөньяга китә. Карап йөре, мин дә күз-колак булырмын. Үлгән әсиргә шинельнең кирәге юк». Уңайсызланганымны сизеп: «Миннән әйтү, калганын үзең кара»,— диде ачуы килеп.

Без шулай гәпләшә-гәпләшә йокыга китүебезне дә сизми калганбыз. Бик туңып уянып киттем. Тыштан салкын җил өрә. Баракның тәрәзәләре ватык, ишеге каерылып алынган. Кинәт салкынайган булса кирәк. Барак эче әле караңгы иде. Кулым белән капшап, Кулибаны эзләдем. Ул минем янда юк иде. Гомумән, сәке өстендә халык сирәгәйгән иде. Бар да каядыр чыгып тайган. Мин дә торып ишегалдына чыктым. Анда халыкны сафка тезеп маташалар иде. Шунда бер сафның артына барып сыендым. Мине немец аннан өстерәп чыгарды да, арт ягыма тибеп, икенче кырыйга җибәрде. Бу сафта аның үзе сайлап алган әсирләр басып торалар икән. Сафка тезелгән әсирләрне ашыктырып лагерьдан алып чыгып киттеләр.

Соңыннан сөйләүләренә караганда, немецлар таза, сәламәтлеге нык булган тоткыннарны сайлап алып, каядыр хәрби корылмаларга эшкә җибәргәннәр. Кулиба да шул төркемгә эләкте булса кирәк, без башкача очрашмадык.

Шул ук көнне лагерьга яңаларны китерделәр. Бу төркемдә барысы да дип әйтерлек аякларын көчкә өстерәп йөриләр иде. Алар үзләре белән дезинтерия авыруы алып килделәр. Әсирләр кырыла башлады. Лагерьда карантин игълан ителде. Тоткыннарны лагерьдан эшкә алып йөрү туктатылды. Яшәү шартлары тагын да кыенлашты. Таза әсирләр шәһәргә чыгып эшкә йөргәндә аз булса да азык-төлек кайта иде.

Ишегалдында шәһәрдән килгән немец солдатларының үзләре ошаткан тазарак әсирләрне сайлап алуларын карап бераз басып тордым да, туңып баракка кердем һәм сәкегә сузылып яттым. Минем янга бите-кулы кара корымга каткан, тәбәнәк гәүдәле бер тоткын килеп утырды. Аның сөйләшерлек тә хәле юк. Авызыннан сүзе ишетелер-ишетелмәс кенә булып чыга. Сораша торгач, шуны аңладым: ул минем якташ булып чыкты. Безнең авылдан өч чакырым ераклыктагы Яңа Җөлби кешесе. Минем Кушлавыч авылыннан икәнне белгәч, йөзе яктырып китте. Бөтен көчен җыеп, Харьков шәһәрендәге бер лагерьда безнең авылның Әхмәтҗан атлы бер кешене очратуын сөйли башлады. «Ул анда үлде. Гәүдәсен мәет күмүче команда өстерәп алып чыгып киткәнен үз күзем белән күрдем. Исән-сау авылга кайтсаң, туганнарына кайда үлгәнен әйтерсең. Онытма, Чыпчык Әхмәт-җаны»,— диде. Истә калдырыр өчен җайлырак булсын дип, күрәсең, исеменә авылда халык арасында таралган кушаматын да өстәп әйтте. Кабат-кабат сорасам да, ул миңа үзенең исемен атамады. Әллә курыкты инде... Баштагы елларда, әсирләрнең күпчелеге, алдагы көнне уйлап булса кирәк, исем-фамилияләрен яшерергә тырышалар иде.

Якташымның хәле көннән-көн начарланды. Әсирләргә көн саен бирелә торган бер чүмеч сыек баланданы алыр өчен чиратка чыгып басарлык та хәле калмады. Чын күңелдән аны савыктырасым килә иде. Шул исәп белән аңа үземә бирелгән баланданы тәкъдим иттем. Ул катгый рәвештә баш тартты. «Минем язмышым хәл ителгән инде, син үзеңне яхшырак кара»,— диде. Кичкә таба ул аңын югалтты. Төн урталарында аяк-кулы салкынайды. Иртә белән әсирләр арасында «капут команда» дип атап йөртелә торган мәет җыючылар мәрхүмне алып чыгып киттеләр. Шулай итеп мин күрше авыл — Яңа Җөлби егетенең исемен дә белми калдым. Әмма аның сурәте мәңге онытылмаслык булып хәтеремә уелган. Ул көннәрдән бирле ярты гасырга якын вакыт узуга карамастан, һаман күз алдымда тора.

Һава шактый салкынаеп, кар явып китте. Мин әле һаман бер кат ертык френчтән йөри идем. Безнең халыкта: «Ходай бирим дисә колына, чыгарып куяр юлына», дигән мәкаль бар. Минем белән дә шулаерак килеп чыкты. Беркөнне аягына басып торырга хәле булган әсирләрне барактан мәет ташырга мәҗбүр иттеләр. Шунда гаҗәп бер хәлне сиздем. Бәлки, миңа гына шулай тоелгандыр, мәетнең гәүдәсе чиктән тыш авыр була икән. Бер үлекне күтәрергә теләп җан-фәрманга тырышып маташканда, бер полицай минем көчсезлегемне күреп, читкә этеп җибәрде. Күзалдым караңгыланып бер кырыйга барып чүңкәйдем. Шунда утырганда минем аяк очына бер шинель ыргыттылар. Тегенди-мондый гына түгел, совет солдаты шинеле. Соңыннан шулай уйладым, полицайлардан кайсыдыр, минем бер кат френчтән генә булуымны күреп, шунда, каршыдагы сәке өстендә аунап яткан мәеттән калган шинельне минеке дип уйлаган булса кирәк. Ишектән чыкканда бер полицай аяк астында яткан шинельне күреп: «Нәрсә, әллә җәйгә чыктыңмы. Тапкан шинель салып утыра торган вакыт!» — дип акырды. Мин шинельне алып

өстемә киюемне сизми дә калдым. Ул шактый зур гәүдәле үлектән калган булса кирәк, итәкләре минем тубыктан иде.

Халык көннән-көн күбрәк кырыла. Мәетләрне җыярга өлгерми башладылар. Тәүлектән артык бер үлгән әсир янында ятып вакыт үткәрдем. Мәетне алып чыгып киткәч, урынына кечкенә гәүдәле, житен кебек сары чәчле бер әсир килеп ятты. Без аның белән башта русча сөйләштек. Кем икәнемне белгәч, ул татарчага күчте. Исемен сораган идем, ул: «Татарча исемем Миңнебай, документларда Михаил дип язылган»,— диде. Аның туган җире — Башкортстан, милләте — мари икән. Ләкин марича бер сүз дә белми. Авылларында бар да татарча гына сөйләшәләр, балаларын да татар телендә укыталар икән. Тагын шунысы кызык, егетнең сөйләвенә караганда, аларның авылларында бөтен кеше ике исем йөртә, бала тугач та, исем татарча кушыла. Читкә китеп, паспорт алырга туры килсә, исемнәре урысчага алмаштырыла. Егетнең фамилиясе Бикметов иде. Минем яшьтәш. Чираттагы чакырылыш буенча армиядә хезмәт иткән. Сугыш башланганда ул хезмәт иткән полк Ерак көнчыгышта, Кытай чигендә торган. Аларны кырык икенче елны ашыгыч рәвештә Харьков юнәлешенә фронтка китергәннәр. Юлда барганда барысының да винтовкаларын җыеп алып, фронт сызыгына җитәрәк яңаны бирергә вәгъдә иткәннәр. Алар төялгән эшелон төнлә бер разъездга килеп туктый. Сугышчылар бар да йокыга талган була. Шулвакыт эшелонны пулеметлар, автоматлар белән коралланган немец солдатлары чолгап ала. Әллә белеп, әллә белмичә, эшелонны дошман кулындагы разъездга китереп керткәннәр икән. Мин бик гаҗәпләнеп: «Әллә бер мәртәбә дә атмыйча әсир төштегезме?» — дип сорагач, ул: «Коры кул белән баштанаяк коралланган дошманга ничек каршылык күрсәтәсең?» — диде. «Бездән — рядовойлардан винтовкаларны җыеп алганда, командирларның шәхси кораллары үзләрендә калдырылган иде. Комиссар минем алда үз-үзен атып үтерде. Хәер, аңа башка чара да калмаган иде. Ул милләте белән яһүд булганлыктан, исән-сау килеш немецкә бирелсә, аны тагын да газаплырак үлем көтә иде. Акылы җитте»,— диде Миңнебай комиссарны мактап.

Миңнебайга да эч китү чире эләкте. Тамагыннан бер тәгам ризык үтмәде. Хәлсезләнеп берничә көн аунап яткач, үлеп бетмәгән килеш мәет күмүчеләр бaрактан өстерәп алып чыгып киттеләр. Мин: «Кая алып барасыз? Ул әле исән!» — дип әйтеп караган идем, «Артыгын белмә!» — дип бер полицай резин таяк белән аркама тондырды.

Миңнебайның авыруы коры эч китү генә булмаган, соңыннан беленгәнчә, лагерьда корсак тифы таралган икән. Бер атна эчендә сәкеләр бушап калды.

Лагерьда суга да кытлык иде. Юыну турында әйткән дә юк, эчәргә дә бик кыенлык белән су таба идем. Минем инде өч айга якын биткулымны юганым юк иде. Кул бармакларының буыны саен шеш чыкты. Алар тишелеп яра хасил булды. Үзәккә иң үткәне бет иде. Йон үскән җирләрдән бетне учлап алырга мөмкин иде. Шунысы гаҗәп: үлгән кешедән бет кача икән. Карап торганым бар, үлгән кеше тәненнән чыккан бетләр сафка тезелеп читкә китәләр. Идән, сәке өсте кап-кара бет белән мыжлап тора. Мин шешенеп авырый башладым. Аеруча җилкәм бик каты шеште. Шешенгән җиргә кул белән катырак бассаң, суы чәчрәп түшәмгә тия иде. Шеш тишелүдән барлыкка килгән җөйләр тәнемдә хәзер дә бар әле. Авырып поликлиникага баргач, врачлар нинди җөй дип сорыйлар.

Лагерьда чакта шешенеп авырганда иң курыкканым аңымны югалту иде. Әгәр аңымны югалтсам, шәфкатьнең нәрсә икәнен дә белмәгән мәет күмүчеләр алып чыгып китәсен көт тә тор. Үзем күрмәдем, лагерьнең арт ягында ике чокыр бар, берсендә биш, икенчесендә өч мең әсир ята дип

сөйләделәр. Чокырларның өсте ябык түгел, көн дә мәетләр өстәлеп тора. Табигый инде, шушы яшьтән анда барып керәсем килми иде.

Миңнебайдан бушаган урынга ике татар килеп урнашты. Шактый олы яшьтәге кешеләр. Башта мине урынымнан куарга теләде болар. Татар икәнемне белгәч, мәрхәмәт күрсәтеп, кешечә сөйләшә башладылар. Хәзер мин аларның исемнәрен хәтерләмим инде. Шунысы истә калган: сөйләүләренә караганда, икесе дә Сталинград өлкәсендәге бер татар авылыннан иделәр. Сталинград өлкәсендә татар авылларының барлыгы турында ишеткәнем дә юк. Әлеге татарларның берсе, мине сүгә үк башлады: «Кирәк бит шулкадәр надан булырга?» — диде. — Кайчандыр Идел буенда урысларның эзе дә булмаган, төрки халыклар яшәгән. Хәзерге Сталинград урынында бөтен дөньяны тетрәткән Алтын Урда дәүләтенең Сарысу исемле шәһәре урнашкан. Революциягә кадәр, аннан соң да әле аны руслар Царицын дип атап йөрткәннәр...»

Тора-бара без өч татар дуслашып киттек. Алар әле күптән түгел әсир төшкәннәр. Шактый нык иделәр. Минем дә хәлем яхшыра башлады. Шешләрем бетеп, температурам нормальләште булса кирәк. Тамагыма каба башладым. Берничә көн элек баланданың исен дә исни алмый идем, укшыта иде.

1943 елның февраль башында, безне, үз аягы белән йөри алучы әсирләрне сафка тезеп, лагерьдан алып чыгып киттеләр. Шәһәр урамнарын тутырып хәрбиләр йөри, машиналар, авыр туплар өстерәп йөрүче тягачлар туктап тора. Гигант «бөкеләр» барлыкка килгән. Артка да, алга да китә алмыйлар. Тротуарда ат җигелгән олаулар тезелеп, җәяүлеләргә юлны япканнар. Аякларын көчкә өстерәп баручы безгә — әсирләргә юл ачарга теләп, йөкләрне ишегалларына куып кертә башладылар. Бу йөкләр барысы да румын армиясенеке иде.

Без чигенгәндә немецләр шушындый «бөкеләр»не сагалап кына торалар иде. Тәрәзә рамына охшаган самолетлары, сәгате-минуты белән килеп җитеп, гаскәр тупланган урынның төгәл координатын кирәкле урынга хәбәр итә. Менә шуннан соң башлана инде мәхшәр... Җир тишегенә керерлек була идек. Безнекеләр нигә йоклап ята? Һаман әле бездә самолетлар юк микәнни соң? Һавадан һөҗүм итеп, дошманның күпме гаскәрен сафтан чыгарырга була монда. Мөмкинлектән файдалана белмиләр. Йөрәк ачыйгысы белән мин шул турыда уйлап баш ваттым.

Безне тимер юл кырыена алып килеп, җиргә утырттылар. Димәк, ашыгыч рәвештә кая да булса күчерәләр. Фикеремне раслап, күршемдә утыручы әсир сүз башлады: «Сталинградта фашистларның арт сабагын укытканнар. Күзләренә ак-кара күренми, драпают», — диде. Ул соңгы сүзләрне зур горурлык белән әйтте. «Хәзер безнең урамда бәйрәм». Мин бернәрсә аңламыйча күршемә карап тора башладым. Аның күзләре генә ялтырап тора. Башын ияк астыннан урап, иске киндер кисәге белән бәйләгән. Минем ул сөйләгән яңалыкны ишеткәнем юк иде. «Аңлатыбрак әйт әле, ничек арт сабагын укытканнар?» — дип сорадым. Ул арада без утырган турыга товар вагоннарыннан төзелгән состав килеп туктады. Әсирләрне ашыктырып, вагонга төяргә тотындылар. Шулкадәр ашыктыралар, вагонга менәргә хәле булмаганын атып үтерәләр. Бертуктаусыз мылтык шартлый. Актык көчемне җыеп вагонга үрмәләдем. Анда утырып торырлык урын калмаган иде, аягүрә баскан килеш бер-берсенә тотынышып кына торалар. Мин вагонга соңгы кеше булып мендем. Ишек шартлап ябылды, аркам белән шул ябык ишеккә терәлдем. Күп тә үтмәде, поезд кузгалды. Вагоннар бер-берсенә бәрелеп, башыбыз түшәмгә тиярлек итеп сикертте. Тынны кысып, сасы ис таралды. Эче китеп авыручылар баскан урыннарында хаҗәтләрен үтәргә тотындылар.

Поезд бик акрын бара. Еш кына тукталып тора. Бер тукталышта вагон ишеген ачып, өшегән чөгендер бирделәр. «Кеше башына берәр чөгендер, артыгын алмагыз», — дип кисәттеләр. Бу вакытта күпчелек

әсирнең өшегән чөгендерне ашау түгел, кулына тотып торырлык та хәле юк иде. Мин чөгендер кулыма эләгү белән кимерергә тотындым. Чөгендер баллы иде. Ашауны озаккарак сузу теләге белән мин аны конфет кебек суырып маташтым. Чөгендернең бетүен сизми дә калдым. Тамак туймады, әлбәттә. Тагы да ныграк ашыйсы килә башлады.

Миңа тотынган әсирнең басып торырлык хәле калмады, егылды. Аягына бастырырга теләп, кулын тоттым. Кулы боз кебек салкын, ул дөнья белән исәп-хисапны өзгән иде инде.

Кичкә таба үлүчеләр саны тагын да күбәйде. Алар берсе өстенә берсе егылып, басып торырлык урын калмады. Мин мәет өстенә утырып торырга мәҗбүр булдым. Тирә ягым үлекләр һәм аңын югалтып, хәлсезләнеп ятучылар белән тулып, сөйләшерлек кеше дә калмады. Беләм, минем аяк астында аунап яткан берничә кеше әле үлеп җитмәгән. Өзгәләнеп эндәшеп карадым, җавап булмады.

Поезд ташбака адымы белән бара. Бик еш туктап тора. Кайчагында тышкы якта сөйләшкән тавышлар ишетелә. Ләкин нинди телдә сөйләшүләрен аерып булмый иде. Без бик озак бардык. Минем исәбемчә, кимендә биш көн үткәндер. Юлда барганда немец үзләренә хас булган төгәллеккә тугры булып калды. Көн саен вагонга 80 данә өшегән чөгендер ыргыттылар. Бу сан Горловкадан киткәндә вагонга ничә кеше утыртылган, шуңа тәңгәл килә. Әмма вагон әһелләренең күбесенә чөгендернең кирәге калмаган иде инде. Тик мин генә аларның чистарагын сайлап, кимереп маташтым. Ничек кенә булмасын, чөгендер капкалагач, котырып ризык сораган ашказаны бераз тынычланган кебек була иде.

Ниһаять, юлга чыкканга бер атна чамасы вакыт узгач, эшелон нарат урманы эченә килеп туктады. Тәүлеккә якын безнең белән кызыксынучы булмады. Мин шушында, салкын вагон эчендә җан бирергә җыенган идем инде. Көтмәгәндә шатыр-шотыр килеп ишек ачылды һәм, раус — чыгарга, дигән команда яңгырады. Ваган эчендәгеләрдән беркем дә урыннан кузгалмады. Бары мин генә үлекләр өстеннән үрмәләп, ишек кырыена килеп егылдым. Аягымнан өстерәп җиргә төшерделәр. Хәтерем алдамаса, вакыт март урталары иде бугай. Кояшлы көн иде. Мин өмсенеп тирә-якны күзәттем. Безнең эшелон туктаган урын чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган иде. Шунда гына ике катлы бүрәнәдән эшләнгән бараклар тезелеп киткән. Алар тирәсе аерым, үрмәкүч оясы кебек иттереп чәнечкеле тимерчыбык белән уралып беткән. Калганнарның тавыш-тыны юк иде. Башка вагоннарда да шул безнеке кебек хәл иде. Һәркайсында, күп дигәндә, биш-алты адәм исән калган. Аягына басып тора алучыларны бергә җыеп санадылар да ишегалдына куып керттеләр. Яңа китерелгән тоткыннарны күреп булса кирәк, берәмберәм бaрактан чыга башладылар. Минем янымa, тырпаеп торган кызыл мыеклы, күзләре тонып эчкә баткан, бөкересе чыгып кечерәеп калган бер кеше килде. Аның башындагы пилоткасы яртылаш янган. Шул янган турысын тимер-чыбык белән эләктереп куйган. Ул беренче сүзе итеп безне кайдан алып килүләре турында сорады. Урысчаны ватып-сындырып сөйләшә иде. Мин аннан: «Син татармы әллә?» — дип сорадым. Аның йөзе яктырып китте. Татар икәнемне белгәч, туганын очраткандай шатланды. Өстәвенә, якташлар да булып чыктык. Ул Әтнә районының мари кырыендагы Ары дигән авылыннан иде. Исмәгыйль исемле. Минем әтием дә чыгышы белән шулар күршесендәге Яңа Шимбер дигән авылдан бит. Арыда безнең туганнар бик күп. Ел саен, җәй көннәрендә без ул авылга кунакка бара торган идек. Ары табигатьнең матур җиренә — урман кырыена урнашкан. Авыл уртасында зур күл бар. Бабай — әтиемнең әтисе Арыда туып, Кышкар мәдрәсәсен тәмамлагач, Яңа Шимбергә имам итеп тәгаенләнгән. Минем әтием Олы Мәңгәр мәдрәсәсендә укып, Кушлавыч авылына мулла булып килгән. Яңа Шимбердә әтиемнең бер-

туган энесе Зәки, Арыда бертуган сеңлесе Галиянең ире Кашиф тә мулла булып хезмәт итә иде. Кашиф җизни безгә азрак туган тиешле дә иде. Яңа танышым Исмәгыйль абый минем туганнарны белә булып чыкты. Хәтта минем бабам Яңа Шимбер мулласы Мөхәммәтгали хәзрәт белән аралашып яшәгән. Бу лагерьга Исмәгыйль абыйны ел башында Харьковтан китергәннәр икән. Ул әсирлеккә кырык беренче елны Запорожье шәһәре өчен барган сугышларда эләккән. Без аның белән бер тирәдәрәк сугышып йөргәнбез. Аның сөйләвенә караганда, кырык беренче елны әсирләргә бөтенләй ашарга бирмәгәннәр. Билгеле бер урынны чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алганнар да, ачык һавада тотканнар. Ул бик бетерешкән, бармак белән төртсәң егылырга тора. «Мин озак яши алмам,— диде ул авыр сулап,— исән-сау илгә кайтсаң, безнең авылга барып, хатыныма, кызыма Славута лагеренда бергә булдык дип сөйләрсең. Минем кызым авыл советында налог агенты булып эшли.» Хатынының, кызының исемнәрен дә әйткән иде, хәзер инде хәтерләмим. Мин бик теләсәм дә, Исмәгыйль абыйның әманәтен үти алмадым. Заманы шундый иде. Әгәр, Исмәгыйль абыйның әсирлектә булуын хәбәр итсәм, аларга зыян китерүдән курыктым. Шулай итеп, Исмәгыйль абый алдында бурычлы булып калдым.

Славута лагерында без Исмәгыйль абый белән айга якын бергә яшәдек. Монда хәрби шәһәрчек булган. Ул күптән патша заманында ук корылган. Бараклар, гаскәр тотар өчен, бөтен җаен китереп эшләнгән. Немецлар бу хәрби шәһәрчекне әсирләр лагерена көйләгән. Ул төрле зоналарга бүленеп беткән. Зоналар бер-берсеннән чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндерелеп алынган һәм электр тогына тоташтырылган. Өстәвенә, койма буйлап бозау зурлыгындагы овчаркалар йөреп тора. Бу кадәр каты режим урнаштыру кемгә кирәк булгандыр, анысын белә алмадым. Безне китергәндә, мондагы әсирләр аякларына көчкә басып торалар иде. Тагын шунысы да әйтеп үтәргә кирәк: көн саен эшелон белән әсирләр килә һәм, шул эшелонга төяп, мәетләр алып китәләр. Аларны кая илтеп ыргыта торганнардыр, белүче юк иде. Халык бертуктаусыз кырыла. Адым саен үлгән адәм баласы аунап ята.

Лагерьда күсе бик күп иде. Баракта, ишегалдында көтүләре белән чабып йөриләр. Халык арасында кайбер әсирләр күсе тотып ашыйлар икән дигән хәбәр таралды. Хәтта бер тоткынга бармак белән төртеп күрсәттеләр. Булса да булыр, ул үзенең кызыл чырае, көр тәне белән башкалардан аерылып тора иде.

Беркөнне татар милләтеннән булган әсирләргә сафка тезелергә әмер булды. Аннан кат-кат санадылар да урман эчендәге аланлыкка алып чыктылар. Башка зоналардан да татарларны сафка тезеп, шушында китерделәр. Бөтенесе йөзгә якын кеше җыелдык. Алан уртасында берничә хәрби әтәч кебек кукраеп басып торалар иде. Әллә инде әсирләрнең хәлсезлеген күреп, теләгән кешегә чүгәләп җиргә утырырга рөхсәт иттелде. Халык тынычлангач, бер чулак фельдфебель карлыккан тавыш белән нәрсәдер сөйли башлады. Тылмач аның сүзләрен тәрҗемә иткәч шул аңлашылды: безне монда йөгертеп карарга алып чыкканнар икән. Бу хәбәр күңелләрдә шөбһә тудырды. Яшен тизлегендә йөгерергә хәле булмаган тоткынны аталар икән дигән хәбәр таралды. Ярты чакрым чамасы җир йөгереп үтәргә кирәк иде. Без Исмәгыйль абый белән бер-беребезгә тотынышып сафка бастык. Бер унтер акырып-бакырып безне аерды. «Ферботен!» — диде, ягъни тотынышып йөгерү тыела. Көчхәл белән дүрт-биш метр җир узгач, артыма борылып карадым. Исмәгыйль абый бер-ике адым атлаган да йөзтүбән капланган иде. Аны күтәреп торгызырга чамалап кире борылуым булды немец артыма типте. Күзалдым караңгыланып, чак аякта басып калдым. Исмәгыйль абыйга ярдәм итәргә рөхсәт булмаслыгын аңлап, алга теркелдәдем. Мең җәфа

чигеп билгеләнгән араны узгач, борылып Исмәгыйль абый ятып калган урынга карадым. Ул анда юк иде инде. Аны тере килеш мәет ыргыта торган чокырга ташлаган булулары бик ихтимал... Мин Исмәгыйль абыйдан ничә яшьтә булуын сорарга өлгермәдем, кыяфәтенә караганда илле тирәсенә якынлашып килә иде булса кирәк. Шулай итеп, якташым сөекле хатынын, бердәнбер кызын күрә алмый Славута хәрби шәһәрчеге янындагы нарат урманы эчендә ятып калды. Ул көннәрдән соң ярты гасыр гомер узуга карамастан, тырпаеп торган кызыл мыегы, уйчан серле күз карашы һаман күз алдымнан китми.

Безне, ягъни йөгереп уза алган әсирләрне, урман эчендәге юл белән җәяүләп алып киттеләр. Озак бармадык, урманны чыккач, алда кечкенә шәһәрчек күренде. Шул шәһәр кырыендагы лагерьга китереп яптылар. Лагерь зур түгел. Тоткыннарны бертуктаусыз алыштырып торалар икән. Без килгән көнне дә бер төркем әсирләрне каядыр озаттылар. «Монда озак тотмыйлар!» дип алар әйтеп калдырды. Соңыннан беленгәнчә, монда үзенә күрә пересыльный пункт булып чыкты. Шәһәрчек Шепитовка дип атала, тимер юл станциясе дә шул исемдә.

Лагерьда, башлыча, Урта Азия халыклары — үзбәкләр җыелган иде. Алар төркемнәргә бүленеп утырганнар да отыштан карта уйныйлар. Банкка паекка бирелгән икмәк, тәмәке төпчеге салына. Карталар кулдан ясалган. Банкирга картаны кулга тотарга рөхсәт ителми. Колода өстәл өстенә куелган. Уенга катнашучы картаны шуннан ерәмтекләп тартып ала. Сөйләүләренә караганда, уенда катнашучыларның кайберләре бармаклары белән чослап нинди карта киләсен белергә сәләтле, имеш. Мин бик кызыксынып, көне буе карта уйнаучыларны күзәттем. Гади генә күзәтү түгел, уенга кушылырга теләп күзәттем. Ләкин банкка салырлык бер нәрсәм дә юк иде.

Икенче көнне, паекка бирелгән кәгазь калынлыгы икмәккә карап тордым да, ни булса да булыр дип, уенга утырдым. гаҗәпләнүемә каршы, ота башладым. Биш мәртәбә рәттән очко булды. Үзбәкләр хафага төштеләр һәм миңа кырын күз белән карый башладылар. Мин бәладән башаяк дип, үземнең хәләл бер паек икмәгемне калдырдым да отып алган ун паек икмәккә суктым. Тагын очко. Бусы инде бөтенләй көтелмәгән хәл булды. Минем алда бөтенесе ике бөтенгә якын икмәк җыелды. Уеннан чыгарга гына кирәк югыйсә... Ярамый. Шулай да, откан икмәкне капкалап алырга рөхсәт ителә икән. Мин тиз генә бер паек икмәкне бөгәрләп авызга тыктым. Миңа нинди юл белән булса да тизрәк уеннан чыгып ычкынырга кирәк иде. Үч иткән шикелле һаман очко җыела. Уенчылар кызып, нишләргә белми башлады. Бертуктаусыз карта колодасын бутап бактылар, нәтиҗәсе булмады. Отаммы, отам.... Негр төсле кап-кара йөзле бер үзбәк мине сихерчелектә гаепләргә маташып карады. Аңа ирек бирмәделәр. Банкротларга уенны дәвам иттерер өчен әҗәткә икмәк, тәмәке төпчеге биреп торуым белән халыкның симпатиясен яуладым булса кирәк, барысы да минем яклы иде. Уенны карап торучы берәү миңа яхшылык теләп: «Шашынма, шашынма, нугай. Кулың китә, күр дә тор. Отыш тан карез бирү ярамас». Аның киңәше бер колагымнан керде, икенчесеннән чыкты. Елмайдым гына. Миңа тизрәк уеннан чыгарга кирәк иде. Киңәш бирүче хаклы булып чыкты. Төштән соң мин оттыра башладым. Беренче алган картаның нинди булуына карамастан, банктагы барлык «байлыкка» сугып, оттырып та бетердем. Әҗәткә тараткан икмәк, тәмәке төпчекләрен сорап тормадым, иркен сулап, урнымнан тордым һәм ишегалдына чыктым. Чәнечкеле тимерчыбык аша тышкы якны күзәттем. Анда, гадәттәгечә, тормыш кайный. Тимер юлдан бертуктаусыз хәрбиләр төялгән эшелоннар үтә. Шулай дөньямны онытып, урамны күзәтеп торганда, лагерь капкасыннан бер төркем әсирләрне алып керделәр. Бар да яхшы киенгән, тазалар. Аркаларына күтәрә алган кадәр капчык асканнар. Арадан берсе туры минем янга килеп басты. «Әнәс, бу син түгелме соң?» Сорау мине аптырашта калдырды. «Мин Иске Җөлбинең

Таhир булам. Көрәшче Хөббулла малае». Искә төшерә алмавымны сизеп, ул сүзен дәвам итте: «Өммегөлсем белән Югары Сәрдәдә бер класста укыдык. Ул миңа синең шигырь китабыңны бүләк итеп биргән иде» . Өммегөлсем минем бертуган сеңлем. Әйе, ул да Югары Сәрдәдә укыды шул. Авылда чакта Таhирның үзен күргәнем юк иде. Ә атасы Хөббулла абыйны яхшы беләм. Арслан кебек таза ир. Хәтта әнисен дә хәтерлим. Иске Җөлби белән Кушлавычны инеш кенә аерып тора, икесе бер авыл дип әйтерлек. Яше-карты бер-берсе белән аралашып яшиләр. Мин дә Иске Җөлби халкының барысын да беләм дип әйтерлек. Сөйләшә торгач, Таhирны да искә төшердем. Ул миннән ике яшькә кече — егерме икенче елны туган.

Таhир мине читкәрәк алып китте. «Әйдә, утырма бу адәм актыклары янында,— диде җитди кисәтеп.— Миңа бер үзбәк сөйләгәне бар. Алар халкында отышка карта уйнау модада икән. Кайсы берләре чүлгә китеп, айлар буе карта сугып яталар, ди. Хәтта картага хатыннарын да оттырып кайтучылар бар икән». Таhир, капчыгын чишеп, бер бөтен икмәк һәм сало чыгарды. Икмәкнең хуш исенә башым әйләнеп, егылып китә яздым. Ул зур бер телем икмәк кисте дә миңа сузды. Мин алырга да, алмаска да белмәдем. Монда, лагерьда шушы икмәктән дә зур байлык юк иде. Авылдашым булуына карамастан, шундый иң кадерле әйберне бушка тоттыруына ышанып бетә алмадым. Ул пәке белән сало турады: «Аша, аша, гөнаһ дип торып булмый, бу шундый җир, нәрсә туры килсә, шуны авызга мүкләргә туры килә» . Күренеп тора, Таhир без күргәннәрне күрмәгән иде әле. Мин аны яңа гына әсирлеккә эләккән дип уйладым. «Ничек анда, безнең якта хәлләр?» — дип сорадым. Ул минем соравымны аңлап бетермәде. «Шуңа әйтүем, син бу якта күптән түгел, минемчә...» Ул елмайды да, кыскача гына башыннан үткәннәрен сөйләп бирде. Кырык бердә, Белоруссиядә әсирлеккә төшкән. Берничә армия чолганышта калган. Бәхетенә дип әйтимме, аңа әлегә кадәр әсирләр лагерында яшәргә туры килмәгән. Аларны Латвиядә яшәүче немец крестьяннарына таратканнар. Хезмәт җиңел булмаган, әлбәттә. Бер таңнан, икенче таңга кадәр камчылап эшләткәннәр. Әмма ач та булмаганнар. «Немецнең Сталинградта арт сабагын укытканнар,» — диде Таhир шатланып.— Хәзер бөтен фронт буйлап сыпырталар. Шуңа күрә, менә, ашыгыч рәвештә крестьянга таратылган әсирләрне җыялар. «Таhир Кызыл Армиянең тиз арада безне азат итүенә чын күңелдән ышана иде. Аның бөтен теләге, армия сафына басып, дошман белән көрәшне дәвам итү икәне әллә каян күренеп тора.

Безнең сүзебез сөйләшеп кенә бетә торган түгел иде. Авыл, анда яшәүче кешеләр шулкадәр сагындырган, урамның бер башыннан кердек, икенче башыннан чыктык, яңа туган балаларга кадәр искә төшердек. Әңгәмәнең үзәгендә, авылыбыздан өч чакырым ераклыктагы, үзебез укыган Югары Сәрдә мәктәбе булды. Без анда, яңгыр димәдек, буран димәдек, өч ел буена көн саен барып йөрдек. Җиденче сыйныфны тәмамлап, кулыбызга өлгергәнлек аттестаты алдык. Укытучыларыбызны шулкадәр хөрмәт итә идек, безгә алардан да акыллы, алардан да белемле кеше дөньяда юктыр кебек иде. Үз чиратларында алар да укучыларын чын күңелдән олылап, бар белгәннәрен безгә бирергә тырышалар иде. Күбесенең махсус педагог белемнәре дә булмаган, мәдрәсә тәмамлагач укытучы булып эшли башлаганнар югыйсә. Шактый еллар үткәч, педагогия институтын бетереп эшкә керешкән укытучыларның эшен күзәтеп, мин шундый нәтиҗәгә килдем: минем укытучыларым практиклар һәм педагогиканың бөтен нечкәлекләрен белеп балалар тәрбияләләр, белем дәрәҗәләре ягыннан да хәзерге педагогларга бирешә торган түгелләр иде. Без аларга үзебезчә, саф татарча «абый» дип мөрәҗәгать итә торган идек. Фамилияләрен сорау турында башыбызга да килеп карамады.

Әхмәт абый, Сапый абый, Хөҗҗәт абый — соңгысы безнең як кешесе түгел, шуңа күрәдерме, исеме бераз ят тоела иде, тора-бара ияләндек тагын. Алтынчы сыйныфта укый башлагач, Казан педагогия техникумын тәмамлаган Әнвәр абый, Хәсән абый һәм Абдулла абыйлар укытучы булып килделәр. Болары үзләрен бөтенләй башкача тоталар һәм картлардан аерылып торалар иде. Абдулла абый керәшен егете иде. Чын исеме ничек булгандыр, белмим. Әнвәр абый татар теле һәм әдәбиятыннан дәрес бирә иде. Ул минем Такташ шигырьләрен яттан сөйләгәнне ярата һәм башка балалардан да минем кебек итеп сөйләгәнне таләп итә иде. Югары Сәрдә авылы клубында концерт булганда, мине үзе белән шул концертка алып кереп, «Мокамай»ны сөйләтә иде. Бу турыда Таһир да белә икән. «Без синең шигырь сөйләгәнеңне сокланып тыңлый торган идек»,— диде. Тагын авылга кайтып булырмы, дип өзгәләнде ул. Бераз алгарак китеп булса да әйтим, Таһир авылга кайтты. Миннән соңгарак калып кайтты. Мин кайтканда әти-әниләре улларының язмышын белмиләр иде әле. Мин әсирлектә аны күргәнемне әйтергәме-әйтмәскәме дип куркып йөрдем. Шушы очрашудан соң аерылгач, башыннан үткәргәннәрне белми идем. Исән калгандырмы, юкмы. Әгәр, исән булмаса, аның белән очрашуымны сөйләп, төзәлә барган яраларын яңартудан курыктым.

Шепотовка лагерында Таһир белән бер генә кич бергә кундык. Безне — Славута лагереннан алып килгән әсирләрне — станциягә алып барып, товар вагоннарына төяделәр. Иң сәере шул булды: вагонга утыртыр алдыннан һәр тоткынга тугыз йөз грамм консерваланган икмәк, ярты шар кило булыр, какланган тозлы ат ите һәм өчәр сигарет бирделәр. Шушы ашамлыкларны кулыбызга тоткач, күзләребезгә ышанмадык. Котыртыр өчен генә биргәннәрдер, менә-менә кире җыеп алырлар төсле тоелды. Кемдер күңелебездә туган шикне дөрләтеп: «Җәмәгать, биргән чакта ашап калыгыз, немецкә аңа ышаныч юк»,— дип кычкырды. Күбебез аның киңәшенә мохтаҗ түгел, нәрсә эшләргә икәнен белә идек. Минут эчендә икмәк белән тозлы ат итен юк иттердек. Газабы озак көттермәде. Эчәсе килүнең ачлыктан да яманрак икәнен шунда гына белдек. Вагонда суның тамчысы да юк иде. Әсирләр нишләргә дә белмәде. Күрше вагоннарда да шул ук хәл икән. Бөтен эшелон буйлап, су сорап ишек дөбердәтергә тотындылар. Озата баручы сакчылар һавага атып җавап бирделәр. Көн азагына таба вагон эчендә аңын югалтып, хәлсезләнеп ятучыларның исәбе юк иде. Кайберәүләр бәвелләрен эчәргә теләп, тышка чыгарга тырышып карадылар. Бөтен кешенең эче кипкән иде. Минем дә хәлем бик мөшкелләнде. Ничек кирәк алай ишек янына елыштым. Андагы ярыктан поезд барган уңгайга җил өреп, бераз хәл кертә иде. Төнлә, безне төягән эшелон, ниндидер станциягә килеп туктады. Паровоз, эшелонны калдырып, китеп барды. Иртәнгә кадәр әсирләрне вагонга бикләнгән килеш тотылар. Ниһаять, таң атып көн яктырды. Мин ишек ярыгыннан, станциядәге бер бинаның почмагына эленгән вывесканы күреп алдым. Анда латин хәрефләре белән «Ирина» дип язылган иде.

Бикле вагоннарда тилмерүче тоткыннарның аһ-зарына игътибар итүче булмады. Ниһаять, көтә торгач тышкы якта сөйләшкән тавышлар ишетелде. Шатыр-шотыр вагон ишекләрен ача башладылар. Безгә дә чират җитте. Вагоннан үз аягы белән бары унлап кеше төшә алды. Без вагоннан төшкән турыда колонкалар тезелеп киткән иде. Халык этешә-төртешә шунда ябырылды. Минем мунчала белән бәйләп билгә асып йөри торган, күгәреп бөткән ике литрлы калай котелогым бар иде. Шуның белән тутырып өч котелок су эчкәнемне хәтерлим, башкасы исемдә калмаган, аңымны югалтып егылганмын. Шактый озак җирдә аунап яткан булсам кирәк, күземне ачканда кояш югары күтәрелеп, төш вакыты җитеп килә иде инде. Минем кебек аңын югалтып, җирдә аунап

ятучыларның исәбе-хисабы юк иде. Аягына баса алучыларны акыра-бакыра сафка тезделәр дә, станциядән алып чыгып киттеләр. Зур су кырыена урнашкан, калын таш коймалы, сәер корылма янына алып килделәр. Койма өстеннән чәнечкеле тимерчыбык сузылган. Вышкаларда автомат белән коралланган сакчылар тора. Койма буйлап, ике-өч метр ара калдырып, җирдән дә чәнечкеле тимерчыбык үткәрелгән. Безне тимер капка янына бастырып кат-кат санадылар да эчкә алып керделәр. Ишегалды шактый киң һәм зоналарга бүленгән. Яңа китерелгәннәрне күреп, андагы әсирләр чәнечкеле тимерчыбык коймага ябырылдылар. «Казаннар бармы? Кемнәр Уфадан? Әстерханнан кем бар?» һәм башка шундый татар күбрәк яши торган төбәкләрнең исемнәрен атап кычкыра башладылар. Һәркайсы яңа килүчеләр арасыннан якташын эзли һәм туган җире турында нинди булса да яңалык ишетергә тели иде. Минем үзебезнең нинди җиргә килеп эләгүебезне беләсем килде. «Бу нинди ил? Лагерьның исеме ничек?» — дип кычкырдым. Телгә ятышсыз, «Демблин крепосте» дигән сүзне ишетеп аптырап калдым. Әйе, безне еракка, үзебезнең илдән читкә алып чыгып киткәннәр. Демблин крепосте Висла елгасы буенда, Польша җирендә. Урта гасыр корылмасы. Шундый итеп төзегәннәр, янына килеп җитмичә күренми. Һәр ягыннан Висла суы белән чолганган, җир өстеннән бер ничек тә якын килү мөмкин түгел. Урта гасыр феодаллары крепость төзү өчен урынны белеп сайлаганнар. Ишегалдына чуер таш җәелгән. Теләгән кешегә утырып торырга рөхсәт бирелде. Мин көчкә басып тора идем, һаман сусаганым басылмый, эчем яна. Утырып биш минут та үтмәгәндер, тәнемне нәрсәдер тешли башлады. Карасам, бөтен җиремне борча сырып алган. Борча тешләгән урыннар бүртеп чыга, шундый авырта, чыдар хәл юк. Кайда ул утырып тору, үрле-кырлы сикертә. Ишегалдында озак тотмадылар, каршыдагы ике катлы таш бинага алып керделәр. Анда ярым җимерек, икешәр катлы сәкеләр тезелеп киткән. Бинага керү белән күзем штукатурланган стенага төште. Стена төрле язулар белән чуарланган, күрәсең, монда булган тоткыннарның һәрберсе үзенең автографын калдырырга тырышкан. Язмаларның нинди телдә генә юк. Димәк, монда төрле милләт халыкларына интегергә туры килгән. Тора-бара белдем, әле дә бездән шактый читтә — уң якта, бер зонада француз әсирләре тотыла икән. Кызыл Хач җәмгыяте аша посылка алганлыктан, аларның тормышлары шактый иркен, немец биргән ашны ашамыйлар, бәрәңгеләрен койма аша совет әсирләренә ыргыталар иде.

Бина эчендә халык берән-сәрән генә, ишагалдына чыгып йөрергә хәле булмаганнар гына ятып калганнар. Мин дә хәлсезләнеп сәке кырыена барып утырдым. Утыруым булды, тагын борча тешләргә тотынды. Борча белән чәбәләнгәнемне күрептерме, яныма ике егет килде. Берсе сүз башлап: «Нәрсә, сикертәләрме?» — дип сорады. Мин җавап бирмәгәч, икенчесе: «Безнең халык түгел бугай ул, татарча аңламый торгандыр», — диде. Чыннан да, мин тышкы кыяфәтем белән татар кешесенә охшамаган идем. Билгә җиткән кызыл сакал, өстемдәге сәләмәләр карачкыны хәтерләтә. Башымда бер кырые янган пилотка, өстә ялан тәнгә кигән кендектән генә калган шинель-итәкләрен берничә мәртәбә кисеп кукуруз чәкәненә алмашкан идем. Ертык чалбарымнан тез башлары күренеп тора. Аякларымның берсендә агач колодка, икечесендә Донбасс шахтерлары эшкә кия торган резин галош. Йөргәндә төшеп калмасын өчен алар аякка тимер чыбык белән беркетелгән. Кулларым җир кебек кап-кара. Эчәргә дә су такы-токы булганлыктан, әсир төшкәннән бирле юынганым юк. Бармакларымның буыны саен шеш. Ниһаять, мин телгә килеп: «Аңлыйм, аңлыйм, татар мин», — дидем. Аларның өс-башлары чиста, сакал-мыеклары кырылган, куллары да минеке төсле шешле түгел, кыскасы, бар да кешечә... Сөйләшә торгач шуны ачыкладым, бу егетләр икесе дә Саба ягыннан иде. Берсе Мәлик, икенчесе Хәлим исемле. Әсирлеккә Изюм-

Барбенково юнәлешендә эләккәннәр. Шактый вакыт Чонстахов шәһәре янындагы лагерьда булганнар. Монда шуннан китергәннәр. Икесе дә минем кебек, сугыш алдыннан чираттагы чакырылыш белән алынып, кадровый армиядә хезмәт иткәннәр. Яшьтәшләр булып чыктык. Мәлик исемлесенең битендә әзрәк шадрасы бар. Җор телле. Уен-көлке ярата. Әтисе оста тегүче икән. Иген эшләре тәмамлангач, кыш көннәрендә авылдан авылга йөреп тегү теккән. Мәликне дә үзе белән ияртеп алып йөргән. Ул тормышның эчендә кайнаган, һәм бик күп мәзәк хәлләр белән якыннан таныш иде. Хәлим киресенчә, бөтен гомерен туган авылында, ата-анасы янында үткәргән. Җиде сыйныфны тәмамлагач, артык укырга туры килмәгән. Сәбәбе, якын тирәдә урта мәктәп юк икән. Ул үзенә күрә түгел, бик җитди, һәр сүзен үлчәп сөйләшә.

Монда, Демблин лагеренда, тормыш чагыштырмача бераз яхшырак икән. Ашарга көн саен 4 кешегә 900 граммлы икмәк һәм кабыклы 4-5 бәрәңге бирәләр. Бу ризык ачлыкка интеккән тоткыннарның тамагына да йокмый иде, әлбәттә. Тагын шунысы, суны күпме телисең, шулкадәр эчәргә мөмкин. Хәтта, юынырга да була... Озак кына суга күнегә алмый алҗыдым. Бер бизгәч, суның һәр тамчысы тәнгә тию белән энә кадалган кебек итеп авырттыра икән.

Безне, бер төркем әсирләрне бәрәңге чүпләргә алып йөри башладылар. Бәрәңге базы крепостьтан читтәрәк, тимер юл станциясе кырыенда иде. Эшкә ике немец солдаты саклап илтә, саклап алып кайта. Соңгы вакытта үзләренә ярдәмгә берничә полицайны ияртә башладылар. Моны шуның белән аңлаттылар: бәрәңге чүпләргә барган җирдән ике тоткын качкан. Полицайлар артка борылып карарга да ирек бирмиләр, овчарка кебек ыжгырып кына торалар. Бәрәңге чүпләргә тоткыннар теләп йөри иде. Чөнки эштән кайтканда ыштан бөрмәсенә берничә бәрәңге кыстырып кайтып була. Ләкин бәрәңге пешерергә һич җай юк иде. Кишер, чөгендер, шалкан һәм башка яшелчәне чи килеш кенә ашыйсың. Бәрәңгене пешерми авызга да алып булмый. Уып, өстенә көн дә бирелә торган кайнар баланданы да салып карадык. Алай да ашарлык булмады.

Ишегалдында, без яши торган бина кырыенда бер чокыр бар иде. Бу чокырга Мәлик игътибар итте. «Әгәр шунда төшеп бәрәңге пешерсәк, ничек булыр икән?» — диде ул. Бу фикер барыбызның да күңеленә хуш килде. Өстән караганда чокырның төбе күренми. Кырыена асылынып аякны сузып карадык, төбенә тимәде. Чокырга бауга тотынып төшеп карамакчы булдык. Бау таба алмагач, өстән күлмәкне салып, җиңнәреннән бер-берсенә бәйләдек. Ике күлмәк белән генә эш барып чыкмагач, дүртне бергә ялгарга туры килде. Тәвәккәлләп, чокырга мин төштем. Чокыр эче караңгы, күзгә төртсәләр дә күренә торган түгел. Сизәм, аяк астында төрле чүп-чар бик күп. Чакма таш белән мамыкка ут үрләтеп, коры чырага кабыздым. Өстән тиз генә мин ябышып төшкән бер-берсенә тоташтырып бәйләнгән күлмәкләргә беркетеп бәрәңге тутырылган котелокларны бирделәр. Аларны дөрләп янган чүп-чар өстенә куйдым. Чокыр эче яктырып, тирә-як ачык күренә башлады. Ләкин мин басып торган җирдән бушлыкның чиге күренми иде. Ул сөзәкләнеп һаман аска төшә. Мине чокырның төбе кызыксындырды. Төшкән килеш барысын да ачыклап менәсем килде һәм түбән таба үрмәләдем. Шулвакыт өстемә шаулап су коела башлады, кырыйга тайпылдым. Су мин төшкән җирдән, чокыр авызыннан сибелә иде. Ут өстенә куелган котелоклар, чүп-чар белән бергә каядыр, очтылар. Нишләргә белми аптырап калдым. Ничек бу тозактан котылырга? Кулым белән цемент стенаны капшап карадым. Ул шундый шома итеп штукатурланган, тотынып өскә менү турында уйларга да мөмкин түгел. Шактый озак калтырап басып тордым. Ярдәм сорап кычкырмакчы булдым. Моннан, җир астыннан кычкырган тавышны кем ишетер икән соң? Шулай да иптәшләремнең ярдәм кулы сузуыннан өметемне өзмәдем. Ялгышмадым. Өстән: «Әнәс!» — дигән тавыш

ишетелде. Мәлик мине чакыра иде. Ул арада җиннәремнән бер-берсенә бәйләнгән күлмәкләр дә төшеп житте. Шуңа тотынып, бар көчемне җыеп, өскә үрмәләдем. Менеп тә җиттем, мине ашыктырып читкә алып киттеләр. Без чокыр авызыннан китеп кенә өлгердек, бер ефрейтор ике тоткынны ияртеп килеп, чокыр тирәсен чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алды. Соңыннан шуны белдек, бәрәңге пешерер өчен яккан утның төтене комендант бүлмәсенә кереп тулган. Комендант утырган бүлмәдән бина астына юл булгандыр, шәт. Крепостьтан качкан тоткын тотылса, шушы бина астына кертеп ябалар икән.

Комендант, кем дә булса чокырга тәмәке төпчеге ыргыткан да андагы коры-сарыга ут капкан дип уйлаган һәм сүндерергә янгын машинасы җибәргән. Минем бәхеткә, янгын сүндерүчеләр чокыр эченә төшеп мәшәкатьләнеп тормаганнар, өстән сиптереп эшне бетергәннәр. Язмыш мине караңгы җир астында ачтан интегеп үлүдән коткарып калды. Шушы хәлдән соң без бәрәңге пешерү турында сүз кузгатмадык. Төрле юллар белән бәрәңге чүпләргә барудан котылырга тырыштык. Ник дисәң, көне буе юеш подвалда утыру ансат түгел!

Көн дә иртән сәгать биштә тоткыннарны сафка тезеп тикшерү үткәрәләр. Анда үрә басып, ким дигәндә сәгатькә якын каңгырап торырга туры килә. Тикшерүне немец солдаты белән полицайлар үткәрә. Бер көнне шулай, тикшерү беткәч, бер полицай мине үзе белән алып китте. Бу полицай тышкы кыяфәте белән башкалардан аерылып тора иде. Озын гәүдәле, киң җилкәле, күзләре ут уйный. Башына кубанька бүрек киеп йөри. Аякларында хром итек. Өстендә ярым хәрби кием — Кызыл армиядә комсоставка бирелә торган гимнастерка белән галифе. Аның белән немецләр дә исәпләшәләр. Башка полицайлар кебек, алар алдында ул үзен бик түбәнсетми. Башкалардан аерып сафтан чакырып чыгаргач, мин шикләнә калдым. Нинди гаебемне таптылар икән дип курыктым. Алар юкны бар итәргә бик оста. Полицай мине үзе яши торган бүлмәгә алып керде. Аңа түрдәге өч катлы таш бинаның ярым подвалыннан кечкенә генә бүлмә биргәннәр дә, ул мине бүлмәсен җыештырырга алып кергән икән. Эшне тиз тоттым. Әллә үзем, әллә эшем ошады, полицай өстәлгә литрлы шешә белән бимбер-поляк самогоны чыгарып куйды. Закускага ярты бөтен икмәк һәм кабыгы белән пешерелгән бер чиләк бәрәңге бар иде. Ул ике стакан тутырып бимбер агызды да берсен миңа тоттырды. Бимбер икебезнең дә телен ачты. Без аның белән якташлар булып чыктык. Башта ул минем кайдан икәнемне сорады. Кушлавыч авылыннан икәнемне әйткәч, аның минем белән кызыксынуы тагын да артты. «Димәк, син Тукай туган авылныкы»,— диде серле итеп.— Авылда аны күреп белүчеләр бармы?». «Бар әлбәттә. Минем әтием дә аны күреп белә. Авылның картырак кешеләре әнисен дә, әтисен дә яхшы хәтерли»,— дидем. Сүз артыннан сүз китеп, мин аның үзе турында сораша башладым. Исеме Абдул, фамилиясе Гайфуллин икән. Туган җире Дөбъяз районының Чувашиле авылы. Аның сүзләренә бик ышанып бетмәдем. Күпчелек тоткыннар кебек, ул да алдаша торгандыр, дип уйладым. Алдамаган икән. Бу турыда алдарак әйтеп үтәрмен. Гәпләшеп утыра торгач, без бер литр бимберне эчеп бетергәнне сизми дә калдык. Абдул тагын бер шешә чыгарды. Мин башка эчмәдем, күбрәк ашарга тырыштым. Икенче литрны башлагач, Абдул бөтенләй изелде. Ул миңа йокыга киткән төсле булып тоелды. Шуннан файдаланып, кызу-кызу бәрәңгене сыпырдым. Нәрсәдер, бимбер минс алмады, тамчы да исермәдем. Ә чиләктәге бәрәңгене ашап бетердем. Әйтергә генә ансат: бер чиләк бәрәңге!.. Корсагым кап кебек булып, көчкә сулап утыра башладым. Ә тамагым туймады. Өстәлдә аунап яткан ярты бөтен икмәккә күзем төште. Тәкатьсезләнеп аны да ашап бетердем. Абдул йокламаган, иркәләнеп кенә яткан икән. Ул әсәрләнеп сикереп торып утырды. Бите комач булып кызарган, күзләре мәченеке төсле ялт-йолт килә. «Чебен

кермәдеме?» — дип сорады ул. Монда немецләрне үзара татарчалатып «чебен» дип атап йөртәләр иде. «Хәзер минем яңга «чебен» керергә тиеш. Күргәннән күрмәгәне артык. Тай тизрәк. «Күзләре чиләккә төшеп: «Бәрәңге кайда?» — дип сорады. Мин аңа корсагымны тотып күрсәттем. Ул ышанырга да, ышанмаска да белмәде. «Харап буласың бит. Шаштыңмы әллә син?!» Ул өстәлдәге икмәкне эзли башлады: «Аны да син ашадыңмы? «Тиз генә тумбочкасыннан икмәкнең икенче яртысын алып миңа тоттырды да: «Бар, тай тизрәк. Бүген авызыңа ризык каба күрмә».

Минем хәл авырайган иде. Көчкә үзебезнең баракка кайтып, сәкегә түндем. Яныма Мәлик белән Хәлим килеп утырды: «Нәрсә булды сиңа? Көчкә сулыш аласың?» Мин аларга Абдул биреп җибәргән икмәкне суздым. Икмәкне күргәч, алар аптыраштa калдылар. «Бер нәрсә аңламыйм»,— диде Мәлик, бик гаҗәпләнеп. Башын кашып миңа карап торды да: «Сак бул, сине бирәр эшкә җигәргә йөрми микән ул»,— диде серле итеп. «Һей, җиккән ди! «Кашын-күзең өчен биргәндер дип уйлыйсыңмы бу икмәкне сиңа. Әләкче итәргә телидер әле!». «Тотсын капчыгын, анысы булмас инде». «Биргәннең битенә бакма диган сүз бар безнең халыкта. Әйдә капкалап алыйк әле — диде Хәлим,— алда тагын күз күрер». «Белергә кирәк, армиядә кем булып хезмәт итте икән. Безнең кебек гади солдат түгелдер...»

Мин Абдул янында булып кайтканнан соң бер-ике көн узгач, төнлә безнең бaрактан өч тоткын юкка чыкты. Аларның берсе — Попов Әхәт атлысы очучы дип сөйлиләр иде. Ул, минемчә, Попов та, Әхәт тә түгел, үзе уйлап чыгарган исем-фамилияне йөрткән булса кирәк. Озын буйлы, киң җилкәле егерме биш яшьләр тирәсендәге егет. Күпчелек тоткыннар аның белән якынаерга тырыша иде. Ләкин ул үзен бик сак тотты. Булыр-булмас кеше белән элемтәгә кермәде. Имеш, ул икенче мәртәбә әсирлеккә эләгә. Икесендә дә Варшаваны бомбага тотарга килгәч һәлакәткә дучар булган. Парашут белән сикереп исән калган. Тоткыннар арасында таралган бу хәбәр күпмегә дөрестер, анысын раслый алмыйм. Бер мәртәбә дә үзе белән сөйләшергә туры килмәде. Мин аның полицай Абдул белән дә сөйләшеп торганын күргәләдем.

Попов белән тагын ике егет юкка чыкты. Алары да бик зәһәр егетләр иде. Немецлар юкка чыккан әлеге әсирләрнең урын-җирләрен кат-кат тикшерделәр. Алар белән янәшә яткан әсирләрне комендатурага чакырып сорау алдылар. Чакырылган кешеләрнең берсен, комендатурада ни турыда сорауларын белергә теләп сөйләштереп караган идем, әйтмәде.

Безнең баракта беренче катта бәдрәф бар иде. Бәдрәф шакшысы шома итеп цемент белән катырылган канау белән Вислага агып киттә. Ул крепость корганда, урта гасырларда ничек эшләнгән булса, шулай үзгәрешсез сакланган. Канау шактый кин һәм биек, мүкәйләп кеше йөрерлек. Ул көндезләрен су белән тулып тора. Төнлә, билгеле бер вакытта суны җибәреп, канауны чистартып алалар. Мин бәдрәфкә кергәндә, Мәлик бик әсәрләнеп, шул канауны күзәтеп тора иде. «Әллә мәрткә киттеңме?» — дидем мин аңа. «Хәлләр бар монда»,— диде ул серле итеп. «Теге егетләрне шушы кану аша чыгып сызганнар, дип сөйлиләр. Ничек уйлыйсың, моннан чыгып китеп булырлыкмы?» Мин башымны чайкап, үземнең берни дә әйтә алмавымны аңлаттым. «Син игътибар иттеңме, юкмы икән, элек төнне канаудан суны җибәрәләр иде. Хәзер тәүлек буе тулып тора». Бу соравына да җавап булмагач, мине шелтәләргә тотынды: «Бигрәк ваемсыз инде син! — диде авыр сулап, кешеләр әнә безнең кебек йоклап гомерне әрәм уздырмыйлар, һәрбер мөмкинлектән файдаланып калырга тырышалар»

Беркөнне иртәнге ашка кабыгы белән пешерелгән бишәр бәрәңге бирделәр. Башка көннәрдә өчәрне генә бирәләр иде.

«Ни гаҗәптер, немец юмартлана башлады әле»,— диде Хәлим.— Әллә теге егетләр шикелле безне дә качып китәрләр дип куркалар инде. Черек бәрәңге ашатып кулга ияләштерергә маташалар бугай».

Төш вакыты житәрәк, барлык тоткыннарны ишегалды уртасына алып чыгып җиргә утырттылар. Таш җәелгән каты җирдә, коры сөяккә калган тоткыннарга утырып тору җайлы түгел иде. Өстәвенә, борча сарып алып рәхимсез рәвештә тешли. Аягүрә басарга рөхсәт ителми. Мин чыдар хәлем калмагач, чүгәләдем. Полицайның резин таяк белән иңбашыма тондырганын сизми дә калдым. Без шулай полицай белән ызгышкан арада, мәйдан уртасына бер төркем халык чыгып басты. Бар да чиста киенгәннәр: кара костюмнан, галстук такканнар, башларында эшләпә. Араларында чалма кигән мулла да бар. «Берлиннан килгән агитбригаданың концертларын башлыйбыз»,— дип татарча әйтелгән сүзләрне ишеткәч, үз колакларыбызга ышанмадык. Ничек инде Берлинда, фашистларның оясында татарның концерт бригадасы булырга мөмкин? «Хәзер, татар дәүләт филармониясе артисты Әмиров «Сәлам хат» дигән җырны башкара». Без кинәт тынып калдык. Шулкадәр тын, чебен очканы да ишетелерлек иде. Моңлы булып җыр агыла башлады. Күзләремнән яшь атылып чыкты. Күз яшен һич туктатыр хәл юк. Чишмә кебек ага да ага. Үземнең кайда утырганымны онытып, хыялымда туган авылыма кайттым. Диңгез кебек киң иген кырлары, чәчәккә күмелгән болыннар буйлап йөреп чыктым. Тирә-юньдә авылым болынында үскән чәчәкләрнең хуш исе аңкыган төсле булды. Алай гына да түгел, җаным-тәнем белән шул хуш исне сизеп утыра башладым. Шулвакыт Һади Такташның «Мокамай» дигән шигырен шагыйрь Баттал сөйли дип игълан иттеләр. Сискәнеп киттем. Шагыйрь Салих Батталның үзен күргәнем юк иде. Бары кайбер шигырьләре белән генә таныш идем. Мин аны ничек тәкъдим ителгән, шулай кабул иттем. Сурәте исемдә калмаган, йөзенең нинди булуын тасвирлый алмыйм, шунысын ачык итеп әйтә алам, башкаларга караганда озын буйлы иде. «Мокамай»ны зур дәрт белән укыды, бөтенебезгә дә бик ошады. (Мин ул вакытта зур дәрт белән шигырь сөйләгән егетнең Салих Батталның энесе Габдулла Баттал икәнен белмәдем, әлбәттә.) Тагын җыр, гармоньда, скрипкада татар көйләрен уйнау башланды. Кайбер номерларны кат-кат сорап башкарттырдык. Туган халкыбызның моңнарына бик сусаган идек шул.

Соңыннан Берлинда оештырылган «Идел-Урал» татар комитетының рәисе Шәфи Алмазга сүз бирелде. Ул тышкы кыяфәте белән башкалардан бик нык аерылып тора иде. Киеме энә-җептән генә төшкән булса кирәк, өр-яңа. Көмеш төсендәге макинтыш кигән, башында шундый ук төстәге эшләпә. Аягындагы туфлиләренең дә төсе шулар белән пар... Йөзенең нинди булуы исемдә калмаган. Ул шактый озак сөйләде. «Алман халкының даһи юлбашчысы Адольф Гитлер безгә, татарларга гасырлар буена килгән теләгебезне тормышка ашырып, үз дәүләтебезне төзергә мөмкинлек тудырды. Шул максат белән Берлинда комитет төзелде. Ул «Идел-Урал» дип атала. Комитет алдында, беренче чиратта, әсирләр лагерында ачлыктан интегүче тоткыннарны азат итеп, аларны үлемнән коткару бурычы тора. Аннан бергәләп дүрт гасыр буена урыслар кул астында газап чигүче туган илебезне — татар илен азат итүгә бөтен көчебезне юнәлтәчәкбез» — диде Шәфи Алмаз.

Ул сөйләп бетергәч, әсирләргә татарча китаплар һәм «Татар әдәбияты» исемле журнал белән «Идел-Урал» дигән гәзит тараттылар. Кулыма эләгү белән мин дөньямны онытып гәзит укый башладым. Гәзит зур форматта, алты битле, латин хәрефләре белән басылган. Анда кызыклы материаллар бар иде. Мине бигрәк тә «Татар опера театры» исемле мәкалә кызыксындырды. Аның башы узган саннарда булуы һәм дәвамы барлыгы хәбәр ителгән иде. Мәкалә азагында М. Гомәр дип имза куелган. Мәкаләне күздән үткәрү белән шунысы аңлашылды, татар опера театрының хәлен болай яхшы белеп, бары шул тирәдә кайнаган кеше генә язарга мөмкин иде. Мәкаләнең гәзиттә басылган бу өлешендә, театрның тантаналы шартларда ничек ачылуы тасвирланган иде. Бик

таныш күренеш иде бу! Чөнки мин үзем дә беренче спектакль «Качкын» операсын карау бәхетенә ирешкән идем. Гәзитнең баш редакторы минем белән бер фамилиядә — Галиев дигән кеше икән! Бу фамилия баш редактор булып кул куйган кешенең чын фамилиясе булгандырмы, анысын әйтә алмыйм. «Татар әдәбияты» журналы һәм китаплар да латин хәрефләре белән басылган иде. Китапларның берсе Шәриф Камалның «Акчарлаклар» повесте, икенчесе Һади Такташның шигырьләр җыентыгы иде. Болардан башка тагын ике шигырь җыентыгы бар иде. Авторлары миңа таныш түгел, хәзер фамилияләре истән чыккан. «Татар әдәбияты» хәзерге «Татарстан» журналы форматында, хәтерем алдамаса, 140—150 битле иде бугай. «Баш редактор профессор Солтанов», дип кул куйган иде. Журналның күп өлешен Туран дигән кешенең романы алып тора иде. Иң гаҗәпкә калдырганы тагын шул булды: әсирлеккә төшкән татар-башкорт солдатларыннан «Идел-Урал» дигән легион оештырылган, алар каядыр, Радом шәһәреннән ерак түгел, Едлино дигән тимер юл станциясе янында өйрәнүләр үтәләр һәм тиз көндә Көнчыгыш фронтка җибәреләчәкләр икән. «Идел-Урал» гәзитендә легионерларның сурәтләре дә бар иде. Аларга немец солдаты формасы кидергәннәр. Башкалардан шуның белән аерылып торалар: киемнең уңъяк җиңенә Идел елгасы фонында җәя белән ук төшерелгән эмблема тегелгән.

Демблин крепостына көн саен дип әйтерлек, әсирлеккә төшкән «Идел-Урал» регионында яшәүче чуваш, удмурт һәм мукшы милләтеннән булган халыкларны китереп торалар иде. Тора-бара, моның сере дә ачылды. Немецлар татар-башкорт «Идел-Урал» легионы исеме белән армия төзеп, аны Советларга каршы сугышка кертергә исәпләгәннәр. Кемнән генә сорама, барысы да дип әйтерлек легионга язылырга риза түгел. Ләкин беркемнән дә ризалык сорап тормадылар...

Хәлне ачыкларга теләп, мин полицай Абдул белән элемтәгә керергә тырышып карадым. Аны беркайда да очрата алмадым. Юкка чыкты. Колактан-колакка: «Абдулны кулга алганнар икән»,— дигән хәбәр таралды. Күпмегә дөрестер, имеш ул, канализация чокыры аша качкан әсирләргә булышкан. Бераз алга китеп булса да әйтеп үтим, мин аның язмышы белән туган илгә кайткач та кызыксындым. Махсус, Чуашиле авылы кешеләрен күреп сораштым. Ул чыннан да, шушы авыл кешесе икән. Кырык алтынчы елның язында кайткан булган. Кичен кайткан, иртә таң белән чыгып сызган. Шул ук көнне артыннан эзләп килеп тә җиткәннәр. Үзен электерә алмагач, туган-тумачаларын каһәрләгәннәр. Шуннан соңгы язмышын белергә туры килмәде.

Җәй урталарында крепостьтагы әсирләрнең тазаларын сайлап, каядыр алып киттеләр. Мәлик белән Хәлим дә шул төркемгә эләкте. Мин аякларын көчкә өстерәп йөрүче авыру әсирләр белән крепостьта калдым. Безне дә монда озак тотмадылар. Бушка ашатып ятудан файда юк дигәннәрдер. Кабыгы белән пешерелгән черегән бәрәңгене санап кына бирсәләр дә, өләшә торгач шактыйга җыела бит. Немецтә азык-төлек мәсьәләсе көннән-көн кискенләшеп, үзләренең дә хәлләре мөшкелләнә бара иде.

Безне Ирина станциясенә алып килеп, эшелонга төяделәр. Мин чиктән тыш кызыксынып, беренче мәртәбә монда килеп төшкәч, су эчеп аңымны югалткан колонкаларны күзәтеп тордым. Вагонга төялү белән тоткыннарга берәр кисәк тозлы селедка өләштеләр. Күрәсең, моның үзенә күрә нindidер сере бар. Югыйсә, Шепотовкадан монда килгәндә булган хәлне кабатламаслар иде. Тоткыннарны суга тилмертеп, тизрәк алардан котылырга чамалыйлар булса кирәк. Мин үземнең өлешемне кулыма тотып та карамадым. Янымдагы бер әсиргә бирдем, һәм башымнан үткән хәлне сөйләп бирдем. «Берүк, комсызланып юлда барганда ашый күрмә»,— дип кисәттем. Безне кая алып баруларын белүче юк иде. Хәер, кая алып барулары белән кызыксынмадык та. Немец армиясенә эләкмәвебезне аңлап, шатлыгыбыз эчкә сыймады.

Икенче көнне бер шәһәр кырыена килеп туктадык. Тышкы якта сөйләшкән авазлар ишетелде. Анда украин телендә сөйләшәләр иде. Димәк, безне, кире үзебезнең илгә алып кайтканнар. Билгесезлектән түземлегебезне югалттык. Кемдер, тышта йөрүчеләргә мөрәҗәгать итеп: «Нинди җир бу?» — дип кычкырды. Озата баручы сакчы автомат түтәсе белән ишекне дөбердәтергә тотынды: «Руэ менш — тавышланма!» Алай да сорау җавапсыз калмады, тышкы яктан:«Львив!» — дип кычкырдылар. Монда без тәүлеккә якын туктап тордык. Ниһаять, таң беленгәч без төялгән вагонны аерып алып икенче бер составка тоташтырдылар. Озак тормадык, кузгалып та киттек. Көн яктыргач, ишек ярыгыннан мин юлны күзәттем. Юл таулар арасыннан үргә менә иде. Як-якта урман, тирә-юньдә авыллар да, шәһәрләр дә күренми. Тагын шунысы, юл бер генә яклы. Бик еш полустанкаларда туктап, каршыга килгән эшелоннарны уздырып җибәрәбез. Бар да товар төягән эшелоннар. Немецләр Украинаның байлыгын Германиягә ташыйлар. Бер урында безнең эшелон кырда туктап торды. Якында гына атышкан тавышлар яңгырады. Алга барган саен атышлар көчәйде. Кемнәр арасында сугыш бара бусы безгә караңгы иде. Шулай да безнең күңелләрдә шатлыклы өмет уты кабынды. Кемнәрнеңдер үзебезне азат итүләрен өмет иттек. Соңыннан юкка өметләнгәнебез беленде. Сугыш украин милләтчеләре белән немецләрнең җәза отрядлары арасында бара икән. Фашистлар аларга каршы бер дивизия гаскәр җибәргәннәр. Тагын шунысы бар: украин милләтчеләре немецләрне да, русларны да бер үк дәрәҗәдә дошман күрәләр.

Шулай итеп, мине язмыш Карпат таулары итәгенә илтеп ыргытты. Беркөнне иртә белән Станислав шәһәренә килеп туктадык. Хәзер ул Ивано-Франко дип атала. Безне вокзалдан җәяүләп шәһәр кырыена алып чыктылар. Тирә-ягы чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынган дүрт катлы йортта сакчылардан башка җан иясе күренми иде. Бәлки йорт эчендә кем дә булса бардыр дип, барыбыз да шунда ябырылдык. Югары катка алып менә торган баскычта кан таплары күреп югалып калдык. Шунда ук канга баткан хатын-кыз, балалар киемнәре аунап ята иде. Югары менгән саен канлы киемнәр күбәя барды. Барлык бүлмәләрнең ишекләре каерып алып ташланган. Савыт-саба ватыкларын ерып йөрерлек түгел. Шулай иснәнеп бүлмәдән-бүлмәгә йөргәндә «ахтунг!» дигән команда яңгырады. Ачы тавыш белән акырып пыяла күзле ефрейтор барыбызны бергә җыеп, сафка бастырды да: «Рейнмахен», — дип бүлмәләрне, баскыч һәм коридорны җыештырып, бөтен җирне чистартырга әмер бирде. Без теләр-теләмәс кенә эшкә тотындык. Эленке-салынкы йөрү ефрейторга ошамады әлбәттә, кизәнә башлады.

Мин сул яктагы бүлмәгә кереп, балта белән туракланган мамык түшәк, матрац калдыкларын җыярга тотындым. Монда кеше каны мамык түшәкне генә буяп калмаган, идәнгә агып, оешып каткан иде. Караватка җәелгән канлы җәймә астыннан кул сәгате килеп чыкты. Ул шундый кечкенә, биш тиенлек бакыр акча зурлыгында гына. Моңа кадәр минем андый сәгать күргәнем юк иде әле. Сәгатьне кая яшерергә белми аптырап калдым. Хәтта аны үзебезне саклаучы сукыр ефрейторга тапшырмакчы да булган идем. Кире уйладым. Бер җәймәнең канга буялмаган җирен ертып алып сәгатьне шуның белән төрдем дә ыштан бөрмәсенә яшердем. Сәгатьнең корпусы сары металлдан эшләнгән. Кулга бәйли торган чылбыры да шундый ук төстә. Мин аларны алтын дип уйлаган идем. Юк, алтын түгел икән. Ярты ел чамасы яшереп йөрткәннән соң, Кассель шәһәрендә заводта эшләгәндә, ышанычлы иптәшкә күрсәтеп, нинди металл икәнен ачыкладым. Ул вакытта ук инде Германиядә сәгать әлләни кыйммәт түгел иде. Без аны бер литрлы банкага тутырылган дуңгыз итенә алмаштырдык.

Бер атна чамасы вакыт узгач Станиславка, безнең янга тагын бер төркем тоткын китерделәр. Алар арасында татарлар юк иде. Барысы да

дип әйтерлек. Урта Азия халыклары: үзбәкләр, казакълар, төрекмәннәр иде. Бик еш ызгышып, бер-берсен тукмашалар. Ызгыш карта уйнаганда чыга. Элек ишеткәнем раска чыкты: алар халкында отышлыга карта уйнау тәмам китмәс чиргә әйләнгән икән. Уен паекка бирелгән икмәкне банкага салып башланып китә. Шул барлы-юклы икмәген оттырган тоткыннарның хәле бик мөшкел иде.

Әсирләрне эшкә алып йөри башладылар. Урман кисәргә. Монда, Карпат таулары арасында, урман кисеп, сал агызу нык җәелгән. Эш авыр, тоткыннар аяктан егыла башлады. Авыруларга бернинди медицина ярдәме күрсәтелми. Бәхеткә дип әйтимме, минем үземә урман кисәргә йөрергә туры килмәде. Тырыша торгач, кирәкле сүзләрне немецча өйрәнеп алган идем. Ун кешедән торган безнең команданы саклап йөртүче пыяла күзле ефрейторга кайбер немец сүзләрен белүем ошады. Ул мине «долметшер-тылмач» дип атый башлады. Аңа еш кына вак-төяк йомыш беән шәһәргә чыгып йөрергә туры килә. Ул үзе белән мине ияртеп йөри иде. Берәр әйбер алып кайтырга туры килсә, миңа күтәртә. Лагерь администрациясе карамагына — йөк ташыр өчен машинаны әйткән дә юк, ат та бирелми иде. Барысына да тоткыннарны җигәләр. Атнасына бер-ике мәртәбә тимер юл кырыендагы складтан азык-төлек алып кайтырга туры килә иде. Азык-төлекне кул арбасы белән мин тартып алып кайтам. Ефрейтор арттан каравыллап кына йөри. Үргә арба тартып менәргә туры килсә, булышкан да була тагын үзе. Тора-бара мин аның ышанычын яуладым. Ул ялгызымны гына калдырып, үз йомышы белән китеп тә йөри башлады. Беркөнне тимер юл кырыендагы склад без килгәндә әле ачылмаган иде. Ефрейтор сүгенде, сүгенде дә каядыр китеп барды. Мин, арбага утырып, юлдан үтүче товар төягән эшелоннарны күзәттем. Алар немецкә хас төгәллек белән ун минуттан ун минутка үтеп торалар. Вагоннар дыңгычлап тутырылган. Шуңадырмы, паровоз аларны көчкә өстери. Кайсыбер эшелон шундый әкрен бара, вагон тамбурына сикереп менеп кунакларга мөмкин. Мондый хәл бик күптәннән кызыксынган күңелемне җилкетте. Уйлап-уйлап тордым да тагын бер мәртәбә бәхетемне сынап карарга булдым. Бер вагонның тамбурына сикереп мендем дә кеше күзенә чагылмас өчен сузылып яттым. Бәхеткә, мин менү белән поезд тизлеген арттырды. Башымда төрле уйлар кайный башлады. Шундый фикергә килдем: миңа бу эшелонда озак торкарланырга һич ярамый, бераз җир китү белән төшеп калырга кирәк. Югыйсә киләсе станциядә тикшерү булырга мөмкин, һәм мине бик тиз эләктереп алачаклар.

Мин яткан көйгә өмсенеп-өмсенеп тирә-юньне күзәттем. Юл буенда тыз-быз чабып йөргән солдатларны күреп, эчем җу итте. Җитмәсә, тагын барысы да СС формасында. Күрәсең, шушы СС солдатлары бу тирәдә кайнашканга эшелонны саклап озатучылар да юктыр. Донбасстан Славута лагерына күчергәндә үз күзем белән күрдем, анда юлда баручы товар төялгән вагоннарны пулеметләр белән коралланган солдатлар озатып йөри иде. Мин очраклы рәвештә юлымның уңышлы башлануына сөенеп бетә алмадым. Соңыннан гына аңладым: болай дуамал качып китү ахмаклыкның башы гына булган икән!

Эшелоннан төшеп калыр өчен җайлы урын эзләп, тирә-юньне күзәтә бирәм. Поезд шактый текә үргә менә башлады һәм тизлеген киметте. Як-якта куе агачлык башланды, кеше-кара күренми. Мин, Аллага тапшырып, җиргә сикердем. Нәк мин килеп төшкән җирдән ерганак башлана икән. Шул ерганак буйлап шуышып барып тимер юлдан читкәрәк тайпылырга тырыштым. Ерганак алга киткән саен тирәнәя иде. Шул ерганак белән шактый озак баргач, елга ярына килеп чыктым. Елганың аргы ягында зур бер авыл күренә иде. Мин турыдан-туры авылга барып керергә кыймадым, камышлыкка яшеренеп, кич җиткәнне көтәргә булдым. Камышлык куе һәм җиргә яткач мине кеше күрерлек түгел иде.

Корырак урын сайлап коры камышларны сындырып җәйдем дә, сузылып яттым. Ята торгач, йокыга киткәнмен. Онытылып, бер нәрсә белми йоклаганмын. Күпме йоклаганымны хәтерләмим. Мин уянганда, кояш батып, көн караңгыланып килә иде. Ни булса да булыр дип, авылга барып, бу тирәдәге хәлне ачыкларга теләдем.

Авыл халкы йокламаган иде әле. Чиркәү тирәсендә никтер шаулашалар. Иң кырыйдагы саман кирпечтән салынган йортның ындыр ягына килеп бастым. Өйнең акшары коелган, бер кырыйдан түбәсен җил кубарган. Ишекне бер карчык ачты. Ул мине күреп, артка чигенеп куйды. Һәм ашыгып ишеккә бастырык салды. «Бабуся, курыкмагыз, курыкма. Мин үзебезнең кеше». «Зинһар, китегез, минем ишегалдыннан, харап итмәгез». «Бер генә минутка чыгып керегез, сорыйсы сүзем бар». «Алла хакы өчен харап иттермәгез. Әгәр сине минем ишегалдында күрсәләр, икебезне дә тотып асачаклар».

Сүзне дәвам итәргә мөмкинлек калмады. Карчыкка ялынып эш чыкмаслыгын аңлап, китәргә җыендым. Урамга чыккач, ул мине кире чакырып кертте һәм чалбар белән шактый таушалган пинҗәк тоттырды. «Мә, тиз генә сәләмәләреңне алмаштыр ичмаса, өс киемең кеше күзенә күренерлек түгел. Әрепләшеп, бәхәсләшеп тормавым карчыкка ошады булса кирәк, миһербанлылыгының төп сәбәбе шундыр, дип уйладым. Ул минем китәсе килми терәлеп торганны сизеп: «Бар, бар, юлыңда бул, бу тирәдән ычкын тизрәк, авыл тулы герман солдатлары»,— диде. Мин килгән юлым белән кире елга арьягына чыктым. Сәләмәләремне салып сазлыкка ыргыттым да, карчык биргән киемне киеп, баягы урыныма барып утырдым. Төн уздыру авыр булды. Нәрсәләр генә уйлап бетермәдем. Никадәр тырышсам да, йокыга китә алмадым.

Көн яктыра башлау белән тимер юл кырыена юнәлдем. Юл үргә менгәнлектән, поездлар монда тизлеген киметәләр. Исәбем, ничек итеп булса да товар вагонының тамбурына эләгеп, бу тирәдән ераграк китү иде. Барып чыкмады. Юл кырыена килеп җитү белән патрульгә очрадым. Автомат белән коралланган солдатлар тотып алдылар. Шунысы гаҗәпләндерде, бу солдатлар үзара украин телендә сөйләшәләр иде. Хәтта аларның СС солдаты булуына шикләнеп куйдым. Чөнки СС армиясендә хезмәт итәргә немецларны генә алалар дип ишеткәнем бар иде. Аларның да әле чиста канлы чын ариец булганнарын гына. Мине арт ягыма тибә-тибә, җилтерәтеп авылга алып киттеләр. Авыл эче машиналар, обозлар белән тулы, солдатларның исәбе-хисабы юк. Бу авылда украин милләтчеләреннән оештырылган «Галичина» дигән СС дивизиясе дислокацияләнгән икән.

Минем белән сөйләшеп вакыт уздырып тормадылар, машинага утырттылар да каядыр алып киттеләр. Артта, алда автомат белән коралланган сакчы утыра. Шундый почет, машинаның як-ягына көйләнгән көзгеләрдән һәрбер хәрәкәтне күзәтеп баралар. Бик озак юлда булдык. Юл буендагы күрсәткечләрдән күренгәнчә, мине Варшавага алып баралар иде. Ниһаять, шәһәргә килеп җиттек. Һава һөҗүменнән шәһәр шактый зарарланган. Бомба төшеп җимерелгән йортлар бик күп. Борма-борма тар тыкырыклардан узып, зур елга кырыендагы биш катлы бина янына килеп туктадык. Озата баручы унтер мине сакчылар карамагына калдырып, эчкә кереп китте. Ул немец иде. «Галичина» СС дивизисе украинлылардан оештырылган булса да, офицерлар бар да дип әйтерлек немец милләтеннән икән. Унтер шактый озак торып чыкты. Ул мине үзе белән эчкә алып кереп китте. Гаҗәпләнүемә, өскә күтәрелмәдек, бетон баскыч белән аска төштек. Монда аста, үзенә аерым бер дөнья. Почмак саен пост куелган. Бертуктаусыз документ тикшерәләр. Мине зур бер бүлмәгә алып керделәр. Анда, түрдәге өстәл артында көмеш погонлы, кара төстәге материядән тегелгән кием кигән офицер утыра иде. Унтер мине аның каршына китереп бастырды. Офицер сәерсенеп карап торды

да: «Малиба... зие зинд айн юде!» — дип кычкырып җибәрде. Мин бу сүзнең мәгънәсен моннан чыгып лагерьга алып килгәч кенә аңладым. Офицер мине яһүд кешесе дип белгән икән. Еврейгә ошатуга билемә җиткән кызыл сакал сәбәпче булгандыр. Ярый әле өс киемнәремне алыштырып өлгергән идем. Әгәр, кызылармеец икәнемне белгән булсалар, шунда ук бер пуля белән эшне бетерерләр иде. Яһүд милләтеннән булган кызылармеецләр белән күп сөйләшеп тормыйлар иде. Менә, язмыш юк диген син...

Бала чакта мин ут кебек янып торган кып-кызыл чәчле идем. Иптәшләремнән оялып, көн аралаш, ялына-ялына әтиемнән чәчемне кырдырта идем. Чәчем тимерчыбык кебек каты булганлыктан бик авыртса да түздем. Ул елларда үткән пәкесе дә юк иде бит әле аның. Чәч кырыр өчен пәкене иске чалгыдан ясыйлар иде.

Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, яшь чагымда сакал-мыегым да кызыл иде. Ни гаҗәптер, еллар үтү белән чәчемнең дә, сакал-мыегымның да төсе үзгәрде. Әллә большевизм чоры бүләге — кызыл бөртекләр коелып бетте инде?..

Әсирлеккә төшкәч, сакал-мыегымның төсенә игътибар итүче булмады, үзем дә аңа әһәмият бирмәдем. Сакалым билгә җитәрлек, озын булып үсте. Гестапо офицеры озын сакалымны күреп, мине яһүд дип кабул иткән. Күп сөйләшеп вакыт уздырмадылар, мине Варшавадагы атаклы яһүдләр лагерена озаттылар. Лагерьга килгәч, бер еврей авызыннан ишеттем, чиста канлы яһүд кызыл чәчле, кызыл сакаллы була икән, ул тумышы белән дәрәҗәле нәселдән килгән кешеләргә генә хас сыйфат дип сөйләде. Ишетмәсәң ишет!

Бик өзгәләнеп, үземнең яһүди милләтеннән булмавымны исбатларга тырышып карадым. Барып чыкмады. Өстәвенә, тагын тегеләргә охшаш бер әгъзамны таптылар. Яһүдләр дә балаларын сөннәткә утырталар икән бит. Ул вакытта сөннәткә утыртуның бөтен нечкәлекләре миңа әле мәгълүм түгел иде. Аларныкы нәрсәсе беләндер мөселманнарныкыннан аерыла да икән. Соңыннан бу турыда миңа бер татар карты сөйләде.

Лагерьга яһүдләрне бөтен гаиләләре белән җыйганнар иде. Ирехатыны, яше-карты, бала-чагасы — барысы да бергә. Монда тәртип әлегә кадәр мин булган лагерьлардан бөтенләй аерылып тора иде. Иртән сәгать биштә йокыдан торгызалар. Алар теле белән әйтсәк, тору белән «водная процедура» башлана. Ишегалды уртасында сасыган сулы бассейн бар. Шушы суны йөзеп чыгарга кирәк. Су кырыена китереп тезәләр дә, йөзәргә теләмәгән кешене төртеп төшерәләр. Өстәвенә иртәнге аштан мәхрүм итәләр. Ишегалдының уңъяк кырыенда агач кисмәкләр тезелеп тора. Иртәнге ашны шул кисмәкләрдән тараталар. Бассейнны йөзеп чыккан кеше кисмәк янына барып җитәргә ике йөз метр ара калгач мүкәләргә тиеш. Болай гына түгел, җырларга мәҗбүр итәләр. «Вир синд юден, унглюк фүр ганце вилд» дип җырлаталар. Мәгънәсе: «Без яһүдләр бөтен дөньяның бәхетсезлеге». Уйлап чыгарырга кирәк бит. Дистә еллар үтүгә карамастан, бала-чага, хатын-кызның йөрәк өзгеч ачы тавышы белән шыңшуы һаман әле колагымда чыңлый сыман. Карачкыга охшаган шәүләләре күз алдымда. Үлгәндә дә оныта алмам төсле...

Һәрбер кисмәк янында үгез төсле ике ир кеше басып тора. Шунысы аяныч, аларның күбесе украин милләтеннән. Кисмәк янына килеп җитүгә белән берсе кулга калай җамаяк тоттыра, икенчесе чүмеч белән кайнар баланда сала. Баланда шулкадәр кайнар, салу белән җамаяк кулны яндырып ала. Ирексездән җамаякны төшереп җибәрәсең. Аеруча балачага кулы пешүгә чыдый алмый. Чүмеч тотып торучы кулдан җамаякның төшеп китүен көтеп кенә тора. «Ә-ә, сиңа герман ашы ошамыймы? — дип, кая туры килде, шунда чүмеч белән тондыра.

Минем хәл чиктән тыш кискенләште. Нинди юл белән булса да, үземнең яһүд милләтеннән булмавымны исбат итү турында баш ватам.

Бәхеткә көтмәгәндә, бер СС солдаты миңа игътибар итә башлады. Ул үзе милләте белән урыс булса кирәк иде. Немецча бөтенләй сөйләшә белми диярлек. Бер көнне уйга батып ишегалдында басып торганда: «Әй, син... тегеләй ителгәнең җитмәгән нәрсә, ничек монда килеп эләктең? Сукыр да күрерлек, син бит яһүд түгел! — дип эндәште. «Мин үзем дә хәзер кем икәнемне белмим»,— дидем мин дорфа гына. «Әле син сөйләшергә дә теләмисеңме? проклятая татарская морда...» Ул резин таяк белән аркама китереп тондырды. Күземнән яшь атылып чыкты. Авыртудан түгел, кимсетеп җәберләнүдән: «Нигә миңа тик торганда сугасыз? Гаебем булса, тел белән әйтергә ярамыймыни?» — дип сукрандым мин. Бөтенләй көтелмәгән җавап ишетеп, гаҗәпкә калдым. «Син Казан татары булсаң кирәк, мин сине ничек тә моннан коткарырга тырышырмын». Ул шулай дип әйтте дә китеп барды. Мин аның сүзләренә ышанырга да, ышанмаска да белмәдем, йөрәгем әрнүгә чыдый алмый, өйгә кереп, бер почмакка чүңкәеп утырдым. Ихтыярымны җыеп, онытылырга тырыштым.

Соңгы вакытта авыр минутларда онытылып торып беразтынычланырга күнегеп килә идем. Кирәк бит, ничәнче мәртәбә инде ахмаклык эшлим. Әсирлеккә төшүемнең ахмакларча килеп чыгуын әйтеп тә торасы юк! Тәҗрибәсез дияр иде, тәҗрибә җитәрлек, кирәгеннән артык. Хак, тәҗрибәгә нигезләп тиешле нәтиҗә ясарлык акыл гына юк! Бер мәртәбә качып авызым пеште бит инде. Тагын шуны кабатладым. Беркем белән киңәшми-нитми, ялгызым качтым. Ялгыз килеш лагерьдан качып эш чыгарып булмаслыгын белеп качтым. Минем кемгә кирәгем бар? Шушы кыяфәтем белән мин кая бара алам? Хәзер менә үземнең яһүд икәнемне исбатларга кирәк. Язмыш, язмыш. Нигә соң, син минем белән болай шаярасың? Чукынып китсен бөтен дөньясы! Онытырга, барысын да онытырга...

Онытылу өчен иң асат юл — шигырь язу. Бәхеткә, илһам килеп китте. Күңелдәге уйларым шигырь юлларына тезелә башлады.

Язын үскән эт эчәгеседәй
Яшь гомремә хәсрәт уралган.
Олы диңгездәге ялгыз ишкәкче күк
Бәхет эзлим, белмим, кайда югалган.
Шат кешене күрсәм мин дә көлгән булам,
Күзләремнән канлы яшьләр аксада.
Ятим калган ялгыз кош баласы кебек,
Оя эзлим әрем үскән бакчада.
Озын юлга чыккан ялгыз сәфәрче мин,
Язмыш мәҗбүр итте монда туктарга.
Канлы хуҗа сизә безнең караганны
Көнчыгышта гөрләп янган утларга.
Буталган җеп төсле хәзер безнең тормыш
Белмим, кемнәр табар аның очларын,
Кайта калсак, кабул итәр микән илем
Тимер читлектә интеккән кошларын?...

Әйе, туган илгә кайтудан өмет өзелмәгән иде әле. Иң зур теләк — сугышның ахырын күрү. Моңа кадәр тарихта булмаган шушы мәхшәрнең азагын күреп булса дөнья белән хушлашырга да мөмкин. Уйлар, уйлар... Ничек кенә юрама, үләсе килми. Шул вакыт немецның, урыс сүзләрен бутый-бутый миңа эндәшкәнне ишетеп, сискәнеп киттем:«Ауф... тегеләй ителүе җитмәгән татарин. Нәрсә, чукракландыңмы әллә? Лаус, лаус, менш.— Тиз, тиз!..» Мин аягүрә басып, үрә каттым. Әле күптән түгел генә резин таяк белән тондырган СС солдатын күреп, чирканып куйдым. Ул мине үзенә ияртеп, капка төбенә үк алып китте. Анда бераз басып торганнан соң комендатурага алып керделәр. Бүлмәдә СС капитаны ялгыз, бүлмә буйлап марш атлап йөри иде. Ул дикъкать белән мине

башымнан аягыма кадәр күзеннән үткәрде дә нидер лыгырдарга тотынды. Сүзләреннән шул аңлашылды: «Еврейгә якын да килми, типик славян. Күзләре чыкмаган булса, аңлаган булырлар иде. Ни шайтаныма монда китергәннәрдер!». Ул мине партизанлыкта гаепләргә теләде. Әмма мескен кыяфәтем белән һич кенә дә партизанга ошамаган идем шул... Озата килүче сүзгә кушылып, нәрсәдер аңлаткач, мине Украинадан Германиягә көчләп эшкә җибәрелгәндә эшелоннан качкан кешегә санадылар булса кирәк, туган җирем турында сораша башладылар. Ул чорда халыкны Германиягә озату кызу төстә бара иде. Кайда эшкә мобилизовать ителүемне сорагач, бераз аптырап калдым калуын, ләкин сиздермәдем. Телемә беренче килгән сүзне такылдарга тотындым. Армиядә хезмәт иткәндә, бер иптәшем Киев өлкәсе, Белая Церковь районы, Шкаровка авылыннан иде. Мин шул адресны әйттем. Озата килүче ялганымны сизде сизүен, ләкин сүзгә катнашмады. Аның тарафыннан күрсәтелгән мәрхәмәтне ничек аңларга да белмәдем. Ходам мәрхәмәте булгандыр, дидем. Чыраенда рәхимлелекнең әсәре дә булмаган СС солдатының мондый мәрхәмәтен тагын ничек аңлатырга мөмкин иде соң?

Начальник телефоннан шалтыратып, бер солдатны чакырып кертте дә мине алып китәргә кушты. Солдат шактый олы яшьтә иде. Куптән түгел госпитальдә ятып чыккан булса кирәк. Бераз аксый.

Бара торгач без елга буена килеп чыктык. Зур елга. Висла елгасы. Әйе, Варшава Висла елгасы буена урнашкан. Шул вакыт гаҗәеп бер хәл булып алды. Трамвайны туктатып, шатыр-шотыр атышырга тотындылар. Солдат тиз генә мине бер ишек алдына алып керде. Һәм без кирпеч койма артына яшерендек. Атыш шактый озакка сузылды. Әйе, поляклар йоклап ятмый икән. Алар көпә-көндез Варшава урамында оккупантларга каршы сугыш алып баралар. Кинәт бөтен дөнья тынып калды, һәм без урамга чыктык. Анда берничә канга баткан кеше аунап ята иде. Араларында хәрби киемдәгеләр дә бар. Солдат: «Ферфлюхте, криг шайзе — ләгънәт төшсен, сугыш начар!» — дип сүгенде дә, тизрәк мине бу тирәдән алып китәргә ашыкты. Без зур күпер аша Висланы үтеп, бер агачлык кырыена килеп туктадык. Анда тимер юл сузылган һәм юл буйлап лабазлар тезелеп киткән иде. Бер төркем халык, зур-зур әрҗәләрне лабаздан алып чыгып, товар вагонына төйиләр.

Солдат мине лабазлар артындагы бер катлы таш бинага алып керде. Озын коридор буйлап түргә узды һәм бер бүлмәгә кереп китте. Бераздан мине дә чакырып алдылар. Анда, өстәл артында СС офицеры утыра иде. Алар миңа игътибар итмичә, солдат белән мин кергәнче башлаган сүзләрен дәвам иттеләр. Күптәнге танышлар булса кирәк, бер-берсеннән хәл-әхвәл сораштылар. Ниһаять, бераздан сүз миңа күчте. Офицер текәп карап торды да, русчалатып: «Германиягә эшкә кайдан мобилизовать ителгән идең?» — дип сорады. Минем җавап бирергә аптырап калганны күреп: «Туган җирең кайда?» — дип өстәде. Мин аңыма килеп, яһүдләр лагерында уйлап чыгарылган кыйссаны кабатладым. Ул минем нигә качуым турында төпченә башлады. «Туган илдән китәсем килмәде», — дип җавап бирдем. Җавабым ошадымы, бу турыда башка сүз озайтып тормады. Өстәл кырыендагы кнопкага басып, бер кешене чакырып кертте: «Менә сезгә тагын бер качкын, — диде, — әгәр тагын качып китсә, башың белән җавап бирәсең». Утыз яшьләр тирәсендәге, өстенә сырма, аякларына кирза итек кигән бу бәндә мине теләмичә генә кабул итеп алды. Ул нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачкан иде, сүзен дәвам итәргә офицер ирек бирмәде, коры гына: «Юлыгызда булыгыз!» — диде.

Таш бинадан чыгу белән теге бәндә минем кем булуым турында сораштыра башлады. Минем исә бу хакта һич тә сүз кузгатасым килми иде. «Син сорама, мин әйтмим!» — дидем коры гына итеп. «Теләсәң — теләмәсәң кем булуың турында сөйләргә туры килә. Офицерның нәрсә әйткәнен үз колагың белән ишеттең бит, мин синең өчен башым белән

җавап бирәм». Мин аның үзе турында тәпченергә тотындым: «Элек сез әйтегез: үзегез кем буласыз?» Ул беравык уйланып торды да: «Син нәрсә, миннән сорау алмакчы буласыңмы? Монда синнән башка да сорау алучылар житәрлек»,— диде үпкәле тавыш белән. «Сорау алмыйм, бары үземнең кемнәр янына килеп эләгүемне генә беләсем килә»,— дигәч, җайлап сөйләшергә тотынды. «Безне Винница өлкәсеннән Германиягә эшкә мобилизовать иттеләр,— диде ул ярым русча, ярым украинчалап,— менә син нинди командага килеп эләктең». «Германиягә үзегез теләп барасызмы?» — дип сорадым, гәрчә көчләп алып баруларын белсәм дә. «Әйе, үзебез теләп барганга күрә, сак астында тоталар»,— диде ул агулы елмаеп. Мин аның җавабыннан бик канәгать булдым. Димәк, әсирләр лагерыннан качып китүем юкка булмаган. Ничек кенә сакламасыннар, бу инде әсирләр лагере түгел. Германиягә алып барулары начар начарын, ярар, алда тагын күз күрер әле. Мин әлеге кешенең соравына, үземнең кем булуым турында югарыда әйтелгән легенданы кабатларга тотынган идем, ул беренче сүздән үк ялганны тотты: «Нәрсә күзгә карап алдыйсың? — диде житди генә.— Син бит кацап, кацап та түгел бугай әле...» Мин аны бүлдем: «Каян беләсең?» — дип сорап куйдым. Ул бераз уйланып торды да, катгый итеп: «Синең кем булуыңны тикшерү минем эш түгел, так и быть, молодец, фашистның башын әйләндерергә кулыңнан килгәч, син хлопец, что надо булырга кирәк. Ләкин, кара аны, тагын качарга уйлый күрмә. Минем синең өчен башымны кистерәсем килми». «Язмышым хәзер сезнең кулда, сез генә мине коткара да, батыра да аласыз. Рөхсәтсез бер адым да читкә атламаска сүз бирәм»,— дидем мин. Җавабым ошады булса кирәк, йөзе ачылып китте. Без шулай гәпләшеп тупикта торучы товар вагоннары янына килеп чыктык.

Вагон эчендә кемнәрдер акырып-бакырып нәрсәдер бүлешәләр, тавышлары еракка ишетелә. «Ах, черти поласатые»,— диде мине ияртеп алып килүче тешләрен кысып, һәм: «Зарецкий!» дип кычкырды. Җәядән аткан ук кебек вагон ишегеннән бер егет җиргә сикереп төште дә: «Нәрсә бар, дядя Степа?» — дип безнең каршыга килеп басты. «Менә бу хлопец сезнең вагонда барыр...» Зарецкий аны бүлдерде: «Безнең вагонда утырып торырлык та урын юк, шыплап тутырылганны беләсең бит...» «Мин аны кая куйыйм? Кызлар яның урнаштырыйммыни? Әйткәнне тыңла син. Зарецкий бәхәснең файдасыз икәнен төшенеп, кулын селтәде һәм мине вагон эченә алып керде. «Менә сиңа шушында сыенырга туры килер»,— диде ул ишек яныннан урын күрсәтеп. Ул арада ике катлы сәкедә ятучылар урыннарыннан төшеп, мине уратып алдылар. Зарецкий аларны куарга тотынды: «Таралыгыз, тарал... аю түгел, сезнең кебек кеше». Минем монда китерелүем бик тиз күрше вагондагыларга да мәгълүм булды. Вагон ишеге төбенә бер төркем хатын-кыз килеп бөялде, алар эчкә үрелә-үрелә мине күзәтә башладылар. Барыннан да бигрәк, аларны минем сакал кызыксындырды булса кирәк. Колактан-колакка нәрсәдер пышылдарга тотындылар. «Хлопцы, бу карачкыны кеше кыяфәтенә кертергә кирәк», диде бер кыз ягымлы тавыш белән. Ул зур зәңгәр күзле, чәчен толымнарга үреп күкрәгенә төшергән. «Ничек рәткә кертәсең мондый шөкәтсезне?» — дип сорады аның янына килеп баскан икенче бер кыз. «Вакытсыз картаеп йөрмәсен, һичьюгында сакалын кырырга кирәк». Сакал үземнең дә эчне пошыра иде. Сакалдан котылу теләге туды. «Берәрсендә кайчы юк микән?» — дип сорадым сары чәчле егеткә мөрәҗәгать итеп. «Нишлисең кайчы белән?» Мин сакалымны тотып күрсәттем. Ул сәке астыннан тактадан эшләнгән чемодан тартып чыгарды һәм аны ачып кайчы алды. Мине каршына бастырды да, тиз генә сакалны төбеннән үк кисеп ыргытты. Бар да эчләрен тотып көләргә тотындылар. Аларга минем мондый кыяфәттә керүем сәер тоелды булса кирәк. «Хлопцы, аның йөзе ала-кола кыркылган сарык тиресенә ошап калган. Бритва табыгыз...» Сакал белән эшне бетергәч, ашау турында кайгырттылар.

Үзем авыз ачып бер сүз әйтмәсәм дә минем хәлне аңлап өлгергәннәр иде инде. Алар өйдән шактый запас белән чыкканнар. Ашау-эчүне иркен тоталар. Миңа сало белән зур бер телем икмәк кисеп бирделәр. Ризыкны күз ачып йомганчы юк иттем. Сары чәчле егет мине үз янына чакырып алды: «Исемең ничек?» — дип сорады. Ни булса да булыр дип, дөресен әйттем. «Әнәс» дигән җавапны ишеткәч, ул урыныннан сикереп торды. «Син татармы әллә?» Мине башымнан аягыма кадәр күзеннән үткәрде дә кочаклап алды. «Ә син?» «Минем төп чыгышым Воронеж өлкәсе, Усман районы». «Әллә Воронеж өлкәсендә дә татарлар бармы?» — «Дөньяда безнең татар булмаган җир бар микән?» Ул татарга охшамаган иде. Зәңгәр күз, дулкынланып торган сары чәч, кылыч борын... Сөйләшүе дә безнең Казан татарларыннан үзгәрәк, ничектер катырак телле. «Воронеж өлкәсендә берничә татар авылы кысылып калган,— диде ул сүзен дәвам итеп,— дөресрәге кысылып калмаган, кысрыклаганнар. Фактта кайчандыр Дон буе безнеке — татарларныкы булган. «Мин аның исемен сорадым. «Чыны Гыйлаҗетдин, руслар мине үзләренчә Гриша дип атап йөртәләр».

Гыйлаҗетдин да минем кебек сугыш алдыннан чираттагы чакырылыш буенча армиядә хезмәт иткән. Аларның полкы кырык беренче елның башында чик буена, Тернополь шәһәреннән ерак түгел урнашкан лагерьга күчерелгән. Беренче көнне үк сугышка кереп, чолганышта калганнар. Озак каршылык күрсәткәннәр. Ахыры әсиргә төшү белән тәмамланган. Сөйләвенә караганда, Гыйлаҗ әсирләр лагерында озак булмаган, качкан. Йөри торгач, Винница өлкәсендәге бер авылга барып сыенган. Шактый иркен тормышлы бер хатын аны кабул иткән. Ирен армиягә алгач, ул җитеп килә торган кызы белән генә кала. Иренең хәлен белми, киткәннән бирле хәбәре юк. Гыйлаҗ бик тиз хуҗа хатынның кызы Галя белән дуслашып, бергә тора башлый. Билгеле, башта ул яшеренеп яши. Әниләре авыл старостасын көйли һәм бераздан аңа тел-теш тидерүче булмый, үз кешегә әйләнә. Ләкин аларга аерылырга туры килә. Гыйлаҗны ирексезләп Германиягә эшкә алып китәләр. Галя йөкле булу сәбәпле, вакытлыча анда барудан котыла.

Мин килеп бер кич кунгач, без төялгән товар вагоннарын пассажирлар йөртә торган поездга тактылар. Озатучы немецлар йомшак вагоннарга күчеп утырдылар. Эшкә мобилизовать ителүчеләрнең үз араларыннан һәр вагонга өлкән итеп бер кеше тәгаенләнгән иде. Бөтенесе өчен шул кеше җаваплы: халыкны чәчми, түкми Германиягә алып барып җиткерергә тиеш. Безнең вагонда өлкән Зарецкий фамилияле кеше иде. Исеме Николай. Авылда өйрәнелгәнчә аны дядя Микола дип атап йөртәләр. Ул яше белән безгә караганда олырак, сүзен бик үлчәп сөйләшә, юкка-барга катнашмый. Шуңадырмы, бар да аны хөрмәт итәләр. Гыйлаҗның сөйләвенә караганда, Зарецкийның авылда карт анасы һәм ике яшь бала белән хатыны калган. Үзе моңарчы башлангыч мәктәптә укытучы булып эшләгән. Нинди сәбәп белән армиягә алынмый калгандыр. Гыйлаҗ ул турыда белми иде.

Поезд Варшавадан кич кырын кузгалды. Мин утырган килеш йокыга китүемне сизми дә калганмын. Йокы дигәч тә, чын йокы түгел инде, изелеп утыру. Ничек кенә булмасын, әгъзалар ял итә.

Поезд ташбака адымы белән бара һәм бик еш туктап тора. Бер тукталышта «Лицманштадт» дигән сүз ишетелде. Минем бервакытта да мондый исемле шәһәрне ишеткәнем юк иде. Мактанып әйтүем түгел, географияне яхшы белә иде. Кайсы кыйтгада нинди илләр, аларның баш калаларын, баш калаларын гына түгел, андагы эреле-ваклы шәһәрләрнең исемнәрен, зур елгаларның кайдан башланып, кайсы диңгезгә коюларын биш бармагым кебек хәтерли идем. Ә инде, Европа илләрендәге атамалар турында әйтеп тә торасы юк. «Бу нинди дә булса берәр полустанкадыр»,— дидем мин Гыйлаҗга. «Юк, брат, бик зур шәһәр булса кирәк.

Әнә, кара, күп катлы йортлар тезелеп киткән. Завод трубаларын санап бетерә торган түгел». Безнең вагон ишеге төбенә кызлар килеп басты. Алар барысын да төпченеп, нинди җиргә килеп туктавыбызны белергә дә өлгергәннәр. «Хлопцы, Лодзе шәһәре, нәрсә йоклап ятасыз?» — дип кычкырды берсе. Әйе, Лодзе Польшаның текстиль промышленносте үзәге. Монда туку фабрикалары бик күп. Сугышка кадәр Лодзе шәһәрендә эшләнгән тукымалар бөтен дөньяда мактала иде. Гитлер әмере белән шәһәрнең исемен үзгәрткәннәр. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында һәлак булган кайзер генералының исемен кушканнар. Күрәсең, безнең илдән үрнәк алганнар. Бездә дә бит, кирәккә дә, кирәкмәскә дә, күпме торак пунктларының атамаларын үзгәртеләр.

Лодзеда озак тоткарланмадык. Паровозны алмаштыру белән кузгалып та киттек. Аннан соң Позен дигән шәһәргә килеп җиттек. Немецлар «Познань» шәһәрен үзләренчә шулай Позен дип атый башлаганнар. Әйе, алар Польшаның күп өлешен Германиягә кушып, исемнәрне үзгәртеп бетергәннәр иде.

Познань шәһәреннән соң озак бармадык, Алман җиренә килеп кердек. Юл буйлап тезелеп киткән вак-төяк шәһәрләрнең, авылларның иге-чиге юк. Бар да төзек, зәвык белән салынган таш йортлар яшеллеккә уралган. Польша белән чагыштырганда аерма җир белән күк арасы кадәр. Менә Одер елгасы буена урнашкан Франкфурт шәһәренә дә килеп җиттек. Шушында калдырмаслармы дип өмет иткән идек. Юк, барып чыкмады. Калдыру турында исләрендә дә юк, поезд Берлинга юнәлде. Шәһәргә якынайган саен җимерекләр күбрәк күзгә чалына башлады. Без килеп кергән якта Берлинның кайбер кварталлары җир белән тигезләнгән иде. Бу күренеш күңелләрдә аңлашылмый торган хис уятты. Бәлки, ярый торган уй да түгелдер, сезгә дә чират җиткән икән, дип шатландык без. Сугышның газабы тәмам үзәккә үткән иде шул.

Берлинга килеп туктау белән безне, ашыгыч рәвештә вагоннардан төшереп, шәһәргә алып киттеләр. Үзебез белән бернәрсә дә алдыртмадылар. Халыкның үзләре белән юлга алып чыккан әйберләре вагонда калды. Җимерек йортлар арасыннан әйләнеп-тулганып йөри торгач, зур мәйданга килеп чыктык. Бу — данлыклы «Александрплац» иде. Монда да тирә-юнь җир белән тигезләнгән иде. Әле дә күз алдымнан китми, җиде катлы бер йортның арткы стенасы, нинди могҗиза беләндер җимерелми калган һәм күңелдә дәһшәтле хис уятып тора иде.

Безне монда ашыгыч рәвештә җимерекләрне җыеп юл ачарга алып килгәннәр икән. Шунда кирпеч, пыяла ватыклары арасында йөргәндә язулы бер тактага күзем төште. Анда эре хәрефләр белән бу йортның подвалында биш йөз кеше күмелеп калды дип язылган иде. Әйе, «фюнф һундерт ман» тере килеш күмелгән. Бу йортның биш йөз кеше сыйдырышлы подвалы һава һөҗүме вакытында төшеп яшеренер өчен көйләнгән булган. Аның өстенә Американың оча торган крепостьларыннан ыргытылган берәр тонналы бомбалары эләккән. Без баштарак, болар бар да безнең авиация эше, дип уйлаган идек. Юк, безнең самолетлар бу тирәдә оча алмаганнар икән әле шул. Союзниклар чын-чынлап эшкә керешкәннәр. Көн саен әллә ничә мәртәбә һавадан һөҗүм итәләр. Гадәттә, һөҗүм төнлә башлана. Башта берничә йөз самолет килеп яндыра торган бомба ыргыта. Бөтен шәһәргә ут кабып, җир өсте шундый яктыра, энә табарлык була. Шушы гигант учак яктылыгыннан файдаланып, самолетларның икенче төркеме төрле авырлыктагы бомба яудырырга тотына. Күпмегә дөрестер, бишәр тонналы бомбалар да бар, дип сөйлиләр иде.

Немецләр үзләре башлаган сугышның чын мәгънәсендә тәмен татыйлар. Бүгенге көн биеклегеннән караганда, бәлки, килешеп тә бетми торгандыр, мондагы җимерекләрне күреп, миндә шигырь язу теләге туды һәм күңелгә түбәндәге шигъри юллар килде:

Гигант каберлеккә охшый Берлин,
Үлем йөри күзгә күренеп.
Барлык халык сукыр тычкан төсле
Көн үткәрә җиргә күмелеп.

Тынны кыса һавадагы сөрем,
Кинәт шунда тынлык бозыла.
Акыралар усал сиреналар,
Һәм кайдадыр бомба сызгыра.

Дәвам итә шулай көннәр буе,
Түккән күз яшьләре файдасыз.
Тынычлык юк Гитлер бар чагында.
Озакламый, бәлки, аңларсыз.

Аңла, фашист, көтмә мәрхәмәтне,
Ярларына сыймый безнең үч.
Ни булса да еламадык, түздек,
Бүген сиңа чират, син дә түз!..

Безне Александрплацка ничек ашыктырып китергән булсалар, шулай тыкырдатып алып та киттеләр. Без моннан алып китүләренә шатланып бетә алмадык. Җәһәннәмнең җиденче катын хәтерләткән Берлиннан тизрәк котыласыбыз килде.

Александрплацтан үзебезне төяп алып килгән вагоннар янына кайтып җиткәнче ике мәртәбә һава һөҗүме башланачагын игълан иттеләр. Сиреналарның коточкыч тавыш чыгарып улавын шәһәр эчендә беренче мәртәбә ишетүебез иде әле. Шуңадырмы, алар безгә бик начар тәэсир итәләр иде. Беренчесендә һава һөҗүме булмады, бик тиз отбой бирделәр. Икенчесендә озак көттермәде, күктә кояшны каплап, исәпсез-хисапсыз «оча торган креспотьлар» пәйда булды. Сөйләүләренә караганда, алар бик югарыда — ун мең метр биеклектә очалар. Имеш, зенит тупларыннан аткан снарядлар андый югарылыкка барып җитми. Аларның бернәрсәдән курыкмыйча, шундый югарылыкта иркенләп очып килүләре күңелдә сәер горурлык тудыра иде. Дөньяда фашистларга каршы торырлык көч бар икән әле, дип шатлана идек.

Безне сарык көтүе кебек куып, бер җимерек йорт ишегалдына керттеләр дә шундагы подвалга төшерделәр. Аны һава һөҗүменнән сакланыр өчен эшләнгән махсус бункер дип сөйләделәр. Бункерда бик озак, сәгатьтән артык утырдык. Монда аяк басар урын да юк иде. Карт-коры, бала-чага чыкмыйча тоташ шунда ята булырга кирәк, бөтен тормышлары шуңа көйләнгән. Йокларга карават куелган, ризыклары, эчәр сулары яннарында. Без бункердан чыкканда күк йөзе ачылган, ләкин тирәякта шартлаулар дәвам итә иде әле. Соңгы вакытта америкалылар акрынлык белән ярыла торган бомбаларны күбрәк тондыра башлаганнар. Алар якын тирәдә җан иясенең пәйда булуын көтеп кенә торалар икән. Шартлаулар берничә тәүлек буена дәвам итә. Берлиндагы хәлләр дини китапларда тасвирланган мәхшәрдән яманрак иде. Һавадан һөҗүм ясалмаган бер генә көн дә юк. Һөҗүм итү көнгә бер генә мәртәбә булса, түзәр дә идең, кайсыбер көнне оча торган крепостьлар сәгать саен диярлек бомбаны ташып кына торалар. Даими рәвештә яшәүчеләр игълансыз да аларның очып килү вакытын минуты белән төгәл әйтеп бирә алалар. Шунысы кызык: һава һөҗүме, күрәсең, ниндидер бер расписание белән башкарыла. Америкалылар расписаниене немецларның үзләренә хас төгәллек белән, үзгәртмичә үтиләр.

Берлинның кайбер районнары тәмам җир белән тигезләнгән булса да, бомбага тоту һаман дәвам итә иде. Фашистлар промышленность предприятиеләренең байтагын җир астына төшереп өлгергәннәр. Эшчеләр көн-төн җир астыннан чыкмыйча, ябылып эшләп яталар. Сөйлә-

үләренә караганда, җир астына яшерергә өлгермәгән заводлардагы станокларны Берлин тирәсендәге урманнарга күчергәннәр һәм алар шунда ачык һавада эшләрен дәвам итәләр. Мин андый урман эчендә көйләнгән станокларны поездда барганда үз күзләрем белән күрдем.

Бәхеткә дип әйтимме, безгә Берлиндә озак тоткарланырга туры килмәде. Килеп туктауга өченче тәүлек дигәндә алып та киттеләр. Шул тулы булмаган өч тәүлек тә өч ел кебек озын-озак тоелды.

Безнең поезд көнбатышка юл тотты. Берлинны калдырып киткәч озак бармадык, таулар арасына килеп кердек. Тау кырыйлары иге-чиге булмаган урман белән капланган. Ярымачык вагон ишегеннән бик соклanып тирә-юньне күзәтеп бардым. Андагы күренеш әкияттәге сыман иде. Тау башларына менгереп салынган замоклар бик еш күзгә чагыла. Гыйлаҗ да шуларны күзәтеп бара икән. Минем артка килеп басты: «Матур бит, ә?» — диде. Мин сүзләренә игътибар итмәгәч: «Әллә чукракландыңмы?» — дип сорады. «Кем белә инде аны. Читтән караганда матур да, эчендә ничектер бит. Минемчә, болар бар да кеше сөяге өстенә төзелгән. Аларны эшләгәндә һәлак булган бәндәләрнең исәбе-хисабы юктыр. Кирәк бит шулкадәр биеккә менгереп төзергә. Ул вакытларда бар да кул көче белән башкарылган лабаса. «Әйе, — диде Гыйлаҗ авыр сулап, — шулай килгән дөнья инде. Җир өстендәге барлык корылмалар да кеше сөяге өстенә салынган». Миңа аның фәлсәфәсе ошамады, сүзне икенчегә борырга уйлап: «Бөтенесе — таулары, замоклары, урманнары үзләренә булсын, Туган илебезгә ни житә?» — дидем. «Кем сине анда кайтара? Кайту юк инде ул безгә.» «Нигә алай өметсезләнәсең әле. Ил каршында гаебең юктыр ич?» «Юк та бит... Армиягә алынгач ант иткәнеңне хәтереңә төшер!» «Кул күтәреп әсир төшмәгәнсеңдер ич?»

Мин ничек итеп булса да Гыйлаҗның күңелендә өмет уты кабызырга теләдем: «Юкка син туган илгә кайтырга куркасың, — дидем, — әсирлектә булган халыкны тикшерерләр, тикшерми беркемне дә җәзаламаслар. Без бит монда миллионнар. Бу инде күбебезнең гаебе булмавын ачыклый. «Мин Гыйлаҗга бу сүзләрне әйттем әйтүен, тик үз сүзләремә үзем ышанмадым.

Көнбатышка киткән саен поезд йөрешен тизләтте. Бик күп вак һәм эре шәһәрләрне артта калдырып, Кассельгә килеп туктадык. Килеп туктауга бөтен булган әйберләребезне үзебез белән алып вагоннардан төшәргә боердылар. Димәк, шушы шәһәрдә туктап калабыз. Монда тирә-якта безнең күз күнекмәгән күренеш иде. Иң элек чисталык күзнең явын ала. Бөтен җирдә тәртип, кешеләр әдәпле, хәтта бер-берсе белән кычкырып сөйләшмиләр дә. Ә бит дөньяда моңа кадәр күрелмәгән сугыш бара. Безне сафка тезеп, урамга алып чыктылар. Аннан бик озак җәяү барганнан соң, шәһәрнең икенче кырыена килеп чыктык. Шәһәр әле бөтен килеш сакланган иде, беркайда да җимерекләр күренми. Монда халык һава һөҗүменең дәһшәтен үз җилкәсендә татып өлгермәгән иде әле.

Без чын мәгънәсендә шәһәрне кисеп уздык. Урамда ир-ат күренми диярлек. Күренгәне дә карт-коры йә сугыш инвалидлары. Бар да безне игътибар белән күзәтә, барган юлларында тукталып, безнең сафларны күздән югалганчы карап торалар.

Ниһаять, бара торгач, тирә-ягы таш койма белән әйләндереп алынган корылма янына килеп туктадык. Безне шунда алып керделәр. Анда бараклар тезелеп киткән. Алар буш, беркайда да кеше-кара күренми. Ишегалды чиста итеп җыештырылган, түтәлләрдә күзнең явын алырлык, төрле төстәге чәчәкләр үсеп утыра. Күрәсең, аларны махсус карап үстерүчеләр бардыр.

Соңыннан беленгәнчә, монда хәрби часть торган. Аларны без килер алдыннан гына фронтка озатканнар.

Кызыл кирпечтән салынган баракның бер башына хатын-кызларны, икенче башына безне — ирләрне урнаштырдылар.

Тын алырга да ирек булмады, икенче көнне таң белән эшкә алып киттеләр. Без, «И. Г. Фарбениндустри» концерны карамагына тапшырылганбыз икән. Бу гигант трестның Кассель шәһәрендә химия комбинаты һәм машина төзү заводлары урнашкан иде.

Беренче көнне завод ишегалдына килеп туктаган вагоннардан кәгазь бәйләмнәре бушаттырдылар. Аларны кәгазь дип атау бик дөрес үк булып бетмәс. Агачтан эшләнгән, кәгазьгә ошаган, бармак калынлыгындагы ак масса. Ул билгеле бер үлчәүдә тигез итеп киселеп, нык итеп төреп бәйләнгән. Һәр кисәкнең авырлыгы 50 килограмм. Аны Германиягә Финляндиядән чимал сыйфатында җибәрәләр икән. Ишегалды бик зур, берничә эшелон шунда тезелеп, бушатканны көтеп тора. Халыкны унарлап төркемнәргә бүлделәр дә эшкә куштылар. Һәр төркемне немец карап эшләтә. Безнең төркемне шактый олы яшьтәге бер немец кабул итеп алды. Җайлы кеше туры килде. Артык кумый да, тик торырга да ирек бирми. Сәгать саен эштән туктатып ял иттерә. Ул безнең белән сөйләшергә тели, ләкин беребез дә аның телен юньләп аңлый алмыйбыз. «Криг шайзе» дигән сүзен генә төшенәбез. Димәк, ул сугыштан риза түгел. Әйе, сугыш бөтен халык өчен начар. Немецка да, русларга да әйтеп бетерә алмаслык зыян китерә.

Ял иткән минутларда, немец берәм-берәм безнең белән танышты. Иң элек һәр кешенең исемен сорап блокнотына язып куйды. Минем исемне ул кат-кат сорады. Мин саф татарча итеп «Әнәс дигәч «интересант» диде, ләкин ни өчен «интересант» икәнен әйтмәде. Ул минем исемне үзебезчә итеп «ә» белән әйтте. Немец телендә безнекенә — татарныкына охшаш авазлар күп икән. Без аның үзе белән дә таныштык. Вильгелем исемле икән. Һер Вильгелем. Мин ул нәрсә әйтер икән дип, «Һер Вильгелем Пик»,— дидем. «Нейн, нейн!» — диде бармак янап немец, ләкин ачуланмады, шуның белән бетерде. Мин эчемнән генә, Вильгелем Пик исемен аңлагач, бу кеше немец коммунистлары турында азмы-күпме белә икән, дип уйлап алдым.

Һер Вилем — без аны, аларның үзләренчә, шулай кыскартыбрак атый башладык, безгә аңлаешлырак итеп әйтү теләге беләнме, сүзләрен гадиләштеребрәк сөйләшә иде. «Варум фиеле лойте гештребен — ни өчен шулай күп халык һәлак була?» — дип сорый да, җавабын да бирә, аңлап кына бетермибез.

Төштән соң һава һөҗүме игълан иттеләр. Ямьсез тавыш белән бертуктаусыз сиреналар үкерергә тотынды. Тиз генә бөтенебезне урамга алып чыгып, бункерга куып төшерделәр. Кайчан эшләп өлгергәннәрдер, ун метр тирәнлектә, берничә йөз кеше сыярлык зур бункер. Уты, суы үзендә. Һава һөҗүменнән сакланыр өчен һәр урамда шундый бункерлар бар икән.

Җир астына төшеп кенә өлгердек, якында гына бомбалар шартлый башлады. Шартлаулар шундый көчле, бетон белән ныгытылган түшәмнән тузан коела. Кисәк-кисәк ут сүнеп тора.

Өч сәгатькә якын җир астында утырып торырга туры килде. Без чыкканда тирә-якта бернәрсә күренми, күкне кара сөрем каплаган иде.

Безне кире завод ишегалдына алып барып, вагоннарны бушатып бетерттеләр. Ярты төнгә кадәр эшләргә туры килде. Баракка килгән юл белән кайтмадык, аннан үтә торган түгел, диделәр.

Ике-өч сәгать эчендә самолетлар шәһәрнең промышленность биналары урнашкан ягын юк иткәннәр. Исән калган халык исерек кеше кебек кая басканын, нәрсә сөйләшкәнен белми.

Без баракка кайтып кергәндә көчкә аякка басып тора идек. Ишектән керү белән ятакларыбызга түндек. Мин бик озак йокыга китә алмадым.

Иртә таң белән уятып, безне шәһәрнең икенче кырыендагы химия комбинатына алып киттеләр. Һава һөҗүменнән соң аның исеме генә калган иде. Ул берничә мең гектар җирне биләп тора. Хәзер асты өскә килгән. Аның бинасы тимер каркаслар ярдәмендә корылган. Безне завод территориясен җимерекләрдән арындырырга алып килгәннәр икән. Бу ансат кына башкарыла торган эш түгел иде. Бинаның өске катын тотып торган юан-юан чуен баганалар шартлап сынган. Шул баганалар өстенә көйләнгән бетоннан катырылган түшәм җимерелеп, кыйммәтле химик эшкәртүләр башкара торган көйләнмәләр чүп астында калган.

Без Гыйлаҗи белән бергә эшләргә вәгъдәләштек. Гыйлаҗи эретеп ябыштыру һөнәрен белә икән, тиз генә сварка аппараты сайлап алды. Миңа да бер аппарат тоттырды. Минем икеләнеп торганны күреп: «Курыкма, курыкма, үзем өйрәтәм»,— диде. Безнең сварка аппараты тотып торганны күреп, карап эшләтүче немец яныбызга килде һәм тантаналы тавыш белән: «Зие зинд швейсер?» — дип сорады. «Йа, йа, их зинд сварщик»,— диде Гыйлаҗи ярым немецча, ярым русчалап. Безнең арада Гыйлаҗидан башка эретеп ябыштыру һөнәрен белүче юк иде. Шуңа күрә безнең сварка аппаратына тотынуны немец хуплап кабул итте. Чөнки мондагы җимерекләрне, чуен баганаларны сварка аппараты белән турамыйча, җыеп алу турында уйларга да мөмкин түгел иде.

Тырышкан борыны белән таш тишкән, дигән борынгылар. Куркып кына тотынсам да, Гыйлаҗи ярдәмендә, сварка аппаратының хикмәтенә тиз төшендем. Бу эш чуен багана кисәкләрен, тимер-бетон ватыкларын күтәреп тышкы якка ташуга караганда күп мәртәбә җиңелрәк иде. Карап эшләтүче немец баштарак минем эштән ризасызлыгын белдереп мырлап маташкан иде, җан-фәрман тырышканны күреп, килешергә мәҗбүр булды.

Безнең эш яхшы ук шома бара иде. Төн җиткәндә җимерекләрне цехтан чыгарыр өчен юл ачып өлгерттек. Шунысы кызык, хуҗалар үзләре дә мәҗ килеп безнең белән бергә эшләп йөриләр иде. Безнең арада кайнашкан, атныкы кебек зур башлы, чандыр озын гәүдәле бер немецне химкомбинатның иң зур хуҗасы диделәр.

Төштән соң һава һөҗүме игълан иттеләр. Якында гына, урамга чыгып, бер чатны борылгач та, һава һөҗүменнән яшеренер өчен махсус эшләнгән бункер бар икән, барыбызны да шунда куып төшерделәр. Бункер бик зур. Берничә бүлектән тора. Алар җир астыннан борма-борма юллар белән тоташтырылган. Минем шул юллар белән йөреп карыйсым килде. Гыйлаҗины да үзем белән бергә барырга чакырган идем, теләмәде. «Арыдым, йөрер хәлем калмады»,— диде. Минем дә аруым тәмам җиткән иде. Шулай да үҗәтләнеп, җир асты юлы белән алга киттем. Эчкә узган саен халык азаеп, бара торгач, бер ялгызым калдым. Ни булса да булыр дип, юлымны дәвам иттем. Шактый баргач, алдарак мыдыр-мыдыр сөйләшкән тавышлар ишетелде. Мин шунда таба юнәлдем. Бераздан сөйләшү аермачык ишетелә башлады. Колакларыма ышанмадым. Әллә төш күрәм инде, әллә саташам, кайдадыр татарча сөйләшәләр иде. Кармаланып аерым бүлмәгә килеп чыктым. Түшәмдәге лампочкадан тонык кына яктылык сибелә. Өч кеше, почмакка посканнар да бик кызып гәпләшеп утыралар. Берсенең кулында шешә-рейнвин, алмадан эшләнгән шәрап. Соңыннан бу эчемлекне татып та карарга туры килде, көчле булмаса да градусы бар, эчкәч башка китә. Әлеге кешеләрнең өстендә ярымхәрби кием. Немец солдатларыннан калган булса кирәк. Чалбарларының тез башларына ямау салынган. Ни гаҗәптер, элек күзем шул тез башына салынган ямауга төште. Мин аларның каршына килеп бастым да сүз башларга кыймыйча аптырап калдым. Мине күргәч: «Ни кирәк икән бу карачкыга?» — диде аларның берсе. Ниһаять, минем дә телем ачылды: «Сез татармы әллә?» — дип сорадым. Аларның минем сорауга җавап бирергә исәпләре юк иде. «Кара, кара, әллә татарча

сөйләшә инде?» — диде икенчесе, миңа игътибар итмичә генә. Алар шешә авызыннан чиратлап рейнвенны эчеп бетерделәр дә тәмләп тәмәке тартырга тотындылар. Шактый вакыт узгач: «Утыр,— дип урын тәкъдим итте берсе,— нәрсә үрә катып торасың?». Болай дорфа сөйләшү кытыгыма тисә дә, сер бирмәскә тырыштым: «Савап булсын, әлек күрешик әле»,— дидем кулымны сузып. Алар теләмичә генә кулларын бирделәр. «Болай килешеп бетми, исемнәрне әйтеп сөйләшик әле»,— дидем мин. «Белер иде бугай?!» «Нәрсәгә аны яшереп торырга? Менә мин Әнәс исемле». Җитди тон белән сүз башлау әңгәмәдәшләремне кинәт үзгәртте. «Ничек син монда килеп чыктың әле?» «Минем монда килеп чыгуымны бер-ике сүз белән генә аңлату мөмкин түгел, озаклап сөйләргә кирәк». Шулай да, кыскача гына булса да узган юлымны сөйләп бирергә туры килде.

Бу өч кешенең икесе минем якташлар булып чыкты. Гаян исемлесе Питрәч районыннан, ә Хәмит Саба ягыннан, Сабай авылында туган. Өченчесе Нурмый исемле — Башкортстаннан. Авылын да әйткән иде, исемнән чыккан, хәзер хәтерләмим. Алар өчесе дә хәрби әсирләр. Кырык бернең көзендә Запорожье өчен барган сугышларда әсир төшкәннәр икән. Мин дә ул сугышта катнашкан идем. Аларга ул турыда сөйләп торуны кирәк тапмадым.

Хәрби әсирләр лагеренда булган кешенең хәле әллә каян күренеп тора, бик йончыганнар, бигрәк тә Гаянның хәле начар. Йөзенә зәгъфран сарысы төшкән. Бертуктаусыз йөткерә. Җитмәсә, үзе тәмәке пыскыта.

Гәпләшә торгач, без тирәнгә кереп киттек. Мин аларга күңелемне кытыклап торган сорауны бирдем: «Сезгә ничек боларны киерттеләр?» — дидем, өсләрендәге ярымхәрби киемгә күрсәтеп. «Син сорама, без әйтмибез»,— диде Хәмит кулын селтәп. Нурмый сүзгә кушылды: «Безне немец армиясенә алмакчылар иде,— диде авыр сулап.— Алла саклады, котылдык». «Ничек?» — дип сорадым мин, гәрчә аларның немец армиясеннән ничек котылулары яхшы таныш булса да. Кырык беренче елны әсирлеккә төшкән солдатларның хәле аеруча аяныч иде. Алар чебен кебек кырылдылар. Бик сирәге исән калды. Исән калганнары да тиз генә аякка басарлык түгелләр иде. Болар да минем кебек сәламәт булмаулары аркасында немец армиясендә хезмәт итүдән котылып калганнар. Башка лагерьларда ничек булгандыр, әйтә алмыйм, мин булган лагерьда ризалык сорап тормыйлар иде, физик яктан таза тоткыннарны аерып сафка тезәләр дә — әйдә киттек, берәр милли легионга, яки Власов армиясенә — РОАга эләгүләрен үзләре дә сизми калалар иде. Без кызып, берберебезнең хәлен сорашып яхшылап таныша башлагач кына, сиреналар ачы акырып, һава һөҗүменең бетүен игълан итте. Теләсәк-теләмәсәк тә таралышырга туры килде. Соңыннан, бер ял көнендә әлеге егетләр үзләре мине эзләп таптылар. Аларның командасы шушы без яшәгән хәрби шәһәрчектән ерак түгел, икенче бер аерым баракта урнашкан икән. Монда килгәнче шактый вакыт Франциядә яшәгәннәр. Анда аларны немецларның «атлантиквал» дигән корылмаларында эшләткәннәр. Күчерүнең сәбәбе шул, сәламәтлеге яхшы булган тоткыннар күпләп француз партизаннары ягына кача башлаган. Әйтүләренә караганда, болар да качарга җыенганнар, ләкин партизаннар белән элемтәгә керергә өлгермәгәннәр. Качкан булсалар да, бу чирләшкәләр әлләни эш кыра алмаслар иде. Хәмиткә бер хатынга өйләнеп Франциядә калырга мөмкин булган. Бер көнне шулай алар яшәгән лагерьга урыс милләтеннән булган егетләрне күреп сөйләшергә теләп, бер карт марҗа килә. Тоткыннар яңа гына эштән кайтып, ашханәдә ашап утырган вакыт була. Лагерь начальнигы марҗаны үзенә ияртеп шунда алып керә. Марҗа ашап утыручыларга мөрәҗәгать итеп: «Кемнәр бар монда урыс милләтеннән?» — дип сорый. Беркем дә җавап бирми. Немец аптырап калмый, марҗаны Хәмит ашап утырган өстәл янына алып килеп: «Менә бу урыс кешесе»,—

дип тәкъдим итә. Маржа аны: «Ник син милләтеңне яшерәсең?» — дип табалый башлагач, Хәмит: «Мин милләтем буенча урыс түгел, татар»,— дигән. «Россия кешесе булгач, миңа барыбер»,— дип, маржа Хәмитне өйләренә алып киткән. Ул череп баеган җирбиләүче бер алпавыт икән. Шактый зур утары бар, бик күп хайван асрый: егермеләп сыеры, берничә баш ат, дуңгыз, тагын вак хайваннар тота.

Маржа беренче эш итеп Хәмитне байлыгы белән таныштыра. Йорт-җир менә дигән, бар да төзек. Кырда иген эшләрен башкарыр өчен тракторы да бар. Гаражында йөк машинасы, җиңел автомобиле. Йортта белсәң, утыр да кит. Китапханәсендәге китапларны да күрсәтә. «Менә шушы йорттагы байлыкка хуҗа буласың киләме?» — дип сорый маржа. Көтелмәгән бу сораудан Хәмит югалып кала. Аны үчекли дип уйлый. Бактың исә ул чын-чынлап сөйләшә икән. Эш шунда, күптән түгел генә ирен җирләгән. Алар сазаеп килә торган кызы белән икесе генә калганнар. Ул турыдан-туры Хәмиткә кызына өйләнергә тәкъдим итә. «Мин хәзер картайдым, туган илем Россиягә кайту турында уйларга да мөмкин түгел. Кызым үзенә кияү табачак, ул турыда шигем юк, әмма ул безнең кеше булачак түгел. Берәмтекләп, күп көч куеп җыйган байлыгымны үзебезнең кешегә калдырасым килә. Ничек кенә булмасын, син үзебезнең ил кешесе. Әгәр кызыма өйләнсәң, йорт-җиремне, бөтен байлыгымны синең исемгә яздырам»,— дип әйтә. Мондый тәкъдим Хәмитнең башын әйләндерә әйләндерүен, шулай да ул өзеп җавап бирми, уйлап карармын»,— ди. Маржа аңа күп уйлап баш ватмаска киңәш итә. «Кызыма өйләнсәң, минем немец властьлары белән сөйләшеп, сине әсирләр лагереннән азат иттерергә мөмкинлегем бар»,— ди. «Мин бөтенләй югалып калдым,— дип сүзен дәвам итте Хәмит,— ярый өйләнерсең, байлыкка да хуҗа булырсың, ә иман, гореф-гадәт, ул хатын мөселман булса тагын бер хәл иде, маржа бит. Ничек инде мин, әниемнең күкрәк сөте белән тәнемә сеңгән иманымны, изге гадәтләрне сатыйм? Күз алдыма, авылыбызда тилмереп мине көтеп торучы әнием килеп басты. Хәбәрем булмаса да, аның мине көтүенә чын күңелдән ышанам. Әгәр өйләнеп монда төпләнеп калсаң, беркайчан да миңа туган илгә кайту насыйп булачак түгел. Бәлки дөньялар үзгәреп, туган илгә кайту мөмкинлеге дә туар, әгәр монда өйләнәм икән, мин анда барыбер чит кеше булачакмын. Юк, чит-ят илдә калу мөмкин хәл түгел. Икенче көнне үк марҗаның тәкъдименнән баш тарттым» «Җүләр син,— диде Нурмый очынып,— очрамады бит миңа шундый бәхет. Икс дә уйламас идем, өйләнеп шушында калыр идем». Нурмый бик яхшы сәүдәгәр иде. Ул немецлар белән теттереп сәүдә итә. Аларның телен дә ярыйсы гына үзләштереп алган. Дөрес, аңа зурдан кубып сәүдә итәргә мөмкинлек юк. Аның товары вак-төяктән тора. Иң үтә торган товар — тәмәке, азык-төлек. Аңа товарны немецлар яшерен рәвештә китереп торалар. Нурмыйның уңышлы сәүдә итүе күзгә күренә башлады. Кешелеккә кияргә аерым кием юнәтте. Таушалган булса да, чиста костюм-чалбар, агачтан алынган тукымадан ак күлмәк, күзнең явын алырлык галстук. Мәгәр, миңа гына шулай күренгәндерме, бу киемнәр аңа бер дә килешми иде. Эш шунда, аның тәнендә чебен чукырлык та ит юк. Кигән киеме элеп куйган шикелле асылынып тора. Тәмәке тарта да бумаланып йөткерергә тотына. Әйтеп үтәргә кирәк, тәмәкенең менә дигәнен, хуш ислесен генә тарта. Каян юнәтә торгандыр, күбесенчә пөхтәләп, көмеш төсле кәгазьдән ясалган капка салынган, төрек сигареты була. Һәр кабында бары алты данә.

Аның бармагы саен балдак. Араларында кыйммәтле металлдан эшләнгәннәре дә бар иде бугай. Ул алар белән дә сату итә. Бармакларындагы балдаклар бер күбәя, бер азая, саннары гел үзгәреп тора.

Гаян да сату итә. Ул — холкы-фигыле белән Нурмыйның капма-каршысы. Йөрергә яратмый. Дөресрәге, эштән соң йөрерлек хәле калмый, кайту белән караватына егыла. Урында ятып торган килеш сату-

алуны башкара. Аның товары — иске-москы кием. Аңа аларны немецлар китерә һәм арзанга гына биреп китәләр. Гаянның яратып сату итә торган товары — аяк киеме. Ул аларның кайсы берсен каккалап-суккалап булса да кеше кызыгырлык иттерә.

Хәмит иптәшләренең берсенә дә охшамаган. Ул аларның сәүдәгәрлеген яратып та бетерми. Шулай да икесен дә чын күңелдән хөрмәт итә. Безнең икебезнең өс-баш киемнәре бертөслерәк. Аннан-моннан табып кигән иске-москыдан гыйбарәт.

Хәмит берничә төрле һөнәргә ия. Төп һөнәре буяучы, мәгәр Саба ягы кешеләренә хас булганча, яхшы тегүче дә ул. Тегенди-мондые гына түгел, җиренә җиткереп тегүче. Аның да, минем дә баш киемнәре бик хөрти иде. Ул тиргә катып каешланган пилотка киеп йөри. Минем башта Станиславтагы лагерьдан качкач авыл карчыгы бүләк иткән иске фуражка. Мин Хәмитне баш киеме тегәргә димли башладым. Ул башта үзенең бервакытта да баш киеме теккәне булмавын сәбәп итеп, бу эшкә тотынырга теләмәде. «Бөтен тегүче дә баш киеме тегә алмый, аңа махсус өйрәнергә кирәк»,— диде. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, газапланып кепка тектереп ятмаска, әзер баш киеме табып кияргә дә мөмкин булыр иде. Минем үзебезнең илдә киеп йөри торганга охшаганны киясем килде. Ялынып сорый торгач, Хәмит кепка тегәргә тотынды. Тегү машинасы юк-югын, аңа кепканы кулдан тегәргә туры килде. Нурмый безгә киелгән солдат френче табып бирде. Сүтеп чистарткач, аннан ике кепка тегәрлек материал чыкты. Хәмит иң элек миңа тегеп бирде. Ул теккән кепканы барыбыз да ошаттык. Мактау сүзләрен ишеткәч, Хәмит канатланып китте һәм тиз генә үзенә дә кепка тегеп киде.

Эш авыр, ашау такы-токы. Минем хәл көннән-көн хөртиләнеп, юк сәламәтлегемнән дә яздым. Төннәрен йоклый алмыйм, манма тиргә батып ятам. Барлы-юклы ризык та тамактан үтми башлады. Температурам күтәрелеп, бөтенләй аяктан егылдым. Бер көнне фельдшермы, врачмы, кем икәнен белмәдем, температурамны үлчәде. Градусникны алгач, әллә күзләренә ышанмады инде, тагын куеп карады. Температурам гадәттән тыш югары күтәрелде, ахры, бөтен тәнем ут кебек янып, бернәрсә сизми башладым. Күземне ачканда аерым бүлмәдә ята идем. Изоляторга урнаштырганнар икән.

Нишләргә белмичә, ут кебек кызышып ятканда минем янга өсләренә ак халат киеп, җиңнәренә кызыл хач сурәтле ак тасма бәйләгән ике хатын килеп керде. Үзара сөйләшүләреннән шул аңлашылды: аларның берсе — врач, икенчесе шәфкать туташы иде. Врачы шактый олы яшьтә, шәфкать туташы баласымак бер кыз. Врач мине чишендереп, бик озаклап күкрәгемне тыңлады. Аннан яткырып, сул як кабыргама озын энә тыкты. Мин энә аша аккан суны күреп шашып калдым. Бик күп су акты. Врач эшен бетереп чыгып киткәч, хәлем җиңеләеп, йокыга киткәнмен. Күпме йоклаганымны хәтерләмим, уянганда бөтенләй икенче кеше идем инде.

Эштән кайткач, Гыйлаҗи белән Хәмит минем хәлемне белергә керделәр. Алар күчтәнәчкә алып кергән, маргарин ягылган калын бер телем икмәкне бик яратып ашадым.

Миндә плеврит дигән авыру башланган икән. Мондый исемдәге хаста турында беренче мәртәбә ишетүем иде. Күкрәктә сары су җыелып, үпкәне кыса һәм температура күтәрелә. Тагын берничә мәртәбә үпкәмнән су суырттылар. Шуннан соң гына бераз рәтләнеп, эшкә йөри башладым. Немецләрнең үзләрен тотышы сәерләнеп китте. Бездән — чит илдән китерелгән эшчеләрдән яшереп үзара сөйләшәләр. Җиңү турында серләшкәндә тавышлары бик көр чыга иде, хәзер, мөгаен, телгә яңа сүзләр кергәндер.

Көннәр, айлар үтә торды. Без яңа — кырык бишенче елны зур өметләр белән каршыладык. Алда фаҗигале язмыш көткәнне беребез дә күз

алдына китерә алмый идек. Дөресрәге, ул турыда уйларга да теләмәдек, бары тик туган илне кайтып күрү теләге белән генә яна идек.

Яңа елдан соң болай да халык белән кырмыска оясы кебек мыжлап торган Германия тагын да тарайды. Фронт якынлашкан тирәләрдән халык ташкыны һаман Германиянең үзәгенә агылды.

Көнбатышта союзниклар Рейнны кичте, көнчыгышта безнекеләр Пруссиягә бәреп керде.

Яңа елдан соң хәлем тагын да мөшкелләнде, бик еш температурам күтәрелеп, аппетитым бетте. Бертуктаусыз ютәл газаплады. Буылып йөткергәндә авыздан кисәк-кисәк куе кан килә башлады.

Март урталарында мине тагын изоляторга илтеп тыктылар. Анда миннән башка тагын ике кеше бар иде. Берсе латыш егете Степпе Петр, икенчесе украинлы Перловский Микита. Алар да кан төкерәләр. Безне изоляторда озак тотмадылар, йөк машинасына утыртып алып киттеләр. Машина агач шакмаклар ягып йөрергә көйләнгән. Чөнки Германиядә күптән инде бензин кытлыгы башланган иде. Аның үз җирендә нефть табылмый, башка илләрдән китерү мөмкин түгел, союзниклар блокада оештырган. Күпмегә дөрестер, самолетларга ягулыкны ташкүмердән алалар дип сөйлиләр иде. Билгеле булганча, немец җирендә ташкүмер җитәрлек.

Утырган машинабыз бик акрын кыймылдый. Безнең кебек үк бертуктаусыз «йөткерә, төчкерә». Агач шакмаклар янганнан барлыкка килгән кара төтен, җил уңаена машина әрҗәсе өстенә тарала, тынны кыса. Ярый әле юл яхшы, бетон плитәләр өстеннән машина салмак кына бара, артык селкетми. Югыйсә, безнең илдәге кебек сикәлтәле юл булса, үпкәләребез өзелеп төшәр иде.

Безне Кассельдән халык эштә вакытта алып киттеләр. Иптәшләрем минем китүемне белми калды. Гыйлаҗи белән мәңгегә аерылдык, аның белән башка очрашырга туры килмәде. Язмышын да белмим. Юлда озак булдык. Берничә мәртәбә машина ватылып, аны рәтләделәр. Ниһаять, кич кырын, чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынган ике катлы бина янына килеп туктадык. Гадәттәгечә, шәһәр кырые юк. Шәһәр зур түгел, бер ягыннан икенче ягы күренеп тора.

Чәнечкеле тимерчыбыкны күргәч, эчем жу итте. Тагын тоткыннар лагере! Шулай ук миңа сугышның ахырын күрергә насыйп булмас микәнни? Капканың төбенә кадәр ачык булуы һәм анда сакчыларның юклыгы бераз тынычландырды. Безне өстенә ак халат кигән карт немец кабул итеп алды. Врач. Димәк, хастаханә сыман урын.

Врач безнең белән озак маташмады, берәм-берәм күзеннән үткәрде дә бер хатынга тапшырды. Бусы шәфкать туташы булса кирәк. Шактый олы яшьтә, төксе генә сөйләшә. Ул безне проходнойдан шактый читтәрәк, бер бинага кертте. Бүлмәдә озын гәүдәле урыс егете ялгызы ята иде. Исеме Вася, фамилиясе Русских икән. Хәл-әхвәл сорашкан арада Мәскәүле булуы белән шапырынып алырга да өлгерде. Сүзен дәвам итеп: «Сездә, димәк, ачык формадагы тбц,— диде,— югыйсә, минем янга теләсә-кемне яткырмыйлар. Авыруым йогуыннан шикләнәләр».

Аның сүзләренә әллә ни игътибар итмәдем. Һаман әле, ачык формадагы үпкә авыруының кеше тормышы өчен куркыныч булуы аңыма барып җитми иде. Бу больницага үлә алмыйча газапланучы, ачык формадагы үпкә авырулы чит илдән көчләп китерелгән эшчеләрне җыялар икән. Шәһәр Һерборн дип атала. «Монда немецләрнең үзләре өчен зур госпиталь бар,— диде Вася, кулы белән тәрәзәгә ымлап:— Әнә ул теге якта, тау башындагы урман эчендә. Анда үпкә авырулы хәрбиләр дәваланa. Безнең халыкны ул тирәгә якын да китермиләр».

Икенче көнне зонага бүленгән ишегалдына чыгып әйләнеп кердем. Безнең якта йогышлы-ачык формадагы үпкә авырулылар, ә икенче якта савыга башлаучылар ята. Бер зонадан икенче зонага йөрү катгый

рәвештә тыела. Больницада ашау-эчү такы-токы иде. Шулай да, әсирләр лагерендагы белән чагыштыра торган түгел. Җан сакларлык.

Килеп берничә көн узгач, латыш егете аяктан егылды. Без аның белән яшьтәшләр идек. Ул минем татар кешесе икәнемне белгәч, бик кызыксынды. Немец һәм урыс сүзләрен бутап, Латвиядә дә татарлар яшәвен аңлатты.

Степпе Кызыл Армия һөҗүмгә күчеп Латвиягә килеп җиткәч, туган иленнән качкан. Германиядә шәһәрдән шәһәргә күчеп йөри торгач, Кассельгә килеп чыга, һәм заводка эшкә урнаша. Тик эшләргә генә туры килми, үпкә чире эләктерә.

Перловский тумышы белән Көнбатыш Украинадан — Львов шәһәре тирәсендәге бер авылдан иде. Атасы таза хәлле крестьян булган. Ике үгез, берничә сыер, күпсанлы дуңгыз һәм вак хайван асраган. Ул Совет строен җаны-тәне белән сөйми иде. Сәбәбе — колхоз. Алар хуҗалыгын колхозга да алмаганнар. Милекләрен конфискацияләп, үзләрен Себергә озатканнар. Микита Себергә китүдән качып котылган. Башта Карпат таулары итәгендә урманда качып яшәгән. Анда да куркыныч тугач, Польшага күчкән. Иң куркынычы чик аша үтү булган. Тырыша торгач, әмәле табылган. Кеше аягы басмаган сазлык аша үтәргә туры килгән. Ул озын таяклардан аяк ясаган. Тирәнгә батмас өчен таякның җиргә тия торган башын тактага беркеткән. Шулар ярдәмендә Польшага чыгып ычкынган. Перловский тасвирлаган агач аяклар миңа бик таныш иде. Авылда, бала чагында без дә таяктан аяк ясап уйный торган идек. Без аны күтәрмә дип атый идек. Күнеккәч, йөрүе кыен түгел.

Колхозлар турында сүз чыкса, Микита агарынып китә һәм калтырана ук башлый. Ул каһәр суккан колхоз аркасында туган иленнән качарга мәҗбүр булган. Шулай да аның һәрбер сүзеннән туган авылын өзелеп сагынуы сизелеп тора иде. Ләкин анда кайтып кеше күзенә күренү мөмкин түгел. Иң яхшы очракта, аны тотып, ата-анасы янына Себергә озатачаклар иде.

Микита белән безнең гәп килешә иде. Күп сөйләшә торгач шул аңлашылды: аның туган авылы мин Станиславадан качып киткәч, каңгырап йөргән тирәдә булып чыкты. Ул укымышлы егет иде. Күп китапны күңеленә бикләгән. Шевченко, Иван Франко шигырьләрен яттан белә. Хәле көннән-көн начарланып, Степпе урыныннан тора алмас хәлгә килде. Аңа ашауны палатага кертәләр иде. Ләкин аның тамагыннан аш үтми башлады. Безнең палатага Урсула исемле шәфкать туташы хезмәт күрсәтә иде. Ул җитен кебек сары чәчле, урта буйлы. Диңгез суы кебек зәңгәр күзләре өздереп карыйлар. Авыруларның бирсен дә чит итми, һәркемгә тигез карый. Урсула дежур торасы көнне без түземсезлек белән көтеп ала идек. Аңа алмашка эшләүче шәфкать туташы Мария шактый олы яшьтә, сытык чырайлы, бер мәртәбә дә елмаеп дәшкәнен хәтерләмим, үзен бик олы сымак тота, немец милләтеннән булган кешене, холкы белән нинди булуына карамастан, якын күрә. Кыскасы, милли социалистлар рухында тәрбияләнгән хатын иде.

Берничә көннән Степпе телдән калды. Ул шулай өч-дүрт көн үлә алмый газапланды. Күзләре ачык, сөйләшергә аңы юк. Без Микита белән чиратлашып төнне баш очында саклап утырдык. Бал кашыгы белән авызына су салдык. Авызыннан су үтми башлады. Чиктән тыш газапланып бик озак җан бирде. «Бу адәмнең Алла каршында бер гөнаһысы да калмагандыр инде,— диде Микита,— кирәк бит шул кадәр газапланырга!»

Степпе яткан карават озак вакыт буш тормады. Бер көнне ишегалдында һавада йөреп кайтып керсәм, Степпе яткан урында Хәмитне күреп, үз күземә үзем ышанмадым. Миннән соң аңа да озак эшләргә туры килмәгән, кан төкерә башлаган. Җимерекләрне җыеп бетерү белән халыкны җир асты цехларына күчергәннәр. Анда Финляндиядән килгән кәга-

зьләрне төрле химикатлар ярдәме белән эшкәртергә тотынганнар. Халык, ач, эш — агулы күп кеше бик тиз аяктан егылган. Хәмитнең сөйләвенә караганда, нәрсәләр генә ясамаганнар казаннарда эшкәртелгән ул кәгазь массасыннан. Ул елларда Германиядә бөтен кием-салым, армияне дә исәпкә алып, агачтан эшкәртелгән массадан барлыкка килгән тукымадан тегелә иде. Эчке кием, костюм-чалбар, ефәккә охшаган ялтыравыклы материядән тегелгән хатын-кыз күлмәкләре — бар да агачтан дип сөйлиләр иде. Аяк киеме, бил каешы һәм башкаларның агачтан эшләнгән синтетик күннән икәне гади күзгә дә күренеп тора иде. Башканы әйткән дә юк, автомашинага ягулык та агачтан алына иде.

Хәмит минем белән бер палатага туры килүенә бик шатланды. «Нурмый белән Гаян да монда,— диде ул,— өчебезне бергә алып килделәр. Аларны икенче бинага алып кереп киттеләр. Әзрәк хәл алгач, бергәләп эзләрбез, Алла теләсә...»

Хәмит шул аерылып торган аз гына арада танымаслык булып үзгәргән иде. Йөзенә зәгъфран сарысы чыккан. Йөткергән саен авызыннан сыек кан килә. Цехның агулы һавасы аны тәмам эштән чыгарган.

Ниһаять, фронт безнең тирәгә дә килеп житте. Артиллерия канонадасы колакны тондыра. Хәтта пулеметтан, автоматтан аткан тавышлар да ишетелеп тора. Немец гаскәрләре күптән китеп беткән булса да, америкалылар шәһәргә кермәделәр. Ләкин шәһәр тирәсен утка тотуны дәвам иттеләр. Көн-төн күктән самолетлар өзелмәде. Алар шулкадәр түбән төшеп очалар, миңа кулны югарырак күтәрсәң, самолетка тияр кебек тоела иде. «Алар үз кешеләрен ничек сакларга беләләр,— диде Хәмит авыр сулап,— безнекеләр кебек күрә торып ут эченә илтеп тыкмыйлар.»

Бер атна чамасы вакыт узгач, Америка солдатлары безнең больницаны уратып алды. Авыруларның аягына басарга хәле булганы капка төбенә ыргылды. Хәлем чиктән тыш авыр булса да, мин дә чыктым. Солдатлар бар да машинага утырган. Бер солдатка бер «Виллис». Каршыларына килеп баскан авыруларга ашау ризыгы өләшергә тотындылар. Ак күмәч, колбаса, сыр, шоколад, тышына дөя сурәте төшерелеп, «Кэмел» дип язылган кәгазь каплы сигарет. Сигаретны мин дә бер суырып карадым. Шундый каты, үтенне сытарлык. Ләкин хуш исле. Күмәчләре сөт кебек ап-ак һәм йомшак, йомарлап тотсаң, бер бөтенә учка сыя.

Ул көнне без больница ашын ашамадык. Алдагы көннәрдә дә Америка солдатлары биргән ризык житеп барды. Хәер, безгә монда озак торырга туры килмәде. Тау башындагы госпитальгә күчерделәр. Ул махсус үпкә чире белән авыручылар өчен оештырылган «Дойче Һаупте Һоспиталь» дип атала. Җимеш бакчасы эчендә ике катлы акка буялган биналар тезелеп киткән. Корпуслар бер-берсеннән шактый ара калдырып корылган. Бөтен җирдә чисталык. Саф һава.

Без монда да Хәмит белән бер палатага эләктек. Өч урынлы палата ятып торыр өчен йомшак ятаклар. Баш очында шәхси әйберләрне саклар өчен тумбочка бар. Урын-җирнең пөхтәлеген әйтеп бетерә торган түгел.

Хезмәт күрсәтүче персонал — бар да немецлар. Хәрбиләр. Погоннарын да салмаганнар. Элек нинди формада булсалар, шул хәлдә йөриләр. Бары җиңнәренә кызыл тәре төшерелгән ак тасма гына бәйләгәннәр. Алар безне яхшы кабул иттеләр. Дошманлык, чит кеше итеп карау сизелми иде.

Күчеп килгән көнне үк мине врач карады. Ярты гасыр вакыт узуга карамастан, врачның дәрәҗәсе һәм фамилиясе истән чыкмаган.— Штабсарц Һартман... Ул мине бик озаклап тикшерде. Арттан, алдан яткырып үпкәләремне тыңлады. Тәнем чиктән тыш ябык, кабыргаларым берәмләп санарлык булып тырпаеп тора. Тикшереп бетергәч, подвалга алып төште. Анда шактый зур бүлмәдә рентген аппараты бар икән, моңарчы

күргән нәрсәм булмагангамы, озак кына аппаратка көйли алмый алҗыдылар. Күкрәгемне рентген нурлары белән яктыртып, врач шәфкать туташына нәрсәдер әйтеп яздырды. Мин ул әйтеп яздырган сүзләрдән «ленкс, лунге каверно!» дигән сүзләрне абайлап калдым. Рентген аппараты артыннан чыккач, күршедәге икенче бүлмәгә алып керделәр. Һаман подвалдан алып чыгарга исәпләре юклыгын сизеп, шикләнеп куйдым. Бу бүлмәдә миңа кушеткага сузылып ятарга боердылар. Аның янында тагын ниндидер аппарат тора иде. Штабсарц итчеләрнеке кебек иләмсез зур кулы белән сулъяк кабыргамны сыйпап алды да, энә кертеп җибәрде. Аннан аппараттагы пыяла приборны күзәтеп, шунда басып торучы шәфкать туташына «лангсам, лангсам» дип ниндидер күрсәтмәләр бирде. Кинәт йөрәгем урыныннан купкан төсле булып, бөтен гәүдәм куырылып килде. Аягымны көзән җыера башлады. Врач мине тынычландырырга теләп, нидер сөйләнде. Процедура шактый озакка сузылды. Подвалдан үз аягым белән чыга алмадым. Носилка белән күтәреп алып менделәр.

Беренче көнне урынымнан кузгала алмадым. Әз генә кыймылдасам да, тәнем меңләгән энә кадалган төсле булып чәнчеште. Соңыннан белдем: минем сулъяк үпкәмне өрдерткәннәр икән. Һава белән үпкәне кыстырып, каверналы яптырганнар. Ике-өч көннән әгъзаларым үпкә кысылганга ияләнеп, хәлем яхшыра төште. Хәтта торып йөри башладым. Аппетитым ачылды. Башта, хәтерем алдамаса, үпкәне көн аралаш өрдерттеләр. Бераздан өрдертү сирәгәйтелде.

Нурмый белән Гаян бездән шактый ерак, бакча түрендәге бинага урнаштылар. Хәмитнең дә үпкәсен өрдерттеләр. Гаянның үпкәсе кабыргасына ябышып үскәнлектән — спайка — өрдертергә ярамый, диделәр.

Госпитальдә озак иркенләп яшәргә туры килмәде. Бертуктаусыз авырулар агылды. Безнең палатага ике өстәмә карават куйдылар. Берсенә — Кинҗәгалиев фамилияле казах егетен, икенчесенә Фролов фамилияле урыс кешесен яткырдылар. Алар икесе дә үзләрен бик серле тоталар, сүзгә катнашмаска тырышалар. Кинҗәгалиевнең хәле чиктән тыш авыр, тамагына бер тәгам ризык капмый. Авызыннан кан килә. Мин татарча эндәшкәч, ул ачылып китте. «Нугаймы сән?» — дип, хәле булмаса да сикереп торып утырды. Ул миңа караганда яшьрәк — бары унтугыз яшендә генә иде. Армиягә кырык дүртнең башында алынган. Варшава тирәсендә барган сугышларда әсир калган. Ике ай чамасы әсирләр лагеренда газап чиккәч, «Төркстан» легионына эләккән. Әсир калган Урта Азия халыкларыннан оештырылган бу хәрби берләшмәдән ул үпкә авыруы белән чирләп котылган. Хәзер аңа бернинди дәва ярдәм итәрлек түгел иде инде. Мин аның тумышы белән кайдан булуын сорарга да өлгерми калдым. Бер төнне бик газапланып җан бирде. Ул үләр алдыннан әнисе белән саташты. Өзелеп-өзелеп әнисеннән ярдәм сорады. Бөтен сүзләрен аңлап бетерә алмадым, әлбәттә. Аның һич тә үләсе килми иде. Туган иленә кайтып җиткәнче генә булса да яшәргә тели иде...

Тора-бара Фролов Петр Иванович белән дә уртак тел таптык. Ул ак офицер. Подполковник. Уфа губернасы, Минзәлә өязендәге авылларның берсендә туган. Татарстан, Башкортстан дигән атамаларны ишетергә дә теләми. Ул үзенең чыгышы белән шапырынырга ярата: «Сез, сез генә түгел күпчелек, революциядән соң Россияне байлар гына ташлап китте дип уйлый. Менә мин үзем ярлы крестьян малае. Бабам крепостной булган. Әтием гомере буе алпавыт утарында эшләгән. Дөрес, аңа җир биргәннәр. Эшкәртергә хәленнән килмәгән. Минем кебекләр монда миллионнар. Бер Франциядә генә әллә ничә йөз мең урыс эмигранты яши». Аның башыннан үткәргән хәлләрне язып та, сөйләп тә бетерә торган түгел иде. Фаҗигале дә, мәзәк тә. Петр Иванович урыс-Япон сугышында катнашкан. Аннан алдарак Порт-Артурда хезмәт иткән. Кытай халкы белән якыннан аралашкан. Аларның безгә ят күренгән кызыклы гореф-

гадәтләрен сөйләп, эчне катырып бетерә торган иде. Гражданнар сугышы елларында ул башта Деникин, аннан Врангель армиясе сафларында булган. Кызыл Армия Кырымны алгач, алар Төркиягә эвакуацияләнгәннәр. Аннан Югославия, Франция... Россиядә аның хатыны, баласы калган. Шуннан соң өйләнмәгән, буйдак булып гомер үткәрә икән. Никадәр тырышса да, гаиләсе белән элемтәгә керә алмаган. Фролов — монархист. Патшадан башка Россияне күз алдына китерергә дә теләми. Сөйләвенә караганда, Гитлер ак эмигрантлардан армия төзеп, Советларга каршы Көнчыгыш фронтка җибәрергә җыенган. Монархистлар аның бу тәкъдимен кабул итмәгәннәр. Имеш, сугыштан соң, Гитлер планы буенча Украина Германиягә кушылырга тиеш булган. Россия Украинасыз Россия түгел!» — ди Петр Иванович катгый рәвештә.

Фроловның яше алтмыштан узган иде инде. Ул һаман туган илгә кайтудан өметен өзми иде әле. Аның уйлавынча Германия җиңелгәч, Америка белән Россия арасында сугыш башланырга тиеш. Бу бәрелештән Америка файдасына тәмамлануына һич тә шиге юк иде. Аннан соң инде телиләрме, теләмиләрме — большевиклар эш башыннан китәргә тиеш булачак.

Язга таба Германияне әйләндереп алган бөҗра кысылганнан кысылды. Гитлерның иң якын иярченнәре аны ташлап кача башлады. «Золдатен цайтунг» гәзитендә — санын хәтерләмим, рейхсмаршал Герингның Берлиннан юкка чыгуы турында кечкенә генә бер мәкаләсе урнаштырылган иде. Шул ук номерда Сталинның улы Яков Джугашвили турында да хәбәр бар иде. Анда язылганча, ул кырык беренче елны әсир төшкән. Артиллерия полкында дивизион командиры булган. «Хәзерге көндә каядыр Альп тауларында бер СС ротасы сагы астында яши», — дип язылган иде. Бу хәбәрне мин үз күзем белән укыдым. Күп еллар узгач ачыкланганча, хәбәр дөреслеккә туры килми иде. Ул вакытта Яков Джугашвили үтерелгән булган инде. Ә халык туган илгә кайту хәстәрен күрә башлады. Кем кая юл таба! Бер көнне Фролов юкка чыкты. Эзне югалтырга чамалый булса кирәк. Перловский да каядыр китеп барды. Саубуллашканда: «Украинага кайтырга исәбең юкмы?» — дип сораган идем, ишетергә дә теләмәде. «Анда кайтып большевикларга кол булып яшисем килми әле», — диде. Бик даулаша торгач Хәмит, Нурмый һәм Гаян да госпитальдән китеп бардылар. Палатада мин бер ялгызым калдым. Шулкадәр ямансуладым, үземне кая куярга урын тапмадым. Чирдән бигрәк мине иптәшләремнән аерылу аяктан екты. Нигә соң әле мин качып булса да шуларга ияреп китмәдем, дип өзгәләндем. Казанга кайткач мин Хәмит белән Гаянны очраттым, ә Башкортстан егете Нурмый белән күрешергә туры килмәде. Бу турыда соңрак искә төшереп үтәрмен әле. Мин Һартманга ялынам: «Җаен табыгыз, илгә кайтарып җибәрегез!» — дип үтенәм. Ул миңа ашыкмаска киңәш итә иде: «Сиңа дәвалануны өзәргә ярамый. Хәлең рәтләнү белән, мин сине бер минут та тотмам. Күпкә түзгәнне азга түз. Хәзер өрдертүне туктатсак, үпкәләрең кабыргаңа ябышып үсәчәк. Аннан соң нәрсә буласын күз алдыңа китерә аласыңмы?» — дип сүзен тәмамлый иде. Мин аңа: «Ни күрсәм дә үзем күрермен, сезгә үпкәләмәм. Туган илемне кайтып күрсәм, үләргә дә риза», — ди торган идем. Ниһаять, ялына торгач теләгемә ирештем. Май азаклары иде бугай. Капка төбенә бик күп санитар машиналар килеп туктады. Тау кырыендагы урындыкка утырып, шул машиналарны күзәтеп торганда, мине шәфкать туташы эзләп тапты. «Лаус, лаус, шнель», — дип җилтерәтеп үзем яткан корпуска алып керде. Анда ду-чат килеп авыруларны озатырга әзерләнәләр иде. Мин дә шул җибәрелергә тиешле кешеләр исемлегенә кертелгәнмен икән лабаса! Һартман үз кулы белән һәр авыруга авыру тарихын тапшыра. Минем авыру тарихы шактый калын, аңа рентген сурәтләре дә теркәлгән.

«Ашыгасың, юнге,— диде ул миңа авыру тарихын тоттырганда,— сиңа әле дәваланырга да, дәваланырга кирәк». Шәфкать туташы ишегалдына кадәр озата чыкты. Анда безне санитар машиналары көтеп тора иде. Һәр машинага дүртәр авыруны утырттылар. Хәле авыр кешегә ятып торырга да мөмкин. Машина каплаулы, шулай да тәрәзәләреннән тирә-як ачык күренә. Мин менеп утырганда анда өч кеше бар иде инде. Моңа кадәр аларны госпиталь тирәсендә күргәнем юк иде. Өчесе дә украинлылар. Сүзгә бик сараннар. Сораша торгач, мин аларның Полтава өлкәсеннән икәнен белдем. Кырык өченче елны көчләп Германиягә эшкә җибәрелгәннәр. Шуны сиздем: алар туган илләренә кайтырга куркалар иде. Сөйләшә торгач сәбәбе дә аңлашылды. Сугыш алдыннан чираттагы чакырылыш буенча Кызыл Армия сафында хезмәт иткәннәр. Полклары сугышның беренче көнендә үк фронтта булып чолганышта кала һәм тар-мар ителә. Дошман тылында каңгырап йөри торгач, туган авылларына кайту бәхетенә ирешәләр. Кайту белән аларны полиция күзәтү астына ала һәм бераздан Германиягә эшкә озатылалар. Өчесе дә минем кебек үпкә авыруы белән газапланалар иде. Әйе, үпкә авыруы начар тормыштагы кешенең аерылгысыз юлдашы. Барабыз, колоннаның бер башыннан икенче башы күренми. Ничә машина булгандыр, өзеп әйтә алмыйм.

Юл тулы халык. Бөтен Германия халкы сәфәр чыккан дип уйларсың. Күмәкләшеп болай кая агылалар, үзләре дә белеп бетерми торганнардыр, ахры. Кайсы арба тарткан, кайсы күтәрә алган кадәр йөген иңбашына аскан. Юл кырыеннан баручы колоннаның иге-чиге күренми. Соңыннан белдем: алар бар да Көнчыгыш Пруссиядән, Силезиядән куылган немецлар икән. Мин әле Һерборнда госпитальдә дәваланганда ук игътибар иткән идем, немец халкының барысы — яше, карты җиңелү фаҗигасен искиткеч авыр кичерде. Дөресен әйтергә кирәк, милли социалистлар — алар үзләрен шулай атыйлар — кыска гына вакыт эчендә немецларга яхшы яшәү шартлары тудырган. Бөтен бәла шунда, яхшы шартлар басып алган илләр хисабына, бары немец халкы өчен генә... Башка милләт халыклары кол булып яшәргә тиеш булган.

Мин үз уйларыма чумып, мәрткә киткән кеше кебек утыра идем, каршымда утыручы юлдашымның: «Нюренберг!» дип кычкыруына сискәнеп киттем. Без зур бер шәһәр кырыеннан уза идек. Әйе, алда Гитлер тарафыннан оештырылган милли социалистлар, фашист партиясенең бишеге Нюренберг шәһәре. Алар үзләренең тантаналы җыелышларын шушы шәһәрдә үткәрә торган булганнар. Шулкадәр тиз барабыз ки, күз ачып йомганчы шәһәр артта калды. Тагын бик күп авыллар, эреле ваклы шәһәрләрне чиглэтеп узып киттек. Ниһаять, атаклы Лейпциг. Бу вакытта әле ул америкалылар кулында иде. Ләкин озакламый, ниндидер килешү буенча Лейпциг шәһәре безгә — Советларга күчә, аның өчен америкалыларга Берлинның бер өлешен бирәләр икән, дигән хәбәр таралган иде.

Безне шәһәр уртасындагы зур бакчага китереп бушаттылар. Шәһәр уртасындагы урман кебек мондый зур бакча барыбызны да гаҗәпкә калдырды. Көн кичкә авышкан иде. Авырулар чиктән тыш талчыккан, күбесенең аякка басарлык та хәле юк. Әйтергә генә ансат, бер көн эчендә биш йөз чакрымнан артык юл үткәнбез.

Бакча эче репатриантлар белән мыжлап тора. Энә төшәрлек тә урын юк. Безне, авыруларны бакча кырыендагы буш урынга җыеп утырттылар. Озак тоткарланмадык, алырга машиналар килеп тә җитте. Шунысы кызык, бу юлы машина йөртүчеләр бар да кара тәнлеләр иде. Лейапиг шәһәреннән демаркацион линия башлана, һәм безнең белән ике арадагы юл кара тәнлеләрдән оештырылган дивизия кулында икән. Бу юлы безне солдатлар төяп йөртә торган йөк машиналарына утырттылар. Машинага менәргә хәле булмаган авыруларга санитарлар булышты. Озак бармадык, урман эчендәге бер аланлыкка илтеп төшерделәр. Каршы якта

безне кабул итеп алырга килгән совет офицерларын күреп шатлыгыбыз эчкә сыймады. Минем әлегә кадәр погонлы совет хәрби кешесен күргәнем юк иде. Шуңадырмы, алар миңа ят булып тоелды. Мин әсир төшкәндә, кырык икенче елның сентябрендә безнең армиядә әле погоннар юк иде. Хәтта, офицер сүзе дә хезмәт халкын изүче сыйныф, капиталист алпавытларга тугры хезмәт итүче патша армиясен сүккәндә генә телгә алына иде.

Кабул итеп алучылар безне сафка тезеп санадылар да, урман эченә алып кереп киттеләр. Алдан, арттан автомат белән коралланган конвой чорнап алды. «Шире шаг» дигән усал команда яңгырады. Күбебезнең аяк атлар хәле дә юк. «А еще вы Симулируете?! Не выйдет! Бегом предатели?! Командага буйсынмый кара. Сафлар алга сөрлекте. Берничә минуттан авызыннан кан китеп, йөзтүбән капланган адәм баласы белән бөтен юл тулды. Мин хафага төштем. Шулай ук туган авылымны, анда калган карт әтием белән әниемне күрү насыйп булмас микәнни дигән уй үзәгемне өзде.

Бераз баргач, урманны чыктык. Асфальт юл башланды. Алда зур елга һәм шул елга кырыена урнашкан кечкенә бер шәһәр күренде. Күп санлы күрсәткечләрдән шәһәрнең исемен дә белдек. Шәһәр Зорау дип атала иде. Хәзер инде хәтерләмим, аның Берлиннан, Лейпцигтан тагын башка зур шәһәрләрдән ничә километр ераклыкта икәне дә язылган иде.

Безне, нинди дер могҗиза белән әсирлек тәмугында янмый калган совет солдатларын, американлылар кешегә санап, үзебезнең ил властьларына машинага утыртып алып килеп тапшырганнар иде дә бит... Монда хөрмәт белән көтеп тормаганнар икән шул. Алай гына да түгел, тизрәк үтереп бетереп, котылырга телиләр иде бугай. Сәбәбен күп еллар узгач кына аңладым. Сталин һәм аның иярченнәре Ауропада яшәүче халыкның тормышын үз күзе белән күргән адәмнәрдән курка икән. Чөнки аларда кеше өчен яшәү шартларының аермасы — безнеке белән чагыштырганда җир белән күк арасы бит. Алар тарихтан сабак алып эш итте. Наполеон белән сугыштан соң Ауропаны күреп кайткан офицерларның декабристлар хәрәкәтен оештыручы булуларын белә иде. Хәзер дә шундый берәр хәл килеп чыгудан котлары очкандыр, күрәсең...

Сафка тезеп юлга алып чыккан халыкның Зорау шәһәренә яртысы да килеп җитмәде. Безне бер йортның ишегалдына алып кереп, җиргә утырттылар. Күбебезнең утырып торырлык та хәле калмаган иде, асфальт өстенә аудык. Монда госпиталь булган. Сугышта яраланган немец солдатлары дәваланган. Аларны каядыр озатканнар. Хәзер безне — үпкә авырулы совет кешеләрен китереп тутырдылар.

Утырып торган килеш кат-кат санадылар да, ике катлы бинаның подвалына алып төштеләр. Подвал шактый киң. Монда фильтрация пункты урнашкан. Берәм-берәм аерым бүлмәгә алып кереп, сорау алу башланды. Миннән бер капитан белән бер лейтенант сорау алды. Дөресрәге, сорау алуны лейтенант башкарды. Капитан өстәмә сораулар гына бирде. Туган көнемнән алып бүгенге көнгә кадәр башымнан узганнарны сөйләп бирергә туры килде. Ничек Украинадан Германиягә көчләп эшкә җибәрелгән кешеләр арасына килеп эләгүемне кат-кат сөйләттеләр. Сизеп торам, һәрбер сүздән гаеп табып, буташтырырга тырышалар. Озак тинтерәттеләр. Ниһаять, лейтенант «кул куй» дип минем җаваплар язылган кәгазьне сузды. Мин бик нык йөткерә башладым. Авыздан кан чәчрәп кул куярга тәкъдим иткән кәгазь чуп-чуар булды. Капитан ишеккә карап: «Уберите его!» — дип акырды. Ике санитар кереп, мине бүлмәдән җитәкләп алып чыгып киттеләр.

Палатада сап-сары чәчле, битенә бераз сипкел төшкән шәфкать туташы каршы алды. Ул бөҗыр кебек җитез хәрәкәтле, яшь кенә немец кызы. Әлегә мин монда беренче авыру. Палата бик чиста. Бөтен нәрсә җитешле. Хезмәт күрсәтүче персонал бар да немецлар дип әйтерлек.

Начальниклар гына совет хәрбиләре. Соңгылары алар белән бик дорфа кыланалар. Авыз-борын майлап сүгенү кирәк дисеңме... Берсе дә калмый.

Шәфкать туташы мин ятасы караватка ак җәймәләр түшәп урынны көйләде дә кулымнан йомшак кына тотып яткырды. «Майн наме Анна»,— дип тәкъдим итте ул үзен. Җавап булмагач: «Ферштейн зи дойтеш?» — дип сорады. «Этвас — аз-маз»,— дидем мин. «Гут, гут. Вас һайсен зи- исемең?» «Әнәс». Кыз минем исемемне ничек әйткән, булсам, шулай «Ә» авазы белән кабатлады. Аның тавышы да үзе кебек матур һәм ягымлы иде.

Шушы минуттан мин совет госпиталендә дәвалана башладым. Эвакогоспиталь номеры 2466. Икенче көнне канны, бәвелне һәм какырыкны анализга алдылар. Анализ шуны ачыклады, мин ачык ТБЦ-туберкулез белән авырыйм. Авыруым йогышлы булганлыктан, озак вакыт минем янга башка кеше кертеп яткырмадылар.

Врач Евгения Ивановна атлы марҗа иде. Медицина хезмәте капитаны. Үзен бик олы сымак тота. Бер сорауга да җавап бирми. Авыруым турында информацияне шәфкать туташыннан сөйләтә идем. Сулъяк үпкәмдәге каверна ябылган. Барыбер өрдертүне дәвам итәргә кирәк булган. Ләкин хәзер өрдертү мөмкин түгел. Үпкәмдә спайка — кабыргага ябышу барлыкка килгән. Өрдертсәң алар өзелеп, кан китү башланачак.

Анна бик еш минем янга кереп утыра. Күзләре гел яшьле була. Ник һаман елыйсың дип сорагач, болыт астыннан чыккан кояш кебек елмая да: «Игътибар итмәгез, без хатын-кыз шулай инде» — дип, елмаеп куя. Тора-бара ул саран гына үзенең язмышын чишә башлады.

Аннан — Бреслау шәһәреннән. Ата-анасының язмышын белми. Шәһәрдән немецларны куганнар. Хәтта исеме дә алыштырылган. Кайчандыр аны поляклар Броцлав дип атаганнар, шул исемне кире кайтарып, шәһәрне Польшага кушканнар. Миллионга якын немецны туган-үскән җиреннән кууны Анна һич башына сыйдыра алмый иде. Өзелеп ата-анасын сагына. Күзләренең гел яшьле булуы шул сагыну нәтиҗәсе икән.

Алар шактый иркен тормышта яшәгәннәр. Әтисе сугышта яраланып, бер аяксыз калган. Терелгәч өенә кайткан, һәм бер сәүдә фирмасына эшкә урнашкан. Үзләренең машиналары булган. «Ах, ауто — дип өзгәләнә иде Анна,— утырасың да җаның теләгән җиргә барасың». Ул машинаны үзе йөрткән. Әнисе беркайда да эшләмәгән. Аның җилкәсенә өй хуҗалыгы белән идарә итү йөкләнгән. Хуҗабикәнең өйне ташлап эшкә йөрүен Анна күз алдына да китерә алмый. Катгый рәвештә: «Хатын-кыз, иң беренче чиратта, бала тәрбияләргә тиеш!» — дип кырт кисә. Аны Зораудагы госпитальгә университетның медицина факультетыннан алганнар. Теләге — сугыштан соң укуын дәвам итеп, врач булу.

Минем янга да авырулар кертеп тутырдылар. Анна белән бер-беребезгә ияләшеп җиткәч кенә юл ябылды. Шулай да ул юк-бар сәбәп табып, палатага кергәләп йөрде.

Бер көнне минем янга өлкән шәфкать туташы кереп утырды. Ул ничек әсир төшүем турында сорашты. Мин әсир төшүем хакында сөйлисөйли арып беткән идем инде. Аның сорауларына теләмичә генә җавап бирдем. Болай төксе сөйләшүем ошамады, әлбәттә. «Сез татар булсагыз кирәк»,— диде ул серле итеп. «Әллә сез дә татар хатынымы?» — дип сорадым мин. Ул елмаеп җавап бирде. Мин татарчага күчтем. «Ул вакытта нигә соң сезне Антонина Григорьевна дип атап йөртәләр?». «Дөреслектә мин Тәүхидә Гыйлаҗевна, урысларга әйтергә читен», «Мулла кушкан исемне үзгәртү килешә торган эш түгел инде».

Тәүхидә тышкы кыяфәте белән татар хатынына охшамаган. Сары чәчле, зәңгәр күзле. Тамбов өлкәсендәге бер татар авылында туган. Минем белән бер елгы — яшьтәшләр. Аны армиягә медицина училищесыннан алганнар. Ярый әле фронтка җибәрмәгәннәр, госпитальгә эләккән.

Минем хәл яхшы якка үзгәрә башлады. Соңгы мәртәбә анализ ясаганда микроб табылмады. Күңелем күтәрелеп, үземне бөтенләй таза кеше кебек итеп хис итә башладым.

Палатага озын гәүдәле, куна кебек кин җилкәле урыс егетен салдылар. Фамилиясе — Галактионов, исеме — Терентий. Без аның белән бик тиз уртак тел таптык. Ул китап укырга ярата, бигрәк тә шигырь китапларын яратып укый. Госпитальдә китапка кытлык иде. Хәтта, гәзит-журнал да күргәнебез юк. Терентий шәһәрдә нинди дер бер ташландык китапханәгә очраган. Ул җае чыкканда качып кына шул китапханәгә барып кайта. Бер көнне аңа ияреп мин дә киттем. Зорау шәһәре Эльба елгасы буенда. Китапханә елганың ары ягында иде. Эльба аркылы салынган тимер күпер шартлатылган. Шактый өстәрәк вакытлыча корылган агач күпер бар. Терентий бу күпердән: «Нәкъ безнеңчә, урысча эшләнгән»,— дип көлә иде. Күпер субай сугып салынган. Анда авыр йөк машиналары белән керергә дә куркыныч.

Терентий мине шул күпер аша елганың аръягына алып чыкты. Монда немецчә, пөхтә итеп, җиренә җиткереп салынган йортлар тезелеп киткән. Һәр йорт янында җимеш бакчасы. Бөтен җирдә үлем тынлыгы. Кергәнчыккан кеше күренми. «Безнекеләр йорт хуҗаларын куып, андагы байлыкны теләгәнчә талаганнар»,— диде Терентий, тынлыкның серен аңлатып. Аңа монда бар да таныш, кирәкле бинага туп-туры алып барып керде.

Китапханә ярым җимерек хәлдә, уку залындагы өстәл, урындыкларны ишегалдына чыгарып, җимереп бетергәннәр. Китапларны шүрлектән идәнгә алып ыргытканнар.

Керү белән бөтен дөньябызны онытып, идәндә аунап яткан иксезчиксез хәзинәне актарырга тотындык. Мине бигрәк тә шигырь китаплары кызыксындырды. Һейне томнарын күргәч, күзләремә ышанмадым. Утыз өченче елны аның шигырь китапларын фашистлар Берлин мәйданнарында утта яндырганнарын ишетеп белә идем. Күрәсең, тыю безнең илдәге кебек каты һәм эзлекле булмагандыр. Бездә бит тыелган китапларны сәгате-минуты белән китапханәләрдән җыеп алып, мичкә яктылар. Һәрхәлдә, әле без китаплар актарып йөргән китапханә өчен, Гитлерның фашистларга ошамаган авторларның китабын укуны тыю турындагы фәрманы кәгазьдә генә калган, тормышка ашырылмаган. Монда урысчадан тәрҗемә ителгән әсәрләр дә шактый иде.

Китаплар белән мавыгып, без вакытның узганын сизми дә калганбыз. Терентий бик әсәрләнеп вакытны сорады. Ул минем сәгатем юклыгын белә иде, әлбәттә. Кайда инде ул миңа, ике елдан артык лагерьдан лагерьга күчерелеп, газап чиккән әсиргә сәгатьле булу. «Кичүдән кичке алтыга кадәр генә үткәрәләр. Госпитальгә ничек кайтырбыз икән?» — диде ул хафаланып. Без китапханәдән чыгып, кичүгә юнәлгәндә кояш батарга якынлашып бара иде инде. «Кичүгә бармыйбыз»,— диде Терентий катгый рәвештә,— анда безне тотып, комендатурага алып китәчәкләр. Аннан соң нәрсә буласын үзең беләсең». Безгә монда кунып калырга да ярамый иде. Әгәр кайтмасак, госпитальдә гауга күтәреләчәк. Күп уйлап вакыт уздырмадык, җимерелгән күпергә юнәлдек. Аның тар-мар китерелгән корыч балкаларына тотына-тотына, аргы якка чыгып китәргә тәвәккәлләдек. Югыйсә, караңгы төшкәч ул җимерек күпер аша да чыгу мөмкин булмаячак. Китапханәдән алган китапларны калдырырга туры килде. Мин Һейне томын гына үзем белән алдым. Аны чалбар каешыма кыстырдым. Тышы путаллы хәрефләр белән бизәлгән бу җыйнак шигырь томын үзем белән Казанга кадәр алып кайттым. Хәтта андагы берничә шигырьне немецчәдән турыдан-туры татарчага тәрҗемә итеп, «Кыен юл» исемендә әсирлектә язылган шигырьләрем тупланган китапка да керттем. Мин үземнең тәрҗемәмне, урысча текст белән чагыштырып

карадым. Шундый нәтиҗәгә килдем, урысча тәрҗемәләр бик иректә ясалган, икенче төрле итеп әйткәндә, мәгънә нык кына үзгәртелгән иде.

...Без госпитальгә кайтып кергәндә караңгы төшкән иде инде. Анна шелтәләп каршы алды: «Сезне эзлиләр, лаус-тиз, чишенеп урыныгызга ятыгыз».

Бу минем беренче мәртәбә, үз белдегем белән госпитальдән рөхсәтсез читкә китеп йөрүем иде әле. Ярый, бәхеткә, зыянсыз тәмамланды, гауга чыкмады.

Минем дөньядагы, илдәге вакыйгалар турында хәбәрем юк иде. Тәүхидәдән иске газитләр сорап алдым. Шуларны укып көн уздыра башладым. Тәүхидә палатага кереп минем караватм кырыена килеп утырды да: «Үзеңнең әсирлектән котылып чыгуың турында туганнарыңа хәбәр иттеңме?» — дип сорады. Җавап бирергә аптырап калдым. «Ах, син оятсыз, нигә туганнарыңа хат язмыйсың?» — дип шелтәли үк башлады Тәүхидә. Ашыгып чыгып китте дә кәгазь, карандаш алып керде. «Мә, хәзер үк хат яз!» — диде боерып. Мин уйга калдым: әти-әниемнең күптән инде бер хәбәр дә алганы юк. Соңгы хатымны кырык икенең сентябрь башларында язган идем. Алганнардырмы, юктырмы. Чөнки, без төньяк Кавказда дошман чолганышында калган идек инде. Хәзер дә җибәргән хатымның бөтен сүзләрен хәтерлим. Аларны тынычландырырга теләп: «авыр сугышлар бара, миннән тиз генә хат көтмәгез, ләкин борчылмагыз»,— дип язган идем ул хатка. Алар мине үлгән дип исәпли, әлбәттә. Ул көннәрдән бирле күпме вакыт узды бит инде. Бәлки хәзер йөрәк яралары төзәлеп килә торгандыр. Оныткан килеш онытсыннар. Әллә кайтып җитәм, әллә юк,— дип уйладым мин. Шул турыда Тәүхидәгә сөйләгән идем, ул мине ачулана ук башлады. «Нишләп кайтып җитмәскә ди? Ата-анаңны шатлыктан мәхрүм итәргә хакың юк»,— диде. Ул янымда карап торып, хат яздырды:

«Исәнмесез әти, әни»...

Үземә-үзем ышанмадым. Дөньяда шушы иң хөрмәтле, иң кадерле ике кеше белән хат алышыр көнгә кадәр яши алуыма ышанмадым. Хатны озын язмадым, үземнең исәнлегемне хәбәр итү белән генә чикләндем. «Калганын кайткач иркенләп сөйләшербез»,— дип тәмамладым. Соңыннан кайтып җитүемә ышанып җитмәсәм дә, тиздән, бик тиздән бергә булырбыз, дип өстәдем.

Авылга кайткач сөйләделәр, хатны китерүче хат ташучыга әнием өстендәге бердәнбер күлмәген салып биргән. Почта йөртүче хатын: «Абыстай, үзең ялангач каласың, алмыйм»,— дип каршы килеп караган, әнием аның сүзен ишетергә дә теләмәгән. Көчләп актык күлмәген биреп җибәргән. Үзе кырык ямаулы иске күлмәк белән калган.

Шушыннан соң миңа яңадан озак хат язарга туры килмәде. Дөресрәге, мөмкинлек булмады. Август азагында аягында йөри алучы бер төркем авыруларны демобилизацияләделәр. Кулга бирелгән кәгазьдә «СССР Верховный Совет Президиумының 25 июнь, 1945 елгы Указы нигезендә демобилизацияләнә»,— дип язылган иде. Шул кәгазьгә өстәп, авыру тарихын, фильтрация узганлыгын күрсәткән белешмә тоттырдылар...

*Ахыры бар*

■ ■ ■



# Рәдиф Гаташ

## БЕР ЙОЛДЫЗНЫҢ НУРЫ

(ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР)

### Кереш

«Мең дә бер кичә»дәнме ул? Кем сүзе?
Гашыйк җанга, бәлки, Җәбраил үзе
Әйтә төштә:— Сине аңлар бер яр бар—
Эзлә шуны... Ул—шаһ Әфраим кызы...

### Ак канәфер сүзе

Бүлмәмдә бүләгең синең—ак чәчәк:
— Күңеленә,—ди, гаҗәп аклык иңәчәк!—
Яңа йолдыз калкыр анда... Көндезен
Янса да ул, исемен—Чулпан диячәк...

### Каләмнән—сиңа сәлам бу

Сиңа ихлас фатихам бу—Каләм бу!—
Юл башында теләгем бу—сәлам бу!
...Ничә Кояшка табындым... Гаҗәпме
Тагын берәү чыкса балкып? Галәм бу...

### Гади бер көн иде

Килдең—«гаиб ирәннәрдәй күрендең»—
Бүлмәм шат авазга, нурга күмелде.
Язмыш каләме язды—Хак куштымы
Ямьләтергә сиңа шушы көнемне?!

---

Рәдиф **ГАТАШ** (Гатауллин)—*шагыйрь, 1941 елда туган, уннан артык китап авторы. Казанда яши.*

## Сурәтең шундый бугай

Яшькелт күзең, алма битең, каш — кыйгач...
Эшләпәңә капса утың — ялкын чәч?!
Күзем туйган кебек булса, нур эчеп,
Сизәм ләкин: күңел карным тагын ач!

## Шул мизгелгә рәхмәт

Җанны тетрәткән илаһи мизгелне
Озайтырга теләдем мин — сизденме?
Күз алдыңда яшәрдем, егет булдым:
Сөләйманны җиңгән Бәлкыйс иденме?

## Күпме теләк үлде?

Бактым ла эзләп үземне күзеңдә...
Ай-һай, каты караш икән үзеңдә:
Ихтыярсыз кызардым — шактый әрсез
Теләк туып, үлде «тыйнак» йөземдә!

## Башта ук күккә күтәрдем

Кагылырга кыймыйм өрфия тәнгә,
Кулларымны бәйли ни ул — бу мәлдә?
Җаның белән җаным аңлашты юкса,
Түзәм: Алиһәм дигәч син гүзәлгә...

## Горурланырсыңмы?

Бер күрүем житте — хис шашып китте,
Дулкынланды уй-тойгы, ташып китте.
Үлдем, беттем... Йә, тантана ит, ханым:
Кайтмас юлга тагын бер гашыйк китте.

## Бер сөйләшү

— Кем чәчәген өзә, ә кем җимешен...
Ә кемдер күзли, сокланып, гөл төсен...
Истән, хистән исереп...— Бу сүземә:
— Кысыр чәчәкләр шуңамы күп? — дисең.

## Ак канатны

Сурәтеңне тиңлим Югары затка,
Фәрештәгә сине охшаттым хәтта.
Әйтерсең күк: җырың да күккә ашсын,
Тотын миңа... тик канатны каралтма!

## Бу елдан бәхет көтимме?

Бу язда да сөю — яшерен сер, чәчәк...
Ирләр аңа юл эзләп баш ватачак
Эт елы бу! Бәхетле итсәң мине,
Дошман нишләр? Дусларым — шаккатачак...

## Без яраткан шәраб ни?

Хафиз Ширази йә Хәйям касәсе
Исерттеме безне ул кич? Нәрсә соң?
Әйттек: — Йөрәкләр дәвасы — мең еллык
Шәрыкнең шигырь шәрабе яшәсен!

## Бу заманга да хас

Кем сөйли — шаһның алтынчы хатынына
Гаҗәеп «саф мәхәббәте» хакында?
Тетрәп киттем: оялу хисе дә әле
Калган икән бит гашыйклар халкында!

## Ахматова искә төшеп

Кулында, аһ, нәфис перчаткаларың...
Берсен җирдән иелеп алдым, ханым...
Ахматова искә төшеп — тезләнгән
Хәлдә калдым! — Җиңелеп калдым, ханым.

## Гашыйк бу баш

Учларыма кысам сине, газиз баш,
Нишлим, җәллим, башсыз, акылсыз булгач...
Мең дә беренче кат исемең кабатлап,
Елый Гаташ, тик бер көнгә айрылгач.

## Дүртенчесе кем?

Бүлмәңдә дәүртәү идек без — дүрт кеше:
Син, сеңлең, мин, Тарзан дигән бер песи...
Ул да кешедер — бик көнче. Гел мырлап,
Арага түгел, шигырьгә керсенче!

## Борынгыча хис

Ниндидер көч ханәмнән кубарганмы?
Син юкта, шашып, бүлмәңә барганмын:
Ишегеңә шигырь укып, ачыл, дип,
Тупсаңда йоклап киткәнмен — арганмын...

## Аh, Зодиак билгеләре

Нинди җиңел — сөйләшү сеңелең белән! —
«Бизмән» билгесенең телен мин беләм...
«Кучкар» белән «Үгезбозау» очрашса,
Гел сөзешә — йә, нишлим синең белән?!

## Бары сине уйлап...

Сеңелеңә иң матур сүзләр әйтимме?
Күрмичә апаңны мактыйм, мин тиле...
Гөлдәй әнкәгез алдында баш иям:
Бәлки уйлап бер үзеңне... тик сине?!

## Сезнең бүлмәдә бер уй

Нинди телдә сөйләр бәхтем йолдызы?
Гитара да фәкать урыс җыр-сүзе...
Йә һинд көе... Ярый бар — үзебезчә
Елмаючы сез — ике татар кызы!

## Кем исеме?

«Гөлфәмә» дигән яңа сүз ишеттем,
Гөлнең яңа төредер дип хис иттем...
Белдем: татар хатыны исеме! Ходаем,
Кодрәтең: Күк кызынамы иш иттең?!

## Сайлану

Сеңлең белән икегезне күргәч, мин
Хәлемне шул кыйссага тиң исәплим:
Уйлыйм «бәхетен» — ике күбә печәннең
Берсен кабалмый, ач үлгән ишәкнең...

## Юатыгыз, гөлләр

Күктән — затың, исмеңдә нур-балкыш бар.
Тик ник салкын? Җанда шуңа сагыш бар...
Бик тәкәббер туганыгыз, яклагыз
Сез мине, гөлләр! — миләүшә, ландышлар!

## Фән арыткан булыр

Студентка булсаң, бер хәл — аспирант...
Шул акыллы, мәгърурәдән наз сорап,
Уңармы җан? Килгәч, качып китсәм мин,
Фән арыткан йөздән куркып — аптырап?..

## Җанымның бәхете

Күпме елатты җанымны бу хәят!
Гашыйк имеш, җиңелдем мин мең кабат...
Әдәп белергә дә вакыттыр, бәлки?
Йә — сөйгәч, сөелү тиеш, ниһаять!

## Бәйрәм көн килерме?

Сусаган саен мин җылы сүз-назга,
Ераклаша гына өмет бу язда.
Ни бу, и яр? Суфыймы мин, гашыйкмы?
Таңы юк төн... Гаете юк ураза...

## Тарих яшендә, бәлки

Әйтсә сеңлең: «Гаташ ничә яшендә?..
Карт түгелдер, дулкын-кара чәче дә...»
Җавап бир: — Чын Нух гомере җанында,
Йосыф аһы хисендә — күз яшендә!

## Кыз көнләшергә ни уй?

Син таләпчән! Тәнкыйтең-фикереңә
Колак салам, хәйран мин белемеңә!
Ә үзеңә багышланган шигыремне
Тик мактыйсың... Ышан кыз көнләшенә!

## Ачыктан-ачык язам

Рәхмәт сиңа, миңа килгән нурың бар.
Җавап булсын! Сиңа ихлас җырым бар.
Яшеренмичә, янып омтылуым — хак,
Көнләшәләр? Гайбәткә дә урын бар...

## Көлке түгел

Рәхмәт, Сөю! Гамьле иттең чал башны...
Шат, ваемсыз дип кем әйтер Гаташны?!
Бүген дә ул, ярын каһәрләп, аңа
Бәетме... васыятьме язып маташты...

## Алдан күрү миңа да хас

Төштә күрәм барсын, дисең, алдан ук.
Яшисеңләр төшеңә өн ялганып.
Мин дә күрәзә... уеңны бик беләм,
Тик күз йомам — сөеп яшим, алданып.

## Аякларың авыртмыймы?

Әллә азагын уйламый, Матурым,
Сине бу хис кыясына чакырдым?
Аякларыңны канатса кыен юл? —
Кызганып куйдым үзеңне, акыллым!

## Шулай итсәң, ә?

Хурларга иде сине бер — сүз белән...
(Мин, ахры, тик назлый торган сүз беләм)
Тиргәп, каргап китәргә иде — иртән
Килеп җитәргә, үкенгән йөз белән.

## Үссә... үлсә...

Синең җанда тиңе юк бер гөл үссә?
Минем җанны шаштырса ул, көйдерсә?
Һәм тилмертсә? Өмет өзеп, мин киткәч,
Үзе, тетрәп, чәчәген койса? Үлсә?!.

## Кайсы кыйтгадан көнләргә?

Бүлмәңдә күккә оча җан: нур, якты...
Уйны бүлеп, ишегең кемнәр какты
Бер-бер артлы?!. Исемен сорамыйм, әйт тик
Телен, динен?! Ауропа, азиатмы?!

## Шулай булмасмы?

Куркам: яшьләрчә уеннарга тартсаң,
«Арбаңа утыртып, җырың җырлатсаң?»
Ансы бер хәл... Чал баштан көлеп туйгач,
Ил-көн каршында кыйнатсаң — җылатсаң?!

## Мин түгелме?

«Бәхет бирәм дияргә юк хакы да.
Байлыгы юк, чамалы акылы да,—
Күккә дәшә, хыялына чакыра»,—
Шулай дисәләр «әфәндең» хакында?!

## Сөйлиләр

Көлә дус-ишләрең: — Күр, бала мыни!
Хыялый бер — Җир йөге аңа мыни?!
Ник кулларын селтәп һаман очына?
— Шагыйрь бит ул...— Ала — ай... Дивана мыни?

## Җанымны син аңла!

Янды бу җан! Алдымы бер шөһрәт-ат?
Юкса бүләккә лаек ул мең кабат.
Күрсен соң кем? «Бөек хис»не аңлардай
Зирәк хан юк... Кемгә илтим шикаят?!

## Нәфесең зур, ай-һай!

Ни тели, әйт, чама белмәс бу җаның?
Нишлим тагын? Янмадыммы мин? Яндым...
Илгә тиңсез гыйбрәт ит мине, дисәң,
Ә бу җыр — ни? Язмадыммыни? Яздым.

## Олыгаюның әйбәт ягы

Шат дисеңме? Уйныйм гына: башка мин...
(Оялчан йә кызу идем башта мин!)
...Читен хәлгә куяр идең, яшь ханым! —
Үз-үземнән көлә белгән яшьтә мин...

## Җанның бар җәүһәрен

Әле авыр хәлем! Сөеп «бөләм» бит:
Җанның бар җәүһәрен сиңа бирәм бит.
Таланган күк ялангач ук калсам? Юк,
Байыйм җырга... Җыр кадерен беләм бит!

## Сүз... эз...

— Сәер дә, түгел дә кебек бер халәт...
Ни булса да, — дисең, — ихлас син, рәхмәт.
Башны әйләндергән сүзне еш тыңлау
Ярамыйдыр, бәлки? Шулай да рәхәт.

## Саубуллашу

Менә — җырларым! Шәп чыкты, күр имди.
Илһам бирдең, яттан сөйләп йөр имди...
Фикер, сурәтен күзеңнән урладым, —
Китәм дисәм, хәзер рөхсәттер имди?!

## Бакчагызга

Арча өстеннән ак болыт үткәндә,
Моңсулатып, җиләс җилләр искәндә,
Дәшәрсеңме мине? — Җәйге бакчамда
Кунак бул! — дип, җыр җимешең пешкәндә?

## Эзләп барганда

Газәленнән аерылган мин — рәдифме?
Кәрванынннан торып калган дәрвишме?
Эссе комда эзләрең. Мин аларны
«Сине уйлыйм» дип укыйм гел — ялгышмы?

## Аһ, шулай булса

«Гөл сулары сибәрләр» ди сөйгәннәр.
Су ташый кызлар, кемнәргә сибәрләр?
Аһ, яшәртсә «гөл суыгыз» — тагын бер
Сезгә хезмәт итәр идем, чибәрләр!

## Бу юлы — бәхет өчен тудым

Туган көнең... Мин дә кабат тудыммы? —
Ялкын-балкыштан синең бар булдыммы?
...Заман — авыр, яңа гомер — газаптыр,
Әмма синең өчен тудым — бу юлы!

## Мәҗнүн җаны сине эзли

Төн. Сәхра. Чулпан калкыр да таң атар,
Ераклардан шәйләнер синең чатыр.
Китим — бүген җырым кунды куеныңда,
Ә иртәгә — чатырга җанны чакыр!

## Чынлап картайсак?

Әйтә Гаташ: — Мин чынлап шаштым бугай,
Яшь йолдызга кул сузмас идем болай...
Газаплырак хәзер хис тә... Картайгач
Нишләрбез, җан? Әле илледә — шулай...

## Үтә күрсәм дә, чигенмим

Белсәм иде уеңны минем хакта! —
Бәлки көлке-гыйбрәт итәрсең ятка?
Ярып карыйммы җаныңны... Сөйгәч бер,
Үзгәрәлмәм — нидер тапсам да хәтта!

## Укучылар булмаса

Уемда шәүләң, өстәлең җанлана! —
Минем күк шигырь язамсың син анда? —
Языйк та, яр, укыйк бер-беребезгә, —
Шигырь аңлаучы азайган заманда!

*Март-апрель, 1994*



# Зиннур Мансуров

## Татар бугазы

Идел-йорттан татар ятимедер —
аз-маз чамалыйсың ич мине.
Нәрсә әйтим, «туган», нәрсә әйтим
йорткән өчен хәтәр исемне.

Биләмәләр чиген билгеләргә
килмим сиңа, Татар бугазы.
Томырылып торган тамырларның
киселмичә калган бик азы.

Кальгаларның тере кылганнары
ничек котылгандыр көч-яудан?!
Урдадагы алтын ырудашлар
тәгәрәшкән затлы кысадан.

Кыйнашларның кара кан-яшьләре
ага сиңа шу-ундый еректан!..
Борынгыда бәгъзе берәүләрең
безне кысып-кысып «яраткан».

Сөембикә затын сәмруг-коштыр
кочагында кысып үтергән.
Тикмәгәме: кемдер тамагына
кемдер төер булып утырган...

Безнекеләр диңгез бугазына
милләт атын кушкан, янәсе.
Йотылулар белән йотуларның
татарлыкка хасрак, йә, кайсы?

Ыңгырашып кыен ашаганда,
йотса йоткан бары яшь кенә.
Тамырларны көн-төн томалыйдыр
эчкә яшерелгән үч-кинә.

Кавемнәрне тәмле кабымлыктай
йотучылар әле ач һаман.

---

Зиннур **МАНСУРОВ** (1949) — *шагыйрь, публицист; унга якын китап авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Татымлырак икән татарларым —
үзен-үзе генә ашаган...

Бездәйләргә Татар бугазында
беләм инде, беләм сан югын.
Йөрәксенеп, «туган», йотмадыңмы
Таһир белән Зөһрә сандыгын?

Суларыңның сизмим сулкылдавын,
өнең дә юк — телең йоттыңмы?
Чишмәләре буйлап чакырттырыр
Иделдәге туган йорт мине...

Шәрыкчәрәк исем шәрифләрең —
шуңа бераз яшем агыза.
Денсезләнмик әле дөньялыкта,
сиңа таба ярым ай йөзә...

*1972—93*

## Баш

Җиде тишекле тукмак...
*(Кырым татар халкы табышмагыннан)*

Борынгыдан бәргәләндең,
      җиде тишекле тукмак:
кавемеңне кабахәтләр
      җирдән себереп түкмәк!..

Ыруыңны, артыксынып,
      гүргә терелләй тыкмак.
Орылудан арынмадың,
      җиде тишекле тукмак.

Мәскәүләрнең мыскыллавы —
      тагы якадан тотмак.
Диварларны дөбердәттең,
      җиде тишекле тукмак.

Ишетмәгән ишекләргә
      әйттең кан-яшьле такмак;
тораташлар төшенгәндер,
      җиде тишекле тукмак.

Милләттәшең мәйданнарда,
      янып, яңадан тугмак.
...Табышмактан тәшвишләндем,
      җиде тишекле тукмак,
кагылудан-сугылудан
      җитмеш тишекле тукмак!..

## Танк һәм танка

1972 ел. Совет-Кытай чиге. Танкодром

Чин — урыслар белән чиләнергә
мин бу чиктә, бәлки, ят сакчы?!
Танкларның төкреп «танго»сына,
танка[1] гына язып ятсаңчы.

Казансуның изге казкайларын
саклый алмагансың сәмруггтан...
Тансыкламый гына танкларны,
танка язып ятчы сау рухтан.

Килешмидер бу чик «килмешәк»кә,
кайтып сакла туган телеңне.
Танкларда дене тоныкланган
танка язгаларга телиме?!

## Тавык тәпие

Пәйгамбәрнең көймәсендә
аша нәҗес чүп-чарны, —
юк, барыбер чукынчыкка
чыгаралар чучканы.

Гөман кылмыйм: һәммә хадим
үз халкына колдыр, дип.
Йөри, әнә, «милли тавык»
тәре эзе калдырып...

## Балта ашы

1993 ел, октябрь.
1905 ел, октябрь. «...Патронов не жалеть!»
*Генерал Д. Трепов*

Имәндергеч канлы империя
һәйбәт үзләштергән «ур-кис!»не.
Инде хәзер урыс орден ала
үтергәне өчен урысны.

Оныттырып канның ырулыгын,
кургаш белән аны ник җылыт?!
Урыс башы өчен орден биреп,
оран сала Рәсәй: «Не жалеть!»

Тәһарәтсез кыргый тәрәккыят

[1] Биш юллы япон шигыре *(кыска җыр)*.

тора төсле тоташ үч-каннан.
Нәрсә көтеп була гомер бакый
«балта ашы» ашап үскәннән.

## Беренче киселгән ярымай

Үз-үземне ээәрлекләп,
гасырларны кичкән бар:
«Җәберләнер ярымайны
әүвәл кайчан кискәннәр,
әүвәл кайчан кискәннәр?»

Күңелемнән, күрәэәдәй,
үткәзәмен бар-югын...
Сөбханалла, сөбханалла:
күрәм... Казан бүреген!

Татарлыкны тотып торган
ханлык таҗы — ганимәт...
Җәрәхәтле йөрәгемне
йомарлатты кан кинәт.

Ачындырды: очындагы
алтын ае... киселгән!
Бәгырькәем, бүрегеңне
салдырганнар көч белән.

Серле сорау сыман борчый
юкка чыккан ярымай.
Күңелләрдә күмелергә
аңа һич тә ярамый!

Мәсҗетләрне мәсхәрәләү
башы шулдыр, мөгаен.
Киек казлы күктә күрәм
Казанымның мең аен!..

Бүректәге беренчесе
әсир киткән ят йортка.
...Төшләремдә, тәшвишләнеп,
кысам шуны йодрыкка...

## Сәнәк белән язу

Сәермени телең сайраганда
суга сәнәк белән язулар.
Ыштансызлар бездә ышанучан:
һәрбер акыллыга — йөз юләр.

Гаҗәпмени тәмуг газаплары,
канга... сәнәк белән язулар[1].
Савыкмадык мондый сабаклардан:
һәрбер акыллыга — йөз юләр...

## Шайтан шамакае

Бәрәкалла: бәгъзе берәү
табут... ашап бетергән (?!)
Юылгандыр юләркәйнең
эчендәге бөтен гамь.

Җене килгән, җинмәк булып,
ахры, үлем куркусын.
Тамагына тыгылмаган —
үҗәтлекнең күр көчен!..

Биләп алды шушы гамәл
күңелемнең түр башын.
Яман нәфес нәҗес итәр
җәсәденең тәрбәсен!!

Шомлы шайтан шамакае
кызык ясый кем өчен?
...Татымаган тоталитар
алабута күмәчен...

Туя алмый, табут ашый —
тамак түгел, тәмугтыр.
«Бисмилла»ны белмәгәнгә,
авызында тәм юктыр.

Вәкарь белән белдерәдер
иблисчәрәк карашын:
«Шундый аштан, шундый аштан
олы булып кара син...»

Тамагына тыгылмаган
табуттагы тәре дә...
Кәфен белән авыз сөрткәч,
гамең булмый тәңредә.

Табут ашау — табу түгел,
биреп булмый... ун камчы.
Фанилыкның фанатигы
гомер итсен үлгәнче!..

---

[1] Казан һәм Уфа губерналарындагы сәнәк сугышы күздә тотыла (1918—20).

## Тары чәчәге

...Төлке төштә тавык күрә,
тавык төштә тары күрә,
тары төштә нәрсә күрсен —
Үги кызлы Айга ашып,
чәчәк аткан чагын күрә...

## Алатаудагы кар бөртекләре

Шундый җиңел, абау, шундый җиңел —
авырлыгын тоймый керфек тә.
Гаҗәпсенәм: тау-тау гөнаһсызлык
яшәп ята бәллүр бөртектә.

Алатауда карлар алиһәнең
таңгы сулышыннан яралган.
Төшүендә җир дә төшенмәслек
җиңеллекләр бардыр, йа аллам!

Тазалаучы галәм тузганагы —
җиңеллекнең соңгы чигедер!
Мамыклары, өф-өф, мамыклары...
сытар, диеп, ничек шик китер?!

...Ишетелә карлар ишелгәне,
балпан[1]нарның тонык «кар-кар»ы.
Алатауда иңрәп үлгәннәрнең
җиңел булсын авыр карлары,
җиңел булсын
авыр карлары...

## Могҗиза

Сөялердәй сердәш сайлаганда,
ишен теләмәгән йөрәк юк.
...Яратышмый яшәп ятканнарны
күзәткәлим — нинди ераклык!..

Чагыштырам күңел чагылышын:
йөзләрендә уртак эз ничә?
Өйрәнелгән ипле өйдәшенә
эт тә охшый башлый үзенчә...

Йөрәкләре нинди ераклыкта —
уртак җепләр булмау, аһ, яман.
Балалары, аллам, балалары
икәвенә бердәй охшаган!..

---

[1] Тау кошы

## Үлән арасындагы таш

Чалгы йөзе ташка тиеп китте
онытылып печән чапканда.
Йөрәк шулай тетрәп куя микән
сиздермичә елан чакканда?!

Төшне өннән бүлеп торган бәллүр
чалтыр итеп төпкә коелды.
Чалгы йөзе ташка тиеп киткәч,
әллә нинди сәер көй туды.

Ерак кышта калган аулак өйнең
тәрәзенә кемдер таш орды.
Чалгы көен бозган тавыш мине
хәтер хөкеменә тапшырды.

Үзем генә белгән чая кызый
чалтыратып сукты яңакка.
Чалгы йөзе ташка килеп тигәч,
чаткы чәчрәп китте як-якка.

Челпәрәмә килгән чәркәденме
ишетелеп алды моңлы чың?!
Алда кинәт яшен чартлап куйды —
Һич тә көтми идем монысын.

Чыңгылдады хәтер чоңгылында,
чылтырт итте тагын әллә ни...
«Төшләр»емә зиһен төшенәдер,
калбем генә мене аңламый.

Юаларны өзеп юанганда,
изми иде башны бер гамь дә.
Чалгы йөзе ташка тиеп китте
чыклы җирне ялмап барганда...

## Киек каз юлы

Телебезнең сихри тылсымнары
иңгән йолдызлыклар аз сыман.
...Болгарларым сине барлагандыр,
туфрак киткәч аяк астыннан.

Шәм-шәрифле җиһан шарлавыгы,
җанга савыласың чыннан да.
Татарларым сиңа тартылгандыр
шахта терәүләре сынганда.

Арабызда, аңлыйм, аргамаклар
кичә алмас бик күп ел барын.
Татарларым әмма тоташтырган
сиңа хәтта лашман юлларын,
тәкъдиреңдә язган юлларын...

# ТАРИХЫБЫЗ ОФЫГЫННАН ИСЕМНӘР КАЙТА...

Садри Максуди (Садретдин Низаметдин улы Максудов, 1879—1957) — күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, сәясәтче, хокук фәннәре белгече, язучы-публицист — совет режимы чорында озак еллар буе матбугатта исемен генә дә телгә алырга тыелган, телгә алганда да, фәкать тискәре яктан гына бәяләнеп, «буржуаз милләтче», «ак эмигрант»лар рәтендә йөртелгән һәм, ниһаять, соңгы еллардагы демократия шартларында гына абруйлы исеме кире кайтарылган зур тарихи шәхесләребезнең берсе.

Ул элекке Казан өязе Ташсу авылында (Татарстанның хәзерге Биектау районына керә) мулла гаиләсендә туып үсә. 1888—94 елларда Казанда Күлбуе мәдрәсәсендә, аннан Татар учительләр мәктәбендә белем алып, ахырда Парижда Сорбонна университетының хокук факультетын тәмамлый. 1906—12 еллардагы демократик үзгәрешләр чорында ул сәясәт мәйданында һәм татар милли азатлык хәрәкәтендә зур эшчәнлек күрсәтә, ике тапкыр Дәүләт Думасына Казан мөселманнарыннан депутат итеп сайлана һәм, депутат буларак, Русиядәге төрки халыкларның мәнфәгатьләрен яклап, Дума мөнбәреннән сөйләгән кыю чыгышлары белән киң җәмәгатьчелеккә таныла. 1917 елгы Февраль көннәреннән соң аның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге тагы да активлаша: Русия кадетлар партиясе платформасына якын торган сәясәтче сыйфатында, кадетларның Петербургта җыелган корылтаенда катнашып, анда төзелгән «Төркестан комитеты»на җитәкчелек итә, ә 1917 елның маенда исә Мәскәүдә узган Бөтенрусия мөселманнары корылтаенда Үзәк бюро әгъзасы итеп сайлана. Бу корылтайның карары нигезендә, аңа төрки-татар халыклары өчен «милли-мәдәни мохтарият» (автономия) проектын төзүне тапшыралар. Ул төзегән проект эчке Русия һәм Себер мөселманнарының 1917 елның июлендә Казанда узган корылтаенда кабул ителеп, аны гамәлгә ашыру өчен С. Максуди җитәкчелегендә махсус комитет оештырыла. Комитет Уфа шәһәрендә эшли башлап, 1917 елның ахырында яңадан корылтай җыя һәм тарихта «Милләт Мәҗлесе» дип кереп калган мәгълүм шул корылтайда «Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының Милли Идарәсе» тәсдыйк ителә. Милли Идарәнең башлыгы — рәисе итеп янә Садри Максуди сайлана.

Әмма Милли Идарә 3 ай да 6 көн генә яшәп кала: илдәге хакимиятне тулаем үз кулына алган большевиклар, милли оешмаларның һәммәсен туздырып, аларның лидерларын һәм тарафдарларын да эзәрлекли башлыйлар. С. Максудига һәм аның мәшһүр фикердәшләренә (Г. Исхакый, Г. Баттал, Г. Терегулов һ. б.) чит илгә чыгып китүдән башка чара калмый.

С. Максуди 1918—24 еллар арасында Финляндия, Германия һәм Франциядә яши, ә 1925 елда, Төркия президенты Мостафа Кәмал Ататөрек (1881—1938) чакыруы буенча, гаиләсе (хатыны һәм ике кызы) белән Төркиягә күчеп килә, гомеренең ахырынача шунда

кала. Төркиядә дә ул иҗтимагый-сәяси һәм гыйльми эшчәнлеген дәвам иттерә: ике дистә елдан артык башта Анкара, аннан Истанбул университетларында хокук фәннәре факультеты профессоры булып эшли, Ататөрек заманында Төркия парламентына (Милли Мәҗлесенә) ике тапкыр депутат булып сайлана: төрек хөкүмәте делегацияләре составында Бөтендөнья Милләтләр лигасының Лондон, Глазго һәм Чехословакиядә уздырылган конгресслары эшендә якыннан катнаша: фән өлкәсендә төрки һәм Шәрекъ халыкларының иҗтимагый-хокукый тарихы, тел белеме, философия һәм социология буенча күпсанлы хезмәтләрен яза. Төркиядә алар Садри Максуди-Арсал имзасы белән нәшер ителәләр.

С. Максуди 1957 елның 20 февралендә Истанбул шәһәрендә вафат була.

С. Максудиның, каләм иясе буларак, туган илендә язган чордагы иҗат мирасы әле тупланып-барлап та, өйрәнеп тә бетерелмәгән. Арадан мәгълүмрәкләре: «Мәгыйшәт», милли хикәя (повесть), «Тәрҗеман руси» *(рус теле буенча дәреслек китабы)*, «Англиягә сәяхәт». *(Авторның Русия Дәүләт думасы депутатлары делегациясе составында Англиягә барып кайтуы турында 1909 елны язылып, 1912 елда басылып чыккан һәм сәяси-иҗтимагый, тарихи мәгълүматларга ифрат бай бу публицистик китабын «Казан утлары» журналы алдагы саннарның берсендә бүгенге укучылар игътибарына да тәкъдим итәргә уйлый).*

Хәзер журнал укучыларына тәкъдим ителгән «Мәгыйшәт» — С. Максудиның нәфис әдәбият бабында язылган бердәнбер әсәредер. Аны иҗат иткәндә авторга әле нибары унтугыз гына яшь була. Гуманистик эчтәлеге, шул заман татар тормышындагы мөһим проблемаларны үзәккә алып, үзенчә хәл итүе белән XIX йөз татар мәгърифәтче язучыларның (Акъегетзадә, З. Бигиев, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими һ. б.) мәгълүм әсәрләрен хәтерләткән, шул ук вакытта татар әдәби теле-стиле мәсьәләләрендә алга таба тагын бер адым ясап, чын халыкчан телдә иҗат ителгән «Мәгыйшәт» повесте, кызганычка күрә, әдәбият тарихчылары игътибарыннан да, мәктәп һәм гуманитар юнәлештәге югары уку йортларында өйрәнү объекты булудан да гел читтә калып килде. Юкса, әдип-галимнең гомерлек дусты һәм фикердәше Гаяз Исхакый билгеләп үткәнчә, «милли тормышны европача әдәби формаларда тасвирларга һәм милләтнең яңа әдәби ихтыяҗына туры килә торган әдәби әсәр тудырырга сәләтле бер көч булып мәйданга чыккан» яшь авторның бу әсәре, унтугызынчы йөз мәгърифәтчелек әдәбиятыннан егерменче йөз башындагы күп жанрлы, күп төсле яңа татар әдәбиятына таба үсеш-күчеш юлында иреншелгән мөһим бер ядкәр буларак, безнең әдәбият тарихында үзенә лаек урынны алырга хаклы.

Рәис ДАУТОВ.

■

## Садри Максуди

# МӘГЫЙШӘТ[1]

МИЛЛИ ХИКӘЯ

### Укучыларга

***Бу хикәя моннан уналты еллар элек бик яшь вакытымда язылган бер әсәрдер. «Мәгыйшәт» 1899 елда язылды, 1900 елда басылды. Ул вакытта саф бер шивәдә[2] язылган милли әдәбият нәмүнәләре[3] мәйданга чыккан юк иде.***

---

[1] Мәгыйшәт — тормыш.
[2] Шивә — диалект, сөйләш.
[3] Нәмүнә — үрнәк.

***Мин төрки телләр арасында Казан шивәсенең дә бер әдәби тел булырга хакы булганына, бу телдә әдәбият ясалуның милли тәрәккыйебезнең зур шарты, мөһим бер баскычы икәнен аңлаучылардан идем. Шул милли әдәбият бинасы нигезенә үз тарафымнан бер таш салу булсын дип, «Мәгыйшәт»не язарга җөсарәт[1] иткән идем. Ләкин бу «Мәгыйшәт»нең талигы[2] бик кызык булды: өч мең нөсхәдән ике меңгә якыны Казанда 1902 елда вакыйгъ булган зур янгында янды.***

***Шул сәбәптән бу китап халык арасында яхшылап таралмыйча калды. Шуннан соң бу вакытка кадәр бастыру сәдәденә[3] керә алмый тордым.***

***«Мәгыйшәт» язылганнан бирле милли тормышыбызда байтак фикри һәм иҗтимагый үзгәрешләр булды. «Мәгыйшәт»нең мәзмуне[4] инде, табигый, искерде. Ләкин шулай булса да, бердән, милли тәрәккыйебезнең бер дәверен, милләт эчендә акрынлап тәрәккый фикерләрнең зоһурын, милли әмәлләрнең тууын тугъры вә дөрест тасвир иткәнлеге өчен, икенчедән, саф Казан шивәсендә язылган милли хикәяләрнең тарихан беренчесе булганлыгы өчен, «Мәгыйшәт»нең һәрвакыт матбугат мәйданында булырга хакы булыр дип уйлыйм. «Мәгыйшәт»тә мин ни әйтмәкче булдым? «Мәгыйшәт», реалист бер юлда язылса да, «фикер» тарату максады белән укучыда «әмәл»[5] тудыру фикере белән язылган бер әсәрдер.***

***Яшь мөхәррирнең милләт эчендә таратырга теләгән әмәлләре нидән гыйбарәт? Моны язып торырга хаҗәт юк, хикәяне укып чыккан һәркемгә бу заһир булачактыр. Хикәянең каһарманы Фатих кечкенә угылы Рәшиднең «галим, диндар, хәмиятле[6], дәүләтле, милли бер кеше булып, милләткә вә дингә теле, фигыле, малы белән файда итәрлек бер адәм булуын Ходадан телидер». Менә, унтугыз яшьлек мөхәррирнең милләте әфрадына теләгән әмәлләре, идеаллары моннан гыйбарәт. Бу идеал «Мәгыйшәт» мөхәррирenә хәзердә дә зур идеалдыр.***

**Садретдин МАКСУДИ**
**Казан, 27 декабрь, 1914 сәнә**

# I

Халид агай сату-алуга булганлыгы, алыш-бирешкә осталыгы аркасында картлыгына таба зур байлыкка ирешеп, тормышы иркенәйгән, эшләре юлына салынган иде. Аның төп сәүдәсе тире-яры илә булып, «К» шәһәрендә тире илә сәүдә кыйлучыларның иң бае һәм ул эшнең иң остасы иде.

Ул елларда «К» шәһәрендә тирече яһүди вә руслар да күп булмаганга, тире кәсебе бөтенләй мөселманнар кулында кеби булып, файдасы да бик яхшы иде. Шуңа күрә Халид абзый алтмыш яшьләренә килгәндә дүрт-биш йөз мең сумма иясе була алган иде.

Халид агай симез генә бәдәнле, түгәрәк йөзле, йонлачрак кына бер адәм иде. Бу яшьләренә килгәндә сакалы, чәче-мыегы һәрбере яртылай агарса да, йөзенең рәвешеннән, агармый калган төкләреннән әүвәлдә дә кара төкле бер кеше булганын белергә мөмкин иде. Халид абзыйның кыяфәте тугъры, тәкауви[7], саф күңелле кешеләр кыяфәте иде.

Һәм, вакыйган[8], Халид агай мөрәүвәтле[9], тугъры, юмарт табигатьле яхшы бер адәм иде. Бик зур дәүләт өстенә бу яхшы сыйфатлар җыелганга, шәһәр халкы арасында сүзе үтә торган игътибарлы кешеләрнең иң зурысы булып, кайда гына бер мәҗлес булса — Халид агай булыр, кайда гына бер сүз чыкса — Халид катышыр иде.

Халид агай, яхшы күңелле булганга, кеше өчен кайгыручан, халык файдасына төшенүчән иде. Сүзе үткән кешеләргә һәрвакыт вәгазь-нәсихәттә иде. Халид агайның вәгазьләре, димләгән нәрсәсе искелек иде.

---

[1] Җәсарәт — батырчылык.
[2] Талигъ — киләчәк, язмыш.
[3] Сәдәд — максат, ният.
[4] Мәзмун — эчтәлек, идея. Зоһур — барлыкка килү.
[5] Әмәл — өмет, ышаныч.
[6] Хәмиятле — яклаучан, кешелекле.
[7] Тәкауви — диндар.
[8] Вакыйган — чыннан да.
[9] Мөрәүвәт — кешелек.

Дөньяда искелектән сөйгән нәрсәсе юк иде. Һәр эштә искечә булуны, әүвәлгечә торуны ярата иде. Аның уенча, халыкның ярлылануына, азуына сәбәп: яңа чыккан нәрсәләр, имеш. Үзенең бу уен дөресткә чыгарырга төрле дәлилләр дә сөйли иде; әлбәттә, дәлилләре дә фикере төсле үк иде.

Халид агай үз фикеренә бик ышанган, үз гакылына бик инанган бер кеше булып, һәр эштә, һәр турыда үзенең фикерен — дөрест, уен тугъры дип уйлый иде. Шуңа күрә үзенең хәдде булмаган[1] эшләргә дә катышып киңәш бирү, мәслихәт сөйләү гадәте бар иде. Баштан сәүдәгәр булганга, сәүдә хакындагы сүзләрен, мәслихәтләрен тугъры санарга яраса да, башка турыларда күп сөйләшүе, белгечләнүе бик урынлы түгел иде.

Хосусән[2] мәдрәсәләр, укулар, укытулар хакындагы сүзләре бер көлке генә иде. Чөнки, үзендә аз-маз язу җырмаларлыктан артык гыйлем булмый торып, галим бер адәм (педагог) кеби, гыйлем эшләрен тикшерүе галим адәмнәргә бик кызыклы тоела иде. Халид агай үз мәхәлләсендәге мәдрәсәнең фәхри[3] мөдире (попечитель) булып, утын, керосин, кизүләрнең яллары — һәрбере аның акчасы илә үтәлә иде. Мәдрәсәгә моннан башка рамазанда зәкят кертү, ашларга чакыру кеби күп яхшылыклар кыла иде. Шуңар күрә шәкертләр Халид агайны яраталар иде. Яту-тору, ашау-эчү кеби эшләрдә мөмкин кадәр Халид агай теләгәнчә булырга, аңар каршы килмәскә тырышалар иде. Алай булса да, Халид агай илә шәкертләр арасында күбесенчә низагълар да булгалый иде. Чөнки Халид агай, шәкертләрнең тормышлары үзе эстәгәнчә булуы илән генә канәгатьләнмичә, укуларының-укытуларының да үзенең надан фикеренә муафикъ булуын телидер иде. Барып котыртучы кешеләрнең сүзләренә карап, мәдрәсәгә барып, укуларын килештермичә, шәкертләрне төрлечә борчый иде.

Мәсәлән, бер шәкерт барып мантыйкны яманласа, иртәгесен барып:

— Кирәкмәс, мантыйк укымагыз, кирәк нәрсә түгел, күңел каралтып-фәлән,— дип шаулап йөри иде.

Берничә вакыттан соң берсе мантыйк яхшы гыйлем, кирәк нәрсә, фикер ача-фәлән дип мактаса;

— Укыгыз, укыгыз мантыйкны, яхшылап укыгыз, мантыйк кешенең зиһенен ача,— дигән булып, фонограф кеби, кеше сөйләгән сүзләрне сөйләп йөрер иде.

Халид агай һәрвакыт: «Мин — надан кеше»,— дия иде. Бу сүзне бер төрле һава илә зурайтып әйтә иде. Гүя надан булу һәркемгә насыйп түгел, имеш. Ләкин наданлыкны теле илә әйтсә дә, эченнән һич үзенең наданлыгын белми иде. Чөнки күңеленнән наданлыгына ышанса иде, надан кеше катышмаслык эшләргә тыгылмас иде.

Бервакыт берәү барып куркыткач, мәдрәсәгә казыйны вә башка зур пишкадәмнәрне җыеп:

— Ник сез зурларга әбҗәд илә иҗек укытмыйсыз? Ул нинди эш ул, мин сезгә утын бирәм, керосин бирәм. Хода риядан[4] итмәсен! Әлхәмделиллаһи, мәхәллә бае, сез минем сүзгә карышмаска тиеш иде, сез монда үзегез белгәнчә теләсә ни укып ятарга килдегезмени? Миңа кичә берегез барган иде. Үзе гакаид укыйм, ди, әбҗәд илә иҗекне безгә өйрәткән кеше дә юк, ди. Ул нинди эш ул, мәдрәсә булсын да, әбҗәд илә иҗек укытылмасын!?. Хәлфәләр! Сезгә яхшылык илә әйтәм, үз белдегегез илә эш кыйласы булмагыз. Мин надан кеше, алай булса да, дөньяны күп күргән кеше. Мин белгән заманнардан бирле һәр җирдә әбҗәд-иҗек — укыла килгән нәрсәләр. Менә мин үзем, әлхәмделиллаһи, иҗек укып кына мәдрәсәдән чыккан кеше, әлхәмделиллаһи, дөньяда торамын, хәтта

---

[1] Хәдде булмаган — «чигеннән (үз даирәсеннән) чыккан» мәгънәсендә.
[2] Хосусән — бигрәк тә.
[3] Фәхри — мактаулы.
[4] Рия — ялган.

язуны да сату итә башлагач алай-болай азапланып өйрәндем... Сез алай итү кирәкмәс иде. Мәхәлләнең бае булгач, рия булмасын, мәдрәсәгә шулкадәр акчалар тоткач, азрак зурлау да көтәсең,— дип ачуланганын, шәкертләр, дәрес укый торган зур шәкертләргә әбҗәд илә иҗек укыту кирәк булмаганын, әүвәлдән дә иҗек вакларга гына укытылганын никадәр аңлатырга тырышсалар да, аңлату мөмкин булмаганын бик күп сөйлиләр иде.

Аның фикеренчә, намаздан калмаган төркихан[1] шәкерт галим иде. Намазга сирәк барган иҗтиһадлы хәлфә надан иде. Галимнәрнең түбән торып, наданнарның югары торуына гаҗәпсенә иде, һичбер төрле аңлый алмый иде. Урамда очраган кешесез фәкыйрьләрне, зәгыйфьләрне мәдрәсәгә китерү — гадәте иде. «Бичара, алай-болай итеп тукланыр»,— ди торган иде. Ләкин аның болай мәдрәсәгә шәкерт булмаган адәмнәрне тутыруына шәкертләр бер дә разый түгел иде. Бәгъзе гакыллы шәкертләр:

— Халид абзый, ник бу кадәр суфыйлар, зәгыйфьләр тутырасыгыз? Мәдрәсә фәкыйрьләр ята торган җир, дарелгаҗизин[2] түгел ләбаса. Мәдрәсә — уку йорты, мәдрәсәбезнең һавасы шәкертләребезнең үзләренә дә җитми, кеше арткан саен шау-шуы арта, мондый бозык һавада, шау-шу арасында ничек гыйлем алмак кирәк? Уку өчен саф һава, тынычлык — беренче шарттыр. Әгәр дә сез фәкыйрьләрне кызгансагыз, аларга аерым бер йорт салдырыгыз. Аларны шунда тотыгыз,— диләр иде.

Ләкин Халид абзый, әүвәл, һаваның булуына ышанмый иде, булуына ышанса, бозылуына ышанмый иде. Мәдрәсәне уку йорты дип белми, «фәкыйрь, торырга җире булмаган адәмнәргә хаксыз йорт» дип белгәнгә, һаман шәкертләр сүзенә бакмый, туры килгәндә фәкыйрьләрне мәдрәсәгә тутырмакта иде.

Үзләрендә гыйлем булмаган бер төрле кешеләр Халид агайны бик галимгә санап йөриләр иде. Андый кешеләрнең бу гөманнарына сәбәп шул иде: Халид агай мәҗлесләрдә, аз-маз үзенең белгәнен чәчеп, меллалардан мәсьәләләр сораштырып утыра иде. Аның сораган мәсьәләләре бер-бер гыйбадәт рәвешен яки бер нәрсәнең хәрам йә хәләл икәнен сорау булмыйча, сорарга муафыйкъ булмаган, аңлаганнарны көлдерерлек сүзләр була иде. Бер мәҗлестә байгураның берсе, мәсьәлә сорыйм дип: «Хәзрәт, Хуҗа Насретдиннан бирле ничә вә ничә буын?» — дип сорап бөтен мәҗлесне көлдергәне мәшһүрдер. Халид агайның сораган сүзләре дә шушы байгураның сүзләренә бик охшый торган сүзләр була иде.

Бердән, дәүләтенең зурлыгыннан, икенчедән, бая әйткәнемчә, юмарт, тәкауи булуыннан, шәһәр халкының күбесе, бер-бер мәслихәт булса, акыл алырга, киңәш өйрәнергә Халид агайга килерләр иде. Гүя аны бер акыл чишмәсе дип саныйлар иде. Дөрест, күп кеше арасында шәһәрдә Халид байга буйсынмаган бәгъзе яшь кешеләр дә булгалый иде, ләкин андыйлардан Халид агай ничек булса да бер җай чыгарып ачуын алырга, аларның алга киткән эшләрен юлдан чыгарырга тырыша иде. Тәкауи исемен күтәргән бер кешегә бу холык килешеп бетмәсә дә, башта гаеп буйсынмаучыларның үзләреннән булганга, мондый яшьләрдән ачу алу, дошман итү Халид агайга гаепкә саналу кайда калды, киресенчә, Халидны сөйгәннәр арасында: «Менә, фәлән, Халид агайга исе китмәгән булып, киңәшләргә килми йөргән буладыр иде. Халид агай үзен ни эшләтте?! Халид абзый ачуы булып, алмый каламы соң!» — дип, бер зур гыйбрәт итеп сөйлиләр иде. Һәм дөресте дә, бер булганрак егет, Халидка бик иләсе килмичә, үзалдынарак эш кылса, Халид шуңа ничек итсә итеп бер зарар тигерергә тырыша иде. Күбесенчә акча аркасында теләгәнен булдыра иде. Үзен яратмаганнардан ачу алуны, аларга зарар итүне

[1] Төркихан — төркичә китап укый белгән шәкерт.
[2] Дарелгаҗизин — гаҗизләр йорты.

Халид агай бер дә гөнаһка санамый, гүя тиешле бер җәза дип кенә уйлый иде.

Чит кешеләр Халид агайны һәр яктан килгән дип мактасалар да, бик якыннары бер холкын бер дә килештермиләр иде. Ул холкы да — хатын-кызга артык һәвәслелеге иде.

Тугърысы, Халид агайның бу холкы бер дә килештерерлек түгел иде. Бүтән эшләрдә никадәр үз-үзен тота белсә дә, хатын-кызга бик ваксынучан иде. Очраган хатын-кызга күз салмый китү Халид өчен мөхаль[1] иде. Хәтта мәчеткә барышлый-кайтышлый юлыккан хатын вә кызга карау да бу карт байның гадәте иде.

Яше алтмышларга җиткәч, бала-чага атасы булгач, Халид агайның бу сыйфатта булуын кем ошатсын?

Кайсы кешеләр Халид агайның болай булуына сәбәп, җәмәгате Хәлимә абыстай илә ике араларында мәхәббәт булмаудадыр, дип уйлыйлар иде. Ләкин ялгышалар иде. Чөнки Хәлимә абыстай Халид агайны сөйгән кеби, Халид агай да Хәлимәне чын күңеленнән ярата иде. Халид Хәлимәне ни өчен сөймәсен?!

Хәлимә абыстай кыз вакытыннан ук яхшы холыклы, күркәм йөзле, җайлы сүзле иде. Халид агай Хәлимә абыстайга өйләнгән вакытта артык дәүләт иясе түгел иде. Хәлимә абыстай килгәннән соң һаман бәхете ачылып, эше алга китте. Чөнки Хәлимә абыстай күңелгә шатлык, җанга рәхәт бирүче җайлы йорт хатыннарының берсе иде.

Һәркемгә мәгълүм, бер кешенең тормышына, холкына хатыннарының бик зур дәхеле буладыр. Күркәм холыклы, тәүфикълы, чибәр генә, эшендә булган яшь егетләр, өйләнеп, начар холыклы, инсафсыз кызларга тап булып, холыклары бозылып, тәүфикъларыннан язалар. Шулай ук киресенчә дә, артык тәүфикълы да булмаган җайсыз егетләр, өйләнеп, җайлы, йомшак күңелле, мөлаем табигатьле кызларга очрап, холыкларын төзәтеп, тәүфикъка утырып китәләр.

Халид агай да, Хәлимә абыстайны алганда дәүләте ул дәрәҗә булмаганы кеби, тәүфигы да уртача иде. Хәлимә абыстайны алуы илә, тәүфигы төзәлгән кеби, бәхете дә алга китте. Хәлимә абыстайның атасы Халидка караганда күп бай иде, алай булса да Халидка кызын бирде, чөнки Халид егет вакыттан ук сату-алуга осталыгы, кеше белән эш кылырга булганлыгы илә мәшһүр иде.

Хәлимә абыстай, атасына бердәнбер кыз булганга, атасының вафатыннан соң утыз мең акча, йорт-җирләр һәркайсы аның исеменә калган иде. Халид агайның ул вакытта суммасы җиде-сигез меңнән артык булмагандыр. Шуның өчен, эшне зурайтасылары килеп, Хәлимәгә калган мирас акчасының азрагын банкка салсалар да, күбесен суммага кушып җибәргәннәр иде. Асылда Халид агайның эшләре зураеп, сатуның җайга китүе шул көннән башланды. Юкса коры осталык илә дүрт-биш йөз мең суммаларга ирешмәк мөмкин булмас иде.

Халид агай Хәлимәнең тәүфигына, эшләренең алга китүенә, зураюына сәбәп булганлыгын үзе дә беләдер иде. Күпвакыт, тәмле сүзләр илә тәшәккер әйтә белмәсә дә: «Рәхмәт, сиңайтәм, минем бәхетем ачылуына син сәбәп булдың»,— дип әйткәлидер иде.

Халид агайның, югарыда сөйләгәнемчә, хатын-кызга шулкадәр хирыс булып та, моңа кадәр яшь хатын алмый торуы — бары шул, яшьтән яраткан, бәхете ачылуына сәбәп булган җәмәгате Хәлимәне ригайә кылып[2] кына иде. Әүвәлдәрәк Халид, үзе никадәр яшь хатын алу исәбендә булса да, мөмкин кадәр ул фикерен йорт җәмәгатьләренә белгертмәскә тырыша иде. Мәхәббәтле җәмәгате Хәлимәдән ояла иде. Ләкин бу уйлар, бу ригайәләр Халид агайның дәүләте арткан саен кимидер иде. Бу ахыр елларда ригайәләр бөтенләй күтәрелеп, Хәлимәнең үзен дә

---

[1] Мөхаль — гайре табигый хәл.
[2] Ригайә кылу — олылау, хөрмәтләү.

күпвакыт: «Өйләнәм, разый буласыңмы? Мин сине рәнҗетер өчен алмыйм ләбаса. Ник разый булмыйсың?» фәлән дигән кеби сүзләр илә борчый башлаган иде.

Чөнки бу елларда байлыгы кәмальгә җитеп[1], саф дүрт-биш йөз мең суммасы булган иде. Шуңа күрә Халид агай эченнән: «Аллага шөкер, байлыгым җитәрлек булды, инде байлыкның рәхәтен күрергә дә кирәк. Дөрест, Хәлимә өстеннән өйләнү бик килешеп тә бетми. Ни эшләмәк кирәк, Хәлимәнең картаюы хак бит, юкса мәхәббәтем юктан түгел, Ходай беләдер. Хәлимәнең миңа булган файдаларын онытасым юк. Ходай бу кадәр байлык биргәч, рәхәтен дә күреп калырга кирәк, гомергә бер хатын белән үткәрү минем кебек бай кешегә үзе килешеп бетми. Инде Хәлимәне ригайә кылам дип әле дә бик күп чыдадым, иншалла, мин бу эш өчен гөнаһлы булмасам кирәк»,— дип уйлый иде.

Ләкин Халид агай уйлый белмидер иде ки: Ходай Тәгалә байлыкны өйләнү өчен генә бирмичә, кешегә зарары тими торган кәефләр илә рәхәтләнер һәм хәер эшләргә сарыф итәр өчен бирмештер. Хәлимәнең файдаларын онытмау — аның яшь хатын алу илә булмый, бәлки аның илән калган гомерен бергә, яшь вакытларын сөйләп, Ходага гыйбадәт кылып үткәрүдәдер.

Халид абзый Хәлимәнең картаюы хак бит дип үзенә өйләнергә юл эзлидер. Белмидер иде ки, Хәлимә абыстайның картаюы хак булган кеби, Халидның үзенең картаюы да бик чын иде. Хәлимәнең картаюы илә Халидка яшь хатын алырга тиеш булса иде, Халид картаюы илә Хәлимәгә дә бер яшь егеткә китәргә тиеш булыр иде. Халид агай үзе Хәлимәнең аерылып бер егеткә китүенә разый булыр идеме? Һичбер юк, кайда ул разый булу! Халид агай ул турыда бик көнче бер кеше иде.

Ләкин Халид агай боларны уйлый белми иде. Моңа кадәр чыдап торганын да бик зур миннәт[2] итәдер иде.

Акрынлап Халид агайның бу фикере чигенә җитте. Һәрвакыт телендә өйләнү, яшь хатын алу була башлады. «Анагыз картайды, яшь хатын алам»,— дигән сүзләр илә, бара торгач, карт балаларын да үзеннән биздерә башлады. Шуңа күрә боларның йорт эчләрендә ата-ана, бала-чага чүкердәшеп, сөешеп көн итүе юк иде. Боларның йортлары гүя хәсрәтле бер йортка әверелде. Ничек шулай булмасын?

Дөньяда бәхет, сәгадәт дигән нәрсә — күңел тынычлыгыдыр. Бу йорттагы кешеләрнең күңел тынычлыгы кайсында булсын?

Халид агай исәбендә булган бер эшне булдырырга уйлыйдыр. Ләкин, булдырса да, һәрвакыт чын күңеленнән, вөҗданән бу фигыленең ярамаганын аңлап эче поша, җаны газапланадыр.

Хәлимә абыстай исә кырык ел әүвәл яшь күңелен, мал-милкен, җәмален фида иткән сөеклесенең бу көндә үзен ташлаячагын уйлап кайгырадыр. Әй, укучылар! Уйлап карасагыз ла, дөньяда син бер-бер кешене сөеп тә, ул кеше сине сөймәү яки ташлау кадәр авыр бер эш бар микән?!

Мәсәлән, бу бичара Хәлимә абыстай кыз вакытында кара кашлы, тулы битле, килешле гәүдәле бер кыз булган. Инсафлылыгы, сүзгә җайлылыгы һәр күргәнне аңа рәгъбәт иттерә икән, бик сакланчак, бик гафифә бер кыз икән. Атасының дәүләте яхшы булып, бик кадердә, һичбер хафа күрми генә үскән. Алай үссә дә, холкы гүзәл, табигате мөлаем булган, ахырында, кәмальгә ирешкәч, Ходаның тәкъдире буенча, Халид агайга кияүгә биргәннәр. Халид бик күркәм кеше булмаса да, Хәлимә шулкадәр матурлыгы илән дә Халидны кимсенми, үзенең насыйбына разый булып, бер-бер кешегә мәхәббәтеннән буш булган күңелен, һич гаепсез бөтен булган күңелен аңа фида иткән. Бар күңеле илә Халидка ярарга тырышкан, тырышу илә Халидка һәм ярап, ничә еллар аңа рәхәт гомер итешкән, бар кайгысы сөеклесе Халидның кәефен китерү,

---

[1] Кәмальгә җитеп — тулыланып.
[2] Миннәт — яхшылык, батырлык.

анын күңелен шат тоту булган. Шул рәвешчә, утыз-кырык ел кичкәннән соңра Халид агай аның бу яхшылыкларына каршылык (мөкяфәт): өстеннән яшь хатын алмакчы буладыр. Шуларны уйлап карасаң, Хәлимә абыстайның вә башка шундый хатыннарның ирләре яшь хатын алуына разый булмавын бер дә гаеп итәргә урын калмыйдыр.

Халид картта бу уйлану фикере һаман үсте. Балаларының ялынычлары, җәмәгатенең хуп күрмәве — һичбере картны бу уеннан туктата алмады.

Берничә вакытлардан соң, бу вакытка кадәр уйда гына булган бу фикерен чынга чыгармакчы булып, халкыбызның гадәте үзрә, иң әүвәл бу мәсьәләне хәзрәткә киңәште. Хәзрәт ни дисен?

Хәзрәт һәр эштә Халид ягына ятып өйрәнгән иде. Эшнең алдын-артын уйламыйча, төрле төрки китапларында күргән кыйссаларны сөйләп, фәлән падишаһның фәлән кадәр хатыны булган, фәлән солтанның фәлән кадәр хатыны вә шулкадәр кәнизәге булган, дигән кеби сүзләр илә Халидка яшь хатын алуны, түгел мөмкин вә дөресткә, бәлки тиешле бер күркәм эш итеп чыгарды.

Гаҗәеп безнең иске хәзрәтләрнең фикере!.. Хатын күп алуны ислам динендә мактаулы бер эш дип саныйлар. Хәлбуки, ислам дине күп хатын алуны күркәм эшләрдән санап кушмыйча, зарурәт булса тыймыйча, рөхсәт кенә бирәдер.

Халид агай мулланың үзенә ягымлы сөйләгәнне күргәч, бөтенләй кайдан алырга кирәклекне үк сорый башлады. Кайда кыз барын, кайдан өйләнергә кирәклекне белү мулла эше булмаса да, Габделләтыйф хәзрәт моны аермыйдыр иде. Үзеннән ни генә сорасалар, җавап бирергә өйрәнгән иде. Һәм аңа киңәшкә барган кешеләр дә аның һәрбер сүзенә ышана иделәр. Әле бу турыда Халидка: «Кайда кызлар барлыгын белмим, яучылардан соратырга, эзләтергә кирәк»,— диясе җирдә:
«Белмим» дигән сүзне күтәрә алмыйча:

— Син, Халид, әлбәттә, өйләнгәч инде яшь кыз алырга тели торгансыңдыр? Әгәр дә чибәр кыз алыйм дисәң, тирече Хөсәен кызына яучы җибәреп кара. Безнең остазбикә бик мактый, төскә-биткә күркәм, укымышы да бик яхшы ди,— дип, яучылык та итеп куйды.

Халид бай, хәзрәттән яхшы киңәш ишеткәннән соң, эшне озакка калдырмады. Ике көн соңра яучы хатын да җибәрде.

## II

Хөсәен Тимерҗанов агайларга һич уйламаганда бер көн Маһруй яучы килеп керде. Хөсәен бай җәмәгате Латыйфа абыстай Маһруйны күрүе илә,— кызлы кешенең гадәте билгеле инде,— каушабрак кына өенә кабул итте. Сөйләшә торгач, Маһруй абыстай җайлап кына үзенең Халид агайдан яучылыкка килүен белгертте. Латыйфа абыстай бу сүзне ишетү илә, кызыма бик бай кешенең угълыннан яучы килде, дип шатланып:

— Соң, ничек, Фатихны өйләндермәкче булалар микәнни?— диде.

Моңа каршы яучы:

— Әле Фатихка өйләнү кая ни, кая?! Имчәк сөте авызыннан кипмәгән дигән кеби, әле аның сызыкка керүенә дә бер-ике еллап бар бугай. Юк! Фатихка түгел, атасы Халид агай үзе яшь хатын алмакчы була,— дип, Латыйфа абыстайның яңа ялкынланган шатлык утын сүндерде.

Латыйфа абыстайның, кызына карттан яучы килүенә бик кәефе китсә дә, Маһруйга аны-моны сиздермәде:

— Мин, Маһруй абыстай, үзеннән башка бер сүз дә әйтә алмыйм, ярый, әйтеп карармын. Ай-һай, бердәнбер кызыбызны картка бирергә разый булыр микән,— дип җаваплады.

Шәһәребезнең яучылары нинди булганы билгеле инде: Алла сакласын, шайтаннан яучы булып килсәләр дә, күндерерлек итеп мактау гадәтләре.

Маһруй абыстай һәм шәһәр яучыларыннан, аларның да бигрәк оста теллеләреннән иде. Гадәте — бер кешегә яучы булып килдеме, шуны булдырырга тырышу иде. Әмма кызның ул адәмне сөячәген, ахыры ничек булачагын, кыз илә кияү буласы бер-беренә тиңдәшме, түгелме — аларны уйлап та карамый иде. Шуңа күрә үз гомерендә байтак чибәр кызларның тиешсез урынга китеп гомергә вәйран булуларына сәбәп булган иде.

Маһруй абыстайның һәрвакыт бертөрле сөйләп теле күнеп беткән иде: «Халид абзый тәкауви, тәүфикълы адәм, бу чагында тәүфикълыны туры китерүе бик читен, бигрәк тә яшьләрнең ышанычлысы азайган, мондаен урынны кеше эзләп таба алмый, Хода биргән инде, Хөсәен абзыйга да киңәшеп кара. Ир — баш, хатын муен, диләр, күндерергә тырыш... Кеч-кенә урын түгел, җайлап сөйләсәң, ул да күнәр»,— дигән кеби сүзләр илә Латыйфа абыстайны алдамакчы булса да, «Ярый, әйтеп карармын»нан башка «иншалла, күнәр-фәлән» дигән кеби вәгъдәләр ала алмады.

Яучы китеп озак тормаенча Хөсәен агай кайтып, Латыйфа абыстай иренә Маһруй килгәнне сөйләгәч, араларында шушы сүзләр йөрде:

Латыйфа: — Сиңайтәм, Маһруйның килүе — Халид байдан кызыбызны сорап. Йа Рабби, ничек кешенең бердәнбер кызын оялмыйча сорыйлар?

Хөсәен: — Фатихны өйләндермәкче булалар микәнни?

— Түгел шул, Фатихка булса, мин дә бер сүз әйтмәс идем.

— Ха-ха-ха, Халид абзый үзе өйләнмәкче буламыни? Күптәннән исәбе бар иде аның.

— Әйе шул, үзе өйләнмәкче була, имеш, йа раббе Ходаем, ашын ашаган, яшен яшәгән, моңа кадәр гомер иткән карт көнендә бу эш нигә кирәк?!

— Һәркем үз эшен үзе белә, синең ни эшең бар?!

— Анысы шулай ла... Бирүен бирмәбез лә, атасы, ул карт җүләргә?

— Алай ук өзеп бетерә алмыймын. Бик зур сөйләшергә ярамый, без әллә кем түгел, яучының килеп торуы үзе бер куаныч. Халид агай начар кеше түгел. Тәүфикълы, булдыклы кеше, яшь-елбагай чагы түгел, зурларга киңәшеп карарга кирәк әүвәл.

— Ай, атасы, алай дия күрмәсәнә, аның суфилыгы илән әллә ни эшләп булмый, яшьләрнең дә картлардан тәүфикълысы буладыр. Минем кызым алай кыю түгел көндәш өстеннән кияүгә барырга. Әллә нинди чая кызлар да, яшь хатын булып баргач, уңайсызлыклар чигәләр. Ходайга шөкер, кызыбызның аты-суы чыкмаган, яше узмаган, Алла насыйп итсә, үзе кеби яшьләр дә табылыр.

Бичара, бала җанлы Латыйфа абыстайның бу энже кеби сүзләре Хөсәен агайга бер дә үтми иде. Чөнки Хөсәен агайда мондый күңелдән чыккан, калыптан ташыган матур сүзләрне аңларлык җан юк иде.

Хөсәен агай бик гаҗәп бер кеше иде, аның нинди кеше икәнен тиз генә белер хәл юк иде. Аны яхшы белер өчен байтак сынау тиеш иде. Шуның өчен күп кешеләр аны, тәмам сынап бетермичә, яхшы кешегә хисаплап йөриләр иде.

Хөсәен абзый бар күңеле белән баюга бирелгән бер кеше иде. Баю юлында никадәр читенлекләр күрсә — түзәчәк, никадәр авырлыкларга очраса — күтәрәчәк иде. Үзе дә егерме-утыз мең сумма иясе булып, үз суммасыннан башка бәгъзе ышанычлар илә дә эшен зурайта иде. Иткән сәүдәсе, Халид агай кеби, тире-яры илән булып, ләкин аңар караганда эше күп кечкенә иде.

Хөсәен агайның өстенә кигән киемнәре, һәр көн базарда тире илән чуалганга күрә, шомарып-ялтырап беткән киемнәр иде. Үзе юантык гәүдәле, чыгынкы корсаклы, ялтырабрак торган битле, тәбәнәгрәк кенә

иде. Үз эшләрен яхшы йөртә белсә дә, халык илә катышырга осталыгы юк, тупас бер адәм иде. Аның көлгәнен бик сирәк күрер идең. Көлгән вакытында бик гаҗәп бер эш өчен булмыйча, үзенең баю фарызына муафикъ бер эш булса, шунда бик көлгәләп сөйләр иде. Мәсәлән, бервакыт чамадан тыш табыш күрсә, яки алган вакытында берәүдән бик бәһане сыгып алса, ул көнне кич чәй янында көлгәләүчән иде.

Хөсәен абзый акчадан башка нәрсәдән ләззәт тапкан кеби түгел иде. Мәсәлән, бәйрәмнәр булса, аның кашы-күзе коелыр, чырае сытылыр иде, чөнки бәйрәмнәр аның берничә хезмәтчесенең эшсез ашап ятканы өстенә, байтак кына акчасының чыгуына да сәбәп буладыр иде. Шуңа күрә ул бәйрәмнәрне,— шатлык көн итеп куану кайда,— бер зур бәлагә санап хафалана иде. Ул бәйрәм ашы хакындагы сукранулары гаҗәеп иде. Аның уенча, бәйрәм ашлары бер дә кирәк булмаган исрафлар, имеш. Мөселман кешегә ул кадәр кылынулар нигә кирәк, имеш.

Хәер, бу бәйрәм ашы хакында хәзердә дә төрле кешеләр төрле сүзләр сөйлиләр. Күбесе Хөсәен фикерен уртаклашып, исраф булуына баралар. Ләкин минем уемча, монда һичбер исраф күренмидер. Чөнки бәйрәм — кешенең берничә вакытлар көтеп ала торган бер зур көннәредер. Башка көннәрдән аермалары киемдә, гыйбадәттә булган кеби, ашау-эчүдә дә һәм булырга тиешледер. Дөрест инде, безнең шәһәребезнең бәйрәм ашлары ашала торган ук нәрсәләр булмыйлар. Һәр ни исә, табын зиннәте булып, бәйрәм көн икәнен белгертерлек нәрсәләрдер. Искедән милләтебездә гадәт булып килгәнлектән, ташлап ук бетерү мәгъкуль түгелдер.

Бер кавемнең гадәтләре бик кыйммәтле нәрсәләрдер.

Бер гадәтне бетерү бик ансат, әмма таратуы бик читен. Мөмкин кадәр милләтнең гадәтләре, ап-ачык зарури күренмәсә дә, ташланмаска тиеш. Бер кавемнең гадәт вә холыклары (горефләре) — аның бүтән кавемнәрдән аермасыдыр.

Гадәтләр ташлана-ташлана килеп, акрынлап бер кавем үзе дә башка кавемнәр арасында югалып китәргә мөмкиндер. Бер кавемнең югалуы исә бик күңелсез бер эштер.

Тарихтан мәгълүмдер, ничә-ничә кавемнәр дөньяда торып, соңра исемнәре дә калмады. Әлбәттә, бер кавемнең бетүенә гадәт ташлаудан башка сәбәпләр дә була, ләкин гадәт ташлау да бетүгә зур сәбәпләрнең берседер.

Халык бәйрәм ашы хакында теләсә ни дисен, әмма Хөсәен абзый аларны пешерүне бер дә мәгъкуль күрмидер иде. Ләкин Хөсәен агайның бу фикере, бу замандагы бәйрәм ашларын исраф санаган кешеләр кеби, бәйрәм ашына тотачак акчаны фәкыйрьләргә тарату яки башка бер хәер эшкә сарыф итү өчен булмыйча, бары тик акчага артык мәхәббәт итүеннән иде.

Дөресте дә, Хөсәен абзыйның акчага артык мәхәббәте камил иде. Бар уйлаганы — акчадан рәхәтләнүдән бигрәк, акчаны күбәйтү иде.

Кайбер кешеләр Хөсәен абзыйны бик сәүдәгәр кеше дип мактыйлар иде. Ләкин алар да, Хөсәен агай кеби, сәүдәгәрлекне ничек булса да акча алырга тырышу дип белгән кешеләр иде. Дөрест, әгәр дә сәүдәгәрлек, хәрамена, хәләленә бакмыйча, ничек кенә булса да үз файдасына тырышудан гыйбарәт булса, Хөсәен агай бик сәүдәгәр бер адәм иде.

Мин сезгә мондый начар холыкларын гына сөйләгәч, Хөсәен абзыйны һәр холкы начар, һәр гадәте әшәке бер кеше, дип уйламагыз. Аның яхшы холыклары да бар иде.

Хөсәен агайның игътикады[1] төзек, иманы таза иде. Ходадан бик курка иде. Тәмугъка керүдән бик куркып, җәннәткә керәсе дә бик килә иде. Шуңа күрә, никадәр эше күп булса да, биш вакыт намазны мөмкин

---

[1] Игътикад — ышану, уй.

кадәре әда итәргә[1] тырышадыр иде. Күбесенчә мәчеткә дә барыр иде. Үзе, бичара, акчага мәхәббәте булганлыктан, акчалы яхшылыклар кыла алмаганга, тән гыйбадәтеннән бер дә эшне калдырмаска тырышадыр иде. Акчалы яхшылыклар кыла алмаганны Хөсәен агай үзе дә бик яхшы беләдер иде. Асылда, тән гыйбадәтләренә бу кадәр бәйле булуы шул кимчелеген тутыру өчен иде.

Хөсәен агай нәфел намазлары укучан, нәфел рузалары тотучан иде. Ләкин кылган нәфел гыйбадәтләренең һәрберсен (күңеленнән) берничә сумлык акчалы яхшылыклар җиренә хисаплый иде.

Моннан башка Хөсәен абзыйның янә бер яхшы гадәте бар иде. Аның һичбер вакыт акча сарыф итеп, эчеп-исереп йөргәнен күрмәс идең. Кайсы кешеләр аның бу сыйфатта булуын тәүфигыннан түгел, акча кызгануыннан дип тә әйтәләр иде. Ләкин анысына без керешә алмыйбыз. Алай дигән кешеләрнең дәлиле шул иде:

— Хөсәен агайның эчмәве тәүфигыннан булса, танышларына кунакка барганда да эчмәс иде. Хәлбуки, алыш-биреш иткән дустларына кунакка барып, кичләрдә кайтканда кып-кызыл булып, исереп кайтадыр,— диләр иде.

Боларның сүзләре дә бөтенләй ялган булмаска кирәк, чөнки Хөсәен агайның корсагының ул кадәр үсүе тиккә түгел иде.

Хөсәен агайның төрле холыклары арасында бер бик кызыклы гадәте бар иде. Ул һәрвакыт шәкерт хәлен тикшерүчән, аларның эшләрен сораштыручан иде. Хәтта мәхәлләсендәге зуррак шәкертләрне исемнәре илән дә беләдер иде. Шәкерт хәлен сораштыручан дигәч тә, гыйлем кадерен аңлаган, шәкерт кадерен чикләгән бер кеше икән дип аңламагыз. Ул шәкертләрне дөнья ләззәтләреннән мәхрүм, бер җәзага мөстәхикъ[2] адәмнәр кеби итеп уйлый иде, шәкерткә киенергә, көләргә, уйнарга, истирахәт[3] итәргә ярамыйча, һәр вакытта тау тишегендәге заһидләр[4] кеби гыйбадәт кенә кылып утырырга тиешле дип белә иде. Бер шәкерт яхшы кием киенсә — хәзрәткә ирештерер, ике шәкерт көлешеп чәй эчсәләр, муллага сөйләр иде. Бу эшне үзе бер дә сүз йөртүчелек, гайбәт, кимчелек, гөнаһлы бер сыйфат дип белми иде. Бер шәкертне хәзрәткә яманласа, гүя бер зур мөстәхәб[5] эш кылган кеби эченнән сөенер иде. Яхшы әле дә, хәзрәт шәкертләре турысында зур дәүләте булмаган Хөсәен агай кеби кешеләрнең сүзенә бик карамый иде. Хөсәен агайның яманлаган шәкерте һәрвакытта мәдрәсәдәге иң тырышып укыган, ачык фикерле, өстен-башын яхшы йөрткән шәкертләр буладыр иде. Чөнки, аның акылынча, шәкерт кеше яхшы киенмәскә, ачык фикерле булып күп эшләр белмәскә тиеш иде. Хөсәен байның күп шәкерт арасында берничә яраткан шәкертләре һәрвакыт дәрескә ялкау, монафикъ[6], риялы, надан, әхлаксыз, өстен-башын ертык-портык йөрткән шәкертләр буладыр иде.

Хөсәен агай шәкерт хәлен беркадәр җентекләп торса да, аларга ярдәм итү, фәкыйрьләренә сәдакалар бирү кеби эшләр исенә дә кереп чыкмый иде. Гомере буенда Габделлатыйф хәзрәт мәдрәсәсенә иткән ярдәме — бер вакытта су ташый торган атларының аягы сынгач, шуны мәдрәсәгә сәдака иткән иде. Ул да әүвәл сатмакчы булып та, егерме сумнан артык бирүче булмагач, алган бәһасен алтмыш сумга хисаплап, Хода юлына бирүне алдан күрүендә генә иде.

Бу шәкертләрне хур, фәкыйрь күрү, үзләрен аларга баш бер кеше санау, яки аларны бик усал бер халыкка хисаплау безнең Хөсәен абзыйдан башка да күп кешеләребезнең гадәтедер.

---

[1] Әда итү — үтәү.
[2] Мөстәхикъ — хаклы, лаеклы.
[3] Истирахәт — ял итү.
[4] Заһид — дөньядан ваш кичкән.
[5] Мөстәхәб — яхшы, сабаплы.
[6] Монафикъ — ике йөзле.

Моңа сәбәп ни икәнен бик яхшы белмәсәм дә, занымча[1], аларны фәкыйрь, мескен күрүгә сәбәп — шәкертләр арасындагы бәгъзе риялы, соранчык шәкертләр булып, усал, явызга санауга да сәбәп — кайсы үз дәрәҗәсен төшереп, тәүфикъны бозып йөргән мәхдүмнәр булса кирәктер. Ләкин моның өчен дә безгә аларның хәлен тикшерергә килешеп бетмидер. Чөнки шәкертләр киләчәктә милләтебезнең дин вә әхлак өйрәтәчәк бер зур кешесе булачак адәмнәрдер. Аларны һәркайсыбыз зур күрергә тиештер. Без, кара халык, аларга әхлак өйрәтмик, киресенчә, алар безгә тугъры юл күрсәтергә тиешледер.

Ни исә, без үзебезнең хикәябезгә килик.

Хөсәен агай, җәмәгатеннән Халидтан яучы килгәнен ишетүе илә, бирергә уйлады. Хөсәен агайга Халидка якынаю, аның ышанычына керү бик кыйммәт торадыр иде. Чөнки Хөсәен агай Халид бай илә катышып китеп, үзенең җаныннан кадерле булган байлыгын тагын да арттыру ихтималы бар иде. Хөсәен агай күптәннән Халид илән дустланырга хәйлә таба алмыйча йөридер иде. Мондый, Ходай биргән җайдан (форсаттан) файдаланмый калу Хөсәен агайга мөмкин түгел иде. Әле яхшы, бу дустлану бер кыз биреп кенә мөмкин булды. Хөсәен агай ул дустлык өчен баладан кадерле бер нәрсәсе булса — аны да бирер иде. Чөнки анда акча мәхәббәтеннән башка бер мәхәббәт юк иде. Бала мәхәббәте, угылкыз шәфкате кеби кальб[2] хисләре Хөсәен агайда күренмиләр иде.

Бердән — гадәт булганга, икенчедән — хатынына җавап булсын өчен, бу эшне Хөсәен агай әүвәлдә хәзрәткә киңәште.

Хәзрәтнең әйтәсе сүзе билгеле инде, баштан үзе димләп булдырган бер эшкә каршы килү ихтималы юк. Хәзрәт, Хөсәен эшне аңлаткач та:

— Хөсәен, сораса бер дә аңа-моңа карама, замана бозылган, тәүфикълы кеше табуы бик читен, яшь кешенең баена да ышанырлык хәл юк, бүген болай, иртәгә тегеләй. Халид агай сыналган тәкауви адәм, төбәп сораткан икән, кайтарма, бир. Иншалла, уңарсың. Минем киңәшем шушы, — дип Хөсәенне кыздырды.

Хөсәен агай, хәзрәттән бу сүзләрне ишеткәч, күңеленнән бөтенләй бирергә уйлап, бирүне тиешлеге чыгарып, эченнән уйлаган серләре шулар булды: «Ие шул, бирергә кирәк, хатын-кыз ни белә, Латыйфа сүзенә карасаң, кулга төшкән җимештән коры калырсың. Ул хатын-кызлыгына бара, сату эшләрен белми, сәүдә хикмәтләрен сизми. Баю дигән нәрсә бик читен, һәрберсен уйласаң — баю кайда, ачка үләрсең! Бүтән эшләрдә: «Сиңайтәм, зинһар, хәрам катышмасын ла, мин хәрамгә разый түгел», — дип каршы килеп йөдәтә иде, менә инде бу кыз бирүдә хәрам катышмый, моның нәрсәсенә каршы килә инде?.. Баламны кызганам, имеш!.. Анда кызганырлык ни бар? Мал эченә бара, ни теләсә шуны кияр, ни эстәсә шуны җыяр дигән кеби. Хикмәт, кайсы кеше байлык кадерен бер дә белми! Кызым картка китә ди дә үлә. Киявенең яшьлеген байлыктан да өстен хисапламакчы буладыр. Җәмәгатең булса да, бөтенләй үз акылыңа китереп, үз холкыңа ияләндереп булмый бит. Гомерем буенча байлык кадерен аңлатырга тырыштым, мөмкин булмады. «Кызганам, килештермим, күңелсез булыр», — дигән кеби сүзләр илә йөдәтте үземне. Аллага шөкер, үзем ир табигатьле булдым, андый вак-төяк нәрсәләрне күп белмәдем. Нигә кешене кызганырга кирәк? Һәркем үзен-үзе кызгансын, кеше акча түгел бит! Кызын картка биргән дип, мине кеше гаеп итәсе, имеш, итсен! Картка биргән, ярлыга бирмәгән. Дөньяда кеше сүзеннән курыксаң, бер атларга хәл юк, әле дә мине кеше чәйнәми тормый, кайсы: гадел кеше түгел, хыянәтче, дип сүгә: кайсы караңгы чырайлы, дип яманлый. Гаҗәп халык! Шулкадәр эш кылып та хыянәт катышмый буламы соң? Безнең кеби сәүдәгәргә караңгы чырайлы булу да бер дә гаеп түгел. Минем кайчан якты чырайлы булырлык туйганчы файда

---

[1] Занымча — фаразымча, уйлавымча.
[2] Кальб — йөрәк, күңел. (Къәлб).

иткәнем бар? Туйганчы табыш итеп тә караңгы чырайлы булсам, гаеп итсә дә итсеннәр иде инде. Юк!.. Кеше сүзеннән котыла алмассың, тотарга да бирергә кирәк. Латыйфаның: «Кызыбыз рәнҗер, гомергә картка биргән өчен үпкә тотар»,— дигән сүзе дә юк сүз. Ата-ана разый булып биргәч, балада ни ихтыяр бар? Карт булса, ни була? Яшь яшьне теләр лә, әле Халид абзый карт булып та яшьне тели! Һәр эш үзең теләгәнчә үк булып бетми шул. Кайчагында, үзең теләгәнне куеп, кеше теләгәнне кыласың. Менә ул яхшы бала булып, атасының ризалыгын аласы килсә, мин биргән урынга еламый-сыктамый барсын. Мин аңа дога кылырмын, баштанаяк бәхил булырмын... Анасын күндерсәм, кызым карышмас иде лә!»

Укучылар, бу сүзләрдән Хөсәен абзыйның нинди фикердәге адәм икәнен аңладыңызмы?

Бичара, дөньяда байлыктан та газиз, дәүләттән кадерле бер нәрсә булуын аңлый алмыйча, үзеннән башка кешеләрнең бәгъзы эшләрен байлыктан алда тотуына гаҗәпсенәдер. Үзе, мескен, акчага мәхәббәте илә, кайчагында хыянәтләргә керә башлап, хатыны Латыйфа абыстай хәрам катышмауны үтенгәненә ачуы килгәнен белгертәдер.

Латыйфа абыстай, моның сүзләреннән аңлануынча, бик нечкә табигатьле, шәфкатьле, тормыш әдәпләрен белгән бер хатын булып, кайчакларда фәлән кешене кызганам, фәлән эшне килештермим, дигән кеби сөйләгәнне яратмаенча, үзендә андый кызгану, кешегә ярдәмле булу кебек эшләр булмавына куанып, үзем ир табигатьле булдым дип мактанадыр.

Бичара Хөсәен абзый белмидер ки, кызгану, шәфкать кеби эшләрнең булмавы — кешенең ирлегеннән булмыйча, бары бик каты күңелле җан табигатьле булуыннан гынадыр.

«Бу кадәр сәүдә илә эш кылып та, бер дә хыянәт катышмый мөмкинме?» — ди. Белмидер ки, дөньяда аннан ничә өлеш зур эшләр йөртеп тә, эшләрендә инә кадәр хыянәт катыштырмаска тырышкан кешеләр дә буладыр.

Үзенең якты чырайлы булмавын туйганчы табыш иткәне булмавыннан күрәдер иде. Бичара, сизмидер иде ки, андый хәсис[1] күңелле, малга хирыс кешеләр тәннәреннән җаннары чыкканга кадәр туйганчы бер эш тә кыла алмыйча дөньядан китәләр.

Бичара Хөсәен агай, аңласагыз, кызганырлык бер адәм иде.

Андый, малның файдасына, рәхәтенә кызыкмый, малның үзенә гашыйк булган адәмнәр, һичбер тынычлык күрми, бар гомерен хафада үткәреп дөньядан үтәләр.

Бер кешегә артык мал һавасы, акча гыйшкы төшмәсен. Ул адәм, ашау, киенү, көлү, шатлану — хасыйле җәмегъ[2], дөнья рәхәтләреннән мәхрүм булган өстенә, гыйбадәтләренә дә кимчелек китереп, ахирәтеннән мәхрүм калуы ихтималдыр.

Сез минем бу сүземнән байлыкны яманлый дип аңламагыз! Юк, мин байлыкны дошман күрмим, байлыкны яратам, байлык бик шанлы бер сыйфаттыр. Байлык аркасында һәркем алда буладыр. Бай милләт дөньяда игътибарлы милләт буладыр.

Хөсәен агай кеби, дөньясын, рәхәтен онытып, шәфкать вә мәрхәмәт кебиләрне җуеп, хәтта үзенең кешелеген дә баюга сатып, акчага җүләр гашыйк булмыйча, бер яктан рәхәтләнеп, тагате гыйбадәт[3] илә дөньяда торып, икенче яктан акчаның рәхәтенә, файдасына гына кызыгып баерга тырышу — һәркайсыбызга тиешледер.

Шулай итеп, кызын кияүгә бирүнең газиз баласына гомерлек иптәш табып бирү икәнен, шуның өчен кияү буласының үзенә килешүеннән бигрәк гомергә бергә торасы кеше — кызының күңеленә ошавы лязем булганын аңламыйча, бара торгач үзенең сату эшләрендә файдалануына,

---

[1] Хәсис — пычрак, түбән.
[2] Хасыйле җәмегъ — җыеп әйткәндә.
[3] Тагате гыйбадәт — Аллага гыйбадәт кылу.

акчалар алып тору мөмкин булачагына кызыгып кызын бирергә — турысы, җария кеби, акчага кызыгып сатарга күңелен утыртты. Хәзрәткә киңәш соңында җәмәгате Латыйфа абыстайга бирергә, вәгъдә куярга һәм әмер итте. Латыйфа абыстай, бичара, ни кадәр каршы килергә тырышса да, мөмкин булмады.

### III

Халид агайның Хөсәен бай кызы Рәбигага яучы җибәрүе бөтен йорт җәмәгатьләренә хафа булды. Хәлимә абыстай, халык теленнән куркып, кеше гайбәт кылыр, «Хәлимә абыстай гомерен ире илә тату үткәрмәгән булырга кирәк, иргә ярый торган хатын булмаска кирәк, юкса Халид агай карт көнендә бу уйга төшмәс иде»,— диерләр дип кайгыра иде. Әткәсенең бу эше, бүтән йорт җәмәгатьләреннән бигрәк, Халид агайның җиткән угылы Фатихның кәефсезлегенә сәбәп булды.

Рәбигага яучы барганны ишетүе илә Фатихның йөзләре күңелсезләнде, шатлыклары кимеде, һәрвакыт уйларга төшеп утыра башлады. Юкса, асылда, Фатих көләч йөзле, шат күңелле, бер мәҗлесен күргән кеше икенче күрергә теләрлек бер егет иде. Тәүфигы камил, кеше илә мөгамәләгә оста иде. Шул сәбәптән бу соң сәнәләрдә атасына бик зур ярдәмче булган иде. Халид абзый үзе газитәләр укып, дөньядан хәбәрдар булып торган бер кеше түгел иде, бая сөйләгәнемчә, иске табигатьле бер кеше иде. Шуңа күрә аның сату-алу эшләре дә искечә садәлек илә генә йөртеләдер иде. Үзенең эше шулкадәр зур булса да, язу-сызу эшләрен башкарган кешесе бер конторщик кына булып, эшләрендә күбесенчә чуалчыклар да булгалый иде. Халидның бер генә конторщик тотуы саранлыктан гына түгел иде. Бары тик ул кадәр язучыларның кирәклеген аңламаганлыктан гына иде. Бухгалтер-фәлән кеби нәрсәләрнең Халид агай, бәлки, исемен дә ишетмәгәндер. Ишетсә дә, яңа булганга, кабул итү ихтималы юк иде. Ләкин угылы Фатих бу турыларда бер дә атасына охшамаган иде.

Фатих, татарчадан башка русча укырга-язарга, сөйләргә белгән кеби, госманлыча да укырга-язарга бер дәрәҗә беләдер иде. Һәрвакыт «Тәрҗеман»нан башка бер рус гәҗите, бер госманлы гәҗите укып, дөньяда булган эшләрдән хәбәрдар булып торадыр иде. Күп егетләр Фатихны, яратмыйча, аңгырага хисап итеп йөриләр иде. Ләкин мин сезгә дөрестен әйтим, Фатих бик төпле, бик акыллы бер егет иде. Аларның аны яратмаулары төрлесенең төрле тиешсез сәбәпләрдән иде. Кайсы егетләр аны «калпания» гә килми, мокыт дип сүгәләр иде.

Ләкин, боларга ияреп, безгә бер дә Фатихны начар дип уйларга ярамый, чөнки бу егетләрнең максудлары «калпания» дисәләр дә, «компания» димәк иде. Ягъни, безнең илә компаниягә килеп кушылу, берничә сумнарны исраф итми дигән сүзләр иде. Йә инде, моның өчен Фатих гаепләме? Кайда ул мондый вак эшләргә катышу? Фатих бик зур күңелле галиҗәнаб бер егет иде. Аның морады башка, уйлары бүтән иде. Аның башы тагын да зуррак эшләрне уйлау илә мәшгуль иде.

Күп вакыт иптәшләре начар җирләргә, кабахәт урыннарга барыйк дип кыстасалар, Фатих, бик кәефе китеп, иптәшләренә шушы сүзләрне сөйли иде:

— Әй, дустларым! Ни өчен мине бу кадәр көчлисез? Мине шул эчеп исерүдән, кабахәтлектә гомерен кичерүче кызларның кылынышларыннан кызык таба дип уйлыйсызмы? Юк, борадәрләрем, юк! Мин кайда андый эшләрдән үзем ләззәт табу, бәлки бөтен адәм баласын ул хурлыктан коткарырга, кулымнан килсә, тырышыр идем. Беләсезме, туганнар! Дөньяда исерткеч, спиртле эчемлекләр кадәр адәм баласына зарарлы нәрсә бармы? Акыллы-акыллы егетләр эчү аркасында кешелектән чыгадыр, абруйлы гына кешеләр исерткеч җәфасы илә эштән дүнәдер. Исерткеч

бәласе илән бер милләт фәкыйрьләнергә, әхлакы бозылырга, хәтта бөтенләй мөнкарыйз булып (югалып) китәргә дә мөмкиндер. Бу заманда Европа халкы исерткечнең зарарлыгын акыл илә табып, исермәк дигән эшне азайтырга төрле чаралар эзләмәктәдер. Исерткеч истигъмален[1] киметергә, спиртле эчемлекләрдән халыкны биздерергә тырышкан әллә никадәр җәмгыятьләр ачылмактадыр. Динебез ислам дине һәртөрле исерткеч истигъмален хәрам кылганга күрә, бу вакытларга кадәр безнең мөселманнар дөньяда исерткеч истигъмаль итмәүләре илә мәшһүр иделәр. Һәрберебезнең бабаларыбыз исерткеч ни икәнен белмичә үлеп китмешләрдер. Динебез тыйган, акыл тыйган, бабаларыбызда гадәт булмаган бер начар нәрсәне истигъмаль итү безнең өчен бик зур кимчелек булачактыр. Моңа кадәр гадәт булмаган бер зарарлы нәрсәне халкыбызда гадәт итеп, халкыбызны бозып калдырсак, бик зур гөнаһлы булачакбыз. Бездән таралачак мөселманнарның яхшылары безгә бик начар дога кылачаклардыр, туганнарым! Күбесе ярлылык бәласе илә һәлакәт дәрьясына төшкән кызларның кыланышларыннан вә әгаюларыннан мин бер дә ләззәт таба алмыйм. Бәгъзы яшьләребезнең шул хурлыкта йөзүләренә бик кәефем китәдер. Бер милләтнең яшьләре ул милләтнең киләчәктә зур вә олугълары булачаклардыр. Әгәр дә без яшьләр халкыбызның алга китүен, бетмәвен теләсәк, бабаларыбызда булмаган кыйтылыкларны гадәт итү кайда, аларда булмаган халыкка файдалы эшләр уйларга тиешлебез. Яшьлегебездә мөмкин кадәр картайгач үкенерлек, кайгырырлык эшләр эшләмәскә тырышырга тиешбез. Яшь егеткә, картайгач үкенерлек бер эш тә эшләмичә, егетлек заманыннан узып китеп, картлыкта яшь заманнарны уйлаганда күңелне кырырлык, кәефне бозырлык бер эшкә дә очрамаслык булу кадәр кәмаләт[2] юктыр. Безнең ул хурлык юлына кергән кызлар янына китеп акчалар исраф итүебез, аларның башлаган эшләрен дә дәвам итүләренә вә башка берничә шундый яңаларының килеп чыгуына сәбәп буладыр. Безнең яшь егетләребез, андый кабахәтлекләргә маилдән[3] котылып, үзләрен яхшы йөртсә, килешмәгән эшләрдән тыелсалар иде, андый хурлыкта гомерен үткәрүче кызганыч кызлар да азаерлар иде. Аларның күплегенә сәбәп: бары бозык кешеләрнең күплегедер. Безнең халкыбызның андый фисык-фәсад[4] вә исрафларга мөбтяла булмыйча гына, үз-үзен саклавы да бик зур эштер. Чөнки безнең халкыбыз хәзердә һәр яктан бик артка калмыштыр. Безгә ул кимчелекләребезне тутырырга, бүтән кавемнәр дәрәҗәсенә җитәргә байтак заманнар тырышырга, күп вакытлар чалышырга туры киләдер. Безнең ачык фикерле яшьләргә андый хурлык җирләрендә ваксынып йөрү тиеш булмыйча, халкыбызга файдалы вә милләтебезгә кирәкле эшләр уйларга тиеш буладыр. Кешесез калган фәкыйрь балаларның, үсеп җиткәч, ирләре — кесәче[5], кызлары фәхишә буладыр. Безгә шундый эшләрне уйлый белергә тиешледер. Әгәр дә без һәм сезнең кеби дәүләтле кешеләрнең угыллары тырышып һиммәт итеп, акчалар җыеп, ул бичара ятимнәргә ятимханәләр ачсак, алар һичбере хурлык юлга китмәсләр иде. Һәрбере, тәрбия илә үсеп, бик гүзәл инсафлы берәр мөселман вә мөслимә булырлар иде. Безгә халкыбызның моның кеби эшләрен аңларга һәм белергә тиешледер. Моннан башка да халкыбызның җитмәгән җирләре бик күптер. Аларның кайсын без аңлый да алмыйбыз. Без — наданнар, һич булмаса, үзебез аңлаган кадәресенә тырышыйк! — дигән кеби сүзләр сөйли иде.

---

[1] Истигъмаль — куллану, файдалану.
[2] Кәмаләт — камиллек.
[3] Маил — тартылу, һәвәслек.
[4] Фисык-фәсад — бозыклык.
[5] Кесәче — кесә карагы мәгънәсендә.

Ләкин ул бичара «калпания» эстәүчеләр бу алтын кеби сүзләрне аңлаудан ерак иде. Аларда андый нотыкларны аңларлык ми юк иде. Булса да, кечкенәдән тиешле тәрбия күрмәгәнгә, бозылып беткән иде. Шуңа күрә ул бичаралар Фатихның сүзләреннән мәгънә ала алмагач, Фатихны җүләргә санап китәләр:

— Мулла кебек безгә вәгазь сөйләгән була. Без синең кебекләрне күргән... Китап укый-укый рәтле сүз дә сөйли белми инде. Китаптан башка нәрсә белми. Ай, «уку батыр», ниләр сөйләгән була!» — дип гаеп итеп йөриләр иде.

Хасыйле[1], Фатихның тәрбиясе бик яхшы иде. Анда һичбер начар уйлар вә бозык фикерләр күренми иде. Фатихның болай булуы соңгы хәлфәсе Камил әфәнде аркасындадыр. Фатих Камил әфәнде кулына төшмәгән булса иде, һич бу кадәр инсафлы, бу дәрәҗә мәгърифәтле булу ихтималы юк иде.

Фатих — Халид агайның картлыкка таба дөньяга килгән бердәнбер угылыдыр. Фатих, бердән, ата-анасының карт көннәренә кадәр балалары тормый килгәнгә бик угыл көтеп торган вакытта туган булуыннан, икенчедән, үзе дә кечкенәдән күркәм йөзле, мөлаем табигатьле булуыннан, кечкенә вакыттан ата-анасы вә кардәш-ыруларының һәрберсенең күз өстендә иде. Халид агай Фатихны җиде яшенә килер-килмәс мәдрәсәгә, Шакир исемле бер хәлфәгә бирде. Фатих үзе дә бик зирәк, тырыш бала булып, хәлфәсенең дә тырышып укытуы аркасында ике кыш тулганчы акрынлап төрки танып, укый башлаган иде.

Бичара хәлфәсе Халид агайга Фатихны язу таныган итеп күрсәткәнче бик күп мәшәкать чикте, хәтта Фатих укый башлаган кыштан соң үзенең дәресләрен карарга да вакыты булмый башлады.

Фатих укый башлаганда Шакир хәлфә яңа пишкадәм[2] булып, үзенең моталәгасе[3] чыгып, тоткан гарәп китапларын аңларлык булса да, әле бөтенләй галим булып җитмәгән иде. Бигрәк тә фикъһы[4], тәфсир[5], хәдис[6] гыйлемнәреннән гафил иде. Дөнья фәннәренең барын да ишеткәне юк иде. Хәлфә үзе дә, әтән моңа көенсә дә, үзенең укуларын, галим булуларын һәрберен Халид бай угылы Фатих өчен фида иткән иде. Чөнки ул Фатихның үзеннән укуына бик куана, аны бик зур эшкә саный иде. Фатих укый башлау Шакир хәлфәнең ата-аналарының да бик сөенүенә сәбәп булды. Алар да бу эшне гүя Ходa тарафыннан җибәрелгән бер зур бүләккә санап, Ходага шөкерләр иттеләр. Угылларына, Халид бай угылын үзенә китертерлек булган өчен, күп догалар кылдылар.

Шакирны Фатих хәлфәсе булуы илә мәдрәсәдәге иптәшләре дә көнчеләп, дошманлык касды[7] кыла башладылар. Кулларыннан килгән зарарны кылырга тотындылар.

Шакир хәлфә Фатихның үзеннән укуына ник бу кадәр сөенә, ни өчен бу дәрәҗә шатлана иде?

Халид агайдан күп сәдакалар булгандыр дип уйламагыз. Вазифасы[8] һәр кечатнада егерме тиен, ягъни айга сиксән тиен иде. Бу әлбәттә, бик аз нәрсә. Моны иң гади бер хезмәтче көнендә дә аладыр. Шакир моңа мохтаҗ түгел иде.

Атасының дәүләте яхшы, тормышы иркен бер мулла иде. Шакирның максуды: бер мөселман баласына дин танытып сәвап алу да түгел иде. Шакирда бу уй булган булса иде, бүтән фәкыйрь балаларны һәм

[1] Хасыйле — кыскасы.
[2] Пишкадәм — мәдрәсә курсын тәмамлаган шәкерт.
[3] Моталәга — уку, өйрәнү.
[4] Фикъһ — хокук гыйльме.
[5] Тәфсир — Коръәннең фәлсәфи аңлатмасы.
[6] Хәдис — Мөхәммәт пәйгамбәр сүзләре, эш-гамәлләре җыелмасы.
[7] Касд (къәсд) — явыз ният.
[8] Вазифа — хезмәт хакы.

тырышып укытыр иде. Хәлбуки, Фатих укый башлаганнан соң бичара егермеләп фәкыйрь балалар вә ничәләп дәрес укый торган шәкертләр яхшылап сабак та ала алмый башладылар.

Юк, Шакир хәлфә акчага да кызыкмый, савапны да уйламый иде. Аның кыйммәт санаган, зурга күргән эше — бердән атнада, бердән җомгадан чыгышлый ат илән Халидка ашка бару, икенчедән, «Халид бай хәлфәсе» дигән исем иде.

Бу Шакир хәлфә Халид бай мәҗлесенә бару илә Халид бай хәлфәсе дигән сүзгә бик кәефе килә иде. Гаҗәеп?!

Акчасына дисәң, мәҗлес сәдакасы бик аз бер нәрсә иде. Бәлки, ат белән утырып бару бик кәефле булгандыр? Уйлап карасаң, ул да балигъка ирешкән, егермеләргә җиткән бер кешенең кәефен китererлек бер эш түгел. Инде хәлфә боларга куансын да, шәрикләре[1], бүтән пишкадәмнәрни өчен бу кадәр кечкенә бер эшне зурга санап көнчелиләр иде? Монда акыллы кеше куанырлык, иптәшләр көнчеләрлек, безнең уебызча, бер эш тә күренмидер. Хәер, бәлки, без кара халык аңламый торган бер сер бардыр? Бәлки, халык көнчели дип Фатих шатлангандыр? Фатих шатлана дип халык көнчели дип Фатих шатлангандыр? Фатих шатлана дип халык көнчеләгәндер? «Холкына күрә холкы, иясенә күрә гадәте»,— диләр.

Ләкин Фатихның бу хәлфәсе, әткәсенең вафаты сәбәпле авылына мулла булырга туры килеп, мәдрәсәдә күп тора алмыйча чыкты.

Халид агай тәкауви, голяма кадерен белә торган кеше булганга, Шакир хәлфәнең Фатихка тиз заманда (ел ярымда) язу танытканын онытмады. Шакир чыккач та, авылының мәчете иске икәнен белеп, бер яңа мәчет салдырып бирде.

Шакир хәлфәнең чыгуы илә Халид агай Фатихны, хәзрәт кушуы буенча, Камил әфәндегә бирде.

Камил әфәнде укыта башладыгы белән Халидтан айлык вазифа тәгаен иттерүне үтенде. Хәлфә кешенең бу эше Халидка бик ярап бетмәсә дә, Латыйф хәзрәт тә: «Камилнең карар кешесе юк, сораса — бирсәң дә зарар юк»,— дию буенча, һәр айда биш сум бирәчәк булдылар.

Фатихның Камил әфәнде кулына төшүе үзенә бик файдалы булып чыкты. Чөнки Камил әфәнде бик зирәк, фәһемле бер шәкерт булып, голүме исламиядән яхшы гына мәгълүмат алган өстенә, үз һәвасе илә госманлы лисанын[2] вә, бераз тәхсыйль[3] итеп, рус әдәбиятын аңларлык бер дәрәҗәгә килгән иде.

Шуңа күрә Камил әфәнде рус, госманлы һәм гарәп, Мисыр гәзитәләре укучан, дөнья әхвальләреннән ләззәт табучан иде.

Камил әфәнденең гәзитәләр укуын мәдрәсә халкы күбесе яратмый иде. Күп вакыт: «Гәзитәдән башка бер нәрсәдә ихласы да юк, һәрвакыт гәзитәләр карап утырадыр-фәлән»,— дип, хәзрәткә дә ирештерәләр иде. Хәзрәт ул юк нәрсәләр (гәзитә) илә шөгыльләнүенә бик кәефе килмәсә дә, бүтән яктан бер дә гаебе булмаганга, бер ул эш өчен ачуланмый иде. Алай булса да, Камилнең гәзитәләргә ул кадәр ихласы булганны белгәч, шәкерт бирүдән, хосусән баерак кеше балаларын бирүдән тукталган иде.

Камил әфәнде Фатихны биргәнгә кадәр дә гәзитә карамый тормый иде. Ләкин аңа кадәр Камилгә иптәшләренең дошманлыгы булмаганга, бу эш хәзрәткә ирешми иде. Камил, гәзитәләргә ихласлы булса да, һәрвакыт гәзитә илә шөгыльләнми иде. Шәрикләренең һәрвакыт гәзитәләр илә утыра дигән сүзләре ифтира[4] иде. Әгәр дә Камил әфәнде һәрвакыт гәзитәләр илә генә шөгыльләнсә иде, көнчеләүче иптәшләреннән һәр фәндә ничек өстен була алыр иде?

---

[1] Шәрик — шәкерттәш.
[2] Лисан — тел.
[3] Тәхсыйль итеп — өйрәнеп, укып.
[4] Ифтира — ялган, яла ягу.

Көнчеләр ни димәс! Ләкин Камил әфәнде һич шөбһәсез фазыйль адәм иде.

Фатихны Камил мәдрәсәдән чыкканга кадәр укытты. Халид баласы дип Шакир хәлфә кадәр үк исе китмәсә дә, укытуы аннан артыграк иде... Дин, иман, игъмаль, гыйбадәт өйрәткән өстенә, җәгърафия, тарих, хисап кеби нәрсәләргә һәм мохтасарән[1] өйрәтте. Камил әфәнде Фатихка бер яктан гыйлем өйрәтә, икенче яктан гүзәл гадәтләргә, күркәм холыкларга алыштырырга тырыша иде. Ләкин Камил әхлакка, инсафка өйрәтергә тырышкан кеби, әллә ни кадәр дәрес укымый, мәдрәсә тутырып яткан инсафсыз шәкертләр Фатих алдында төрле әшәке сүзләр, бала алдында сөйләргә ярамаган эшләр сөйләп, Фатихны бозарга тырышалар иде. Чөнки бу рәвешчә Фатихны әшәке юлга җибәреп, Камилне Халид күзеннән төшерергә ихтимал бар иде.

Фатих үзе дә тумыштан мөлаем булган, Камил әфәнде дә туктамый үгет-нәсихәт итеп торганга, Фатих андый әшәке холыкларга, бозык гадәтләргә өйрәнми, бик тәрбия-адәп илән генә үсеп, мәдрәсәдән чыкты. Кайбер бала, мәдрәсәдән чыккач, төрле начар адәмнәргә ияреп, бозылып китәдер. Ләкин Фатих, Камил әфәндедән оста тәрбиясе аркасында, мәдрәсәдән чыккач та тәүфикъны, инсафны җуймады. Һәрвакыт гыйлемнән ихласы, мәгърифәттән һәвәсе сүнмәде. Асылда, мәдрәсәдән чыгуына да Фатих разый булып, чыгасы килеп чыкмады. Халид агай көчләгәнгә генә, атасына каршы килмичә генә чыккан иде.

Фатих, мәдрәсәдән чыккач, әткәсеннән үтенеп, бер кыш чамасы русча укыды. Үзенең зирәклеге аркасында шулкадәр генә укуы илән дә русча бик аңлый башлады. Хәер, инде аңларга да, сөйләргә дә тиз остарып китүенә руслар илә күп катышуы сәбәп булды. Эшләре зур, рус белән катышулары да күп иде. Фатих, русчасын арттыру һәвәсе илә, ничек булса да рус күрде исә сөйләшә, сөйләшкәндә дә һәрвакыт бер файда алырга тырышадыр иде. Дөньяда тырышып булмый калган эш бик сирәктер. Тырышу аркасында Фатих та эстәгәненә иреште. Бара торгач, сөйләшүенә бөтен кеше гаҗәпкә кала башладылар. Чөнки Фатихның сөйләшүе дөрест — русның нәхүенә (грамматикасына) муафикъ иде. Әмма Фатихның сөйләшүенә гаҗәпсенгән кешеләр, русча беләбез дип йөрсәләр дә, һәр сүзләре ялгыш, нәхү кагыйдәләреннән буш иде. Шуңа күрә алар Фатихка: «Син господалар күк сөйләшәсең», — диләр иде. Хасыйле кәлям[2], Фатих бик мәгърифәтле, ачык һәм җайлы бер егет иде. Аның атасы Рәбигага яучы җибәргәнне белгәч, каралулар, күңелсезләнүләре кайгычан, тонык булуыннан булмас, башка бер сердән иде.

Кешенең серен чишү килешмәсә дә, гыйбрәт алыну, акыл өйрәнелү ихтималы булганга, Фатихның кәефсезлегенең чын сәбәбен сөйлим.

Фатихның кайгысы атасы өйләнгән өчен генә дә түгел иде. Атасының алтмыш яшендә ваксынып өйләнеп йөрүен килештермичә, анасына көндәш булуын эстәмичә бераз кәефе китсә дә, бу кадәр хафага төшүенә асыл сәбәп икенче иде. Ел ярымнан бирле Фатих Хөсәен кызы Рәбиганы сөядер иде. Ике араларында бик каты бер мәхәббәт, аерылмаслык бер дустлык бар иде...

Фатих илә Рәбиганың бу мәхәббәт вә дустлыкларының сәбәбен, ни рәвешчә башланып китүен, әлбәттә, беләсегез бик килер. Ләкин бу эш кешегә мәшһүр булып, кеше белеп булган эш түгелгә күрә, бу турыда мин дә бик аерып белмимен. Алай булса да, белгән кадәремчә бу мәхәббәтнең башлануларын сезгә сөйлим.

---

[1] Мохтасарән — кыскача.

[2] Хасыйле кәлям — сүзнең кыскасы.

## IV

Фатих, мәдрәсәдән чыккач, Камил әфәнденең биргән вәгазьләрен, сөйләгән нәсихәтләрен онытмыйча, сату эшләренең тәмам җаен алып, атасына бик зур ярдәмче булып, тәүфигында гына йөри иде. Фатихның сатудан кала иң ихлас биргән шөгыле уку иде. Шулкадәр укуга бирелгән иде ки, аз гына буш вакыты булдымы, хәзер гәзитә, китап йә роман моталәгасенә ябышыр иде.

Кайчагында Халид агай, үзенең искелеге белән, бу кадәр укуга ихласы өчен: «Уку җене кагылдымы әллә? Бер туктамый кулыңда гәҗит тә китап!» — дип, Фатихны шелтәлидер дә иде. Ләкин бу шелтә тиешсез иде. Чөнки Фатих, уку илә шөгыльләнсә дә, үзенең сәүдә эшләренә бер дә кимчелек китермидер иде. Бу китап уку, гәзитә карау илә шөгыльләнү Фатихка кызыклы булган кеби, Халид агайга да зарарлы бер эш түгел иде.

Халид бай бу турыда юкка гына үзенең акыллы угылын шелтәли иде, чөнки Фатих гыйлемгә һәвәс салып, укуга ихлас бирмәсә иде, кем белә, әллә нинди әшәке юлларга кереп китәр иде. Аның болай тәүфигында торуы бары уку аркасында гынадыр.

Мәдрәсәдән чибәр генә булып чыккан бай угыллары, белү ләззәте вә дөньядан хәбәрдарлык рәхәтен сизмәгәнгә, укуга һәвәс итмичә, төрле начар юлларга кереп китәләр. Бу бик сыналган эштер.

Дөньяда кеше һичбер тик торырга ярамыйдыр, шөгыльсез булдымы, адәмне эч пошу дигән нәрсә борчый башлыйдыр. Бу эч пошу бик начар бер авырудыр. Аның дәвасы — бер нәрсәгә бик каты ихлас биреп, шуның илән шөгыльләнүдер. Безнең бай балаларының, һәркемгә мәгълүм, эшләре күп булмыйдыр. Шуның өчен аларның күбесе, балалыктан чыгып, уенчыклардан кызык тапмый башлагач, эчләре пошып, башка төрле кызыклы, бүтән төрле истирахәтләр эзли башлыйлар. Менә шушы вакытта бу егетләр гыйлемгә һәвәс салып укуга ихлас куйса, күп нәрсәләр белеп, зиһене ачылып, акылы киңәйгән өстенә, эч пошу бәласеннән һәм котылалар. Әмма безнең күп егетләр уку ләззәтен белмәй, уку галәменә керә алмаенча калып, эч пошканын бетерергә, карлы басулардан чәчәк эзләгән адәм кеби, хурлык вә рәзаләт[1] җирләреннән кызык вә җуаныч эзләргә башлыйлар.

Егетләрне тәүфикъларында саклар өчен болай яшьлек мизаннары[2] тигез вакытта, күбесенчә, өйләндерү дә бик файда итәдер. Ләкин өйләндерү, «кыз алып бирү» мәгънәсендә генә булмаеп, «иренә иптәш, сердәш булып, аның кайгыларын таратырга, эч пошканнарын бетерергә тырыша торган һәм ир булачак адәм яратырлык бер рәфыйка[3] табып бирү» мәгънәсендә булырга тиешледер. Угыл эстәмәгән нинди генә булса да бер кыз алып бирү, угылны начар юлларга китүдән саклау булмаеп, бәлки, шул юлга китүенә иң зур бер сәбәп буладыр. Ләкин һәр нәрсәдән артык, кешене тәүфикъ вә инсафта саклый торган нәрсә — укудыр.

Менә Фатих беренче мисалдыр. Аның илә бергә мәдрәсәдән чыккан егетләрнең күбесе бозык юлларга кереп киттеләр, әмма Фатих, кайда үзе бозылу, башкаларны да хурлык эшләрдән туктатырга вәгазьләр, үгетләр сөйлидер иде. Чөнки аның бик абруйлы, бик мактаулы шөгыле бар иде — ул һәрвакыт укучан иде. Фатихның укыган китаплары арасында төрле хикайәтләр, мәхәббәт һәм гыйшык романнары да очрап, өйләнү, мәхәббәт, гаилә сәгадәте кеби нәрсәләрнең нидән гыйбарәт икәнен ул яхшы аңлаган иде.

Үзе никадәр сату илә укуга ихлас биреп, һәрвакыт шулар илә мәшгуль булса да, фикереннән өйләнергә вакыт булганны, өйләнү һич үзенең сату

---

[1] Рәзаләт — хурлык, түбәнлек.
[2] Мизан — хатын, юлдаш.
[3] Рәфыйка — хатын, юлдаш.

эшләренә зарарлы булмаячагын белеп, өйләнүне бик соңга калдырасы килмәенчә йөридер иде.

«Аллага шөкер, минем дөньяда мәгыйшәт башлап җибәрергә чаралар эзләп йөрисем юк, эшләремез корылган, кәсепләремез юлына салынган, байлыгымыз да, шөкер, җитәрлек. һөнәр яки тиҗарәт[1] мәктәпләренә кереп укый алмадым исә дә, шул Ходай биргән байлыкны исраф итмәй, юлга салынган эшләремезне туктатмай тора алсам, шул үзе миңа бер кәсеп булыр инде. Хәер, мондаен мәктәпләрдә уку зарар итмәс иде. Дөньяда бездән дә бай кешеләр бар, алар да, үзләре ни эштә булсалар, шул эш яхшы укыла торган мәктәптә угылларын укыттыралар. Тиҗарәт мәктәбендә (сату-алу гыйлеме укыла торган мәктәптә) укыган булсам, эшемезне оста йөртергә, дәүләтемезне арттырып, халкымызга зур файдалар ясарга мөмкин булыр иде, ләкин ул эш миңа мөмкин түгел инде. Минем әткәем рөхсәт бирү ихтималы юктыр. Адәм баласының гомере күп түгел. Шуның өчен өйләнүне соңга калдырмавым яхшы булыр.

Хәер, инде мәдрәсәнең пишкадәмнәре һәм университетның студентлары — хасыйле, һәр укыган кешеләр егерме биш — егерме җиде яшьсез өйләнмиләр, кайсылары утызларга да калалар. Ләкин аларга соңга калсалар да килешәдер. Чөнки алар укып калалар, уку бөтен адәм баласына файдалы эш булганга, алар үзләренең гомерләрен кызганмый, өйләнүләренең соңга калуына да кәефләре китми. Укуда үткәрүләре бөтен адәм балалары файдасына бик зур бер фидакярлекләредер. Шуның өчен аларның соңга калып өйләнүләре кәмаләткә саналырлык бер эштер. Әмма мин уку юлына китә алмадым инде. Минем өйләнүемнең соңга калуы кәмаләт булмаячак, бәлки бер noксан[2] гына саналачактыр. Мөмкин булачак булса, тиздән өйләнеп, гаилә сәгадәте, мәхәббәт кеби мактаулы хисләрнең ниндәен нәрсәдән гыйбарәт икәнен белергә башларга тиешмен», — дип уйлый иде.

Фатих тиз өйләнү кирәклеген, өйләнүдә гаилә сәгадәте, мәхәббәт кеби къәлб рәхәтләре булганны аңласа да, кайдан өйләнү хакында фикере бик тирбәнә иде. Шәһәрдә бай кешеләр булмаганнан түгел, шәһәремездә Фатихларга тиңдәш булырлык әллә никадәр байлар булып, күбесенең кызы һәм бар иде. Ләкин Фатих аларның һәркайсын сораштырып, төрлесенең төрле гаепләре булганны белгән иде. Ул кызларның косурлары[3] төстә, җәмалда[4] түгел иде. Фатих җәмалга бик үк исе киткән кеше түгел иде. Кызларның косурлары әхлак, тәрбия, гадәт җәһәтеннән иде. Кайсы әдәпсезрәк, кайсы каты сүзлерәк, кайсы тонык иде. Мондаен гаепләре берсе дә булмаганнары гыйлемнән мәхрүм калган наданнар иде. «Кызымызның төсе-бите күркәм, байлыгымыз ярыйсы, укымаса да алучы булыр, кызымыз муллага бармас», — дип, укытмый калдырган аталарның кызлары иде.

Фатих матурлыкка исе китми дигәч тә, алачак туташының сукыр йә аксак булуын теләми иде, әлбәттә. Ләкин һәр ни исә, бик матурлыкка гына ихлас куймаеп, матурлыгы бер дәрәҗә булса да, әхлагы, җайлылыгы бик гүзәл булуны телидер иде. Чөнки Фатих, күп китаплар укып, «мәхәббәт бер матурлыкка карамаеп, әхлак вә инсафына карап булганга, бер матур әхлаксыз кыз алып, татсыз сүзләр, килешсез кыйланышларга чыдап гомер итүдән, матурлыгы артык булмаса да, яхшы әдәп вә инсафлы бер кыз илә рәхәтләнеп, сәгадәтле гомер кичерү мең дәрәҗә артык» икәнне белгән иде.

Сораштыру соңында үзләренә тиң баерак җирләрдә муафикъ кызлар булмаганын белгәч, Фатих түбәнрәк җирләрдән үзенә охшаулы бер кыз эзләү фикеренә килде. Бер вакытта Фатихлардан түбәнрәк кеше кызлары

---

[1] Тиҗарәт — сәүдә.
[2] Ноксан — кимчелек, җитешсезлек.
[3] Косур — кимчелек.
[4] Җәмал — матурлык, чибәрлек.

арасында Хөсәен кызы Рәбиганы хатын-кызның яратып, мактап сөйләгәнен ишетеп, дөрестлеген бик беләсе килеп, сеңлесе Һәдиядән сораштырды. Чөнки Һәдия ундүрт яшьлек бер кыз булып, Рәбига илә бер остазбикәдә укыйлар иде.

Һәдия Рәбиганың әхлагын, гадәтләрен һәм төс-битләрен бер-бер мактап сөйләгәч, Фатих Рәбиганы бик күрү һәвәсенә төште. Күп егетләремез: «Безнең халыкта күреп өйләнеп булмавы бик читен бер эш, үзең илә гомергә бергә торасы кешене һич бер күрми алырга ничек батырчылык кыйлмак кирәк? Мадам ки[1], өйләнмәк өчен күрергә рөхсәт бирәдер, хәтта күп китапларда күреп алуны сөннәт дип әйтәдер, ни өчен күрмәскә кирәк? Һич булмаса, төсен күрсәң дә ярар иде»,— дип, халкымызда бер дә күрү юк дип белеп, халыкка үпкәләп йөрсәләр дә, төрле хәйләләр илә тырышкач, күреп алган кешеләр дә булгалыйдыр. Бигрәк тә сеңлесе булган егетләргә алачак туташын күрү бер дә авыр эш түгелдер. Кызлы йортта кызлар мәҗлесе булу шәһәремездә искедән калма бер гадәттер. Бу мәҗлестә алачак кызыңны күрергә түгел, әхлагын, сүзен, һәр кыйланышын сынарга, хәтта бүтән кызлар белән чагыштырырга да мөмкин буладыр. Дөрест, бу күрү дә бик ансат түгел, аерыбрак күрү өчен ишек яки шкаф арты кеби бер тыгыз җирдә тирләп-пешеп беткәнче торырга туры киләдер. Ни исә, бер дә күрмәгәнгә караганда бер күрү дә бик яхшы. Чөнки бер мәҗлес үткәнче, кешене бик күп сынарга мөмкин буладыр.

Сеңлесе Һәдия булганга, Фатихка Рәбиганы күрү читен булмады. Бер мәҗлес ясалып, Фатих та Рәбиганы эстәдеке кадәр күрде, теләгәне кадәр сынады. Рәбиганың матур тавышлары, җайлы сүзләре, нурлы йөзләре, ягымлы кыйланышлары, ирексез, Фатихны Рәбигага гашыйк итте.

Бәлки, Халид агайларда моңар кадәр кызлар мәҗлесе булмагандыр да, булса да, Фатих илтифат итеп карап тормагандыр. Һәр ни исә, Фатих бу вакыткача һичбер күп кызлар күргән, аларның гадәтләрен, мәҗлесләрен тикшергән бер егет түгел иде. Бу мәҗлестән соң Фатих, Рәбиганың һәр холкын вә гадәтләрен яраткач, бөтенләй күңел төшеп, алырга уйлап, гыйлеменең һәм ярыйсы булуын теләп, сораштырып карады. Рәбиганың гыйлеме бик яхшы иде. Ул укыган остазбикә, бүтәнчә яучылык хезмәтен булдыра алмый башлагач, кызлар укытырга тотынган карчыклар җөмләсеннән түгел иде. Акылы ирешкәнчә үзе белгән кадәрен яхшы укыта торган иде. Күп остазбикә исемле карчыклар, үзләре язу белмәгән сәбәпле, бичара кызларны язу язмак кәмаләтеннән мәхрүм калдыралар. Ләкин Рәбиганың остазбикәсе, бер хаттат[2] мулланың кызы булганга, язуга бик оста иде. Үзеннән укыган кызларга бик яхшылап язу өйрәтү гадәте иде. Шуңа күрә Рәбиганың язуы һәм бик матур иде. Сеңлесе аркасында Фатих Рәбиганың язган язуларын һәм күрде.

Рәбиганың үзен дә яратып, гыйлеме вә язуы һәм яхшы икәнне белгәч, Фатихның эченнән уйлаган уйлары шулар иде: «Безнең халыкта инде моннан да һәр яктан килгән кыз табуы читен булыр. Әле язу яза белгәнен табып та булмас дип курка идем. Рәбиганың язуы күп ир кешеләрнекеннән артыграк. Гадәтләре, кылынышлары да күңелемә охшады. Ходага тапшырып, шуны алырга кирәк инде... Дөрест, гыйлеме әллә нинди түгелдер. Әлбәттә, инде ул җәгърафия, тарих, хисап кеби фәннәр белмәс, белмәве һәм гаеп түгел. Дин, гыйбадәт белеп, гүзәлчә язу язганы да бик зур эш. Безем кавемемездә андаен дин гыйлемнәренә дә, фәннәргә дә ашнән[3] кызны ничек тапмак кирәк? Мөселманча да, русча да укыган, ислам тәрбиясе илә үскән бер дә булмас дип әйтергә ярамый, күп халык арасында, бәлки, бардыр да, ләкин мин таба алмам инде. Чөнки мин үзем, гәрчә күп нәрсә белсәм дә, тәртипле мәктәптә үк укыган кеше

[1] Мадам ки — чынлыкта.
[2] Хаттат — китап күчерүче.
[3] Ашнән — мәгълүматлы, хәбәрдар.

түгелмен. Русча гына белгән, бәлки, табылыр да иде. Ул тагы миңа мәгъкуль түгел, чөнки мин, укуым күп булмаса да, бик милләт сөйгән, халкымызны яраткан бер адәмдер. Үзем милләтемезчә торуны яраткан кеби, үземнең зәүҗәмнең[1] дә милләт гадәтләрен белгән, халкымыз укыган нәрсәләрне укыган булуын телимен. Миңа Рәбига бик тиң, бик мәгъкуль, Аллага тапшырып, шуны алыйм инде».

Фатих тиз өйләнергә, Рәбиганы алырга уйлап йөрсә дә, Халид агайда угылын өйләндерү уйлары бер дә юк иде.

Фатих, берничә вакытлар атасының өйләндерү уена керүен көтеп тә бернәрсә чыкмагач, Рәбиганың бүтән кешегә китүеннән бик курыкты. Чөнки Рәбига тәмам өлгереп җиткән бер җимеш иде. Аны алырга һәвәс итүче күп булачагы шөбһәсез иде. Фатих та тиздән өйләнәсе килгәнен, Рәбиганы алмак эстәдекен атасына белгертерлек кыюлык тагы юк иде. Рәбиганы башкага бирмәскә күп хәйләләр уйлый торгач, хәтеренә шул хәйлә килде: үзенең Рәбиганы чын күңеленнән ятратканын вә һич шөбһәсез алачагын алдан белгертеп куярга уйлады.

Кешенең күңелендәге кеше яхшылап белгертә-аңлата алмас дип, Фатих үзенең серен Рәбигага хат илә язып аңлатырга теләп, шушы хатны язды:

**«Гыйффәтле гүзәл кыз!**

**Мәгълүмдер ки, дөньяда Хак тәгалә һәр нәрсәне чәффат (пар) итеп яратмыштыр. Адәм баласының үзенә бер хәбиб[2] тапмагы табигый кануннардандыр. Һәркемгә үзенә муафикъ бер яр табып, шуның илә мәсгуданә[3] мәгыйшәт итмәк тиешледер. Дөнья төзеклеге шуның иләдер. Мин дә күп вакытлар үземә муафикъ бер зәүҗә эзләп йөреп, ахырында сезне таптым. Һәр кылынышың, һәр килешең миңа бик ошады. Гафу боерыңыз, рөхсәтсез мин сезнең төсеңезне һәм карадым. Сораштырасораштыра холкыңызны да өйрәндем. Әхлакыгыз, җәмалегез һәрберсе мине сезгә гашыйк итте. Разый булыр исәңез, мин сезнең илә парланмак эстәр идем. Бу хатымны кабул итсәңез, миңа хат илә белдереңез. Бу тугърыда оялмак кеби эшләр файдасыздыр. Эчеңдә ни булса, шуны яшермәскә кирәк буладыр. Кабул итмәячәк булсаңыз, бу әдәпсезлегем өчен гафу итеңез.**

***Гашыйкыңыз...»***

Бу хатны Рәбигага ирештерү Фатихка бер дә уңайсыз булмады. Сәбәбенә керешкәч, һәр эш буладыр. Дөрест инде, бер-ике кеше сергә катышмый мөмкин булмады. Ләкин ул кешеләр катышсалар да, сер чыгачак кешеләр түгел иде.

Рәбига бу хатны алгач бик каушады. Бу хатны бер мыскыл итәр өчен язылган дип уйлап, бик ачуы килеп, ертып ташлаячак булды... Күңеле бармады. Бер кабул итәргә дип уйламакчы булды. Янә үз-үзенә ачуланып, һич кабул итәргә ярамый дип уйлады. Хатны кырык кат укыды. Һәр укыганда төрле төсләргә керде: бер кызарып хурланган төскә килде, бер көлемсерәп йөзендә шатлык әсәре беленде. Тиз генә бер якны да ихтыяр итә алмады. Берничә көн йөрде. Күп уйлый торгач, бервакыт хатның күңелдән булуы өскә чыкты. Хәтта берничә кеше хатның алдау икәнен килеп әйтсәләр дә, ышанмаслык бер дәрәҗәгә килде. Күңелдән күңелгә хәбәр бар дигән сүз бөтенләй юк сүз түгел!..

Рәбига Фатих кеби тәүфикълы, гакыллы, күркәм йөзле бер егетнең мондаен матур сүзләрен аңламаслык җүләр түгел иде. Бигрәк тә атасы тупас бер кеше булганга, бер начар урынга китеп, гыйлеменең һәм үзенең вәйран булуыннан куркып, Фатих кеби бер егет насыйп булу беренче

[1] Зәүҗә — ирле хатын.
[2] Хәбиб — сөекле, сөелгән.
[3] Мәсгуданә — бәхетле рәвештә.

теләге иде. Рәбигага Фатих ишетмәгән, күрмәгән дә бер егет түгел иде. Фатихның төсе-кыяфәте, тәүфигы, хәтта бәгъзе сөләгән сүзләренә кадәр Рәбигага мәгълүм иде. Шуңа күрә Фатихның үзенә үк баруны өмет итмәгәнгә, һәркайчан Фатих кеби бер егеткә баруны Ходадан сорый иде.

Рәбига, хатны алгач күп уйлаганнан соң, ахырында бер җавап язу өстенә тиеш булганны аңлап, озын хат язарга оялып: «Хатыңызны кабул иттем»,— дип бер язу җибәрде. Фатих бу «кабул иттем» дигән язуны алганнан соң, янә бер озын хат илән үзенең эчендәге уйларын тагы да яхшылап аңлаткач, бик оялса да, каршы язмый калу ярамаганын белеп, Рәбига шушы озын хатны язды:

**«Гакыллы вә фәһемле егет!**

**Хатыңызны алдым. Әйе, дөрест, үсеп җиткәннән соң егетләргә кызлардан, кызларга егетләрдән күңеленә ошаган бер пар табып, шуның илә рәхәт мәгыйшәт итү ляземдер. Моны беләмен. Парлыкта зур бер сәгадәт булганлыгын да аңлыйм. Мин дә сезнең кеби һәрвакыт муафикъ бер пар насыйп булуын Ходадан теләмәктәмен. Сез муафикъны табып, эстәгәнеңезне алуда ихтыярлысыз. Әмма, үзеңезгә мәгълүм, безнең хатын-кызда теләгәнен сайлау, эстәгәненә бару ихтыяры юктыр.**

**Шуның өчен безгә алдан фараз итеп, муафикъны эзләп кую файдасыздыр. Минем бу көнгә кадәр сайлап муафикъ табып баруга уйлаган һичкемем юктыр. Хатыңыз тугърыдан исә, сез мине сайламышсыз. Бу илтифатыңызга бик мәмнүн булдым[1]. Бик куанып, бердән зәүҗәңез, икенчедән хадимәңез[2] булырга разыймын. Чөнки сезнең кеби егетләрнең хезмәтендә булу үзе бер зур сәгадәттер.**

**Бу хатыңыз күңелдән булса, ни өчен әдәпсезлек булсын?**

**Әгәр без хатын-кыз таифәсенең[3] йомшак күңеле илә уйнау гына булса, бәлки әдәпсезлек кенә дә түгелдер, анысы хакында күңелегездән (вә вөҗданыңыздан) сорап карарсыз.**

*Мәгълүмә...»*

Менә, укучылар! Фатих илә Рәбига арасында дустлык, вәгъдәләр шушы хатлардан соң башланды, аерылмаслык мәхәббәтләр шул көннән урнашты. Араларында хатлар туктамады. Бер-берен күрмәк тә авыр эш түгел иде. Эстәдекләре вакыт күрешерләр иде. Ләкин, күрешсәләр дә, мөгамәләләре бик гафифанә[4] иде. Фатих, гафил егет булганнан, элгәре күрешүдә үк Рәбигадан зәүҗә булырга разый булганын әйттереп, үзе һәм зәүҗ булганын сөйләп, бу вәгъдәләрне сергә катышкан ике егеткә ирештереп, шәргый[5] бер килешү дә ясаганнар иде.

Фатих атасы Халид агай өйләндерә башлавын көтеп йөри иде. Атасы өйләндерә башлап кыз эзләсә, максуды Рәбиганы аласы килгәнне белгертергә иде.

Менә шулай ике яшь күңел тиздән никахлы, бер-беренеке булуларын көтеп йөргәндә Халид агай үзе өчен Рәбигага яучы җибәрмәсенме! Фатих бу эш өчен кайгыру-хафалану тиеш идеме? Түгелме? Әлбәттә, кәефе китми-хәсрәтләнми мөмкин түгел иде. Чөнки Фатих — Рәбиганы, Рәбига Фатихны бик яратып, бөтенләй бер-берен үзләренеке дип белгәннәр иде. Аерылышу күңелләренә килеп тә китми иде. Фатих вак-төяккә исе киткән бер егет түгел иде. Һәр эшкә бер тәдбир[6] тапкан, һәр манигъка[7] күкрәк куйган бер егет иде. Ләкин бу мәсьәлә башка булды. Фатихны бөтенләй

---

[1] Мәмнүн булдым — шат булдым.
[2] Хадимә — хезмәтче кыз-хатын.
[3] Таифә — төркем, җәмагать.
[4] Гафифанә — саф, пак.
[5] Шәргый — шәригатьчә.
[6] Тәдбир — тиешле чара.
[7] Манигъ — киртә, тыю.

каушатты. Бичара Фатих, әткәсеннән Рәбигага яучы киткәнне белгәннән соң, бүлмәләрдә ялгыз калып: «Аһ, Алла! Ни генә эшләмәк кирәк инде? Соң, әткәйгә өйләнү нигә кирәк? Бала-чагасы, яшьтән гомер иткән җәмәгате илә һәйбәт кенә торачак җирдә бөтен йортыбызның рәхәтен, тынычлыгын боза ләбаса! И Ходаем! Карап торырга акыллы гына кеше кеби, ничек бу фигыленең килешмәгәнлеген аңламый!? Яшьтән яхшы тәрбия күрмәгәнгәме бу? Гаҗәп, безнең иске картларның күбесе картлыгында бер яшь кыз алып, тол калдырудан кызык табалар! Инде өйләнә икән, өйләнсеннәр инде, холыкатька[1] каршы килергә адәм баласының куәте юк. Ходай тәгалә аларны шулай хатын-кыз һәвәслесе итеп холык иткәч, адәмдә чара юк. Ләкин алар үзләренең бер һәвәсен бетерү өчен бер кешенең бөтен гомерен вәйран итмәү кирәк иделәр. Үзләре карт булып та яшь кыз аласы килгән кеби, яшь кызлар бигрәк тә яшьрәк кешегә барасы киләчәген уйлау кирәк иде. Ләкин болай өйләнүчеләрнең күбесе бары бер кылангычлык булсын дип кенә өйләнәләр. Үзләренә бер хатын бик җитәдер. Әгәр чыннан ук хатын-кызга артык һәвәсле, фәүкыльгадә[2] хирыс булып холык кылынган булсалар, ике түгел, теләсә өч хатын да алсыннар иде, чөнки күп хатынлы булу һәр вөҗһе[3] илә гайре мәшругъ рәзаләттән[4] алдадыр. Ләкин күп хатын алган кешеләр, үзе карт булса яшь кыз алмаеп, һәрвакыт бер керрә яшь ир күргән, разый булып килгән тол хатын алырга тиешледер. Хасыйле, һәр яшь кеше гомерендә бер яшь илә зәүҗәләнергә тиешледер.

«Һай, әткәй, ничек сиңа бу эшләрне аңлатырга? Бөтен йортыбызның тынычлыгын боза инде, мин һәм Рәбига гомергә үкенечкә калабыз. Йортыбызга Рәбига килеп йөри башласа, мин ничек торырмын? Йа Раббе! Башымны алып китиммени инде? И Ходаем, үзең бер акыл, бер чара бир!

Җаным Рәбига ни уйларда икән? Бичарам!.. Һич булмаса, яшьне алганда да Рәбигадан башка кыз беткәнмени? Ничек шуңа гына каныктылар икән? Мулла котыртты шул, хәзрәт димләде. Ул димләмәсә, бәлки, Хөсәен абзый да бирмәс иде. Гөнаһлы да булып бетәм инде. Ул хәзрәткә өйләнү кебек эшләргә катышу нигә кирәк?» — дигән сүзләрне моңаеп кычкырып йөргәли башлады. Бу эшне туктатырга төрле хәйләләр эзләде, ләкин таба алмады. Ахырында Рәбигага хат язарга исенә төшеп, шушы хатны язды:

**Сөекле Рәбигам!**

**Бу хатым бүтән вакыттагы кеби сөенеч хәбәрләр, матур сүзләр хаты түгелдер. Бу юлы сезгә бик хафалы, бик күңелсез бер мәктүб язамын. Гафу итеңез. Безнең әткәй бу арада, үзе өйләнмәкче булып, хәзрәткә киңәшкән. Хәзрәт әткәйгә сине димләгән. Хәзрәт сиңа яучы да барган, имеш, Хөсәен абзый бирәчәк, имеш. Әнкәеңгә бик яхшылап сөйлә, разый булмаганыңны белгертергә тырыш!**

**Бу эш оят кебек күренсә дә, бер дә оялмаенча, ике арамызда вәгъдә вә танышлык булганын белгертергә тиешсең, юкса эш узар, сөйгәнем!**

**Һәр икемезнең морадымызның булуы шушы көннәрдә синең өстеңә күтәрергә тиеш булган авырлыкларга чыдавыңа бәгълыдыр. Вәссәлам. Мәгълүмең...»**

## V

Ике көн соңра Хөсәен байларга Маһруй яучы яңадан килеп керде. Исәнлек-саулык сорашкач, Латыйфа абыстай илә ике араларында шушы сүзләр йөрде:

---

[1] Холыкать — кешенең үзгәлеге, холкы.
[2] Фәүкыльгадә — гадәттән тыш.
[3] Вәҗһ — матур, гүзәл.
[4] Гайре мәшругъ рәзаләттән — шәригатьчә башка яманлыклардан.

— Ничек, Латыйфа, киңәштеңезме? Картың ни ди?

— Картымнан бер дә тоткар юк. Хәзрәткә дә киңәшеп караган, ул да бик мәслихәт күреп, бирергә димләгән. Аллага тапшырып, тәвәккәлләмәкче буламыз инде.

— Бик яхшы, бик яхшы. Бу урынны инде Хода биргән.

— Шулай инде!.. Атасы разый булды. Юкса, Маһруй абыстай, мин үзем ул кадәр кайнеш, көндәш өстеннән бирүне бик җөпләмәгән идем дә... Бигрәк инде, кызымыз да инсаф белән генә, юаш кына үскән... Аллага тапшырдык инде, насыйбы шулдыр.

— Әй, Латыйфа! Бер дә җәфаланма. Аллага шөкер, барасы җире байлыкның чигендә. Көндәш диергә, Хәлимә илә бергә бер бүлмәдә торасы түгел, каенеш диярлек бөтән әллә кем дә юк инде. Һәдия җитеп килә, кызларның гомере күп түгел, күрмәй дә калырсың, кияүгә дә китеп барыр.

— Инде, Маһруй абыстай, язмышка каршы килер хәл юк. Ходаның үзенә тапшырдык. Зур кешеләр дә димләп торгач, иншалла, хәерле булса кирәк.

— Шулай, Латыйфа, бик дөрест. Кыз баланы вакытында тапшырган яхшы. Кызлар гөл кеби, гөл чәчкәле вакыт кадерле. Алайса, Латыйфа, мин белә-белә барып әйтим. Шушы рәвешчә вәгъдә булсын. Ләкин Халид абзыйның исәбе озакка сузарга түгел бугай. «Мин яшь кеше түгел, миңа бер көн туй да булсын, шул көн кияү дә керергә булсын. Мин эшнең соңга калуын сизмим»,— ди.

— Безнең өчен кайчан булса да бер. Әллә ни хәзерләнәсемез дә юк. Булачак булгач, тиз булса ни, соң булса ни? Безгә бар да бер. Теләсә иртәгә туй итсен, улысында ихтыяр анда.

— Ярый, мин шул сүзләрне барып әйтим. Халид абзый ни әйтер. Туй кайчан булса да, мин соңрак бер әйләнермен. Ярый, хуш, сау булыңыз! — дип чыгып китте.

Бирергә вәгъдә куелганы Рәбигага ишетелде. Рәбига Фатихтан хат алгач та бик җәфаланган иде. Инде бөтенләй, бирергә вәгъдә куелгач, бичара кыз, бөтен кайгылары башына җыелган кеби бер зур җәфага төште. Бу җәфа Рәбиганың гомерендә иң беренче җәфа иде. Рәбига һич бер җәфа күреп үскән кыз түгел иде, аның уналты-унҗиде яшьлек бер гомере бик тыныч кына, бер төсле генә агып киткән иде. Һәр көн бер төсле, ел бер рәвешле булып узган иде. Аларның йортында Рәбига шул яшькә җиткәнгә кадәр бер генә дә зур вакыйга булмагандыр. Кыскасы, Рәбиганың бу уналты-унҗиде еллык гомере һич мәшәкатьсез, гаваилсез[1] кичкән, үсеп кеше булгач та хәтерләрдә саклана, сагыныла торган гомернең кадерле еллары иде.

Рәбига кечкенәдән бик матур иде. Аның кара кашлары, озын чәчләре, нәфис сөякләре, ак нурлы йөзе, тәмле сүзе, ягымлы кылынышлары һәр күргәнне сокландыра иде. Хөсәен агай кеби бер адәмнән бу илә гүзәл бер кыз тууы һичкемнең акылына килмәс. Ләкин ул Хөсәен агайга охшамаеп, анасы Латыйфа абыстайга охшаган иде. Ачыклыгы, шәфкате, мөляемәте, төсләре — һәрбере Латыйфа абыстай холкы иде.

Рәбига җиде яшьләренә җиткәндә остазбикә абыстайга йөри башлады. Күп кеше, сабак өенә йөри башлагач, Рәбига бозылыр, әдәпсезлеккә үгрәнер дип курыкканнар иде.

Остазбикә абыстайлар, күбесенчә, карт булып, балаларын тыя алмаганга, теләсә ни сөйләп, теләсә ни кылынып, сабак өен балаларның шаяруы мәшһүрдер. Һич тәрбия күрмәгән, начарлыкны кечкенәдән күреп үскән әдәпсез кызлар илә яхшы тәрбия илә үскән кәбаир[2] кызларны бер

[1] Гаваил — бәла, борчу.
[2] Кәбаир — олы.

жиргә җыеп, әхлакларын бозыштыру безнең остазбикәләремезнең имтиязларыдыр[1].

Хәер, бу хакта абыстайларда гаеп юк! Алар ничек балаларның ни сөйләшкәннәрен, ни кылынганнарын карап өлгерсеннәр! Алар, шәрик итеп укытуның җаен белмәенчә, һәр баланы аерым-аерым укытканга, илле-алтмыш баланы чирегешәр сәгать кенә укытканда да ун-унбиш сәгать вакыт кирәк буладыр. Остазбикәләр баерак кеше кызларын чирек сәгать кенә дә укытмыйлар, күп көннәр була, фәкыйрь гаилә эчендә үскән кызлар сабак та ала алмаенча калалар. Шуңа күрә сабак өенә йөри башлаганда ни холыкта, ни дәрәҗәдә әдәпле булсалар, берничә еллар сабакка йөргәч тә һаман шул әдәптә булалар. Фәкыйрьлек сәбәпле вак, түбән халык арасында алган начар холык вә әдәпсезлекләре бетмәй, һаман шул көенчә каладыр. Хәер, кайсы кызларның сабакка килә башлаган вакытка караганда башкалардан ишетү, күрү илә әдәпсезлекләре байтак тәрәккъый дә итәдер.

Ләкин, Ходаның рәхмәте, мөлаем Рәбига сабак өендә дә бозылмады. Кечкенә вакыттагы инсаф, әдәп — һәрбере үскәнгә кадәре сакланды. Чөнки Рәбиганың остазбикәсе, кыз балаларны саклау, аларны инсафлы эшләр, әдәпле сүзләргә үгрәтү бик тиеш эш икәнне белгәнгә, үзеннән укыган кызларның тәрбия белән үсүенә кулыннан килгән кадәр тырышадыр иде. Рәбига үзе дә һәрвакыт инсафлы кызлар илән генә катышадыр иде.

Уналты яшьләренә килгәндә Рәбига Маһирә остазбикәнең укыта торган нәрсәләрен тәмам итте. Маһирә остазбикәнең укыта торган нәрсәләрен бик кечкенә дип уйламаңыз! Әлифба «Кисекбаш»тан алып «Ярым Алма» китабы, «Бакырган», «Йосыф», «Йәк хикайәт», «Хәмде Бихөдде», «Тәгълимес-салават», «Сәгълүк», «Мөхәммәдия», «Дәкаикыль-әхбар»га кадәр бара иде. Рәбига укыган нәрсәләрнең һәрберен бик белеп барды. Шулкадәр күңеленә беркетеп укыйдыр иде ки, ел үткәч, укыган гарәби китапларына дөрест мәгънә бирергә әзер иде.

Сез, бәлки, гаҗәпсенерсез: «Сарфы-нәхү укымаган кыз ничек гарәпчәгә дөрест мәгънә бирсен?» — диярсез. Ләкин бу дөрест. Безнең халкымызның хатын-кызлары арасында сарыф-нәхүсез, ишеткәнчә гарәпчә дөрест укырга белгәннәре бик күп очрыйдыр. Бу бер дә гаҗәп түгел. Андаен кызлар артык зиһенле, ифрат куәтле хафизә сәхәбәсе[2] булалар. Әгәр андай кызларга тәртип илә сарыф-нәхү укытылып, кирәге кадәр башка фәннәр дә белдерелсә иде, бик галимә һәм тәрбияле милләт аналары булырлар иде. Әмма тиешле тәрбия, тәртип тәгълим әле безнең ирләремезгә дә мөйәссәр[3] булмаган. Хәлемезгә язык, мең язык!.. Ләкин ни кылырга кирәк? Хода үзе ислях итсен[4]!

Укыган сабаклары арасында Рәбиганың «Мөхәммәдия»дән яратканы булмады. «Мөхәммәдия»гә шулкадәр күңел бирде ки, эшсез булдымы, шөгыльләнгән нәрсәсе, «Мөхәммәдия» уку иде. Бу «Мөхәммәдия» уку Рәбигага гаҗәеп килешә дә иде. Чөнки Рәбиганың тавышы ачык, көмеш кебек шыңгырдавыклы, күңелгә якын бер тавыш иде. Аның «Мөхәммәдия» укыганын бер ишеткән кеше һәрвакыт икенче тыңласы, икенче тыңласа, өченче ишетәсе килә торган иде. Белмим нәрсәдер, Рәбигада кешене үзенә тарта торган бер куәт-җәзбәлек бар иде. Кирәк сөйләсен, кирәк тик торсын — һәрхәлдә, Рәбига күрергә бик кызыгырлык бер кыз иде. Чибәр, шөбһәсез матур кыз иде. Бәгъзе, кеше таныган акыллы хатыннар: «Бу кадәр чибәр кыз, инсафлы бала, кайсы бәхетле егеткә насыйп булыр икән? Моны алган кеше бик бәхетле кеше булыр», — дип сөйлиләр иде. Кара кашлы, озын чәчле, тулы битле булуы өстенә, яхшы киемнәр һәм киенеп, сайрый торган кошларны көнчеләтерлек матур

---

[1] Имтияз — аерма, өстенлек.
[2] Хафизә-сәхәбәсе — «күңелдән ятларга сәләтле» мәгънәсендә.
[3] Мөйәссәр — җиңел, җиңел үтәлешле.
[4] Ислях итсен — үзгәртсен.

тавыш илә «Мөхәммәдия» укыганда йөзенә инсаф нуры таралып, гаҗәеп бер сурәттә була торган иде. Кайчагында оялып, укый торгач эсселәпкызарып, битендә тир бөртекләре чыккач, чык төшкән кызыл алма төсле була иде. Һай, шул вакытта рәсемен алырга!..

Ләкин Хөсәен агай кебек бер адәм йортында моның кеби акыллы, әхлаклы, җәмал иясе бер кыз булуы кем акылына килер?! Әй, бичара Рәбига, кем белер, тагы да яхшы тәгълим күргән булса, бу кадәр кабилияте[1], бу кадәр гүзәл тавышы, көйгә-шигырьгә һәвәсе, уку-гыйлемгә ихласы илән милләтемезнең беренче әдибә, мөхәррирәсе булган булыр иде. Ләкин ни эшләмәк кирәк? Әле болай укып калганына да бик шөкер. Чөнки күп кызларымыз гадәт әсире булып, түгел Рәбига кеби генә, бәлки җөзъәни[2] мәгълүматтан, хәтта язу танымактан да мәхрүм булып, мәңге наданлык эчендә калмакталардыр.

Рәбига шулай үсте. Бар шөгыле уку, йортка бер интизам[3] бирү, җыештырудан гыйбарәт иде. Күңел ачкан эше дә кызлар мәҗлесенә бару илә кайчагында якын кардәшләренең кызларын кунарга чакырып куну иде. Дөрестән дә, Рәбигаларга кунарга кызлар килгән көн бик күңелле була торган иде. «Өч угълы булган карт» хикәясе, «Баласы булмаган падишаһ» хикәясе һәрбере бер кат сөйләнә иде. Аннан кала сүзләре киемнәр, зиннәтләр хакында була иде. Фәләннең энҗе калфагының яхшылыгы, фәлән бай кызының асыл күлмәгенең итәгенә тоткан нәрсәсе, туган кеше кызының камзулы, шәле, беләзек-йөзекләре, брошка, хәтта булавкасына кадәр бер кат сөйләнә иде. Бер күлмәк илә бер-ике җиргә кунакка барган кызларны бик гаеплиләр иде. Рәбиганың иптәш кызлары өсте-башы простойрак, бер күлмәк белән төрле мәҗлесләргә барган кызларны: «Шуны киеп йөрергә оялмый, фәлән»,— дип бөтенләй гаеп үк итә башлыйлар иде.

Ләкин Рәбига акыллы иде, андый кызларга ияреп ярлы кызларны яманламый, кешене киеменә карап үлчәми иде. Дуст кызлары шундый простой киенгән кызларны яманлый, кылынып бизәнмәгән туташларны гаепли башласалар, Рәбига хәзер аларны гаептән туктатып, шундый акыллы сүзләр сөйли торган иде:

— Дуст туташларым! Ник болай, тәрбиясез кызлар кеби, халыктан көләсез? Күлмәк начар материядән булуның нәрсәсе гаеп? Дөньяда һәркем булса кияргә яратадыр. Ул бичара сез әйткән кызлар ярлы кеше балаларыдыр. Чакырган җиргә бармый калмас өчен барын киеп килгәннәрдер. Сез кешенең әдәбенә, инсафына, сүзенә карагыз. Ул сез әйткән простой күлмәкле кызның киеме шулай гына булса да, әдәбе нинди иде?! Ул кызда бездәге шаркылдаулар, бездәге кылынышлар бар идеме? Сез шуны уйлап карагыз! Ул кыз мәҗлестә үзен гүя бер зур абыстай кеби тотты, һәркем илә сөйләшүе ачык, сүзе җайлы, көлүе әдәпле иде. Киемнәренең бик кыйммәтледән булмавы, калфагының энҗе илә капланган булмавы гаеп түгел. Кыйммәтле киемнәр эчендә булып та, холкың, гыйлемең, әдәбең очсыз-тәкәллефсез[4] киемнәр эчендәге кызлардан ким булуы бик оят. Кеше холкына, әдәбенә, гыйлеменә карап үлчәнергә тиешледер,— ди торган иде.

Бәгъзе вакыт кыюырак иптәш кызлары кияүгә бару хакында да сүз чыгаралар иде. Бере берсеннән нинди кияүгә барасы килгәнне сораштыралар иде. Бу кияү хакындагы фикерләре төрлесенең төрлечә иде. Кайсы: «Мин озын мыеклы кияү булса иде дип телим», кайсы: «Мин булган, русчарак киенгән егет булса иде димен», кайсы: «Мин егет сыманрак, тәмәке тарта торган кеше булса иде дип уйлыймын»,— ди торганнар иде. Ләкин бу турыда Рәбига күп сөйләшүне бик яратмый,

[1] Кабилиятле — сәләтле, булдыклы.
[2] Җөзъәни — өлешчә.
[3] Интизам — тәртиплелек.
[4] Тәкәллеф — ясалмалык, кылану.

әдәпсезлек саный иде. Алай булса да, иптәш кызлары һәрбере үз фикерен сөйләп бетергәч ахырдан гына ул да, елмаеп кына шушы сүзләрне сөйли иде:

— А!.. Алайса сез бер дә кияүнең үзен уйламыйсыз икән, кайсыңыз мыегын, кайсыңыз тәмәкесен, кайсыңыз өстендәге киемнәрен уйлыйсыз икән. Мин киемнәрен, мыекларын уйлап та караганым юк. Мин киявем булачак кешенең иң элек акыллы кеше булуын, моның соңында яхшы холыклы, йомшак күңелле булуын, аннан ары галим, тәүфикълы булуын Хода тәгаләдән телимен,— ди иде.

Кыскасы, Рәбиганың бу вакытка кадәрге гомере матур узды. Һәрвакыт күңеле шат, һәрнәрсәдән кызык табучан иде.

Уналты яшьләренә килеп, «Мөхәммәдия»ләрне укый башлагач, Рәбигада бер зур үзгәрү күренде. Рәбига күпвакыт уйлаучан, көйләүчән була башлады. Гүя дөньяда бүтән бер кызык, башка бер юаныч эзли башлаган иде. Һәрвакыт күңеленнән бер нәрсә көткән кеби тоела иде. Бу һәркемдә була торган бер халәттер. Балалыктан чыгып, уеннардан ләззәт тапмый башлагач, һәрбер яшь кешедә бу үзгәрү күреләдер.

Бу хәлнең нидән икәне бик беленмәсә дә, һәрвакыт кеше парланганнан соңра югалып киткәне сыналмыштыр. Рәбига шул хәлдә вакытта Фатих илә мөнәсәбәт башланып китеп, ул уңайсыз эч пошулардан да котылган иде. Фатихка бөтенләй күңел биреп, тиздән никахлы зәүҗә улмакны көтеп тормакта иде.

Менә Халид байдан яучы килүе, аталарының карт булса да бирергә вәгъдә куюлары Рәбигага шундаен бер күңеле парлакъ[1] өметләр эчендә вакытта иреште. Бичара кыз, бу эшкә разый булмаганын анасына белгертеп карады. Әнкәсе үзе дә эченнән бер дә бирергә теләми иде. Ни эшләсеннәр?.. Бу эш Хөсәен агай ихтыярында иде. Аңа никадәр ялынсалар да, кабул итү ихтималы юк иде. Анасына сөйләп тә файда булмагач, бичара кыз, зарын сөйләргә кеше тапмаенча, аулакларда калып үз-үзеннән сөйләнеп йөри иде.

«Ай Алла, шулай ук бәхетсезмени мин?.. Ничә еллардан бирле чын ихласым белән яратып, бөтен күңелем илә сөйгән Фатихыма барып гомер итүләр кая киттеләр?! Уф, Алла, ни генә эшлим? Кемгә генә серемне белгертим?.. Кияүгә бару дигәч, һәрвакыт өйләнмәгән яшь кеше уйлый идем. Бара торгач Фатих илә вәгъдәләр бирешкәч, аны сөя башлагач, аннан башка кешегә бару күңелемә дә килми иде. И Ходаем, ни генә кыйлыйм? Мин ни эшлим? Шулай ук мин Халид абзый хатыны булырмынмы инде? Аның илә ни сөйләшермен? Карт кешегә ни әйтермен? Миңа ни кызык булыр? Йа раббем, язма бу эшне!.. Әй, Халид абзый, сиңа минем кеби яшь кызны елатып ни була инде? Сезнең кеби картларга яшь кыз килеп куанып торыр дип беләсезме? Яшь күңелне бер карт илә канәгатьләндерү мөмкинме? Никадәр яхшы гафифә булса да, алтмыш яшендәге бер картка барган яшь кызның күңеле бер яшь кеше уйлаудан туктамас!.. Мөмкин түгел!

Менә мин Халид абзыйга бардым дип Фатихымны онытырмынмы? Алла сакласын! Картлыкта яшь хатын алучылар бу турыны аңламыйлар микәнни? Хатыннары үзләренә ихласлы булмавына эчләре пошмый микәнни?!

Картлар теләсә ни булсын иде. Бичара яшь кызлар харап була! Гомере эчендә бер хатын күрмәгән бер яшь кешегә барып рәхәт гомер итүдән мәхрүм калалар. Ай, Алла! Мин дә шулар кеби булырмын микәнни?!. И Ходаем, язма бу эшне!»

Ул һәрвакыт шуның кеби кызганыч моңнарын сөйләп, уйлап йөрде. Бирү вәгъдәсе куелгач, күп уйлаганнан, елаганнан соң Фатихка хат язарга исенә төшеп, шушы хатны язды:

---

[1] Парлакъ — якты, нурлы.

**«Җаным, Фатихым!**

**Мөбарәк хатыңны алдым. Бу көн тәмам бирергә вәгъдә куеп җибәрделәр. Безнең әткәйләр, башкалар әткәсе кеби, шәфкатьле, балаларының сәгадәткә ирешүен теләүче түгелләр икән. Һәр икемезнең гомергә рәхәтемезне җуярга сәбәп булалар, ахры. Әнкәйгә разый булмаганымны белгертеп карадым, миһербанлы әнкәем, бичара, үзе дә бер дә бирәсе килми, әткәйгә җалынып карады, күндерү мөмкин булмады. Сөекле Фатихым, шулай ук аерылырмыз микәнни? Һәрвакыт кайчан гына сиңа барып тора башлармын икән дип уйлый идем. Синең кәефең өчен һәр эшкә разый булачак бер яр булмакчы идем. Бәхетсез икәнмен, моңа кадәр генә дөнья мине бәхетле кеби итеп алдап торган икән. Газизем, миндә бер чара да юк инде. Ахыр өметем синдә калды. Сез, шаять, бу эшне туктатырга бер чара табарсыз. Сез дә бер чара тапмасаңыз, хуш, сау бул, сөеклем! Безгә дөньяда рәхәт булмас инде, ахрысы...**

*Мәгълүмәң...»*

Фатихка Рәбиганың бу хаты бик каты тәэсир итте. Бирү вәгъдәсе тәмам булганны белеп, үзенең моңа кадәр һичбер чара уйламаганына эче бик пошты. «Мин бер егет булудан да бу эшкә бер чара тапмый, аңгыраеп калмак бик ояттыр. Бу эшнең зарары бер миңа гына түгел бит, бер бичара кызны гомергә үкенечтә калдырмак һич гакыл эше түгел. Моны һич инсаният күтәрми. Мин моның өчен гөнаһлы булырмын. Ни эшләсәм эшлим, бичарамны бу бәладән коткарыйм»,— дип уйлый иде. Фатих бу уйлардан соң, язу өстәленә утырып, өч хат язды. Өмете шул хатлар илә эшне туктату иде. Ул хатларның берсе Рәбигага иде. Рәбигага язган хат шушы иде:

**«Рәбигам!**

**Хатың тапшырылды. Бирү вәгъдәсен белеп, бик мәхзүн[1] булдым. Ләкин, сөйгәнем, бер дә хафаланма, ничек булса да мин бу эшне бетерергә тырышачакмын. Хатыңдагы «Хуш, сау бул, безгә моннан ары дөньяда рәхәт булмас», дигән сүзеңнән бик шикләндем. Алай-болай эш булыр дип белеп бер-бер эш кыйла күрмә. Мин ничек булса да бу эшне булдырмамын. Әгәр дә минем уйлаган чарам булмый калып, кияү керә башласа, ишекне бикләп сакланырсың. Эш ул дәрәҗәгә җитсә, мин дә синең ярдәмеңә җитешермен. Кияү керә башлаганчы мин уйлаган эш булмаса, үзем барып җитеп, ничек булса да сине котылдырырмын. Фатих».**

Калган ике хатның берсе Хөсәен абзыйга иде. Берсе кемгә икәне мәгълүм түгел иде.

## VI

Рәбиганы Халидка бирү вәгъдәсенең икенче көне иде...

Бу көн кешегә фаш итмәй генә Рәбигага никах булып, кичкә кияү керәсе булганга, Хөсәен байлар йорты эчендә шау-шу, өстән карагайда гүя шатлык иде. Бичара Рәбига бер бүлмәгә яшерелде, моңа да сәбәп акыллы яучы булды. Ул: «Мондаен вакытта котыртучылар күп була, кыз янына кеше кертергә ярамый»,— дип, Рәбиганы һичкемгә күрсәтмәде.

Рәбига бичараның ялгыз бер бүлмәдә елаудан башка шөгыле юк иде. Кәрә-чыга йөреп рәхимле Латыйфа абыстай кызының бу хәлен игътибарга алды. Рәбиганың ятып елаганнарын күреп, яучыга:

[1] Мәхзүн — кайгылы, көенечле.

— Ай-һай, Маһруй абыстай, бу эш хәерле булыр микән? Кыз бик җылый бит! — дигәч:

— Яшь кызга җыламый китү үзе килешми, Латыйфа, мин бик күп туйлар, никахлар күрдем. Инсафлы кыз җыламый китмәс. Картка бирү илдә юк эш түгел. Бичара, Ташкент сартларына[1] кыз бирәләр әле. Телен белмәгән, гадәтен үгрәнмәгән бер пычрак сарт белән гомер итәләр. Халид сарт түгел әле, картлыгы да чамасыз түгел. Үкенерлек эш юк, Латыйфа, җыласа җылар. Хәзер җыласа, кияүгә баргач көләр. Безнең әнкәй: «Кияү керәсе көн җылау киләчәктәге мәхәббәт галәмәте»,— дип әйтә торган иде. Бер дә борчылма, иншалла, хәерле булыр,— дип, оста яучы Латыйфаны тиз туктатты.

Кияү керергә берничә сәгатьтән ары калмагандыр, ыгы-зыгы эчендә Фатихның Хөсәен абзыйга язган хаты Латыйфа абыстай кулына иреште. Соңга калган калуын да... һәр ни исә, Латыйфа абыстай Хөсәенне бер бүлмәгә чакырып, кемнән килгәнне сөйләп, хатны Хөсәенгә бирде. Хөсәен хатны озак таный алмый тора торган иде. Шуның өчен Латыйфа абыстайга укырга кушты. Хатта болай язылган иде:

**«Хөрмәтле Хөсәен абзый, миһербанлы Латыйфа абыстай!**

**Гафу итегез, кызыгыз Рәбига илә елдан артык мөнәсәбәтебез булып, арамызда бер-беребезнеке булырга вәгъдәләремез дә бардыр...»**

Хатны шул җирдә өзеп, Латыйфа абыстай:

— Сиңа әйтәм, харап булдык!

Хөсәен: — Ни тилерәсең?!

Латыйфа: — Аңламыйсыңмы юкса? Рәбиганы харап иткәнмез!

Хөсәен: — Күп сөйләшмә, бетерденме укып?

Латыйфа (укый): —

**«Бер кешенең вәгъдә вә гакыдлы сөйгәне ул кешенең әткәсенә шәригатемездән дөрес түгелдер, ягъни Рәбига минем зәүҗәм булганга, әткәйгә аслан дөрест булмыйдыр. Шуның өчен тиздән әткәйгә бу тугърыны белгертеңез! Юкса кызыгызны харап итеп, өстенә гөнаһлы һәм буласыз.**

***Фатих Алтынбаев».***

Хөсәен: — Аһ, оятсыз, шыпырт кына эченнән тынып калмастан, оялмыйча хат яза тагы, мена җүнсез!

Латыйфа: — Яхшылап аңла, ник аны гаеплисең? Рәбига әткәйгә хәрам дигән ләбаса. Аны ник яшереп калсын? Хәрам була торып бирер идеңме?

Хөсәен: — Ни эшләп хәрам булсын? Юк сүз, юк!.. Аһ, оятсыз! Мин сине, атаң үземезнеке булып бетсә, ничек өйрәтергә белермен!..

Латыйфа: — Сиңайтәм, ник ачуланасың? Яратышканнарына ышанмыйсыңмы?

Хөсәен: — Яратышсалар — бер оят, оялмаенча ул эшне белгертү — икенче оят!.. Мена намуссыз!

Латыйфа (елап): — Ничек бер дә беленмәгән соң? Шул Фатихны угълым кеби күреп ярата идем. Насыйп кына булмаган икән! Никах булды шул инде... Ай, газиз балам! Шундаен матур бер егеткә барырга уйлап йөргәндә без сине җәберләдекмени? Сиңайтәм, зинһар, әле кияү кермәгән, эшемез халыкка да фаш булмаган, хат җибәреп, Халид агайга белгертсәк ничек булыр икән?

Хөсәен: — Мена сүз!.. Җылама да, җылавыңны кызганмыйм да... Син баштан ук бу эшкә кире килеп бардың, бетсен! Әйтмә миңа шул сүзне! Бер малай сүзенә карап, Халид агайга кыз бирүдән каласы, имеш?!

Латыйфа: — Атасы ник шулкадәр...

Хөсәен: — Сөйләмә! Бетсен!

Хөсәен агай сүзне бик кыска тотты.

---

[1] Сарт — үзбәк

Кияүнең килер сәгатьләре житте. Капка төбенә көтәргә кешеләр һәм куелды.

Рәбиганы көчләп киендереп, кияү керәсе бүлмәгә яптылар...

Менә бервакыт: «Кияү килде!» — дигән хәбәр булды... Ләкин кияү көтүчеләр чалмасыз карт көтәләр иде, килгән карт чалмалы, төсе дә Халид агайга охшамый, кем белә, бәлки кияү булгач үзгәргәндер...

Кызның ишегеи ачмакчы булдылар — бикле булды. Дөбердәттеләр, файдасыз чыкты. Килгән карт кыз бүлмәсен сорамый, Хөсәен агайның үзен сорый башлады.

Ахырында беленде ки, килгән кеше кияү түгел, хәзрәт, имеш. Караңгылык белән ялгышканнар, имеш. Хөсәен чыкты.

Хөсәеннең чыгуына янә бер карт чабып килеп керде, монысы инде чыннан да кияү иде. Сачен ап-ак итеп китәрткән, мыегын җеп кеби итеп ике яклап нечкәрткән, камчат бүркен кыеклап башка алган, киң җакалары чыккан, бу — Халид агай иде.

Хөсәен, хәзрәт, Халид агай ишек алдында бергә җыелдылар.

Хәзрәт Хөсәен агайга карап:

«Халидка, кияү булып кергәнче, әйтәсе сүзем бар. Безне бер аулак җиргә алып керсәнә!» — диде.

Бүлмәгә керделәр. Ишек бикләнде.

Хәзрәт:

— Халид, Хөсәен, син дә тыңлап тор, мин сезгә бер нәрсә укыймын,— дип, кесәсеннән бер язу чыгарып, укый башлады. Шулай язылган иде:

**«Фазыйләтле[1] остазым! Сезнең кеби адәмләргә хат язмак ни дәрәҗә әдәпсезлек идекен белсәм дә, язачак мәсьәләм бик мөһим (кирәкле) булганга, сөкүт итеп[2] калу мөмкин булмады. Бу хатны язмасам, берничә кеше гомергә вәйран булачак вә берничә кеше гөнаһлы булачакка күрә, мөнәсәбәтсезлек булса да, язарга җәсарәт[3] иттем. Гафу боерыңыз. Бу көннәрдә җәнабеңезнең димләве буенча әткәмез алачак кыз Рәбига минем гакыдлы[4] зәүҗәмдер. Бер адәмнең зәүҗәсен башкага бирергә һичкемнең ихтыяры юктыр. Шәригатемездә кызның ризасы иң бөек шарт булып та, никах вакытында аталар тарафыннан кыздан ник соралмый икән? Алма кеби яшь кызларны дөньяда бер кат торып бетергән картларга җәберләп бирергә шәригатемез куша микән? Остазым, бу мәсьәлә күптән каралып, хәл ителеп бетәргә тиеш иде. Ничә вә ничә кызлар маймүн кеби картларга китеп дөньяда гаилә сәгадәте, зәүҗ мәхәббәте дигән нәрсәләрнең ни икәнен дә белмәенчә калдылар.**

**Бичара Рәбиганы да, әткәйнең дәүләтенә кызыгып, Хөсәен агай вәйран итмәк эсти, имеш. Үтенәмен, остазым, бу хатны алгач та, бу эшне ничек булса да бетерергә тырышсаңыз ла? Хөсәен абзый да, әткәем дә синең сүзеңнән чыкмаслар иде. Эстәсәңез зәүҗәм улдыгын исбатка, гакыдымызда булган шаһитләремез дә әзердер. Рәбига минем зәүҗәм булгач, әткәйгә һич дөрес булмаска тиештер. Сез шәригатьне миннән игъләмсыз.**

***Фатих бине Халид Алтынбаев».***

Фатихның без белмәгән өченче хаты шушы булды. Хәзрәт, хатны укып бетергәч, Халид илә Хөсәенгә карап:

— Аңладыгызмы, Халид агай, бу угълың Фатихның хаты! Эш ачык беленсен дип, бу хатны үзеңезгә укуны мәслихәт күрдем. Хөсәен агай кызы Рәбига илә ике араларында мәхәббәт булган булса кирәк...

---

[1] Фазыйләт — өстен, хөрмәтле.
[2] Сөкүт итү — дәшми тору.
[3] Җәсарәт — җөрьәт, батырчылык.
[4] Гакыдлы — килешүле.

Хөсәен: — Хәзрәт, юк ул...

Хәзрәт: — Тукта, мин сөйләп бетергәнче көт! Фатих Рәбиганы зәүҗәм, ул минеке дигән, ике арамызда иҗабе кабул[1] — гакыд булды, шаһитләремез һәм бар, дигән. Алай булса, Рәбига Фатихның шәригый зәүҗәсе, ягъни хәләл җәмәгате буладыр. Халид агайга аслан[2] дөрест булмыйдыр. Менә «Мохтасарел-викайәдә» гыйбарәсе шушы рәвешчә: «Вә хәрәмә гәләлмәръа аслиһи, фәрәгаһә вә фәрәга аслиһил-кариб вә салибәти аслиһил-багыйд, үмму зәүҗәтиһи вә бинтүһа мәутуәт вә зәүҗәти аслиһи вә фәрәгаһә». Безгә кирәклесе шул ахырдагы «вә зәүҗәти аслиһи фәрәгаһә» дигән сүз, ягъни атасының, бабасының зәүҗәсе, ягъни хатыны, никадәр югары китсә дә, угылының һәм угылының угылларының зәүҗәсе, ягъни хатыны никадәр түбән китсә дә, ир кешегә никахланырга дөрест булмыйдыр, дигән сүз буладыр. Хуш, инде килеп, Фатих Халидның угылы булгач, аның фәргасе буладыр. Рәбига Фатихның хатыны булгач, Халид агайга Рәбига «зәүҗәте фәрфәргиһи», ягъни угылының хатыны буладыр да, аслан дөрест булмыйдыр. Аңладыңызмы? Менә сезгә ачык мәсьәләсен әйтеп бирдем.

Халид, башын түбән иеп, бик күңелсезләнеп: «Ай, Алла! Һа, һа!» — дип тик утырды.

Хөсәен:

— Хәзрәт, юк сүз ул, юк сүз! Мин үз кызымны үзем беләмен... Нинди шаһит булсын да, нинди гакыд булсын? Бар да ялган! Минем кызымда андый эш юк, хәзрәт, шул малай сүзенә карап эшне боза күрмәсәнә инде! — диде.

Хәзрәт:

— Юк, Хөсәен, бу эш булган булырга тиеш. Мин кызыңызны да бик егълый дип ишеттем. Гакыдлары, шаһитләре, бәлки, юктыр да, алай булса да, кыз илә егетнең күрешкән, ултырашкан булуында шик юк. Күрешкән булгач, Халидка башка яктан да хәрам буладыр. Эшне хурлыкка калдыруда файда юк. «Кирәк булса, шаһитләрне дә табармын», — дигән. Ләкин алай хасиятсезләнүдә мәгънә юк.

Бу сүзләрне ишеткәч, Хөсәен агай ишекне ныклабрак ябып, хәзрәткә актык сүз итеп:

— Хәзрәт, булган эш булсын инде. Сәдакасыннан эш калмас. Шәригать үз кулыңда, зинһар, бер җаен тапсаңыз ла! — дип карады.

Хәзрәт:

— Ай, Хөсәен! Син наданлыкка барасың! Ярамагач ярамый инде. Синең әз-мәз сәдакаң илә кеше шәригать алмаштырамы соң?

Халид:

— Юк инде, Хөсәен, бу эш булмады. Бу эш минем хурлыкка каласыма гына булган эш икән!

Хәзрәт:

— Инде әле әллә ни булмаган. Әле яхшы, килеп өлгердем, гөнаһ шомлыгы! Остазбикә, эш бозылмасын дип, хатны бирми торган. Сез шулай итегез инде: әле бу мәсьәлә халык арасына чыкмагандыр. Бу эш тиздән, яшертен булган эш. Никах мәҗлесенездә ят кеше юк иде. Мин хәзер Халидтан кызны аерыйм. Фатихның зәүҗәсе булган булса, никах вакыйгъдә[3] булмаган буладыр. Алай булса да аерыйк. Иртәгә йә берсекөнгәме яхшылап туй ясап Рәбиганы Фатихка никахлыйк. Халык эшнең ничек булганын сизми дә калыр.

Халид:

— Хәзрәт, мин ни әйтергә дә белмим.

Хөсәен: — Бу эш булмый торган булгач, бик яхшы булыр иде. Кыз баланы барыбер тапшырасы, Халид абзый, шулай итиклә алайса?

---

[1] Иҗабе кабул — ярәшү, ризалык.
[2] Аслан — һич, һичбер.
[3] Вакыйгъдә — чынлыкта.

Хәзрәт: — Халид, син белмәгәч, кем белер? Угылыңны өйләндерү өстеңә фарыз. Өйләндер, өйләндер! Шушы Рәбиганы — сөйгәнен алып бир! Бу эш өчен бер дә ачуланма. Бу яшьлек бәласе. Менә, Хөсәен, тиз-тиздән киңәшеңез дә, төгәлләңез. Бу көе калсаңыз, халыкка бигрәк көлке булырсыз. Фатихка алып бирсәңез, халык бүгенге йөрүләрне иҗабе кабул мәҗлесе дип кенә белер дә калыр. Менә мин аерыйм да китим, Халид, сез дә кайтыңыз, бүгенгә йоклап карыйк әле, иртәгә тагы күрешермез.

Шушы эшләрдән соң Рәбиганы Халидтан аергач, кияү булып килгән Халид агай, кияүне кертмәскә килгән хәзрәт һәр икесе кайтып киттеләр. Хәтәрсез, хәвефсез бичара Рәбига котылды.

## VII

Хәзрәтнең һәр ике якны димләве, нәсихәтләп йөрүе аркасында шул атна эчендә бик зур туй ясалып, Рәбига Фатихка никахланды. Халид агай никадәр разый буласы килмәсә дә, язмышка каршы килә алмады. Ниһаять, ике, адәм кулы тимәгән яшь чәчәк кеби пакь балалар бер-беренә кавыштылар, морадларына ирештеләр. Зөфаф кичәсендәге шатлыклар, куаныч вә сөенечләргә чик юк иде. Һәр икесе Ходага ни рәвешчә шөкер итә белүдә гаҗиз иделәр. Рәбиганың, эш ахыр чиккә җитеп тә, Фатихның тәдбир табып эшне бетерүенә гаҗәпсенеп, куанып Фатихка әйткән тәшәккерләр, рәхмәтләр, бүсәләр[1] чиксез иде. Фатихтан ахыр хат килгәч ни дәрәҗә куанганын, ишекне бикләп, Ходадан ничек булса да бу бәладән котылырга сораганын, ишек аркылы Халид киткәнен анасыннан тәгаен сорап белми ишекне ачмаганнарын — һәрберен Рәбига Фатихка сөйләде. Куаныштылар, сөенештеләр... Гомер буена бик сәдакатьле[2],бик мәхәббәтле зәүҗ вә зәүҗә булачакларына мең төрле вәгъдәләр куештылар.

Зөфаф кичләре кичте. Фатих һәр көн зәүҗәи мәхбүбәсе[3] янына йөри иде, араларындагы мәхәббәт рабиты[4] көннән-көн артмакта иде. Угълына яхшы, инсафлы кыз булуыннан — Хәлимә абыстай, кызының Фатих кеби бер гакыллы егеткә китүенә Латыйфа абыстай һәрбере бик шат иделәр. Инде Хөсәен абзый да бу эштән бик мәмнүн иде. Халид агай карт кеше булып, берничә еллардан барча малы Һәдия илә Фатихка калачакны, ниндәен бай бер кияве булачагын уйлап, Фатих яшьрәк тә булганга, Халидтән да артыграк файда итү мөмкин булганнарын аңлап, бик шатланган иде.

Рәбига илә Фатихның парлануыннан куанмаган бары Халид агай иде. Сакал-мыек төзәтеп, бүрекләрен кыңгыр итеп кияү булып барып та, кыз янына керә алмаенча кайтуына хурланганы күңеленнән китмәгән иде. Чөнки, никадәр халыкка фаш булмады дисәң дә, Рәбиганы башта Халид ала башлап та, соңра Фатихка туй ясалганын белгән кешеләр дә бар иде.

Фатих кыз катына һәр көн йөрмәктә иде. Фатихның киенеп китүләре, шатланып кайтулары һәрбере Халид агайга үзен мәсхәрә итү өчен, аның ачуы килсен өчен йөргән кеби күренә иде. Шуның өчен Халид агай угылына һич сәбәпсез көннән-көн дошманламакта иде.

Халид агай яшь хатын ала башлаганчы ачучан, борчулы кеше түгел иде. Әмма шул өйләнә башлаганнан соң холкы бөтенләй бозылды. Бар эше ачуланып-сукранып йөрү була башлады. Хезмәтчеләрен һич гаепсез ачулану, йорт җәмәгатьләрен һич сәбәпсез орышу-тиргәү гадәте булып китте. Йорт эчендә бигрәк ачуланган кешесе Фатих иде. Ул бичараны

[1] Бүсә — үбешү, үбү.
[2] Сәдакатьле — дус, тугърылыклы.
[3] Мәхбүбә — сөелгән, яратылган хатын.
[4] Рабиты — бәйләнеше.

шулкадәр тыгыз тота башлады ки, хәтта гәзитә карарга да рөхсәт бетте. Китап укыганын күрсә, буран чыгара иде.

Бичара Фатих бу кадәр ачуга, дошман тотуга һич сәбәп таба алмый иде. Күп уйлагач, яшь вакытта әткәсенә яхшы тәрбия күрсәтмәгәне өчен бабасына бик үпкәли иде. Акрынлап бичара Фатихка үз атасының йорты нурсыз күренеп, ихтыярсыз үзе торган йортта торасы килми башлаган иде. Чөнки Халид абзыйның борчуы чиксез иде. Бәла өстенә бәла!

Бер көн Халид агай, Фатихны ачуланып-ачуланып сәүдә дәфтәрләрен тикшереп утырганда, почтальон сурәтле бер журнал («Нива») китереп ташламасынмы?! Фатих шулвакыт, һич гаебе булмаса, билләһи, җиргә керергә разый булыр иде. Халид агайга эчендә сакладыгы ачуны, дошманлыкны чыгарырга җай чыкты. Гәзитә вә журнал алуны ул кадәр зарарлы бер эш дип белмәгән почтальон нахактан шулкадәр сүгелди ки, яхшы әле тиз генә чыгып котылды, юкса берничә йодрык та күтәрәчәк иде. Халид агай, бик ачуланып хәтта кулларын күтәреп:

— Зачем такуй газет ташчиш? Муя сын ни урыс бит, такуй патрит руским ташчи! — дип, русның артыннан кычкырып калды.

Бу йортка гәзитә кертүеннән шулкадәр эшләр чыгасы хәтеренә дә килмәгән рус чыгып котылганына куангандыр... Бәлки, моннан ары картрак мөселман булган йортка гәзитә кертергә шикләнгәндер дә.

Рус котылды, әмма Фатих бичара бик авыр бер хәлдә иде. Эшләгән гаепне, кабахәтне инкяр итмәк, танымак мөмкин түгел иде. Берничә көннәр әүвәл сурәтле «Нива» журналын аласы килеп сигез сум җибәрүе хак иде. Халид агай бу эш өчен угылы Фатихны эстәдеке кадәр сүкте, теләгәне кадәр гарьләде. Хурландыра торган сүзләрнең һичбере калмады. Кәефне җибәреп, күңелдән китми торган ямьсез сүзләр бар да әйтелде. Читтән тыңлаган кешеләр бу кадәр сүгү, бу дәрәҗә орышуны һичбер гыйлем арттырмак өчен гәзитә алганга дип белмәс иде. Ачулангандагы сүзләре гүя фәхешханәләрдә берничә мең сумнар исраф иткән угылын сүгә торган сүзләр иде.

Һай, бичара Фатих!.. Әле ярый юанычы — сөекле Рәбигасы бар иде, юкса бичарага дөнья бигрәк кәефсез булыр иде. Халид агайның бу орышуы гәзитә өчен булса да, асыл ачуның сәбәбе Фатихның өйләнүе, Рәбиганы алуы иде. Гәзитә ачуын алырга бер бәһанә[1] генә иде.

Халид агайның күптәннән эчендә тоткан дошманлыгының гәзитә мәсьәләсеннән соң үче чыкты. Гәзитә вакыйгасыннан бер көн соңра өстендәге киемнәре илә генә Фатихка ата йортыннан чыгарга әмер булды. Туган йортта торырга рөхсәт бетте. Хәлимә абыстайның ялынуы да файда бирмәде. Затән[2], Халид агайның хәзердәге могамәләсе Хәлимә абыстай илән дә бик суык иде. Халид агай мәгълүм вакыйгадан соң бөтенләй үзгәргән иде. Сүзендә, кыланышында, хәтта йөзендә дә бер үзгәлек күренә иде.

Фатих, бичара, кесәсендә булган берничә сумнар илә торган йорттан чыгып китте. Гаять авыр бер көннәр күрде... Шулай да түзде. Үзен-үзе харап итмәде.

Аның кеби егетлек падишаһысы, яшьлек үрнәге бер егет харап булырмы? Һич!..

Фатихның әткәсе йортыннан чыгып берничә көн торгач, иң беренче шөгыле әнкәсе Хәлимә абыстайга бабасыннан калган йортта торырга банкыда анасы исемендәге акчаны алып эш йөртү булды. Хәлимә абыстайның әткәсеннән калган йорты илә Халид суммасына кушылудан калган алты мең сум акчасы үз исеменнән чыкмаганнар иде. Бу малларда Халид агайның дәхеле[3] улмаеп, һәрбере Хәлимә абыстай ихтыярында

[1] Бәһанә — сылтау.
[2] Затән — нигездә.
[3] Дәхеле — катнашуы.

иде. Фатих кулына керү өчен аның угылына бирергә разый булуы житә иде.

Фатих әнкәсенә бу җайларны аңлаткач, Хәлимә абыстай газиз угылын эшсез, акчасыз урамда калдырып вәйран итәсе килмәде: Фатихның ничек булса да бер кеше булып эш кыла башлавын тели иде. Угылының эшсез калып бозылып китмәк ихтималыннан курка иде. Бу турыда, хатын булса да, фәһеме Халид агайдан артыграк иде. Шуңа күрә, ире Халид ачуланачагыннан да курыкмаенча, йортның һәм акчаның угылына булуына куанып разый булды. Бу кадәр акча угылы кулына калып, кызы Һәдиянең малсыз калу хәвефе юк иде. Чөнки Һәдиягә Халидтан калачак мал да житәрлек иде. Бер көн Фатих, берничә еллар Хәлимә абыстайның сандыгында кузгалмый яткан йортның һәм акчаның сәнәдләрен[1] алып, анасы илә нотариус һәм банкыга барып йортны һәм алты мең акчаны Фатих исеменә күчерттеләр.

Булганлыгы аркасында Фатих һәрберен рәтләде. Эстәгәнен булдырды. Тиешле урыннарга заявлениеләр биреп, ун-унбиш көн үткәнче алты мең сум акчаны кулына алып, анасы йортына кереп тора да башлады.

Фатих анасы йортына кереп, алдыгы акча илә үзенә күрә эш кыла башлагач та, һаман һәр көн кич Рәбига янына бара иде. Үз хәленнән үзе бик мәмнүн иде. Атасы йортыннан чыкканга кайгыру кайда, бәлки сөенә иде. Чөнки өйләнгәннән соң булган әткәсенең ямьсез мөгамәләләре, күңелсез кылынышлары, бертуктаусыз каһәрләүләре бичараны туйдырган иде.

Хәлид агай Фатихның болай үзалдына эш кыла башлавына бик эче пошты. Бердән, угылының газапланып йөреп-йөреп, яңадан керергә ялынмавына, икенчедән, Фатих чыкканнан соң сәүдә эшләренең тәртибе бозылганга бик кайгырды. Хәлимә абыстайга: «Фатихны димлә, килеп ялынсын, кертермен»,— дисә дә, файда юк иде. Чөнки Хәлимә абыстай, угылы кайтып керәм дисә дә, кермәскә димләячәк иде. Угылының моңа кадәр орыш астында чыдап торганын да бик кызгана иде. Йортта Фатих булмаганнан соң Халид агайның ачуын ала торган кешесе Хәлимә абыстай булып калды. Аның йорты белән акчаны киңәшми угылына биргәненә бик ачулана иде. Һәрбер начар эшне Хәлимәдән күргән кеби, һәрбере өчен аны ачулана иде. Фатихның килеп керергә ялынмавын, керәсе килмәвен — һәрберен Хәлимәдән дип уйлап, аның өчен дә аны шелтәли иде. Чөнки Хәлимә абыстайның Фатихка барып йөрүенә дә эче поша, көнли иде.

Бервакыт Хәлимә абыстайга Фатихка барып йөрергә дә рөхсәт бетте. Рәхимле ана газиз баласына бармый, аның хәлен белми ничек түзсен? Көннәрдә бер көн Хәлимә, угылын бик күрәсе килеп, хәлен сораштырасы килеп, Халид өйдә юкта, Фатихка барган иде... Рөхсәт булмый торып баруына Хәлимә абыстай ахырдан үкенде, әмма эш үтте... Халид агай ерткыч хайван кеби булып Хәлимәгә ачуланды, тиргәде, хәтта гомердә булмаган эш — берничә йодрык та әләкте. Һай, бичара, Халид абзый бозылды! Ачуы илә белештермәй: «Тагы да Фатихка барасы булсаң, миннән талак»,— дип ычкындыра куйды. Бу «талак» дигән сүзе Хәлимә абыстайга бик авыр булыр дип уйлаган иде.

Кайда ул, бу сүз Хәлимә абыстайга авыр тоелу, хәтта «талак» дигән сүзне ишеткәч, шатланган кеби булды. Чөнки карт көнендә яшьтән сөйгән иреннән бу кадәр хурлаулар күрергә түземе калмаган иде. Иртәгесен, Халид өйдә юк бер вакытта, Хәлимә абыстай угылы Фатихка күчмәсенме?!!

Халид агай бер секундта белештермәй үзеннән ычкындырган бу сүзнең ахыры нигә барганны белеп үкенде. Никах яңартачак булды. Әмма Хәлимә абыстай күнмәде. Хәзрәт димләп карады, файда булмады. Чөн-

[1] Сәнәд — документ.

ки Хәлимә абыстай, яңадан килсә дә, Халидның иске борчулары, сәбәпсез каһәрләүләре туктамаячагын белә иде. Халид агай да, Хәлиманең риза булмаганын белгәч, бик ялынасы килмәде.

Шул көннән башлап кырык елдан артык җәмәгать илә торып үгрәнгән Халид абзыйга ялгыз көн итәргә туры килде. Карт бер адәмгә зур йорт эчендә җәмәгатьсез көн итү ансат бер эш түгел. Бичара Халид агайның бу хәле кызганыч иде. Ике хатын илә кылынып, иркәләнеп гомер итәргә фарыз кыйлып йөргәндә бер хатыннан да мәхрүм калмак, хәтта угылыннан да язмак бик авыр тоелды. Халид абзый баштарак сер бирмәскә тырышып йөрде. Никадәр хәле читен булса да, угылына кайтып керергә әмер итмәде. Җәмәгатенә яңадан никах илә килүне яхшылап әйттермәде.

Ничә вакытлар шулай кичте. Никадәр сиздермәскә тырышса да, бу ялгызлыктан Халид агайның эче бик поша, җаны борчыла иде. Һәрвакыт уйлаучан, сызгыручан булып киткән иде. Өйләнергә йөргән вакытка караганда бик күп ябыккан да иде. Берничә вакытлардан соң акыллы Фатих, әткәсенең хәле авыр булачагын белеп, газиз әткәсен кызганып, үзе һич кайтып керәсе килмәсә дә, үзен йортка кертергә үтенеп, анасын яңадан алырга димләп, әнкәсен күндерергә вәгъдә куеп, озын бер хат язып карады. Халид агай күнмәде.

Кеше бер нәрсәгә ачуы килеп, яки үпкәләп, холкы бозылдымы, кечкенә генә үч алмак, яки ачуы килгән адәмне үкендермәк өчен үзенә тау кадәр зарарлар кылә торган эшләрне эшләп ташлый да, үзенең кылганына һич үкенмидер. Халид агайның да эченнән, хәленә чыдый алмаенча, угылына кайтып керергә, җәмәгатенә никахланырга үтенергә уйлап йөргән вакытта, йомшак күңелле угылының атасына үтенергә урын калдырмый язган үтенүләрен кабул итмәенчә киреләнүе бу кабилдәндер[1].

Халид агай, Фатихтан хат алгач, бераз кәефләнеп китеп: «Менә шулай ялынырсың, алай көн итеп булмыйммыни-фәлән»,— дип йөрде. Бу хатны кабул итмәгәч, Фатих янә үтенеп язар дип уйлаган иде. Фатих кешенең фикерен каян белсен, ул бер кәррә хат язып өстеннән бурычны төшергән иде. Әткәйнең кертү ихтималы юк икән дип, өметен кисеп, анасы илә бик рәхәт көн итүләрендә дәвам иттеләр.

Фатихтан яңа үтенүләр булмагач, иске мәгыйшәтләр кайту өмете бөтенләй бетеп, Халид агайның хәле бигрәк авырлашкан иде. Халид агай ялгыз ашар, ялгыз эчәр, ялгыз кунар иде. Чөнки кызы Һәдия дә әнкәсе белән бергә киткән иде. Аның кайтып торуына никадәр тырышса да, мөмкин булмады. Кыз бала атадан бигрәк ананы якын күрүчән булуы һәркемгә мәгълүм. Анасыннан аерылып Һәдиянең дә киләсе килмәде.

Халид бигрәк тә ашаган-эчкән чакларда уйга китеп, моңаеп, ялгызлыктан җаны борчыла иде. Ашый-эчә торган бүлмәдә күкеле сәгатьнең тавышы, искедән Халид агайның яратып алган мысыр күгәрченнәренең гөрләүләре — һәрбере Халид агайга: «Ай, мескен Халид, кая китте синең элеккеге тормышларың? Кадерен белмәдең! Инде сиңа бу байлык ни файда бирә?» — дигән кеби тоела иде. Бигрәк тә пар, матур тавышлы күгәрченнәрнең матур гөрләүләре: «Гакылсыз карт, мәхәббәтле хатыныңны ташлап өйләнмәкче булдың? Бер күңелдә ике мәхәббәт җыймак мөмкинме? Үзең адәм булып та, шуны аңламадыңмы? Син бездән гыйбрәт алу кирәк иде. Ничә еллар без бергә гөрелдәшеп яшимез, гөрелдәгән саен мәхәббәтебез арта, бер-беремез күңелемезгә утырадыр, шатлыгымыз бергә, кайгымыз бергә. Бер-беребезгә мәхәббәтсез саясендә[2] хәбестәге[3] күңелсез мәгыйшәтемезнең үткәнен дә тоймый каламыз. Без өчәү булса идек, бу рәхәт мәгыйшәтемез булмас иде. Өченчемез ата күгәрчен булса — аналар арасында, ана күгәрчен булса — аталар арасында, шиксез, бер низагъ чыгар иде. Бу рәхәт-тынычлык бозылыр иде. Рәхәт,

[1] Кабил — төр, төркем.
[2] Саясендә — нигезендә, юлында.
[3] Хәбес — тоткынлык.

тыныч мәгыйшәт — пар яшәмәктәдер. Без, кечкенә хайванчыклар, моны беләмез. Һәрвакыт икәү яшимез, син, зур хайван булып та, моны белмәденме? Әй, адәм! Син, һич булмаса, әтәч илә тавыктан гыйбрәт алу кирәк иде. Тавыклар илә әтәч арасында безнең арадагы кеби мәхәббәт, берлек бармы? Юк, юк! Мәхәббәт-рәхәт пар мәгыйшәттәдер!» — дигән кеби ишетелә иде. Кайсы бүлмәгә керсә — анда бушлык, кая барса — анда тынлык, ирексез, картның күңелен йомшартып, хафасын зурайта иде. Хыялый адәм кеби, кинәттән куркучан, уйчан була башлады. Искедәге җәмәгате Хәлимә абыстай, угылы-кызы һәрбере бергә иткән мәгыйшәтләр, куанышып-сөйләшеп эчкән чәйләр Халид агайга төшендә генә күргән кеби уйлана иде. Ул вакытлар хәтеренә төшеп, бик сагына иде. Күбесенчә елый да иде.

Әмма ул вакытлар кичмеш иде. Халид агай күп сөйләшми башлады. Намазга барганда-кайтканда бик моңаеп кына йөри иде. Әүвәлге кеби хатын-кызга карап ваксынып йөрүләр беткән иде. Хәлимә абыстай бар чакта намазга барганда чалмаларын биреп, кайтканда салдырып алган вакытлары исенә төшкәч, юк булып китә иде.

Хәлимә бикә аерылып, байтак вакытлар үткәч, Корбан гаете тугъры килеп, бу көн кадәр Халид абзыйга авыр тоелган көн булмаган иде. Гаеттән кайткач, өйдә асраулардан башка кеше булмагач, башка гаетләрдәге гаеттән чыгуга, хатыны көтеп, шатланышып-куанышып эчкән чәйләр исенә төшеп, үткән рәхәт гомеренең һәр елларын берәм-берәм, һәр көннәрен адым-адым искә төшереп, бүтән кешеләрнең намаздан чыгып шатланып утырганнарын уйлап, җаны борчылганга чыдый алмаенча, бик каты елады. Ярый әле, өметсезләрнең, бәхетсезләрнең ахыр юанычлары — рәхимле күз яше бар! Бара торгач ялгызлыклар, үкенүләр Халид агайны акылга китерде. Үзенең бу хәлен, бу күңелсезлекнең нидән килгәнен уйлап, сәбәбен эзли башлады. «Ай, Алла, мин ник картлыгымда бу кадәр хафага калдым? Атам-анамны да рәнҗеткән кеби түгел идем, сәдака-хәерсез дә тормаган кеби идем! Бу ни булды миңа! Минем бу кадәр үкенечкә калуыма сәбәп ни икән? Әлхәмде лиллаһи, байлыгым да бар, рәхәте юк ләбаса! Ай, кадерен белмәгән икәнмен! Дөньяның рәхәте балаң-чагаң, яшьтән алган яшь мәхәббәт, багъланган җәмәгатең илән тату тору, аларны рәнҗетмәенчә гомер итүдә икән! Бу байлык илә мин ни эшлим инде? Һай, байлыгым кимрәк булсын иде дә, хәзер дә җәмәгатьләрем илә торсам иде. Бу кадәр малны җыйдым, инде миңа монда ни файда булыр? Тәмсезләнмәенчә, ахыр гомеремә кадәр үз угылымны үземдә тотып, малымны аның кулына тапшырып үлсәм, җаным рәхәт булыр иде. Бар да бар, малым угылыма кала, ләкин күңеллелек белән булмый. Уйлап карасаң, угылымның артык гаебе дә юк. Ни өчен мин үз баламны үзем хур итеп куып чыгардым?! Кеше балалары ашап-эчеп тә йөриләр. Әлхәмде лиллаһи, угылымда андый эшләр юк иде. Ни өчен чыгардым мин аны?! Угылымны үзем чыгарып җибәреп тә, аның өчен ник Хәлимәгә ачуландым? Аны ник аердым? Ай, Алла, миңа ни булды?..»

«...Бу бер-ике еллар эчендә мин ниләр кылдым? Ник бу эшләрне эшләдем? Уф, Алла! Бозылдым мин, бозылдым. Әллә ни булды миңа!.. Мин ник үкенәм? Бу үкенечкә сәбәп ни булды? Җәмәгатем Хәлимә илә рәхәт гомер итүләр ник бетте? Ай, яшь вакытларым! Ул вакыт исемә төшкән саен хәзерге хәлем читен күренәдер. Хәлимәгә кыз катына кергән көннәрем нинди кызыклы иде. Хәлимә бигрәк матур бер кыз иде! Ике арамызда бик куәтле бер мәхәббәт багъланмыш иде. Мин Хәлимәгә мәхәббәтем булып, бик яраткач, гомеремдә синнән башка хатын күрмәсәм иде, дип теләгән идем. Син сәламәт булганда гомеремдә өстеңнән һичбер вакыт хатын алмам дип вәгъдәләр биргән идем. Бер-беремезне шулкадәр ярата идек, болай ташлашулар күңелгә дә килми иде. Бу мәхәббәт, бу вәгъдәләр кайчан бозылды соң? Боларны кем бозды? Үзем боздым мин! Шулкадәр кызыклы яшь вакыттагы вәгъдәләрне мин оныт-

тым. Мин Хәлимәне ташлап, яшь хатын ала башладым. Вәгъдәмә хилафлык кыйлдым. Менә болай үкенечкә калуыма сәбәп шул. Шуның өчен Хода мине үкенеч җәзасы белән җәзалый икән. Гаеплемен. Рәхәт вакытларның кадерен белмәдем, йорт рәхәтен чуалттым, иске вәгъдәләрне боздым. Җәзага тиешлемен, җәзага!..»

Халид агай шундаен уйлар илән кыйлган эшләренә үкенеп, бик еш елый да иде. Бу кадәр үкенгәннән соң, бәлки, янадан Хәлимә абыстайны алып, рәхәт көн иткән дә булыр иде. Дөньяда булган рәхәт-сәгадәтнең кадерен вакытында бик белергә кирәк. Дөньяда бер кителгән эш икенче төзәлгәне бик сирәк. Халид агай, Хәлимәне ничек итсә итеп янадан алырга уйлап йөргәндә бик каты авыру эләгеп китеп, түшәккә егылды. Һай, дөнья! Ник син бу кадәр ышанычсыз?!

Әткәсенең авыруын ишеткәч, Фатих әткәсенә һәркөн икешәр килә торган иде. Һәдия бер дә әткәсе яныннан китмәде. Халид агайның авыруы көннән-көн катылашты. Әткәсе яхшы ук авырый башлагач, Фатих та әткәсе яныннан рәтләп китми ук башлады. Ике баласы әткәләренең хезмәтенә әзер иделәр. Фатих берничә докторлар да китереп карады. Файда күренмәде, һәрбер өмет булмавын сөйләделәр. Фатихның эчкерсез булуына, тугырап хезмәт итәргә торуына Халид абзыйның күнеле бик йомшап, угылына кочаклап-кочаклап догалар әйтә иде.

Авыруының унберенче көне хәле бигрәк авыр кеби булды. Иртә торгач та Халид агай угылын чакырып, елап:

— Угылым! Хәлем бик авыр, ахры, бу авырудан терелеп гомер итүләр булмас инде. Үлсәм үләрмен. Ходай тәгалә иман илә үтәргә насыйп итсен. Ләкин бер эшкә бик эчем поша, күңелем кырыладыр: әнкәң хәзер дә миннән аерылган көе торадыр. Бу эшкә минем бик эчем поша, күңелем борчыладыр. Акылым китеп, өстеннән өйләнергә йөрсәм дә, һичбер вакыт әнкәңезгә мәхәббәтем беткәне юк. Башыма киләчәк хафа булганга җилкенгәнмен. Хәлимәдә яшь мәхәббәтем бетәсе юк, кыяматкә дә үзем илә барачак. Хода насыйп итеп, җәннәткә кергәч тә Хәлимә илә бергә булуны телимен. Ләкин, угылым, никахымда калмагач, Хәлимә минем илә булмас дип бик куркамын. Дөньяда күп торасым калмады, аның илә бәхилләшеп үтәр идем, кыяматтә дә бергә булыр идек. Әйтеп карасана, угылым, янадан никахланырга күнмәс микән! — диде.

Фатих, бу сүзләрдән соң күңеле бик йомшап, яшь тулган күзләре илә әнкәсенә барып сөйләде. Хәлимә абыстай күнмәү, разый булмау кайда, хәтта бу сүзләрне ишеткәч йомшап, эченнән куанып, елап, разый булганын сөйләде. Никадәр җан бизгән кеби булса да, яшь мәхәббәт күңелдән китмәгән иде. Тол калса да, Халид агай никахында калуын калебе эсти иде.

Хәлимә абыстай тиздән Халид йортына килде. Тиз генә хәзрәт килеп никахларын яңартып китте. Бичара, үлем түшәгендәге Халид агай илә Хәлимә абыстай бәхилләштеләр, елаштылар. Халид агай васыятьләрен әйтте, хәленең авырлыгын сизеп, җәмәгате, бала-чагасына карап шушы сүзләрне сөйләде:

— Вафатым сәгатьләре якынайды. Күңелем шулай сизәдер. Үлсәм үләрмен, һич күңелсезләнмим. Аллага шөкер, бик матур гомер иттем. Алтмыш елдан артык бер гомер — бик озын бер гомердер. Бу яшьтә пәйгамбәрләр, башка изге адәмнәр үләләр. Ходага шөкер, гомеремне фәкыйрьлек илән дә үткәрмәдем. Яшь вакытымда да, әлхәмде лиллаһи, һич үкенерлек эшем юк, исерткеч, мутлык кеби нәрсәләрне белмәдем. Ходага шөкер, тәүфигым камил булды. Тырыша торгач, зур дәүләткә дә ирештем. Дәүләтем илә кулымнан килгән кадәр хәер эшләр кылдым. Бик бәхетле адәм икәнмен. Хода миңа мәхәббәтле җәмәгать бирде, зур дәүләт бирде. Дәүләтем булып та, бала-чагам булмай дип хафаланган идем. Ахырга таба Хода тәгалә бала да бирде. Мең шөкер! Дөньяны күрдем, тордым, тойдым. Ничек шөкер итә белүдән гаҗизмен. Инде

миңа Ходай тәгалә хәерле үлем насыйп итсен. Бу рәвешчә җәмәгатең, бала-чагаң кулыннан, мөселман тәрбиясе эченнән үтү олугъ бәхеттер. Мөселман адәмгә ислам динендә җаны рәхәт көенчә үлүдән артык сөенеч юктыр. Сөекле җәмәгатем Хәлимә! Разый бул, мин синнән мең кәррә бәхил. Дәүләтеңне, хезмәтеңне, үзеңне — һичберен син миннән кызганмадың. Мин сиңа бу яхшылыкларны кайтара алмадым. Нанкүрлек[1] иттем. Яхшылыкларыңны онытып, хәтта сине ташлый да башладым. Гафу ит, хата миндә булды. Ул рәвешчә хатын-кызга артык һәвәс бер азгынлык кына икәнен синнән аерылып торган көннәремдә белдем. Мин, үлгәндә никахымда калмый, җәннәттә бергә булмыйбыз дип, бик хафаланган идем. Әлхәмде лиллаһи, инде күңелемдә ул борчу да калмады. Хуш, сау бул, бәхил бул, мин разый, бәхил: җәннәттә бергә булсак иде. Мине доганнан онытма. Бу ике бала — әүвәл Ходага, соңра сиңа аманәт. Һәрвакыт балаларыңны яхшылыкка димлә, бу — синең бурычыңдыр.

Угылым, миннән сиңа бик зур дога. Синнән бик разыймын, бу мал өчеңезгә исә дә, саклау, күбәйтү — синең эшеңдер. Тәүфикъта бул. Дәүләтеңне арттырырга тырыш, дәүләтеңнән, бердән, үзең файдалан, икенчедән, бөтен мөселман файдалансын: хәер-ихсанлы[2] бул. Рәхәт булырсың, тәүфигыңда бул, мохтаҗлык күрмәссең. Тәүфикълы бул, шәфкатьле бул, ярдәмле бул, тәвазыгълы[3] бул, юмарт бул, яхшы бул, диндар бул, хуш, угылым, сиңа дога шушы.

Кызым, сиңа да бик күп дога. Күркәм холыклы, тәвазыгълы, акыллы бул. Сиңа беренче васыятем — гыйффәтле булудыр. Хатын-кызга гыйффәттән кадерле нәрсә юктыр. Гыйффәтле кыз — дөнья зиннәте, гыйффәтсез кыз дөнья бәһаседер. Гыйффәтеңне җаныңнан артык сакла. Кызым, «пычак ярасы төзәлер, намус карасы төзәлмәс», хуш, кызым, дога сиңа.

Халид шул рәвешчә һәрберенә васыятьләр әйтеп, бәхилләште.

Менә бервакыт акрынлап кич булды. Төн җитте. Бу төн Халид абзыйның авыруының уникенче төне, дүшәнбегә каршы төн иде. Ул төнлә һичбере йокламадылар. Хәлимә абыстай вә ике баласы һәрбере аталарының баш очында газиз аталарының актык сүзләрен тыңлап утырдылар. Халид агай таң ата башлаганчы телдән язмады. Таң ата башлаганда Халид абзыйның хәле начарланган иде. Халид абзый, үз хәлен сизеп, җәмәгатен, балаларын — һәрберен берәм-берәм кочаклап елады. Һәрберсенең күзе яшь илән тулган иде. Халид абзыйның шушы кочаклаудан соң теле нәсихәт сөйләүдән тукталы, кәлимәи шәһадәт[4] кенә әйтә башлады. Әткәсенең бу хәлен күргәч, Фатих, тәһарәт алып, елый-елый Ясин сүрәсен укырга башлады. Һәдия елап, Хәлимә абыстай да елый-елый иренең колагына яхшы сүзләр әйтеп тора иде.

Таң атты. Иртәнге намазга азан әйткән вакытта Халид абзый матур гына фани дөньядан китте. Алла рәхмәт әйләсен!

## Хатимә[5]

Халид абзыйның вафатыннан соң, Фатих әнкәләре илә бергә атасы йортына күчеп тора башлады. Баштарак уңгайсыз булса да, акрынлап аталары үлгән хафага да өйрәнделәр. Хәлимә абыстай, намаз арты саен Халид абзыйга дога кылып, җәннәттә бергә булуларын Ходадан сорый иде. Фатих әткәсе мәрхүм кабере өстенә бик матурлап чардуган (чәһардивар) кордырып, аның эченә агачлар утыртып, бер һәйбәт таш һәм яздырып куйды. Халид агай мәрхүмнең яшел рәшәткә илә

[1] Нанкүр — яхшылык кадерен белмәүче.
[2] Ихсан — ярдәм, изгелек.
[3] Тәвазыгълы — тыйнак, түбәнчелек.
[4] Кәлимәи шәһадәт — үлем сүзләре.
[5] Хатимә — ахыр сүз, эпилог.

чорналган кабер өсте яшәреп торган агачлары, катыйфә[1] кеби үләннәре илә бик моңлы бер рәвештә булган иде. Фатих әткәсенең бу мәркадән[2] һәр җомга зыярәт итә иде. Ходадан сораган догалары шул әткәсе кабере өстендә була иде. Чөнки зыяратның моңлы рәвеше, бигрәк тә атасының каберенең яшәреп, мөкаддәсләнеп торуы хисле Фатихның күңелен бик йомшатканга, догасы да шунда мәкъбүл булыр кеби буладыр иде.

Әткәсе үлгәнгә алты ай тулганда Фатих Рәбиганы йортына китерде. Моңа кадәр барып кына йөри иде. Хәлимә абыстай угылы илә килененең бер-берсен сөеп, үзенә дә тәгаззымле[3] булуларыннан бик куана иде. Балаларының яхшылыгына куанып ире булмаган хафаны да тоймый иде. Фатих сатуларны җайга салып җибәрде. Әткәсе фатихасында һәр эше алда иде. Фатихның дәүләте яхшы, эше юлында булып, үзе һәр хәлендә бик шат булганга, йорт җәмәгатьләренең рәхәте, сәгадәте өчен дә җаны-тәне илә тырыша иде. Мөмкин кадәр сораган нәрсәләрен китерергә, эстәгән нәрсәләрен алып бирергә иҗтиһад итә иде. Рәхимле абзыйсы аркасында Һәдия дә бик шат иде. Бигрәк тә Фатих илә Рәбиганың көннәре рәхәт иде. Мәхәббәт вә дустлыклары ниһаятьсез иде. Бер-берен күргән саен күрәсе, сөйләшкән саен сөйләшәселәре килә иде. Һич бер-береннән туя алмыйлар иде. Көннән-көн мәхәббәтләре артмакта, яратышулары үсмәктә иде. Гомерендә һич башка кеше күрмәй үскән ике чәчәк үзләренең сабыр, гыйффәт вә истикамәтләренең[4] файда вә нәтиҗәсен тапканнар иде. Рәбига килгәннән соң Фатих, зәүҗәсеннән остазбикәсеннән өйрәнгән гыйлеме илә генә канәгатьләнми, һәрвакыт төрле нәрсәләр укыта иде. Рәбига дин, игътикад мәсьәләләрен бер дәрәҗә белсә дә, динемезнең башлану, исламның ничек зоһур булуын[5], пәйгамбәремез Мөхәммәд (салиуллаһы галәйһиссәлам)нең сиярәтен[6], исламдагы бүтән зур кешеләрнең тарихын, ничек дөньяда торганнарын бер дә белми иде. Шуның өчен Фатих зәүҗәсенә бик яхшылап ислам тарихын, исламда булган адәмнәрнең ничек булганнарын, динемезгә, өммәтемезгә ниндәй файдалар китергәннәрен һәрберен өйрәтте.

Рәбига сөекле зәүҗенең гәзитә укыган кыяфәтен бик яратса да, гәзитә ни икәнне бик үк белми иде. Фатих зәүҗәсенә күп сүзләр сөйләп, сораган бер сүзләренә, бүтән ирләр кеби: «Сезгә ни эшкә ул, хатын-кызга?» — димәенчә, бик озын-озын бәяннар илә җавап биреп, көннән-көн Рәбиганың гыйлемен арттыра, фикерен киңәйтә иде. Гафифә кыз зәүҗенең бундаен йомшак мөгамәләләрен күреп көннән-көн шатлана, көннән-көн иренә мәхәббәте арта иде. Фатих Рәбиганың укырга өйрәнеп китүенә бик тырыша иде, һәрвакыт яңа чыккан файдалы китапларны алып китерә иде.

Рәбига бәхетеннән, кирәкле китаплар, фикер ача торган рисаләләр, аз булса да, һәрвакыт чыккалап тора иде. Фатихның Рәбигага китергән китаплары һәрвакыт мәгыйшәтемезгә катышлы, тәрбия вә әхлак өйрәнергә файдалы, хатын-кызга тиешле вазифаларны, ана булачак яшь ханымнарга кирәкле әдәпләрне өйрәткән китаплар буладыр иде. Рәбига бу китапларны бик һәвәс илә укый, белмәгән сүзләр очраса, Фатихтан сорый иде. Фатих бу сорауларга ачуланмый, бик куанып җавап бирә иде. Рәбиганың аналык вазифа вә әдәпләренә өйрәнүенә бер остаз кеби улып, җаны-тәне илә тырыша иде. Фатихның һәрвакыт укытуы, һәрдаим төрле нәрсәләр сөйләве аркасында, берничә вакытлардан соң Рәбига бик тәрбияле ханым булып киткән иде. Башта Казан төркичәсенчә язылган китапларның да кайсын аңлый алмаган, гәзитә кеби нәрсәләр ни икәнен

---

[1] Катыйфә — хәтфә.
[2] Мәркад — кабер.
[3] Тәгаззымле — олылаучы.
[4] Истикамәт — тугърылык.
[5] Зоһур булу — килеп чыгу.
[6] Сиярәт — көнкүреш, әхлакый сыйфатлар.

белмәгән Рәбига, бара торгач, Истанбул әдәбиятын аңларлык бер дәрәҗәгә килеп, зәүҗе Фатих искедән яратып укыган Истанбул гәзитенең килеп җитүен бер зур интизар илә көтеп алып, килеп җитсә, бик зур ихлас илә укый иде. Укыган китапларында гыйбрәтле кыйссаларны, файдалы хикәяләрне Рәбига үзеннән кечкенә кешеләргә бик матурлап сөйли иде. Рәбига, китаплар, гәзитәләр укуны бик яраткан кеби, үзенә тиешле булган хезмәтләрне дә бик яхшы үтәп, каенанасына, иренә — хасыйле, бөтен йорт җәмәгатьләренә яраклы, аларның рәхәтенә тырышкан бик тәрбияле бер йорт анасы булып киткән иде.

Кыскасы, Рәбиганың күңеле шат, хәле рәхәт, җаны бик тыныч иде.

Фатихның эшләре дә бик алда иде. Дәүләте һаман арта иде. Дәүләтенең күплегеннән Фатих, бердән, үзе рәхәтләнә, йорт җәмәгатьләрен шатландыра, икенчедән, милләтенең кирәкле җирләренә сарыф итеп, халкымызны файдаландыра иде. Эшләре алда булып, зәүҗәсеннән дә уңганга, Фатих бик шат иде. Бунлар һәр икесе, хәкыйкатен, бик бәхтияр вә мәсгуд[1] иделәр. Ходай тәгалә бара торгач бу ике мәхәббәткә бер матур угылан багышлады. Фатихның искедән яраткан бер исеме бар иде. Угылы булса, Рашид кушмак уенда иде. Вакыйган[2], уйлаган исемен куйды. Фатих илә Рәбига кеби ата-анадан туган өчен генә дә кечек Рашид[3] бик бәхетле бер бала булды. Чөнки Рашиднең киләчәге яхшы булмак өчен бер атасының галим, фикерле булуы гына да җитмәс иде. Рашиднең кечкенәдән тәрбияле булып, әдәпле эшләр күреп, яхшы сүзләр ишетеп, киләчәктә бер зур адәм булмагы өчен Фатихтан бигрәк Рәбиганың галим, тәрбияле булуы бик шарт иде. Фатих угылы Рашидне бик тәрбия илә үстереп, бик укыттырачак иде. Угылының бик тәрбия илә, ислам рухы илә үсеп, галим, диндар, хәмиятле[4], милли бер кеше булып, милләткә, дингә теле, фигыле вә малы илә файда итәрлек бер адәм булуын Ходадан тели иде. Аның теләге моннан гыйбарәт иде: «Йа Рабби, угылым дәүләтле, диндар, хәмиятле, холыклы, галим бер адәм булып, халкымызга, өммәтемезгә[5] файдалар китереп, милләтемезнең тәрәкъкыенә тырышып дөньяда бик исем калдырачак, ахирәттә сәваплы булачак бер адәм булса иде».

Амин!

*Бетте.*

[1] Бәхтияр, мәсгуд — бәхетле.
[2] Вакыйган — чыннан да.
[3] Рашид — «туры юлда йөрүче, зиһенле, батыр-кыю» дигән мәгънәне аңлата
[4] Хәмиятле — кешелекле, яклаучан.
[5] Өммәт — милләт, мөселман динендәге кеше.

# ШИГЪРИЯТ



## Илдус Гыйләҗев

### Кем икәнем торсын күренеп

Дустым әйтә: — Урыс түгеллегең
Сөйләшкәндә бик тиз беленә:
Басымнарны бутый... көрмәкләнә —
Татарлыгың чыга телеңә.
Белем сай булганнан түгел лә ул,
Үртәлгән юк андый нәрсәгә.
Кай милләттән синең булганлыгың
Балкып тору — үзе мәртәбә!
Үз халкымча тормыш итә белсәм,
Гел аныңча булса гамәлем —
Сөенеп бетә алмас идем әле
Ялгыш узмады дип гомерем...
Бер теләгем калыр дөньялыкта,
Ятканда да җирдә күмелеп:
Ай бизәгән агач утыртыгыз,
Кем икәнем торсын күренеп!
...Татарлыгым торсын күренеп...

### Ай-һай...

Сатыйк диләр җирне, ваклыйк диләр,
Кем акылы моңа җиткәндер?
Сүле качкан илдә мөгаен дә
Сатып баер әйбер беткәндер..
Туфракны соң кеше ясаганмы?

---

Илдус **ГЫЙЛӘҖЕВ** (1946) — *шагыйрь, «Җир китабы», «Җилкену» һ. б. китаплар авторы. Азнакайда яши.*

Кемнәр аны әйбер итмәкче?
Җир йөзендә без бит кунак кына
Мәңгелеккә күчеп киткәнче.
Шуның өчен газизебез-Җирне
Туган анабызга тиңләдек!
Актарсак та, сөреп елатсак та,
Бәяләмә куеп көлмәдек.
Без Әнине сатып өйрәнмәгән...
Ул сәүдәгә булмас күнегеп.
...Ничек ятмак кирәк сатлык җирнең
Үги туфрагына күмелеп...

## Эш кирәк шул

Мөстәкыйльлек сагыз түгел,
Чәйнәп кенә үзләнмәс.
Сүздән ботка ясап яшәп,
Дөнья артык үзгәрмәс.
Буш йодрык селтәүләрнең
Тапмыйм бер дә кызыгын:
Азатлыгым ныгысын дип,
Бармы каккан казыгың?

## Бар да элеккечә

Майламаган күчәр кебек
Шыгырдый заман.
Сулар һава авырайды
Сагыштан, зардан.
Дегете бар үзебездә,
Буясы гына...
Тик Мәскәүдә утыра шул
Хуҗасы менә.
Аннан рөхсәт сорау кирәк,
Акса да муллык.
Шушы була инде, туган,
Бүгенге коллык...

* * *

Һәрбер кеше — аерым бер дәүләт кебек,
Эчке эше була, тышкылары.
Тышкысына түзә, мәгәр кичерми ул
Эчке эшләренә тыкшынганны.

* * *

«Маймылны кеше итүче —
Хезмәт» — диеп язалар.

Киресенчә түгел микән?
Уйлыйк әле, агайлар...

## Шундый чагым

Ыргытыгыз дулкыннарга,
Карышмыйм, агып китәм.
Ак күбекләр арасында
Хәл җыеп булмас микән.
Томырыгыз болытларга,
Күкләрне иңләп килим.
Соңгы юлым шул якларга...
Сәбәбен күреп белим.
Юк, юк, берүк кагылмагыз,
Җиремдә чабыйм гына.
...Артык авыр уй күтәреп
Җиңеләйгән чагым гына...

* * *

Ята миндә яшеренеп
Бу дөньяга үпкә.
Үземнән дә сорамыйча,
Кемдер сырлар уя биткә.
Мыек чыга, чәч коела,
Үсә, кими буең.
Нәрсә соң бу? Кем башлаган
Аңлап булмый торган уен?
Үз тәнеңә үзең хуҗа
Була алма, имеш.
Мин дә китеп барыйм мени
Берни аңламаган килеш?..
Түрдән, күңел почмагыннан
Ул-билгесез дәшә:
— Сәбәпләрен белсәң, энем,
Кызык булмас иде яшәү...

* * *

Асты-өскә килер җирнең,
Күкләр төшәр ишелеп.
Тик барыбер бозыклыктан
Арынмас бу кешелек.
Җиргә аяк басуы ук
Башланган ич гөнаһтан.
Төзәлергә өмет булса,
Куалармы оҗмахтан...

## Хак вә нахак

Минем сине күрүем
Хак.
Һуштан язып йөрүем
Хак.
Озатырга килүем
Хак.
Тупса атлап керүем
Хак.
Назларыңнан җебедем,
Хак.
Изрәп төштем, җиңелдем —
Хак!
...Бер айнырсың әле, дисең,
Монсы — нахак!

## Шагыйрь кайчан бәхетле була?

Мәшһүр шагыйрь Тукай булган,
Батыр шагыйрь Җәлил булган;
Моңлы шагыйрь Туфан булган,
Хисчән шагыйрь Хәким булган.
Моңлылар да, батырлар да
Булыр әле киләчәктә.
Бәхетлесе табылмас тик
Халкы тоткын, мәхбүс чакта.
...Сүзем, татар, синең хакта...

* * *

Тукыма юкта — озын, мул вакытта —
Кыска була кызлар итәге.
Урман кимесә — үрчи гүрничә,
Күп чакта, өй — тавык кетәге.
Бик астыртын кемдер көлә бездән,
Көн эсседә җитми күләгә...
Күз гайрәте кими барган саен,
Матур кызлар илдә күбәя...



Соңгы елларда без тормышта да, шигъриятта дә әллә кайларга кереп киттек, шактый ук буталып беттек. Татар кешесе өчен мең еллар буена гаять кадерле булып килгән шигърият тә бүгенге иҗтимагый тормышыбызда бер ятим хәлендәрәк калды. Язылган шигырьләребездә дә йә тупаслык, йә примитивлык өскәрәк чыга башлады. Ә бит татар шигыре традицион рәвештә сафлык, чисталык, нәфислек, мәхәббәттәге иң-иң садәлек, тирән һәм югары фәлсәфә белән татар укучысының күңел түренә үтә торган иде. Чү, соңгы елларда шушы асыл традицияне югалта, кулдан ычкындыра башладык түгелме? Болай уйлавы, шуны тоюы ямьсез, хәтта куркыныч та.

Флера Тарх球ованың яңа шигырьләрен укыгач, күңелдән әнә шул шик, шул ямьсез уйлар таралып китте, «Юк, әле татар күңелендә лирика дарысы юкка чыкмаган икән», дигән тынычлану туды, икенче яктан, Тархановaның бу шигырьләре күңелдә якты сагыш та уята. Мәхәббәт шигырьләре алар, әмма чын мәхәббәтнең сагышы да күп шул аның. Әнә шул якты сагышны шигырьдә чагылдыра, үз сагышың белән укучыны да сагышландыра алуың — шагыйрьлек шулдыр инде, күрәсең.

Флера Тархановaның укучыга тәкъдим итеlә торган бу шигырьләре әнә шул турыда сөйли.

Гәрәй РӘХИМ,
Татарстан Республикасының
Г. Тукай исемендәге
Дәүләт премиясе лауреаты.

# Флера Тарханова

## Хушлашу

Күзләреңнең алыйм очкыннарын,
Йөрәгеңнең кайнар утларын.
Туйганчы бер эчеп калыйм әле
Иреңеңнең дымлы сутларын.

Башларымны куеп калыймчы бер
Миңа бишек булган җилкәңә.
Исерткәнче безне тибрәткән моң
Сеңеп калсын иде. Иртәгә,

Шушы моңны эчтән көйли-көйли,
Иреннәрең тигән эзләрне
Кабат барлармын мин уйларымда —
Тик йөрәгем моңа түзәрме?

## Әйләнермен әле

Килеп кердем синең тормышыңа,
Рөхсәт сорамыйча-нитмичә.
Дөресрәге, үзең юл күрсәттең —
Мөмкин түгел карап китмичә.

Ул юлларда — синең сөю тулы
Җаның белән бергә йөрдем мин.
Зәңгәр дулкыннарында тирбәлеп,
Төпсез диңгезеңдә йөздем мин.

Моңсу карашыңның назын тойдым,
Сагышыңны күрдем йөзеңдә...
Язмыш бирми барлык кешегә дә
Бу бәхетне гомер көзендә.

Уйлый идем: дөрләп янган учак
Синдә инде күптән сүнгән дип.
Ялгышканмын икән: син һаман да
Сөю-сәгадәттә икән бит.

Илһамланып инде кайтып барам
Туры юлдан, кире китмичә.
Бәлки тагын әйләнермен әле,
Рөхсәт сорамыйча-нитмичә.

## Нигә?

Нигә миңа мондый яшәү:
Җанда өмет калмагач,
Икәү кабызган учактан
Бергә җылы алмагач?

Нигә кирәк мондый яшәү:
Мине синсез тилмерткәч,
Йөрәгемдә чиксез сагыш,
Бетмәс сагыну йөрткәч?

Юк, шулай да яшим әле —
Син барны тоеп, бәгърем:
Газаплы бөек бер ләззәт
Биргәндер миңа Тәңрем.

* * *

Мангайдан аккан ачы тир
Тубыкка житсә, тоз була,
Колактан кергән авыр сүз
Йөрәккә житсә, боз була.

*«Идегәй» дастаныннан.*

Ачы яшь йөрәккә житсә,
Тоз да була, боз да була —
Тозы яраны төзәтсә,
Бозы җанны суындыра.

Синең белән киткән юлда
Адашып, югалып калсам,
Ачы яшь каплар күземне,
Табыныр кыйбламны алсаң.

Тозлы яшь йөрәккә житсә,
Төзәтер, бәлки, ярасын,
Тик белеп тор: йөрәгемнең —
«Син» дип типкән йөрәгемнең
Тораташ булып каласын.

* * *

Йөзләреңдә чиксез сагыш эзе,
Күзләреңдә — мөлдерәмә яшь,
Үпкә катыш сагыну сүзләреңнән
Әрнү саркый. Күңел өзелгәч,

Тулып ашкан күлләр чайпалдылар,
Бормаланып кайнап актылар,
Шул ташкыннар мине, бөтереп алып,
Утлы дәрьяларга аттылар.

Бер баттым мин анда, бер калыктым,
Котым очып чумдым дулкынга...
Күзең сузган нурга тотынып чыктым —
Төшермәдең барыбер упкынга.

## Сагыну шулдыр инде

Песи кебек иркәләнеп,
Сыенып куеныңа,
Чәчем дулкынына күмеп,
Сарылып муеныңа,
Пышылдыйсым килә сиңа
Иң татлы сүзләремне,
Үбәсем килә, иркәләп,
Сагышлы күзләреңне.
Чәчләреңнән борма-борма
Юллар саласым килә,

Шул юлларда сине генә
Күтәп аласым килә...
«Ишек ачык, кер шакымый,
Газизем»,— диярмен дә,
Син керүгә, бигем салып,
Назлармын, сөярмен дә,
«Мәңгегә миндә кал»,— дип,
Чыгармам сине кире...
Сагынуың нинди, дисең —
Сагыну шулдыр инде.

## Гайбәтләрдән өстен булып калыйк әле...

Кара эчле кайберәүнең гайбәтеннән
Үзебезне өстен итеп саныйк әле.
Сөя алмый интеккәннәр сокланырлык
Аерылмас ярлар булып калыйк әле.

Зәһәреннән зәңгәрләнгән кайберәүләр
Зур ләззәтне татый алмый калсын әле,
Явызлыктан салкынайган йөрәкләре
Туңа-туңа бозлар булып катсын әле.

Кара эчле, боз йөрәкле кайберләрнең
Гайбәтеннән өстен булып калыйк әле,
Мәхәббәтне изге диеп белгәннәрнең
Күңеленә бәлзәм булып тамыйк әле.

## Әйдә әле...

Әйдә әле, бер әйләнеп кайтыйк
Кичке урамнарны, икәүләп.
Өебез тулы чиксез якты хисләр
Ятмасыннар әле биләүдә.

Безнең йөзләрдәге бәхет нуры
Балкыш булып төнгә таралсын —
Аеры йөреп, күпме тилмергәннәр
Үз парларын эзләп табалсын.



# ПУБЛИЦИСТИКА



**Фарсель Зыятдинов**

## ТОННЕЛЬДӘН ЧЫГАР ЮЛ БАРМЫ?

Барып-барып та кая барганыңны белмәсәң, елап-елап та күзеңнән яшь чыкмаса, сөйләп-сөйләп тә тыңлаучының күңеле булырлык җылы сүз әйтә алмасаң, шуннан да читен хәл юктыр. Бүген дә менә гади халыкны, намуслы хезмәт кешесен куандырырлык җылы сүз әйтүләре, ай-һай, читен. Рәсәй паровозы тоннельгә кергән көннәрдән бирле дөм-караңгы. Алда, һич югында, черек уты кадәр генә яктылык күренсен иде... Юк шул. Ә паровоз бара да, бармый да кебек. Менә шул паровозга соңгы вагоннарның берсе буларак без дә килеп тагылдык. Шуңа куанабыз, үзебез сөенәбез. Хәтта тимер кебек нык һәм сабыр кешеләребез дә: «Ярый әле тагылдык, тагылмасак, ни эшләр идек бүген?» — дип көрсенәләр. Имеш, хәзер иркен сулыш алдык, имеш, күп юнәлештә, шулай ук икътисадта да ирекле хәрәкәт итә алабыз. Шулай шул. Паровозга тагылган вагон ничек ирекле булмасын ди?! Уңда — тоннель ташлары, сулда — тоннель ташлары, алда — империя паровозы. Ул барса, барабыз, ул бармаса, тик торабыз. Әмма паровоз бармый икән шул — рельслар сүтелгән. Шпалларын алдан үтүчеләр төяп киткәннәр. Юлны төзәтү турында уйлаучы юк. Паровозда Рәсәй сәясәтчеләре һәм икътисадчылары җан-фәрман бәхәсләшә, чын-чынлап түгел, ә форма өчен, паровозны ничек тә кулга төшерү өчен бәхәсләшәләр. Кем кулына төшсә дә, паровоз барыбер урыныннан кузгалмаячак. Чөнки алар арасында юлны төзәтә, паровозны йөртә белүче юк. Кулларыннан берни килмәсә дә, һәркайсының үзенә күрә «тоннель»не үтү программасы да бар кебек. «Выбор России» лидеры Гайдар әфәнде, мәсәлән: «Бер карыш та артка чигенү юк», — ди. Шулай булгач, арттагы шпалларның кирәге булмаячак. Аларны сүтеп алып, паровоз алдына тезәргә кирәк, бары тик алга — капитализмга!

Анысын әйтә белә белүен, тик тоннельнең чиге бармы, юкмы — анысын үзе дә кистереп кенә әйтә алмый, чөнки программасы буш сүзләргә корылган.

Черномырдин әфәнде исә башкачарак фикер йөртә: «Бераз артка чигеник тә, житештерүне үстереп, көч туплап, алга кузгалырбыз,— ди.— Шулай, бераз чигеник тә, алга омтылыйк, чигеник тә, алга омтылыйк. Иң мөһиме — барган кебек булсын, кем белә, бәлки, шулай инерция белән кузгалып та китәрбез...» Ихтимал, тик алда бит рельслар сүтелгән...

Коммунистлар да алга бару ягында, тик тоннель аша түгел. Дөрес юл тоннельгә керер алдыннан уңдарак калган. Шуңа күрә башта паровозны артка чигереп, тоннельдән чыгарырга да, шул уңда калган юлга керергә кирәк, диләр.

Хәер, алар да үзләренчә хаклы. Тик соңармадылар микән? Тимурчылар арттагы шпалларны сүтеп, паровоз алдына тизә башласа, артка чигенүе мөмкин булмаячак бит, коммунист иптәшләр...

Паровозда бәхәс кыза. Тик берләшеп, сүтелгән юлны төзәтү турында гына уйлаучы юк. Һәркайсы бары тик үзе турында гына уйлый. Гайдар әфәнденең Останкино каналы буенча җавапларын тыңлагач, үз-үзен тотышын күргәч, аның юлы белән Рәсәйнең тоннельдән чыга алуына карата булган шигем тагын да куера төште. Юк аның фәнни нигезләнгән үз программасы, нәкъ халыкара валюта фонды әһелләречә фикерли ул. Имеш, аның «программасы»н тормышка ашыру өчен Рәсәй җитәкчелегенең ихтыяр көче җитми. «Ельцинның ихтыяр көче җитмиме?» — дип сорагач, ул читләтеп җавап бирде: «Ельцинга ярдәм кирәк, җәмәгатьчелек ярдәме». Бәлки, кирәктер дә, тик фикере, теләге көн саен үзгәреп торган, кая барачагын кистереп кенә әйтә алмаган кешегә ничек итеп ярдәм итмәк кирәк? Ә бит җәмәгатьчелек баштагы чорда ярдәм итмәде түгел, итте. Ә хәзер исә җәмәгатьчелек тә, аерым кешеләр дә ышанычны югалта баралар. Чөнки ил язмышы, халык язмышы турында кайгырту юк, күбрәк соңгы елларда формалашкан өстен катлам, коррупционерлар, дәүләт аппаратына кереп оялаган мафиоз группаларның ихтыяҗы кайгыртыла. Бу чирнең йогышлы вируслары безнең җирлеккә дә күчте.

Бүгенге көндәге хәлне гомумиләштереп караганда, Рәсәйдә билгесезлек, хуҗасызлык, башбаштаклык хөкем сөрә, хезмәт кешесенең тормыш-көнкүреш хәле начарлана бара. Уртача хезмәт хакының сатып алу мөмкинлеге өч-дүрт тапкыр диярлек кимеде. Бу — бәяләрнең хезмәт хакына караганда гаять кызу темплар белән арту нәтиҗәсе. Әйтик, югары уку йортында укытучы доцент торгынлык елларында бер айлык хезмәт хакына ике суыткыч яисә 43 центнер бензин, яисә 175 кг колбаса сатып ала алган булса, хәзер аның өчтән берен генә ала. Күрәсез, продукциянең, товарның төренә карап хезмәт хакы 4—7 тапкыр хәлсезләнгән. Дөресрәге, халык шунын кадәр хәерчеләнгән дигән сүз. Икенче кварталда, ягъни апрель-июнь айларында хезмәт хакы бөтенләй индексацияләнмәячәк, дигән иде Шумейко әфәнде. Сүзе хак килде, аның каравы, бәяләр тагын да үсте. Шулай итеп, хезмәт хакының сатып алу мөмкинлеге тагын да кечерәйде. Ә Татарстанда инде күп кенә төр товарларга, продуктларга бәяләр Мәскәүне дә узып китте. Моны ничек аңларга диярсез. Базар икътисадына йомшак кертеп, катыракка утырту шул буладыр инде, шат. Монысы әле баласы гына, диләр...

Шулай да ел ахырына безне нәрсә көтә соң? Моны ачыклау өчен Рәсәй лидерларының фараз-мазарларына күз төшерик. Карап торуга Гайдар әфәнденең «кризистан чыгуын» күзаллавы бик шома кебек. Әйтик, инфляцияне киметергә, базар икътисадының иркле үсешен тәэмин итәргә, элекке союздаш республикалар белән икътисадый элемтәләрне торгызырга, ди ул. Хак сүзләр кебек. Әйтүен әйтә, тик менә инфляцияне генә туктату, һич югында аның киметү юлларын башкачарак сукалый. Алай гына да түгел, җитештерүне кискен киметү, завод-фабрикаларны, предприятиеләрне, гомумән, эшләүдән туктату ягында ул. Имеш, бөлә бирсеннәр. Бу теорияне безнең интеллигенция вәкилләре арасында да яклаучылар бар. Имеш, нигә ул җитештерүне җайга салу: җимерелсен, туктасын, бетсен. Товар һәм продукцияне чит илләрдән кертәләр бит, шул җиткән, диләр алар.

Менә бу, ичмасам, икътисадның киләчәген Гайдарча аңлауның өлгесе инде. Өстән уйлау нәтиҗәсе. Әйтик, җитештерү туктады, ди. Димәк, байлык чыганагы, керем чыганагы, яшәү чыганагы да юкка чыга дигән сүз. Чит ил товарын нәрсә исәбенә алырга соң ул чакта? Агач рубльләргәме? Кемгә кирәге бар аның чит илдә? Үз товарлары бәрабәренә алар бит кирәкле чимал яисә доллар гына таләп итә. Ә долларны байлыксыз юнәтеп булмый. Димәк, халыкара валюта фонды диктаты нәтиҗәсендә үсә барган доллар курсына тугры калып, ярты бәясенә чимал сатарга, яисә шахта-рудникларны чит ил эшкуарларына бирергә туры киләчәк... Димәк, Рәсәй генә түгел, шартнамә белән Рәсәйгә нык итеп бәйләнгәнлектән, без дә коллар иленә әвереләбез дигән сүз. Гомумән, үзендә җитештерүне киметкән, туктаткан һәм чимал сатуга күчкән ил үз тәнен сатучы фәхишә хәлендәрәк күз алдына баса.

Җитештерүне барлык ысуллар белән буарга, туктатырга тырышуның сәяси ягы да бар. Урамга чыгарып ташланган меңнәрчә, миллионнарча эшсезләр, канәгатьсезлек, хәерчелек, бунт һәм 1917 елның кабатлануы да ихтимал. Дөрес, монысына әле халык массалары өлгермәгән. Казандагы иң зур җитештерү берләшмәләренең берсендә берничә эшче сөйләшә:

— Каныктылар... Бу юлы мин элэктем кыскартуга,— диде урта яшьлэрдэге бер татар.— Берэрсе яклап ник бер сүз әйтсен...

— Әй, туган,— диде икенчесе,— мондый коточкыч чорда ярдәм итәм дип, кемнең эшсез каласы килсен соң?

— Шулай ярыкка постыгызмыни,— мин әйтәм.— Мәче үзенең үткен тәпиләре белән иртәгә кайсыгызны элэктерер икән дип калтырап яшисезме?

— Яшәмичә ни эшлисең, туган. Ашыйсы, яшисе килә бит. Аена 40—60 мең булса да ярап тора пока.

— Директорларның, баш белгечләрнең, гомумән идарә итү аппаратында эшләүчеләрнең сезгә караганда дистәләрчә тапкыр күбрәк хезмәт хакы алуы һич тә борчымыймы сезне? Үзләре балда-майда яшәгәч, нигә алар җитештерүне җайга салу турында, сезнең турыда кайгыртсыннар! Шулай түгелме?

— Шулаен ул шулай да... Анысын үзебез дә беләбез... Әлеге дә баягы — ни эшләмәк кирәк...

— Бергәләп, җыелып үз сүзегезне әйтә алмыйсызмыни?

— Әйтеп кара,— диде әлегә эштән куылырга өлгермәгән агай көрсенеп,— иртәгә үк эзең дә булмас... Аннан соң, демократия бетте инде ул. Сине яклап беркем сүз әйтмәячәк.

Шулай, агайлар дөрес сөйли. Әлегә һәркем бары тик үзе турында кайгырта. Шуңа күрә дә бу яктан «демократлар» тыныч, артык куркыныч күрмиләр. Ә кем әйтә ала менә шушы эшсез калган һәм үзләрен шундый ук язмыш көткән кешеләр иртәгә берләшмәсләр дип, Гайдар әфәнде?.. Димәк, бу юл белән икътисадта гына түгел, сәясәттә дә әллә ни майтарып булмый.

Ә менә Черномырдин әфәндененң фаразлавы, киресенчә, башта җитештерүнең кимүен туктатуны, аннары үстерүне күз алдында тота. Моңа ул бөлеп бара торган предприятие, берләшмә, завод-фабрикаларга, тармакларга күпләп льготалы кредит бирү юлы белән ирешергә уйлый. Сүз дә юк, өметле предприятиеләргә, кредитны тулысынча инвестицияләүгә юнәлтүче предприятиеләргә мондый ярдәм булышмый калмас. Әмма бу юл белән генә мәсьәләне хәл итеп булырмы соң? Бирелгән кредит комга түккән су кебек юкка чыкмасмы?! Бирелгән кредитның абсолют күпчелек өлеше җитештерүне торгызуга түгел, ә күпсанлы идарә итү аппаратын асраргa, аларның хезмәт хакын үстерүгә китәчәк. Тәҗрибә күрсәткәнчә, моның шулай буласы көн кебек ачык. Бу аппарат гаять ишле әле... Җитмәсә, иң зур хезмәт хакы аларда: директорлар, аларның урынбасарлары эш бармаса да, товар сатылмаса да, хезмәт хакын миллионлап кына алып яшиләр... Шулай булгач, нигә алар җитештерүне җайга салу турында кайгыртып баш ватсын да вакыт әрәм итсен. Аннан соң аларның бит үз милекләрендә дә эш азмыни: фатирын яңага алыштырасы, коттеджын төзетәсе, машинасын яңартасы бар. Җае чыкканда долларын да туплап калырга кирәк.

Менә шундыйларның кулына эләккән кредит хезмәт кешесенә дә, җитештерүне инвестицияләүгә дә барып җитә алмаячак. Шулай булгач, нәрсә эшләргә соң? Уйлаган, башын эшләткән кешегә, билгеле, коллектив файдасына монда мөмкинлекләр юк түгел. Иң мөһиме — хезмәткә түләүдә тәртип урнаштыру, идарә итү аппаратын минимумга кадәр кыскарту, һәм бу аппаратны яхшылап чистарту таләп ителә. Каешланган, икътисадый фикерли белмәүче җитәкче кадрлар базар икътисады шартларында җылы урыннары белән, һичшиксез, саубуллашырга тиешләр. Ә калган очракта икътисадый рычагларны эшкә җигәргә, уйлап эшләргә, эшләп ашарга өйрәнергә тиешләр. Ә бит җитәкчеләре уйлап эшли торган предприятиеләр бүгенге авыр шартларда да бар, әйбәт күрсәткечләргә ирешәләр. Әйтик, «Терминат» җитештерү берләшмәсе, Казан моторлар төзү заводы, Әлмәт батырма насослар җитештерү һәм Чистай сәгать заводлары шундыйлар бит. Әйбәт тә эшлиләр, җитештерү дә үсә, җитештерелгән продукцияләре дә сатылмый ятмый. Димәк, җитештерүне җайга салуның юллары бар. Ул бюджеттан ярдәм итүгә, льготалы кредит бирүгә генә кайтып калмый, димәк. Башны эшләтергә, уйланырга, базарны өйрәнергә, фаразлый белергә, иртәгә, киләчәктә нинди төр товарларга сорау артачагын исәпкә алып, соңармыйча шул товарларны җитештерүгә күчәргә кирәк була. Бары тик менә шундый изге эшкә чын-чынлап алынган, булдыксыз җитәкчеләрдән арынган предприятиеләргә генә инвестицияләү максатында льготалы кредит бирергә мөмкин. Кредитны күпләп бирү, сүз дә юк, беренчедән, хуҗасызлыкка китерә, икенчедән, ул инфляциянең кискен артуына сәбәпче була. Бу исә, үз чиратында, кабат хезмәт кешесенең кесәсенә суга, хәерчеләнүенә китерә.

Яшәрдәй предприятиеләрне яшәтүнең бүген бердәнбер дөрес юлы — аларга карата икътисадый рычагларны белеп, дөрес итеп куллану. Бигрәк тә налог

системасыннан отышлы файдалану кирәк, ул житештерүне үстерүгә омтылган предприятиеләрне бууучы сыйфатында түгел, ә киресенчә, стимул бирүче ролендә кулланылырга тиеш. Монда күп төрле льготалар куллану, контроль булганда, һичшиксез, көткән нәтиҗәне бирәчәк. Аннан соң, житештерелгән әйберне кыйммәткәрәк сатып баерга омтылу инде нәтиҗә бирмәячәк. Бу чор үтте. Халыкның да, сатып алучы предприятиеләрнең дә акчасы юк. Кем үзенең товарын бүген арзангарак һәм тизрәк сатып, капиталның тизрәк әйләнеп кайтуына ирешә, шул отачак, шул бай булачак.

Авыл хуҗалыгын дотация бирү белән көйләү базар икътисадына туры килми. Ул житештерүченең инициативасын киметә, хуҗалык исәбен җимерә һәм хуҗасызлыкка китерә. Аннары дотация бүлгәндә хәрәмләшүгә дә урын кала, кемдер каерып ала, кемдер тиешлесеннән дә коры кала. Авыл хуҗалыгы продуктларына тәңгәл сатып алу бәяләре булганда, массакүләм дотациянең бөтенләй кирәге калмый. Тик сатып алу бәяләре фәнни яктан нигезләнгән, чыгымнарны капларлык һәм кимендә 25—30 процент табыш алырлык булырга тиеш. Ә менә бик начар табигый-икътисадый шартларда эшләүче хуҗалыкларга, фермерларга дәүләт ярдәме кирәк булачак. Барлык цивилизацияле илләрдә дә бу эшләнә.

Ни өчен бүген дотация бирү белән мавыгабыз соң? Имеш, авыл хуҗалыгын җимерелүдән саклап калабыз. Хикмәт анда түгел. Дотация бирүдән эквивалентлы сатып алу бәяләре кертүгә күчүнең хакимият башында, җитәкче оешмаларда утыручы күпсанлы артык кашыклар өчен зыянлы ягы бар — күпләрнең властьны, авыл хуҗалыгы өстеннән хакимлек итүне югалтулары, эшсез калулары ихтимал. Ләкин бу бары тик файдага гына булачак.

Чынлап та, авыл хуҗалыгындагы милеккә кем хуҗа соң бүген? Соңгы вакытта миңа берничә тапкыр Актаныш районы хуҗалыкларында булырга, үзгәртеп корыла торган хуҗалыкларның җитәкчеләре, икътисадчылары, гомумән, белгечләре, терлекчеләре, механизаторлары белән мәсьәләне уртага салып сөйләшергә туры килде. Дөресен әйтергә кирәк, районның икътисадый хәле шәптән түгел. Саф авыл хуҗалыгы районы буларак, бөтен керемнәре икмәк, ит, сөт җитештерүдән һәм продуктларны үзләре өчен файдалы итеп сатудан бәйле. Мәгълүм булганча, хәзергә мондый мөмкинлек юк. Сатып алу бәяләренең һаман да өстән билгеләнүе һәм аның түбән булуы табыш алу мөмкинлеге калдырмый. Узган ел бөртеклеләрнең һәр гектарыннан район буенча 24 центнердан артык уңыш алынса да, хуҗалыклар җитештерелгән ашлыкны сатудан мантый алмадылар. Район хуҗалыкларының 1993 ел йомгаклары буенча ике миллиард сумга якын бурычлы булып калуы нәкъ шул турыда сөйли.

Актанышлылар, үзләре җитештергән продукцияне бары тик күршеләре — Башкортстанның Илеш районына җиткерелгән сатып алу бәяләре белән саткан булсалар да болай бурычлы булып калмаслар иде. Киресенчә, шактый табыш алырлар иде. Чагыштырып карыйк. Илешлеләр икмәкнең һәр центнерын 8 мең сумга сатканда, актанышлылар аны уртача 5 мең сумга гына саттылар. Һәр центнердан күршеләренә караганда өч мең сум югалттылар. Сөт продукциясенә килгәндә дә шундый ук хәл. Илешлеләр аның һәр центнерын 20 мең сумга саткан бер үк вакытта, актанышлылардан сөтне нибары 14 мең сумга гына сатып алдылар. Шулай итеп, актанышлылар үзләре җитештергән продукцияне күршеләре илешлеләрдәге кебек бәя белән сатсалар, өстәмә рәвештә кимендә өч миллиард сум керем алырлар иде. Димәк, елны бурычлы түгел, ә табышлы төгәлләрләр иде.

Сатып алу бәяләренең түбән булуы турында сүз чыкса, безнең хөкүмәт җитәкчеләре, авыл хуҗалыгына дотация бирәбез, дип кабатларга яраталар. Ә тирәнтенрәк исәпләп карасаң, монда да мактанырлык нәрсә юк. Бирелгән компенсация авыл хуҗалыгында кулланыла торган техника, комбайн, тракторлар, ашлама, ягулык материалларга арта барган бәяне һич кенә дә каплый алмый. Таякның юан башы һаман да колхоз, совхоз, кооператив берләшмәләре, фермерлар өстенә төшә. Фермер хуҗалыкларының мантый алмавы да нигездә шуның белән аңлатыла.

Компенсация дигәннән, Илеш районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы А. Романовның әйтүенә караганда, компенсация Башкортстанда да бирелә. Илешлеләр аны актанышлылардан һич тә ким алмыйлар. Шуның өстенә, әйткәнемчә, аларда авыл хуҗалыгы продуктларын сатып алу бәяләре, актанышлыларга караганда, 40—45 процентка югары. Әнә шундый анализлардан соң актанышлыларның күршеләре белән чагыштырганда тигезсез шартларда эшләвен, авыл хуҗалыгын тагын да үстерү өчен мөмкинлекләренең чикләнгән булуын күзаллау читен түгел.

Мондый хәлнең актанышлылар өчен генә түгел, гомумән, Татарстан авыл хуҗалыгы өчен төзәтеп булмаслык зыян китерүе мөмкин. Иң югары уңыш үстергән, терлекчелек үсеш кичергән елда да хуҗалыкларның авыр хәлдә калуын, акчасыз яшәвен берничек тә аңлатып булмый. Министрлар кабинетында эшләүче кайбер җаваплы агайларның колагына шуны әйтәсе килә: авыл хуҗалыгы исәбенә крестьян җилкәсендә гомумкризистан котылырга омтылу — бүген ул зур хата. Утызынчы елларда индустрияләштерүне авыл хуҗалыгы исәбенә үткәрү аклангaн булса да, бүгенге хәлне берничек тә аклап булмый. Бүгенге тынгысыз игенче, терлекче үзе тир түгеп житештергән продукцияне гадел, тәңгәл бәяләр белән сатарга хаклы. Авыл хуҗалыгы продукциясенә бәяләр көйләнә икән, ул промышленность товарларына да эквивалентлы көйләнергә тиешле. Ә бу юк. Авыл эшчәннәре исәбенә күпме көйләргә, күпме яшәргә мөмкин? Бүген алар көне-төне эшләп тә бурычлы, ә житештерүне бермә-бер киметкән промышленность предприятиеләре житәкчеләре каерып хезмәт хакы ала. Нәрсә исәбенә? Үзләре житештергән продукциягә бәяләрне иркле күтәрә бару исәбенә, билгеле. Бәяләрне шулкадәр күтәрделәр — хәтта алучы да бетте. Хәзер инде, товарларны алучы юк дип, атнага өч-дүрт көн генә эшли башладылар. Һәр предприятие товарны күбрәк житештереп, арзанрак сатса, начар булыр идемени? Кризистан чыгарбыз дип куркалармы? Ә бит капитал әйләнештә булмаса, бөлүең көн кебек ачык. Бу — базар икътисадының төп кануны.

Шулай итеп, промышленность бәяләрне комсызланып үстерүдән, ә авыл хуҗалыгы, киресенчә, эквивалентсыз бәяләр куюдан газап чигә. Аннары авыл хуҗалыгы предприятиеләре шул арзан бәягә саткан продукцияләренә тиешле акчаны берничә айлар буе ала алмый аптырадылар. Инфляция нәтиҗәсендә аларның алачак акчаларының кыйммәте 4—5 тапкыр кимеде. Шулай итеп, игенче ел әйләнәсе диярлек бушка эшләгән булып чыга. Күпчелек хуҗалыкларга хезмәт хакы 4—5 ай буе түләнмәде. Ярый әле өстән узган елгы бурычны 13 мартка кадәр түләргә дигән әмер булды. Бу датага Рәсәй думасына сайлаулар билгеләнмәгән булса, аны түләү турында уйларлар идеме икән? Кем белә аны. Чөнки басынкы авыл халкы бушлай эшләргә өйрәнгән инде ул. Вакыты белән йөз грамм икмәккә дә, ярты тиен акчага да эшләде, ә вакыты белән буш «таякка» да көнне төнгә ялгап тир түкте. Бушка эшләргә өйрәнгән кеше хезмәт хакын бер ел соңарып алганга гына шәһәр халкы кебек, шахтерлар, укытучылар кебек баш күтәрмәс, түзәр ул, дип уйлыйлар, күрәсең...

Тик шунысын истән чыгармыйк — бүгенге авыл хезмәтчәне инде бүтән. Түзәртүзәр дә сүзен берәгәйле итеп әйтүе мөмкин аның. Аннан соң авыл өчен быел аерата читен ел. Күп кенә жирләрне, бигрәк тә көнчыгыш районнарда, яз сөреп чәчәргә туры килде, шактый гына уҗымнар бозып чәчелде. Ашлама да узган ел белән чагыштырганда аз кертелде. Компенсация бирелә дисәк тә, булган техника нык искереп бара, акрын яңартыла. Болар өстенә елның коры килүен, игенченең, крестьянның фигылендә канәгатьсезлек, битарафлык билгеләренең ныграк чагылуын исәпкә алсак, алда зур сынау көтә.

Менә шул булачак сынауны алдан күрепме, актанышлылар кышын колхоз һәм авылларны үзгәртеп коруга керештеләр. Барлык хуҗалыкларда да диярлек һәркемнең жир һәм милек паен исәпләп, аны үзгәртеп коруга багышланган җыеннарда халыкка житкерделәр. Милек пае колхозчының яисә совхоз эшчесенең соңгы биш елдагы хезмәт хакына һәм эш стажына карап бүленде. Тик шунысы гаҗәп: үзенең жир һәм милек паен алып, аерым фермер хуҗалыгы оештырып җибәрергә теләүчеләр бик аз. Төп сәбәбе — алда санап кителгән авыр шартлар куркыта аларны, бүгенге хәлдә хуҗалыкны ялгыз гына алып бара алуларына ышанып житмиләр. Икенчедән, тулы мөстәкыйльлек булмау, бигрәк тә дәүләт заказларының узган ел дәрәҗәсендә калуы, сатып алу бәяләренең түбән булуы да шикләндерә аларны.

Районда фермерлык тәҗрибәсе юк димәс идем. Бүген район хакимият башлыгының икътисад буенча урынбасары булып эшләүче Ингел Фәттахов үзе үк фермердан күтәрелгән кеше. Үзенең техникасы, тракторлары бар. Узган ел моңарчы иген үсмәгән уңайсыз жирләрне үзләштереп, һәр гектардан 30 ар центнердан артык уңыш үстереп алган. Быел инде җаваплы эштә эшләсә дә, фермерлыкны ташламый, шул ук жирдә отышлырак, табышлырак культуралар үстерә.

Төп эшендә дә аның жирдән килүе үзен сиздерә. Хуҗалыкларны үзгәртеп коруга, хуҗалык итүнең төрле-төрле формаларына күчүгә игътибар бирә. Райондагы хуҗалыкларның кайберләре кооперативлар берләшмәсе, икенчеләре ябык типтагы акционерлык җәмгыятьләре, өченчеләре крестьян хуҗалыклары һәм

кооперативлар ассоциацияләре итеп үзгәртелә. Бу яктан «Җиңүнең 40 еллыгы» колхозында үзгәртеп коруга беренчеләрдән булып керешкәннәр иде. Кооперативлар берләшмәсе җитәкчесе Рәфис Шәйдуллинның тәҗрибәле булуы, икътисадый фикер тирәнлеге эшнең уңышлы тәгалләнүенә ышаныч тудыра.

«Үзәк» крестьян хуҗалыклары һәм кооперативлары берләшмәсенең киләчәге дә өмет уята. Биредә, авыл хуҗалыгы производствосы белән шөгыльләнүче кооперативлардан тыш, эшкәртү промышленносте кооперативы да берләшмәнең икътисадый хәлен яхшыртуда үзеннән шактый өлеш кертәчәк. Аны оештыру эшендә инде җитди адым ясалды. Биредәге төзелеш материаллары җитештерү цехы керамзиттан җиңел һәм уңайлы блоклар җитештерә, берләшмәдәге складлар, хуҗалык объектлары шуннан төзелә. Мондый блоклар киләчәктә читкә сату өчен дә эшләнәчәк. Моннан тыш, тимерчыбыктан койма үрү, хуҗалык кирәк-яраклары җитештерү, тегү, кәнбагыш мае сыгу цехлары да инде продукция бирә. Бу берләшмәнең рәисе Равил Камильянов хәзер бәрәңге эшкәртү, ягъни аннан крахмал һәм башка төр продуктлар җитештерү цехы оештыру юнәлешендә эш алып бара. Моның да максаты бар. Актаныш якларында кабул итү пунктлары ерак булу сәбәпле, бәрәңге әрәм-шәрәм була иде. Бу цех ачылса, проблема хәл ителә дигән сүз. Аны тормышка ашыруда Казанның «Аверс» банкы да үзеннән капитал белән өлеш кертергә исәпли.

Әмма кайбер колхоз һәм совхозлар, җисеменнән бигрәк, исемен үзгәртү белән канәгатьләнергә исәп тота. Моннан котылу өчен «Ташъелга» колхозында мәсьәләне бөтенләй башкача хәл итәргә уйладылар. Дөресрәге, колхозны тараттылар. Һәркемгә милек һәм җир паен бүлеп бирделәр дә, ирек бирделәр: теләсә ничек эшләгез, телисез икән, аерым фермер хуҗалыклары булып эшләгез, телисез икән, хуҗалыкны берничәшәр гаилә берләшеп алып барыгыз, диделәр.

Без килгәндә элекке идарә әгъзалары балталары суга төшкән сукбай хәлендә иделәр.

— Колхозны тараттык,— диде аның элекке рәисе Рәскат Хәертдинов,— беркем дә аерым гына эшләргә теләми. Миңа 70 кеше гариза күтәреп килде инде. Крестьян хуҗалыклары берләшмәсе төзик, диләр...

Ләкин мондый берләшмәнең биредәге шартларда крестьяннарны мул тормышка алып чыгуы шикле. Рәскат әфәнде үзе дә шул хакта уйлана иде. Ни өчен дисәң, кырларның уңдырышлылыгы бик түбән, уңдырышсыз җирләр бер елны да 12—13 центнердан артык уңыш бирми. Сөрүлек җирләрнең мәйданы 950 гектардан артмый, ә авылда өч йөзгә якын эшче кул бар. Тагын хуҗалыктагы 100 баш сыерны кушсак та, аларның барысын да эш белән тәэмин итү авыр мәсьәлә.

Озак фикерләшкәннән, киңәшкәннән соң биредә табигатьнең матур гына түгел, ә гаҗәеп бай булуын, болыннарның җитәрлек булуын исәпкә алып, мөгезле эре терлек җыеп симертү һәм аны эшкәртү объектлары төзергә, үрдәк, каз үстерү, балык тоту кооперативлары оештырырга, муллыкка шулар аша ирешергә дигән фикергә киленде.

Бу эшләрне башкарып чыгу өчен Чаллыдагы «Дизельстрой» фирмасы белән берлектә хуҗалыкны акционерлар җәмгыяте итеп үзгәртергә булдылар. Башлангыч капитал туплангач, ашламасы да булыр, кырларның да уңдырышы күтәрелер, шәт. Әйе, өметсез шайтан гына, диләр бит.

Район хуҗалыкларында колхозчыларның күмәк хезмәттән аерылырга теләмәүләрен исәпкә алып, исеме белән генә түгел, җисеме белән төп таләпләргә җавап бирә торган кооператив берләшмәләре оештыруга керештеләр. Моны беренче булып «Агыйдел» колхозында башлап җибәрделәр.

«Агыйдел» колхозын кооперативлар берләшмәсе итеп өр-яңадан сүтеп җыярга туры килде. Биредә һәрбер колхозчы (пенсионерлар һәм интеллигенцияне дә кертеп) кооперативлар берләшмәсе оешкач, үзенә тигән җир кишәрлеге — ә ул һәр кешегә дүртәр гектар туры килә — һәм милек пае белән аерым-аерым кооперативларга берләште. Барысы 6 кооператив төзелде: өчесе — Гәрәй, Чалманарат, Шәбез кооперативлары — игенчелек һәм терлекчелек продуктлары җитештерәчәк. «Уңыш» кооперативы ашлык эшкәртү, чәчүлек орлыгы, ашлама хәзерләү, җирләрнең уңдырышын күтәрү белән шөгыльләнәчәк. Җитештерүче кооперативларга ул түләүле хезмәт күрсәтә, ягъни суктырылган икмәкне алардан сатып ала һәм аның ашлыгын — ашлыкка, чәчүлек орлыгын орлыкка куллану өчен бөтен яктан әзерләп, яңадан үзләренә үк сатып бирә. «Уңыш» кооперативы белән элекке баш агроном җитәкчелек итә.

Машина-трактор паркы үзе бер кооперативка керде. Аның җитәкчесе — баш инженер. Ул ремонт үткәрә, игенчелектә, терлекчелектә эшләүчеләргә техник хезмәт күрсәтә, сатып бирү юлы белән ягулык-майлау материаллары, запас

частьлар юнәтә. Бу кооперативның еллык кереме Гәрәй, Чалманарат, Шәбез кооперативларына хезмәт күрсәтүдән алына. Димәк, никадәр яхшы эшләсә, керем дә шулкадәр күбрәк була. Ә акча эшләү юллары аз түгел. Һәртөрле ягулык та сатып бирелә. Мәсәлән, хәзер А-76 бензинының бәясе 300 сум тора. Шуңа бензин җибәрүченең һәм аны ташучы шоферның хезмәт хакын, амортизация чыгымнарын кертеп, өстәмә түләү дә өстәлә. Болардан тыш, тегүче, шәхси хуҗалыклар, оста куллар (мәктәптә) кооперативлары төзелде. Аларда да һәрбер хезмәт мөнәсәбәтләре бары тик акча белән генә хәл ителә. Хезмәт күрсәтүче кооперативлар күбрәк акча эшләү өчен тырышачаклар, чөнки аларның хезмәт хакы шуңа бәйле. Шәхси йомышлар өчен дә түләү акча белән эшләнәчәк. Әйтик, 2 сәгатькә бакча сөрергә киткән тракторчы көннәр буе югалып йөри алмый, чөнки аңа шул 2 сәгать өчен генә түләячәкләр.

Кооперативлар «Агыйдел» берләшмәсе эчендә йөри торган кыйммәтле кәгазь, ягъни акча бәрабәренә хезмәт күрсәтәләр. Акчаларны исә кооператив берләшмәсе бастырды. Аның бер ягы акча формасында бизәп эшләнгән — Сөембикә манарасы, Татарстан гербы төшерелгән. Ә икенче ягына «Кыйммәтле кәгазь» дип язылган. Шунда ук «Агыйдел» кооперативлар берләшмәсе рәисе Әхнәф Сәлаховның имзасы һәм мөһер сугылган. Кыскасы, аны ясау мөмкинлеге юк.

Бу акча берләшмәдәге кооперативлар арасында түләү, алыш-биреш операцияләрен башкару ролен үти. Шунысы мөһим — ул бернинди өстәп язуларга да урын калдырмый, бөтен эшне автомат рәвешендә акча үзе эшли.

Колхоздан аермалы буларак, берләшмәдә элеккеге кебек күп санлы идарә итү аппараты юк хәзер. Аның урынына баш бухгалтер һәм икътисадчы-коммерсант һәм кассир составында финанс исәп-хисап коммерция үзәге оешты. Ә элек эшләгән белгечләрнең теләгәннәре кооператив бухгалтерлары булып китте, теләмәгәннәре башка эшкә күчте. Үзгәртеп кору барышында идарә итү аппараты 12 кешегә кыскартылды.

Берләшмәдә акча ничек йөри соң? Барлык акча массасы коммерция үзәгендәге банкта саклана. Акча бары тик продукция житештерүче кооперативларга житештереләчәк продукциянең күләменә карап бирелә. Әйтик, Гәрәй кооперативы май аенда 400 центнер сөт житештергән, ди. Һәр центнер сөтнең сатып алу бәясе 14000 сум. Ай эчендәге барлык чыгымнарга түләү һәм хезмәткә түләү өчен бу кооперативка сатып алу бәяләре белән шушы айда сатылачак сөт бәрабәренә 5 миллион 600 мең сум акча бирелергә тиеш. Әмма исәп-хисап коммерция үзәге шуның 55 процентын гына кооперативка бирә. Ә 45 проценты страхованиегә, пенсия фондына, резерв фондына, башка төр налоглар түләү һәм шулай ук берләшмәнең идарә итү аппаратын яшәтү өчен тотып калына. Соңгысы 6,7 процент тәшкил итә. Шулай итеп, кооператив карамагына сатылачак продукция бәрабәренә 3 миллион 30 мең сум акча бирелә. Гәрәй кооперативы шул акчадан, мәсәлән, МТП кооперативына, фермага хезмәт күрсәткән, фермага ягулык алган, тотылган электр энергиясе өчен, башка кооперативлардан печән, сенаж сатып алса, аның өчен түли. Ә калганы кооперативта эшләүчеләргә хезмәт хакы итеп бүленә. Чыгымнар никадәр кимрәк, продукция никадәр мулрак булса, хезмәткә түләү өчен акча да шулкадәр күбрәк кала дигән сүз. Ләкин хезмәт хакы түләр өчен кооператив карамагында калган бу акча коммерция үзәгендә урыс акчасы — рубльгә алмаштырып бирелә.

Берләшмәнең эшен уңышлы алып бару өчен элеккеге колхозның дәүләткә түләнми калган бурычы комачаулый. Юк дисәң дә, ул 170 миллион сум. Кооперативларга моны кайгырту авыр. Чөнки авыл хуҗалыгы продуктларына сатып алу бәяләренең бик түбән булуы, чыгымнарны киметеп, продукция житештерүне шактый арттырган очракта да, чак-чак кына очын очка ялгап барырга житәчәк. Кооперативта эшләүчеләр үзләренең хезмәт хакларын 40—50 мең сумнан арттыра алмаячаклар. Нишләргә? Бары тик бер юл — әлеге бурычны соңрак чорга күчереп тору яисә гел гамәлдән чыгару гына кала.

Күрәсез, районда колхоз һәм совхозларны үзгәртеп коруның төрле формалары кулланыла. Әгәр дә аларга тернәкләнеп китү өчен тиешле шартлар булмаса, сатып алу бәяләре һаман да эквивалентсыз кала бирсә, диктат дәвам итсә, аларның да гомере кыска булачак. Юктан бар булмый. Бер танышым миңа, бәлки, актанышлыларга якташлары — Президентыбыз ярдәм итәдер, дип шаяртты. Әмма актанышлылар, киресенчә, якташыбыз Президент булмаса, бәлки, яхшырак шартларда яшәр идек, диләр. Ник дисәң, борын төбеннән газ үтә, ә Актаныш моңарчы газсыз районнарның берсе булып кала бирде. Финанс хәле ярлылардан ярлырак. Быел хәтта Актаныш үзешчәннәре Казанга үзләренең осталыкларын күрсәтергә дә килә алмадылар. Акча юк. Бөтенләй

авыл хужалыгына катнашы булмаган кирәк-кирәкмәс кешеләргә Венгриягә бару өчен акча табыла, ә культураны, сәнгатьне үстерүгә — юк. Актанышлылар әнә шулай фикер йөртә.

Сөйләгәннәрдән чыгып, Черномырдин әфәнде күзаллаган фараз тормышка ашырылган очракта без илны ничек тәгәлләячәкбез соң? Сүз дә юк, кредит бирү белән артык мавыгу көткән нәтиҗәне бирер дип уйламыйм. Күпләп кредит бирелгән, ә максатка барып җителмәгән айларда инфляциянең 35—40 процентка житүе мөмкин. Исегезгә төшерәм, ул январьда — 22, февральдә — 9,9, мартта — 12 булды. Промышленностьта җитештерү әле стабильләшмәгән, предприятие җитәкчеләре күбрәк кредит юллау белән мәшгуль. Икътисадый рычагларга игътибар кими төшәчәк, ә житештерү белән искечә җитәкчелек итәргә өйрәнгән, каешланган җитәкчеләр иркенрәк сулыш алачак. Үзләре эшләп табу, эшләп ашау турында азрак кайгыртачак, товар чыгару да, аны кертү дә кимиячәк. Агач рубльнең курсы тагын да агачланачак. Ел ахырында долларның курсы 3600—3800 сум чамасы булачак. Ә болар, үз чиратында, халыкның тагын да ярлылануына китерәчәк. Уртача хезмәт хакы 70 доллар чамасы булыр, ә хәзер исә Рәсәй буенча ул 80 доллар.

Җыеп кына әйткәндә, Рәсәй хөкүмәтенең хәзерге тоткан курсы ике елга соңарды. Бер таралгач, җыюы авыр шул ул. Кризисның шаукымын киметү өчен, административ чаралардан бигрәк икътисадый рычагларны эшкә җигү юлын карау мөһим. Базар тууына тәки ирешә алмадык. Монополь предприятиеләр исән чакта конкуренциянең тууы шикле. Бу шартларда вак предприятиеләр һәм эшкуарларны төрле налоглар белән буып, житештерүне җайга салу мөмкин түгел. Киресенчә, налог системасы җитештерүне стимуллаштыруга төп рычаг, сыгылмалы рычаг булырга тиеш. Бу таләпләргә игътибар булмаганда, менә шундый авыр хәлләр көтә Шартнамә белән Рәсәйгә тыгыз бәйләнгән Татарстан халкын.

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ



**Фәрит Хатипов**

# ТӘНКЫЙТЬ РЕАЛИЗМЫ БУЛГАНМЫ?

Европа XIX йөз әдәбиятына житди сыйфат үзгәреше алып килде. Сүз сәнгате реализмның югарырак баскычына күтәрелде, аеруча зур казанышларга иреште.

Моның өчен ул барыннан да бигрәк эстетик азат рухлы даһи талантларга бурычлы иде. Алар элекке казанышларны, шул исәптән, романтизм, сентиментализмның кайбер мөмкинлекләрен ижади үзләштерделәр, бәгъзе методларның тышауларыннан арындылар. Яңа методның төп максаты — дөреслеккә, хакыйкатькә тугры калу, реалистик сурәтнең поэзиясен ачу, чынбарлыкның гүзәл, камил образын гәүдәләндерү иде. Жиһан үзе һич тә саекмый торган матурлык чыганагы булганлыктан, моңа ирешүдә ул үзен берни белән дә чикләмәде, хәятның бетмәс-төкәнмәс бизәкләрен иркен файдаланды. Татар әдәбиятында мондый сыйфат үзгәреше XX йөз башында барлыкка килде.

Совет әдәбият белеме исә бу чор ижат методын **«тәнкыйть реализмы»** дип атады, ягъни аның тискәре күренешләрне фаш итү хасиятенә басым ясады. Реализм сәнгате, прокурор кебек, тәнкыйтьләү, гаепләү вазифасы белән чикләнгән ысул дип тәкъдим ителде. Шулай итеп, бу методны, исеменә карап, кимчелекләрне, тормышның кара төсләрен, ягъни ямьсезлек гүзәллеген чагылдыру сәнгате дип аңларга урын кала иде. Совет эстетикасы бу чор әдәбиятын әнә шулай итеп күрергә теләде.

Сорау туа: тормыштагы, кеше холкындагы алама якларны бәян итү тәнкыйть реализмына гына хас күренешме әллә? Алай түгел, әлбәттә. Кара эчле явызларны, тискәре типларны инде без, антик дәвердән башлап, барлык методларда, шул исәптән, романтизмда да очратабыз. Шул ук вакытта бер генә «критик реалист»ның ижаты да тик караңгы төсләрдән генә тукылмаган. Бальзак, Диккенс, Теккерей, Пушкин, Толстой, Достоевский, Тукай, Ф. Әмирхан әсәрләрендә, киресенкә кичерешләр белән бергә, кеше рухының бик күркәм яклары да гәүдәләнә.

Кайбер хезмәтләрдә «Критик реализм тормыштагы аерым кимчелекләрне генә түгел, бәлки җәмгыятьнең нигезләрен тәнкыйтьли торган реализм ул» дигән фикер уздырыла. Ягъни әдәбият, эстетик вазифасын онытып, сугышчан ижтимагый фәнгә әверелгән кебегрәк аңлатыла. Ләкин шулай да XIX—XX йөз классиклары ижатында без «җәмгыятьнең нигезләрен тәнкыйтьләү»не очратмыйбыз. Бу мәсьәләгә Н. А. Гуляев саграк карый. Ул болай ди: «Бальзак, Диккенс, Теккерей, Флобер тормышны революцион үзгәртү методларын кабул итмәделәр» *(Әдәбият теориясе. М., Югары мәктәп. 1977, 233 б.)*. Гәрчә большевиклар Л. Толстой исемен инкыйлабка әзерлек максатында файдаланырга, ижатын ре-

волюция көзгесе итеп күрсәтергә тырышсалар да, бу әдип явызлыкка көч белән каршы тормауны мәслихәт санады, әсәрләрендә әнә шул идеяне үткәрде. Достоевский да җәмгыятьне үзгәртү карашын, революцион хәрәкәтне хупламады.

Ләкин шулай да монда сүз «критик реализм»да чынбарлыкка тәнкыйть мөнәсәбәте булу-булмау хакында бармый. Хәятның гарип якларын фаш итү пафосы анда, әлбәттә, шактый көчле. Кискен сыйнфый каршылыклар сүз сәнгатенең тәнкыйть карашын үткенәйтүгә, тирәнәйтүгә нык кына йогынты ясады. Монда критик мөнәсәбәт башка методларга караганда да ачыграк сизелә, ягъни бу җәһәттән дә ул башка ысулларны бераз узып китте. Ләкин шулай да, аеруча азат рухлы реализм, тышауларның бер тереннән котылып, икенчесен бәйләргә, иҗатын кара буяулар белән генә чикләргә омтылмады, беръяклылыкны һичкайчан үзенең программасы дип игълан итмәде. Шуңа күрә «критик реализм» кушаматы методның табигатен дөрес билгеләми кебек, чөнки ул аерым күрсәткечне, бер генә кисәкне бөтен дип, күренешнең асылы дип тәкъдим итә. Димәк, хәзер бу ысулны теоретик беръяклылыктан арындыру, аңа төгәл исем кушу сорала. Мин аны, әдәбият үсешендәге урынын, биеклеген истә тотып, **«җитлеккән реализм»** дип атау ягында торам. Бу исем методның офыкларын тарайтмый: тәнкыйть пафосын да инкарь итми, аны үз эченә ала, башка билгеләрен дә үз канаты астына сыйдыра, шул ук вакытта казанышлары турында да әйтеп тора. Аңлашыла ки, әгәр тагын да төгәлрәк, уңышлырак исем табыла калса, уртак фикергә килеп, аны үзгәртергә дә мөмкин булачак.

Җитлеккән реализмның иң мөһим үзенчәлеге шунда ки, ул чынбарлыкның, кеше характерының, гамәл, хисләренең асылына тирәнрәк үтеп керә алды, җиһанны сәнгатьчә камил, гүзәл образларда сурәтләп бирде. Ул тормышны дөрес гәүдәләндерүнең чиксез эстетик мөмкинлекләренә таянды, аларга ихлас ышанып карады.

Яңа чор реалистлары, эстетик кысанлыктан азат булган кебек, каһарман характерын да бер генә тарафтан, калку бер сыйфаты белән генә яктыртмадылар, киресенчә, аны тормыштагыча, бар байлыгы, универсальлеге, бар төсләре, бизәкләре белән балкыттылар. Моңа мисал итеп Галиябануны күрсәтергә була. Ул чибәр, рухи бай, поэтик табигатьле, тирән хисле, тәвәккәл, батыр йөрәкле, мәхәббәтендә тугрылыклы, аны байлыктан өстен куючы, көчле кешенең-байның җинаятен фаш итәргә сәләтле. Менә болар һәммәсе персонажны җанлы итеп яшәтә, кичерешләрен тамашачыга якын, аңлаешлы итә.

Җитлеккән реализм — аеруча киң офыклы иҗат методы. Ул типларны сайлауда ук үзен бернинди нормалар белән дә чикләмәде, барлык катлам вәкилләренә дә әсәрләрдә капканы киереп ачып куйды. XX йөз башы татар әдәбиятында без крестьян, бай игенче, сәүдәгәр, шәкерт, студент, мулла, эшче, интеллигент, морза, офицер, артист, шагыйрь, полицейский, хезмәтче, саилче, музыкант образларын күрәбез. Рус, Европа әдәбиятында типлар тагын да күбрәк төрле. Татар әдәбиятында тик, үз дәүләтчелегебез булмагач, соңгы дүрт ярым гасырдагы ил башлыкларын гына очратмыйбыз. Рус, Европа әдәбиятларында исә король, патшаларның да күптөрле образлары тасвир ителә. Моңа кадәрге бер ысул да әле типларга шулкадәр бай түгел иде. Моңа бәйле рәвештә җитлеккән реализм, мөһим вакыйгалар белән беррәттән, көндәлек тормыш күренешләренә дә бердәй дикъкать белән карады, аларны характерның теге яки бу төсмерләрен ачу, калку итеп күрсәтү өчен файдаланды. Уильям Теккерейның «Ярмарка Тщеславия» романында Мисс Кроули аш өстәле янына ничегрәк килеп утырырга кирәклеге хакында сөйли: «Мисс Кроули сэр Хадлстон ярдәменнән баш тартты һәм шундый приказ бирде: моннан ары Родон Кроули аңа кулын суза һәм, култыклап, аны өстәл янына алып бара, ә Бекки, мендәр тотып, аның артыннан иярә: йә булмаса ул Бекки кулына таяна, ә мендәрне Родон китерә». Күрәсез, сүз арасында әйтелгән шушы бер-ике җөмлә герой характерының аерым бер ягын көтелмәгәнчә балкытып ала.

Көндәлек тормыш картиналарын уртачалык, төссезлек дип аңларга ярамый. Оста язучы кулында һәр деталь нәтиҗәле ялтырый, күркәм образ гәүдәләндерүгә хезмәт итә.

Критик һәм социалистик реализм теориясендә, каһарманнарның эш-гамәлләрен нигезләү турында сүз барганда, аеруча иҗтимагый дәлилләүгә басым ясала иде, ягъни геройның адым, хәрәкәтләре башлыча социаль хәлләр белән билгеләнә диган фикер хакимлек итә. Ул караш совет эстетикасының иң җитди җиңүләреннән санала иде. Бәндә, әлбәттә, тирәлектән, иҗтимагый-сәяси хәлләрдән бәйсез яши алмый. Ләкин шулай да әсәрләрдә ышандыру, исбатлауның башлыча шушы ягына игътибар юнәлтү теоретик нормативлыкны китереп

чыгарды, безнең дәвер әдәбиятын зәгыйфьләндерү, имгәтүгә сизелерлек өлеш кертте, кайбер әсәрләрне иҗтимагый-тарихи хезмәтләргә якынайтты. Әдәбият белемендәге вульгар социологизмның тамырлары да әнә шуна барып тоташа иде.

Чынында исә житлеккән реализмда социаль детерминизм һич тә хәлиткеч нигезләү буларак кулланылмады. Әдипләр, барыннан да бигрәк, характерның эчке куәтенә, күңел хәрәкәтенә, тормыш логикасына өмет багладылар. Әгәр дә иҗтимагый-сәяси мәсьәләгә кагыла икән, алар аны гыйльми, тарихи планда түгел, ә бәлки персонажның ничек кабул итүе, ягъни күңел хәрәкәте аркылы яктырталар. Инглиз язучысы Теккерей, мәсәлән, житкән кыз Эмилиянең Наполеон сугышына һәм сөйгәне поручик Осборн язмышына бәйле кичерешләрен менә болай тасвирлый: «Аның аңында Европа язмышы поручик Джордж Осборн язмышы белән бәйләнгән. Осборн өчен барча куркынычлар үтеп китте һәм Эмилия моның өчен ходайга шөкерана кыла иде. Осборн — аның Европасы, императоры, аның союздаш патшалары һәм тажлы принцы иде». Бу юллар социаль детерминизмның хәлиткеч әһәмияте турындагы фикер белән бәхәс кебегрәк тә яңгырый.

Күңел хәрәкәтен сурәтләү житлеккән реализмда, бигрәк тә аның прозасында аерым урын биләп тора. Гәрчә хисләр ташкынын чагылдыруның тәүге үрнәкләре яңарыш чорында, хәтта аннан да иртәрәк күренә башласа да, прозада психологизмга тышкы хәлләр белән тигез хокук бирү турындагы таләпне нәкъ менә житлеккән реализм вәкилләре күтәреп чыкты. Бальзак тойгы, кичерешләрдән башка кешене аңлау мөмкин түгеллеген күрсәтте, Чернышевский, Л. Толстой (һәм, әлбәттә, башка күренекле реалистлар) үзләренең иҗатында күңел диалектикасы чагылганын раслардылар. Психологизм герой гамәлләренең пружинасын эчке яктан яктырта, теге яки бу хәрәкәтнең нинди кәеф, нинди караш җирлегендә барлыкка килгәнен, икеләнү очракларында кайсы уйның, кайсы карарның өстенлек алганын күрсәтә.

Әнә шундый эчке балкыш — ни хикмәт! — укучыны ныграк ышандыра, кайчак хәтта гамәлнең, билгеле бер хәтәр адымның гомуми нормадан авыша төшүен дә аклый, эстетик җәһәттән социаль нигезләүгә караганда да нәтиҗәлерәк була. Тормышчан психологизм исә аеруча житлеккән реализмда тирән тамыр җибәрде, әсәр сюжетында үзенә лаеклы урын алды, тышкы хәлләр кебек, сюжетка хәрәкәтчәнлек бирүче мөһим факторга әверелде. Ул, әйтик, сентиментализмдагы берьяклылыктан арынды, реаль хис-кичерешләрнең матурлыгын чагылдырды. Психологизм әдәбиятка, бигрәк тә эпик төргә, лирик ягымлылык алып килеп кенә калмады, әсәрнең ышандыру, нигезләү куәсен дә бермә-бер арттырды. Шуна күрә житлеккән реализм классиклары әдәби дәлилләүнең бер генә төренә өстенлек бирмәделәр, тормыш һәм сәнгать канунн арына ярашлы рәвештә, һәммәсен дә кирәгенчә файдаландылар. Житлеккән реализм сәнгатьчә нигезләүнең тормышчанлыгына, универсальлегенә омтылды. Ф. Әмирхан повестеның баш герое Хәят тормышындагы барлык борылышлар күңелендә туган үзгәрешләр нәтиҗәсендә барлыкка килә. Пушкин, Лермонтов, Гоголь, Толстой, Достоевский, Тургенев каһарманнары, бер сыйныфтан булсалар да, характер-холыкларына карап, төрлечә фикер йөртәләр, төрлечә хис итәләр һәм эш-гамәлләре белән бер-берсеннән шактый аерылалар. Алар хәтта, автор ихтыярыннан тыш, күпмедер дәрәҗәдә мөстәкыйль тормыш белән яшиләр, кайчак хәтта хәвефле адым да атлап куялар. Бу хакта Пушкин, Л. Толстой, Короленко, А. Толстой һәм башка әдипләр язып чыктылар.

Ф. Энгельс 1888 елда М. Гарнесска җибәргән мәгълүм хатында реализмның өч билгесен күрсәтеп китә: беренчедән, ул типик характерларны дөрес итеп сурәтләүне, икенчедән, аларны типик хәлләргә куеп яктыртуны, өченчедән, детальләр дөреслеген күздә тота. Мәгърифәтчелек реализмы образларны башлыча аң-белем ноктасыннан карап яктыртканлыктан, каһарман яшәешендәге башка яклар искә алынмаганлыктан, бу ысулда әлеге сыйфатлар тулы күләмендә күренми, анда әле характерларга да, тормыш күренешләренә дә кайчак типиклык житеп бетми. Димәк, ул билгеләр, барыннан да бигрәк, житлеккән реализмның табигатен ачыклый булып чыга, ягъни бу ысул әсәрләрендә персонажлар теге яки бу катлам кешеләренә, профессия, белем ияләренә, яшь аермасына аеруча хас булган холык-гамәлләрне, тойгы-омтылышларны гәүдәләндерәләр. Шул ук вакытта алар кабатланмас индивидуаль шәхесләр, җанлы кешеләр булып күз алдына килеп басалар, тормышның теге яки бу тармагына хас иң характерлы, шул ук вакытта үзенчәлекле шартларда яшиләр. Автор хәтта сурәтләү чараларын, детальләрне кулланганда да чынлыкка, дөреслеккә хилафлык китермәскә

омтыла. Ләкин болар гына да әле житлеккән реализмның йөзен тулысынча сыйфатлап бетерә алмыйлар. Моңа тагын әле бик мөһим дүртенче билге — төзү материалының — телнең типиклыгы өстәлә. Классицизм каһарманнары, алдарак күреп үткәнчә, нигездә бер стильдә, салон теле белән сөйләшәләр иде. Моннан үзгә буларак, Ш. Камалның «Хажи әфәнде өйләнә», «Акчарлаклар», Ф. Әмирханның «Хәят», «Фәтхулла хәзрәт», Г. Камалның «Банкрот», «Беренче театр» әсәрендә һәр персонаж характерына ятышлы үзенчәлекле, шул ук вакытта типик, төгәл тел белән сөйләшә, барысы бергә милли телнең бик күптөрле төсмерләрен, бизәкләрен чагылдыра.

Совет әдәбият белемендә «критик реализм»ны тагын да югарырак ысул — **«социалистик реализм»** алыштыра дигән фикер ныклап урнашкан иде. Исеменнән үк күренгәнчә, бу методның күз карашы социализм җәмгыятенә төбәлгән, ягъни ул социализм дөреслеген яктыртуны вәгъдә итте. Хуш, бу чынбарлык нәрсәдән гыйбарәт иде соң? Социалистик борылышка әзерлек елларында большевиклар карап торышка бик кешелекле лозунглар күтәреп чыктылар: җир, азатлык, тигезлек, тынычлык вәгъдә иттеләр. Шулар белән алар халыкны революция эшенә җәлеп итә алдылар. Әдәбият, сәнгать тә шул идеяләр белән рухланды. Ләкин чынлыкта тигезлек дигәне җәмгыять членнарының күпчелеген, һәрхәлдә, җитәкчелектә булмаганнарын, ярлылык ягыннан тигезләү булып чыкты, рәсми документларда, әсәрләрдә фәкыйрьлек озак вакытлар буена горурлык күрсәткече дип саналды. Ярлылыкны тотрыклы саклау юнәлешендә җәмгыять дөнья күләмендә сизелерлек уңышларга иреште. Тигезләү мөлкәтне тартып алу, талау юлы белән барды. Нәтиҗәдә, тынычлык урынына, гражданнар сугышы кабынып китте. Авыл кешеләре җирдән мәхрүм калдылар, азатлык урынына партия, хакимият диктатурасы урнашты.

Болар иҗади илһамлану, дәртләнү өчен бәрәкәтле җирлек түгел иде, әлбәттә. Әмма, таш арасыннан шытып чыккан үсемлек кебек, талант та үзенә юл ярырга тырышты. Утызынчы еллар башында совет әдәбиятының иҗат методы «социалистик реализм» дип игълан ителде, аның норматив эстетикасы эшләнде. Гәрчә иҗат тибының асылын төсмерләгәндәй фикерләр Аристотельдә үк күренә башласа, элекке дәверләрдә кол биләүчелек, феодализм, капитализм реализмы төшенчәләре булмады. Иҗат ысулының хасиятен җәмгыять исеме белән билгеләүне без совет чорында гына очратабыз. Әдәбиятның офыгы социалистик чынбарлык, коммунистик идеология белән чикләнде. Тарихи тематикадан искене яманлау, сыйнфый бәрелеш, сугыш күренешләрен, диктатор патшаларны, империя төзүчеләрне генә сурәтләү хупланды. Хәятнең башка төбәкләренә ныклы йозак салынды. Шуңа охшаш хәлләр турында Бомарше персонажы Фигаро бер монологында болай дип сөйли: «Казна икмәген ашап ятканда, диделәр миңа, Мадридта теләсә нинди әйберләрне, хәтта матбугат әйберләрен дә ирекле сату хокукы бирелде. Үземнең мәкаләләрдә минем бары тик хакимияткә, дингә, сәясәткә, әхлаклылыкка, дәүләт эшендәге кешеләргә, ышанычлы корпорацияләргә, Опера театрына һәм гомумән башка театрларга, шулай ук нәрсәгә дә булса мөнәсәбәте булган кешеләргә генә кагылырга хакым юк икән,— ә калган барлык әйберләр турында ике-өч цензор күзәтүе астында иркенләп яза алам икән».

Бу сүзләр ике гасыр элек совет әдәбияты турында әйтелгән кебек яңгырый. Аның сулышы ни дәрәҗәдә кысылган булуы Гаяз Исхакый иҗаты фонында ачык сизелә. Чит җирдә яшәгән бөек язучы, фидакарь көрәшче әдәби һәм публицистик әсәрләрендә үзе кирәкле, әһәмиятле дип тапкан барлык темаларны иркенләп яктыртты, татар милләтенең элекке һәм хәзерге тормышының бик күп, мөһим тармакларына сәнгать нуры төшерде. Ил эчендә калганнар исә алар хакында уйларга да базмыйлар иде. Хакимиятнең зур масштабта золым кылырга хакы булса да, әдәбиятның аны күрсәтергә хокукы юк иде.

Рөхсәт ителгән олы иҗтимагый күренешләр дә тик бер төрле — хакимият бәясе яктылыгында гына бәян ителде. Шуңа күрә гражданнар сугышының нилектән килеп чыгу сәбәпләре ачылмады, кызыллар көрәше тик романтик төсләргә манып тасвирланды. Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романында данлыклы ишанны шул болгавыр елларда бер гаепсезгә, тик абруйлы, тирә-юньдә йогынтылы булганы өчен генә кызылларның судсыз-нисез атып китүе сурәтләнә һәм шуннан соң, кансызлыкны аклагандай, кануннан маддәләр эзләп торырга вакыт юк иде, рәвешендәге аңлатма бирелә. Совет власте, миллионнарга җәбер-золым чәчеп йөрсә дә, мәсләге гадел булмаганлыктан, түшәк өстендә яткан рухани затның абруеннан да шүрли иде. Революция юлы белән дәүләт төзелешен үзгәртүне, сыйныфлар бәрелешен, көч ярдәмендә хакимияткә үрләүне максат итеп куйган коммунистик сәясәт әдәбияттан әнә шул рәвешчә гуманизмны кысырыклап чыгарды.

Устав язучылардан тормышны революцион үсештә яктыртуны таләп итте, ягъни аны хәрәкәттә чагылдырырга киңәш итте. Бу мәсьәләдә менә нәрсәне искәртеп үтәсе килә. Чынбарлыкны үз рәвешендә, агымда сурәтләү һич тә социалистик реализмга гына хас күренеш түгел. Рәсем, сынлы сәнгатьтән аермалы буларак, бер әдәби ысул да яшәешне тик тору хәлендә күрсәтми. Һәммәсе дә аны, хәятның үзенә хас булганча, динамикада, процесста чагылдыра. Асылда әлеге киңәш язучының төп игътибарын «коммунистик яралгылар»га туплауны, аларны инде яралгы хәлендә итеп түгел, киң таралган типик күренеш итеп гәүдәләндерүне аңлатты, ягъни ул да чынбарлыктан читләшүнең, нормативлыкның бер чагылышы иде. Шуңа нигезләнеп әсәрләрнең түренә уңай геройлар, аеруча коммунист житәкчеләр менеп кунаклады. Шулай итеп, социалистик реализм эстетикасы бик гади схемага корылган иде: совет әдәбиятына ул хуплау вазифасын йөкләде, житлеккән реализм өлешенә кимчелекләрне сурәтләү бурычы калды, берсе — мактаучы, икенчесе — тиргәүче ысул итеп күрсәтелде. Социалистик реализмда барлык әсәрләр тик бер карашны — коммунистик идеяне расларга, әдәбият үзе дә, кешеләр кебек, партияле булырга тиеш иде.

Төрле характердагы чикләүләр әдәбиятның сулышын кыса, табигый үсешен тоткарлый иде. Сәнгать тарихында социалистик реализм бер урында таптану гына түгел, мәгълүм дәрәҗәдә чигенеш тә булды. Ул кешелекнең бик мөһим, житди кыйммәтләреннән баш тартты, аларны санга сукмады, сәнгать әһелләрен дә шуңа өндәде.

Шулай да, совет чорында язылган әсәрләр нинди иде? Аларга карата нинди бәя гадел булачак? Иң әүвәл бу дәвер, электәге кебек, бик зур талант ияләренең исемнәре белән бәйләнгән. Совет чорында М. Шолохов «Тын Дон», М. Ауэзов «Абай», Ч. Айтматов «Гасырдан озын көн», И. Гази «Онытылмас еллар», Ф. Хөсни «Йөзек кашы», «Җәяүле кеше сукмагы», Г. Бәширов «Туган ягым — яшел бишек», Ә. Еники «Әйтелмәгән васыять», «Гөләндәм туташ хатирәсе», Н. Фәттах «Итил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар» исемле повесть, романнарын, А. Твардовский, Ф. Бурнаш, Һ. Такташ, М. Җәлил, С. Хәким, Х. Туфан, Н. Исәнбәт, Т. Миңнуллин матур-матур поэтик, драматик әсәрләр яздылар. Аларның һәм тагын шундый бик күп гүзәл әсәрләрне рухи тарихыбыздан сызып ташларга берәүнең дә кулы күтәрелмәс дип уйларга кирәк.

Хәзер безнең әдәбиятта житлеккән реализмның өзелеп торган буынын ялгап җибәрү, азат рух белән аны дәвам иттерү омтылышы сизелә башлады. Шушы арада, мәсәлән, Р. Батулла «Сөембикә» романын бастырып чыгарды. Кереш сүзендә автор бу темага ничек курка-өркә тотынуы турында искәртеп үтә. Әдип Сөембикә образына соңгы вакытта иҗтимагый карашларның үзгәрүе жирлегендә мөрәҗәгать итте һәм гүзәл ханбикәгә лаеклы бик матур әсәр язды. Халкыбызның ерак тарихында күңелдә ихлас горурлык хисләре уятырдай андый асыл затлар хәтсез җыела.

Әгәр дә без элегрәк язылган әсәрләрдән М. Гафуриның «Ачлык тырнагында», Г. Ибраһимовның «Адәмнәр», Ә. Еникинең «Саз чәчәге», «Рәшә», «Әйтелмәгән васыять», Н. Фәттахның «Артта калган юллар», «Кичү», С. Батталның «Сигезенчесе кем?», «Батый ханга ачык хат» кебек әсәрләренә текәлебрәк карасак, без аларның социалистик реализм кысаларыннан шактый чыгып торганлыгын, мәгълүм дәрәҗәдә әлеге житлеккән реализм рухына тартым булганлыгын күрербез. Үз вакытында аларның усал тәнкыйтькә юлыгуы да нәкъ шул хакта сөйли булса кирәк. Хикмәт монда гына да түгел, әлбәттә. Аларның житлеккән реализмга якынлыгы, барыннан да бигрәк, югары сәнгатьлелегендә күренә. Гәрчә совет чорында күп кенә әйбәт әсәрләр язылса да, социалистик реализм, тулаем алганда, дөнья күләмендәге житлеккән реализм үсешендә чагыштырмача зәгыйфь буын булды. Шуңа күрә ул, идеология белән бергә, үз позицияләрен бик тиз югалтты. Хәзер инде ул житлеккән реализм белән ярыша алмый. Ул аңа юл бирергә мәҗбүр. Безнең бүгенге әдәбият, шулай итеп, табигый үзәненә кайтып төшү, дөнья күләмендәге сәнгать агымына кушылу алдында тора.

Күчеш дәвере, гадәттә, үзе белән кайбер югалтулар да алып килә. Әгәр дә буа ерылса, ташкын белән бергә чүп-чарлар, балчык, ташлар да агып китә, суы болгана. Шуның кебек, сәнгатьчә иркенлек шартларында кайбер елгыр каләм ияләре язмаларының тематик затлылыгы белән мөхәррирләр, укучылар күзен камаштырмакчы булалар, тәнкыйть хезмәтләреннән күренгәнчә, карапама хәлендәге чи әйберләрен газета-журналларда бастырып чыгаралар. Андыйларның бер ысул белән дә алыш-биреше, уртаклыгы юк, әлбәттә. Сәнгать тарихында халтура методы дигән ысул туганы юк әле.

# Сөләйман Бакыргани

(?—1186)

**Сөләйман Бакыргани (Кол Сөләйман, Хәким ата) Хәрәзмдәге Бакырган дигән авылда яшәгән. Ул — Әхмәд Ясәвинең иң талантлы шәкертләреннән берсе, поэзиядә аның юлын дәвам иткән суфи шагыйрь.**

**Шигырьләре элек-электән Идел буенда кульязма күчермәләр рәвешендә халык кулында йөргән, шушы төбәктә аерым бер җыентыкка тупланган. 1846 елда ул җыентык, «Бакырган» исемле китап рәвешендә, Казанда басылып чыга. Шуннан соң да күп мәртәбәләр (ел саен диярлек) басылган.**

**Күренекле төрек галиме Фуад Күпрелезадә раславынча, Сөләйман Бакыргани әсәрләре Идел буенда гына сакланып калган, башка төбәкләргә соңгы гасырларда гына шуннан кабат таралган.**

* * *

Сәнең дәрдең бәңа дәрмандин артык ,
Сәңа кол булганым — солтандин артык!

Сәнең йадыңны әйсәм чүл эчендә,
Булыр ул чүл бәңа бостандин артык.

Сәнең йадың әгәр китсә телемдин,
Вөҗүдем корыгыр вәйрандин артык.

Мәнең хур булышым — үз гъәфләтемдин,
Мәгәр кыйлсаң нәзар — ихсандин артык.

Гъәзиз-хур кыйлгучы солтан сән үксән,
Сәнең лотфың камуг әлуандин артык.

Нә хуш бу дөнйада иман вә Къөрьан!
Нә булгай дөнйада имандин артык!

Мәнем бу дәрдем һич кемсә белмәс,
Әгәр белсә — Хәким Локмандин артык!

Бу йаңлыг гасый икән Кол Сөләйман,
Гъинайәт үмәнүр барындин артык.

---

Бәңа — миңа. Йадыңны — биредә: исемене. Бостан — бакча. Вөҗүдем — барлыгым, күңелем. Вәйран — хәрабә, җимерек. Гъәфләт — гамьсезлек, ваемсызлык. Нәзар — күз салу. Ихсан — изгелек. Лотфың — яхшылыгың. Камуг — барлык. Әлуандин — төстән. Бу йаңлыг — шуның кебек. Гасый — гөнаһлы. Гъинайәт — ярдәм, кайгыртучанлык. Үмәнүр — өмет итәр.

* * *

Мәнем жаным сәнең гъишкын беләдүр.
Тәнем гажиз, вәли жаным әүлядүр.

Бу гъишык гәр булмаса ниткәй ирдем?—
Камуг «аһ»ым мәнем гъишкым кыйладур.

Зиһи хәл(е), зиһи хәл(е), зиһи хәл:
Мән йыгларман, һәммә галәм көләдүр.

Гашикъдин сормаңыз дөнйа вә гъәкбе—
Гашикъ мәгъшук өчен һәр дәм үләдүр.

Гашикъны көйдерүр гъишык уты.
Гашикълар гъишык утынга мөбтәлядүр.

Мәнем сән бакмагыл бу сурәтемгә—
Йөрәгем кан булуб, бәгърем суладур.

Айырды гъишык мәне хили хизземдән—
Күзем йәше акыб, мәңзем суладур.

Күрең нә хәлгә төште Кол Сөләйман:
Камуг гъишкым мәнем рәнҗем беләдүр.

* * *

Гашикъ булур ул кеше, тиксә гъишык сайасе.
Рәнҗү берлә михнәт ул гашикъка гъишкъ дайасе.

Йул озакдур, төн катыг, кылгыл жаныңны сатыг,
Төбсез диңгездүр, батыг мәхәббәтнең дәрйасы.

Кирәк ирсә гәүһәр-дәр, жандин кичеб къәдәм ор.
Җандин куркъсаң, йырак тор,— хазирдер вакыт иләсе.

Хазир торган вакът улур һәм бәхт, дәүләт улур,
Дәргяһыңа тәхет улур — төшсә нәзар кимәсе.

Хазир торган корылур, гъәиб хазир күренүр,
Сәгадәткә үрелүр һәм дин вә һәм дөнйасы.

........................................

Сән белерсән, илаһым: эчкә тулды мең «аһ»ым,
Кол Сөләйман гөнаһым — йукдур хәтта кыйасы.

---

Вәли — ләкин. Әүлядүр — өстендер, бөектер. Гәр — әгәр. Ниткәй ирдем — нишләр идем. Зиһи — нинди яхшы. Гъәкбе — бирелә: теге дөнья. Дәм — бик кыска вакыт, мизгел. Мөбтәлядүр — дучардыр. Хили хизземдән — байтак әлешеннән. Мәңзем — йөзем. Рәнҗем — авыртуым, сагышым.

Сайасе — күләгәсе. Дайасе — тәрбиячесе, сөт анасы. Батыг — батарлык. Дәр — энҗе. Къәдәм ор — аяк бас, юлга чык. Улур — бирелә: «булыр», «табар» мәгънәсендә. Дәргяһ — ишек төбе, бусага. Нәзар — караш, уй. Кимә — көймә. Гъәиб — күзгә күренми торган. Кыйасы — тиңе, охшашы.

# РИЗАЭТДИН БИНЕ ФӘХРЕТДИН ХАТЛАРЫ



Халкыбызның мәшһүр галиме һәм талантлы журналисты буларак, Р. Фәхретдинев, бәрәкәтле гомерендә күп шәхесләр белән таныш булып, алар белән даими элемтәдә торган. Галимнең кызлары Зәйнәп (1894—1985) һәм Әсма (1906—1993) апа Шәрәфнең сүзләренә караганда, әткәләре көн саен дистәләгән хатка җавап язган, кайбер вакытларда исә адреслар язу хәстәрлеген кызларына да тапшырган. Риза казый гарәп укымышлылары белән генә чикләнмәстән, Финляндия, Франция, Германия, Испания, Кытай, Япония, хәтта Канада һәм АКШта яшәүче галимнәр-зыялылар белән дә бәйләнештә булган.

Күптән түгел миңа Р. Фәхретдиневнең 1909—1929 елларда якын дусты Габдрахман Гомәригә язган хатлары[1] белән танышырга насыйп булды.

Хатлардан бу ике кеше арасында фикер һәм көрәш берлеге нигезендә бик җылы мөнәсәбәт, эчкерсез дуслык, үзара самими ихтирам яшәгәнлеген күрү читен түгел.

Кыскача гына ачыклыйк: кем булган соң ул Габдрахман Гомәри?

Г. Гомәри — мәгърифәтче, педагог, нашир, мөхәррир, матбагачы, җәмәгать эшлеклесе, ислам дине галиме; 1867 елның 6 гыйнварында Әстерхан шәһәрендә бакчачы Исмәгыйль абзый һәм Рәхилә апа гаиләсендә дөньяга килә[2]. Биш яшьтән мәктәпкә йөри башлый, башлангыч белемне Әстерханда ала. 1881—1889 елларда Казанда, ул заманда иң яхшылардан саналган Ш. Мәрҗани мәдрәсәсендә укый (1875 елда ачылган, Казанның хәзерге Зәйни Солтанов урамы, 6 йорт). Мәрҗани шәкертләргә тарихтан, географиядән, астрономиядән, математика һәм әдәбияттан үзе мәгълүматлар бирә[3]. Табигый сәләте, тырышлыгы, эш сөюе белән Габдрахман мәдрәсәдә тиз танылa. Унсигез яшь тулганда ул гарәп, фарсы һәм төрек телләрендә сөйләшергә өйрәнә. Хәлфәлек эшчәнлеген Г. Гомәри Ш. Мәрҗани мәдрәсәсендә башлый. 1893—1908 елларда Әстерханда, мәдәниятебезгә Зәйни Солтанов (1892—1952), Мәрзия Даутова (1895—1962), Габдрахман Минский (1906—1983) кебек күренекле эшлекләләр биргән Тияк бистәсендә, үзе төзегән «Мәдрәсәи Низамия»дә эшен

---

[1] 24 хат, 3 кушымтаны эченә алган җыентыкны Габдрахман Гомәринең Владимир өлкәсендә яшәгән уртанчы улы Габделхәмит ага (1905—1989) 1970 еллар азагында Уфага юллады. Мәҗмуга 68 сәхифәдән гыйбарәт. Яхшы кәгазьдә, гарәп хәрефләре белән ачык, зур осталык һәм зәвекъ белән матур итеп язылган алар, кайбер искәрмә-аңлатмалар да бирелгән. *(Равил Үтәбай-Кәрими искәрмәсе.)*

[2] Гомәринең туган елы ялгыш күрсәтелгән чыганаклар да очраштыргалый. **Карагыз:** Каримуллин А. Г., «Татарская книга начала XX века», Казан, Таткитнәшр. 1974, 176 б.

[3] Абдуллин Я. Г. Татар мәгърифәтчелегендә мәктәпләргә реформа мәсьәләсе.— «Совет мәктәбе», 1974, № 1, 54 б.

уңышлы дәвам иттерә. Ул шәкертләргә төпле белем бирүгә зур көч сала. Хәлфәлек белән шөгыльләнү өстенә, Гомәри тәрбияче вазифасын да үти, дәрестән тыш вакытта укучылар белән өстәмә эшли, яшьләрдә уңай сыйфатлар тәрбияләргә тырыша. Авыр шартларда Гомәригә мәдрәсәне саклап калырга, патшаның урыслаштыру сәясәтенә юл куймаска тырыша.

Г. Гомәри турында фикер йөрткәндә, аның укыту эшчәнлеген һәм оештыру хезмәтләрен искә алу белән генә чикләнү һич тә дөрес булмас, чөнки заманында ул үзен галим итеп тә таныткан шәхес. Остазлык эшендә дәреслекләр һәм уку әсбаплары житешмәүне күреп, Г. Гомәри гарәп теленең морфологиясе һәм синтаксисе турында китаплар яза. (Алар 1917 елга кадәр тугыз тапкыр басылган). Гарәп теле грамматикасы буенча саф гарәп телендә XIII гасырда төзелгән бик атаклы «Кафия» исемле хезмәтне киң аңлатмасы белән татар телендә Г. Гомәри чыгара. Аның бу хезмәтләре, беренче нәүбәттә, шул вакытның татар мәктәпләре ихтыяжын күздә тотып язылган. Ул төзегән китаплар белән әллә ничә буын шәкертләре шөгыльләнә.

Г. Гомәринең педагогик һәм журналистик, җәмәгать эшчәнлеге бигрәк тә 1905 елгы революциядән соң активлаша. 1907 елда Габдрахман Гомәри Әстерхан шәһәрендә, берничә кешене оештырып, уртак татар матбагасын нигезли. Анда 1908—1914 елларда, академик Ә. Г. Кәримуллин исәпләүләре буенча, 123425 данә китап һәм байтак татарча гәзит-журналлар басыла[1]. Шушы елларда Г. Гомәри тарафыннан нәшер кылынган «Нугай җырлары» җыентыгы безнең көннәрдә дә әһәмиятен югалтмаган.

Шул ук 1907 елдан башлап Әстерханда Г. Гомәри нәшир-мөхәррирлегендә «Идел» исемле гәзит чыга башлый. 1910 елның җәендә мәшһүр шагыйрь Сәгыйть Рәмиевне Әстерханга гәзитнең секретаре итеп чакырып китерү дә очраклы хәл түгел, әлбәттә. Бу вакытта Әстерханда табиб һәм язучы Нәриман Нәриманов (1871—1925) сөргендә була. С. Рәмиев аның белән танышып, каләмдәше эшчәнлеген киң таныта. «Идел» сәхифәләрендә 1913 елның 16 июлендә (№ 571) «Доктор Нәриман бәк Нәримановны озату мәрәсиме» исемле мәкалә дә бастыра. Хәер, С. Рәмиевнең «Хөсәен Ямашевнең вафаты» (20. III. 1912. № 437), «Рәсми татар артисты» (24. IV. 1912. № 447), «Тукаев үлгән» (5. IV. 1913. № 542) мәкаләләре дә «Идел»нең сәяси юнәлешен, йөзен ачык күрсәтә. Гәзит полиция күзәтүенә алына, Г. Гомәри, С. Рәмиев фатирларында тентүләр үткәрелә, алар турында төрле җирләрдән өстәмә мәгълүматлар туплана, эзәрлекләүләр гадәти хәлгә әверелә. Гәзит патша хакимиятләре тарафыннан 1914 елда гыйнварның 27 сеннән бөтенләй туктатыла, Г. Гомәри һәм С. Рәмиевкә патша хөкүмәте сәяси ышанычсызлык күрсәтә, алар кулга алынып, Әстерханнан эчке Русиягә сөреләләр. Г. Гомәригә сөрген вакыты 4 ел микъдарында билгеләнә. Хак, моннан соң да аны эзәрлекләүдән туктамыйлар. Ул Әстерханга 1917 елның апрель урталарында гына кайта.

Г. Гомәри Русия мөселманнарының җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Ул 1917 елдан соң да яңарыш хәрәкәтенең үзәгендә кайный. Бик борынгы (XIII гасыр), «Хәзрәте Госман Коръәне» дип мәшһүр булган кульязма Коръән нөсхәсен[2] 1923 елның августында Уфадан Ташкентка күчерүче өч кешелек комиссия әгъзаларының берсе булып Гомәри бара. 1926 елда (май — сентябрь), Ризаэтдин Фәхретдин житәкчелегендә, Бөтендөнья мөселманнарының Мәккә шәһәрендә үткәрелгән 1 конгрессында да катнаша. Алар икесе дә, форсаттан файдаланып, Гарәбестанның хөрмәтле вә кадерле башка урыннарын да зыярәт итәләр.

Г. Гомәри 1933 елның 17 мартында дөнья куя. Кабере Архангельск шәһәреннән 25 чакрым ераклыктагы Малые Карелы исемле урыс авылының зиратындадыр.

Габдрахман Гомәри — халкының милләтпәрвәре, заманының киң карашлы, тирән белемле кешесе. Татар халкын белемле итүгә, башка халыклар белән дуслыкны көчәйтүгә дә ул күп көч куя. Соңгы вакытта аның тормышы һәм эшчәнлеге Тәүфикъ Әйди тарафыннан киң җәмәгатьчелеккә танытылды, әмма бу эшне киләчәктә дә дәвам итү бары файдалы гына булыр иде.

Түбәндә Ризаэтдин Фәхретдиннең төрле елларда Г. Гомәригә язган берничә хаты урнаштырыла. Чор, тел үзенчәлекләрен саклау өчен хатлар үз асылына муафыйк, ягъни үзгәртүләрсез бирелде. Бу хатлар матбугат сәхифәләрендә беренче мәртәбә тәкъдим ителә.

Равил ҮТӘБӘЙ-КӘРИМИ,
Шәрекъ вә Исламият белгече.

**Борәдәр мөхтәрәм мелла Габдрахман әфәнде!**
**Әссәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.**

28 март тарихлы мәктүбеңез тәслим улынды. Хужи[1] хән исеме хакында улан фикереңез, иншаэ Аллаһ тугрыдыр. Мәктүбеңезне гайнән дәрҗ идәрем. «Шура»ны[2] һәрвакыт, дикъкать илә укыб тордыгыңызны аңлаб, мәмнүн улмакдамыз.

Бәйрүт шәһәрендә Мохасиб әл-Гариф Җәмил әл-Газим нам кемсә Кәшшафелзанунга зәйл языб, бу көн басдырмак тәдарекендә йөрдеген һәм дә соң тәснифләр

---

[1] Каримуллин А. Г. Татарская книга начала XX века. 172—177 бб.
[2] Смирнов Н. А. «Очерки истории изучения Ислама в СССР». — М., СССР ФА нәшрияте, 1954, 131—132 бб.

хакында вә мөәллифләре турысында языб йебәрүне үтенеб игълан таратдыгын гарәб матбугатында күрмешдерсез. Фазыйль Мәрҗани[3]нең матбуг китабларының җөмләсендән берәр данә ошбу әдәмгә йебәрелсә, мәшһир иләйһи хәзрәтләренең нәм вә шөһрәтләре таралуына, бәлки, сәбәб улыр иде. Бу тугрыда Казанга язарга кеше табмадым. Бу хезмәт Сезгә гаид улса кирәк. Фазыйль Мәрҗанинең тәрҗемәисене «Асарь»да[4] мөфассал яздым. Фәкать шәкертләрендән ошбу остазның мәнзиленә лаек сурәтдә хезмәт итмәдекләренә үпкә итдем. Сезнең исемеңезне хосусый сурәтдә зикер әйләдем.

Борадәр! Бән Шиһабетдин хәзрәтнең шәкердләрендән, тугрысы, нәразыймын. Бондан алмыш гыйлемләре, фазыйльләре, дөнья вә ахирәтләре илә исеменә хезмәт итмиләр, мөдафәга кыйлмыйлар. Мөхәммәд Габдәһүне[5] «Әл-Мәнар» сахибе[6] бер ялыңызы гаршеләргә чыкарды. Шиһабетдин хәзрәт шәкердләре әгәр дә иттифак вә гайрәт идәр улсалар иде, «Әл-Мәнар» сахибенең ундан бере кадәр эш күстәрмәзләр идеме? Зан идәрем, күстәрерләр иде, фәкать гайрәтләре юк, һимматләре йерендә дәгел. Бу сүзләремне якын күреб яздым. Гафу боерыңыз.

*Ризаэтдин бине Фәхретдин.*
*4 апрель, 1909 сәнә, Оренбург.*

---

**СҮЗЛЕК:** *Әссәламугаләйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ* — Сезгә тынычлык, Аллаһның рәхмәте һәм муллык булсын! (гарәпчә традицион исәнләшү гыйбарәсе); *борадәр* — дус, иптәш, ир туган; *мөхтәрәм* — хөрмәтле; *мәктүб* — хат; *тәслим* — тапшыру, бирү; *иншаэ Аллаһ* — Аллаһ теләсә, Аллаһ кушса; *гайнән* — үзгәртмичә, үзенчә; *дәрҗ* — бастыру; *мәмнүн* — шат; *нам* — исем; *кәшшафелзанди* («кәшфелзонун» шәкелендә дә кулланыла) — берәр яңа нәрсә ачучы; *зәйл* — өстәмә, кушымта, аңлатма; *тәдарек* — хәзерләү, кулга кертү; *тәсниф* — бүлекләргә аеру, сортлау; *мөәллиф* — китап язучы, төзүче; *фазыйль* — инсафлы, намуслы, гүзәл холыклы; *мәшәһүр* — «мәшһүр» сүзенең күплек сандагы шәкеле; *матбуг* — басылган; *гаид* — берәр нәрсәгә кайтучы, бәйләнешле; *асарь* — «әсәр» сүзенең күплеге; *мөфассал* — тулы, җентекле; *мәнзил* — йорт, туктап китә торган урын; *зикер* — искә алу; *наразый* — разый булмау; *мөдафәга* — саклау, каршылык күрсәтү; *мәнар* — маяк; *сахиб* — ия, юлдаш, дус; *гареш* — тәхет, күкнең иң югары катлавы; *иттифак* — бер сүздә булу, союз; *зан* — якынча гына булган уй; *һиммәт* — тырышлык, ялкынлы дәрт, теләккә омтылу.

**АҢЛАТМАЛАР:**

[1] Ж у җ и хан (1227 елда вафат) — монголларның атаклы гаскәр башлыкларыннан, Чыңгыз ханның өлкән улы, Кытай (1211—1215), Урта Азия (1219—1221) һәм Дәшти Кыпчак җирләрен басып алуда катнашкан.

[2] «Ш у р а» («Киңәш») — Оренбургта Шакир (1857—1912) һәм Закир (1859—1921) Рәмиевләр нәширлеге, Ризаэтдин Фәхретдин баш мөхәррирлегендә 1908—1918 елларда айга ике мәртәбә чыгып килгән әдәби, фәнни һәм сәяси журнал.

[3] Ш и һ а б е т д и н ибне Б а һ а в е т д и н ибне С ө б х а н ибне Г а б д е л к ә р и м  ә л - К а з а н и  ә л - М ә р җ а н и (1818—1889) — күренекле татар мәгърифәтчесе, тарихчы һәм философ галим. Ризаэтдин бине Фәхретдин 1886 елда Ш. Мәрҗани белән Казанда очрашкан, фикер алышкан, кыскасы, олы гыйлемнең озын дилбегәсен мәшһүр Мәрҗани фатихасы белән кулына алган.

[4] «А с а р ь» — Ризаэтдин бине Фәхретдин бине Сәйфетдиннең 15 кисәктән торган беренче һәм икенче томнары басмада, өченче, дүртенче һәм бишенче томнарының кульязмада сакланып калган хезмәте — тарихи чыганак.

[5] М ө х ә м м ә т  Г а б д ә һ ү (1849—1905) — гарәп Көнчыгышының мәшһүр философы, Мисырның күренекле җәмәгать эшлеклесе; әфганлы Мисыр галиме, гарәп Көнчыгышында колонизаторларга каршы көрәш идеологы, публицист Җәмалетдин Әфганинең (1839—1897) якын дусты; хезмәтләре — «Ислам хакыйкате», «Рисаләй әттәүхит» («Аллаһның берлеге турында трактат», 1897), «Тәфсирел Коръәнел хәким» («Коръән тәфсире», «Ниса» сүрәсенең 125 аятенә кадәр — 1898—1904 еллар) һ. б. Аның «Ислам вә һануту» (Закир Кадыйри тәрҗемәсе, Оренбург, 1909) һәм «Тәүхид» (Г. Буби тәрҗемәсе, Казан, 1911) исемле китаплары татар телендә дә нәшер кылынган. Әйтергә кирәк, ул Л. Н. Толстой (1828—1910) белән дә хат алышкан. Мөхәммәт габдәһү атаклы татар мәгърифәтчесе, галиме, педагогы, Уфадагы «Галия» мәдрәсәсе мөдире Зыя әл-Камалиның (1873—1942) әл-Әзһәр университетындагы сөекле остазы, хәтта әл-Камәли әтисе Җамалетдин бабай кушкан Пәрвазетдин исемен дә, М. Габдәһү киңәше буенча, Зыяэтдингә алмаштыра.

[6] «Ә л - М ә н а р» с а х и б е — Мөхәммәд Рәшид Рида (1865—1935). 1898 елда Каһирәдә нәшер кылына башлаган «Әл-Мәнар» («Маяк») журналының нигезләүчесе һәм баш мөхәррире, Мөхәммәт Габдәһүнең турылыклы шәкерте вә тәрҗемәи хәлен төзүче, заманының мәшһүр җәмәгать эшлеклесе, гарәп халкының милли мөстәкыйльлеге өчен көрәш тарафдары.

**Сезгә сәлам мәнсүб тәблигъ итәмез. Үземез бер хальдә сәламәт көн уздырамыз...**

**Хәерле мосыйбәт булсын[1], хәсрәтеңезгә иштирак итәмез вә бәрабәрендә охрави — доньяви сәваблар булуына Хак тәгаләдән телимез. Сабырлы булыңыз, җәсарәтләреңезне гаиб итмәңез. Иншаә Аллаһ, гакыйбәте хәерле булыр... Һәрбер милләт хадимләренең юллары ошбу рәвешдә бер юлдыр.**

**Сезгә һәрвакыт хәер-хаһ[2] Ризаэтдин бине**

**Фәхретдин.**
**31 гыйнвар, 1914 сәнә, Оренбург.**

---

**СҮЗЛЕК:** *җәнаб* — олылау сүзе; *мәнсүб* — бер нәрсәгә караган; *тәблигъ* — ирештерү, хәбәр итү; *мосыйбәт* — бәла, хәсрәт; *иштирак* — катнашу, уртак булу; *бәрабәр* — бертигез; *охрави* — мәңгелек, ахирәткә бәйләнешле; *сәваб* — әҗер, изге эш; *сәваб* — турылык, дөреслек; *җәсарәт* — батырлык, кыюлык, йөрәклелек; *гаиб* — күз алдыннан югалучы; *гакыйбәт* — ахыр, эшнең соңы, нәтиҗәсе; *хадим* — хезмәтче; *хәер-хаһ* — теләктәш; *сәнә* — ел.

**Аңлатмалар:**

[1] Урыс патшасы хөкүмәте татар мәгърифәтчелеге, мәгарифе өлкәсендәге һәр алдынгы күренешкә аяк чалып килде, халкыбыз мәгърифәтчеләренең эшчәнлегендә җимерү эшләре, царизмга каршы көрәш күрде. Кадимчеләрнең һәм урыс карагруһчыларының вакытлы матбугатында халкыбызның алдынгы карашлы вәкилләренә каршы пычрак ату башланды.

[2] 1914 елның башында Габдрахман бине Исмәгыйль бине Гомәри дә кулга алынып, 4 ел Әстерхан шәһәреннән сөрелә. Хат шушы вакыйга мөнәсәбәте илә язылган.

Габдрахман Гомәри Ризаэтдин Фәхретдиннән алынган хатның, ягъни шул ук кәгазь битенең аскы өлешенә: «1914 сәнә Казанга мәнфи булып барганда дуслардан алынган беренче мәктүб», — дип язган, могтәбәр зат Ризаэтдин бине Фәхретдиннең чын, эчкерсез, ихлас дус икәнлеген изһар кылган.

***Фазыйләтле мелла Габдрахман әфәнде!***
***Әссәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.***

**Моннан өч-дүрт көн мөкаддәм язган мәктүбемдә, үз исеменә йебәрелгән бер йөз илле мең сум акчаңызның табшырылмаганлыгыны языб, почтага заявление бирүеңезне мөнасиб күргән идем. Ошбу көн ике кисәк мәктүбеңез берлә шул бер йөз илле мең сум әманәтеңезне сәламәт алдым. Сезгә бик рәхмәт... Хәтереңезгә алуыңыз өчен тәкърар вә тәкърар догалар кыйламыз.**

**Дөрест, мөфтинең интикале[1] барымызга да авыр тәэсир итде, әгәр дә форсәт вә фәраванчылык вакытлар, матбуг вә матбугатымыз эшләб торган чаклар булса иде, бу хадисә айлар вә елларга сузылыб бәхәс ителер вә хасыять изһар кылыныр иде, мәгәр дә һәркем нәфес-нәфес, диб мәшгуль булганлыкыннан шул хәлдә үтеб барадыр. Казаннан язылган бер мәктүбдә генә: «Тәрҗемәи хәле тәртиб ителү хакында мөзакәрә барадыр» — диб язылган иде. Бәлки, үзенең хәвас әхбабы вә әсхабы бу эшне мәйданга куярлар.**

**Вологдага йебәреб кайтарылуы[2] истисна кыйлынганнан соң бу кеше инде бу мәмләкәтнең генә түгел, бәлкә бик күб ислам мәмләкәтенең бәхетле голямаларыннан булды. Һәркем диярлек үзенә мөхлис булды. Мелла Габдуллаларыннан башлаб, байгураларына кадәр үзенә ярдәм итеб, ихтирам кыйлыб тордылар вә иң ахыр гомерендә үз мәмләкәтемезгә нисбәт берлә югары урын булган мөфтилек мәнсабендә утырттылар. Курсави[3] вә Мәрҗаниләрнең (Рәхим Алла) дәрәҗәләре хәвас вә бәгъзе бер әгъния кашында дөрест танылган булса да, үз гомерләрендә моннарны гомуми рәвештә таный алмадылар. Мәрҗани хәзрәтләренең хәвас түгел, хәтта гавәм халыклардан шикаять итеб, Хөсәен Фәйзханига[4] язган мөәссир мәктүбләрене укыганым бар.**

**«Мәрҗани» исемле әсәр[5] басылыб таралгандан бирле: «һәй, бу нөсхәне Мәрҗани хәзрәтләре үзе күреб укыса иде, Габделхәмид әл-Мөслими[6] берлә Хөсәен Фәйзхани вә шунарның әкъраннары вә фикердәшләре күрсә иде!» — диб хыяллинам, вә Мәрҗани дә Аллаһе тәгалә хәзрәтенә шөкер итү йөзеннән: «Илаһым! Һәммә күргән мәшәкъкатьләренә риза булдым, һичкемгә рәнҗемим вә һәммәсеннән кичдем, хакымны хәләл кыйлдым, мине шушындый бер хәл өчен хәзерләгәнсең икән!» — диб, башыны сәҗдәгә куеб, игълан идер диб уйланам. Бик күб тәэлифләрдән риза булмаганым хәлдә, ни өчендер, шушы «Мәрҗани»**

**китабыңдан ризамын, тора торгач, алыб, бер урныңдан укырга керешәм вә озак вакыт шуның берлә мәшгуль булыб утырам. Моны мәйданга чыгаруда Сезнең дә күб хезмәтеңез, мәдди вә мәгънәви тәэсиреңез булды. Остазның хакыны ифа итдеңез, үлгәндән соң тәкърар терелүенә сәбәб булдыңыз. Бу җәһәттән Сез үзеңез дә бәхетлесез. Әлхәмду лилләһи гали заликә, әлхәмду лилләһи гали көлли хәл...**

**Безнең тарафымызда инде катлык гаясында, хосусан, Уфа шәһәре кыйммәтчелек тугрысында нәзыйрсыз булыб китде...**

**Мөфти хәзрәтләре Казан сәүдәгәре баласы булганлыктан, ата-бабаларыңдан мирас булыб калган истигъдады сәбәбендән дөнья көтүгә вә мәгыйшәт әсбабына истихзар кыйлу вә истикъбалене тәэмин итүгә маһир иде. Йосыф ахун[7] мәхәлләсендә имамәт кыйлганлыгыңданмы вә янә шуның сохбәте тәэсире берләме (Мәрҗани хәзрәт тәгъриф иткән), Сәгыйть хәзрәт балаларыңданмы — мәдар ысулыңдан да хәбәрдар булыб, хәтта боңа гасабә булган иде. Шул сәбәбдән бу кыш ачлыгыңдан мәшәкать күрмәде вә күрәчәк дә түгел иде. Шәкердләре вә мөридләре күб булуның да бу көндә мәнфәгатене күргән иде... Безнең үземездә мәгыйшәт гыйлеме вә гамәле нәкыйс булганлыкдин фәраван елларда моның зарарыны күрмәгән булсак да, буел авырлыгыны күрдек вә күреб киләмез. Бу көнгә килеб йетү өмидемез юк иде, җан биргәненә Аллаһе тәгалә юнь биргәнлегендән, инде бу көнгә килеб ирешдек. Аллаһе тәгаләгә мең-мең шөкер...**

**Монда американларның «Җәмгыяте хәйрия»ләре декабрь унбишләрендән игътибарән ашханәләр ачдылар. Унсигез яшьдән түбән балалар, йөкле хатыннар вә бала имезүчеләр шунда ашыйлар... «Ара» исемендә булган бу җәмгыятьнең[8] Уфа комиссиясенә нәзарәт[9] тарафыңдан вәкил булыб Җиһангир ахун Абызгилдин[10] хезмәт итәдер...**

**Кәшшаф казый[11] Мәскәүдән кайткан иде, шушы көнләрдә... китәр...**

**Күб яздым...**

***Догачыңыз Ризаэтдин бине Фәхрелетдин.***
***18 җөмадиәлахир 1340 сәнә (14 март 1922 сәнә). Уфа, Тукай, 50.***

---

**СҮЗЛЕК:** *мөкаддәм* — алда, элек; *мөнасиб — яраклы, муафыйк, әдәпле; әманәт* — бүләк, сакларга бирелгән әйбер; *тәкърар* — кабат, күчеңү; *фәраван* — мул; *хадис* (хадисә) — вакыйга, күренеш; *изһар* — күрсәтү, ачып салу; *мөзакәрә* — фикер алышу; *хәвас* — югары сыйныф; *әхбаб* — дуслар, сөекләләр; *эсхабиялар* — хуҗалар, юлдашлар, дуслар; *истисна* — чыгарма; *мөхлис* — ихласлы; *мәнсаб* — дәүләт хезмәте; *әгъния* — бай, дәүләтле кешеләр; *гавам* — халык, кара халык; *шикаять* — зар; *мөэссир* — тәэсир итүче; *әкъран* — яшьтәшләр; *сәҗдә* — табыну; *тәэлиф* — җыйнау, төзү; *ифа* — эшне, бурычны үтәү; *кахт* — корылык аркасында иген булмау, ачлык, кытлык; *нәзыйр* — охшаш, иш, үрнәк; *истигъдад* — сәләтлелек, үткенлек; *мәгыйшәт* — көнкүреш, тормыш; *истихзар*-хәтергә төшерү; *истикъбал* — киләчәк, булачак; *сохбәт* — бераү белән сөйләшеп утыру; *тәгъриф* — таныту, аңлату; *мәдар* — үзәк, нигез, бер әйбернең әйләнү юлы; *гасабә* — кабилә, ата ягыннан булган туганнар; *нәкыйс* — ким, кыска, тулы түгел; *игътибарән* — әһәмият биреп, санга санап.

**АҢЛАТМАЛАР:**

[1] Сүз 1917 елның май аенда Мәскәүдә уздырылган Гомумрусия мөселманнарының беренче съездында мөфти итеп сайланган галим Галимҗан бине Мөхәммәтҗан әл-Барудиның (Галиевнең) 1921 елның 6 декабрь көнне вафаты хакында бара.

[2] Урыс патшасы хөкүмәте 1908 елда 1905 елгы революциягә катнашы булган адәмнәргә үч алу чараларын куллануны дәвам иттерә. 1908 елның 8 маенда Казан губернаторы, Эчке эшләр министрлыгы фәрманы белән, милли хөр фикерләр таратканнары өчен мөдәррис һәм имамнардан Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Галиевне (1857—1921), Салихҗан Мөхәммәтҗан улы Галиевне (1862—1931), Габдулла Габделкәрим улы Апанаевны (1862—1919) һәм соңрак Габделхәмит Казаковны ике елга Вологда шәһәренә сөргенгә җибәрә.

[3] Габделнасыйр әбу ән-Насыйр ибне Ибраһим ибне Иштирәк әл-Курсави (1776—1812) — татар халкының фәлсәфә галиме, 1903 елда Казанда нәшер кылынган «Әл-иршәд лил гыйбад» («Туры юлга күндерү») һ. б. әсәрләр авторы.

[4] Хөсәен Фәезханов (1828—1866) — Ш. Мәрҗанинең сөекле шәкерте, соңыннан дусты, фикердәше, Петербург университетында Шәрекъ телләре укытучысы, мәгърифәтче.

[5] «Мәрҗани» мәҗмугасе — Казан, «Мәгариф», 1915. 639 бит. Китапның 485—505 битләрендә Габдрахман Гомәринең остазы Ш. Мәрҗани хатирәсенә багышланган зур күләмле мәкаләсе урнаштырылган.

[6] Габделхәмид әл-Мөслими — «Мәрҗани» җыентыгының рецензенты. Ул озак еллар Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыткан, «Шура»да педагогик темага күпсанлы мәкаләләр бастырган.

7 Йосыф ахун — Мөхәммәт Йосыф Габсаттар улы әс-Сәгыйди әш-Ширдани (Сәгыйтов), 1909 елның 31 январендә үлгән (кайбер чыганакларга караганда, 1907 елда вафат), кадимче мулла, Фатих Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» әсәренең төп герое, прототибы. Ике сыйныфлы бәләкәй мәдрәсә тоткан. 1901 елда «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»нең (Казан, Г. Тукай урамы, 34) өч катлы бинасы Йосыф хәзрәт мәктәбе артына салынган. Хәзрәт үлгәч кенә әлеге ике сыйныфлы мәдрәсә «Мөхәммәдия»гә кушылган.

8 Хаттагы бу юллар ачлык фаҗигаләре тәэсирендә язылган.

9 Нәзарәт — патшабикә Екатерина II нең фәрманы белән 1789 елның 4 декабрендә рәсми ачылган Дини идарә. 1940 елларга кадәр «Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте» исеме белән йөртелгән.

10 Җиһангир ахун Абызгилдин — Хәйрулла Госманов (1847—1907) вафатыннан соң Уфадагы «Госмания» мәдрәсәсе (1887 елда ачылган) мөдире, публицист. Шәрекъ фәлсәфәсенә багышланган хезмәтләре дә бар. 1920—1930 елларда Уфадагы 1 санлы мәчеттә имамлык вазифасын да башкарган. 1936 елның 12 апрелендә, Ризаэтдин бине Фәхретдиннең махсус васыяте нигезендә Җ. Абызгилдин галимне дәфен кылуда актив катнашкан. Хатыны Гайшә Абызгилдинә, Фатыйма һәм Мәрьям Алкиналар шикелле, Уфада хатын-кызлар хәрәкәтен оештыручылардан. Җиһангир Абызгилдин, шәхес шөһрәте корбаны, атылырга 2 сәгать калгач, төрмәдә татар-башкорт милләтеннән булган тоткыннар өчен астрономиядән лекция сөйләгәне мәгълүм.

11 Кәшшаф казый — Кәшшаф бине Кыямәтдин Тәрҗемани (1877—1940; кайбер мәгълүматларга караганда 1943 елда вафат). Яшьлегендә Казан шәһәрендә имам 1920—1930 елларда, Р. Фәхретдиннең урынбасары сыйфатында, Диния нәзарәтендә, зур оештыру эшләре алып барган. «Госмания» мәдрәсәсендә мөселман фикъһе гыйльме (юриспруденция) мәсьәләләрен эченә алган «Кодури» буенча сабак биргән. Бик бай китапханәсе булуы мәгълүм. Кәшшаф казый — шәхес шөһрәте корбаны.

***Бисмилләһи-р-рәхманирр-рәхим.***
***Фазыйләтле борадәр мелла Габдрахман хәзрәткә, гаиләңез иттибаг кирамеңез вә әхбабыңызны ихтива сәлам мәнсүб тәблигъ итеб,— догаи утенәмез...***

**Көз көнендә бик фәна хальдә кышка кердек. Гыйнварга кадәр яшәвемезгә дә өмид калмаган иде. Бер урышга мөгаллим булыб китәргә дә хәзерләнеб йеткән вә бөтен китабымны сатарга да карар биргән идем. Ләкин Аллаһе тәгалә фазыйле вә мәрхәмәте ирешде, дуст-ишләремез генә түгел, хәтта арамызда бөтенләй галякалары булмаган кешеләр дә ярдәмегезгә йетешделәр вә бик ерак йерләрдән, хәтта чит мәмләкәтләрдән, ярдәм биреб тордылар. «Барыб йетә алмамыз»,— диб уйланган гыйнвар аендан игътибарән көнемез тәдәрреҗ берлә яхшы гына барды. Бу көн инде мәгыйшәтемез бөтенләй тәэмин ителде... Әлхәмдулилляһи... Кәшшәф казый һәмишә Мәскәүдә...**

**Бу көндә Башкортстан Уфага күчеб шөгыльләнә[1]. Башкортлар моҗәррәд хиссияткә бирелеб, кирәк түгел урында үзләре өчен мөфти вә казыйлар сайлаганнар иде[2]. Инде ул мөфтиләре вә казыйлары да монда күчсә кирәк. Башкордлар вә гомумән мөселманнар ач вә ялангачлыкдан ифрат дәрәҗәдә кырылдылар. Хәтта Ислам гонсыры инкыйразга очрады диярга лаек бер хәлдә. Эш шулай була торыб, бер шәһәрдә ике дини мәркәз булыб яшәү вә һәрвакыт араларында рәкабәт булыб тору мөнасиб эш күрелми. Моның өчен бик борчылам. Кәшшаф казыйның булмавы да уңгайсыз. Хәзерге хәлдә нәдвә җыярга да имкян күрелми (юл йөрүләр, ашау-эчү мәсьәләләре мөшкел вә бәһале). Шулай итеб, хәйрәтдә торам. Аллаһе тәгалә инде бу эшне мөселманнар мәнфәгатенә муафыйк рәвешдә хәл кыйлсын иде. Бәлки, ахыры хәерле дә булыб, әмма әүвәлге көнләрне уздыру читен булырга охшаб торадыр. Урысларның: «Мөселманнар ачлыкдан кырылыб торалар, хәтта адәм ите ашыйлар, әмма бер шәһәрдә ике дини идарәләре шул мөселманнар елкәсендән яшиләр»,— диб сөйләүләренә түзү авыр тоела, вөҗданым газаблана. Бу хәлдә истигъзам кыйлыб чыгуны да зиһенемә сыйдыра алмыйм. Эшнең нәтиҗәсе нидән гыйбарәт булса да, иншә Аллаһ, Сезгә язармын...**

**Мәхәлләмез инде үз хәлендә дәвам итеб торадыр...**

**Үз хәлеңездән, ул тарафда булган мөселманнар хәятындан аз гына булса да язсаңыз — шәүкъ берлә укыр идек. Гыйлем берлән иштигаль кыйла аласызмы? Мин үзем инде «Әл-Бәлягуль Мөбин» не тәмам итү өстендәмен[3] Күб гомер вә күб иҗтиһад сарыф итдем, фаидә алучы булырмы-юкмы?[4] Якә фаидә алынырлык мәгънәсе күрелерме-юкмы? Моңа инде җавап бирә алмыйм. «Гыйлем өстендә үлгән кеше — шәһид» мәзмунындагы хәдискә мосаддыйк булуга таммаг йебәреб: «Барыбер үләрмен, шушы эш өстендә үлим»,— диб дәвам итдем, ашарга булмаган вакытларда да шушы эш өстендә утырган булдым[5]. Мәгәр дә китабларымның бер**

**кыйсьме таралуы эшемне авырайтды[6]. «Энә берлә кое казыдым»,— дисәм дә, дөрест. Аллага табшырдым.**

**Догаңызны үтенәм, үлсәм, онытмаңыз.**

*Ризаэтдин бине Фәхретдин.*
*1922 ел, 18 июль, Уфа, Тукай, 50.*

---

**СҮЗЛЕК:** *иттибаг* — буйсыну, ияру; *кирам* — хөрмәтле, затлы, намуслы; *ихтива* — үз эченә җыю; *мәнсуб* — бер нәрсәгә караган; *тәблигъ* — ирештерү; *фәна* — юкка чыгу, һәлакәт; *галяка* — бәйләнеш; *тәдәррежҗ* — акрынлап күтәрелү, хәрәкәт итү; *һәмишә* — һәрвакыт, өзлексез; *мөҗәррәд* — ялангач; *гонсыр* — токым, ералыш, табигать; *инкыйраз* — бетү, юкка чыгу; *мәркәз* — башкала; *рәкабәт* — көндәшлек; *мөнасиб* — яраклы; *нәдвә* — киңәшмә, җыелыш; *имкян* — мөмкинлек; *хәйрәт* — аптырау, хәйран булу, акыл җитмәү; *истигъзам* — зурайту, хәяттереклек, яшәеш, гомер, тормыш; *шәукъ* — кызыгу, дәрт, көчле теләк; *иштигаль* — шөгыльләнү; *иҗтиһад* — тырышлык; *шәһид* — хак эш өчен үлүче; *мәзмун* — эчтәлек; *мосаддыйк* — раслаучы; *таммаг* — бик теләүче; *кыйсем* — өлеш, бүлек.

## АҢЛАТМАЛАР:

[1] Бөтенрусия Үзәк Башкарма Комитетының 1922 елның 14 июнь карары нигезендә Уфа губернасы бетерелеп, җире Башкортстан республикасына кертелә, Уфа исә Башкортстан АССРның башкаласы итеп игълан ителә.

[2] «1921 елның 11 мартында Стәрлетамак өязе Аллагуват авылында Гомумбашкордстан голяма вә зыялылар нәдвәсе булып, вәкилләрнең теләве илән, Уфа Диния нәзарәтендән аерым, Башкордстан өлкәсенә бер дини идарә торгызу карарына килделәр... Бинаән галәйһи Башкордстанга мөстәкыйль дини идарә әгъзалары сайланды. Мөфти Мансур әл-Халикъ, әгъзалары Сәгыйдҗан Акбирдин, Вәлиҗан Тимербулатов, Фатих Яушевлар»...

Эшчәнлеге бөтенләй өйрәнелмәгән, Башкортстанда яшәгән мәгърифәтче Вәлиулла Рамазан улы Шонкаровның (1881—1931) бу тарихка бәйләнешле язмаларыннан... Кульъязма бездә саклана (27—28 битләр).

[3] «Ә л - Б ә л я г у л ь  М ө б и н» («Ачык ирештерү — рәүшан бәян кылу» мәгънәсендә) — мөхтәрәм Ризаэтдин бине Фәхретдиннең дөньяга мәшһүр фәлсәфи хезмәтләренең иң соңгысы. 208 битлек «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр», 552 сәхифәдән гыйбарәт «Җәвәмигуль кәлим шәрхе» 1914 һәм 1917 елларда Оренбургта нәшер кылынганнар. «Әл-Бәлягуль Мөбин» исә, ни аяныч, кулъязма рәвешендә калган. 1960 еллар уртасында миңа бу зур күләмле хезмәтнең асыл нөсхәсе белән тулысынча таныйшырга, аны җентекләп, өйрәнергә насыйп булды. Әмма Диния нәзарәтендә 23 ел дәвамында мөфти вазыйфасын башкарган Шакир Шәйхелислам улы Хәялетдиновның (1890—1947) вафатыннан соң кулъязманың төп нөсхәсе гаиб булды. Хәер, ул гынамы?! 1975—1980 елларда 40 меңнән артык китаплы нәзарәт китапханәсе тәмамә ерткычларча таланды. Кайларга гына бармадым, кемнәргә генә мөрәҗәгать итмәдем мин... Әллә нинди салкын шик-шөбһәле елмаю, мәкерле күз уйнату, каш җыеру, йөз чөеру, ниһаять, кул селтәү — шуннан башка «теләктәшлек» тапмадым. Зыя әл-Камали, Нурмөхәммәд Мамлеев, Җиһангир Абызгилдин, Габдулла Сөйләймани, Мөхлисә Бубя, Гыйниятулла Капкаев, Мөхәммәтсабир Хәсәнов китапханәләрен черетеп, машина-машина төяп, түктеләр: Ә Габдрахман Рәсүли, Кәшшаф Тәрҗемани, Ризаэтдин бине Фәхретдин (соңгысының китапханәсендә генә дә 2 меңнән артык китап) мирасына «чын хуҗалар» табылды. Моннан берничә ел элек Башкортстандагы бер әдәбиятчы галим миңа: «Сез беләсезме, Диния нәзарәтендә Р. Фәхретдиневның бик бай китапханәсе бар бит,— диде. Исең китәр бу гафләт йокысына! Әйе, беләм, ул китапларның кайберләрен хәзер мин илебезнең төрле почмакларында яшәүче, гарәп хоруфатында эш итә белүче бәндәләрдә күрәм. Шөкер, 1960 еллар башында аспирант Миркасыйм Госманов Казаннан гыйльми максатларда Уфага килеп, Диния нәзарәте архивыннан беренче булып Р. Фәхретдиннең бай мирасын казып чыгарды. Бу, һичшиксез, зур ачыш, килер буыннар моңа рәхмәт әйтер. Кыскасы, хәзер «Әл-Бәлягул Мөбин»нең 879 сәхифәлек бер күчермәсе Диния нәзарәтенең китапханәсендә булса, 4 томлык хезмәтнең[1] томы Фәннәр академиясенең Урал бүлеге Башкорт фәнни үзәге архивында сакланса кирәк.

[4] Ризаэтдин Фәхретдин үз хезмәтләрен ничек кенә булса да саклауларын, үзеннән соңгы буыннар вәкилләренә җиткерелүен тели, үтенә... Ошбу гарыз, вафатына бер ай чамасы вакыт калгач, 1936 елның 15 мартында, хезмәттәше Кәшшаф Тәрҗемани исеменә язган соңгы васыятендә аеруча инандырырлык көчтә. Васыять бездә сакланмакта.

[5] Карагыз: Гайнуллин М. Х. Татар әдәбияты. XIX йөз. Казан, Таткитнәшр., 1968, 629 б.

[6] XIX йөз татар әдәбияты. Казан, Таткитнәшр., 1985, 319—320 бб.

*Фазыйләтле мөхтәсиб, сәфәр юлдашымыз[1]*
*мелла Габдрахман хәзрәт!*
*Әссәламу галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтуһ*

**19 март тарихлы мәктүбеңезне алдым. Мәскәүгә, Мәскәүдән Казанга барыб килдек вә беркадәр эшләр артындан йөреб, Уфага кайтдык. Гомуми рәвешдә**

**хажга изен алу хакында бер нәүгъ хәрәкәтемез булуны Сезгә үземне хажга бара, диб ишетдергәнләрдер.**

**Шәкерд чагымда ике дәфга вә андан соң бер дәфга икъдам кылыб да бу эш насыйб булмаган иде. Шушы эшне, тәхсил өчен Бохарага барырга[2] диб сәфәр инша кыйлганымдан соң, юлдан кире кайтырга мәҗбүр булу вакыйгасына кушыб, үз хакымда: «Нинди генә бер зур эшне арзу кыйлсам, ул эш булмый, мәкъсудыма ирешә алмыйм икән»,— диб кагыйдә төзегән идем. Ләкин соң вакытымда хыялга килмәгән бәһанә вә хыялга килмәгән рәвеш берлә Бохара вә башка шәһәрләрдә йөреб кайтканымдан соң: «Юкса бәгъзе бер олуг эшләр дә мөясәр буладырмы?»— дигән шөбһә килә башлады. Шуның өчен: «Аллаһе тәгалә әҗәлгә сабырлык бирсә, монысына түгел, бәлки киләсе хажга икдам кыйлсам, ни булыр?»— дигән бер фикер төшде. Шушы хәлне лятыйфә тарзында сөйләгәнемдә Камал әфәнде Фәхретдин (Сезнең берлә зыяфәтенә дә бардык): «Аллаһе табшыр, хәзрәт! Ярым мәсрафың минем өстемдә!»— диде. «Ярымы түгел, зәкяте яки гошере булса да зур эш!»— дидем. Эш шушы минвәлдә.**

**Голяма шурасы вә мөхтәсибләр мәҗлесе сентябрь башларында булу фарыз ителеңдә вә рөхсәт сорау тәдарекендәдер.**

**Дини укулар хакында хөкүмәт тәдбире бу көндә Әстерханга барыб ирешкән булыр.**

**Мелла Салих[3] Истанбулга сәфәр итә икән, өч айлык мәслихәт алды. Бәлки гайддән соң сәфәр итәчәкдер.**

**Артык йомыш булмаса да, хат соравыңызга күрә яздым. Казанда Мәрҗани төрбәсенә[4] (башка мәшаһиргә дә, мисал, дамелля Галимҗан[5] Садыйк ибне Галикәй[6] вә Сөләйман Аит...[7]) зиярәт итдек, Борһан мәхдүм[8] гаиләсендә зыяфәтдә һәм булдык (Борһан мәхдүмнең киявендә).**

**Һәрхәлдә сәфәрдә күб кеше күрдем, беркадәр күңелем дә күтәрелеб кайтдым. Әлхәмдуллиһи гали залика. Моңдан соңгы халләр Аллаһы тәгаләгә мәфруз...**

***Ризаэтдин бине Фәхрелетдин.***
***1943 ел[9], 20 Рамазан әл-мөбарәк[10]. Уфа, Тукай, 50. Гайд, Инша Аллаһ, җомга көн булыр — Рузәгә чәһаршәнбә кергән идек.***

---

**СҮЗЛЕК:** *мөхтәсиб* — ислам фәлсәфәсе буенча галим; *изен* — рөхсәт; *нәүгъ* — төп, сорт, женес; *дәфга* — тапкыр, кабат; *икъдам* — тырышу; *тәхсил* — гыйлем алу; *инша* — барлыкка китерү, уйлап чыгару; *арзу* — теләк, омтылыш; *бәһанә* — гозер, ялган сәбәп; *мөяссәр* — җайлы; *ләтыйфә* — мәзәк, *тарыз* — үрнәк, рәвеш, тәртип, ысул; *зыяфәт* — кунак итү, сыйлау; *мәсраф* — чыгым; *зәкят* — сафлык, пакьлек, тазалык, сәүдәгәрләргә еллык керемнең 40 тан бере күләмендә салынган еллык салым; голяма — «галим» сүзенең күплек санда кулланылышы; *шура* — киңәш; *тәдбир* — тиешле чара; *мәслихәт* — киңәш, эшнең уңышлы барып чыгуына сәбәп булган нәрсә, рөхсәт; *гайд* — бәйрәм; *төрбә* — кабер өстенә мәетне зурлап корылган бина; *зиярәт* — күрергә бару; *мәхдүм* — хөрмәткә лаек кеше, дин башлыкларының ир балаларына бирелгән исем; *Әлхәмдуллиһ гали залика* — Аллага өзлексез бөек дан булсын (гыйбарә).

**АҢЛАТМАЛАР:**

[1] Сәфәр юлдашымыз — 1923 елның августында Ризаэтдин Фәхретдин һәм Габдрахман Гомәри әл-Хажитархани, югарыда язылганча, VIII гасыр гарәп язуының ядкәре булган хәзрәте Госман Коръәнен Төркестан вәкилләренә тапшыру өчен Урта Азиягә, хосусан, Ташкентка сәфәр кылалар. Әйтергә кирәк, Габдрахман бине Гомәринең ошбу Төркестан сәяхәте турында язылган әсәре кульязма рәвешендә сакланып калган. Бу сәфәргә, Совет хөкүмәте вәкиле буларак, язучы-журналист, Мәскәүдә Көнчыгышны өйрәнү институтында һәм Милләтләр эше халык комиссариатында эшләгән Габдулла Төхфәтулла улы Гыйсмәти (1883—1938) дә катнаша. Ул 1924 елдан Уфада бик җаваплы урыннарда хезмәт итә — Башкортстан мәгариф халык комиссары була. Кыскасы, бергә Төркестанга баруны күз уңында тотып, Р. Фәхретдин дусты Г. Гомәригә «сәфәр юлдашымыз» дип мөрәҗәгать кыла.

[2] Галимнең кызы мәрхүмә Әсма апа Шәрәф сүзләренә карагандa, Риза казый гомере буе читтә, ягъни зуррак уку йортларында укый алмавына үкенеп яшәгән.

[3] Мелла Салих — Салихҗан Мөхәммәдҗан улы Галиев (1857—1931) Казанның Яңа бистәсендәге 10 мәчет мәдрәсәсе мөдәррисе. Өлкән улы Мөхәммәд абзый Казан дәүләт педагогия институтында физика укытты. Шушы юлларның авторы Казанның 12 санлы татар урта мәктәбендә РСФСРның атказанган укытучысы Мәхмүт Салихҗан улы Галиевтән физикадән сабак алды. Әйтергә кирәк, Гомәри Салихҗан Галиев белән дә якын мөнәсәбәттә булган, аның белән элемтәдә торган. Бездә Габдрахман Гомәринең Салихҗан бине Мөхәммәтҗанга 1922 елның 1 январендә язган хатының күчермәсе саклана.

[4] Мәржани төрбәсе — Казанның Яңа бистә зыяратында, 15 юлда.
[5] Галимҗан — Галимҗан бине Мөхәммәдҗан әл-Баруди (1857—1921).
[6] Садыйк ибне Галикәй — Казан могтәбәрләреннән, Коръән-хафиз Мөхәммәдсадыйк бине Мөхәммәтсафа бине Галикәй.
[7] Сөләйман Аит — Сөләйман Мөхәммәдҗан улы Аитов (1859—1922), сәүдәгәр, 1909 елда Казанда кызлар мәктәбе ачыб укыткан мөгаллимә Фатыйха Габделвәли кызы Аитова-Яушеваның (1866—1942) ире. Бу мәктәп 1916 елда гимназиягә әверелдерелә, 1918 елга кадәр эшли. Каберләре янәшә — Яңа бистә зыярәтының үзәк юлында.
[8] Борһан мәхдүм — Ш. Мәрҗанинең улы (1854—4.III.1916), 35 ел имамлык иткән. Кабере Яңа бистәдәге зыяратның 15 юлында.
[9] 1343 ел, 20 Рамазан әл-мөбарәк 1925 елның 13 апрель көненә туры килә.
[10] Рамазан әл-мөбарәк — ай (камәри) календаре буенча 9 ай исеме. Исламда изге айларның берсе, мөселманнар бу айда рузә тота, шушы тоткан рузә кабул булсын өчен сәдака бирәләр.

*Фазыйләтле дамелля Габдрахман хәзрәтләре!*
*Әссәламу галәйкум вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтуһ*

Бу тараф бер хәлдә сәламәтлек. 9 шәһри Рамазан тарихлы мәктүбеңезне алдым. Сәламәтлек хәбәреңездән мәмнүн булдым. Аллаһы тәгалә хезмәтләреңезгә дәвам вә рәваҗ һәм дә фәрагать кылыб насыйб итсен.

Кәшшаф казый Мәскәүдә иде. Йомышыңызны «Ислам мәҗәлләсе»[1] идарәсенә табшырдым, шаяд башкарырлар.

Хөснетдин ахун, Сәхәбетдин, Морад әфәнде анасы — һәммәсе бер туган булыб, Зәйнетдин бине Габдрәшид исемле имамның балалары. Балаларның кәмаләт вә рәзаләт берлә сыйфатлануларында ана тарафындагы сәләфләрнең тәэсире галиб була, диб ишеткәнем бар. Морад әфәндедә[2] булган истигъдад вә фазыйләт ана тарафындагы галим гаиләсендән мирас булыб калган булса кирәк.

Китабыңызны[3] шушы көнләрдә, сораб алыб, уку фикерендәмен.

Артык яза алмыйм, мәгъзүрмен. Хаҗәтеңез шушы кадәре берлә, иншаэ Аллаһ, үтәлгән булыр...

Доганызны рәҗи

***Ризаэтдин бине Фәхретдин.***
***1346 ел, 18 шәһри Рамазан. Уфа[4].***

---

**СҮЗЛЕК:** *дамелля* — зур укымышлы, югары мәктәп укытучысы; *шәһри* — айга бәйләнешле, айга караган; *рамазан* — ай елының тугызынчы ае исеме; *рәваҗ* — таралу; *фәрагать* — ял итү, эштән канәгатьлек алып бушану; *мәҗәллә* — журнал, җыентык, китап; *кәмаләт* — җитешкәнлек, тулылык, өлгергәнлек; *рәзаләт* — хурлык, түбәнлек, яманлык; *сәләф* — борынгы, алдагы буын кешесе; *галиб* — җиңүче; *истигъдад* — сәләтлелек, булдыклылык; *мәгъзүр* — гозерле, гозер иясе, берәр сәбәп белән бер эшне эшли алмаучы; *рәҗи* — өмет итүче, ялваручы, үтенүче; *мәэтәмә* — конгресс.

**АҢЛАТМАЛАР:**

[1] «Ислам мәҗәлләсе» — Уфада, 1924—1927 елларда, Кәшшаф Тәрҗемани мөхәррирлеге һәм нашырлегендә айга бер мәртәбә чыккан журнал. Ислам фәлсәфәсен яктырткан мәкаләләрдән тыш, журнал сәхифәләрендә халыкара иминлек мәсьәләләре дә рәсми рәвештә яктыртылган.
[2] 1908 елда, Оренбург шәһәрендә, нәшер кылынган, 2 томлык «Тәлфик әл-әхбар вә тәлких әл-әсарь фи вакагыйк Казан вә Болгар мөлек — әт-татар» тарихи хезмәт авторы Рәмзи Морад турында фикер сөрелә булса кирәк.
[3] Г. Гомәринең «1926 елда Гомум мөселманлар мәэтәмәренә бару хатирәсе» китабы. Кульязма хәлендә калган.
[4] 1346 ел, 18 шәһри Рамазан — 1927 елның 17 мартына туры килә.

Суфиян Поварисов

# ЭНҖЕЛӘР КАЙДА ЯТА?

Фронтта миңа бик мәгълүматлы кешеләр белән бер сафта дошманга каршы көрәшергә туры килде. Инженер, математик, философ...— тагы да әллә кемнәр бар иде. Сугыш уты тынган арада, ял иткәндә, алар дөнья хәлләре, фән, үткән һәм киләчәк тормыш турында фикер алышып, кызып-кызып бәхәсләшеп тә алалар иде. Уфада Галия мәдрәсәсе тәмамлаган бер абзыйның бөтен белгәне — төрки халыклары хакында, дин турында сөйләү. Шуңа күрә мөселманнар аны «Мулла бабай» дип атады. Орел, Белград, Кременчуг тирәләрендә сугышканда, җае туры килгән саен, бу җирләрдә кайчандыр — чал тарихта — һуннар, скифлар, шумерлар, сарматлар, хазарлар, татар-монголлар, кыпчаклар булуы турында сөйләп исне китәрә иде ул.

Мин исә, чабата ясап үскән җиде сыйныф белемле авыл «өтеге», «Мулла бабайның» хикәятләрен, кем әйтмешли, авыз суларымны түгеп, колакларымны торгызып тыңлый идем. Аның сөйләвенчә, ул ыруг-кабиләләрнең барсы да заманында гаҗәп көчле, данлы булган. Ләкин тора-бара, исемнәре генә калып, җисемнәре комга сеңгән су кебек юк булган.

Аннан соң Польша, Румыния, Чехословакия, Германия, Австрия, Венгрия җирләрендә сугыштык. Барсы белән дә сөйләшәсе килә — әмма тел юк. Шулай да үземнең «крестьян тубалына» (башыма) берникадәр чит «орлыклар» салып кайту бәхетенә ирештем.

Ә сугыш беткәндә миңа егерме бер яшь тә тулмаган иде әле. Венгриядә хезмәт итә башладык. Уналты яшьлек бер мадьяр (венгр) кызы белән дуслашып алдым. Күзләр күзгә нур чәчә. Җылы карашлар бүләк итешәбез. Телләр тибрәнә, ләкин сүз чыкмый. Күп тел белгән — күп ил гизгән, диләр. Әмма без күп ил гиздек — күп тел белмәдек. Ә инде мондый очракта, шундый форсат чыгып торганда, нигә югалып калырга? Ул мине мадьярча сөйләргә өйрәтә, ә мин аны — русчага. Шулай итеп, аның да күңел сандыгына, минекенә дә моңа чаклы бөтенләй уйланылмаган, көтелмәгән, яңадан-яңа сүзләр хәзинәсе өстәлә башлады. Бәй, баксаң, бу тел, кайсы ягы беләндер, безнекенә якын икән лабаса: балта, алма, өстәл, кирәк, корым, ары...— әллә күпме сүзләр — татарныкы. Фәкать басым гына бертөрле түгел: аларда — беренче, бездә соңгы иҗеккә төшә ул.

Ни эшләп болай бу? «Мулла бабай» исән булса, аңлатып бирер иде, бәлки. Ул Днепр буенда ук гүр иясе булды шул. Мин, чокыр эчендә посып утырган караңгы авылда үскән җиде сыйныф белемле «томана» малай, ул вакытта мадьярларның ерак тарихта Урал буйларында яшәгәнлеген, сигезенче йөзләрдә көнбатышка күчеп китеп, Дунай тирәләрендәге урыннарны сайлап төпләнүләрен, боларның безгә ерак кардәш икәнлекләрен кайдан белим, ди.

Бишенче, алтынчы, җиденче сыйныфта рус, немец телләрен өйрәндек. Дәресләрне, грамматик кагыйдәләр ятлаттылар. Ә инде армиягә килгәч, үземнең русча әле юньләп ипи белән тоз сорап та ала белмәвемә әрнеп йөрдем. «Акыллы тыңлар, дурак сөйләр»,— дисәләр дә, күпме генә тыңлама, сөйләмәгәч, чит тел бик авыр бирелә икән. Рус сүзләрен дөрес әйтә алмаудан гарьләнеп йөрүемне үзем генә беләм. Ә инде немец теле турында сөйлисе дә юк!

Фронтта чуаш, якут, хакас егетләре дә бар иде. Алар да безнең кан-кардәшләр. Шулар аша мадьяр теленә килеп юлыгу, ничектер, арттырып әйтсәм, яңа

гөлбакча капкасын ачып кергән кебек булды. Сүзләрне әйтү дә, җөмлә төзү дә кыен түгел. Мин сорауларына дөрес җавап биргән саен әлеге мадьяр кызы **«jo»**, **«jo»** *(я-йа-йә)* дип куя.

Ул вакытта **«jo»**ның нәрсә икәнлегенә игътибар итмәдем: тойгы аңлата торган ымлыкмы ул, әллә сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерүче модаль сүзме? Хәер, ул чагында минем өчен аның әһәмияте дә юк иде. 1947 елда, кош кебек очып дигәндәй, өзелеп-өзелеп сагынган Башкортстаныма кайттым. Аннан язмыш җилләре Кытай чигендә яшәгән кыргызлар арасына алып барып беркетте. Бу телне дә ихлас өйрәндем. Икенче елны әлеге усал язмыш җиле мине Үзбәкстанга китереп ташлады. Тагын яңа тел. Монысын инде өстән-өстән генә түгел, төбеннән-тамырыннан алып өйрәнергә туры килде. Чөнки өч ел үземчә әзерләнеп, экстерн рәвешендә, 1951 елны шаһәдәтнамә алу өчен имтихан тоттым. Хәзер вузга керергә кирәк иде. Мин тел яратам. Телче булу — төп максатым. Ләкин кайсы телне сайларга? Үзбәк теле үземнеке түгел. Әтием Иван, әнием Мәрүскә булмагач, хәзер инде рус телен бөтен киңлеге, тирәнлеге белән өйрәнеп булмас. Туган телем дә хәзер — арпа белән буталган бодай дәрәҗәсендә. Ләкин минем өчен бодай иде әле ул. Тукай әйтмешли, туп-туры Казанга китеп, педагогия институтында укый башладым. Дөрес, телне җимерә-җимерә сөйләвемнән дә, диктантта йөзәр хата җибәрүемнән дә нык көләләр иде. Бер ел буе уртны чәйни-чәйни, гарьләнә-гарьләнә, утырган каздай сеңеп укырга туры килде.

Икенче курста безгә туган телнең эчке мөмкинлекләрен, җаен, асылын чын мәгънәсендә аңлап морфология китабы язган зур галим, иҗтиһатлы, акыллы, мәдәниятле кеше Вәли ага Хангилдин лекция укыды. Сүз ясалышын тамырыннан башлап өйрәнәбез. Җае чыккан саен мин «кыргыз телендә шулай», «үзбәк телендә болай», «мадьяр телендә тегеләй» кебек сүзләр әйткәлим. Вәли ага, бик мәгълүматлы галим булса да, башка төрки телләрне белми иде. Шуңадыр, бәлки, миңа «чат ябышты» ул. Аның житәкчелегендә татар, башкорт, казах, кыргыз, үзбәк, уйгыр телләрен чагыштырып бер хезмәт яздым. Аспирантурада калып, аны кандидатлык диссертациясе дәрәҗәсенә җиткерергә тиеш идем. Әмма язмыш җиле рөхсәт итмәде. Очырып алып китте дә, Татарстанның Актаныш районында өч ел мәктәп директоры итеп эшләтте. Аннан — Уфа. «Кызыл таң». 1960 елда Башкорт дәүләт университетыннан Хәсән Сәрьян Казанга китеп баргач, мине шунда эшкә чакырдылар. Аның урынына. Морфология һәм татар әдәби теле тарихын укытырга.

Кардәш телләр бер чыганактан булган. Бер тамырдан үсеп чыккан кәүсә күп ботаклар җибәргән кебек, бер ыруг-кабилә теленнән күп мили телләр барлыкка килгән. Шуңа күрә, бигрәк тә борынгы чор әдәби телен үткәндә, аны башкорт, үзбәк, кыргыз, казакъ һ. б. төрки телләренә чагыштырып өйрәнергә кирәк була. Ә инде морфологиядә сүз ясалышын үткәндә бу ысул белән эш итү бигрәк тә кирәк.

Бервакыт шулай сыйфатларның ясалышы турында сөйлим. «Яхшы» сүзе хәзерге татар әдәби телендә тамырлашып киткән. Телчеләрнең аңлатуынча, аның тамыры — як. Бу тамыр әле дә мәгънә аңлата: күңелемә якты (ошады), күңелгә ягышлы. Димәк, якышлы-ягышлы-яхшы. Татар телендә ике сузык арасына туры килгән «к» авазы «г» авазына әйләнә (Ак идел — Агыйдел, ака иде — ага иде һ. б.) Монда да шул ук хәл. «К» һәм «х» авазларының чиратлашуы хәзер дә бар: хатын, катын (Башкортстан татарлары телендә).

Сүзләрнең ясалышын тикшергәндә, аның иң кечкенә, башкача морфемаларга (кисәкләргә) бүленми торган кисәген табасы килә. Ә бу якын кардәш телләрнең туганлыгын гына түгел, ерак кардәш телләрнең, хәтта кардәш булмаган телләрнең дә бер-берсенә мөнәсәбәтен ачыкларга ярдәм итә. Бер генә аваз-хәрефтән торган тамыр сүзләр әле дә бар бит: **и** *(талны и)*, **у** *(керне у)*. «Як», этимологик яктан тикшереп караганда, янә морфемага бүленмиме? Берәр телдә шуның я (йа, йә) формасы хәзер дә йөрмиме? Бервакыт, келт итеп, әлеге мадьяр кызының **«jo», «jo»** дип торуы искә төште. Венгерча-русча сүзлекне актарам. Әйе, «jo» «яхшы» дигәнне аңлата икән: jo кеп-уе *(яхшы икмәк)*, **jo ismeros** *(яхшы таныш)*, **jo ido** *(яхшы һава)*.

Хәзерге татар телендә **я** (йа, йә) кулланыламы? Куллана. «Килерсең, яме?» дип сорагайга, «я» (йә) дип кенә җавап бирү бар. «Яме» дә, «я» (йә) дә халык телендә яхшы төшенчәсен белдерү җәһәтеннән файдаланыла.

Димәк, «яхшы» сүзенең иң борынгы тамырын мадьяр теленнән таптык.

Ни өчен язам моны? Мәсьәлә шунда: Мөхәммәт Мәһдиевның «Европа — безнең хакта...» исемле мәкаләсе басылып чыккан иде *(«Казан утлары», 1990, № 2)*; автор анда венгр галимнәренең татар халык иҗаты энҗеләре, аның теле, гореф-

гадәте, мәдәнияте, әдәбияты белән кызыксынуы турында яза. Аның бик хаклы әйтүенчә, татар теле һәм аның мәдәнияте белән мадьярлар гына түгел, АКШ, Франция, Финляндия һ. б. ил галимнәре дә нык кызыксына. Ә инде мадьярлар белән тарихи якынлык бер бишектә йоклаган игез балалар мисалында бит. Моңа чал Урал шаһит.

Бервакыт, моннан ун еллар элек, мадьяр галимнәре Башкортстанның Илеш районында үзләренең борынгы туганнарын (мари, мордваларны) эзләп йөрделәр һәм таптылар. 1991 елда аларның ике галиме Башкорт дәүләт университетына килде. Бик кызыклы очрашу булды. Башкорт телендә дә, тататр телендә дә иркен сөйләшәләр. Икесе дә фәнни доклад ясады. Шундый еракта яшәп тә, алар безнең халык телен, рухын, аның эчке серен, җаен нык беләләр икән. «Һәм башкалар, һәм башкалар» диясе урынга «әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр» дип әйткәч, көлеп кул чаптык хәтта.

Мәкаләсенең азагын Мөхәммәт Мәһдиев болай тәмамлый:

«...Мадьяр галимнәре безнең гыйльми, мәдәни үсешебез өчен нинди игелекле эшләр башкарып яталар икән! Аларның гыйлем дөньясында безнең татар халкының акылы, эстетик фикере, мәдәнияте шаулап яшәп ята икән.

Безнең халкыбызга, тарихыбызга ихтирам саклап, безнең белән аралашырга колач җәеп әзер торган бу галимнәргә халкыбыз исеменнән рәхмәт! «Казан утлары» журналының укучылары да фикеремә бердәм кушылырлар дип өмет итәм».

Мадьяр кардәшләр турында язу өчен кулга каләм алырга Мөхәммәт Мәһдиевның шушы сүзләре мәҗбүр итте мине. Рәхмәт аңа!

Хәзер әлеге **«jo»**, я (йа, йә) мәсьәләсенә янә әйләнеп кайтыйк. Аңа «к» өстәлгән «як» (йак) формасы борынгы төрки язмаларында да очрый: «яхшы» урынына «як», «яг» кулланыла.

Ул «Кыйссаи Йосыф» та да бар (XIII йөз):

> Яһүдә әйде: «Бу вәгъдә рәва ирмәз[1],
> Карендәш карендәшне һич үлтермәз,
> Буны кылан, халикдан рәхмәт булмаз[2],—
> Ягрәк улдыр[3]: тәүбә кылып дунең имди.

Ә менә «як», «яг» формалары мадьяр телендә дә бармы? Бар икән шул: **jog aban all** *(ул яхшылыкта, яки ул дөреслек юлында)*; **jogos** *(дөреслек, яхшылык)*; **jogosult** *(дөресләнгән яхшылык)*; **jog** *(яхшы канунга нигезләнгән). Чагыштырыйк: татарча — күңелемә нык яга; мадьярча:* **jogos** *(дөрес кеше, яхшы кеше). «Яхшы» сүзе рәвеш функциясендә килгәндә «о» тамырына башка кушымча ялгана:* **jol jartam** *(юлым яхшы булды)*.

Янә (я, йа-йә) тамырына әйләнеп кайтыйк. Хакас телендә аның иң борынгы формасы да саклана: че, килем- йә, килермен; бездәге яхшы да кулланыла: чахсы, килем. Мари телендәге сай (йа-йә, җай), монголдагы сайн (сайн хун-яхшы кеше), фин телендәге hy vin, эвенктәге ай да шулар белән «тугандаш кебек.

Борынгы классик әсәрләребезнең гәүһәре булып исәпләнгән «кыйссаи Йосыф»та я (йа) да (Я, Йосыф! Көләчең хуш, үзең гарлу-яхшы, Йосыф! көлүең матур, үзең әдәпле), як та кулланыла (ягрәк улдыр тәүбә кылып дунең имди). Ягрәк — яхшырак дигән мәгънәдә. «Кыйссаи Йосыф»та «яхшы» сүзе дә я (йа-йә), якларга мәгънәдәш буларак кулланыла: «әүвәл улдыр: кадде яхшы Зариф үзлебуе яхшы, зирәк табигатьле».

Я(йа-йә), як, яхшы сүзләре, хәзерге татар телендәге кебек, мадьяр телендә бик күп төшенчәләрне үз эченә ала **jo ejt** *(яхшы ял ит, төнең яхшы үтсен, яхшы бәу-бәу ит мәгънәсендә)*. Мадьяр телендә ей, ый, ой тамырлары йокы белән бәйле. «Кыйссаи Йосыфта»: «Зөләйхә бер көн ятып оер **(ojor)** иде — йоклый, ял итә иде».

Я (йа, йә) як, якшы (яхшы) сүзләренең мәгънәдәшләре (синонимнары) бик күп. Мадьяр телендәге ач (ар) ныклы, яхшы бәйле булуны аңлата. Татар телендә ару (ару гына күренү), башкорт телендә арыу (арыуланыу — яхшыру).

Мадьяр телендәге **alap, alapzat** сүзләре бөек якшылык төшенчәсе белән бәйле. Башкорт телендә алап зурлыкны аңлата, легендаларда, риваятьләрдә сөйләнелгән Алып батырны искә алу да җитә. Йосыфның физик һәм рухи сыйфатын Кол Гали шул сүз белән тәгъбир итә: «алып йөрәкле һәм һәйбәтле».

---

[1] Рәва ирмәз — дөрес түгел.
[2] Халикдан рәхәт булмаз — алладан рәхмәт тапмас.
[3] Ягрәк улдыр — яхшырак булыр.

Мадъяр телендә **zamat** шулай ук йо төшенчәсе белән бәйле. Әмма ул тәм, зәм-зәмгә дә тартым: **zamatos** *(тәмле)*. Ул гына түгел, мәгънәле, акыллы, килешле, «тәмле» кеше дигәнне дә аңлата. Борынгы әсәрләрдә **məzə** *(мәзә, маза)* шул мәгънәдәрәк кулланыла: «сән яхшылык кыйл, яхшылыкта бар мәза» (Мөхәммәдъяр. XVI йөз). Татар телендә: эшнең мәзәсе юк. Төрекмәндә: **мазалы сес** *(яхшы тавыш)*. Яхшы (якшы) үзе дә кулланыла; **говы, оңат** *(уңки ат, уңай исем, узган кеше) дигәннәре дә бар*.

Чуваш телендә яхшының лайах, аван, ырран, селем, хукет кебек мәгънәдәшләре бар. Лайакның татар телендәге лаек белән бәйләнешен сизү кыен түгел. Яки: яхши, обдан, хоп, макул, бопту, мәйли (уйгыр); жаксы, макул, дурыс, жарайды (казакъ); эк, эки (Тува); жаксы, тәүир (каракалпак); аруьев, ярасык (нугай), якшы, һәйбәт (башкорт), **iyi, guzet** (төрек). Эк һәм эки (тува)нең мадьяр, татар телләрендәге йа, йә, як тамырлары белән бәйле булуы бик мөмкин.

Хәзерге татар әдәби телендә тамырлашып киткән сүзләр бик күп. Ул һәр мөстәкыйль сүз төркемнәрендә генә түгел, ярдәмлекләрдә дә очрый: кузгалак, беләзек, йомран (исемнәр); яшел, кызыл, зәңгәр (сыйфатлар); егерме, утыз, кырык (саннар); мин, син, без (алмашлыклар); былтыр, югары, түбән (рәвешләр); кебек, шикелле, сыман (бәйлекләр) — барысы да ясалмалар. Этимологик анализ ясап карасаң, аларның тамыр һәм кушымчалары булу ачыклана. Ул төрле фонетик кануннарга да бәйле. Татар телендә, мәсәлән, ике сузык арасына туры килгән **к** авазы **г** авазына әйләнә: кузы колагы (кузыколак) кузгалак. Ләкин ул төрле телдә төрлечә: башкортча — кузгалак; татарча — кузгалак; кыргызча — козу кулак; уйгырча — коза кулак; төрекчә — кизикu**lodi;** азербайҗанча — гузугулагы; үзбәкчә — кузикулок. Яки: татарча — кырык, якутча — төрт уон; татарча — алтмыш; якутча — алты ун; татарча — беләк йөзеге; уйгырча — беләк-йөзек; татарча — менә шушы; уйгырча — мошу h. б.

Хәзерге татар әдәби телендәге күп кенә сүзләрнең ясалма икәнлекләре сизелеп тора. Билгеле, ул бу өлкәдә ихлас, мөкиббән шөгыльләнеп, тел диңгезендә бер аркылы, бер буй йөзгән, аның төбеннән тел энҗеләрен армый-талмый кызыксынып эзләүче тел галиме өчен генә шулай тоеладыр, бәлки. Әмма моны ачыклау аңа да бик җиңел бирелми. Аның өчен, югарыда әйтелгәнчә, күп телләрне белергә кирәк. Бездәге алама дигән сүзнең ясалма икәнлеге аңлашылып тора. Тамыры — ал. Мадъяр телендә ал начар төшенчә белән бәйле. Ул алдакчы, алдау, алама дигән мәгънәләрне аңлата. Мадъяр телендә, грамматик күрсәткечләр (кушымчалар) белән катлауланган саен, ал ның мәгънәсе дә үзгәрә бара: йокы яраткан, йомшак, булдыксыз кешене алар **alamuzi** диләр; **aludni** *(йоклау)*ның да тамыры алдыр, бәлки; **alm, alom** *(салам җәелгән алама урын)*нарның да тамыры ал булырга мөмкин. Мадъярларның белән бәйлеген Башкортстан татарларыча беләә, кыргызларча белет дип әйтүләрендә дә тирән сер бар кебек.

Урыс теле аша кабул ителгән нисби сыйфатларны үзләштерүдә бик күп төрле фикер каршылыклары булды. Егерменче йөз башында, аннан соң да аларны үзгәртми дә алдылар: революционный көрәш, социалистический төзелеш, актуальный мәсьәлә. Ә инде татар һәм башкорт телләренең эчке кануны аларны кыскартып алуга һич тә каршы килмәде: революцион көрәш, социаль хәле, актуаль мәсьәлә. Ә инде мадъяр теле аларны тагын да кыскартыбрак җибәрде: урысча — партийный, татарча — партияле, мадъярча — парт. Якутлар кыскарту белән «мавыкмады»: октябрьская социалистическая революция — октябрьской социалистической революции; актуальный — актуальная. Янә чагыштырулар: татарча — арпа ярмасы; мадъярча — арпа дара; урысча — ячменная крупа h. б.

Соңгы вакытта урыс теленә төрки телләрдән кергән сүзләрне өйрәнүгә зур игътибар ителә башлады. Дөрес, аларның күбесе һаман әле бәхәсле булып кала килә: урыс теленә төрки телләрдән алынганмы, әллә киресенчәме? Мадъяр теле кайбер очракта бу мәсьәләне чишүгә дә ярдәм итә. Урыс телендә стол сүзенең төрки телләрдән алынуы бәхәссез. Татар телендә өстәлнең тамыры — өс. Мадъяр телендә — **as,** яки: **asztal.**

Мондый мисалларны бик күп китерергә мөмкин. Әлбәттә, күп кенә тамырлар фонетик үзгәрешкә дучар булган. Бу — табигый хәл. Шулай да кайберләре үзгәрешкә бирешмәгән (**alma** — *алма,* **balta** — *балта,* **арпа** — *арпа,* **арок** — *арык* h. б.) Мадъяр телендә андый сүзләр дә күп кенә. Алма, балта, арык — тарихи яктан караганда ясалма сүзләр, һәрберсенең тамыры һәм кушымчасы бар. Димәк, мадъяр һәм татар теле (башка төрки телләр дә) бер-берсенә якын мөнәсәбәттә булган. Ерак тарихта ук тамырлашып киткән күп кенә уртак сүзләр аларның гасырлар төпкелендәге ата-бабалары дөньясына зур кадер-хөрмәт белән сәяхәт итәргә кызыксындыра.

Венгр, мадъяр сүзләренең ясалышы да шактый кызыклы. Әмма аларны тикшерү бу хезмәтнең төп вазифасы түгел. Мәкаләнең язылу сәбәбе әйтелгән иде инде.

**Ә «Казан утлары» журналын укучылар рухына ярашамы бу мәкалә? Автор бу хакта да уйланмады түгел. Егерменче йөз башында Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, Җ. Вәлиди һ. б. әдипләр телебезнең эчке хосусиятын, асыл сыйфатын, байлыгын ачу җәһәтеннән күп кенә хезмәт яздылар. Алардан соң Г. Бәширов, Ә. Еники, Ф. Хөсни кебек каләм осталарының сүз сәнгате турында нәшер иткән хезмәтләре күпме укучының күңел даирәсенә нур өстәде. Соңгы вакытта телебезнең асылы, көчкодрәте, җир йөзендә тоткан шөһрәте, үткән ерак тарихы белән галим, язучы, журналист, укытучы гына түгел, киң җәмәгатьчелек җитди, мөкиббән уйлана башлады. Бу мәкаләнең язылуы шул уй дулкынының бер сирпелүедер, бәлки. Янә икенче төрле әйтсәк, тел диңгезе дулкыннарыннан фәкать бер тамчы алып күрсәтү генә бу. Сүз энҗеләребез чал тарих төпкелендәге кара пәрдәгә төренеп ята икән ләбаса. Ул пәрдәләрне ачу, ерткалап ыргыту, ата-бабалар күмеп калдырган энҗеләрне табып, аларны хәзерге укучыга бүләк итү, минемчә, гаҗәп мөкатдәс эш һәм кирәкле шәйдер. Моның өчен, бәлки, күп галимнәребез, зыялыларыбыз җиң сызганыр.**

**Янә шуны әйтик: бер үк тамыр һәм ясалма сүз кайбер очракта мадъяр әдәби телендә бер төшенчә, ә инде халык телендә икенче мәгънә белдерә. Халык телендәгесе — тагын да борынгырак. Бу үзе генә дә бик борынгы сүз энҗеләрен эзләргә кирәклекне искәртә. Әлбәттә, янә кабатлыйк, моның өчен кардәш һәм кардәш булмаган күп телләрне белү мотлак. Иншалла, булыр шундый галимнәребез! Хәзер милләтне төрле яклап көзге итеп ялтырату максаты куела. Бер яклап кына аксак та, җир йөзендә ялтыраячак көзгенең бер як чите китек булачак.**

Мөхтәрәм укучы!

Сез кульгызга сирәк очрый торган истәлек алдыгыз. Ул — мөһаҗирлектә туып үскән Сафия ханым Имренең сөекле әтисе, якташыбыз, чит илләрдә танылган кәсепче Әхмәтвәли Ибраһим Мәңгәр турында язган хатирәләре.

Сафия ханым безгә әдәби әсәр дә, тарихи язма да, гыйльми хезмәт тә тәкъдим итми. Катлаулы һәм катмарлы язмыш кичергән, болгавыр заманада кесәсендә нибары бер доллар акчасы булган гади татар кешесенең танылган кәсәбәчеләр дәрәҗәсенә күтәрелүе, аның милләттәшләребезгә ярдәмчел булуы хакында дулкынланып язылган юллары безне уйландыра вә гыйбрәт алырга чакыра.

Сафия ханым исеме чит илдә яшәүче милләттәшләребез белән аралашкан кешеләргә бераз мәгълүмдер. Һәрхәлдә, «Ватан» җәмгыяте әгъзаларына аның гаиләсе яхшы таныш. Беренче чиратта, Сафия ханымны һәм аның балаларын, килене Назлы ханымны, Вәли әфәндесенең табибы, Мәңгәрләрнең гаилә дусты Мөхмүт Әлүкәйне без мәрхәмәтле, ярдәмчел кешеләр дип беләбез.

1991 ел. Фетнә көннәре. Татарстаннан өч яхта, Кара диңгез кичеп, беренче тапкыр Төркиягә сәяхәт кылдылар. Капитан Алмаз Алиев үзе белән әле Югары Совет тарафыннан расланмаган Татарстан байрагын алып китте. Һәм ул байрак халыкара ярышларында җилкәнле көймәләр өстендә башка байраклар белән бергә җилфердәп торды. Истанбулда безнең яхтачыларны баштанаяк киендереп, аларга ярдәм итеп торучыларның берсе Сафия ханым, аның балалары һәм гаилә дусты Фәрит Бичури булды.

1993 ел. Апрель ае. «Ватан» җәмгыяте беренче тапкыр бер төркем балаларны Анкарага Халыкара фольклор фестиваленә алып барды. Истанбулда балаларны «Татарстан» дип язган «Мерседес» автобусы каршы алды. Безнең балалар уңышлы чыгыш ясадылар — 35 мөстәкыйль дәүләт байрагы янында бу юлы да Татарстан байрагы эленеп торды.

Нәни артистларыбызның сәяхәтен оештыруда Төркиядә яшәгән милләттәшләребез зур ярдәм күрсәттеләр. Бу юлы да беренче булып ярдәм кулын Сафия ханым һәм аның туганнары суздылар.

Мондый мәрхәмәтлелек, олы җанлылык, милләтебез хакында кайгырту кебек гүзәл сыйфатларны Сафия ханым, аның балалары, күрәсең, данлыклы Вәли Мәңгәрдән сеңдергәннәр.

Кайчандыр Вәли әфәнде утырткан «алмагачлар» бүген күркәм уңыш бирә. Кечкенә генә мисал. Бүген Казан урамнарында йөгергән зәвыклы «Отомарсан» автобуслары Мәңгәрләрнең ширкәтендә эшләнә. Вәли әфәнде үзе татар җиренә аяк басмаса да, аның игелекле эше әнә шулай Татарстанга ярдәм булып кайта.

Әхмәтвәли Мәңгәрнең нәсел-нәсәбәсе — Арча төбәгеннән. Мәгълүм ки, Арча ягы, ягъни Казан арты — халкыбызның мәдәниятен, телен, гореф-гадәтләрен йолаларын, яшәү рәвешен һәм башка затлы хәзинәләрен саклап калган гүзәл төбәк. Ул як халкыбызга Тукайны, Мәрҗанине һәм башка бик күп күренекле шәхесләрне биргән. Дөнья кәсәбәчеләре арасында танылган Әхмәтвәли Мәңгәр дә шул йолдызларның берсе.

Дамир ГЫЙСМЕТДИНОВ.
«Ватан» җәмгыяте президенты.

## Сафия Имре

# ӘТИЕМ[1]

*Адәм баласының эчке дөньясын аңлау һәм аңлату бик авыр эш. Бигрәк тә ул олы талантлы, күпкырлы шәхес булса. Бигрәк тә аның яшәгән көннәре давыллы бер чорга туры килсә.*

*Әтием үзе турында бары тик кечкенә генә кульязма калдырган һәм бу хатирәләрнең күп өлеше кәсеп, бизнес, сәяхәт хакында.*

*Аны яхшы белгән кешеләр берәм-берәм бу фани дөньядан китеп бардылар. Ә вакыт кеше йөргән эзләргә ком сибә. Мин әтиемнең бердәнбер баласы, язучы булмасам да, кулыма каләм алырга ниятләдем. Билгеле инде, мин әтием кебек олы*

[1] төрекчәдән Ф. Бичури, Д. Гыйсметдин тәрҗемәсе.

*бер шәхесне тирәнтен тасвирлаган хезмәт язарга алына алмыйм. Укучы бу язмамны әдәби әсәр итеп түгел, якын кешем, сөекле әтием хакында уйлануլар, аның күпләргә билгеле булмаган сыйфатларын азрак яктыртып киткән хатирәләрем, истәлекләрем дип кенә кабул итсә иде.*

АВТОР



*1. Әхмәтвәли Ибраһим Мәңгәр (1891—1978)*

**Әтием — Әхмәтвәли Ибраһим Мәңгәр, үзенең әйтүенә караганда, 1891 елның 8 декабрендә, ә паспорты буенча 1892 елда Казагыстанның төньяк чигенә якын Петропавловск Кызыльяр шәһәрендә туган. Әтинең ата-бабасы Татарстан җөмһүриятенең башкаласы Казан арты, төгәлрәге, Мәңгәр авылыннан. Әниемнең нәсел очы Казан губернасы Сабабашы авылыннан.**

**Татарстан, татар иле, урта Идел белән Урал таулары арасында урнашкан бер төбәк. Атаклы тюрколог венгр Рашони әйткәнчә, татарлар борын заманнардан иген игү, аучылык, балыкчылык һәм умартачылык белән шөгыльләнгән, тынычлык яраткан бер халык булган.**

**1552 елда Явыз Иван тарафыннан яулап алынганнан соң Казан халкын көчләп христианлаштыра башлаганнар. Христианлыкны кабул иткәннәргә дәүләт оешмаларында эш, урын, дәрәҗәле исемнәр һәм җир биргәннәр. Соңрак алар арасыннан атаклы урыс композиторлары Рахманинов, Римский-Корсаков, язучылар Аксаков, Тургенев, Гоголь һәм Распутинны үтерүчеләрнең берсе кенәз Юсупов чыккан. Заманында христиан динен кабул иткәннәрнең исемнәрен барлап, бер китап та чыгарганнар[1]. Христианлашкан татарларны «крәшен» дип атый башлаганнар. «Ике мәчет арасындагы намаз» дигән төрек мәкале крәшеннәргә рас килә. Билгеле инде, аларны татарлар яратмаган, урыслар да үз итмәгән. Вакытлар узу белән, кайберләре белем алып, сәүдә эшенә керешкәннәр, төрле һөнәр ияләре булып киткәннәр. Христианлыкны кабул итмәгәннәрне күпләп Иделгә, Казансуга батырганнар, очлы казык башына утырткannар, күзләрен чокып чыгарганнар[2].**

**Татар халкы Иван патшага «явыз» атамасын менә шушы залимлекләреннән, кан коюларыннан соң биргән. Ләкин безнең бабаларыбыз тезләнмәгәннәр, диннәре өчен җаннарын фида кылганнар, йөрәкләрендә басып алучыларга карата нәфрәт йөргән. Әле бүген дә, ничә гасыр үткәч тә, кайбер славян илләрендә, мәсәлән, Боснийдә, мөселман каны коела. Кызганыч, мондый җәберләүләрне урыс классиклары, мәшһүр Лев Толстойдан башлап Солженицынга кадәр, аклап килделәр.**

**Византия империясе төрекләр тарафыннан яулап алынгач, урыслар үзләрен Византиянең варислары, православие дөньясының башлыгы дип игълан иткәннәр. Татарларны патшалар тарафыннан җәберләү сәясәте бигрәк тә Петр I вакытында аеруча көчәеп киткән. Казанда 453 мәчет, мәдрәсә җимерелгән, яндырылган: алар урынына монастырьлар, чиркәүләр салынган. Татарларга Казанга 30 чакрымнан да якынрак урынга төпләнергә рөхсәт ителмәгән. Аларга хәтта затлы ташлы йөзекләр, кыйммәтле әйберләр киеп йөрү тыелган булган. Урыс алпавытлары басып алынган халыкны кол рәвешендә эшләткәннәр, җае чыккан саен җәберләп килгәннәр.**

[1] Х. А. Баскаков. «Төрек нәселеннән килгән урыс гаиләләре».
[2] М. Энгин, Ф. Аги, Н. Дәүләт, А. Акыш «Казакъ һәм татар төрекләре».

Даими гаскәре булмаган төрки халыклар күп тапкырлар урыс патшасына каршы баш күтәрсәләр дә, азатлыкны яулап ала алмаганнар.

1773 елда башланып, 5 ел дәвам иткән канлы Пугачев фетнәсеннән соң урыс патшасы Екатерина II Салават Юлаев белән очрашуы хакында болай дип язган, имеш (әтиемнең әйтүенә караганда). Екатерина II: «Пугачев — талаучы, үтерүче, нигә аңар кушылдыгыз?» — дигән сорауга Салават: «Без урыс хакимиятенә каршы булган һәр адымны хуплыйбыз һәм аңа һәрвакыт кушылачакбыз!» — дип җавап биргән.— «Без монда 16 кеше. Безне асарлар. Ләкин миллионлаган татарлар һәм башкортларны үтереп кенә бетерә алмассыз. Сез безнең милли һәм мәдәни тормышыбызга балта чаптыгыз, дини китапларыбызны яндырдыгыз, мәчетләребезне, мәктәпләребезне, мәдрәсәләребезне юк иттегез. Ләкин без китапларыбызны яшереп саклап калдык, аларны кулдан язып меңләрчә кешеләргә тарттык. Без бу эшебезне дәвам иттерәчәкбез».

Әби патша, татар-башкортларга каршы көч куллануның нәтиҗәсез икәнен күреп, Казанда агач мәчет салдырткан һәм Коръән-Кәримне бастырырга рөхсәт биргән. Ләкин бу кыска вакытлы мәрхәмәтлелек кенә булып кала. Җәберләнгән татарлар, изелү һәм мәсхәрәләүдән кача-кача, күрше Башкортстан далаларына таба күченә бара.

XIX гасырның икенче яртысында, Россиянең халык саны бик нык арта башлагач, хөкүмәт кешеләрне яңа җирләргә күчерә башлый. Ул дәвердә Россиянең башында булган патшалар Себернең кара туфраклы җирләренә меңләгән халыкны китереп утырталар. Биредәге табигать байлыгының, төрле җәнлекләрнең, бигрәк тә кыйммәтле кеш җанварының зур табыш китерәчәген урыс патшалары бик яхшы аңлаган. Әлбәттә, очсыз-кырыйсыз дала-урманнарда тормыш корып җибәрү бик авыр булган. Бу юлы да иң беренче итеп яңа җирләргә татарларны сөргәннәр.

Әтиемнең кайсы бабасы Себергә күчеп киткәнен белмибез, ләкин дәү әтиебез Мөхәммәтҗан Ибраһимның Петропавловскига барып урнашканы мәгълүм. Әтием Мөхәммәтҗан Ибраһим белән Аден Бануның уникенче, ягъни актык баласы булган. Янә бер дәү әтиебез җиде килене белән бергә торган. Әтиемнең әйтүенә караганда, килennәр чиратлашып кер юганнар, аш пешергәннәр, бала караганнар һәм атнага бер тапкыр үз гаиләләре янына барып йөри торган булганнар. Бу дәү әтиебез Мөхәммәтҗан Ибраһимның әтисе идеме, әллә Кытай һәм Төркестанга кәрван йөртүче дәү әтиебез Озын Шаһ идеме — анысын төгәл әйтә алмыйм. Унөч баланың унөчесе дә исән калганмы, яисә бала чакта үлгәнме, бу хакта да хәбәрем юк. Һәрхәлдә, әтиемнең апаларының исемнәрен атаганын ишетмәдем.

Ике абыйсы бар иде — Хәлил белән Сабирҗан. Апаларыннан иң зурысы булган Шәһәрбану беренче баласына узганда, дәү әнием дә әтиемнән йөкле булган. Башка апалары арасында яше белән әтигә иң якын булганнары — Хәтиҗә белән Айны апа икән. Әтием, үзеннән 14 яшькә олы булган Хәлил туганын бик яратса да Сабирҗан абыйсын үз итмәгән. Күрәсең, бик кире, тар фикерле бер кеше булгандыр. Җитмәсә, ул кияү булып йортка кергән булган. Андый кешеләр хакында әтием һәрвакыт болай дип әйтә торган иде: «Үзем тапкан мал түгел, әтинеке җәл түгел». Дәү әтием Мөхәммәтҗан Ибраһим әфәнде укымышлы кеше булган, озак вакыт яһүдләр белән эш иткән. Ул Казагыстан һәм Төркмәнстаннан җыйган малларны Англия, Италия, Германия кебек көнбатыш илләренә җибәргән. Ләкин әтием 12 яшендә чагында дәү әти ревматизмнан вафат була, гаиләнең хәле бөтенләй кыенлаша. Тормышны алып бару, балаларны үстерү әнисе Аден Бану ханым белән Хәлил туганы ө+стенә төшә. Хәлил абый урман-агач



2. Әтиемнең абыйсы Хәлил Ибраһим.

эшләре белән шөгыльләнгән. Аден Бану ханым зур гаиләне, балаларны кырыс итеп тәрбияләгән. Үзе саран да булган, һәрнәрсәне санап, бирәмтекләп тоткан. Авыр чакларда аш өстеннән җыйган өрене ихата алдындагы мичкәгә салып барган. Соңрак аны сабынчыга биреп, сабын ясаткан. Әти әйтә иде: «Шешә саен чирек тиен табыш алыр өчен әни хәтта серкә дә ясап сатты». Аден Бану ханымның каты холыклы булуы хакында әтием болай дип искә төшерә иде. Берзаман Хәлил туганының җиде яшьлек олы кызы Әшрәф йортның өстәге катыннан егылып төшә. Ходайның рәхмәте, бала озын итәкләре белән бакчадагы алмагачка эленеп кала. Егылып төшкәндә Әшрәф дәү әниемнең тәрәзәсе төбендә үсеп утырган яран гөлләрен аударган була. Дәү әнием: «Йа, Ходаем, яран гөлләрем харап булды!» — дип бик уфтанган, имеш.

Кайчак әтием, җәмәгать эшләре белән мавыгып, кичләрен өйгә соңрак кайта торган булган. Дәү әнием әтиемнең әйткән сәгатендә кайтмавын күреп, өйнең ишеген бикләп куя икән. Андый чакта әтием төнне печәнлектә уздырырга мәҗбүр булган.

Әтием балачагында урысча белмәгән, соңрак үзенең яшьтәшләре, урыс гимназиясендә укыган татар яшьләре ярдәмендә бу телне тиз арада өйрәнә алган. Урыс классиклары белән мавыгып, аларның китапларын төннәрен, яшерә-яшерә, шәм яктысында укыган. Дәү әнием моңа бик борчылган. «Инде кяфер булып бетәсең» — дип ачулана торган булган.

Алты яшендә әтием «Ысулы кадим» мәктәбенә укырга кергән. Башы бик яхшы эшләгәнгә ул үзеннән 7—8 яшькә олырак шәкертләр укыган шәригать хокукын һәм Коръән тәфсирләрен бик тиз өйрәнгән. Бу мәктәптә канәгатьләнерлек белем ала алмагач, әти Истанбулга элеккеге исеме «Мектеби Султани», бүгенгесе — «Галатасарай» лицеенә укырга китәргә хыялланып, ике иптәше белән өйдән качкан. Боларны Одессада тотып алганнар һәм Петропавловскига кайтарып җибәргәннәр. Шуннан соң ул Сабирҗан абыйсының тырышлыгы белән аның кибетенә булышчы булып эшкә урнашкан. Мәктәптәге хатирәләрен әтием елмаеп искә төшерә иде. Кайчак ул дәресләрдә үзен укытучы итеп: «Хуҗам, мин бу эшкә сезнең кебек өйрәнә алырмынмы?» — дип сорый икән. Укытучысы да елмаеп, күзлеге белән әтиемнең башына суга икән: «Син юкка гына таз түгелсең икән». (Таз — чәч сырхаулыгы. Халык арасында «Тазларның башлары яхшы эшли» диган әйтем дә бар). Ул вакытларда татарлар хәзерге кебек чәчләрен пәке белән алганнар. Бритвадан элэктерелгән сырхаулык аркасында әтиемнең башы һәрвакыт бозыла торган була, чәчләре дә үсми диярлек. Шәһәрдәге бер герман докторы әтиемнең башын һәр көн гарәп сабыны белән юарга, ә чыккан чәчләрне кайчы белән кисә торырга киңәш иткән. Апалары моны файдасыз эш дип уйласалар да, Рабига җиңги һәр көн баланың башын юып, чәчләрен кисеп торган. Кер юу өчен дәү әнием, саран кайнана буларак, Рабига җиңгигә бер генә кисәк сабын бирә икән. Билгеле инде, ул чакларда күп балалы гаиләдә сабын житкерү шактый кыен бер эш булган. Шуңа күрә Рабига җиңги үзенең акчасын яшереп кенә әтигә баш сабыны алыр өчен биреп барган. Кыскасы, ярдәмчел вә игелекле Рабига җиңгине әтием бик ярата, һәрвакыт сагынып искә ала иде.

Әтием — бала яраткан сирәк ирләрнең берсе иде. Ул Хәлил абыйсының Рабига ханымнан туган 5 кызын һәм 1 ир баласын бик иркәләгән. Күп фоторәсемнәрдә бу балалар, йөзем тәлгәшләре кебек, әтиемнең йә башына утырып, йә җилкәсенә атланып төшкәннәр.

Әшрәф апаның теле ачылган чорда әтиемә: «Апут абзый» дип әйтүе аңа гомер буена кушамат булып тагылып калган булса кирәк. Бәләкәчләр иркәләнеп әтигә шулай дип дәшәләр иде.

Балалар арасында әти Әминә апаны һәм төпчек Шамил абыйны (әниләренә бик охшаганга, күрәсең) барысыннан да артыграк ярата иде. Әшрәф апа бик зирәк һәм тиктормас булганга, үзеннән бәләкәйрәкләрне үчекли торган булган. Бервакыт Әминәне бик ачуландыргач ул Әшрәфкә: «Дуңгыз»,— дип әйткән. Моны ишеткән әтием бөтен балаларны җыеп, бер урысның дуңгыз абзарына илткән, үзләренә пычракта аунаган хайваннарны күрсәтеп: «Син туганыңа әнә нинди әшәке сүз әйттең» — дигән. Ләкин күп тә үтмәгән Әшрәф Әминәне янә нык ачуландырган. «Апут абзый» рөхсәт итмәсә дә, син дуңгыз, дуңгыз, дуңгыз»,— дип кычкырган ул Әшрәфкә.

Рабига ханымның барлыгы 9 баласы туган. Алтысы исән калган, өчесе үлгән. Соңгы баласына йөкле чагында Рабига җиңги аннан котылырга теләгән. Һәм бу эшне табип ярдәменнән башка гына хәл итәргә тырышкан. Әмма бәла аяк астында дигәндәй, эшнең ахыры фаҗигале була. Үлгәндә Рабига ханым әтиемне янына чакырып: «Вәли, балалар сиңа әманәт»,— дип васыять иткән. Әйтергә

кирәк, әти аларны үз канаты астына алды. Һәммәсенә чит телләрне укытып, югары белем бирдерде. Ә Шамил абыйны хәтта «Калифорния Беркелей» университетында укытып чыгарды.

Әти бала чактан ук сату-алу эшләрен яраткан һәм моңа маһир булган. Мәктәптә укыганда балаларга карандаш, каләм, дәфтәр, бозгыч саткан. Тапкан акчаны әнисенә биреп барган. Сабактан буш вакытта тирә-юньдәге кешеләргә җеп, энә, резинка, төймә кебек кирәк-яраклар саткалаган. Моннан кергән табышны да әнисенә кайтарып биргән. Кибеттә ярдәмче булып эшләгәндә җыйган 400 алтын рубльне әнием: «Бусы да Вәлинең өлеше»,— дип, әтинең абыйларына биргән. Әтием кибеттә өстәл астына одеял җәеп, шуның өстендә йоклаган. Туганыбыз Ибраһимовның кибете Кызыльярдан 40 чакрымнарда урнашкан Мәүләт авылында икән. Себергә ишелеп-ишелеп килгән кешеләр бөтен кирәк-яракны шул кибеттән сатып алганнар. Яңа күчкән кешеләр бигрәк тә икмәккә мохтаҗ булганнар. Шуңа күрә алар өчен әтием туганнары белән бергә тиз генә пекарня салып биргән. 1909 елда Сабирҗан абзый өйләнгәннән соң, Хәлил абый әтием белән кибеттән китеп, үзләренә яңа эш башлыйлар: чит илләр өчен тире, йон, чәй җыялар. Гомумән, Россиядә татар, башкорт, казакъ сәүдәгәрләре бөтен тире, йон һәм йомырка сәүдәсен үз кулларында тотканнар. Ул елларны Казагыстанның эчке төбәкләренә, Шәркый Төркестанга чит илләр, шул исәптән урыслар да бик керә алмаганнар. Чөнки алар өчен мондагы халыкның дине, яшәү рәвеше аңлашылмаган, чит булган. Фәкать банк хуҗалары гына чит ил кешеләре булган. 1938 елның көзендә мин, очраклы рәвештә, Австриянең Инсбрук шәһәрендә Миланда мех эшкәртү «Пачетти» фирмасында эшләгән сеньор Риззи белән таныштым. Бу сеньор әтием белән бергә эшләгән кеше булып чыкты. Хәтта алар бик якын дуслар да икән. Ял иткән вакытларында велосипедка утырып, Ишем елгасына су коенырга йөри торган булганнар.

Әтием мал табар өчен төрле төбәкләрдә, ярминкәләрдә күп йөргән, азмы-күпме табыш алган. Ләкин киң җәелеп китә алмаган. Бәлкем шуңадыр, ул хәтта тәҗрибәле сәүдәгәрләрнең сүзләренә колак салмыйча, Россия һәм Монголиядә ачылган Германиянең йон туплаучы «Штукен К» фирмасы бүлекчәсе белән эшли башлаган. Кайбер вакытта сәүдә эшендә тәвәккәллек таш яра. 22 яшьлек егеткә Штукенның Монголиядәге вәкиле булып эшләү, алман сәүдә системасын, немескә хас булган төгәллеккә һәм тәртипкә өйрәнү, әлбәттә, зур бер мәктәп була. Әтием ул чакларда керемнәрдән тыш зур гына премияләр алганын да үз хатирәләрендә язып калдырган. Бүген дә «Штукен» фирмасы Көньяк Африкадан йон җыя һәм Төркиядә «Алтын йолдыз» («Бойнерлар») фирмасы белән эшли. Кызык, 2 ел әүвәл бу фирманың кешесе, киләчәктә дә бергә эшләү мөмкинлекләрен өйрәнү өчен булса кирәк, безне эзләп килгән иде... Димәк, әти тарафыннан яуланган абруйлылык әле дә аның компаньоннарының хәтерендә яхшы саклана.

Татарлар, үзләренең телләрен, диннәрен саклап калу йөзеннән, урыслар белән бик аралашмаганнар — кыз алмаганнар, кыз бирмәгәннәр. Урыслар белән кушылганнарны безнең халык читләштергән. Кайбер гаиләләрдә уллары урыс кызына өйләнергә теләсә, аны, бердәнбер бала булуына карамастан, өйдән куып чыгарганнар. Югарыда әйтелгән сүзләр профессор Ласло Рашониның «Төркиләр — тарихта» дигән китабында язылган. Татар хатыннарының гыйффәтле һәм гаиләгә нык бирелгән булуларын Рашони мактап яза. Ә инде бүген Төркиянең Кара диңгез ярларына чемодан туризмы өчен килгән урыс хатыннарының секс әхлагы ни дәрәҗәдә түбән булуы хакында язып та торасы килми.

1860—1905 елларда Россиядә Дума эшләгән чорда татарлар үзләренең төрле җәмгыятьләрен төзегәннәр, кайда яшерен рәвештә, кайда рөхсәт алып, театрлар оештырганнар, бихисап гәзит-китап бастырганнар, халык арасында концертлар, төрле сәяси бәхәсләр уздырып, аның үзаңын үстерергә тырышканнар. Әлбәттә, Мәскәү чиновниклары тарафыннан ошбу милләтне кузгату, күтәрү эшләренә һәрдаим басым ясалган, киртәләр куелган. Мәркәздәге һәм урындагы чиновникларны татар байлары акчага, дөресрәге, ришвәткә сатып алганнар. Әтием дә 16 яшеннән башлап татар җәмгыятьләрендә катнашып йөри, төрле спектакльләрдә уйный. Әлбәттә, инде шул чорда ул татар яшьләре белән нык аралаша. Алар арасында гимназиядә укыган матур татар кызлары да була. Шуларның берсе — Сафия исемлесе, минем аңлавымча, әтиемнең беренче мәхәббәте булган ахрысы. Бу сылукай әтиемне җәлеп иткән. Инде күп еллар үткәч, әти вафат булганнан соң аның кәгазьләре арасыннан бу кызның зурайтылган бер рәсемен тапкан идем. Әтием Сафиягә гыйшык тотса да, мәдрәсә шәкерте генә булганга үзен аңа тиң дип санамаган, күрәсең. Алар аерылышканнар. Бәлки минем исемемнең килеп чыгуы да шул яралмаган мәхәббәт истәлегенә бәйледер...

Ул вакытларда Кырымлы Исмаил Гаспралы әфәнденең «Телдә, фикердә, эштә — берлек» — дигән өндәмәсе астында төрки халыкларга багышланган «Тәрҗуманы Хакыйкать» исемле газетасы Россиядә киң таралган. Аны төрле җәмгыятьләрдә укыганнар, алдынгы фикерләрне халыкка житкерергә тырышканнар. Бу гәзит дини темага язылган мәкаләләре белән кайбер дин әһелләре гади халыкка житкерә алмаган тәгълиматларны оста һәм аңлаешлы итеп яктыртып барган. Османиянең күренекле мәгърифәтчесе Исмаил Хаккы Манастырлы тарафыннан язылган вәгазьләрне җомга намазларыннан соң татарларга сөйли торган булганнар.

1917 елда патшаны бәреп төшергән Ленин халыкларга азатлык вәгъдә итеп, төрек кавемнәрендә киләчәккә өмет уята. Татар халкының байтак өлеше бу сүзләргә ышанып, коммунистларга булыша башлый. Моны аңлап була. Тик залим Сталин большевистик өндәмәләргә бизәлгән империя сәясәтен бик оста тормышка ашыра. Ленин, Троцкий һәм башка көрәштәшләрен юк итеп, ул, Көнбатыш тарихчыларының исәпләүләренә караганда, 25 миллионга якын совет гражданнарын лагерьларга озата. Аларның күбесе шунда һәлак була. Россия тимер пәрдә артында кала. Миллионлаган кеше моны аңласа да бернәрсә эшли алмый. (Солженицын язмаларыннан алынды.)

Мәгълүм ки, 1917 елда большевистик инкыйлабтан соң Рәсәйдә гражданнар сугышы кабынып китә. Бу хакта күп язып тормыйм. Шунысын гына әйтәм, Колчак армиясенә американнар ярдәмен житкерүдә әтиемнең дә өлеше булган. Соңрак, 1923 елда әтием, энә буенча, Маньчжуриягә барып чыккан. Анда ул әнием Гайшә Сатылган белән танышкан һәм ярәшкән. Әниемнең энесе Хәсәнжан Сатылганны урыс гимназиянең соңгы сыйныфында укыганда солдатка алганнар. Гайшә дә гаиләсе белән бергә ак армиягә ияреп, Ерак Көнчыгышка киткән. Бу вакытта әнием 19 яшендә, ә иң кечкенә туганы 3 яшендә булган. Әнием дәү әтием Илмүхан һәм дәү әнием Маһпәрвәрнең алты балалы гаиләсендә икенче бала булган. Илмүхан бабай, Каһир һәм Җиһангир Уфадан ерак түгел Бирск шәһәрендә ашлык һәм йомырка алып-сату белән шөгыльләнгәннәр. Бу гаиләнең ата-бабасы Явыз Иван заманында Казаннан Башкортстанга качкан булган. Дәү әнием Агыйдел буендагы бер авылда туып үскән. Дәү әтием кыз сайларга барганда, яшь кызлар арасында дәү әниемне күреп алган. Шундук аңа күзе төшкән һәм аны сораткан. Дәү әниемнең өе Бирскиның иң күркәм биналарының берсе икән. Ул заманнарда ук йортта электр уты, жылы бәдрәф, Венадан кайтартылган затлы кәнәфиләр, утыргычлар булган. Инде әтиемә килсәк, ул гражданнар сугышыннан соң Россиягә кайта һәм ак гаскәрләргә ярдәм кылганы өчен коммунистлар тарафыннан кулга алына. Соңрак бер татар сакчысының ярдәме белән ул әсирлектән атка атланып кача. Аның артыннан куа чыгалар. Ләкин әтием Монголия һәм Кытай якларында күп сәүдә иткәнгә бу тирәләрне бик яхшы белгән. Өстәвенә, оста җайдак та булган. Кыскасы, бәхетенә күрә, аны куып тота алмаганнар.

Рәсәйдәге инкыйлаб әтиемнең кәсеп эшләренә дә зур зыян китергән. «Штукен» фирмасы белән дә элемтәләре өзелгән. Владивостокка килгәндә әтиемнең кесәсендә бер доллар акчасы калган була. Урамда бер аяк киеме чистартучыны күреп, ул үз-үзенә: «Кәсеп кешесенең капиталы булырга тиеш» — дигән. — «Ә синдә исә 1 доллар, нәрсә эшләргә җыенасың? Ярый әле шушы аяк киеме чистартучы һөнәрен башкара алсаң»,— дигән. «Шул чакта,— дип әйтә иде әтием,— мин үземә сүз бирдем. Өйләнеп, балам булса — малаймы, кызмы, бер нәрсәгә карамыйча, аңа югары белем бирәчәкмен».


Әнием әтидән 2 ел буена хәбәр ала алмаган, яраткан һәм ярәшкән кешесен һаман көткән. Ниһаять, 1925 елның 27 апрелендә Маньчжуриядә әнием белән әтием өйләнешкәннәр. Туй мәҗлесенә бик күп милләттәшләребез җыелган. Никах укыганда дәү әтием: «Кызым, син гыйффәтле, улым, син мәрхәмәтле бул»,— дигән. Әтием бу сүзләрне бик ярата иде һәм никах укыганда аларны еш кына кәләш белән егеткә әйтә торган иде. Шул ук елның май аенда Тензин шәһәренә килгәндә, әтиемнең кесәсендә 200 кытай доллары була. (1 кытай доллары — 25 америка центы.) Ул 120 долларны торакка түләп, калган акча белән эш башлап җибәргән.

Ул чакта Тензиндә биш-алты татар гаиләсе була. Бер миллион халкы булган Тензин шәһәре диңгезгә коя торган бер елга буена урнашкан. Шәһәрнең бер районы Англия, Франция, Бельгиядәге кебек идарә ителә икән. Шәһәрдә Россиядән качып килгән яһүд кәсеп ияләре яшәгән. Бу районда күбрәк инглизләр идарә иткән. Шәһәр ике телдә — инглизчә һәм урысча сөйләшкән.

1927 елда, мин дөньяга килгән вакытта, безнең гаилә француз районында «Ру де Пастер» дагы бер өйдә яшәгән. Хәтеремдә, өй ниндидер бер йортның почмагы иде. Астагы катта амбарлар, өстәге катта — торак һәм конторлар урнашкан иде. Йон һәм мех эше белән шөгыльләнгәнгә өйнең чардаклары шул мал белән тулы иде. Йортның иң өске катында әтигә булышучы яшь хезмәткәрләрнең йокы бүлмәсе бар иде. Аларның берсе — Исхак Арслан, башкалары Габбас белән Вагиз Сөләймановлар, Али белән Хәсән Ибраһимовлар һәм Алимҗан иде.

Әтием яшьрәк чакта эш белән Мәскәүгә бик еш йөргән. Буш вакыты калса, опера һәм балет театрына бара торган булган. Ул Аурупа музыкасын бик ярата иде. Бала чагымда бүлмәмнең ишегенә элгән таганны селкетеп әтием еш кына «Цыганский барон», «Принцесса Чардаш» арияләрен әкрен генә көйли иде.

Яшьлек елларында татарларның иреге өчен бик күп хезмәт куйган әтинең исеме Ерак Шәрыкта билгеле иде. Татар мөһаҗирләре (Япониядә 25—30 мең кеше бар иде) аны Корылтай җитәкчесе итеп сайлаганнар. Корылтай, кызганычка каршы, бер тапкыр гына Маньчжуриянең Мукден шәһәрендә җыела алды. Бөтен Кытай, Маньчжурия, Япония һәм, хәтта, Монголиядә яшәгән татарлар бу Корылтайга делегатлар җибәргәннәр. Анда мәктәп, мәгърифәт, яшьләр, балалар тәрбияләү һәм башка бик күп сәяси мәсьәләләр буенча карарлар кабул ителгән. Бу хакта «Милли байрак» газетасында күп тапкыр язып чыкканнар. Шул ук вакытларда Истанбул университетының тюркология бүлеге профессоры Рәшит Рәхмәти Аратның төрекчә әлифбаларны зур бер посылка итеп әтиемә җибәргәнен дә хәтерлим.



*3. Әтием, әнием һәм мин.*

Профессор Рәшит Рәхмәти әфәнде Берлин университетында тюркология бүлеген тәмамлаган иң зур галимнәрнең берсе иде. Рәшит Рәхмәти «Котадгу белек»не тәрҗемә иткән галим, әтиемнең якын дусты булды. Төгәлрәк әйткәндә, Рәшит әфәнде безнең җингәбез Рабига ханымның туганы, ә чыгышы белән ул Арча районыннан Мәңгәр авылы белән күрше Иске Өҗемнән иде.

Әтием мәдрәсәдә укыганга күрә Коръәнне, гомумән, динне бик яхшы белә иде. Аның никах, җеназа, җомга һәм бәйрәм намазларын да башкарганын хәтерлим.

Мәгълүм булганча, 1930—1932 елларда дөньяда икътисадый кризис башланды. Әтиемнең яңа гына корылган эше шушы кризис аркасында уңышсызлыкка дучар булды. Ул вакытта без шәһәрнең француз бүлемендә тора идек. Йортыбыз хакында инде әйтеп узган идем. Әти төшке ашка өйгә кайтканда сул күзенә алтын акча зурлыгында монокль кебек бәләкәй түгәрәк шоколад кыстырып куя иде.

Мин ул бүләкне алыр өчен һавага сикерергә тиеш идем. Шоколадны эләктергәч, әти креслога утырып: «Кил яныма!» — дип мине кочагына ала иде. Кайчак чәч алучыга барганда мине дә үзе белән алып бара иде. Рикша арбасына утырып, чәчтарашка бару, чәчемне кистереп, шампунь белән юдыру минем өчен бик зур куаныч вә бәхет була иде. Чөнки сәяхәтебез чәчтараш бүлмәсендә генә тәмамланмый, дәвам итә. Чәчтараштан чыккач, без бер бик зур кибетнең уенчыклар бүлегенә керә торган идек. Әти: «Кызым, нәрсә телисең?» — дип сораганда, мин, 4 яшемнән бирле укый-яза белгән бала буларак, курчакларның бәяләренә карап, 6 доллардан арзанракларын гына сайлый идем. (Ул вакытта 6 кытай доллары 1,5 америкаң долларына тиң иде). Мондый әдәплелек әтиемнең күңеленә хуш килә иде. Мәктәптә укыганда яхшы билге алып кайткач, «Ай, рәхмәт, кызым, бүген мин тагын бер сөямгә үстем», — дип мине мактый иде.

1932 елда, акча ягыннан шактый кыенлыклар кичергән чорда, җәйге йортыбызга, ягъни дачага йөри алмый идек. Хәтерлим, ул елның җәендә әнием белән аның апасына, Монголия чигендә урнашкан Хайлар шәһәренә киттек. Бала чактан ашказаным авырту сәбәпле күп ризыкны миңа ашарга рөхсәт итмиләр иде.

Хайларга баргач, бер көнне иптәш кызларым белән урманга чыктык. Алар ниндидер җиләк ашый башлагач, мин дә кызыгып, шуны авыз иткәнмен. Эт корсагына сары май килешми, дигәндәй мин, кинәт хасталанып, аяктан егылдым. Ул елны Хайларның тирә-юнен су баскан иде. Шул сәбәпле шәһәрдә телефон, телеграф эшләми, тимер юллар өзелгән иде. Әтиемнән бернинди хәбәр ала алмыйча бер ай чамасы сырхаулап яткач, ниһаять, Харбинга бара алдык. Шунда әтием белән күрештек. Ул миңа: «Аша, кызым, аша, күңелең ни тели, шуны аша», — дигәч, мин бер персик алып ашаганымны хәтерлим.

Гаиләнең матди ягы мөшкел булу сәбәпле ул чакта әнием миңа әтиемнең иске киемнәреннән күлмәк тегә иде. Мин танышларыбызга өстемдәге күлмәкнең калдык-постыктан тегелгәнен аңлатканда, әниемнең оялудан бите кызара иде.

Ниһаять, әтиемнең эшләре җайлана башлады. Ул Америкадагы «Чейз Манхеттен Банк», «Ферст Нэйшнл Сити Банк оф Нью-Йорк» белән уңышлы эшли башлады, алар белән тыгыз элемтәләр урнаштырды. Әтием янә зур күләмдә чит илләргә мал җибәрүгә керешә. Төркиядән китеп, Америкада урнашкан әрмән эшмәкәрләре Карагөзянларга дөя, сарык йоны, Монголиядән җыештырган көмешсу төлке белән бәрән тиреләрен Англиядәге «Лидл Бразерс» фирмасына сата башлады.



*4. Профессор Рәшит Рәхмәти Арат*

Һәр сугышның нигезендә сәяси генә түгел, икътисадый сәбәпләр дә ята. Беренче дөнья сугышында җиңелеп, Африкадагы колонияләрен югалткан герман индустриясе соңрак аякка нык баса башлый. Ә колонияләре хисабына көн күреп яшәгән Англия һәм Франция Германия белән индустриаль яктан узышалмаслык хәлдә калалар. Гитлер хакимияткә килгәч, әтием дөньяның янә бер сугышка йөкле булуын аңлап алды. Шуңа күрә 1935 елда мине француз лицеена әзерләгән булсалар да, герман мәктәбенә укырга җибәрделәр. Әтинең фикеренчә, урыслар Германиягә каршы торырлык хәлдә булмаган. Ошбу бәрелештән соң Рәсәй империясе таркалыр дип өмет иткән әтием Кытайдагы алман «Мелчерс К» фирмасы белән эш башлап җибәрде. Бу вакытта ул Кытай, Маньчжурия һәм Кытай Төркестанында үзенең 43 сатып алу мәркәзен корган иде. Аның инде йон юа торган өч ширкәте дә бар иде.

1931 елда японнар Маньчжуриягә гаскәр кертәләр, ә 1937 елның җәендә Кытайны басып ала башлыйлар. Без бу хәлне белеп, дачадан кайтырга

чыктык. Тензин тимер юлы станциясен бомбага тотып җимергәннәр иде. Торган җиребезгә көчкә генә кайта алдык. Ул чакта без инглиз районында тора идек. Кайткач та «Фалкланд Виллас» дигән киң бер коттежга күчендек һәм контор өчен аерым бина алдык. Эшкә йөрер өчен әтием бер автомобиль юнәтте һәм шофер яллады. Йортка яңа зәвыклы мебель кайтартты һәм зур келәм эшләтте.

Банк директорлары белән нык дуслашып китеп, әтием инглиз ягындагы «Рэйс Курс Клуб»та әгъза булды һәм ат чабышларына йөри башлады. Хәтта үзенең бер аты да булган диләр. Кәсеп әһелләренең берләштергән «Бридж Клубы»нда да әгъза булып торды.

Ул елларда СССРда Сталин, империячел сәясәтне яңадан көчәйтеп җибәреп, мәчетләрне, мәдрәсәләрне яптыра башлады. Дистәләгән милләтләрнең тамырын корыту эшенә кереште. Совет концлагерьларында миллионлаган кеше һәлак булды. Алар арасында 2 миллионга якын татарлар да булган, диләр. Әтием ул вакытта радио янына утырып, төннәр буе тоткынга сөрелгәннәрнең, һәлак булганнарның исемнәрен тыңлап чыга иде.

Японнар Маньчжурия һәм Кытайны яулап алгач, бөтен кәсеп эшләрен хөкүмәт карамагына күчермәкче булганнар. Әлбәттә, бу кәсепчеләрнең хәлен нык кыенлаштырган. Көн саен кайсыдыр эшмәкәрнең соаль алыр өчен японнар тарафыннан кулга алынуын ишетеп тора идек. Шуңа күрә әтием, тиз генә бөтен эшләрен бетереп, Мелчерс ярдәмендә «Нансен» (дөнья мөһаҗирләрен яклау) ассоциациясенең паспорты белән 1938 елның 2 февралендә бөтен гаиләбез белән Кытайдан киттек. Әлбәттә, безнең ниятебез Төркиягә бару иде. Чөнки Төркия төрки дәүләтләр арасында үзенең бәйсезлеген саклап калган бердәнбер ил иде. Әтием ассимиляциядән һәм чит халыклар эчендә юкка чыгудан куркып, бигрәк тә минем киләчәгем турында кайгырту сәбәпле, Япония һәм Америка аша Германиягә килгәч тә, Берлиндагы төрек илчелегенә виза артыннан йөри башлады. Ләкин аның мөрәҗәгатьләре җавапсыз калды. Виза көтеп торганда, вакытымны бушка уздырмас өчен мине Берлиндагы кызлар мәктәбенә яздырдылар. Сугышка хәтле Германиядә бөтен ашамлыклар карточкага сатыла иде. Карточкасыз яшелчә-җимеш һәм икмәк алырга мөмкин түгел иде. Германиягә, башка дәүләтләр ягыннан игътисадый эмбарго салыну сәбәпле бернинди чимал килми иде. Кытайдагы игелекле эшләренә рәхмәт йөзеннән Мелчерс әфәнде әтиемә Герман армиясе өчен йон хәзерләү нияте белән Багдадта бер фирма төзергә тәкъдим итте. Әтием үзе белән йон эксперты итеп Исхак Арсланны алып (ул Хәлил абыйның кечкенә кызы Рәшидәгә өйләнде) 1939 елның көзендә Багдадка китте.

Ниһаять, 1938 елның ахырында төрек илчелегеннән сөенечле хәбәр алдык һәм 1939 елның 14 гыйнварында Истанбул шәһәренә килеп төштек.

Икенче Бөтендөнья сугышы башланып китү сәбәпле, Багдадтагы эш нәтиҗәле булып чыкмады. Инглизләр һәм американнар герман капиталына һәр җирдә эмбарго салдылар. Әтием капиталын гына югалтып калмады, хәтта «кара» исемлеккә эләкте. Мерчерсның Швециядәге Лузерн шәһәрендә «Ульрих Мейер Зоне» исемле бер фирмасы бар иде. Багдадта германнар белән бергә алып барылган эшнең зыянын кире кайтарыр өчен Мелчерслар фирмасында компаньон итеп алдылар һәм «Ульрих Мейер» фирмасында генераль директор урынын бирделәр. Сугыш уты эчендә кайнаган Аурупода кәсеп эшләре алып барырга авыр иде. Әтием сугыш аркасында ачлык, хәерчелек кичергән шәһәрләргә, авылларга тәмәке кәгазеннән башлап, лимонга хәтле табып китерә иде. Без аны Истанбулда җидешәр ай күрә алмый идек. Хәтта хәбәре дә булмый иде. Моңа әнием дә, мин дә бик борчыла идек. Янныбызда туганыбыз һәм якын кешеләребез булмаганга бу көннәрне кичерү тагын да кыенлаша иде. Әтиемнең Кытайдан Ульрих Мейер ярдәмендә алып чыккан акчалары белән тугыз елга якын яши алдык.

Әтиемнең ул вакыттагы ике бүлмәле офисы Истанбулдагы Банкалар Җаддәсендә, ягъни урамында, «Ассикуразиони Генерали» (бүгенге «Умум Сигорталар») йортында урнашкан иде. Ул вакытта әтием Миландагы «Пачетти» фирмасы өчен сеньор Риззигә куй тиресе сата иде. Аннан соң Чехославакиядәге «ТКД» фирмасыннан радиоалгычлар кайтарта иде. Сугыш елларында әтием, Швециядәге Ульрих Мейер фирмасының генераль директоры булып эшләгәндә, «Кызыл хач» җәмгыяте аша Мелчерста эшләгән дусларына ашамлык әйберләрен посылка белән җибәреп торган. Мелчерснең идарә хәяте башлыгы Карл Линжеманн ул чакта бик абруйлы фирмаларның («Норддойчер Ллойд», «Фабер Кастелле», «СКФ» һәм «Отто Вольф») идарә әгъзасы булган. Әйтергә кирәк, ул әтиемне бик хөрмәт итә иде.

Сугышның беренче көненнән башлап әти Алман армиясенең Россия буйлап хәрәкәт итүен картада билгеләп барды. Күпләр урысларның җиңелүенә ышана иде. Бу вакытта немец армиясенә әсир төшкән төркиләрне азат итү өчен аларны Германиянең Миттенвальд шәһәрендә һәм башка мәркәзләрдә туплаганнар. Шул әсирләрдән гаскәр төзү һәм аларны урыс-алман фронтына җибәрү хакында әти өебездә җыелышлар уздыра иде. Антикоммунистик оешмаларның җитәкчеләре — Кырымлы Джафер Сейдахмәт, Гаяз Исхакый, Зәки Вәлиди, Рәшит Рәхмәти Арат һәм Фоат Казак әфәнделәр дә бу очрашуларда катнашалар иде. Мостафа Чакайуглы, Сәгыйт Шамил, Рәсүлзадә, Хәйдәр Бәмат, Галимҗан Идриси һәм Эдиге Кырымал кебек мәшһүр кешеләрнең исемнәре өйдә еш ишетелә иде. Кырымлыларның «Әмәл», татарларның «Яңа милли юл», төрекмәннәрнең «Яшь Төркестан» һәм «Шимали Кавказия» белән «Куртулуш» журналлары өебезгә даими килеп торды.

Германнарның сугышны оттыруы белән әтинең төрки халыкларның азатлыгы хакындагы хыяллары юкка чыкты дияргә була. Янә көн күрү кайгысы, тормыш өчен акча эшләү кебек мәсьәләләр беренче чиратка басты. Сугыш барышында әтием төрки әсирләр оешмасы эшләре белән Германиянең тышкы эшләр министрлыгына асат кына кереп йөри иде. Инде алманнар тар-мар ителгәч, әтием Америка армиясе генералы Вильсон белән дуслашып китте. Әтиемнең сүзләренә караганда, Вильсон алман халкын эшсезлеккә, рәхәт тормышка өйрәтсәң генә, җиңеп була дип сөйләгән. Һәм, чыннан да, сугыштан соңгы Германиядә әхлак таркаулыгын искә алсаң, Вильсонның сүзләре чынбарлыкка туры килгән дип әйтеп була.

Әтием сугыш елларында хезмәттәшлек иткән Мелчерс Нюрнберг трибуналы тарафыннан ирегеннән мәхрүм ителә. Ләкин 5 ел узгач, бу хөкемне нигезсез дип табалар һәм Мелчерсны иреккә чыгаралар. Линдеманн әфәнде, Кытайда намуслы эшләгәнен искә алып, әтиемә сугыштан соң таркалу хәлендә булган «Бош», «Мерседес», «ВДО», «Руд Каттенфабрик», «Кейбл», «Гмейндер» кебек атаклы герман фирмаларының филиалларын Төркиядә ачарга тәкъдим иткән. Яхшы хәтерлим, 1948 елның 31 маенда, ягъни миңа 21 яшь тулган көнне, безгә кичке ашка «Мерседес-Бенц» фирмасыннан Беккер һәм «Роберт Бош» фирмасыннан Карл Зехендер әфәнделәр килде. Бу очрашуда мин тәрҗемәче булдым. Ул кичне яратып йөргән кешем Иззәт әфәнде белән күрешеп, нииндидер кичәгә барырга вәгъдәләшкән идек. Әмма әтием катгый рәвештә: «Утыр утырган урыныңда»,— дип әйткәч, тыңламый булдыра алмадым.

Шул ук елның җәендә бу ике фирманың да Төркиядәге филиалларын без алдык. Конторабыз Таксим мәйданындагы «Калмис» йортына күченде. Ләкин, әтиемнең акчаларына американнар тарафыннан эмбарго куелу сәбәпле, һаман да эшләре авыр барды. Бигрәк тә «Мерседес» филиалын уңышлы эшләтеп җибәрү өчен зур капитал кертергә кирәк булды. «Мерседес» үз филиалларына бик зур таләпләр куя иде. 1951 елда әтием Ульрих Мейердан аерылды. Бурычларын Мелчерсның Кытайда үз итеп күргән Клаусен әфәндегә ирегенә калдырды, эшне зурайту өчен Мелчерстан беркадәр акча алды. Әти үлгәннән соң гына белдек — Мелчерсның үзенең Кытайда эшләгәндә әтигә бурычлары булган икән. Бизнес эшендә иң мөһиме — тугрылыклы компаньон табу. Бу юлы да әти озак уйлап тормады — андый кешене татарлар арасыннан сайлап алды. Казан байларыннан чыккан мөһаҗир доктор Фоат Казак әтием белән бергә эшли башлады. Нәкъ шул башлангыч чорда әтиемнән ярдәм сорап, мөхтәрәм профессор Рәшит Рәхмәти әфәнде мөрәҗәгать итте. Ул төрек мәдәниятен өйрәнү институты төзергә һәм «Казан» журналы чыгарырга җыена иде. Ләкин ул вакытта, төрле сәбәпләр аркасында, әтием тиешле ярдәмне күрсәтә алырлык хәлдә түгел иде. Соңрак, Рәшит әфәнде вакытсыз үлеп киткәч, әтием сөекле профессорга үз вакытында ярдәм итә алмаганы өчен бик борчылды. Моңа гомере буе үкенеп яшәде. Төрек мәдәниятен өйрәнү институты башта Төркия президенты карамагында иде. Бүләнт Эҗевитның премьер-министр булуы белән бу ярдәм туктады. Соңрак әтием институтка да, Истанбулда һәм Анкарада төзелгән татар җәмгыятьләренә дә булышу йөзеннән бер Фонд төзергә теләгән иде. Ләкин төрек кануннары Төркиядә яшәгән барлык халыкларның файдасына эшли торган фондларны гына салымсыз оештырырга рөхсәт итә иде. Ә татар җәмгыятьләре бу канунга туры килмәү сәбәпле әтием фонд оештыруны башкарып чыга алмады. Җитмәсә, безнең фирмаларыбызның ул чакта житәрлек матди көче дә юк иде.

Икенче Бөтендөнья сугышы азагында Сталин, Рузвельт һәм Черчиль катнашында узган Ялта конференциясеннән соң Балкан илләре Советлар Союзының көчле йогынтысы астында калдылар. Төркия дә коммунистик ил басымына

эләкмәсен дип, әтием һәм аның кебек зур кәсепчеләр бу илгә Ауропадан капитал кертүне тизләтергә өнди килделәр. Әтием беренче чиратта германнарга зур күләмдә заводлар төзергә, капитал салырга тәкъдим итте. Һәм 1958 елда бу эшне үзе үк башлап җибәрде. Тормыш иптәшем доктор Иззәт Имре, 1984 елда вафат булган доктор Фоат Казак һәм 1991 елда дөнья куйган Исхак Арслан әфәнделәрнең ярдәме белән 1967 елда «Отомарсан Отобүс вә Моторлу Арачлар» һәм 1970 елда «Роберт Бош Моторлу Арачлар Ян Санай» фирмалары төзелде. Әйтергә кирәк, инде күп еллар буена бу фирмалар шактый уңышлы эшләп киләләр. «Мерседес-Бенц Төрек» фирмасының хәзерге урыны әтием тарафыннан заманында «Бош» фирмасы өчен сатып алынган иде. «Бош» фирмасы контракт төзергә соңга калганга күрә, бу җир «Мерседес» белән ясаган килешү нигезендә «Отомарсан» фирмасына бирелде. Анда бүгенге биналарны инженер доктор Фоат Казак төзеткән иде. Сугышның азагында «Мерседес» шактый уңышлы эшли башлады. Моның өчен әтиемне германнар бик хөрмәт итәләр иде. Соңрак алар бик әйбәт эшләп китеп, зур акчалар казангач, ике арада ниндидер ризасызлык, аңлашылмау барлыкка килде. Әтием тора-бара алманнарга үпкәләде.

1950 елларда Төркиягә Кытайдан күпләп татар мөһаҗирләре килә башлады. Ул заман Мао Цзэ Дун башлаган мәдәни инкыйлаб кешеләрне җәберләүгә, меңләгән гаепсезләрне төрмәләргә утыртуга, үтерүгә китерде. Азиат коммунистларының Сталин юлыннан барып, халыклар өстендә янә бер зур канлы эксперимент үткәрүләре бөтен дөньяны тетрәтте. Меңләгән кеше шушы башбаштаклыктан, тәмуггтан куркып, чит илләргә кача башлады. Татарларның күбесе, әлбәттә, Төркиягә килде. Шул мөһаҗирләрне эш белән тәэмин итү йөзеннән әтием Тракияда (Төркиянең Ауропа өлеше) Силиври дигән кечкенә шәһәргә якын бер җирдә ферма сатып алды. Ул Бөтендөнья чиркәүләренең эмигрантларны яклау комитеты белән бергә биредә бер лагерь төзергә ниятли иде. Ләкин бу оешма лагерьның беренче чиратта мөселманнар өчен булачагын белеп, ярдәм күрсәтмәде. Минемчә, бу ферманы сатып алу, икътисадый яктан караганда, акчаларны ялгыш сарыф итү иде. Чөнки әтием игенчелекне дә, терлекчелекне дә бик үк белеп бетерми иде. Шуңа күрә хата җибәрде. Үзләрен бу эштә зур белгеч итеп йөргәннәргә бушка әллә ни хәтле акча түләп торды. Озак та үтми Төркиядә эшчеләр һәр җирдә үз профсоюзларын оештыра башладылар. Монысы да әтиебез өчен көтелмәгән бер борчулы хәл булып чыкты.

Дөрес, баштарак бу эш шактый уңышлы вә өметле булып күренде. Әти Ауропадан, Америкадан яхшы нәселле сыерлар кайтартты. Моңа хәтле Тракияда һәм Адапазары тирәсендә андый нәселле терлекләр үрчетелмәде. Бу яктан караганда әти максатына өлешчә булса да ирешә дип әйтергә була.

Төркиядә әтиемнең дуслары бик күп иде. Алар арасында Берлинда, Мәскәүдә һәм Токиода илче булып эшләгән Феридун Җемал Эркин белән Казым Ташкент әфәнделәр бигрәк тә якыннары иде. Казым әфәнде Ташкент төрек бизнес дөньясына ярдәм итәр өчен «Хезмәттә чикләү юк» дигән өндәмәсе нигезендә «Япы Креди Банкасы» дигән банк төзеде. Әтием дә бу эштә катнашты. Казым әфәнденең банкасы Музаффер Өзсой һәм Оуз Карахан әфәнделәр вакытында эшләп килде. Ләкин соңрак банк бер гаиләнең кулына күчкәч, барлык акцияләребезне сатып җибәрдек.

Әтиемә 65 яшь тулганда ул әле бик таза, калын сөякле, озын буйлы, йөз килограмм тарткан бер матур ир кеше иде. Аның чәчләре куе коңгырт, ә йөзе ак иде. Шуңа күрәдерме, аны кояш алмый иде. Инде кызарса да, икенче көнгә аннан берни калмый иде.

Әти Беренче Бөтендөнья сугышына катнашмаган. Чөнки авырлыгы белән патша гаскәренә алына торган солдатлар үлчәменнән артык булган. Икенчедән, аның башкарган кәсеп эшләрен хөкүмәт өчен файдалырак дип тапканнар.

Әтием әниемне бик ярата иде. Хәтеремдә, мин 8 яшемдә чакта әнием бик каты авырып китте. Хастаханәдә аңа бик катлаулы операция ясадылар. Әтиемнең шул вакыттагы борчылулары аркасында бер атна эчендә чәче агарды.

Тормышта әтием бик гади иде. Ашау-эчүгә дә бик исе китмәде. Ләкин рәхмәтле иде. Өстәл яныннан торганда һәрвакыт «Аллаһ әкбәр, әлһәмдүлиллә, бик шөкер»,— дип әйтер һәм өстәп куяр иде — «Хатынымның куллары сызлаусыз булсын, ни хәтле тәмле ашлар пешергән бит». Тәмсез бер аш ашаса да, һичбер вакыт чәпчемәде. Шулай да ит ашларын күбрәк ярата иде: «Үлән ашарга мин бит сыер түгелмен»,— дип шаярта иде.

Әтием туганнарына, дусларына бик игътибарлы булды. Якыннарының туган көннәрен, өйләнешү көннәрен һичбер вакыт онытмыйча гаиләне җыеп, матур итеп котлый иде. Татар милли җырларын матур тавышы белән җырлый, кайчак әнием дә пианинода уйнап аңа кушыла иде. Төнге сәгать унике тулгач, әти

урынынннан кузгалып: «Йә, балалар, инде ашадык, эчтек, жырладык, көлдек, китәргә вакыт житте»,— дип жырлый башлый иде. 29 яшенә хәтле хәмерне авызына да алмаган әтием, соңрак ни хәтле эчсә дә, исерми иде. Шунысы кызык, аракы эчкәч ул, төчкерә-төчкерә, аның тәэсирен киметә белә иде. Әтием гомере буе сигара тартты. Өйнең залы һәм әтинең кабинеты һәрвакыт, йә зәңгәр, йә коңгырт төтен эчендә була иде.

Әтием ачык кеше иде. Беркайчан да уй-фикерләрен яшереп сакламады. Һәр нәрсәне әниемә әйтеп, аның рөхсәтен алырга тырышты. «Чирен яшергән үләр, бурычын түләмәгән банкрот булыр»,— дип әйтә торган иде. Янә бер матур вә мәгънәле мәкальне ярата иде: «Сөю һәм сагыну гаилә эчендә башланыр. Чит кешеләр килер ди китәр, ләкин гаилә кешеләре һәрвакыт бергә калыр»,— дия иде.

Чит илләргә барганда, мөмкинлекләре иркен булганга, иң яхшы кунакханәләрдә туктала һәм иң яхшы рестораннарда ашый иде. «Мерседес» фирмасы аңа һәр барган илендә машина һәм шофер бирә иде.

Әтием чит илдән килгән кунакларны йә ресторанда, йә өйдә сыйлады. Өстәлендә күгәрчен сөтеннән гайре һәр нәрсә була иде. Бүләк биргәндә дә әтием юмарт иде. Нужалы кешеләргә ярдәмчел булды, бик күп шәкертләрне укытып кеше итте.

Әтием үз-үзенә бик таләпчән һәм гайрәтле кеше булды. Саф шөһрәте һәм исеме белән горурлана иде. Эш иткәндә һәрвакыт бик житди булды. Житдиятсез эшләрне яратмады. Бер нәрсә хакында ике сөйләмәде. Икенче кат әйткәнне жене сөйми иде. Конторда кычкырып сөйләшкәнне яратмады. Андый вакытта аның кан басымы күтәрелә иде. Кызып киткән чакта компаньоны доктор Фоат Казак белән әйткәләшеп тә ала иде.

Дини мәктәпне тәмамлаганга күрә, әтием бу өлкәдә бик белемле һәм хәбәрдар иде. Динне дөрес юлдан алып баруны хуплап яшәде, бу мәсьәләдә наданлыкны, халыкны алдауны кабул итмәде. Ә динне үз мәнфәгате өчен кулланып, Алла белән иман арасында арадашчы булып йөргәннәргә нык ачулана иде.

Төркиядә бернинди клубта әгъза булмады, бернинди фиркагә кермәде. Соңгы көннәрендә бик хәсрәтле булды, чөнки туган якларын ифрат сагына, юксына иде. Россиягә кире кайтырга өмет итте, татар китапларын, фильмнарын алыр өчен урыс консуллыгына еш кына барып кайта иде.

Алман докторлары, артык юаная башлагач, йөрәге начар эшләгәнне исәпкә алып, әтигә диета тотарга куштылар. Ләкин ун килограммга якын ябыккач, ул диабет белән авырый башлады. Гомере буе аз хәрәкәт иткәнгә, аяк буыннарына тоз утырган иде. Шуңа күрә гомеренең соңгы елларында йөрү аның өчен газаплы бер эшкә әверелде.

Ул көннәр буе китап укыды. Төркиләр хакында нинди китап булса, дөнья китапханәләреннән шуларны кайтарта иде. Һич булмаса, күчермәләрен алдыртты. Үлгәннән соң бу китапларны төрек мәдәниятен өйрәнү институтына жибәрдек. Ләкин уку бәхете озакка бармады. Кызганыч ки, күзләре начар күрә башлады. Алманиягә барып дәвалану да файда бирмәде. Күзләре көннән-көн начарайды. Укудан мәхрүм булгач, әтием соңгы ике елда дөнья белән бөтен элемтәләрен өзде. Бернәрсә белән кызыксынмады, иң яхшы дусларын да танымас булды.

Әтием бик күркәм кеше иде, олы тәжрибәле, дөньяга гашыйк, көчле бер кешенең сүнеп баруын күрү — минем өчен зур бер кайгы һәм фажига булды.

1978 елның 10 ноябрендә, Корбан бәйрәменең Гарәфәсендә, 87 яшен тутырууга бер ай кала, әтием дөнья куйды.

Кызганыч, ул үзенең гомерлек хыялын — СССР империясенең таркалуын күрә алмады. Әгәр дә исән булса, йөри алмаса да, бу хәбәрне ишетеп, ул чиксез шатланыр иде. Бигрәк тә бөтен дөньядагы татар халкы мөкиббән китеп яшәгән Казанның, Татарстанның үзенең мөстәкыйльлеген игълан итеп, хөррият юлыннан бара башлавы әтиемнең йөрәк яраларына шифалы бер дәва булыр иде. Ул үзенең сөекле докторы Мәһмүт Әлүкәйне кочып күңеле белән гомере буе сагынып яшәгән изге ватанына барып кайтыр иде.

Бу язмаларны укыган һәрбер кеше әтиемнең хәләл көче белән тапкан акчасын гаиләсен байлыкта яшәтер өчен генә түгел, ә халкы мәнфәгатен кайгырту йөзеннән, аның бу дөньяда гаип булмавы һәм киләчәк азатлыгы өчен сарыф иткәнен дә аңласын иде.

*Истанбул. Май. 1993 ел.*

# ГЫЙБРӘТЛЕ ШӘҖӘРӘЛӘР

Һәр милләт шанлы тарихы, бөек ата-бабалары белән горурлана. Әнә шундый тарихка һәм шәхесләргә ия булу, үз нәүбәтендә, халыкның яшәү дәртен һәм дәрманын арттыра торган тиңсез куәтне тәшкил итә. Менә ни өчен илбасар җиңелгән якның каршылыгын тәмам сындыру максатында аны иң әүвәл тарихи хәтереннән мәхрүм итәргә, асыл затларыннан аерырга тырыша. Без моны татар-урыс мөнәсәбәтләре көзгесеннән дә бик яхшы күрә алабыз.

Күп гасырлы колониаль изелү, җәберләнү шартларында яшәгән халкыбыз чын тарихын, милли барлыкны саклауга һәм ныгытуга хезмәт иткән каһарманнарын белүдән генә түгел, хәтта илбасарларга хезмәткә күчкән, аларның кодрәтен-фәнен, мәдәниятен, тулаем дәүләтчелеген үстерүгә сәләтен дә, көчен дә кызганмаган шәхесләрнең тамырларын танытудан да тыелды. Чөнки алар әсир милләтнең, акыллы һәм эшлекле шәхесләр үстерә алуын тоеп, милли горурлыгын ныгытыр һәм, ихтимал, сәяси хыялларын да дөрләтер, дип хәвефләнде. Халыклар дуслыгын кайгыртуы хакында лаф орган, чынлыкта исә шовинизмга гына хезмәт иткән совет режимы, КПСС сәясәтенә урыс ягына чыккан татар кенәзләре һәм морзалары тормышы һәм эшчәнлеге бик шәп мисал һәм үрнәк буларак хезмәт итәргә тиеш иде югыйсә!

Ит юкта үпкә тансык, дигәндәй, халкыбызның сәләтле икәнлеген исбатлар өчен, чукынган ханзадәләр, би-морзаларның урыс кенәзләре, патшаларына хезмәттә күтәрелүе дә гыйбрәтле, алар белән дә мактанырга мөмкин. Чөнки бәйсезлеген югалткан татарга соңгы гасырлар аеруча газаплы, михнәтле килде — аңа бай потенциалын бик күп өлкәләрдә үзе булып калып ачу мөмкинлеге беткән иде. Әмма дошманнарына хезмәткә күчкән, чукынган дуңгаләкләр тарихы белән яхшырак танышкан саен, аларның славян кенәзлекләрендә, Рәсәйдә күтәрелүләре, зур дәрәҗәләргә ирешүләре туган кавем-кабиләләрен туктаусыз зәгыйфьләндерү, юкка чыгару, өзлексез сату бәрабәренә казанылуын күрәсең, кайчандыр сан ягыннан урыстан калышмаган татарның бүген инде ни өчен егерме тапкыр азрак калуын аңлыйсың. Чөнки һәр аксөяк яңа хуҗа карамагына йөзләгән, меңләгән «карасын» да алып киткән.

Сәләтле, тырыш, атаклы булсалар да, сатлыклар үз халкының горурлыгына әйләнә алмый. Сатылудан да әшәкерәк әхлаксызлык юк, әхлаксызлыкны исә бер генә халык та уңай бәяләми. Димәк, сатылып дәрәҗә казанучылар безгә ничек яшәмәскә кирәклеген аңлауда гыйбрәт бирә ала.

Шөкер, татарның милли бәйсезлеге, шан-шөһрәте көчәюенә хезмәт иткән, шуның өчен гомерен дә кызганмаган чын каһарманнары — Бачман, Чура, Колшәриф, Батыршалары, Кол Гали, Сафагәрәй кебек сәнгать һәм дәүләт эшлеклеләре дә булган, алар безнең ихлас мәхәббәтебезгә һәм олылавыбызга лаеклы дип кенә әйтү аз — алар булмаса, без бүген татар халкы булып яши дә алмас идек.

Түбәндә тәкъдим ителәчәк язманы укыганда моны истә тоту аеруча урынлы булыр.

Т. РАМАЗАН.

## Ерак чорлар авазы

Мәскәүнең «Современник» нәшрияты 1991 елда ике томлык бик тә гыйбрәтле бер хезмәт бастырып чыгарды. Һәр томы утыз бишәр табак күләмендәге бу басма «История родов русского дворянства» дип атала һәм аның үзенчәлеге шунда ки — бүген генә туган хезмәт түгел бу. 1986 елда Санкт-Петербургта, үз чорының мактаулы академигы булган П. Н. Петров җитәкчелегендә бер мәртәбә дөнья күргән инде бу шәҗәрәлек. Яңа нөсхә ике-өч битлек

кереш сүз белән баетылган һәм ниндидер күләмдә редакцияләнгән. Һәрхәлдә, бүгенге язылыш тәртибенә якынайтылган булса кирәк.

Урыс дворяннарының борынгыдан килгән шәҗәрәләрен тасвир иткән андый китаплар бездә егерменче еллардан бирле басылмады гына түгел, хәтта патша заманнарында дөнья күргәннәре белән танышу мөмкинлекләре дә бик-бик чикләнгән иде. Тарихи әһәмиятле андый хезмәтләрне бездә ике-өч йозак астында, төрле-төрле «тыелган фонд»ларда яшереп саклау гадәткә кертелгән иде. Хәзер ул «саклагыч»ларның ишеге беркадәр ачылды. Ләкин хәзер дә әле «үтә яшерен» тамгасы сугылган тимер ишекләр артында ятучы андый тоткын китапларның барлыгы җәмәгатьчелеккә мәгълүм. Әйтик, беренче бөек урыс революционеры һәм демократы данын алган А. Н. Радищевка багышланган бер зур гыйльми хезмәтнең язмышы шундыйрак. Украина тарихын һәм шуңа бәйле рәвештә ерак бабаларыбыз булган кыпчаклар һәм кырым татарлары белән Киев кенәзлекләре бәйләнешләрен «советча» тасвирламаган зур галим Михайло Грушевскийның да унөч том чамасындагы хезмәтләре шундый ук серле, тыюлы сандыкларда сакланды. Алар белән танышу ышанычлылыклары кат-кат тикшерелгән зур галимнәргә аерым очракларда гына рөхсәт ителә иде.

Хәер, элек болар гына түгел, Сталин тарафыннан тәнкыйть утына алынган совет чоры тарихчысы Покровскийның да, «мактаулы урыс тарихчысы» саналган Соловьевның да, урысның борынгы хәл-әхвәлен миссионерлар күзлегеннәнрәк карап бәян иткән чукынган татар морзасы Карамзинның да хезмәтләре шундый ук тоткын хәлендә булды.

Байтак кына тарихи хезмәтләрнең совет чоры укучысына «килешмәгән», аның зиһененә кире йогынты ясардай дип уйларлык ике сәбәп бар иде, минемчә: беренчесе — аларда патшаларны, алпавытларны зурлап, данлап күрсәтергә тырышылган. Икенчесе, беренчесеннән дә куркынычрагы — милли аң мәсьәләсенә кагылуы. Якыннанрак баксаң, Рәсәй тарихы, ике төрле онны кушып пешерелгән бер бөтен ипи кебек, тамырыннан ук татарлар дөньясына бик нык бәйле. Рәсәй дәүләтчелегенең шушы ике тамырдан үсеп киткәнлеге тарих чоңгылына чумган саен ачыграк күренә бара. Без белгән бүгенге Рәсәй дәүләтенең башлыча Мәскәү-Владимир кенәзлекләре җирлегендә барлыкка килүен һәркем белә. Ә менә аның шәҗәрә башында торучыларның тумыштан ук ярым татар-кыпчак булганлыклары һаман яшерелә килде диярлек. (*Владимир-Суздаль кенәзлегенә нигез салган Андрей Боголюбскийның анасы кыпчак, хатыны Болгар ханнары нәселеннән. Галимнәр раславынча, ул «татар-монгол» кыяфәтендә булган. Аны, ә элгәрәк атасы Юрий Долгорукийны тәхеткә күтәреп утыртучы гаскәрнең төп күпчелеге — шул ук кыпчаклар*). Әйе, Грушевский, Карамзин, Вельяминов-Зернов һ. б. олуг тарихчылар язган китапларда «явыз, килмешәк, баскын, надан, үз тарихы йөзе булмаган» татар халкына, ул халыкның бабалары төзегән ил-дәүләтләргә карата байтак кына җылы, матур сүзләр дә ычкынгалаган икән ләбаса. Шул исәптән бу халыктан чыккан мактаулы шәхесләр дә үткән тормышның иң алгы сәхифәләрендә эз калдырып киткәннәр икән. Боларны хәтта «История государства Российского» дигән күп томлы мактаулы хезмәтендә Н. М. Карамзин да, гәрчә чорының дин башлыклары таләп иткән «кара» рухтарак язарга тырышса да, һәр урында да татарларга бәйле тарихи фактларны каралтып бетерә алмаган. Монархы аның томнары да совет укучысыннан яшереп сакланды.

Ә инде аерым шәхесләргә килгәндә, галимнәрнең берничә буыны тарафыннан әзерләнгән, СССР Фәннәр академиясенең «Академкнига» нәшриятында утызынчы еллар урталарында нәшер ителгән **«Александр Николаевич Радищев» китабының әле дә юкка чыгып торуының төп сәбәбе, минемчә, әлеге дә баягы «килмешәк, баскын татар»га бәйле. Ничек инде ул шундый олуг шәхес, үз чорының иң зирәк акыл иясе тумышы белән татар була алсын? Җитмәсә әле, кайбер замандашлары кебек татарлыгын яшермичә, шуның белән берникадәр масайсын да, имеш! Татар дигән кыргый халык телен үзе белү генә җитмәгән, ул телне, имеш, улларына да өйрәтеп, алар белән татарча хатлар алышсын әле!** Әлбәттә, бу хезмәт дөньяга чыгу белән үк Сталин, Суслов ише «милли сафлык»ны кайгыртучылар тарафыннан караңгы сейфларга яшерелә; ә бәлки әле болай да күп булмаган тиражының байтак өлеше бөтенләй юкка да чыгарылгандыр.

Мәгълүм ки, Рәсәй дәүләте тарихы, европалы тиңдәшләре белән чагыштырганда, бер «фәнни» тәртипкә шактый ук соң салына. Ул тарихи китапның беренче авторы да Рәсәйдә яшәүче немец галиме була. Ләкин аерым төбәк-кенәзлекләрнең үткәне шул төбәк монастырь кенәгәләренә теркәлеп барган. Ә инде беренче шәҗәрәлек Мәскәү кенәзлеге тарихында бөек кенәз Василий Дмитриевич заманында барлыкка килә. Ул «Степенная книга» дип атала.

Долгоруков «Родословная...»сын төзегәндә шул кенәгәдә китерелгән кайбер фактларга да таянган дип белдерелә. «Степенная книга»ны төзүче, язучы да көнбатыштан чыккан бер зыялы — Византия җитәкчеләре тарафыннан ул башта Киев кенәзлеге митрополиты итеп җибәрелә. Владимир-Мәскәү митрополиты үлеп, Мәскәү, Рязань, Тверь кенәзлекләре арасында зур ызгыш башлангач, күршеләреннән өстен чыгу максатында, митрополит Киприанны мәскәүлеләр үз якларына аудара һәм Владимир шәһәренә күчерүгә ирешә.

«История родов русского дворянства» китабының ике томына 339 иң зур дәрәҗәле Рәсәй фамилияләренең килеп чыгышы, 150 ләп герб тасвирламасы һәм 32 шәҗәрә таблицасы урнаштырылган. Беренче том мондый аерым бүлекләрдән тора: **1.** Кереш аңлатма; **2.** Кенәз Романовлар шәҗәрәсе; **3.** Бөек кенәз Михаил Чернигов варислары; **4.** Бөек кенәз Владимир Мономах варислары. Тармаклар: Смоленск кенәзләре, Ярослав кенәзләре, Владимир-Суздаль вә Мәскәү кенәзләре; **5.** Литваның бөек кенәзе Гедимовичның Рәсәйгә бәйле варислары; **6.** Шәҗәрәләре Европа дәүләтләренә бәйле өч токым; **7.** Фин-угыр кабиләләреннән, татар һәм буряттан чыккан 14 токым; **8.** Монгол-татарлардан чыккан кенәзләр: Казан, Әстерхан ханнары варислары, кыргыз-казакъ, нугай морзалары токымнары; **9.** Грузиннан чыккан кенәзләр.

Күренә ки, шәҗәрәләр Рәсәй дәүләтенә хезмәт күрсәтә башлау вакытына карап төзелгән. Угыр-фин токымыннан чыккан кенәзләрнең монгол-татар хан-морзалары варисларыннан алда китерелүе дә, грузин кенәзләренең иң соңгы буынга куелуы да шуны аңлата.

Икенче томга тумыштан ук кенәз булмаган аксөякләр кертелгән. Дәрәҗәле исемнәр бирү Беренче Петр патша заманында урнаштырыла. Шундый беренче указ 1707 елда чыгарыла. «История родов...» басылганчы (1886 ел) узган йөз сиксән елда төрле патша һәм императорлар тарафыннан 32 кешегә «кенәз» дәрәҗәсе бирелгән, 126 сы «граф» булырга лаеклы дип табылган. Беренче Петр тарафыннан кенәз дәрәҗәсе иң беренче булып әшнәсе А. Д. Меньшиковка һәм Кече Русияне *(Украинаны)* Рәсәй карамагында калдырырга зур булышлык күрсәткән А. А. Безбородкога бирелгән. Граф титулы беренче булып Әстерхан «бунты»н бастыручы Борис Петрович Шереметьевка, өченче булып ике туган Апраксиннарга бирелә *(болар өчесе дә тумышлары белән татарга бәйле шәхесләр)*. Шул ук 1707 ел указы белән барон титулына да ике «шик»ле чыгышлы кеше — янарак чукынган яһүд Шафиров белән ярым-татар Строганов лаек булалар. Әйе, Беренче Петр, кайбер риваятьләргә караганда, үзендә мукшы каны да булган патша, кешене кайсы токымнан булуына карап түгел, эштәге булдыклылыгыннан чыгып бәяләгән.

Икенче томда теркәлгән кенәз яки графларның күпчелегенең варислары бу титулларны куллануда мәхрүм була. Дәрәҗә бирелү указында сирәк очракта «барлык варисларына күчә» дип өстәлгән. Кайбер очракта исә «варисларының беренче буынына гына күчә», диелгән. Ягъни, варислардан беренче туган ир-балалар титуллы булып, шул ук ата-ананың икенче, өченче уллары титулсыз калган. Түбәндә китереләчәк шәҗәрәләрдән икесе шундыйлардан: указ нигезендә кенәз дәрәҗәсе алган Кочубейларның бер тармагы тулы хокуклы, ә шул ук елларда, шундый ук рәвештә кенәз титулына ия булган Тарковскийлардан фәкать беренче туган ир бала гына ул дәрәҗәне йөртә алган. Титулның кыз буынына күчү очраклары да булгалаган. Мәсәлән, нугай морзасы Йосыф шәҗәрәсен дәвам иттерүче буын өзелгәч, 1885 елгы император указы белән соңгы кенәзнең кызыннан туган Феликска кенәз дәрәҗәсе кайтарыла, һәм ул Йосыпов-Сумароков фамилиясен йөртергә тиеш була. Шундый ук хәл өзелгән Тенишевлар шәҗәрәсе белән дә кабатлана — 1875 ел указы нигезендә аларның кыз буын варисына кенәз дәрәҗәсе кайтарыла. Рәсәй тарихында андый берничә очрак теркәлгән.

Укучыга шушы китаптан берничә шәҗәрә тәкъдим итәбез. Аларның икесе беренче томнан — «тумыштан кенәзләр», икесе — указ нигезендә бу титулга ирешкән шәхесләр. Боларның өчесенең дә бабалары ерак төрки-татар токымыннан.

Иң әүвәл «История родов...»ның беренче томында китерелгән иште исемлектән төрки-татар фамилияле кенәзләрне күздән кичерик: **Әбердиев (1690), Аинов (1690), Алачев (1640), Байгелдиев (1681), Бәхтехуҗин (1690), Биглов (1690), Булаев (1690), Булышев (1690), Гилдиев (1690), Давытов (1672), Дәүләткилдиев (1690), Җансөеров (Сюерев, 1658), Дивиев (1690), Егупов-Черкасский (1627 һәм 1792), Енадаров (1690), Еналиев-Шогеров (1690), Енбарсов (1690), Енгилдиев (1690), Енгалычев (1690), Еникиев (1690), Енодаров (1692), Заманов (1692), Илмәмәтов (1658), Ибердиев (1690), Ишеев (1690), Килдишев (1690), Канбаров (1636), Кошаевлар (1690), Кугушевлар (1658 һәм 1692), Крымский (1690), Кудашевлар (1690 һәм**

**1692), Колычаков (1690), Курмагалин-Мансуров (1680), Кутуев-Кутовлар (1658 һәм 1692), Мамаевлар (1627 һәм 1692), Мәмәтхуҗиннар (1690), Мәмәтов (1690), Мәмлиев (1680), Мангушев (1690), Мансырев (1690), Мещерский һәм Мәлкиев (1690), Моратов (1690), Мостафиннар (1680), Облесимовлар (1690, татарча Әбләсимнән булса кирәк), Сәетовлар (1627 һәм 1692), Сембикаев (1690), Семинеев (1690), Себер Смаиловлары (1627 һәм 1640), Сулышевлар (1627), Тайшиннар (1676 һәм 1692), Тенишевләр (1658 һәм 1692), Тинеев (1690), Тугушев (1690), Төмәнев (1690), Урмышетевлар (1627 һәм 1692), Урысов, Чегодаевлар (1690), Черкеский, Черьяровлар (1690), Шәйдәковлар (1627 һәм 1692), Шәйсоповлар, Ширинскийләр, Шихматовлар (1636 һәм 1692), Йосыповлар (1627 һәм 1692), Ялымов (1690).**

Шушы исемлектә 1690 ел белән теркәлгән 61 фамилиягә сотник дәрәҗәсе бирелә һәм хәрби хезмәт урыннары билгеләнә.

Әмма аларның күпчелеге соңыннан «природный кенәз»ләр исемлегеннән төшеп кала. Кенәзлекне фәкать берничә фамилия генә саклый ала: Мещерский, Черкаский, Дондуков, Урысов, Йосыпов, Тенишев һәм тагын бер-ике кеше. Чөнки Петр патша 1816 елда бик тә усал бер указ чыгара: кем дә кем динен алыштырмый, чукынмый — шулар утар һәм җир биләмәләреннән генә түгел, элгәре бирелгән дәрәҗәләреннән дә мәхрүм ителә. Байтак кына токымнар капма-каршы якка бүленәләр. Әйтик, урыс кенәзләре Тенишевләр булган кебек, чукынмаган татар зыялылары — «чабаталы морза» Тенишевләр да яшәүләрен дәвам иттергән.

## Мещерский фамилияле кенәзләр

Күчкәндә алган фамилияләре, башка урыс кенәзләренә хас булганча, яшәү урыннарына бәйле. *(Әйтик, Смоленскида яшәсә — Смоленский, биләмәгә Вязьма шәһәре туры килсә — Вяземскийлар һ. б.).* Бу кенәзләрнең бабалары элекке урыс һәм мукшы җирләре чигендәге урманлы, саз-баткаклы төбәктә — урысча «мещера» дип йөртелгән урыннарда яшәгәннәр. Шуннан инде «Мещерский» булып киткәннәр. Аларның шәҗәрә башында Мөхәммәт атлы кеше торган. Дин әһеле. Аның чыгышы болайрак аңлатыла: ул Зур Урдадан *(ягъни, Алтын Урдадан)* килеп төпләнгән. Шуннан чыккан Ширинскийлар токымыннан, имеш. Мещерага килү елы — 1298 исәпләнә. Килүенең максаты — җирле халык арасында ислам динен тарату була.

Монда ялгышлык бар бугай. Безнеңчә, ул җирле халыктан чыккан. Болгарда яшәгәндә ислам динен кабул иткәндер дә иленә кайтып шуны таратырга керешкәндер.

Мещерский кенәзләрнең император Беренче Павел чорында (1798 ел) раслангaн герблары мондыйрак: урыс монархлары бүреге астындагы калкан дүрткә бүленгән. Шуның беренче өлешендә *(сулдан беренче)* кара сызыклы мәйданда ике көмеш ярым ай — яңа ай сурәте. Икенче һәм өченче бүлекләрнең җирлеге күк. Икенче бүлектә күк җирлектә — көмеш кальга рәсеме, өченчедә — кулына кылыч тоткан атлы гаскәри. Дүртенче бүлемтәнең җирлеге ике төсле — кара сызыклы һәм күк. Шулар өстеннән көмеш таш күпер сурәте сузылган *(яртылаш күк, яртылаш карасу җирлектә)*.

Алда аталган Мөхәммәтнең бер улы Бикләмеш була. Шул Бикләмеш инде Михаил исеме белән христиан динен кабул итә һәм Мещерский кенәзләрнең шәҗәрәсен башлап җибәрә. Аның оныгы Юрий Федорович Мещерскийның үз полкы белән бөек кенәз Дмитрий Донской ягында Куликов кырында сугышканлыгы мәгълүм. Оста сугыша. *(Ләкин әле, алдан күренгәнчә, Мәскәү кенәзенә турыдан-туры буйсынмый. Ягъни, ул Мәскәү һәм Рязань кенәзлекләре арасындагы бер мөстәкыйль кенәз була.)* Мещераның мөстәкыйль соңгы кенәзе — шәҗәрә башы оныгының улы Юрий Семенович була. Ул, туганы Василий, туганнан-туганнары Константин һәм Иван Борисович Мещерскийлар белән элекке үз биләмәләрен Мәскәүнең бөек кенәзе Өченче Иван тәкъдим иткән вотчиналарга алыштырып, күченә. Шул вакыттан аларның Мәскәү дәүләтендә хезмәтләре башлана. Юрий Семенович оныкларының воевода булып хезмәт итүләре мәгълүм. Григорий Дмитриевич Мещерский 1506 елда Казан ханлыгына каршы оештырылган походта Зур полк белән житәкчелек итә. Константин Борисович Мещерский 1514—1520 елларда Мещерада, аннары Костромада воевода булып тора. Григорий Дмитриевичның ике энесе аерым буын булып аерылалар: Василие Киясларга, Михаилы Висковатыйларга нигез сала. Боларның өчесенең дә уллары

ул чорда югары хәрби чинда булалар: төрле төбәк шәһәрләрендә *(нигездә Мәскәү белән Казан ханлыгы аралыгында)* воеводалар. Алдарак телгә алынган кенәз Иван Борисовичның да оныгының улы — Григорий Федорович Мещерский Казанны алу сугышларында актив катнаша, аннары 1556 елгача Свияжскида воевода була.

Соңрак та Мещерскийлар — гаярь сугышчылар. Михаил Романов патшалык иткән чорда алар токымыннан җиде кеше зур кала-биләмәләрдә воевода булып исәпләнә. Иван Борисович Мещерский варисларыннан булган дүртесе: Богдан Матвеевич — Острог шәһәре воеводасы (1626), Булат Михайлович — Бежескида башлык, Иван Афанасьевич — Торопец шәһәрендә һәм соңрак Мәскәүнең бер өлешендә (1624), Никифор Яковлевич — Серпуховта (1616) һәм Тулада (1624) воевода. Никифор Федорович Мещерский 1611 елда, Новгородта воевода булганда, шведларга каршы нык тора, тик соңрак әсир ителә. Шуннан котылгач та берничә шәһәрдә, шул исәптән Сургутта воевода була, шунда 1652 елда үлә. Семен Федорович Мещерский Беренче Петр заманында батырлыгы белән танылган полковник; ул Анна Иоановна патша вакытында генерал-поручик чинында үлә (1732). Улы Григорий Семенович Елизавета патшалык иткәндә генерал-поручик дәрәҗәсенә ирешә. Шул ук дәвердә һәм шул ук генерал-поручик чинында Федор Васильевич Мещерский да мәгълүм (үлеме — 1756 ел). Аның кызы кенәгинә Наталья Федоровна Николай Иванович Неплюевта кияүдә. *(Неплюевның баштарак Төркиядә илче, соңрак Оренбург губернасын оештыручы губернатор һәм төрки халыкларның гореф-гадәтен, телен яхшы белүче булганы мәгълүм. Соңрак бу токым — күбесе шулай ук татар-төрки морзалардан күтәрелгән — Карамзин һәм Чернышевлар, мәгълүм Татищевлар, Апраксин һәм Строгановлар белән аралашып бетә.)*

## Урысов кенәзләр

Урысов кенәзләр токымы Алтын Урда ханнары һәм әмир Аксак Тимер яраннарына барып тоташа. Шәҗәрәләренең башы Батый хан оныклары чорына туры килә. Батый оныгы Мәнге Тимер ханны Тудай Мәнге үтереп хан була. Ләкин тәхеттә озак утырмый, аны үтерелүченең улы, соңыннан үзе кыпчаклар ханы булган Тукта юк итә. Туктага каршы Мәнге Тимернең туганнары Талабуга белән Акбуга каршы чыгалар. Тукта Талабуганы, ә аның гаскәр башлыгы Нугай икенче туган көчләрен җиңәләр. Нугай ике туганны да кылычтан уздыра һәм соңра, зур көч-куәткә ия булып, Тукта ханга (1290—1315) да буйсынмый башлый. Оста гаскәр башлыклары Мамай белән Идегәй дә шушы Нугай варисларыннан була инде. Идегәй баштарак Аксак Тимер гаскәренә житәкчелек итә. Соңыннан Алтын Урда тәхетен дә яулап алуы мәгълүм. Менә шушы Идегәй варислары — Урысов кенәзләр *(«История..., 391 бит)*.

Идегәйнең ике варисы була: Нуретдин белән Мансур. Нуретдин морза Василий Темный чорынача яши бугай. Ә аның бердәнбер улы Аказ бөек кенәз Иван Өченченең замандашы була. Аның өч улы: Муса, Ямгырҗы һәм Арыслан морзалар — уналтынчы гасыр кешеләре. Муса Рәсәй ватандашлыгын алмаса да, даими рәвештә аралашып, урыс дәүләтенә дус булып яши. Аның сигез улыннан өченчесе, Җаекның аскы агымы һәм Каспий төбәкләрен биләүчесе, Иван Грозныйның атасы Василий кенәз заманыннан ук урысларга даими булышлык итеп килә. Аның исеме Котым морза була. Котым морзаны Герберштейн да истәлекләрендә телгә ала. Шушы Котымнан Рәсәйдә кенәз Котымовлар шәҗәрәсе башлана. Мусаның бишенче улы булган Йосыф морзадан исә кенәз Йосыповлар нәселе китә. Мусаның җиденче улы Шәйдәк морзадан кенәз Шәйдәковлар токымы башлана.

Урысов кенәзләр исә шушы Муса морзаның соңгы, сигезенче улы варислары. Аның исеме Исмәгыйль була. Аның бердәнбер улы Урыслан Мәхмәт Айдарович *(шәҗәрәлектә ул Магмет Айдарович дип ялгыш язылгандырмы, әллә соң Исмәгыйльнең икенче аты Айдар булгандырмы, ачыкланмады)*. Шул нугай морзасы Рәсәйгә күчеп чыга һәм Борис Годунов 1600 елда Касимов шәһәрен биләмәләре белән шул Урысланга (Арыслан) бирә. Унҗиденче гасыр болганышы барышында Урыслан морза 1610 елда Самозванец тарафыннан Калуга шәһәрендә үтерелә. Ләкин тиздән тегенең үзен дә морзаның оныгы — Акарыслан улы Петр Урысов дөмектерә, бабасының үчен ала.

Урысов кенәзләрнең гербы шактый катлаулы: монархия бүреге астындагы калкан җиде өлешкә бүленгән. Дөресрәге, алтыга бүленгән калканның үзәк өлешенә тагын бер калкан уелган. Үзәк калканның җирлеге кызыл һәм урталыкта ярым ай тора, ай тирәсендә дүрт алты кырлы *(борынгы төркиләр билгесе)* йолдыз. Ай да, йолдызлар да алтыннан. Алты бүлемтәнең сулдан беренчесендә — күк төсендәге җирлек, анда кулына ук тотып ак атта чабып баручы җайдак; икенчесендә — көмеш төсендәге җирлектә кулына бөркет тоткан татар кешесе сурәте; өченчесенең җирлеге алтын, анда угы өскә каратылган уклы җәя; дүртенчесендә — яшел җирлектә алтыннан басып торган арыслан сурәте; бишенчесендә — күксел җирлектә канатлы юха елан сурәте; алтынчыда исә — алтын җирлектә сарык тәкәсе рәсеме. *(Күренә ки, бу кенәзләрнең гербында бер генә дә Рәсәй тамгасы юк диярлек, барлык гербларга хас Мономах бүреген һәм калканнарны эченә алган ас мехыннан тегелгән тунны исәпләмәсәң).*

Урыслан-Магмет *(Арыслан Мөхәммәт)* морзаның алты улы булган: Каһан, Ак Арыслан, Сатый, Байтирәк, Касыйм һәм Көбеш. Шулардан беренче өчесе Урысов кенәзләр булып китәләр. Аларның беренчесенең дүрт улы була: Курмыш, Яндан, Бәй һәм Арыслан. Курмыш морза бер ара патша хезмәтендә булып, үз гаскәре *(өч мең чамасы)* белән 1626 елда Әстерханда торса да, динен алыштырмый. Шунлыктан варислары да мәгълүм түгел. Яндан морза чукынгач Борис исемен ала, Мәскәү кенәгинәсе Татьяна Петровна Ахамушокова-Черкасскаяга өйләнә. Ләкин варислар калдырмыйча 1620 елда үлә. Хатыны шуннан монастырьга китә, шунда озак кына яшәп үлә (1646).

Бәй морза чукынгач Петр Канмурзич булып китә, патша Михаил Федорович Романов чорында стольник дәрәҗәсенә күтәрелә, патшаның икенче өйләнүе вакытында (1626) озатып йөрүчеләр арасында була. Арыслан морза хакында хәбәребез юк. Мөгаен, ул да мөселман динендә калгандыр.

Ак Арысланның сигез улы була, шуларның өчесе христиан диненә күчә. Урак — Петр Арысланович була, Зарбәк — Александр Арысланович һәм исәп буенча дүртенче морза Янсох исә Иван Арыслановичка әверелә.

Монда Урыслан Мөхәммәт улы Сатый морза варисы Касыймны искә алу хәерле. Чукынгач ул Андрей Сатыевич Урысов булып язылa. Рәсәй кенәзләре Урысовлар башлыча шушы Андрей варислары була. Чөнки Петр Арыслановичның бердәнбер улы кенәз Василий Петрович Урысов нәсел калдырмый. Федор Алексеевич патшалык иткәндә ул стольник дәрәҗәсенә ирешә, кенәгинә Степанида Ивановна Репнинага өйләнгән була.

Сатый морзаның кенәз Андрей Сатыевичтан башка да уллары була. Шулардан Гали Сатеевич, Йоныс һәм Сөенче Сатеевич исемнәре Михаил Федорович һәм Алексей Михайловичлар патшалык иткән заманда боярлар кенәгәсендә стольник һәм башка хезмәт башкаручылар исемлегендә теркәлгәннәр. *(Алар, мөгаен, чукынмагандыр, шунлыктан варислары теркәлмәгән.)*

Андрей Сатыевич Урысов берничә ел Нижний Новгород воеводасы була, 1647 елда Мәскәүдә үлә. Аның улы Семен Урысов Литва белән сугыш чорында дан казана һәм Брест каласында литва кенәзе Сапеганы 1655 елда әсир итә. Ике елдан соң үлә, дүрт улы кала, дүртесе дә бояр дәрәҗәсендә булалар. Петр Семенович Степанида Строгановага өйләнә, 1686 елда нәсел калдырмыйча вафат була. Минзәләдә воевода булган Юрий Семенович та 1684 елда нәсел калдырмыйча үлә. Дүртенче улы Федор 1681 елда боярлыкка билгеләнә, 1684 елдан Новгород воеводасы вазифасын үти, аннары кабат Мәскәүгә алына, Тупчылар приказы башлыгы була. Анардан бер кыз кала — кенәҗнә Мария Федоровна Беренче Петр патшаның Голландиядәге илчесе кенәз Борис Куракинга кияүгә чыга.

1679 елда бояр итеп билгеләнгән кенәз Никита Семенович, шулай ук Новгород воеводасы, нәселгә уңдырышлы: кенәҗнә Евфимия Щербатова белән икесенең биш улы туа. Беренче Петр патша стольнигы Алексей Никитович Урысовның өч улы була. Кенәз, генерал-поручик Григорий Урысов 1743 елда үлә, ике ул һәм ике кыз калдыра. Кызлары Щербатов белән Гагарин кенәзләргә кияүгә чыга. Василий Алексеевич кенәҗнә Прасковья Долгорукова өйләнә, аның варисларыннан улы Сергей Васильевич һәм кызы Екатерина Урысова бар. Сергей Васильевич 1787 елда үлә. Аның улы Дмитрийдан ике оныгы туа. Сенатор Никита Сергеевичның шулай ук бер улы — Сергей Никитович Урысов һәм кызы — генерал С. Е. Батурин кәләше була.

Генерал-майор, кенәз Александр Васильевич Анна Андреевна Волковага өйләнгән була, кызлары Софьяны гофмаршал барон А. С. Строгановка ярәшәләр.

Полковник Алексей Васильевич Урысов (1722—1796) графинә Екатерина Шереметьевага өйләнгән була. Аларның Василий исемле уллары һәм ике кызлары —

Анна белән Варвара туалар. Үз чиратында Василий Алексеевичның дүрт улы: Алексей, Александр, Николай һәм Петр кенәз Урысовлар туа. Аларның токымтокыясы әлегә барланмаган.

Кенәз Михаил Васильевич Урысов дворянка Алябьевага өйләнгән, ул — булачак обер-камергер һәм Дәүләт советы әгъзасы кенәз Александр Михайловичның (1766—1853) атасы. Александр Урысов Екатерина Татищевага өйләнә, аларның сигез уллары була. Шуларның өлкәне, генерал-лейтенант кенәз Михаил Урысов Нижний Новгородта губернатор, соңрак сенатор, аның хатыны Екатерина Энгельгардт.

Өченче туганнары кенәз Павел Александрович мәгълүм токымнан Александра Уваровага өйләнә, хәрби хезмәттә генерал дәрәҗәсенә ирешә. Алтынчы туганнары Петр Александрович патша карамагында камергер була. Кыз туганнарыннан Мария Александровна беренче мәртәбә Иван Мусин-Пушкинда, икенчесендә кенәз Александр Горчаковта кияүдә була. Кенәжнә Софья Александровна кенәз Деопольд Радзивил белән ярәштерелә. Кече кызлары Наталья граф Ипполит Кутайсовка кияүгә чыга.

Василий Александрович улы генәз Петр Урысов (1755—1803) Александра Салтыковага өйләнгән була, аларның ике кызы һәм генерал-майор дәрәҗәсенә ирешәчәк уллары туа.

Икенче тармак Урысовлар шәҗәрәсенә күчсәк, боярин Никита Семеновичның улы Семен туа, дип әйтелгән иде. Семен Беренче Петр патша фельдмаршалы граф Борис Шереметьевның өлкән кызы Софьяга өйләнгән була. Кайбер мәгълүматларга караганда, Шереметьевлар да тумышлары белән татар токымыннан һәм, имештер, чукынгач та әле дистә еллар буе өйләрендә мөселман динен тотканнар, шул максат белән сарайларында махсус яшерен бүлмә дә корганнар. Боларның ике улы туа, шулардан кечесе Михаилдан нәсел калмый. Василийдан өч ул туа: Сергей (1721—1755), Николай һәм Юрий Васильевич Урысовлар. Сергейның ике кызы һәм нәселсез улы Никита туа. Бу җәһәттән кенәз Юрий Васильевич бик бәхетле — аның алты баласыннан өлкәне, генерал-майор кенәз Николай кенәжнә Хитровага *(шәҗәрә башында шулай ук татар морзасы)* өйләнә, аларның ике улы һәм бер кызлары була. Сергей Николаевич Урысов (1816 елгы) — Дәүләт советы әгъзасы, сенатор, император галиҗанәпләре канцеляриясенең II нче бүлеге идарәчесе. Кенәжнә Елизавета Трубецкаяга өйләнгән.

Нугай Урдасыннан Рәсәйдә мәгълүм фамилияләр алтмышка якынлаша. Шулардан Дәүләт Газый токымы Долотказиннарны, Чаадаевларны, Карамурзин, Еналиев, Янышев, Мурзалимов һәм бүтәннәрне атарга мөмкин. *(«История родов...», II том, 390—398; 400—404 бб.)*

## Кырым ханлыгы бәкләре Кочубейлар

Герблары катлаулы. Төп калкан дүрт өлешкә бүленгән. Иң беренче өске уң кулда кызыл җирлектә алтын ике грек тәресе һәм алты кырлы *(төрки)* йолдыз белән янәшә ярым ай *(болар да алтыннан)*. Икенче һәм дүртенче бүлектә — Кочубейларга Беренче Петр патша тарафыннан тәкъдим ителгән билге — йөрәк сурәте эченә алынган ике янәшә тәре. Бу ике бүлекчәнең җирлеге күк төстә, йөрәк сурәте җете кызыл, тәреләр алтыннан. Өченче бүлекчәнең җирлеге шулай ук кызыл, бүлекчәнең урталыгында көмештән бөркет канаты *(парлы)*, аның өстендә алтыннан учак күренеше, иң аста — күтәрелеп килүче бал корты алтыннан. Калканның сул ягында — сул «кулына» буздыхан *(Кече Русия гетманнары булавасы)* тоткан арыслан басып тора. Уң тарафтан калканга уң кулын куеп украина казагы басып тора. Билендә кылычы. Аның сул кулындагы ту — гаскәри байрак. Байрак уртасында кылыч сурәте, кылычның як-ягында ике ярым ай. Калканның дүрт бүлемтеге бергә тоташкан урында Рәсәй патшалары гербы белән уратып алынган җирлеккә «Н» хәрефе чигелгән. Бу инде кенәзлекне раслаучы патша исеменең баш хәрефенә ишарә. Калкан астында шәҗәрә башлыгы исеменә Беренче Петр тарафыннан әйтелгән мактау сүзләренең латинча язылышы.

Күренгәнчә, бу герб Кочубейлар шәҗәрәсенең барлык чорын, барлык үзгәрешборылышларын эченә алган. Рәсәйгә керү дәверендә генә дә Кочубейларга өч мәртәбә шушындый үзбилгеләр бирелгән. Беренчесе, гади дворянлык билгесе, аларга Беренче Петр патша тарафыннан бирелә. Император Беренче Павел заманында, Рәсәйдә илле өченче кеше буларак (1799 ел, 4 апрель) Виктор Павлович Кочубей граф дәрәҗәсенә күтәрелә. Аннары император Беренче Нико-

лай аны. Рәсәй тарихында уникенче кеше буларак, токымлы кенәз итә *(ягъни, кенәзлек дәрәҗәсе барлык ир һәм кыз варисларына күчә торган дәрәҗә бирә)*. Бу хәл 1831 елда, 6 декабрь указында билгеләнә.

Кече Русия гетманнары тирәсендә пәйда булганчы Кочубейлар Киев кенәзлегенең көньягында *(Кырым ханлыгының төньяк тарафында)* Днестр елгасы буйларында тормыш иткәннәр булса кирәк. Шәҗәрә башларында татар бәкләре торган. 1787 елда Варшавада басылып чыккан һәм Таврия төбәге тарихына караган бер хезмәттә — 83 биттә мондый юллар язылган: Ольгерд *(Литва һәм Киев кенәзлекләренең бөек кенәзе)* туганы Кориятның уллары белән Подолиягә һөҗүм итә. Бу гаскәр дала ягы бәрелешендә татарларның өч чирүен тар-мар итә. Ул урда-төркемнәр башында Квятубаха, Кочубей *(Кече бәй)* һәм Дымейтек торган (XIV йөз).

Шул Кочубей бәй токымыннан берәү XVII гасыр тирәләрендә Кече Русия казаклары ягына чыга.

Төрки дөнья тарихында казакка чыгу мисаллары бик күп. Әйтик, булачак әмир Аксак Тимер дә, атасы үлеп, үзенә тигән биләмә өлешеннән беркадәр читләштерелгәч, «казак» булып китә. Ягъни, тәхет-түрәлектә утырган агай-энегә буйсынмыйча, алар биләмәсенә барымта *(барып талау)* оештыргалап, яу чапкалап берничә ел йөри. Үз тирәсенә ишле генә гаскәр туплаганның соңында гына бәрәм-бәрәм тәхетләр яуларга керешә. Аксак Тимер оныгы Заһретдин Бабыр белән дә шундый ук хәл кабатлана. Ул да яшүсмер чагында агалары тарафыннан кыерсытыла һәм биләмәсез кала. Берничә ел «казаклык»та йөргәч, көч-куәт туплагач, туган-үскән төбәге Фирганәдән китеп, Әфганстан тәхетен яулап ала. Киев кенәзлегенең көньяк өлешендә, Днепр «бусагалары» төбәгендә оешкан, «Запорожье казаклары» дип тарихка кергән казаклар да төрки тамырдан чыккан, урыс язмаларында Черные Клобуки дип аталган зур гына бер халыкның кыйпылчыклары. Кыпчак һәм каракалпакларның бер өлеше христиан диненең Кече Азиядә һәм Кавказда таралган мәзһәбен — Несториан динен үз итү сәбәпле, алар Кырым ханлыгының бер читендәрәк торып кала. Шул ук вакытта алар баштарак Киев кенәзләре тарафдары да булып бетми — ике чик арасында калып, ике як биләмәләрне дә талап көн күрәләр. Алар төркеменә кырым ханлыгы ягыннан да, урыс-малорус биләмәләреннән дә канәгатьсезләр килеп кушыла тора. Шул рәвешле казаклар саны арта. Димәк, Кочубей бәк токымыннан да кемдер, үз яраннары һәм якыннары белән әлеге казаклар төркеменә килеп кушыла.

Казак булып киткән Кочубей, чукынганның соң, Андрей исемен ала. *(Запорожье казаклары тарихын яхшы белгән һәм хәтта бу хакта ярым фәнни бер әсәр дә язган Н. В. Гоголь «Тарас Бульба» романында тәгаен шушы Андрей язмышын да күз уңында тоткандыр кебек.)* Андрейның улы Леонтий тиздән гетман Хмельницкий гаскәрендә уң кулга әверелә — зур дәрәҗәгә ирешә. 1650 еллар тирәсендә Леонтийның улы Василий туа. Гетман шушы яшь Кочубейны *(тел белүен дә истә тотып булса кирәк)* 1675 елда әдернәгә төрекләр белән килешү төзергә җибәрә. Шуннан соң Василий Кочубейның 1687 елларда гетман Мазепаның уң кулы — баш кәтибе булганлыгы мәгълүм. Аннары ул 1694 елда баш казый итеп билгеләнә. 1700 елда Василий Кочубей Рәсәй патшасы Беренче Петр тарафыннан стольник чинында раслана. Нәкъ шул вакытта Кече Рәсәй гетманы Мазепа белән Кочубейлар гаиләсе арасында ара бозыла. *(Бу хәл А. С. Пушкинның мәгълүм поэмасында да тасвир ителә: Мазепа әшнәсенең яшь кызын үзенә карата.)* Шул вакыйгалардан соң Кочубей гетманның кырын эшләре, Рәсәй тәхетенә карата хыянәтчел адымнары турында Беренче Петр ярдәмчеләренә хәбәр иткәли башлый. Ләкин патша станындагы түрәләр аны дөрес аңлап бетермиләр. Ә Мазепа яклылары тиздән бу хакта гетманга да сиздерәләр. Шуның нәтиҗәсендә Василий Кочубей кулга алына һәм каты җәзалаулардан соң, 1708 елның 14 июлендә Белая Церковь каласы тирәсендәге бер авылда үтерелә. Тик берникадәр вакыт үткәч кенә Кочубейның хак булуына, аның ялгыш җәзаланганлыгына төшенәләр, үкенәләр. Үтерелгән стольникның хатынына һәм балаларына тартып алынган җир биләмәләре һәм авыллары кире кайтарыла. Беренче Петр патша аның хакында: «Үлеме белән бөекләгән расланган инсан», дигән мәгънәдәге латин мәкален әйтә. Шул җөмлә соңра Кочубейлар гербына теркәлә.

Кочубейнең Василий һәм Федор исемле ике улы һәм ике кызы кала. Анна — Ободовскийга кияүгә чыга, ә Мазепаның элекке сөяркәсе Матрена гетманның баш кәтибе Чуйкевичка ярәшелә. Василий Васильевич Кочубей янадан хезмәтен Полтава полкында полковник дәрәҗәсендә дәвам иттерә. Аның өч улы үсә: Семен, Василий һәм Павел. Семен Васильевич Кочубей Кече Русия гаскәрендә баш обозчы һәм баш тупчы дәрәҗәсендә хезмәт итә, Кече Русия белән

идарәчеләр коллегиясенә керә. Аның кызы Надежда полковник Потемкинда кияүдә була. Улы Михаил Рәсәйдә действительный статский советник дәрәҗәсенә ирешә. Дворянка Бакуринская белән никахтан аның да фамилиясен дәвам иттерүче улы Николай туа.

Кочубейлар токымындагы өченче Василий *(җәзалап үтерелүченең оныгы)* гетман Разумовский туганының кызына — Марфа Демьяновна Оболенскаяга өйләнә. Үзе югары чинда дәүләт хезмәтендә эшли. Аларның кызлары Елизавета Ив. А. Маркевичка кияүгә чыга. Уллары, шулай ук Василий исемле, Елена Туманскаяга өйләнә. Бу Василийның токымы бик ишле: аларның дүрт улы һәм бер кызлары туа. Өлкән уллары Василий (1784—1844) хезмәт юлын тайный советник дәрәҗәсендә тәмамлый. Ул Варвара Николаевна Рахмановага өйләнә. Аларның өч кызы һәм Василий исемле уллары туа. Олы кызлары Елизавета Васильевнаны икенче буын Кочубейлардан туган кенәз Лев Викторович Кочубейга бирәләр.

Василий Кочубей белән Туманскаядан туган икенче ул — Демьян (1786—1859) Рәсәйдә хакыйкый яшерен советник дәрәҗәсендә, Дәүләт советы әгъзасы була. Аның энесе Александр Кочубей (1788—1866) шулай ук император җәнаплары каршындагы Дәүләт советы әгъзасы дәрәҗәсенә ирешә. Кече энеләре Аркадий Кочубей (1790—1878) сенатор була. Ул 1824 елда кенәгинә Мария Николаевна Вяземскаяга өйләнә. Бу никахтан өч ул туа: Михаил, Василий, Николай. Василий Аркадьевич Кочубей кенәгинә Наталья Петровна Салтыковага, ә Николай Аркадьевич исә графинә Столыпинага өйләнәләр. Сеңелләре Елена Кочубей (1793—1863) действительный статский советник, император фәннәр академиясенең гамәли әгъзасы А. В. Маюровта кияүдә була. «История родов...» китабы 1886 елда нәшер ителгәнлектән, шәҗәрәнең дәвамы юк. Гражданнар сугышы дәверендә Төньяк Кавказ төбәгендәге атаклы «кызыл атаман» Кочубей бу шәҗәрәнең кайсыдыр тармагыннан булырга тиеш.

Беренче Петр заманы стольнигы Василий Леонтьевичның кече оныгы Павел Васильевич — Кочубейларның Рәсәй дәүләте хезмәтендәге икенче тармагы башында тора. Павел Васильевич Кече Рәсәйнең баш казые, мәгълүм Андрей Яковлевич Безбородко кызы Ульянага өйләнгән була. Дәүләт эшендә үзе статский советник дәрәҗәсенә ирешә. Аларның ике кызы: Аграфена — бригадир *(хәрби чин)* А. Фролов-Багреевта, Александра Павловна исә яшерен киңәшче Г. П. Милорадовичта кияүдә булалар. Өлкән уллары Аполлон Павлович Кочубей император галиҗәнапләренең камергеры хезмәтен башкара.

Бу токымның иң күренекле шәхесе Виктор Павлович Кочубейны (1768—1834) әби патша егерме дүрт яшендә Төркиягә илче итеп җибәрә. 1798 елда исә император Беренче Павел сәләтле яшь Кочубейны вице-канцлер итеп күтәрә. Өченче император — Беренче Александр Виктор Павловичны Эчке эшләр министры итеп билгели. Ул Дәүләт советы әгъзалыгына сайлана.

Император Беренче Николай заманында Виктор Павлович Кочубей Дәүләт советы рәисе һәм канцлер дәрәҗәләренә күтәрелә. 1831 ел 6 декбрь указы белән ул Рәсәйдә мөмкин булган иң югары хөрмәткә лаек була — «нәселле кенәз» исемен ала. Ягъни, Рюрик, Мономах, Долгорукийлар токымыннан ук килүче «табигый кенәз»ләр белән тиңләшә.

Виктор Павлович Кочубей булачак кенәз токымыннан (1839 елдан) Мария Васильевна Васильчиковага өйләнә. Аларның бер кызы һәм дүрт уллары туа. Өлкәне — действительный статский советник Лев Викторович Кочубей (1809—1886 елдан соң) Елизавета Васильевна Кочубейга, камергер Василий Викторович Кочубей (1811—1850) кенәгинә Елена Павловна Бибиковага, Михаил Викторович Кочубей (1813 елда туган) кенәгинә Мария Ивановна Барятинскаяга өйләнә, хезмәтендә гормаршал дәрәҗәсенә ирешә. Сергей Викторович Кочубей (1819—1880) действительный статский советник, Полтава губернасы дворяннары башлыгы була, граф Бенкендорф кызы Софья Андреевна Демидовага өйләнә. Наталья Викторовна Кочубей граф Александр Григорьевич Строгановка кияүгә чыга. *(Бу күренекле сәүдәгәр һәм промышлинникларның да бабалары татар токымыннан.)*

Кочубейларның бу тармагыннан (унтугызынчы гасыр азагында) фәкать канцлерның улы кенәз Сергей Кочубей гына токымны дәвам иттерә — аның ике улы бар. («История родов...», II том, 26—29 б.)

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН**

#ҺӘР ЯЛТЫРАГАН АЛТЫН ТҮГЕЛ

**1552** елдан бирле әсирлектә яшәп килгән татар халкының үзаңын бутау, тарихи хәтерен югалту юлында Русия туктаусыз эшләп килә.

Татар дәүләтләре буйсындырылгач, урыс хөкүмәте халкыбыз тарихына, мәдәниятенә тиңе күрелмәгән эзәрлекләү сәясәте уздырды. Алтын Урда, Олы Урда, Казан, Хаҗи Тархан, Себер, Касыйм, Кырым ханлыкларының дәүләт документлары соңгы битләренә кадәр юкка чыгарылды. Гаҗәп, хәтта бәйсезлеген югалткан Польша дәүләте дә татар ханнары белән булган аз санлы дипломатик документларны саклап калган (мәсәлән, Туктамыш ханның Польша короле Ягайлого 1392—1393 елларда язган бер ярлыгы һәм бер хаты). «Описание царского архива»[1] дигән китапта Казан ханлыгының йөзләгән дәүләт документлары урыс падишаһлары архивында саклануы күрсәтелә, ләкин ул исемлектәге Казаннан алып кителгән китаплардан урыс дәүләтендә бер бит язу да юк.

Яулап алучыларның тырышлыгы белән татар халкының формалашу, тарих кичү дәверенә караган документлар кеше кулы җитәрлек урында калмаган диярлек. Халыкның тарихи аңы телдән яшәгән «Чыңгызнамә», «Идегәй», «Чура батыр», «Гайсә углы Амәт», «Каһарман» кебек дастаннар сюжетларында гына сакланган.

Бу дастаннар гасырлар кичеп килгән һәм аларда узганга мөнәсәбәт реаль чагыла. Санап үтелгән әсәрләр һәм аларның төрле вариантлары, нәсел шәҗәрәләре белән берлектә, милли тарихыбыз белән кызыксынучылар өчен илһамлы чыганаклар системасын тәшкил иткәннәр.

Татар халкының 1552—1775 еллар дәвамында милли азатлык һәм бәйсезлек өчен алып барган кораллы каршылыгы колонизаторларның татарларга карата уздырылган милли сәясәтенә үзгәрешләр кертергә мәҗбүр иткән. Тупас хәрби көч, икътисадый һәм социаль изү юлы белән генә басып алынган халыкларны буйсындырып тотуга ирешмәячәкләрен аңлыйлар һәм коллык урнаштыру өчен булган агрессияне идеологик яссылыкка күчерәләр.

Милли изүне саклауга хезмәт иткән кануннар тезмәсе, дини хурлаулар өстенә дәүләтнең рәсми идеологиясен чагылдырган урыс тарихы татар халкы үткәнен иң оятсыз хурлау юлына баса.

Христиан уку йортларындагы православие галимнәре татар халкына каршы уздырылган геноцид сәясәте өчен яңа «рецептлар» әзерли. Моның нечкәлекләре Е. Малов көндәлекләрендә бик тулы чагыла *(Идел, 1993, № 5—8)*.

Шушы дәвердән Русия шартларында милли изүнең идеологик юнәлеше алга чыга. Идеологик юнәлешнең асыл максаты халыкның тарихи аңын югалту һәм урыслашуга юнәлтү була.

Миссионер Ильминский даирәсе тәэсирендә үскән В. И. Ленин һәм аның рус шовинизмы чире белән «җәфаланган» коммунист-большевиклары 1917 елдан соң милли сәясәткә Русиянең әүвәлге «кадерле» багажын ала. Коммунистлар партиясе, милли мәсьәләдә бик тирән һәм еракка китә торган планнар белән мавыгып, бу эшкә СССР Фәннәр Академиясе институтларын да җәлеп итә.

Әлеге фәнни оешмалар урыс колониаль империясе тырнагына эләккән һәр халыкның тарихларын үзләре өчен өйрәнеп, куелган бурычка хезмәт күрсәтә башлый.

Тарих тулаем сәясәтчеләрнең максатларын аклау коралына әйләнеп бетә. Коммунистлар партиясе тарафыннан уздырылган бөтен канлы

[1] Описи царского архива XVI века и архива посольского приказа 1614 года. Изд-во Восточной литературы. М., 1960. 193 б.

җинаятьләрне тарихи «хакыйкать»не торгызу итеп белдерәләр.

Төрле халыкларның тарихларын фальсификацияләү башлана. Русия патшаларының мәкерле яулап алу сугышларын бөтен СССР халыкларына иң гадел һәм прогресска хезмәт иткән эшләр дип ышандыралар. Дагыстан азатлык хәрәкәтенә 30 ел җитәкчелек иткән каһарман Шәех Шамилгә «инглиз шпионы» дигән ярлык тагалар.

Урыс коммунистлары, Һитлер белән килешеп, 1939 елның сентябрендә Польша дәүләтен өзгәләп ташлый. Шул көннәрдә басылган «Правда» газетасы мәкаләләре Польшаның җимерелүенә эчке шатлыгын яшерә алмый.

Икенче империалистик сугыш тынганнан соң да СССРда урыстан башка милләтләрне җәберләү сәясәте дәвам итә һәм әлегәчә туктаганы юк. Җәберзолым торган саен арта гына бара. Тарихлары бозылып, халыкларны бер-беренә каршы кую сәясәте дә торгынлык елларында чәчәк атты. Татар халкына карата башкортны, чуашны, марины, удмуртны һ. б. котырткан материаллар басылды.

1973 елда Чабаксарда чуаш телендә басылган «Палнай» (Чуаш халык балладалары һәм җырлары җыентыгы) китабы бу җәһәттән аеруча кызык. Анда татар, урыс һ. б. халыклар исемен дә белмәгән «Вутла тавал пек килче Супетей» («Утлы давыл кебек килче Сүбүдәй») исемле җыр бирелгән. Бу җыечтыкта «карак нугай», «Мамык хан», «Истанбул», «Пугачев» кебек тарихи темаларга, шәхесләргә бәйле тарихи балладалар бар. Ләкин аларның халыктан чыккан булуы гына шөбһә уята. Җырларның тел төбе татарга дошманлык арттыруга хезмәт итә.

Мәскәү властьлары тарафыннан татарларның бабаларын, тарихларын бутау өчен чыгарылган «болгарчылык» концепциясе Идел буе халыкларының берсен дә канәгатьләндерерлек түгел иде. Бу концепция татарларга каршы чуашларны, мариларны, удмуртларны котырту өчен шәп табылдык булды, аның хәзер дә көн тәртибеннән алынганы юк.

Әлбәттә, бу мәсьәләне әле саналган барлык халыклар тарихына кагылышлы рәвештә чишәргә мөмкин. Ләкин иң элек этник тарих хронологиясе анык куелырга тиеш.

Болгарларның бүгенге чуашларга тарихи мөнәсәбәте. Чуаш халкы формалашу тарихы XIX гасыр башында гына төгәлләнә. Аңа хәтле, XII гасырда хәзерге Чуаш республикасы төбәгендә яшәгән мәҗүси (өлешчә мөселман) болгарлар өстенә килеп утырган күпсанлы мари ыруларын авыр шартларда ассимиляцияләү барган. Бу процесста катнашкан болгар ырулары аздан гына юкка чыкмый кала һәм, үзләренең күп мирасларын югалтып, яңа этнос тәшкил итә. Алар үзләренә марилар кушкан суас (чуаш) этнонимын кабул итеп ала. Марилар аларга карата, тарихларын хәтерләп, «суаслы мари» (чуашлы мари) этнонимын бүгенге көнгә кадәр кулланалар. Бүгенге чуаш җирендә булып узган бу тарихи болгар-мари тел контакты XII—XVIII гасырлар дәвамында барган. Владимир-Суздаль князьлеге кул астына эләккән угыр-фин халыкларын көчләп чукындыру башлангач, алар XII гасырда болгар дәүләте җиренә күчеп утырган[1].

Бүгенге мари һәм удмуртлар составына болгарларның төньяк тармагы — бисерманнар (татарча почырманнар) аз кермәгән. Бисерманнар шулай ук Нократ буйларына утырган татарлар арасында да очрыйлар.

1236 елда, монгол һөҗүмнәре вакытында, болгарларның бер өлеше Ука елгасы буйларына күчеп утырган һәм алар анда урыс халкы арасында эрегән.

Бу этник процесслар барган җирләр ул вакытларда Русия дигән дәүләт биләмәсен тәшкил итмәгән, киресенчә, ул җирләр татар дәүләтләре карамагында булган. Этнос мәсьәләсенә килгәндә, мөселман болгарлар инде XV гасыр башында аерым берәмлек тәшкил итүдән туктыйлар, Идел-Чулман буендагы халыклар составына кереп эриләр.

Татарларга карата уздырыла торган икенче зур бер провокация аларның РСФСР өлкәләре һәм республикалары составында калган этник төркемнәренең үзаңнарын бутау.

Бүгенге көндә Башкортстан республикасында калган милләттәшләребезне башкортлаштыру, Себер татары белән Идел буе татары арасына чөй кагу, Әстерхан өлкәсендәге татарларны аерым нугай халкы итеп тәрбияләргә тырышу һәм башкалар бара. Бу эшләрдә элеккеге партократия чиновниклары башлап йөри.

Моннан тыш, Татарстанның үзендә һәм һәр өлкәдә, республикада татар тарихын ваклап бозу туктаусыз дәвам итеп килә. Андый бозуның иң соңгысын филолог Леонид Арсланов язмала-

[1] История Татарии в материалах и документах. М., 1937. 7 б.

рында күрергә була[1]. Ул бернинди тәнкыйть күтәрмәслек фикерләре белән фәнни җыентыкларга килеп керә. Бу кешенең тел төбе яхшы мәгълүм: имеш, татарлар мари җиренә утырган. Л. Арсланов Татарстанның Казан арты һәм Кама аръягы төбәкләрендә, бу җирләрдә, урта гасырлардан бирле яшәгән угыр-финнәрнең гидронимия атамалары калган дип расламакчы була, ләкин дәлилләре көлке дәрәҗәсендә генә. XVII гасыр уртасына кадәр нугай далалары составына кергән Кама аръягында нинди чирмеш, ар, коми, хантылардан калган топонимнарны саклаган «Академия» яшәде икән? Ник дигәндә, бу төбәкнең утраклык тарихы XIV гасырларда бетеп, XVII гасырның уртасыннан яңадан башлана. Казан арты исә XI—XII гасырлардан бирле болгарлар җире була.

Бүгенге татарларның Алтын Урда тарихы белән бәйләнешләре дә күп дистә еллар дәвамында бозылып күрсәтелде. Бу өлкәдә әдәбият, тел галимнәре хезмәтләрендә уңай фикерләр күренсә, эзәрлекләнделәр (проф. Әмир Нәҗип язмышы гыйбрәтле).

Совет тарих фәненә татар халкының Алтын Урда дәүләтенә мөнәсәбәтен ачтырмау өчен, түбәндәге ялган концепцияләр килеп керде:

**1.** Бүгенге татарлар — турыдан-туры Болгар дәүләтенең халкы, ул татар түгел. Казан ханлыгы — Болгар дәүләтенең турыдан-туры варисы.

Әлеге концепцияне ныгытырга теләп көчәнүчеләр соңгы елларгача эшләп килә. Ләкин дәлилләр башка нәрсә хакында сөйли. Татар шәҗәрәләре борынгы татарлар, кыпчаклар, угызлар белән кардәшлекне күрсәтәләр. Соңгы елларда уздырылган фәнни анализлар Идел-Урал буе татарларының килеп чыгышында төп рольне Нугай урдасы халкы уйнаганын ачыклый[2].

Болгар дәүләте һәм халкы өчен төп тарихи чыганаклар булып хезмәт иткән болгар эпиграфикасы материаллары XIII—XIV гасыр дәвамында болгарларның татарлаша бару процессын гына күрсәтә. Ул чорда болгарларда «икетеллелек»нең ни белән беткәне ачык мәгълүм. Ташъязмаларда болгар теле югала бару процессы күренә.

Алтын Урда 1243 елны төзелгәч, аның идарәсе бөтен баскычларда да Чыңгыз нәселеннән булган хан һәм солтаннар кулында була. Батый хан башкаласы Болгарда тагы нинди булса да (җиңелгән) ханның утыруына юл куйган дип ышанып булмый. Әүвәлге Болгар дәүләте милли автономиясен Алтын Урда составында саклый алмаган. Болгар дәүләте улус статусында калып, аның белән Чыңгыз нәселеннән булган солтаннар — улус биләре идарә иткән.

**2.** Болгар улусын «Алтын Урда феодаллары килеп талаган» дигән сүз бер мантыйкка да сыймый. Болгар улусын урыс ушкуйниклары һәм князьләренең талаулары 1229 елда туктап калганнан соң, 1359 елдан яңадан башлана һәм бик тиз көчәя бара. XIV гасырның соңгы 40 елында алар Болгарны тәмам бөлдерә. Аксак Тимер исә 1395 елны Идел буеның Казаннан түбән бөтен татар шәһәрләрен нигезенә кадәр җимерә. Болгарларның калдыклары яңа оешып килгән Нугай урдасы кул астындагы татар ыруларына кушыла һәм Идел-Урал буенда яшәгән урман эчендәге ыру-кабиләләр арасына кереп эри. Казан тирәсендәге болгарлар үзләре чакырып китергән татарлар белән кушылып китә. Әлеге процесс XVI гасыр урыс әдәбияты ядкаре «Сказание о царстве Казанском» әсәрендә дә чагыла[3].

Урта Иделгә килгән татар отрядлары чыгышлары буенча Кырым һәм Кара диңгез буйларыннан була. Шунлыктан Кырым һәм Идел-Урал буе татарларының этник кардәшлеген инкарь итеп язучы тарихчылар шулай ук ялганлау белән шөгыльләнүчеләр исәбенә керә.

---

[1] Арсланов Л. Ш., Казаков Е. П., Корепанов К. И. Финны, угры и самодийцы в Восточном Закамье (III в. до н. э.—XIV в. н. э.). Елабуга, 1993; Арсланов Л. Ш. Марийский пласт в топонимии Елабужского района Татарской АССР.—«Советское финно-угроведение» V., 1987, № 2, 101—104 б.б; Арсланов Л. Ш. Топонимия финно-угорского происхождения в районах Западного и Восточного Закамья Татарской АССР.—«Вопросы марийской ономастики». 6 чыгарылыш. Йошкар-Ола, 1987. 78—88 бб.

[2] Булатов А. Б. Некоторые материалы о ногайско-татарских связях в прошлом.—«Материалы по татарской диалектологии», Казан, 1974. 186—190 бб.; Әхмәтҗанов М. Идел-Җаек арасы.—«Идел», 1991, № 10—11, 63—65 бб.; Әхмәтҗанов М. Татар халкы оешуда нугайларның катнашы. «Идел». 1992 № 3—4, 58—65 бб.; Әхмәтҗанов М. Юрматы шәҗәрәсе.—«Идел», 1993, № 1, 48—49 бб.; Әхмәтҗанов М. Нугай урдасы һәм аның татар этник тарихына мөнәсәбәте.—«Из истории Золотой Орды». Казан, 1993, 142—160 бб.

[3] Сказание о царстве Казанском. М., 1959. 33, 231 бб.

3. Тарих фәнендә: «Татар этнонимын безгә урыслар таккан, безнең бабаларыбыз болгарлар булган»,— дип лаф орып йөрүчеләр бар. Урыс колониаль изүе астына эләккән халыкның бердәм милли этнонимын сакларга дүрт йөз ел дәвамында мөмкин булмады. Асыл болгарларның безнең өчен телләре дә, китаплары да, фольклорлары да, эзлекле тарихлары да сакланмаган. Алар Алтын Урда татар халкын барлыкка китерүдә өлеш булып катнаша. Шунлыктан бүгенге халкыбызның «татар» дип аталуына бер шөбһә дә булырга тиеш түгел. Татар исеме абруйлы, без аның абруен тагын да күтәрү юлы белән генә бүтәннәр алдында мәртәбә казана алырбыз. Болгар исемен яңартырга тырышып йөрү татар милләтенә карата уздырылган геноцид сәясәтенә риза булу дигән сүз. Исемнәрен алыштырып кына бүгенге украиннар, үзбәкләр, алтайлылар, марилар һ. б. бәхеткә тиенә алмадылар. (Неоколонизаторлырның урыстан башка бер халыкны да хөрмәт итмәгәнлекләре соңгы алты ел эчендә Русиядә бик ачык күренде. Русия башында утыручы идарәче даирәләрнең фашистик рухын кемнәр күтәргәне дә узган елның декабрендә Думага сайлаулар вакытында яхшы күренде).

Шушы максат белән әвәләнгән «Шан кызы дастаны», «Бараҗ дастаны», «Җәгъфәр тарихы» кебек зур күләмле кеше ышанмаслык тарихлар, дастаннар татар тарихын бутауның ифрат тирәнәя барганын күрсәтәләр. Ләкин бу әсәрләрнең фальшивкалар икәнлеге дәлилле рәвештә матбугатта кире кагылды[1].

Тарихыбызны бозу, әлбәттә, аның һәрбер почмагына кагыла. Бу очракта бүгенге татар халкының иң мөһим тарихи мәсьәләсенә — килеп чыгышына багланышлы фикерләр бәян ителде.

Этник тарих, кайберәүләр уйлаганча, әйберләрнең механик кушылмасы гына түгел, ул гаять катлаулы һәм дәвамлы процесс. Шунлыктан аны өйрәнүгә намуслы һәм җитди тикшеренүчеләр алынуы кирәк. Бары алар гына дөрес юлга басып, яңа чыганакларга таянып, хакыйкатьне ачар. Алтын Урданың этник тарихын барлау өчен, татар, кырым татары, башкорт, Кече жөз казакълары, каракалпак, нугай, үзбәк шәҗәрәләре комплексын өйрәнү гаять мөһим ачышлар ясарга мөмкинлек бирер иде.

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

[1] Ю з и е в Н и л. Олы ачышмы, әллә...— «Ватаным Татарстан», 1993, 11,12 май, № 92—93; А х м е т з я н о в М. По поводу одной публикации.— «Независимость», 1993, № 4; Ә х м ә т җ а н о в М. Ялганның аягы кыска, яки без ничек «бетле татар» булдык.— «Идел», 1993, № 5, 61—65 бб.; Ә х м ә т җ а н о в М. Күпме ялганларга мөмкин.— «Мирас», 1993, №9, 113—116 бб.

# БОРЫНГЫ ОТКРЫТКАЛАРДА — КАЗАН

**Хәтер — тарих ул. Хәтер булмаса — тарих юк. Тарих булмаса — халык юк.**

*Фрэнсис Бэкон.*

Узганыбызны чагылдыручы рәсемле открыткаларны һәр өйдә диярлек очратырга була. Мондый открыткаларны җыю белән мавыгучыларны филокартислар дип атыйлар.

«Филокартия» атамасы грекчадан «яратам» һәм латинчадан «карта» яки «бит» сүзләреннән килеп чыккан.

Открыткалар җыю — файдалы шөгыль. Бу мавыгу кешенең дөньяга карашын киңәйтә, культура дәрәҗәсен үстерә. Гадәттә открыткалар альбомга яки аерым битләргә теркәлә, ә инде аларның саны меңнән артып киткән очракларда аерым тартмаларда саклана.

Коллекция җыючының тулы эшчәнлеге өч өлештән тора: беренчедән — материал туплау; икенчедән — аны системага салу, эшкәртү һәм саклау; өченчесе (иң мөһиме) — коллекциянең җәмгыятькә хезмәт итүе, кешеләргә файда китерүе. Шәхси бер коллекциянең дәүләт эшчәнлегендә зур роль уйнавын күрсәтүче дәлилләр дә бар: Бөек Ватан сугышы чорында дошман басып алган шәһәрләрнең, фашистлар карамагында булган урыннарның күренешен сурәтләүче открыткалар кирәк була. Ә мондый бай материал исә танылган филокартист М. Тагринның открыткалар коллекциясеннән алына. Аның коллекциясендә миллионга якын открытка булган. Бу открыткалар җентекләп өйрәнелә. Хәрби бурычны үтәүче очучылар карталарда да күрсәтелмәгән аеруча җаваплы ориентирләр белән танышалар, партизаннар аларны үзләренең планнарына кертәләр, командование булачак сугышлар өчен уңайлы урыннарны билгеләп куя. Кайбер илләрдә шәһәр күренешләрен сурәтләүче открыткалар номерлар куеп чыгарыла. Әгәр бу открыткаларны тәртип саны буенча тезеп карасаң, шәһәрнең кечкенә генә панорамасы килеп чыга.

М. Тагрин коллекциясенең файдасы зур булган. Сугыштан соң Совет Армиясе командованиесе аны күпсанлы трофейлы открыткалар белән бүләкли. СССР фәннәр академиясе президиумы аның коллекциясен «Безнең чор культура тормышының энциклопедиясе» дип билгеләп уза.

Хәзерге вакытта, үзе үлгәннән соң, коллекционерның теләге буенча, аның әлеге хәзинәсе дәүләт милке булып санала. Бу коллекция нигезендә почта открыткалары музее төзелә. Аның өчен махсус бина да билгеләнә.

Мәскәүле М. С. Забоченның йөз меңнән артык открыткадан гыйбарәт коллекциясе дә җәмгыятькә зур файда китерә. Аның открыткалары Шевченконың ике томлык сүзлегенә кертелгән. Киевтәге Л. Украинка музее да коллекционерга чит илләрдә шагыйрә дәваланган шәһәрләрне күрсәтүдәге ярдәме өчен М. С. Забоченга рәхмәт белдерә.

Безнең көннәрдә күп кенә тарихчылар, киночылар, архитекторлар, музей хезмәткәрләре һәм башка сәнгать белгечләре хезмәтләрендә файдалану өчен борынгы открыткаларны эзлиләр. Әйтик, Ялта һәм Таганрогның А. П. Чехов чорындагы яки И. Е. Репин яшәгән «Куок-кала» станциясендәге агач вокзалның элеккеге күренешен бары тик шул заманда чыгарылган открыткалар гына гәүдәләндерә ала.

Тагын бер мисал. Петербург шәһәрендә трамвай беренче тапкыр 1895 елда Нева елгасы аша җибәрелә. Кышын бозга рельслар сузылган һәм трамвайлар ике яр арасында йөргән. Ул вакытлар инде күптән артта калды, ә «Нева трамвае» күренеше исә открыткаларда әлегәчә саклана.

Шундый бер хәл булган, открытка хәтта җинаять эшен ачарга да ярдәм иткән. Бер ханым бриллиант муенсасын ламбардка куйган була. Ләкин анда муенсаны үз бәясеннән түбәнрәккә бәялиләр, ә муенса хуҗасын исә, залогны азрак түләргә була, дип тынычландыралар һәм муенсаны, тиешле бәясе түләнеп беткәч кире кайтарып бирәбез, дип ышандыралар. Әмма боларның берсе дә үтәлми. Муенса юкка чыга, аны алырга дип килгән иясенә тиешле акчаны квитанциядәге бәя белән генә түлиләр. Ә муенсаны кайтарып алу, яисә аның бәясен исбатлау өчен дәлил кирәк. Шул чакта открытка ярдәмгә килә. Әлеге муенса элек танылган бер

актрисаныкы булган. Актрисаның муенсаны киеп төшкән портреты сурәтләнгән открытка сакланган булып чыга һәм ул җинаятьчеләрне тизрәк табарга ярдәм итә. Җинаятьчеләр тиешле җәзаларын алалар.




*Хат ташучы.*

Рәсемле открыткалар кайда һәм кайчан барлыкка килгән? Беренче карашка гади булып тоелган әлеге сорауга хәзергә кадәр төгәл җавап юк. Борынгы Мисырның Бәнигассандагы (Б. э. к. 4000 ел) фрескаларның берсендә кулына сурәтле һәм язулы ачык бит тоткан атчабар тасвирланганы мәгълүм. Кайбер коллекционерлар шушы битне открытканың беренче үрнәге дип саный. Аралашуга мохтаҗлык адәм баласына борынгыдан ук хас. Аурупа, Азия, Төньяк Американың кыяларында һәм мәгарә диварларында аучыларның сурәте, ауга чыгу күренешләре, кешеләр һәм хайваннар сурәтләре сакланган. Бу рәсемнәр (петроглифлар) ерак бабаларыбызның тормышын һәм көнкүрешен чагылдыралар.

Беренче Вавилон нәселе чорыннан ук килгән ике хат, мәсәлән, Лувр музеенда саклана. Аларның берсе Җамал — Мардуктан Бибиягә, икенчесе Навиртумнан Хусутиягә атап язылган. Болар чөй рәвешендәге язма кулланып, балчык тактачык өстенә төшерелгән. Шундый ук тактачыкларны инглиз Ляйярд Ассирия патшасы сараенда да тапкан. Үзара язышу серен саклау өчен, ул тактачыкны балчык белән сылаганнар һәм аның өстенә адрес язылган. Балчык тактачык яндырылган һәм «конверт» язманы ныклап каплаган. «Хат»ны ачарга кирәк булса, тактачыкны кабат яндырганнар. Бу вакытта барлыкка килүче су парлары ярдәмендә конверт язмадан бик җиңел аерылып төшә. Шуңа күрә, Мисырдагы «ачык бит» рәсемле открытканы хәтерләтсә, Ассирия һәм Вавилонның конверт сыман әйбер эченә салынган балчык тактачыкларны рәсемле һәм гадәти почта открыткаларының иң беренче үрнәкләре дип санарга мөмкин.




*Татар мөгаллимнәр мәктәбе.*

1717 елда Беренче Петр Петербургта почтамт оештыра. Әмма хатлар, нигездә, очраклы кешеләргә биреп җибәрелгән. 1772 елда элегрәк ачылган ямчылык идарәсе бетерелә һәм өч елдан соң, почта кәнсәсе булган җирләр дә, ямчы почталары да ябыла. 1833 елга кадәр бары тик байлар гына асраулары, хезмәтчеләре аша хат, чакырулар җибәрә алганнар. 1833 елда Петербургта шәһәр почтасы барлыкка килгәч, аннан гади кешеләр дә файдалана башлаганнар. Мәскәүдә шәһәр почтасы 1845 елда оештырыла. 1850 елдан башлап Варшавада, Казанда һәм тагын башка шәһәрләрдә дә почталар ачылган.

Почта открыткалары беренче тапкыр дөньяда 1869 елда барлыкка килә. Аларны 83x123 мм үлчәмле калын саргылт кәгазь бите рәвешендә Австрия почта идарәсе чыгара. Битнең кырыйларына әлләни катлаулы булмаган кыса ясалган, кыса эчендә, өске өлешкә алман яки мажар телендә «хат язу өчен карточка» дип язылган. Ә аннан бераз уң яктарак, ике крейцер бәясендәге лимон төсле почта маркасы ябыштырылган. Аскы өлешкә ясалган сызыклар өстенә адрес язарга мөмкин булган.

Шулай да, почта открыткасын уйлап табучы булып Пруссиянең оберпочтмейстеры Һенрих Штефан санала. Ул 1865 елның 30 ноябрендә Карлсруэ (Алмания) шәһәрендә узган «почта бите» рәвешендә ачык хәбәрләшү кертергә тәкъдим итә. Ләкин аны җибәрү кыйммәт булу сәбәпле, бу тәкъдим кире кагыла.

Австриянең беренче открыткалары рәсемсез була. Болай дип сөйлиләр: «Франция-Пруссия сугышы вакытында Бретаньнең Конли дигән бер җирендә 1870 елда, күз күне Франциянең күпсанлы гаскәре җыела. Булган барлык почта кәгазе бетә, бер конверт та калмый. Галәмәт зур буталчыклык килеп чыга: гадәти конвертлар урынына почтага теләсә нинди кәгазь ертыкларына язылган хатлар керә башлый. Моннан гаять эшлекле җирле сәүдәгәр Леон Беснардо оста фай-





*Апанаев җәйге театры.*

далана. Ул үзендә булган бристоль картонның 66x98 миллиметр үлчәмле карточкаларга кисәкли һәм аларны сата башлый. Шунда ул кайбер солдатларның карточкаларга язып кына түгел, рәсемнәр дә ясап җибәрүләрен күрә. Леон Беснардо әлеге карточкаларга ватандар эчтәлектәге гади генә рәсемнәр дә бастыра. Менә болар инде — дөньяда иң беренче рәсемле открыткалар. Алар шулкадәр табыш китерәләр ки, чая сәүдәгәр хәрби кирәк-ярак һәм кораллар сурәтләнгән тагын бер рәсемле открытка партиясен сатуга чыгара.

Әмма алманнар беренче рәсемле открытка Алманиядә чыккан дип саныйлар. Түбән Саксониянең Ольденбург шәһәрендә яшәүче сәүдәгәр А. Шварц 1870 елда сатуга артиллерия солдаты рәсеме төшерелгән открыткалар чыгара. Бераз вакыт үткәч, үзе нәшер итә торган «халык хәбәрчесе» журналыннан берничә рәсем алып открыткалар эшли һәм аларны ике серия бастыра.

Открытка сату бик табышлы эш булганлыктан, башка сәүдәгәрләр дә рәсемле почта открыткалары чыгаруга керешә, шулай итеп, алар тиз арада бөтен дөньяга тарала.

1874 елда егерме ике ил вәкилләре Швецариянең Берн шәһәренә Бөтендөнья почта корылтаена җыела. Аның төп нәтиҗәсе — Бөтендөнья почта берлеге оештырылу. Шунда ук транзит почта җибәрү өчен бертөрле почта бәяләре раслана һәм халыкара почта элемтәсен үстерүгә юнәлдерелгән башка килешүләргә кул куела. Бу корылтайда хат-открытканың халыкара үлчәме гамәлгә кертелә, ул 90x140 миллиметр зурлыкта була. 1925 елда исә 105x150 миллиметр итеп үзгәртелә.



*Болак буе ярминкәсе.*

Русиядә почта карточкалары рәвешендәге ачык хатлар 1871 елда гамәлгә кертелә. Баштарак аларны бернинди бизәксез гади бланклар рәвешендә чыгаралар. Тора-бара рәсемле открыткалар да барлыкка килә башлый.

Шартлыча беренче урыс рәсемле открыткасы 1895 елда чыгарылган дип санала. Ул Мәскәү шәһәренә багышланган һәм аның өске ягына өч рәсем (А. С. Пушкин һәйкәле, Сухарев манарасы һәм инглиз чиркәве) файдаланылган. Открытка чәчәкләр белән бизәп эшләнгән.


Ике елдан соң изге Евгениянең Кызыл Хач оешмасы рәсемле дүрт открытка бастырып чыгара. Бу оешма 20 ел эчендә 30 миллион данә открытка, шул исәптән, Русиянең 200 географик урынын сурәтләгән 3 мең открытка бастырып чыгара.

Рәсемле открыткалар чыгару эше күп кенә шәһәрләрдә, шул исәптән, Казанда да җайга салына. Кызганыч ки, аларның чыгарылу көннәре күрсәтелмәгән һәм беренче чыгарылган открыткаларның басылу вакытларын почта аша җибәрелгәндә сугылган мөһер аркылы гына белергә була.

Беренче рәсемле открыткалар ак һәм кара төсләрдән генә торган. Соңрак төсле, хромолитографик ысул белән чыга башлый. Мондый ысул белән эшләгәндә оста форманы таштан ясаган. Оригиналда ничә төс катнашса, ташлар да шулкадәр эшләнгән. Бу ысул тулысынча камилләшеп җитмәгәнлектән, кайчак төсләр туры килеп бетми, яисә калып шуып китү очраклары була.

XIX гасырның 90 елларында фототипия ысулы белән бастыру үсеш ала: башта — акка-кара, соңрак — төсле. Чөнки фототипия ысулы белән басканда рәсемнәр башка ысулларга караганда сыйфатлырак һәм төгәлрәк төшерелә. Ләкин бу ысул белән рәсемнәр акрын һәм аз санда басыла. Бер калып белән меңгә якын гына открытка нәшер ителә. Шундый тираждан соң аны яңасы белән алыштырырга туры килә. Моннан тыш, фототипия өчен югары сыйфатлы кәгазь һәм буяу сорала.

Шуңа да карамастан, фототипия күп еллар дәвамында рәсемле открыткалар бастыруның төп ысулы булып хезмәт итә. Гадәттә бер кәгазь табагында берничә төрле күренештәге открыткалар басыла һәм соңыннан алар стандарт открыткалар үлчәмендә киселәләр.



*Аркадия бакчасы.*

Казан күренешен сурәтләгән открыткалар хромолитография һәм фототипия ысуллары белән басылган. Фототипия ысулы аеруча киң тарала. Открыткаларның күпчелек өлеше Казан нәширләре заказы буенча Мәскәүдә һәм Стокһольмдә басыла.

Мәскәү фирмаларында басмаларның сыйфаты начар түгел: рәсемнәр төгәл, буяуларның төсе ачык. Стокһольмдә рәсемнәр төгәл килеп чыкса да, төсләр үзгәртеп бирелә.

Бу фирмалардан тыш төрле шәһәрләрнең күренешләрен сурәтләүче открыткалар нәшер итүдә Казан һәм башка калаларның осталары, аерым сәүдәгәрләр, китап сатучылар да шөгыльләнгән.

Казанда открыткалар нәшер итүчеләрдән аеруча В. И. Бреев, В. М. Ключников, Опарин, соңрак Опарина, Ю. Г. Ивановалар зур эш күрсәтә. Н. О.



*Кабан күле күренеше.*

Прокофьев открыткалары аеруча киң тарала. «Баронин, Фетисов һәм К°» ширкәте дә күпсанлы открытка серияләре чыгара. Саратов шәһәрендә китап сату белән шөгыльләнүче М. В. Клюкин шулай ук Казан күренешләрен гәүдәләндергән берничә открытка бастырып тарата. Казан күренешләрен чагылдырган открыткаларны В. П. Санников, Харитоновлар да чыгарган.

Чит шәһәрләрдәге нәширләрдән Түбән Новгородтан М. П. Дмитриевны атап узарга кирәк. Ул Идел киңлекләренең, аның кушылдыкларының матурлыгын

тасвирлаучы. Идел буенда яшәүче халыкларның авыр хезмәтен чагылдыручы меңгә якын открытка бастырып чыгарган. Алар арасында Казан шәһәре һәм аның тирә-ягының матур табигатен гәүдәләндергән открыткалар да бар.

Самара нәшире А. П. Васильевның открыткалары арасында да Казан күренешләрен чагылдырганнарны күрергә мөмкин.

Революция алдыннан открыткалар чыгаручы иң зур нәшриятләрдән «А. С. Суворин һәм К° контрагентлыгы» санала. Суворин — «Новое время» («Яңа вакыт») газите хуҗасы була. Ул танышлык аша Русиянең барлык станция һәм пристаньнарында бары үзе генә газит һәм китаплар сату хокукы ала. Аңа «Матбугат контрагентлыгының» элеккеге арендачысыннан открыткалар эше дә күчә. Суворинның «контрагентлыгы» Русиянең барлык шәһәрләренең диярлек (шулар арасында кечкенә генә тимер юл станцияләрен дә санап) күренешләрен чагылдырган открыткалар бастырып чыгара. Шул исәптән, берничә дистә открытка Казанга багышлана. Казан күренешле открыткалар Санкт-Петербургта «Р. Голике һәм А. Вильберг» һәм Дресслер, Мәскәүдә Отто Ренар һәм К. Фишер, Парижда Лапин ширкәтләре тарафыннан да чыгарыла.

Открыткалар нәшер итүдә урындагы һәм чит шәһәрләрдәге нәширләр Казанның күп кенә танылган фотографларының фоторәсемнәреннән файдаланганнар. Алар арасында М. Якобсон, Фельзер, Локке, В. Г. Федоров, М. А. Засыпкина, С. И. Иванов һәм башкаларның (кайбер открыткаларда авторлар күрсәтелмәгән) фоторәсемнәре бар.

Открыткаларда Казан күренешләрен чагылдырган меңнән артык сюжет билгеле. Алар — төрле урамнарның, аерым биналарның рәсеме, шәһәр тирә-ягы күренешләре, Идел һәм Кама буе пейзажлары. Открыткаларның күпчелек өлеше шәһәрнең үзәк өлешен — хәзерге Ленин, Бауман, Маркс урамнарының, Ирек, Беренче Май исемендәге мәйданнарның элекке күренешләрен күз алдына бастыра.



*Идел буендагы татар авылы.*

Открыткаларда шәһәр тормышының кызыклы сәхифәләрен чамаларга мөмкин. Шулай ук алар инде юкка чыккан. Александр II һәм Державин һәйкәлләрен, Воскресенский һәм башка чиркәүләрнең күренешләрен сурәтли.

Күп кенә открыткалар Казан император университеты турында сөйли. Идел, Кама, Болак елгалары һәм Кабан күлен сурәтләгән кызыклы открытка серияләре дә бар. Нәрсәләр генә күрмисең ул открыткаларда! Пристаньнар, су коену урыннары, яр буйлары, йөк төяүчеләр, бурлаклар тормышын сурәтләгән рәсемнәр... Нәкъ менә шул иске открыткаларда элекке пароходларны, салларны тамаша кылырга мөмкин.

Шәһәрдәге тарихи истәлекле урыннардан бигрәк тә тимер юл вокзалы һәм шәһәр театры фотолары еш очрый. Открыткаларда шәһәрнең кайбер урамнары берничә төрле күренештә сурәтләнә. Открыткалар арасында бүгенге көнгә кадәр сакланмаган яки танымаслык булып үзгәргән кайбер биналарның үзенчәлекле рәсемнәре сурәтләнгән. Кышкы ат чабышларын, Казан өстеннән очкан беренче аэроплан рәсемнәрен бары тик открыткаларда гына күрергә була. Документаль рәвештә төшерелгән барлык рәсемнәр дә шәһәр тарихы һәм архитектурасы белән танышыр өчен бай чыганак.

Вакыт аяусыз! Күп тираж белән басылган кайбер открыткалар бер генә данә (коллекция җыючыларның альбомнарында гына) сакланып калган. Открытка — ул узган заманның кечкенә генә бер истәлеге, мөһим документы.

«Коллекционерлар — иң бәхетле кешеләр»,— дип Гете дөрес әйткән. Чөнки кичә нәрсә булганын белми торып, алдагы көнне нәрсә көткәнен чамалау кыен. Тарих ул — халык хәтере. «Хәтереңне югалтсаң — акылыңны югалтырсың»,— ди халык.




*Кургәзмә цирк һәм театр.*

Коллекцияләү өчен открытканың үз уңайлыклары бар; аларның күләме кечкенә, үлчәмнәре бер, саннары берничә меңнән артып китсә дә, саклавы җайлы. Открыткалар күп төрле сюжетларны гәүдәләндергәнлектән, һәркем үзе яраткан темага коллекция туплый ала. Ләкин барлык төр открыткаларны дәүләт китапханәләре һәм саклау урыннары гына җыя ала.




*Аккош күле.*

Туган якны өйрәнүче коллекционер буларак, минем егерме ел мавыккан өч яраткан темам бар: Идел һәм Кама буйлары, Әстерхан һәм Казан төбәкләре. Бүгенге көндә мин шул төбәкләрнең революциягә кадәрге үткәнен сурәтләгән бай открыткалар хәзинәсе хуҗасы. Бу хәзинәне җыю, өйрәнү минем өчен ял итү чарасы булудан тыш, тарих, география һәм башка тармаклар буенча зур мәгълүмат алу чыганагы да. Кызыксынучылар белән мин бу мәгълүматларымны уртаклашырга һәрвакыт әзер. Коллекциям өч бүлектән тора: «табигать һәм типлар», «тарих», «фән һәм мәдәният». Беренче бүлеккә документаль һәм репродукцияле открыткалар керә. Алар шул өлкәнең табигатен, аерым урыннары күренешен, шәһәр һәм авыл халкы яшәешен, гадәт-йолаларын, көнкүрешен һ. б. чагылдыра.

«Шәһәр күренешләре «дигән бүлек шәһәрнең, аның төрле урам-мәйданнарын, йортларының үзгәрешен, үсешен күз алдына китерә.

Өлкәләргә багышланган коллекцияләр дә шул ук система буенча төзелгән. Алар аерым төбәкләрнең табигатенә, икътисадына, тарихына һәм мәдәниятенә багышланганнар.

Төрле оешмаларда, мәктәпләрдә, китапханәләрдә, клубларда, кино-театрларда күргәзмәләр оештыру коллекция җыючының иҗади активлыгын күрсәтә. Шул рәвешле коллекцияләр белән күпләр таныша ала. Бу филокартияне пропагандалауның да җайлы ысулы. Ләкин мондый күргәзмәләрне оештыруда тиешле оешмалар атлыгып тормый. Егерме ел эчендә минем коллекцияләрем бары тик Бауман урамындагы китап кибетендә, «Татарстан» кинотеатры фойесында һәм элемтәчеләр клубында гына оештырылды. Мондый күргәзмәләр халык тарафыннан җылы кабул ителә. Ләкин аларны оештыру җиңел түгел: уңайлы биналар, кирәкле стендлар, әйбәт саклау мөмкинлеге һ. б. юк. Һич югы борынгы Казан күренешләрен сурәтләгән стена календаре бастырып чыгару да беркемнең башына килми.

Открыткалар коллекцияләү — җәмәгать эшенең бер төре. Безнең көннәрдә үзең өчен генә коллекция җыю, үз эчеңә бикләнү ярамый. Коллекционерга һәрвакыт башкалар белән аралашу, кешеләр белән һәм кешеләр файдасына эшләү хас. Соңгы еллар эчендә күп кенә нәшриятлар тарафыннан борынгы Петербург, Мәскәү, Түбән Новгород, Минск, Саратов һәм башка шәһәрләрнең күренешләрен сурәтләгән альбом-китаплар дөнья күрде. Без, татарлар гына, бу эштә артта калабыз, әле һаман үткәнгә игътибарыбыз җитеп бетми.

Һәрбер коллекционерның хезмәте тынгысыз эзләнүләр, тикшеренү эшләреннән гыйбарәт, ул укучыларга, эшче яшьләргә, студентларга, хезмәт ияләренә әхлак һәм матурлык тәрбиясе бирүдә зур урын тота. Менә шуның өчен дә минем «Казан турында хикәят» дигән темага багышланган лекциямне озак еллар инде яратып тыңлыйлар.

Бәхетемә, безнең Казанда да шушы файдалы һәм кызыклы эш белән мавыгучылар саны арта бара. Алар арасында инде танылып өлгергән А. Григорьев, П. Норден, Г. Фролов, И. Камал һ. б. филокартистларның исемнәрен күрергә мөмкин.

Минем уйлавымча, аларның һәркайсы үзенең шушы өлкәдә туплаган бай тәҗрибәсе хакында кызыклы итеп сөйли, открыткаларын күрсәтә ала.

**Хаҗи Абдулла ДУБИН.**
(Лилия Гатауллина тәрҗемәсе)

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XII КОРЫЛТАЕ

3 июньдә Казанның Актерлар йортында Татарстан язучыларының XII корылтае булып узды. Аны, кыскача кереш сүз белән, әдәбиятыбызның аксакалы, Татарстанның халык язучысы Гомәр ага Бәширов ачты.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең ике корылтае арасындагы эшчәнлеге турында идарә рәисе Ринат Мөхәммәдиев хисап тотты.

Язучылар корылтаенда Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев чыгыш ясады. Иң элек ул Татарстандагы бүгенге сәяси һәм икътисадый хәлләрне яктыртты. Аннары Президент Татарстан белән Россия арасында төзелгән Шартнамәгә һәм Б. Н. Ельцинның Татарстанга визиты йомгакларына кагылышлы фикерләре белән уртаклашты. М. Шәймиев үз чыгышында татар телен дәүләт теле буларак тормышка ашыру, татар мәктәпләре һәм балалар учреждениеләре санын арттыру, газета-журналлар нәшер итү, китап бастыру, язучыларның матди хәлләрен җиңеләйтү, аларга иҗат мөмкинлекләре тудыру мәсьәләләренә дә киң тукталды.

Корылтайда катнашучылар Татарстан мөхтәсибияте сәркатибе Харис хәзрәт Салихҗан вәгазен тыңладылар.

Аннары ревизия комиссиясе отчеты, төрле жанрлар буенча докладлар тыңланды. Фикер алышуларда Р. Фәйзуллин, күренекле рус язучысы С. Михалков (Мәскәү), Ә. Баян, Ә. Еники, Ф. Баттал, Г. Ахунов, С. Баттал, Т. Галиуллин, Р. Хисмәтуллин, М. Нәзиров (Уфа), Р. Вәлиуллин, З. Зәйнуллин, М. Маликова, Т. Пулатов (Мәскәү), Х. Әшрафҗанов катнашты.

Корылтайда Татарстан Язучылар берлегенең төзелешен үзгәртеп кору хакындагы декларация кабул ителгәч, ачык тавыш бирү юлы белән яңа идарә әгъзаларын сайлау булды. Идарәгә 27 язучы кертелде. Аннары идарәнең беренче утырышы уздырылып, язучы Ринат Мөхәммәдиев — аның рәисе, Зиннур Мансуров — иҗат эшләре буенча, Мансур Шиһапов — оештыру эшләре буенча урынбасарлар итеп сайландылар.

## ТАТАРСТАН ЮГАРЫ СОВЕТЫ СЕССИЯСЕНДӘ

6—8 июнь көннәрендә Казанда Татарстан Республикасы уникенче чакырылыш Югары Советының чираттан тыш XX сессиясе булып узды.

Сессиянең беренче көнендә Татарстан Республикасы икътисадын тотрыкландыру буенча беренче чираттагы чаралар планы турында ТР Премьер-министры М. Сабиров чыгыш ясады. Халыкны социаль яклауга кагылышлы закон проектлары блогы буенча доклад белән Премьер-министр урынбасары Р. Моратов чыкты. Алар депутатларның күпсанлы сорауларына җаваплар бирделәр.

Аннары бу мәсьәләләрне тикшерү даими комиссияләрдә дәвам иттерелде.

Сессиядә «Татарстан Республикасында катлаулы социаль-икътисадый хәл уңаеннан Татарстан Республикасы Президентына өстәмә вәкаләтләр бирү турында»гы мәсьәлә дә каралды һәм тулаем кабул ителде.

Сессия эшендә Татарстан Президенты М. Шәймиев катнашты. Сессия утырышларын Югары Совет Рәисе Ф. Мөхәммәтшин алып барды.

## ТӨРКИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Төркия Президенты Сөләйман Дәмирәл 16 июньдә Әнкарада Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге делегацияне кабул итте.

Очрашу барышында Казанда Төркиянең генераль консуллыгын ачу мөмкинлеге турында да сүз барды.

## КАЗАН КРЕМЛЕНДӘ ОЧРАШУЛАР

Татарстан Президенты М. Шәймиев 10 июньдә Кремльдә Франциянең Дәүләт киңәшчесе, Европаның реконструкция һәм үсеш банкына нигез салучы — аның президенты Ж. Аттали, компанияләр группасы президенты С. Варсано, фирма директоры П. Серна, «Маримпекс» фирмасы директоры В. Шмидт әфәнделәрне кабул итте.

Кунаклар республикабызның икътисадый, финанс мөмкинлекләре белән кызыксындылар. Франция һәм Татарстан арасында сәүдә-экономик мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен сөйләшүләрне дәвам итәргә әзер торуларын белдерделәр.

* * *

Татарстан вице-президенты В. Лихачев 10 июньдә Финляндиянең иң эре сәүдә фирмаларыннан саналган «Стокман» фирмасы вәкилләрен кабул итте. Сөйләшүләрдә әлеге фирманың халыкара эшчәнлеге мәсьәләләре буенча директоры И. Арвола һәм директорның коммерция мәсьәләләре буенча урынбасары Д. Бәдретдин әфәнделәр катнашты.

Әңгәмә вакытында Татарстан белән Финляндия арасында сәүдә-экономик, фән-

ни-мәдәни элемтәләрне тагын да ныгыту, Татарстанда мәдәни үзәк ачу, ә алга таба Финляндиянең консуллыгын булдыру турында сүз барды.

## СОГУД ГАРӘБСТАНЫНА ВИЗИТ

14—24 майда Согуд Гарәбстаны Короле Фәхд ибн Абдель Азиз Галиҗәнапләре һәм ил Хөкүмәте чакыруы буенча Татарстан Республикасы Президенты аппараты җитәкчесе, ТР халык депутаты Х. Низамов һәм Президент аппаратының җаваплы хезмәткәре Т. Акулов Гарәбстанда булып кайттылар.

Очрашуда Согуд Гарәбстаны Парламенты делегациясенең шушы ел азагында Татарстанга визиты, шулай ук ике ил арасында үзара файдалы икътисадый, сәүдә һәм мәдәни элемтәләрне җайга салу турында килешүгә ирешелде.

## ТАТАРСТАН ВӘКИЛЛЕГЕ

13 июньдә җөмһүриятебез Президенты М. Шәймиев Татарстанның Россиядәге Вәкаләтле вәкиллеге турындагы Указга кул куйды. Шул ук көнне имза салынган икенче бер Указ белән Россиянең Федерация эшләре буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары булып эшләгән Наил Гали улы Әминев Татарстанның Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиле итеп билгеләнде.

## ЭЛЕМТӘЛӘР НЫГЫЙ

13 майда Казан Кремлендә тантаналы шартларда Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев һәм Чуваш Республикасы Президенты Н. Федоров ике республика арасында Дуслык һәм хезмәттәшлек турындагы Килешүгә кул куйдылар.

25 майда Кремльдә Омск өлкәсе, 17 июньдә исә Коми Республикасы белән шундый ук Килешүләргә кул кую тантаналары булды.

Бу Килешүләрнең әлеге өлкә-республикаларда яшәүче дистә меңнәрчә милләттәшләребезгә мәдәни хезмәт күрсәтүдә, татар мәктәпләре ачуда, татар китаплары белән тәэмин итүдә уңай йогынтысы булыр, дигән ышаныч бар.

## КИЕВТА — ТАТАР КОНГРЕССЫ

11—12 июнь көннәрендә Киевта Украина татарларының беренче корылтае булып узды. Аны оештыруда Киев, Харьков, Симферополь, Севастополь, Львов шәһәрләрендә төрле исемнәрдә барлыкка килгән татар милли-мәдәни оешмалары җитәкчеләре һәм вәкаләтле вәкилләре катнашты.

Казаннан исә бирегә Бөтентатар конгрессы башкарма комитеты рәисе, университетның тарих факультеты деканы, академик И. Таһиров, шул ук югары уку йортының татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты деканы, профессор, язучы Т. Галиуллин, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, академик М. Зәкиев килгән иде.

## «СӘЛАМ»

«Идел — Урал төрекләре культура вә ярдәмләшмә дәрнәге», ягъни Төркиядәге милләттәшләребез җәмгыяте быел чыгара башлаган бюллетень әнә шулай дип атала. Ул кварталга бер мәртәбә басылачак. Аны җәмгыятьнең идарәсен тәшкил иткән Аттила Көнтөз (рәис), Гөлтән Ураллы (рәис урынбасары), Якуп Акчура (кәтиб), Илхан Байкал, Габдулла Йәнәр (әгъзалар) гамәлгә куйган. «Сәлам»нең беренче санында Г. Тукайның «Туган тел», «Бәйрәм бүген» шигырьләре, Бөтендөнья Татар лигасы рәисе Гали Акыш, профессор Надыйр Дәүләтнең котлаулары һ. б. мәкаләләр, хәбәрләр дөнья күргән.

## ТАТАР-ТӨРЕК ЛИЦЕЕ БӘЙРӘМЕ

5 июнь көнне Казанның К. Тинчурин исемендәге театр бинасында Эртугрул Гази исемендәге I нче татар-төрек лицее бәйрәме булды. Анда Татарстан халык мәгарифе министры В. Гайфуллин, аның милли мәктәпләр буенча урынбасары Г. Садриев, академик Ә. Кәримуллин, язучы Р. Батулла, шагыйрь Ә. Рәшит, профессор Г. Даутов, җәмәгать эшлеклеләре, укытучылар, ата-аналар чыгыш ясады.


## ЯКТАШЛАРНЫ ОЛЫЛАУ

Лениногорск шәһәре һәм районы хакимияте шушы районда туып-үскән һәм эшләгән якташлар белән очрашу уздырды. Казан, Чаллы, Әлмәт, Бөгелмә, Азнакай шәһәрләреннән һәм башка төбәкләрдән кайткан кунаклар Иске Шөгер сабантуенда булдылар, Лениногорскида күренекле язучы Шамил Бикчурин яшәгән йортка мемориаль такта куюда һәм Тимәш авылында шагыйрь, галим, педагог, җәмәгать эшлеклесе Габдрахман Утыз Имәни әл-Болгари каберенә мавзолей-төрбә ачу тантанасында катнаштылар.

## «ТАТАРСТАН ДУЛКЫНЫНДА»

4 июньдә, ниһаять, күптән көтелгән вакыйга булды — читтә яшәүче милләттәшләребезгә атап әзерләнгән «Татарстан дулкынында» дигән тапшыру эфир аша яңгырады. Аны Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты белән берлектә, Татарстан радиосының әдәби-драматик тапшырулар бүлеге хәзерләгән иде.

Бер сәгать тә ун минут барган әлеге тапшыру вакытында татарлар яшәгән бик күп төбәкләрдән кызыклы, мөһим мәгълүматлар бирелде, әдәбият-сәнгать әһелләре, татар халкы мәнфәгатьләрен кайгыртып йөрүче фидакарь затлар белән әңгәмәләр үткәрелде, җырлар яңгырады.



# ДӘВЕРЛӘР КАПКАСЫ

Яшь рәссам Равил Заһидулла тормышына беренче уңыш Г. Тукайның 100 еллыгына багышланган сәнгать күргәзмәсе көннәрендә килеп керде. Ул тәкъдим иткән унбишләп миниатюра, ягъни «Кырлай сериясе» шагыйрь иҗатына аһәңдәшлеге, аны барлыкка китергән мохитның тетрәткеч хакыйкате, халык алга сөргән традицияләрнең, гадәт-ырымнарның гүзәл тотнаклыгы һәм, ниһаять, рәссам пумаласының сихри кагылышыннан туган бөҗәксыман тапларның онытылмас яшел җанлылыгы белән күңелләрне биләде. Энҗе бөртегедәй саф, күләме буенча кечкенә, ләкин гаҗәп зәвыклы, зиннәтле итеп башкарылган рәсемнәр,— һәрберсе озак вакытлар буенча җентекләп, игътибар белән карауны таләп иттеләр. Тамашачы һәм тәнкыйтьче әсәрләрне сәерсенеп, үзе сизмәстән бирелеп һәм йотлыгып кабул итте. Киндер тукымаларга олылап иңдергән киң күкрәкле атлетлар, кешедән көлеп, масаеп басып торган «торataш» сыннар, колосслар хөкем сөргән бер чорда мондый самими, кешене кеше итеп, кабартмый һәм парчаламыйча, бозмый сурәтләгән вөҗданлы иҗат, чынлап та, гаҗәпләнү уятырлык иде. Инде бу елларда без үзебез дә шактый гына дорфалаштык, шәрекъ миниатюраларының нәзакәтен, Леонардо да Винчи, Рафаэль шедеврларының формат буенча бары тик китап кадәр генә булуын, ләкин үзләренә никадәр нәфислек, тойгылар байлыгы, камиллек туплаганын онытып бара идек. Шулай итеп, дистәләрчә исемнәр, алымнар, агымтрадицияләр һөкем сөргән катлаулы иҗат процессына Равил Заһидулла әсәрләре ничектер сискәндереп, «яңа сәнгать» чагылышы булып килеп керделәр. Сәнгать белгечләре аларны иҗади ачыш, дип бәһаләде. Мәскәү, Казан журналлары, басмаханәләре әсәрләрдән репродукцияләр басып чыгарырга ашыкты. Аксакаллар Равилга юл бирде: СССРның халык рәссаме Х. Якупов иҗаткярне үзенең остаханәсендә укырга чакырды; сәнгать патриархы Б. Урманче яшь остага рәссамнәр берлегенә керергә рекомендация бирде. Шулай итеп, рәссамның сәнгать рингындагы тормышының җәмәгатьчелек һәм тамашачылар тарафыннан кызыксынып күзәтелә башлаган икенче өлеше башланып китте. Милли ырым-ритуаллар, манзаралар, пейзажлар, колоритлы йөзләр-типажлар исәбенә үсеп, киңәеп киткән Тукай сериясе, авыл циклы һәм соңыннан, гомумән, табигатькә, тирә-юньгә, тормышның якты күренешләренә багышланган ирекле бер жанрга әйләнеп китте. «Июль ае», «Безнең әбиләр», «Авыл», «Печән чабу», «Атлар коендыру», «Таллар арасында» дигән әсәрләр, һичшиксез, өлгергән сәнгать җәүһәрләре тәсбихына әйләнде. Сериядәге көмеш-яшел, сөтсыман, фирәзә төсләрдән торган «хәтер көзгесе» гаммасы — декоратив палитра, якты төсләр балкышы, төрлелек чаралары («гөллелек») белән алышынды. Элек аерым-аерым урнашкан тәңкә-тәңкә таплар, импрессионистик нокталар бер-беренә керешеп, әреп, кыр-басулар, яшел алан, болын-тугайлардан гыйбарәт булган тормыш фактурасын хасил иттеләр; болар өстенә, рәссам чын профессиональ осталык белән күксел-зәңгәр томан гыйбарәләре өрде; ул һава агышы, катлаулы перспектива сыман авыр сәнгать мәсьәләләрен чишәргә керешә. Кечкенә формат тетрәп, хәрәкәтләнә башлаган кебек тоелды, шулай итеп, күләмнәргә чыгу ихтималы туды. «Детальләп, җентекләп эшләү» стилен саклаган хәлдә, рәссам тарих темасына багышланган әсәрләргә ургылды. Болгар, Казан манзаралары калкып чыкты... Сөлгеләр, чигүләр белән бизәлгән, ак киез эшләпә, чабаталар кигән йомры төзек гәүдәләр, бала-чага, карт-коры, тәбәнәк көчле батырларның хәрәкәтләре тулы урман итәгенә иңдерелгән, самими, меңъелларча тәрәккый иткән тыныч, ямьле ыруг ырымы — «сабантуй» барлыкка килде. Аннан соң хыялы аны Казансуы янындагы иңкүлеккә — милли йөзләр, киемнәр, олаучылар һәм сәүдәгәрләр, гади халык тулы, тир түгеп эшләп булдырылган, бәрәкәтле мал өелгән Ташаяк базары ыгы-зыгысына алып кереп китте. Мондагы агач һәм таш гыймарәтләр (пулатлар) матурлыгы, мәчетләр өстендә тибрәлгән алтын айлар, урамнардан бөркелеп торган зәвыклы җанлылык, энергия, эш һәм бәйрәм күңеллелеге катнаш тормыш атмосферасы күңелләргә тереклек суы кебек тәэсир итә (XVI гасыр Казаны).

Худяковларны, Мәрҗаниләрне укыган Равил Казанның илаһи матурлыгын үзенчә, рус миниаютраларына, татар халкының тарихи риваятьләренә таянып, фил сөягеннән яки зур гәрәбә кисәгеннән уеп эшләгән затлы әйбер, үтә күренмәле тылсым — «тарих төпләренә киткән әкияти «Китсәк» (ул «китеш» сүзеннән килеп чыккан) итеп сурәтләде. Рәссамның «Казаннамәсенә» кергән «Кышкы базар»,

«Шәһәр интерьеры» әсәрләрендә һәм күпсанлы пейзажларда рәссам үзе татыган халыкчан тугры гүзәллек, хәрби һәм көнкүреш киемнәренең гүзәллеге, таш һәм агач архитектураның йөз сыны, алардагы бизәкләр — антропология, йөзләр үзенчәлеге — болар бары да зур осталык белән нигндидер сөю тулы тылсымлы табигать, тирә-юнь фонына сеңдерелде. Халыкчан фәлсәфәгә корылган «Ялгыз агач», күп фигуралы «Күчеп утыру» эпослары һәм, ниһаять, «Төньяк илләргә күченү» дигән тарихи пейзаж әсәрләре калкып чыкты.

...Әсәрнең алгы планында — убылып, балчыгы-комы актарылып беткән калкулыктагы мәңге каракучкыл яшел, төз гәүдәсе биек-биек мәһабәт чыршылар, яфраклары коелып беткән меңъяшәр шомлы кара өрәңгеләр, нарат, юкәләр, ягъни, эченә тулы бер халык кереп югалырлык төпсез һәм караңгы, бетмәс-төкәнмәс агачлар массивы — «кара урман». Уртада — шушы томанлы язгы иртәдә, тәгәрмәч эзенә җыелган, узган яңгыр шарлавыгы буйлап сузылган төньякларга, яңа сәүдә бәйләнешләренә алып баручы юл; шул юлларны ярып барган олау-олау, арба-арба сәүдәгәрләр кәрваны... Алда — атларга атланып, камзол-бүрекләр кигән, ук-җәяләр белән коралланган җайдак-эзтабарлар. Аларның җиңел гәүдә пропорциясе урманны очсыз-кырыйсыз караңгы тирәлек, танылмаган байлык итеп күзалларга ярдәм итә. Җиргә төшәлгән яшел хәтфә үлән, андагы утрау-утрау сары чәчәкләр, җир өстеннән күтәрелгән зәңгәр томан, саф һава, иртәнге салкынлык һәм төз гәүдәле агачлар — болар барысы да шишкиннарча оста, чын реализм калыпларында сурәтләнгәннәр.

Бу әсәрдә дымлы томан эчләреннән еракларга чакырып торган юл буйлап, әле мәгълүм булмаган җирләргә курыкмыйча чыгып киткән ата-бабаларыбыз — Америка «пионерлары» кебек — торгынлыкка сәйях, тәвәккәл кешеләр итеп тасвирланган. Мәһабәт урман эченә осталарга иңдерелгән мавыктыргыч сәүдә кәрваны,— хәрәкәттә-бәрәкәт фәлсәфәсен яшәү девизы итеп кабул кылган борынгы ыругдашларыбыз,— чыннан да, яңа яшәү ысулларын, тәрәккый итүнең яңа төрләрен, формаларын тудыручы прогрессив кешеләр итеп күз алдына килеп баса. Шул рәвешле тарихның чын бөек романтикасы, күләмлелеге ачыла.

Инде хәзер төп сорау: бер-бер артлы туып, сәнгать сөючеләрнең күңелен һаман үзе белән әллә кайларга — чал тарих, табигать, гореф-гадәтләрнең архаик төбенә алып кереп киткән Р. Заһидулла әсәрләренең тәэсир итү сере нәрсәдә соң? Равил эшләрендә нинди яшерен хикмәт, могҗиза ята? Ни өчен алар чүлдә кызган комнар арасында җемелдәп торган кое кебек күңел рәхәтлеге, иркенлек тудыралар, саф өметләр уяталар?

Медицинада ретрогипноз — «борынгылык белән дәвалау» дигән ысул бар. Минемчә, Равил Заһидулла иҗатының асылында шушы күренеш ята. Рәссам сынландырып биргән натураль-гади тормыш, табигатьлеккә, чиста самими хисләр, гореф-гадәтләр, әхлак тирәгенә, яшәү органикаеына, һәм чын тарихка, борынгылыкка, гадел хакыйкатькә кайту — ялган сәясәттән, ясалмалылыктан, урбанистик тормыш калыпларыннан, ул тудырган зәгыйфьлекләрдән, чирләрдән арыну — дәвалану-савыгу дигән сүз. Борынгылыкка кайту! Равил өчен борынгылык — Болгар чоры гына да, Казан патшалыгы дәвере генә дә, 18—19 гасырлар да түгел. Нинндидер рухи чор, күңел чорыдыр ул. Кешенең әһлагы белән тирә-юнь табигатьнең илаһи тәңгәллек ноктасы. Аларның моңы тоташкан нокта... Болгар, Казан, Тукай, татар җыры, орнаменты — гали мизгелләр!

Сәнгатебездә бүгенге чор — фикер һәм форма стереотипларыннан, официаль-академик сәнгать калыпларыннан, тупас-примитив образлылыктан һәм меңъеллар буенча халык практикасында үзен аклаган, кыйммәтен җуймаган принципларның халкын, яңарып чыгу чоры...

Менә шушы чынлык һәм гаделлек атмосферасына, ата-бабаңа, анаңа, Ватаныңа сине үстергән хәләл табигатькә, шагыйрьнең дәртле авазына чын сөю сүзләрен әйтү — ант эчү һәм табыну ул Равил Заһидулла иҗаты. «Динамизм», «монументальлек», «гомумиләштерү» дигән сүзләргә капма-каршы яңгыраган, узган елларда иҗат олавыннан ялгыш төшеп калган, халык әхлагында кайнаган «сагыну», «олылау», «кадерләп карау» дигән мәгънәле төшенчәләрне — җил исү, үлән тибрәнү, яфрак яру, бөре чыгару кебек тыйнак гүзәл хиссияләр аша ассоциацияләр, торгызып бирү...

Розалина ШАҺИЕВА,
сәнгать белгече.

**Тышлыкның беренче битендәге фотосурәт «Туран» фонды коллекциясеннән алынды.**

**Тышлыкның беренче битендә:** Равил Заһидулланың «Төньяк илләргә күченү» картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Әнәс Галиев.

М. КОЗЛОВСКИЙ фотосурәте.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Җәмит Рәхимов. Батырша. Тарихи роман — Казан: Татар. кит. нәшр., 1992, 479 б. Тиражы — 25 000 данә.

Батырша исеме күп еллар буена халык йөрәгендә яшәде, әмма моңарчы аның турында татар әдәбиятында, язма әсәрләр юк иде. Хәер, XVIII гасыр урталарында татар һәм башкорт халкын колонизаторларга каршы көрәшкә күтәргән бу каһарманның исемен моңа кадәр телгә алырга да ярамады. Җәмит Рәхимов романында Батырша образы халыкны иреккә, азатлыкка канатландыручы мәшһүр шәхес булып күз алдына килеп баса. Әсәр үзенең фактик материалга бай булуы, художество эшләнеше белән дә кызыклы һәм мавыктыргыч.


Гакыйл Сәгыйров. Кабатланмас моң. Шигырьләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1994, 207 бит. Тиражы — 5000 данә.

Самара өлкәсенең Кошка районындагы Иске Фәйзулла авылында яшәп иҗат итүче шагыйрь һәм рәссам Гакыйл Сәгыйров катлаулы тормыш юлы узган шәхес. Тормыш аны тешенә каләм кыстырып шигырьләр язу, рәсем ясау язмышына дучар иткән. Аның шигырьләре гаҗәеп дәрәҗәдә матур, ихлас тормышчан. Ул шигырьләрдә яшәү матурлыгын, тормышның ургылып, ташып торуын сизми мөмкин түгел. Алар оптимистик рух, һәркемгә якын, таныш моңнар белән сугарылган. Әлеге китапта урын алган рәсемнәр дә автор тарафыннан иҗат ителгәннәр. Китап киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.



Бәясе 1100 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог